# Аяз Гилязов

## ИЗБРАННЫЕ ПРОИЗВЕДЕНИЯ

в пяти томах

1 том

*Рассказы, повести*

КАЗАНЬ
ТАТАРСКОЕ КНИЖНОЕ ИЗДАТЕЛЬСТВО
2002

# Аяз Гыйләҗев

САЙЛАНМА ӘСӘРЛӘР

биш томда

1 том

*Хикәяләр, повестьлар*

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2002

УДК 820/89(470)
ББК 84(2Рос=Тат)-4
Г92

РЕДКОЛЛЕГИЯ:

*З.Р.Вәлиева, Р.М.Миңнуллин, Ф.Г.Галимуллин, М.Б.Галиев, Д.С.Шакиров, Х.Г.Әюпов, Р.Х.Корбанов*

Төзүчесе *Нәкыя Гыйләҗева*

**Гыйләҗев Аяз**

Г92 Сайланма әсәрләр. 5 томда. 1 том.— Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. — 431 б.

ISBN 5–298–01209–4

© Татарстан китап нәшрияты, 2002



# Балта явызлар кулында

Аяз Гыйләҗев — әдәбиятыбызның төрле тармакларында ат уйнаткан кеше. Ул күренекле прозаик, үзенчәлекле драматург, үткен каләмле публицист һәм очеркист, ниһаять, усал телле тәнкыйтьче. «Сайланма әсәрләр»*енә бары прозасы керде. Алар арасында хикәяләр, повестьлар, романнар бар. Иң зур урынны, әлбәттә, повестьлар алып тора. Темалары һәм проблемалары, күләмнәре һәм бөтенлекләре, сәнгатьчә эшләнешләре һәм тәэсир көче ягыннан ул әсәрләр бик тә төрле-төрле. Кайчан да булса фән өлкәсенә норматив тәнкыйть кысаларыннан, соцреализм догмаларыннан азат яшьләр килерләр һәм А.Гыйләҗев әсәрләрен бәйнә-бәйнә өйрәнерләр әле. Мин исә язучы иҗатының бер карауга күзгә ташланып торган кайбер тышкы сыйфатларын санау белән чикләнмәкче булам.

...А.Гыйләҗевнең «Качак» (1959), «Берәү» (1959), «Өч аршын җир» (1962) кебек беренче әсәрләре үк безнең шул чордагы тәнкыйтьне тирән шөбһәгә салды. Тормышыбызның матур якларын, замандашларыбызның үрнәк булырдай образларын сурәтлисе урында, бу соң, янәсе, тырышып-тырышып ямьсез күренешләр, әшәке геройлар эзләп азаплана түгелме?!. Дөрес, гел матур, уңай нәрсәләр турында язарга дигән закон юк. Ара-тирә тормышыбызда очрый торган аерым кимчелекләрне, ямьсез күренешләрне тәнкыйть утына тотардай сатира әсәрләре дә кирәк. Әмма ләкин яшь автор иске тормыш күренешләрен, капитализм калдыкларын социализм җимешләре дип расларга җыена түгелме соң?! Бу бит... бу бит... бүгенге гүзәл тормышыбызга яла ягарга маташу бит бу!

Тора-бара норматив тәнкыйть тарафдарларының шикшөбһәләре дөрескә чыкты. Аларны хафага салган тенденцияләр язучы иҗатында көчәя, ачыклана һәм тирә-

---

* Аяз Гыйләҗевнең 1994 елда Татарстан китап нәшриятында чыккан 4 томлык «Әсәрләр»е сүздә тотыла (*Ред.*).

нәя барды. «Өч аршын җир»дән соң «Урамнар артында яшел болын» (1970) романы, «Язгы кәрваннар» (1972) һәм «Күзгә-күз» (1975) повестьлары язылды. Коммунистик диктатура һәм шәхес, социализм һәм гаделлек кебек мәсьәләләр А.Гыйләҗев иҗатында төп урынны алды. Шул чордагы әдәбият иске тормыш күренеше, капитализм калдыгы дип раслап килгән гарип күренешләрнең (икейөзлелек, әхлаксызлык, имансызлык, эчкечелек, караклык һ.б., һ.б.) байтагын совет чынбарлыгы үзе тудырды, дип барды. Шуның белән партия алга сөргән лозунгларның дөреслеген, без табынган идеалларның изгелеген шик астына алды. Утны капитализм өстеннән социализм өстенә күчерде. Безнең әдәбиятка Аяз Гыйләҗев алып килгән иң зур яңалык шул иде.

А.Гыйләҗев — әдәбият мәйданына бай тормыш мәктәбе, озын һәм ураy юллар узып, төрмәләр, концлагерьлар «шулпасын эчеп» килгән кеше. Иҗатында системаны гаепләгән әсәрләрнең күп булуы табигый хәл. Сүз «Берәү», «Өч аршын җир», «Язгы кәрваннар», «Күзгә-күз», «Урамнар артында яшел болын», «Балта кем кулында?» кебек әсәрләр турында гына бармый. Игътибар белән укыганда, андый урыннарны «Качак» белән «Урталыкта»н да, «Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят» белән «Дүртәү»дән дә, хәтта «Җомга көн кич белән» повестеннан да табарга була.

Лозунглары матур тоелса да, ата коммунистларның эш-гамәлләре бүтәнчәрәк булып чыкты. Сүздә алар халык мәнфәгатьләрен кайгыртабыз, халык байлыгын арттырабыз, халыклар дуслыгын ныгытабыз, халык дошманнарын юк итәбез, дип лаф ордылар. Чынлыкта шуның нәкъ киресен эшләделәр: үз мәнфәгатьләрен кайгырттылар, халык байлыгын туздырдылар, туры сүзле, принципиаль партия членнарын — шәхси дошманнарын юк иттеләр. Тора-бара илдәге бөтен власть беренче секретарьлар, өлкә, шәһәр, район башлыклары, завод-фабрика, колхоз-совхоз җитәкчеләре кулына күчте. Алар аерым каста булып оештылар. Тирә-юньнәрен куштаннар, ялагай бәндәләр белән уратып алдылар. Кода-кодагыйлык, ришвәтчелек, мораль һәм җенси бозыклык, эчкечелек чәчәк атты. Үзләре генә шулай яшәсәләр бер хәл иде. Алар карьеристлар һәм әләкчеләр, торгашлар һәм һәртөрле җинаятьчеләр өчен уңай шартлар, җирлек, зәмин тудырдылар. Аннары бергәләшеп халык канын эчәргә тотындылар. Туры сүзле, намуслы кешеләргә яшәү нык кыенлашты, аларның бер тиенлек кадере калмады. Гади хезмәт кешесенә көн тәмам бетте. А.Гыйләҗев әсәрләрендә бу

хәлләр шактый тулы һәм дөрес сурәтләнә. Исхак белән Тәнзилә, Мирвәли белән Шәмсегаян, Арзу белән Хәбибрахман карт, Җәүдәт белән Мөзәкир, Нәҗип белән Наилә генә түгел, ахыр килеп Бибинур карчыкны да системаның корбаннары дип карап була. Гыйбадулла белән Мәүлихалар, Алик белән Моратлар, Гыйльми Салихы белән Тазюковлар, Сабит белән Степановлар, Иван Иванович белән Басыйр Бариевичлар яшәгәндә, алар өстенә кояш төшмәячәк — чөнки балта алар кулында. А.Гыйләҗев әсәрләрен укыганда туган төп фикер шундый.

Һәр яшь автор, дөньяны үзгәртеп корам дип, каләмгә тотына, диләр. Ихтимал, А.Гыйләҗев тә шулай башлагандыр. Әмма бер кеше генә дөньяны үзгәртә алмый, хәтта бик талантлы булса да. Ә менә әдәбиятны үзгәртүе бар. Сүз А.Гыйләҗев турында барганда, бусын шикләнми әйтергә була. Алда кайберләрен әйттем, тагын бер-икесен санап китим.

Аяз Гыйләҗев язучыны үз әсәренең иң төп һәм иң мөһим герое дип саный. Шуңа булса кирәк, әсәрдәге вакыйгалар агышына әледән-әле үзе кушылып китә. Геройларына кушылып, ул да уйлана, кайгыра, шатлана, хыяллана. Нәрсәнедер хуплый, нәрсәнедер кире кага. Еш кына без авторның үз тормышы, шәхси борчулары белән танышабыз. Шул нәрсә, ягъни авторның турыдан-туры вакыйгаларга катнашуы, язучы иҗатына үзенчәлекле яңа төсмер өсти: әсәрләренең пафосын билгели, кайнарлыгын, эмоциональ яңгырашын көчәйтә. А.Гыйләҗев әсәрләренең сәнгатьчә эшләнеше, ул иҗат иткән образларның тормышчанлыгы, ышандыру көче турында хөкем йөрткәндә, моны истән чыгарырга ярамый.

А.Гыйләҗев прозасы фикергә, фәлсәфи уйлануларга бай. Әсәрләрен укыганда, без уйлана һәм уйландыра белүче геройлардан тыш, дөньяның агышы, гомернең мәгънәсе турында, шулай ук дөньякүләм хәлләргә кагылышлы бик күп фәлсәфи фикерләргә юлыгабыз. Күп булулары өстенә, алар бик тә кызыклы һәм оригиналь булулары белән игътибарны җәлеп итәләр, тирән һәм яңа булулары белән гаҗәпкә калдыралар. Әйтергә теләгәнебез шул: А.Гыйләҗев тагын әле безнең әдәбиятның интеллектуаль дәрәҗәсен күтәрергә булышкан язучыларыбызның да берсе.

А.Гыйләҗев иҗатында Галимҗан һәм Хәбибрахман карт, Шәмсегаян һәм Бибинур карчык кебек саф күңелле, намуслы, тырыш, уңган хезмәт кешеләренә күп урын бирә. Шулай да аның аеруча яратып, үз итеп һәм җан җылысын салып тудырган геройлары — яшьләр. Алар арасындагы мәхәббәт хисләрен тасвирлаган төшләр аның әсәрләрендә-

ге иң матур урыннардан санала. «Язгы кәрваннар» повестенда Әдилә белән Ибраһим арасындагы самими саф хисләр бөтен әсәргә үзгә бер нур, яктылык сирпеп, аны эчтән җылытып, балкытып тора. Әдилә белән Ибраһим кебек геройлар, шундыйрак мәхәббәт сызыклары аның иҗатында байтак. Галимҗан белән Сөмәя («Үги ана яфраклары»), Җәүдәт белән Наза («Күзгә-күз»), Мөзәкир белән Зәйтүнә («Урамнар артында яшел болын»), Исхак белән Сания («Берәү»), Гәрәй белән Гәүһәрия («Зәй энҗеләре»), Арзу белән Ибраһим («Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят») турында да, алар йөрәгендә кабынган мәхәббәт утлары турында да шул ук сүзләрне кабатлап булыр иде. Билгеле булганча, А.Гыйләҗев әсәрләрендә без күбрәк тормышның ямьсез күренешләре, фаҗигале хәлләре, тупас бәндәләре белән очрашабыз. Әлеге яшьләр, алар арасындагы мәхәббәт хисләре булмаса, шактый авыр тәэсир калыр иде. Бәхеткә алар бар! Явызлык, гаделсезлек дөньясындагы якты нур булып, алар А.Гыйләҗев әсәрләренә нур өстәп, укучылар күңелендә өмет чаткысы кабызып, тормышка ышаныч уятып торалар.

*Фарваз Миңнуллин, 1993*

## *Чи ана яфраклары*

### 1

Бер-берсенә сырышып утырган тәбәнәк агач келәтләр арасыннан ургылып чыккан дуамал җил такырда коенты бодайларны чүпләп йөргән эре, ак казларның канатларын каера, аларга тыныч кына ашарга ирек бирми, йолыккалый, туктаусыз бимазалап тора. Келәтләр авылдан шактый еракта, атау сыман калкулыкта, нәкъ жил күзендә тезелешкәннәр. Казлар, очып китәргә җыенгандай, берара җилгә буйсынып ияреп баралар да кинәт туктыйлар, ка-ка дип кычкырып, ялгыз түгеллекләренә өерелеп куаналар да, сүз берләшеп, тагын келәт алдындагы бодайлы машинага таба тартылалар.

Каравылчы Мифтахетдин, тол дүдәк булганга, төнлә генә түгел, көндез дә келәтләр янында урала. Ул, озын кулларын җәеп, казларны куа башлый, учларын бер-берсенә сугып шапылдата, яргаланган юка тиреле кызгылт иреннәрен бөрештереп сызгыра:

— Кө-өш! Көш, дим, каһәрләр! Фью-фью!

Мифтахетдиннең буйлы-буйлы көрән чалбарының утыра торган җиренә тегәрҗеп белән эре-эре атлатып дәү кызыл ямау салганнар, ул стоп-сигнал кебек янып әллә кайдан келпеп тора. Ямауны күреп, шофер Галимҗан җыр-җыр көлә.

Казлар бер тамчы да курыкмыйлар, алар кемне кемнән аералар, бүрекле ата каз егетләрчә гаярь басып, Мифтахетдингә каршы ук китә һәм озын, юан чыбыркы муенын сузып яман ысылдый. Озак еллар каравылда торып мылтык асып йөрергә өйрәнгән Мифтахетдин коралсыз калганда тач куркакка әйләнә, ул, вак-вак адымнар белән йөгереп, кабина кырына килеп ышыклана, анда да шүрләп икенче якка ук чыга. Галимҗан көлүен оста яшереп авызын учы белән каплый: өйләнмәгән егеткә тол төнге каравылчы белән ызгышмау яхшырак...

Тезенә төшеп торган озын әлинүр күлмәгенең итәгенә вак-вак шадралар чуарлаган киң битен сөртә-сөртә

келәт ишегеннән йөкче Хәнәфи килеп чыкты. Амбарчы белән берне көйрәтеп, ул кинәнеп кенә тәмәке тарта башлады. Мифтахетдин дә аларга барып кушылды, сүз китте. Ул арада Галимҗан, түземсезләнеп, машинасын кычкыртты. Кычкыртуы булды, Хәнәфи, тәмәке төпчеген җиргә бәреп, тиз-тиз кабинага кереп утырды:

— Дөрес итәсең, бүген ашыгырга кирәк. Үрләт әйдә! — диде.

Мифтахетдин чалшайган үкчәле туфлие белән Хәнәфинең төтенле төпчегенә баса-баса кычкырып җибәрде:

— Штраф түләтермен! Бу җилдә...

Машина куанып гөрли башлауга, казлар җыйнаулашып алгарак чыктылар. Әллә көчле җил, әллә көзге туклык шаукымы аларның онытылып беткән кыргый, ирекле чакларын искә төшерде, иң элек шәбәеп ата каз аваз салды, ана каз куштанланып аның тирәсендә әйләнгәләде, бәбкә икәнлекләрен аермаслык бала казлар, яңа, шук тавышлар белән каңгылдашып, әткә-әнкәләренә кушылдылар. Кузгалып чаба башлаган машина кинәт тукталды, авыр, җәһәт эштән соң изрәп барган Хәнәфинең маңгае чак түбәгә бәрелмәде.

— Яп-яланаяк,— дип сүгенде ул, гадәтенчә яратып.— Нәрсә бар тагын, Галимҗан?

— Әнә, казлар...

Хәнәфи берәр юньсез бәбкә тапталгандыр дип исәпләп чыраен сытты һәм, кабина тәрәзәсеннән башын тыгып:

— Кырып бетерәсе затлар! — дип кычкырды.— Берәрсе чәнчелдеме?

— Юк,— диде егет, юаш кына.

— Ни булды соң?

— Очалар,— диде Галимҗан, казлардан җемелдәгән күзен ала алмыйча.

Казлар чыннан да дәү, ак канатларын җилпеп-җилпеп җил уңаена йөгереп бардылар да, келәтләр тезелешкән атаудан аерылып, үзән өстенә һавага күтәрелделәр: һава чуп-чуар булды!

— Моторыңны ник сүндердең?

— Тавышларын тыңлыйм. Ишетәсеңме, очканда гына шулай каңгылдашалар бит алар! Кыр казлары дип белерсең!

Хәнәфи йон баскан кыска муенын кашып алды:

— Бодай тыгынганнар да очалар! Ул Мифтахетдиннең муенын борасы бар! Себереп ал, дим, иренә!.. Казлар симергән, түлләре мул, шаярасылары килә.

— Симезлектән очмый алар, Хәнәфи абый,— диде егет, сокланып.— Ерак-ерак бабаларының кыр казлары, ирекле кошлар икәнен оныта алмыйлар! Каннарында бәйсезлек-

не, күк биеклеген тою уяна! Җилләр белән көч сынашалар алар!

Хәнәфи оеп утырган җылы урыныннан ялт кына калкынды, җиту сакал-мыекларын кул аркасы белән ышкып алды.

— Нәрсә, нәрсә диден әле син?

Галимҗан йөкчесенең ни әйтергә теләвен бик яхшы аңлады, дөнья, табигать, яшәү кануннары хакында сүз чыкканда алар еш кына эләгешәләр иде, шуңа күрә Хәнәфинең соравын уенга алды:

— Әйттем дә оныттым, Хәнәфи абый!

Бүген Хәнәфи белән тәмсезләнәсе килми иде аның... Теләсә ни уйласын!

Казлар үзән өсләп очып үттеләр дә аръякка, әрәмә кырына ук барып кундылар. Галимҗан җиңел сулап куйды: шактый ара үтте казлар! Кузгалдылар. Такырны артта калдырып, үзәннән бара башлагач, машина тагын шып туктады. Рәхәт ойый башлаган Хәнәфи, йокы тиз эленгән күзләрен көч-хәл белән әйләндереп, тагын сүгенде:

— Яп-яланаяк, нишлисең син? Ятьрәк ташып бетерик тә якты күздә өйгә ычкыныйк әле бүген.

Шофер ияге белән уңга ымлады. Тегермән ягыннан килгән тар сукмакта кабалана-кабалана берәү бу якка таба атлый иде.

— Рәисме? — дип сорады нигәдер пышылдап Хәнәфи.

— Үзе.

Хуҗалар белән очрашудан һәрчак ниндидер хәвеф көткән йөкче ипи калагы төсле эре, саргылт тешләрен күрсәтеп, ачуланырга тотынды:

— Ни шайтаныма кирәкте әле ул сиңа? Шыпан-шыпан гына ташып бетерик тә сызыйк инде. Үз юлыбыз, үз эшебез.

— Туктарга кушып кул изәде.

Колхоз былтыр гына «Москвич» машинасы сатып алган иде. Гадәттә бер дә машинасыннан төшми торган председатель Шәйхулла, урак өсте җиткәч, әллә нишләде. «Москвич»ын калдырып җәяү генә чыгып китә дә юл уңаенда туры килгән машиналардан файдалануны артыграк күрә иде. Эреләнми, атка да утырып китә! Шәйхулланың бу гадәтен белеп өлгергән Хәнәфи, малай-шалай сыман тузанлы әрҗәдә аунап барырга туры киләсен уйлап, Галимҗанны әрләргә тотынды.

— Күрмәмешкә салышып ычкынасы да бит, үз акылыңны биреп булмый. Тинтәк!

— Галимҗан,— диде Шәйхулла, исәнлек-саулык алышканнан соң,— сезнең янга ашыга идем. Семенаны кичкә ташып бетерәсезме?

Егет тын гына һаман казларны күзәтә иде, аерылмады, борылмыйча гына баш какты.

— Бик әйбәт,— диде шуны гына көтеп торган Шәйхулла.— Алайса менә шул, бодай төяп төнгә Зәйгә чыгасыз. Удар бишкөнлек игълан иттеләр!

— Ярар,— дип, Галимҗан шунда ук ризалыгын бирде.

— Эшне тизрәк очлыйк дисәң, менә Хәнәфи абыйны да ияртерсең.

Галимҗан, сүзне беткәнгә санап, кулын тормозга сузганда, Хәнәфи аның уң беләгеннән эләктереп алды:

— Бәләкәй генә сабыр ит, энем... Миңа да барырга кушуың булдымы, Шәйхулла? Удар бишкөнлек игълан итүләре калхуз өчен үтә дә шәп анысы! Бодайны алып барырга кирәк, анысы хак. Хәтта ки, бик кирәкле эш! Тик үз хәлемне әйтәм: Зәйгә чыгып китә алмыйм!

Рәиснең йөзе кырысланды:

— Нигә?

— Соң, Шәйхулла, уракка чыкканнан бирле гел машинада! Басу белән келәт арасыннан кайтып кергән юк! Бүген симәнәләрне салып бетергәч, әзрәк әл-хәл алып, мунча чабынып, кырынып, берәз адәм сурәтенә керерменме эллә дигән идем. Ипидер менә, катын янына ятырга оят!

Шәйхулла Галимҗанның кардай ак күлмәгенә төртеп күрсәтте:

— Күзең бар ич, күр! Синең белән бергә йөри! Әле иртәрәк тора, соңрак кайта. Машина арасында урала! Ә үзе, күкәйдән бүген яралып чыккан чеби кебек, чеп-чиста!

Хәнәфинең ансат кына бирешергә исәбе юк иде:

— Егет кеше лә ул! Ак күлмәгенең дә бер-бер хикмәте бардыр, Зәйгә барам дип кимәгәндер. Атлыгып торалар ди берәүләр... Бишкөнлекләр әнә-әү күпме булды инде безнең гомердә! Аннары, Галимҗанга аңа нәрсә? Мокыт бит ул, җиде камыт кидерсәләр дә тарта торган нәмәрсәкәй! Җене өзелсә дә, теле аркылы килсә дә дәшмәс ул, тартыр!

Галимҗанның сабыры бетте, ул, шап иттереп, машина ишеген япты, газ бирде. Кузгалдылар.

— Кая шулхәтле куасың?

— Үзең тизрәк бул дидең ич, Хәнәфи абый.

— Бая әйткән идем шул... Хәзер кусаң ни дә, кумасаң ни! Ике чабата бер кием!.. Калхуздан, колхоз рәисеннән игелек көтсәң, икенче көнне үк тәпи сузарсың.

Хәнәфи, тәмәке кабызып, таракан кырырлык зәһәр төтенен йота-йота, үзе белән үзе сөйләшеп бара иде. Ул шоферга чынлап торып ачуланган иде, тик кайсы яктан чеметергә икән дип җай эзли иде.

— Казлар нигә оча диден әле син?

— Ирекне сөеп, бәйсезлекне тоеп, дигән идем.

— Шул шул менә! Казлар булып алар да ирекне яраталар, ара-тирә булса да күккә менәләр, телсез мәхлуклар! Ә синең кебек сары бәбкәләр авыз ачарга да куркып утыралар! Шәйхулла күренүгә тормозларыгыз бушый, тотмый башлый! Егетлек юк синдә, энекәш!

Галимҗан бүген Хәнәфи белән ачуланышмаска, сүзгә кермәскә тырыша иде, бу юлы да мөмкин кадәр сабыр булырга тырышып җавап бирде:

— Син өндәгән нәрсә, Хәнәфи абый, егетлек түгел. Кирелек аның чын исеме. Дөрес әйтәсең, анысы миндә юк. Мәгънәсезгә тәртәгә тибүне җенем сөйми!

— Син бер булса да тибеп күрсәт! Нигә без һаман-һаман үшән ат сыман тәртә арасында йөрергә тиеш? Үз хакыңны хаклап сүз әйтерлек чама юкмыни синдә?!

— Ә егетлеккә килгәндә,— дип дәвам итте Галимҗан,— аны тыр-пыр итеп күрсәтеп йөреп булмый.

— Ә син аны күрсәт, күрсәт! — дип бәйләнде Хәнәфи.

— Кешеләр дә кайвакытта казлар сыман биеккә күтәрелә, Хәнәфи абый.

— Күрсәт син аны миңа, күрсәт!.. Шалиш, калхузчының канат әллә кайчаннан киселгән. Эх, йомран баласы! Курай чыжтырдаса да, өненә кереп сеңә торган нәрсә!

Егетнең сабырлыгы Хәнәфинең ачуын һаман дөрләтә иде. Ул алай итеп тә, болай итеп тә рәт чыкмагач, гади генә әйтеп куйды:

— Соң, апаң мунча ягып көтеп тора. Бәлеш салган булырга тиеш. Алган яртым мич артында балкып утыра булыр...

— Күптән шулай диләр аны! — Егет яңгыратып көлеп җибәрде.— Мунчаңа да барырсың, Хәнәфи абый, өлгерерсең! Зәйгә үзем генә чыгып китәрмен.

— Ә яртыны кем белән эчәрмен?

— Үзең генә!

— Бер башым аракы чөмереп утырырга син мине, теге кем, саран Гаптери дип белдеңме әллә? Мин бит шешәне синең белән икәү бөкләргә дип адарынып алган идем.

— Нигә минем белән? — Егет шулай дип сорады да оялды һәм, кызарынып, өстәп куйды.— Эчәсем килми.

— Кайчан исә бер башларга кирәк ич!

— Исәп башламаска.

— Тел сөйли ул! Безнең тормыш — ...кырмыш, үзеннән-үзе эчертә! Әле яшьлек тилелеге белән генә сайрыйсың! Барыбыз да бертөсле, бер калыпта сугылган.

— Бертөсле түгел!

— Әй!..

Йөкче, сүгенеп, йонлач кулын селкеде.

Юка тузан өертеп олы юлдан бардылар-бардылар да борылып басу өстенә керделәр. Тигез кыркылган бодай камылларын сытып, аркылы-торкылы машина, комбайн эзләре сузылышып яткан. Ике-өч җир буе киткәч, Галимҗан, уңга каерылып, яңа эз салып бара башлады. Бераздан алар чәчелмичә калган буш җир кырына барып тукталдылар.

Өй урыны кадәр генә өчпочмаклы кишәрлектә котырынып чүп үлән үскән. Сары, ак ромашкалар, ипи чәчәкләре, шартлавыклар, билчән-шепкәннәр бергә-бергә җилдә рәхәт чайкалышып утыралар. Бодай арасында җәй буе интегеп утырган чүп үләннәр иркенгә чыкканнар!

— Нәрсәгә алып килдең син монда? — диде Хәнәфи ярсып, калкынып.

— Күрәсеңме, Хәнәфи абый?

Бодайны Хәнәфи үзе чәчтергән иде. Галимҗан шуны онытмыйча, төпченеп, казынып йөриме әллә?..

Һәм Хәнәфи күкерт шикелле кабынды:

— Син, энем, бармагыңны минем күзгә төртмә! Белдеңме? Кеше эшеннән гаеп-кыек кына эзләргә торалар. Сәхра кадәр басуда песи учы хәтле җир чәчелмичә калган икән, синеке кимедеме әллә?

— Мин аны әйтмим, Хәнәфи абый... Күр әле, дим, нинди матур чәчәкләр!

Хәнәфи иренеп кенә карап тора иде, башын чайкады, авыр сулап әйтеп куйды:

— Чүп-чар диген, әкәмәт! Нинди чәчәк булсын ди.

— Чүп-чар түгел! — диде кызып, егет.— Һәммәсенең дә исе, төсе, исеме бар аларның. Тик без белеп кенә бетермибез. Менә бу кырыйдагылары күзлут дип атала.

Йөкче мәзәк кенә пырхылдады:

— Урыны бәләкәйрәк, чабып алганда, ярыйсы булыр иде. Күзлутмы, чузлутмы, сыерга аңа барыбер, бөтерә дә тыга! Шәйхулладан курмыны барыбер бик каера алмассың.

— Ә менә шушы чәчәкне беренче тапкыр күзлут дип атаган кешегә барыбер булмаган ул, Хәнәфи абый!.. Ә син кешеләрне бер калыпка сугалар, дисең! Алай түгел бит... Бик күпләр чүп дип йөрткәннәр, йөзләр, меңнәр уйлап-нитеп тормаган, шуны кабатлаган, ә берәү тоткан да «күзлут!» дип исем биргән. Безнең борынгы бабайлар үләнне «ут» дип йөрткәннәр. Шуннан утар, утлык, утау сүзләре калган. Атлар утлап йөри дибез икән, бу инде бахбайлар үлән ашыйлар дигән сүз була. Күзлут — күз кебек үлән. Чыннан да, зәңгәр күзгә охшаган бит чәчәкләре?

Хәнәфинең тирән чокырларда утырган күзләре туктаусыз елтыраштылар, ул, борын яфракларын киереп, һава сөзде:

— Чәчәген белмим, әмма ачы бал исе килә! Берәр җамаякны түңкәйтеп җибәрергә диген син! Мунчадан соң, ә? Менә булыр иде эш!

Машина тагын җәлт кенә кузгалды. Киттеләр. Тәгәрмәчләр, сары камылларны чыштырдатып, күңелле генә тәгәриләр. Уңда, Кырынды тавы өстендә, тракторлар борчак җирен сөреп бетереп киләләр. Җил. Коры тузан уйнап тора.

— Ә син боларны каян беләсең? — дип сорады Хәнәфи, бераз баргач.

— Укыдым.

— Шундый гыйлемлегең булгач, нигә колхозда изаланасың?

— Изаланмыйм, эшлим.

— Таптың эш! Теләсә кем теләсә кая куа. Сәгате-минуты язылмаган, их, синең урында булсаммы мин!.. Төкерер идем авылга. Тормышмыни бу, яшәүмени? Шәйхулла типкесендә йөр инде. Сәнәктән көрәк булган нәмәстәкәй!..

Галимҗан, баягы сөйләшү кузгаласын ачык тоеп, сүзгә катышмады.

— Яши белмисең... «Саный белсәң, саесканның коерыгы — уналты» дип әйтә иде минем әткәй мәрхүм...

— Нигә санамадың соң, Хәнәфи абый?

— Җүләр булганга! Менә синең кук чакта акыл бирүче булмаган. Тотып ярган булсалар, аңлаган булыр идем, мөгаен! Хәзер инде соң. Гомер үтте. Күләгә булып, шәүлә булып, сүзсез-өнсез сарыктай яшәлде...

Хәнәфинең үзалдына сөйләнә торган гадәте барын белә иде Галимҗан. Ул, аны тыңламыйча, акрын гына үз уйларын уйлый иде. Аның уйлары да шактый күңелсез, очсыз-кырыйсыз иде бугай бүген.

Чәчәкле кишәрлекне төнәгеен үк күреп киткән һәм сокланып үткән иде Галимҗан. Төнәгеен үк аның башында бер план да төзелгән иде. Семенаны ташып бетергәч, эштән соң, туп-туры шушында килергә һәм бер кочак кыр чәчәкләре җыеп алырга иде аның исәбе... Бик кирәк иде аңа бу чәчәкләр. Бик кирәк! Ак күлмәкне дә юкка гына кимәгән иде ул. Соңгы рейстан өенә дә кереп тормаска иде аның исәбе. Тик менә соңгы рейс булмаячак. Аның урынына бодай төяп, Зәйгә чыгарга кирәк.

Бәлки Галимҗан чыннан да куркактыр? Мокыттыр? Киреләнсә, карулашса, йә булмаса чиргә-сырхауга сабышса, мондый көнне (бүген алар семенаны ташып бе-

терәләр бит!) Шәйхулла артык кысмас та иде. Дәүләткә дигән ашлык та ташылып бетеп килә. Бер машинадан ни була?

Иртәгә кадәр бу чәчәкләр торырмы-юкмы? Хәзер печән бик кадерле, берәрсе чабып култык астына кыстырып китсә? Иртәгә тагын берәр мәшәкать килеп чыкса? Чыннан да, Галимҗанның көннәре, гомере, Хәнәфи абыйсы әйткәнчә, нәкъ башкаларныкы сыман ук төссез, чырайсыз үтеп китәрмени? Эш, тагын эш, тагын эш...

Хәнәфи һаман үзенекен сукалый:

— Әйтик, менә бүген, нигә ризалаштың инде?

Чыннан да, нигә ризалашты әле ул?.. Тик бу сорау да аның күңелен тулаем биләп тора алмады, егет һич тә көтмәгәндә, Хәнәфигә борылып, сәер генә сорау бирде:

— Ә синең, Хәнәфи абый, айлы төннәрдә, апрель азакларында кыр казларының каңгылдашып килүләрен ишеткәнең бармы? Алар биектә-биектә авыл өстеннән үтеп китәләр!..

Йөкче эндәшмәде, кабина тәрәзәсе аркылы лач итеп төкереп куйды. Ул аптырашта иде. Ни булган бу малайга? Сүгәсең, ачуланасың, тик утыра. Элек келәт, иген тирәсендә кош-корт күрсә, «колхоз икмәген әрәм итәләр» дип пошына иде. Чүп үләннәр үскән бу ызаннар очрый калса, «бу җәфалар күпме орлыкларын биреп калдыралар инде!» дип зарлана иде. Бүген әнә әллә нишләгән...

Башка вакытта ындыр табагына барып җиткәнче рәхәт кенә черем итә торган Хәнәфи, бу юлы пошыргаланып, борчылып утырды. Беләсе дә бик килә иде, сорарга да уңайсызланды. Нәрсә булды икән?

Моннан ары алар телгә алырлык сүз сөйләшмәделәр. Егет таркау һәм уйчан, Хәнәфи турсайган һәм хәтере калган иде.

Семенаны кичкә кырын соң гына ташып бетерделәр.

Районга кузгалганчы, иң элек өйгә кагылып чыгарга кирәк иде. Йөк белән өйгә кайтырга яратмаса да, Галимҗан бүген кереп чыгасы итте.

Хәнәфиләр турысына җитеп аны төшереп калдыргач, Галимҗан җиңеләеп киткәндәй булды, машина тыелып торган арада сиздермичә генә, әмма ниндидер яшерен өмет белән йөкчесенең өй тәрәзәләренә карады. Җил булганга, тәрәзәләр ныклап ябылган иде, өйдә хәрәкәт сизелмәде. Болдырга чыгып килүчесе Хәнәфинең озын, матур хатыны иде, ахрысы. Өй ягыннан бәлеш исе дә килгәндәй булды, егет көлемсерәп Хәнәфигә кул болгады һәм машинасын урам буйлап алга куды.

Өйгә кайтып, аяк өсте генә капкалады, баздан сөт алып

чыгып, ишекле-төрле мыраулап йөргән песигә салды. Салкын, дымлы чүлмәкне күтәреп үзе дә сөт эчте. Өзелеп карыны ачкан икән, рәхәт булып китте.

Эш бетте. Ул, аскы иренен тешләп, урам коймасы янына килде һәм түбән очка, яңа гына үзе кайткан урамга карап тора башлады. Әнкәсе кайтырга иртәрәк шул әле... Кинәт ул үзенең бөтенләй әнкәсен көтмәвен, өйгә кайтуының максаты да аны күрү түгеллеген, хәтта аның турында уйлап та карамавын, күңелен бөтенләй башка кеше, үзгә уйлар тетрәтеп торуын аңлады.

Ни аяныч! Вакыт үткәреп өйгә кайтып йөрүнең һич кирәге калмаган иде бүген, тамагын элеватор буфетында да ялгый ала иде, ул тәкатьсез көтеп алган кичтә өметләр акланачак түгел, сабырсызланып, гасабиланып көткән кешесе күзгә-башка күренмәячәк иде! Ничек күрешсеннәр ди, ул да кеше кешесе, үз ихтыярында түгел, хәзерге минутларда җәйләүдә сыерлар савып, эшен бетереп йөридер. Галимҗан авылдадыр дип күңеленә дә китерми торгандыр! Аның эше бетүгә, егет машинасы белән җәйләүгә барып җитәргә тиеш иде! Кабинасында бер кочак хуш исле кыр чәчкәләре булырга тиеш иде аның: ромашкалар, ипи чәчәкләре, күккүзләр, күзлутлар. Кыз чәчкәләрне күреп гаҗәпләнергә, кабина ишеген ачуга: «И-и, монда миңа урын да калмаган икән!» дип кычкырып җибәрергә тиеш иде...

Егет авырттырып тешләрен кысты, әйе, алар бүген таш яуса да очрашырга тиешләр иде! Очрашырга һәм аңлашырга!

Дөрес, моңарчы да алар күрешми тормадылар. Бер авылда яшәп, бер урам-тыкрыклардан йөргәч, очрашмый каласыңмы соң? Аңлашырга җайлы вакытлары да булмады түгел, тик Галимҗан аның белән аңлашуны ниндидер олы, тиңдәшсез зур, мөһим эш итеп күз алдына китерә һәм ул минутларны гомергә онытылмаслык итәргә омтыла иде. Юк, Хәнәфи абый, кешеләр ахыр чиктә бер калыпка сугылмаганнар! Һич югында, бер тармакта булса да, кеше үз казанында кайнап пешә! Кеше дигәнең инкубатор чебеше түгел, башка күп җәһәттән алар берберсенә охшасалар да, күңел ягына килгәндә адәм уллары үзгәлеккә омтылырга тиешләр!.. Кешенең хет күңеле буйсынмыйча ирекле калсын! Хет бер ягы белән бүтәннәрдән аерылып торсын! Галимҗан шулай уйлый иде. Шуңа күрә егетнең кызга мөнәсәбәте тирән сер иде, күңеле серенә ул үзе, бер башы гына, хуҗа иде. Ул башка бик күпләр кебек, уртага яртыны куеп кызлар турында шалтырарга яратмады. Аның күңел капкасы бүтәннәр өчен ябык, бикле иде.

Бүген ул шул капканы киң итеп ачарга һәм аны күңел түренә чакырып кертергә тели иде. Егет күңеле мөлдерәмә тулган һәм бүген чайпалырга тиеш иде...

Ә Зәйгә бармаса? Таңнан, караңгыдан чыгып китә ала ич ул!.. Аңа бер сүз дә әйтүче булмаячак. Айлар, еллар буе сүз тыңлап, бер карышусыз эшләп йөргән егеткә кем базып сүз әйтә алыр?!

Бару-бармау мәсьәләсен хәл итүдә ул ирекле диярлек иде. Әнә шул ирекне тою аны юлга ныграк этәрә, тик күңеленең кайсы чирегендәдер туган икеләнү боҗрасын тиз-тиз өзеп ташлый алмау гына аны сәерсендерә иде. Хәнәфи абыйсының усал хөкеме борчыдымы аны? Япь-яшь Галимҗан, Шәйхуллага башын биреп, аның ишәгенә әйләндеме? Кем белсен!

Егет Шәйхулланы ярты сүзеннән аңлады. Менә бу иртәдән бирле котырынган җил тикмәгә түгел, аның артыннан ияреп яңгырлар килә. Ә яңгырлар бер башланса, районның иң кырыена урнашкан авылдан Зәйгә үтеп йөрүләр, ай-һай! Юллар бик начар шул әле, бик начар! Юлларның рәтләнер исәбе дә күренми!.. Һәм Галимҗанның күңеленә ят бер уй кагылып үтте: кайсысыннан ныграк курка Шәйхулла — яңгырданмы, әллә район игълан иткән бишкөнлектәнме?.. Район башлыкларыннан ныграк шүрлидер рәис, менә аны кеше кешесе дисәң дә ярый!..

Ни генә булса да, яңгырлар тоташтан шәбәергә керешкәнче, иген үз урынында, коры амбарда булырга тиеш. Галимҗан шуны белә, шушы кагыйдәгә башын бирә...

Ә мәхәббәт? Ә якты хыяллар? Ичмасам, мәхәббәттә булса да үз-үзеңне табарга тырышулар?.. Галимҗанга да башкалар кебек ашык-пошык кына, йә эш арасында, әйтик, клубтан кайтканда, капка баганасын саклап кына аңлашырга туры килерме? Алай икән, апрель азакларында кыр казларын нигә тетрәнеп озаткан ул, кыр чәчкәләренең матурлыгы алдында нигә телсез калган? Күңелендәге иң якты теләкләр, иң сихерле сүзләр шул аңлашу вакытында телгә килерлек булмагач, нигә ул егет исемен күтәреп йөри?..

Мотор теләр-теләмәс кенә кабынды. Урам буп-буш иде. Тик нindидер мәгънәле серләр яшергән кебек буш иде. Җил тузан уйната, түгәрәк өермә ясап ындырларга, бәрәңге бакчаларына кереп китә. Тузан машинага кара койрык булып тагылып уйнаклап бара. Кабинага керә, егетнең ап-ак якасына куна, күлмәген каралта. Каралсын, инде хәзер барыбер. Алда юл, алда мәшакатьле төн, алда Зәй, алда ялыктыргыч ялгызлык...

Кемдер аның исемен яңгыратып кычкырган кебек булды. Ул колагы белән ишетүдән бигрәк, күңеле белән сизенеп, як-ягына каранды һәм Галәмәйләр тыкрыгын-

нан чыгып килүче аны күрде. Ул ап-ак күлмәк кигән иде. Йөгергән, ахры, йөзе, колаклары бурлаттай яна.

— Галимҗан абый! Уф...

Егет үз күзләренә үзе ышанмыйча машинасы белән бергә дерелдә, калтырый иде.

— Мине дә Зәйгә утыртып бар әле, Галимҗан абый.

Зәйгә? Каян белгән ул аның Зәйгә барасын? Монда ничек килеп чыккан? Нигә мондый ап-ак өр яңа күлмәк әле аның өстендә?..

Һаман телгә килә алмады егет, сүзсез генә кабина ишеген ачты, утыргычны учы белән кат-кат сыпырды. Кыз, утырып, киң итеп сулыш алды, җәһәт кенә чәчләрен рәтләде. Кузгалдылар.

— Галимҗан абый, син безнең турдан үтмә инде, яме,— диде кыз, оялып кына.

Егет шунда ук борылып тыкрыкка керде һәм ындыр артлатып олы юлга чыкты.

«Олы юлга!» дип уйлады да, Галимҗан әсәренеп китте.

Аның белән!

Янында ул утыра!

Кыз, ярым көлемсерәп, егеткә күз ташлап ала һәм, аның уйларын аңлаган кебек, бер сүз дә эндәшми. Икесе дә күрешү кинәтлегеннән исәңгерәп шактый вакыт сүзсез бардылар. Тик гел-гел болай барып булмый ич инде, нидер сөйләшергә дә кирәк! Икесе дә моны аңлыйлар, йөрәксенеп сүз башларга гына базмыйлар иде.

Эштән кайтучылар, юлаучылар аларга борылып-борылып карап калалар иде. Ап-ак күлмәкләр киеп, әрҗәгә бодай төяп кая баралар болар? Ул Хисами Галимҗаныннан әллә ни көтәргә була, юаштан юан чыгар, диләр булыр, аны күрүгә күзләрен тасырайталар. Бәлки, әнә шул ят күз карашлары аларны ятсындырып, телләрен бәйдә тотадыр? Юк, анысына да артык исләре китми иде аларның, ахрысы...

Кичке моңсу төтеннәре, куанычлы ыгы-зыгылары белән авыл артта калды, өянкеләр мул бизәгән Сай чокырны да үттеләр һәм икесе дә, сүз берләшкәндәй, җиңел сулап куйдылар.

Сүз үзеннән-үзе килеп чыкты, ялганды.

— Син бик арыгансыңдыр инде, Галимҗан абый,— диде кыз, аңа җылы карап.

Егет баранкасын кысыбрак тотты:

— Ә үзең, Сөмәя?

— Мин бүген армадым! Юк, кая ди ару! — диде кыз, кабаланып.— Армадым!

Егет өчен бу сүзләр кадерле иде. Кыз бүген диде бит! Ул аның таңнан торып кичкә хәтлениләр эшләгәнен

күз алдыннан үткәрде: мәшәкатьле авыр хезмәт ул сыер саву! Ә ул әнә армаган! Аны көткән!

Кызның ничек итеп үзен көткәнне генә белә алмый иде Галимҗан! Чөнки кыз әбәт вакытында ук егетнең килә алмавын, икмәк төяп Зәйгә чыгасын ишеткән иде инде. Шуның өчен иптәшләре аның кичке савымын бүлешеп алдылар, ул беренче туры килгән машина белән авылга кайтып җитте. Алар бүген, һичшиксез, очрашырга тиешләр иде!

— Юл әйбәт,— диде кыз.

Егет бу сүзләрдә үзенә теләктәшлек, якынлык, җылылык сизде. Шофер өчен юл — ярты гомер дигән сүз...

Аннары бүген сүзләр, авыздан чыгуга ук, яңачарак мәгънә алалар иде. Сүзләр генә түгел, юл да, күнегелгән тирә-як та икенчерәк, катлаулырак һәм серлерәк иде бүген. Авылдан шактый ерагайгач, бәләкәй, юаш таучыкта сураеп утырган җил тегермәне турына килеп җиттеләр. Күз иялəнгәнгә, кайчагында күрмичә дә үтеп китә торган иде аны ул. Ә бүген тегермәннең япа-ялгыз икәнлеген дә, сукмагын үлән басуын да, канатларының җил-яңгырда калшаеп, сәлперәеп салынуын да ап-ачык күрде. Гаҗәп: кыз да тегермәнгә текәлеп бара икән!

— Нинди дәү һәм мескен безнең җил тегермәне! — диде ул, уйчан гына.

— Картайган инде.

— Урын алып кына тора. Ник сүтмиләр икән үзен? — дип сорады кыз. Шулай дисә дә, тавышында шушы тегермән харәбәсен кызгану аһәңнәре яңгырады.

— Кемнең кулы барсын? Беркемнең дә сүтәсе килми. Сугышка кадәр әллә кайчан җиткергәннәр аны. Салучы осталар да, тегермәнче дә әйләнеп кайтмаган. Истәлек! Авылдан җитмеш биш кеше үлеп калган. Безнең авылда аларга бүтәнчә һәйкәл юк та диярлек... Алар салган өйләр тузган, яңаларын ара-тирә уллары, оныклары җиткерә. Ә тегермән, карт бөркет кебек, һаман барыр, кайтыр юлларны саклый...

— Безнең әткәй: «Күпме утын череп ята!»— ди. Ватып ташларга кыҗрап йөри,— диде кыз, нигәдер әрнеп.

— Юк, Хәнәфи абыйның да кулы бармас! Теле белән әллә ни әйтер, эш сүтүгә барып җитсә, уйлар...

— Биектә утыра...

— Биектә!

— Кызганыч, еллар аямас, үзеннән-үзе череп таралыр инде. Һәйкәл дисең бит, Галимҗан абый.

— Аңынчы кешеләр берәр нәрсә уйлап табар! Җитмеш бишәү ятып калган бит!

Тегермән боегып артта калды. Бормаланып-бормала-

нып аккан тар инешне кичтеләр. Күпер култыксалары да кыйгаеп, җимерелеп беткән иде. Юл тузанлы, тигез диярлек иде. Иренеп кенә караңгы төште. Аның көндәгедән иртәрәк иңүен икесе дә сизделәр.

— Менә килеп тә җиткәннәр,— диде егет, күккә ымлап.

— Яңгыр ишә башласа? — диде кыз, куркып кына.

— Зыян юк. Брезент йөк өстендә. Хәзер каплыйбыз аны.

— Ә юл? — диде кыз, көлемсерәп.

— Юлны брезент белән каплап булмый.

Кыз тыелып кына көлеп җибәрде:

— Җитмәсме?

— Аңа бетон, асфальт кирәк,— дип аңлатты егет.

— Шәһәрдәге кебекме?

— Юньле хуҗалар бар җирдәге кебек. Машиналарны сирәк-сорак кайтаралар, анысы, бәлки, худка китәр. Асфальтны бирмиләр.

— Кайчан исә бер булыр әле, Галимҗан абый.

— Булыр булуын...

Егет күз кырые белән кызга күз салгалай иде. Сөмәянең җитди, олы булып үзен тыңлап баруы аңа ошый да, берникадәр сәер дә иде. Алар, чыннан да, икәү баралармы? Янәшә? Зәйгә?! Валлаһи, икәү бит! Алайса нигә көндәгечә эш, тормыш мәшәкатьләре хакында сөйләшә башладылар әле алар? Сүзләр бүтән кирәк иде бит, башка уйлар, башка фикерләр... Каян, ничек табарга шул яшерен, серле сүзләрне?

— Аклы күлмәгеңне кигәнсең, Сөмәя.

— Үзең дә, Галимҗан абый.

— Каралды инде. Машина акны сөйми.

— Ак кулны да, Галимҗан абый.

Ничек мине эзләп киләсе иттең, дип сорарга теләде егет. Базмады, бу сорау артык гади иде, кызның дәрәҗәсен, очрашуның бәясен төшерә кебек тоелды аңа. Бүген алар очрашырга тиешләр иде бит! Сөйләшеп куйганнар иде!

Машина уты, үзенә юл таләп итеп, һаман алны ялый, алда җил. Җил тузанны кабинага бөркеп кертә, битләргә, колакларга сибә.

— Җил!

— Җил, Галимҗан абый. Бүген урман көне буе гөжләп торды. Чыгам да тыңлап карыйм: гөж-гөж итә. Туктаусыз гөжли. Машина тавышы дип әллә ничә кат алдандым. Күккә карыйм, кояш әле әнә кайда-а!

— Җил! — диде куанып егет.

— Яңгыр китерер микән?

Кызның соравына җавап биргәндәй, кабина тәрәзәсенә беренче эре тамчы килеп сыланды.

Егет шундук машинасын туктатты, җәлт кенә кабинадан чыкты да әрҗәгә сикереп менде. Кабалана-кабалана брезентны җәя башлады.

Сөмәя, башын ишеккә тыгып, аңа карап тора иде.

— Чыкма, чыкма, чыланасың!

— Ява бит, Галимҗан абый!

— Ява! — дип, нигәдер шатланып кычкырды егет өстән.

— Ничек шыбырдый,— диде кыз, учын яңгырга куеп.

— Уҗымнарга дым кирәк иде,— диде егет, кабинага кереп утыргач. Аның чәчләре чыланып маңгаена сыланган, үзе яшәреп, малайланып калган иде.

— Кырынды өсте иртәгә күпереп үсеп чыга инде.

— Тормыш шундый. Яшәргә, орлык бирергә тиеш.

— Тоташ яңгырга әйләнеп китмәсме? — дип сорады кыз.

— Әле иртәрәк!

Егетнең тавышында шундый тирән ышаныч, ныклык бар иде, кыз кинәт тынычланды һәм алдан да, яннан да коеп яуган яңгырга сокланып бара башлады. Яңгыр астында юлда рәхәт! Әле ул пычранып өлгермәгән, тузан басылган, тәрәзәдән дым исе, юеш кыр исе, нарат урманы исе кереп тулды.

— Кашка тау турысына килеп җиттекме әллә?

— Таулар,— диде егет, уң якка ишарәләп.

— Син күрәсеңме аларны, Галимҗан абый?

— Күрәм.

Кыз да караңгыга текәлеп карады. Яңгыр тоташ стена булып коя иде. Тик шулай да караңгылык арасыннан ул нарат агачларының томанлы очларын күргән сыман булды. Үзе исә:

— Ә мин күрмим... Берни дә күрмим,— дип борчылып кабатлады.

Егет үз ягындагы тәрәзәне яба башлады.

— Тимә, Галимҗан абый.

— Үтәли җил йөри. Сиңа салкындыр.

Кызга чыннан да салкынча иде, тик аның кабина эчендә бернәрсәне дә үзгәртәсе килми иде. Ничек булган, шулай булсын! Менә шулай, менә шулай...

— Үтәли җилдән курыкмыйм мин. Салкыннан да.

— Ява! — диде егет, кулъяулыгы белән битен сөртеп.

— Яусын! — диде кыз, тантана белән.— Ныграк яусын!

Яңгыр тавышыннан бөтен тирә-як җанлангандай бул-

ды, караңгылык хәрәкәткә килде, бу үзгәреш, җанланыш шушы кара төндә икәү генә калган юлчыларга ниндидер сөенеч, шатлык өсти иде. Алар шулай, әчтән генә куанышып, төнге яңгыр шавы астында, бер-берсенә сыенып шактый озак бардылар.

Тирә-як кинәт тынычланып, гадиләнеп калды. Алар, сәерсенеп, мотор тавышын ишетә башладылар. Ни булды? Җил көчәйгән иде шикелле, ә тавышлар тынды. Егет, елмаеп, кызга карады:

— Теләгең кабул булмады, Сөмәя, яңгыр туктады.

— Миңа җитәрлек булды, Галимҗан абый.

— Чыландыңмы?

— Бераз бар!

— Туңарсың инде?

— Туңмыйм, туңаммы соң! Җылы ич бүген!.. Ә һавасы нинди?.. Борыныңа төреп тыгарлык, ди безнең әткәй.

— Ул шулай дип әйтә беләме?

— Сирәк-мирәк! — Кыз яңгыратып көлеп куйды.— Тауларны үттекме әле, Галимҗан абый?

— Тауларнымы? Тауларны үтеп булыр иде, алда Тирән чокыр бар әле. Караңгыда дәшми-тынмый гына астан килеп чыга ул! Сагалап тора! Менә аны үтәсе бар!

Кыз егет тавышындагы хафаны аермачык ишетте.

— Шулай бит әле. Истән чыккан. Зәйгә бармаганга да байтак шул. Тирән чокыр ярты юл буламы?

— Ярты юл.

— Шулай рәхәт булып китте, иеме, Галимҗан абый?

— Язгы яңгырлар күңеллерәк. Анда, ичмасам, тамган бер тамчының үлән, иген тамырына сеңүен аңлыйсың. Һәрбер нәни тамчыда көч, тормыш яшерелгән. Ә көзге яңгырлар моңсу, әллә ниләр уйлата...

Яңгыр монда шәбрәк яуган, ахрысы. Борылмадан үтүгә, зур-зур җәенке күлләвекләр очрый башлады. Димәк, урта юлга җитеп киләләр. Тирән чокырга... Тирәнлеге Сай чокырдан әллә ни артык булмаса да, атналар буе кипми торган авыр үзле балчыгы өчен аңа шундый исем такканнар. Шоферларның теңкәсенә тия торган әшәке бер урын иде бу. Ел саен, нәзек бүрәнәләр тәгәрәтеп, яңа күпер сугалар, ел саен яз башында тракторлар, авыр машиналар үтеп-сүтеп ул бүрәнәләрне сындырып, чәрдәкләп бетерәләр. Аннары шоферлар җәй буе күпер төбендәге зирек, тал әрәмәсен аяусыз ботарлыйлар.

Машинаның хәле китте, тәгәрмәчләр, машина авырлыгын тигез тота алмыйча, таеп-таеп китәләр иде.

— Чана кебек салулый!

— Үтә алырсыңмы, Галимҗан абый?

— Үтәргә кирәк иде, Сөмәя.

Күпер башына язын бульдозерлар өйгән балчык дам да җебеп аккан, монда аерата уяу булырга кирәк. Галимҗан кайда нәрсә ятканын ап-ачык хәтерли иде. Күпергә хәтле зыянсыз гына килеп җиттеләр, машина, киреләнеп, янтаеп-янтаеп алгаладьі, андый мизгелләрдә кыз күзләрен чытырдатып йома һәм егетнең таза беләгенә ябыша иде.

Ниһаять, машина иләмсез янтайды, әче улап тукталды. Көчәнеп алга ыргылып карады, кузгала алмады, тәгәрмәчләр сыек балчыкта сыпкы боламыгы болгатып зыр-зыр әйләнделәр.

— Утырдык,— диде егет, кызга карап. Аның күзләре көлә иде.

— Ныкмы, Галимҗан абый?

— Утырсак нык инде,— диде егет.— Казынтылы, хәтәр урын.

Ул, кабина ишеген ачып, янтаеп артка карады.

— Күлнең күзенә генә басканбыз. Төшмә, төшмә, Сөмәя.

Егет, чалбар балакларын өскә кайтаргач, чупырдап аска төште. Кыз каерылып аңа карап утырды да, туфля, оекларын салып, аның артыннан иярде. Су салкын, җил вак дулкыннар куалап кисеп-кисеп исә иде. Галимҗан, кабина артына беркетелгән тимер көрәген алып, баткан арткы тәгәрмәчләр янына килде.

— Казырга туры килә,— диде ул, учын төкереклләп.

Кыз болганчык судан башка берни күрә алмыйча иелгәләп каранды да, егетнең максатын аңлады, Галимҗан, канау казып, чокырга җыелган суны агызырга тели икән.

— Көрәгеңне алай текә тотма, Галимҗан абый,— диде ул, йомшак кына. Күпердән ерак та түгел куаклар караеп утыра иде.

— Балтаң бармы? Ә, Галимҗан абый?

— Шунда, кабинада,— диде егет, еш-еш сулу алып.

Бераздан шатыр-шотыр агач сынганы ишетелә башлады. Егет сокланып караңгыга карады:

— Сөмәя, өстеңдә ак күлмәк ич!

— Һей, Галимҗан абый!

Егет казыган тар канаудан су түбәнгә, дамба астына ага башлады, кыз кочак-кочак ботак-сатак китереп торды. Шактый озак азапландылар. Тез тиңентен су шәрә балтырларны өшетә, тирләгән аркаларны суык җил үчегеп кыйный иде.

Су күзгә күренеп кимеде, Сөмәя байтак ботакларны тәгәрмәч асларына җәйде.

— Хәзер кузгатып карыйбыз,— диде егет.

— Галимҗан абый, бу юлларны берәр заман рәткә салырлар микән?

— Салырга кирәк иде дә... Тик әлегә мин белә-белгәннән бирле юл төзүче оешмада начальниклар гына алышына! Ә юллар һаман шул килеш!

Агач-магач түшәлгән баткактан машина тиз генә чыгарга ашыкмады. Тәгәрмәчләр, ботакларны туздырып, атыпбәргәләп бер урында әйләнделәр. Кыз, яланаяклары белән тая-тая, иңе белән әрҗәне алга этте. Менә тәгәрмәчләр аны сыек сыпкы белән коендырып кузгалдылар, ул бар көченә:

— Китте, китте! Бара, Галимҗан абый! — дип кычкырды.

Машина үксеп-уфтанып кузгалды, күпер өстенә керде һәм үрне менеп җитеп тукталды. Егет, кабинадан сикереп төшеп, кызны чакырды:

— Монда кил, Сөмәя.

— Бармыйм.

— Нигә?

— Мин сыпкыга, лайга батып беттем, Галимҗан абый.

Егет, эре-эре адымнар белән сикергәләп, кыз янына төште, үргә алар җитәкләшеп менделәр. Ут яктысына чыккач, бер-берсенә карашып, озак кына көлештеләр.

— Миңа ачуланасыңмы, Сөмәя?

— Ник ачуланыйм ди, Галимҗан абый! Шундый күңелле булды, шундый кызык!..

— Монда ерак түгел чишмә бар,— диде егет, кыюсызланып.— Юынып алабызмы әллә?

— Кайда чишмә, кайда елга барын син беләсең инде, Галимҗан абый. Хәтерең дәме, мин бәләкәй чакта син, бездәй ыбыр-чыбырны җыеп, Тугай суына көпшәгә алып барган идең?

— Онытмадыңмыни әле шуны?

— Карыным ачып, кайтыйк инде, дип җылаганым да исемдә... Әйдә, юынып киләбез, Галимҗан абый!

Кыр өстеннән, дөм караңгыда җитәкләшеп бару нинди рәхәт! Төн салкынча, күк аязган, яңгыр юган күкнең кара шәленнән йолдызлар тамарга тора. Аяк астындагы юеш үләннәрне кабартырга тырышып, җил йөгерә.

— Чишмәгә еракмы әле?

Кызның зур ачылган күзләреннән якты нур ага.

— Менә монда, чокырда.

Алар, җитәкләшеп, төшә башладылар, егет таеп шуа башлаган иде, яланаяклы Сөмәянең кулларына тотынып калды. Эре-эре яфраклар белән капланган чокыр төбендә тонык кына кара су елтырый иде.

— Менә ул!
— Бу бит Хәйри кизләве!
— Әллә килгәнең бар?
Кыз сүзсез генә ым какты.
— Шушы чишмә янына агач утыртырмын дип йөрим, һаман өлгерә алмыйм.
— Алайса бергәләп киләбез! Мине дә алып килерсеңме, Галимҗан абый?
— Минем бу ярларга өрәңге, имәннәр утыртасым килә. Нык агачлар. Озак үсә алар, ләкин мәңге утыралар. Юын, Сөмәя.
Кыз су өстенә иелде дә озак итеп тавышсыз карап торды:
— Галимҗан абый, кара әле, йолдызлар!
Су өстендә кызның дерелдәп торган тонык күләгәсе белән янәшә сансыз-исәпсез йолдызлар тирбәлә иде. Ул, кушучлап су чумырып алып, шаяра-көлә юына башлады. Егет аннан күзен аера алмыйча текәлеп карап тора иде. «Менә хәзер, менә хәзер!» дип типте аның йөрәге. Ул юынып кына бетерсен дә... Менә хәзер... Үзендә ниндидер арганлык сизеп, егет сөзәк ярга утырды. Кыз, чишмәгә иелгән килеш, аңа борылып карады.
— Нинди салкын, юеш яфраклар.
— Ә син аларның исемнәрен беләсеңме?
— Белмим.
— Үги ана яфраклары дип атыйлар аларны.
— Нигә икән, Галимҗан абый?
Егет, кулында үги ана яфракларын бөтереп, сөйләп бирде:
— Ул исемне тапкан кеше шагыйрь булган... Гомумән, безнең бабайлар шагыйрь булганнар алар! Күккә караганнар да, Киек Каз Юлы, дигәннәр. Тимер казык йолдызын белгәннәр. Җиргә караганнар да менә шушы иң төссез, салкын чокыр яфракларына Үги ана исемен биргәннәр.
— Сәер исем...
— Бу үләннең чәчәге яз башында, кар китүгә үк чыга. Кайбер авылларда аны умырзая дип тә йөртәләр. Бездә, кимәшә башы, дип атыйлар. Кимешәсе нидер тагын, яздыр, мөгаен.
— Күргәнем бар! Чәчәге сап-сары була, яр буенда сибелеп утыра.
— Чәчәген ата, ә яфрагы һаман юк. Яфрак белән чәчәк бервакытта да очрашмыйлар. Яфрак үсеп чыкканда, чәчәге беткән була инде.
— Бер дә, бер дә очрашмыйлармы? Кызганыч...
Егет тә, кыз да ниндидер серле мәгънә алган салкын

яфракларны җыя башладылар. Яфраклардан ниндидер төче саз исе, ләм исе аңкый иде. Галимҗан үз кулындагы яфракларны кызга сонды.

— Менә!

Алар икесе дә тавышсыз гына көлеп җибәрделәр. Бик, бик рәхәт, күңелле иде. Кайдадыр еракта машина гөжләгән тавыш ишетелеп китте.

— Сәгать ничә икән, Галимҗан абый?

— Белмим, Сөмәя.

Ул көннең озынлыгын уйламас өчен сәгатен өйдә калдырган иде.

— Ишетәсеңме, Галимҗан абый?

— Ишетәм, Сөмәя. Зәй ягыннан берсе кайта.

Беравык тын алырга да базмыйча тыңланып тордылар.

— Йөгердекме, Галимҗан абый?

Җир өсләп кенә юлга йөгерделәр.

— Сиңа салкын тимәсме?

— Бүген юк!..

Юлда аларның машинасы юаш кына көтеп тора иде. Зәй ягыннан килүче машина һаман якыная, гөжләве ачыграк ишетелә.

— Галимҗан абый!

— Әү, Сөмәя.

— Нинди машина булыр бу?

— Ибраһим булырга тиеш.

— Мин аның белән кайтып китәм.

Егет үз колакларына үзе ышанмады:

— Син миңа үпкәләдеңме?

Кыз егеткә сыеныпрак, аңа иркәләп эндәште:

— Мин бүген бик бәхетле, бик... Тик соң инде! Син әйләнеп кайтканчы әле... Миңа иртәнге савымга өлгерергә кирәк... Аннары көн яктысында бу өс-баш белән кайтып керү дә уңайсыз булыр.

Кызның сүзләре хак, мәгънәле иде. Егет карышырлык дәлилләр тапмады, тик аңа нигәдер бик күңелсез булып калды. Тагын шулай гына, сүзсез-аңлашусыз аерылырлармы алар? Ул ниндидер тирән мәгънәле сүзләр эзләп азапланды. Шул арада теге машина килеп тә җитте.

— Син нәрсә, ватылып ятасыңмы әллә? — диде Ибраһим, күрешкәч.

— Юк. Сине көтәм. Менә Сөмәяне утыртып кайт инде син.

— Ә ул каян кайта?

— Киек Каз Юлыннан! — дип көлде кыз һәм Галимҗанның зур, кытыршы учын үзенең нәни, кайнар кулына кысты.

— Рәхмәт сиңа, Галимҗан абый!

— Хәерле юл, Сөмәя!..

Кабинага кереп утыргач кына, Ибраһим кызның өсбашы шактый юеш, пычрак икәнлеген абайлады һәм, кулындагы яшел яфракларга күрсәтеп:

— Шушы себеркене җыярга килдеңме әллә? Әйт әле, нинди ырымы бар аның? Үзебезнең Чүке буенда да күп ич алар,— дип тезеп китте.

Кыз эндәшмәде, яфракларны күкрәгенә кысты.

* * *

Сөмәя дөрес әйткән икән, яңа көн тугач кына әйләнеп кайтты Галимҗан. Хәнәфиләр турысына җиткәндә, ул ирексездән машинасын акрынайтты. Йорт янындагы бакчада алмагачлар арасына тартылган кер бавында очып китәргә җыенган дәү аккош кебек ак күлмәк җилферди, бакча як тәрәзә төбендә зәп-зәңгәр вазада яшькелт үги ана яфраклары балкып утыра иде. Егет туктап тормады, урамдагы бозауларны, казларны өркетә-өркетә, урам буйлап Югары очка менеп китте.

*Июль, 1961 ел, Ялта*
*Март, 1964 ел, Казан*

# Тәрәзәләр

Картлыкның алама яклары яшьтән үк колагыңа керә башлый, әмма аның бөтен аяныччлы төсләре картлыкны үзең кичергәндә генә өстеңә ябырыла икән. Һәркем үзенчә картая! Берәүнең акылы икенчегә һич ярамый! Гомере буе аралашкан, ашка-суга йөрешкән, тугандай якын күргән кешеләре белән көннәрдән бер көнне Һашим карт арасын кырт өзәр дип кем уйлаган? Әүвәле нык аралашкан таныш-белешләре, соңгы өч-дүрт ел эчендә, Һашимны тәмам югалттылар. Чакырдылар — кунакка килмәде, үзе өндәмәде, сирәк-мирәк телефоннан кәеф-хәтерләрне белешә иделәр, анысы да авызына су капты. «Ни булды Һашимга?» дип Казан баш ватты, ә картның дөньядан ваз кичүе бер дә сәбәпсез түгел иде. Ул үткән гомерен искә төшерергә, үткәннәр хакында сөйләшкәнне яратмый башлады. Карт-коры җыйналса, ни хакында гәп куерта? Күпчелек үткәннәрне сүтә-җыйный, яшь чагында кылган гамәлләре белән мактанып ала, кайта-кайта яшьрәк чакларын сагына. Үткән гомере белән Һашим абзабыз дус-ишләрен, туган-тумачасын, кыскасы, аны белгән шаһитлардан үзе теләп баш тартты.

Моннан өч җәй элек Һашим балыкка барган җиреннән берәү белән танышып кайтты. Аларны яр буе тынлыгы, сүзсезлек якынайтты. Шундый хәл дә була икән, Иделнең аулак ярында, тал куаклары арасына җайлап урнаштылар да, калкавычларына текәлеп, көн дәвамында бер сүз алышмадылар. Яңа танышы Һашимнан «нигә кызың албан кешесенә кияүгә чыгып чит илгә китте?» дип сорамады, улын урыс килене Мурманскига дөбердәтеп алып китүе белән дә кызыксынмады, «ерак Вьетнамда, җәһәннәмдә хезмәт итүче төпчегең кайчан кайта?» дип тә күңелне тыкырдатмады. Эрерәк балык эләккәндә «Һәй аны!» дип бер кычкырып куйды да тынды. Һашимга шул гына кирәк иде дә! Сүзсез, ияк кагып кына аерылыштылар, ни хикмәттер иртәгесен шул ук тугайда, шул ук таллар арасында тагын очраштылар. Бер очраштылар, ике, атналар буе калкавыч сагаладылар, яңа танышының

Фәхриев фамилияле икәнен белде Һашим, шуннан артыгы белән кызыксынмады. Тора-бара ул Фәхриевнең кайда торганын, адресын язып алды, эче бик пошкан ялгызлык мизгелләрендә Фәхриев янына барып кергәләде. Анда да сүз эзләп, арадашлыкны зарыгып түгел, тынлык, җайлы сүзсезлек йөртте аны. Фәхриев, сүз башларга омтылып, авызын ача, елмая, йөзе балкып китә, әмма Һашимның суыклыгы, өшегәнлеге ачылган авызны ябарга мәҗбүр итә, алар, ике карт, ике пенсионер сәгатьләр буена кара-каршы утырып шашка уйныйлар, җиңсәләр дә, җиңелсәләр дә рәнҗемиләр, дәшмиләр. Фәхриев, Һашимның ни өчен килеп йөргәнен сизенгән кебек, балыкчы танышын борчымый, ул килгәндә үзе дә сүзсез-өнсез җан булып кала иде. Һашимга ни кирәк тагын?..

Менә бүген дә алар урамнан икәү үтеп баралар. Һашим, Фәхриев шәбенә басарга тырышып, әкрен генә атлый, гаҗәп, ул да, юлдашына ярарга тырышып, аякларын алмаштыра, адымнар бутала, икесе дә туктап калалар. Фәхриев, нидер әйтергә теләгәндәй, озын урамның аргы башына карый, аннары бөтенләй туктый да оялып кына:

— Күрче, ничаклы тәрәзәләр! — дип куя.

Һашим карт аның сүз катуына рәнҗеми, авызы ирексездән ачыла, сүзгә зарыккан иреннәре арасыннан аксак-туксак җөмлә кысылып чыга.

— Тәрәзәләргә күтәрелеп караган юк бугай... Картлык — дөньяда иң алама нәрсә икән... Картлыкта тәрәзә дә чепи күз кебек кенә...

Фәхриев, юлдашының авыз ачуына сөенгән кебек, сүзен йомгакларга ашыга:

— Тәрәзәләрне көндез түгел, төнлә, караңгыда карарга кирәк. Кичләрен җан керә аларга! Тәрәзәдә нур бар икән, тормыш бар, тереклек бар дигән сүз.

— Нигә боларны искә төшерәсең әле, тәрәзәләрне, дим?

— Мин гомерем буе пыялачы булып йөрдем ич. Шуннан пенсиягә чыктым.

— Каһәр суксын пенсиясен, картлык яман!

— Нишләп яман булсын? Гомереңнең якты чагы да булган ич! Картлык хатирәләр белән яши...

Фәхриев, сыңар кулын уйнатып, тагын нидер сөйләргә җыенган иде, сулдан, яңа йортлар салынып яткан мәхәлләдән, бер төркем яшьләр килеп чыкты. Яшьлектән дә, яшьләрдән дә курка башлаган Һашим аның чалбар каешына кыстырылган буш җиңеннән тартты:

— Китик!

Фәхриев, кемнедер эзләгән сыман, туктап калды. Яшьләр арасыннан спай киенгән, нык гәүдәле бер егет аерылып чыкты да, якынлашкач, кычкырып җибәрде:

— Фәхриев абый!

— Исәнме, Һади,— диде ул, тыныч кына.

— Алтынчы йортны тапшырдык. Бүген күченеп килә дә башладылар. Безне өй туена чакырдылар. Кызык!

Һашим уңайсызланып читкә тартылды, Фәхриев белән егет нидер сөйләштеләр, көлеп тә куйдылар.

Егет киткәч, Фәхриев Һашимга таба борылды:

— Картлык яман диденңме әле син?

— Үтә яман. Чиге-чамасы юк.

— Картлык — яшьлекнең дәвамы ул. Әгәр картлыгың хәзерге яшьләргә, яшьлеккә тоташса, бүтәненә һич исем китми минем! Эштән котылгач уйланырга вакыт кала. Һади бу. Минем сыман пыялачы егет. Сөйлимме аның турында?

Алар ябалдашлары чак лепердәшкән яшь агачлар арасына кереп утырдылар...

Һашим абзыйның ачылып киткән чагын мин дә очраттым, кулсыз пыялачы Фәхриев һәм аның шәкерте Һади турында миңа ул сөйләде, бу хикәяне шуннан алып яздым.

## 1

Өстәлгә ике тәлинкә, юка итеп туралган ипи телемнәре һәм ике кашык куелган. Берсе зуррак, бизәге уңган агач кашык, икенчесе кечерәк — сабы бөгелеп, кыегаеп беткән алюмин кашык. Тәлинкәләрнең берсе буш, икенчесендәге сөтле өйрә суынып, өстенә пәрәвез юкалыгы җыерчыклы ак элпә сарылган.

Кысан бүлмәгә тынлык чак сыеп тора...

«Челтер-р!» иттереп тәрәзә пыяласы коелган тавышка Маһирәнең йөрәге «жу-у!» итеп китте. Авызына капкан икмәген йотып бетермичә ул абына-сөртенә ишеккә атылды. Урындык авып калды, аның тез күмәчендә ясмык кадәр генә кан күренде. Ул иске җил тегермәне сыман кулларын җилпеп егылудан котылды һәм тар, озынча коридорга чыкты.

Маһирә, ярым караңгы коридордан якты көнгә чыккач, беравык һични аермый сукыраеп торды. Күзе, иләшә төшкәч, иң элек ямь-яшел мүк каплап кутырлаган таш диварлар арасында дымлы почмакка сеңгән улы Һадида тукталды. Адашып калган хәлсез чебине сырып алган дәү, иләмсез каргалар кебек аны биш-алты хатын ураган. Каян җыелып өлгергәннәр диген үләксә козгыннары! Каргалар өере башында дәү козгын — керфексез ала күзле, утын түмәрләрен таслап бергә укмаштырган гәүдәле, сеп-симез, икенче катта яшәүче полковник хатыны

Өммегөлсем иде. Ул язгы ташкын шомарткан таш кебек йомыры, итләч йодырыкларын йомарлап, тутый кош сурәтләре төшкән ефәк халатының киң җиңнәрен җилфердәтеп, Һади өстенә очып-очып куна: малай, туплы уйнаганда, ялгыш аларның тәрәз өлгесен ваткан икән.

Мул тормышта, эшсезлектә яшәгән икенче кат хатыннары, кулларына туп кадәр туп дәлил булып кергәч, бөтенләй тугарылганнар. Күз күрмәгән, колак ишетмәгән гаепләрне куркудан дер-дер калтырап тагын да курачланган арык малай өстенә өяләр генә. Әллә кайчангы, кадимдәге хәлләр, югалган кер баулары, онытылып беткән галушлар, сөткә төшкән тычканнар, ниндидер велосипед тәгәрмәчләре телгә алына.

— Башыбызга кара хәсрәт булды инде! — Өммегөлсемнең чәрелдәве аермачык ишетелеп тора. Черек күл полковнигы хатынының тавышы шул!

Һади еламый, ул бәләкәйләнгәннән-бәләкәйләнә һәм күгәргән төксе стенага сеңә бара. Яңак һәм борын тирәләрендә төрле түгәрәкләр ясап әйләнгән йодрыклар артыннан күзе иярми аның... Кыйнамасыннар гына! Тәпәли башласалар, Өммегөлсемнең корсагына берне төртергә дә камалыштан ычкынырга кирәк.

Шул чагында малай башын калкытып карады һәм, өметсезләнеп, тешләрен кысты: ычкынып кая бара аласың? Өч яклап тезелгән тәрәзәләр ишегалдына текәлеп акайганнар. Ух, бөтенесен ватып-кырып, томалап бетерәсе иде шуларның! Кинәнә-кинәнә, рәхәтлектән мырлый-мырлый кырыр иде аларны Һади! Иркенләп тын алыр, уйнар хәл юк, йә берсеннән, йә икенчесеннән ачулы берәр кеше сузыла да: «Әй, кая чабасыз? Тәрәзә ватарсыз! Керләрне пычратмагыз! Йокыдан уятасыз! Тузан куптарасыз! Тегеләй итмәгез! Болай кыланмагыз!» — дип бакыра башлый. Кайчагында бишәр тәрәзә берьюлы ачыла, хатыннар күмәкләшеп малайларны өшкерәләр. Һади андый минутларда хатыннарга түгел, тәрәзәләргә ныграк ачулана иде.

Бу юлы хатыннар кыйнамадылар. Базмадылармы, яхшысынмадылармы — белеп булмый. Арттарак басканнарның: «Ятим бала бит, нинди тәрбия күрә ул?» — дигән кызгану катнаш әрнүле сүзләре карга-козгыннарны тыйлыктырдымы, сукмадылар. Усалланган, кан баскан күзләр, тез күмәче бәрелүдән бераз аксабрак килүче Маһирәне күреп алдылар. Малай, арбадан төшеп калган нәни төенчек булып, бер читтә калды, каргалар яңа корбанга — Маһирәгә ябырылдылар.

Гауга көчәйде, «П» хәрефе итеп салынган өч катлы йортның өч ягыннан уннарча тәрәзәләр ачылды, тузган чәчләр, бигудиле бөдрә башлар, мендәр йонына манчыл-

ган сакал-мыеклар, кызыл муеннар, алтын погоннар, эреле-ваклы йолдызлар ишегалдына сузылды:

— Тагын Маһирә малаемы? Вәт шпана! Төрмә көтә аны, төрмә! Яше генә керсен! Күрә торып төрмә кошы үстерәбез!

Сүз дә юк: өч катның өчесендә дә Һадины беләләр иде...

Кайчандыр тоткыннар салган бу өч катлы төнтек йортта күпчелеге МВДда хезмәт итүчеләр яши. Икенче, өченче катта тоташ алар. Ваграк тәрәзәле аскы катта ыбыр-чыбыр урнашкан. Маһирәләр яшәгән озын коридорлы, алты ишекле дәү квартирага ишле гаиләле ярлы-ябагай, җылак балалар, маңкалы кызлар, эт һәм песиләр кереп тулган. Тар, кысан бүлмәләргә сыймагач, алар, ду килеп, ишегалдына өерелеп чыгалар да өске каттагы кәттә начальникларның симез хатыннарының тәмле тынлыгын бозалар. Өске каттагыларның бала-чагалары ишегалдына уйнарга чыкмый, алар җәйләрен Идел буендагы шәпшәп дачаларда, лагерьларда үткәрәләр...

Ярты сәгатьтән Маһирә иңбашына зур агач тартма күтәргән берәүне ияртеп кайтты һәм, кулын сузып, икенче катта шыраеп торган буш өлгене күрсәтте. Пыялачы, ишекне үтеп, икенче катка күтәреләм дигәндә, аның юлында борын астында күтик мыек төрткеләре калдырган солдат пәйда булды.

— Кая үрмәлисең... ач бет!

Пыялачыны Өммегөлсем дә күреп торган икән, коридорга чыгып, түбәнгә, солдатка кул изәде.

— Керсен!

Пыялачы менәргә ашыкмады, кире борылып чыкты, ишегалды уртасында исән калган бердәнбер агач янына килде, кәкре карама ышыгындагы өстәлгә тартмасын куйгач кына менеп китте. Тәрәзә ватылгач кайсы кая тәгәрәгән малайлар кай арада җыелып өлгерделәр, алар, авызларын ачып, борын тишекләрендә казынып пыялачының һәр хәрәкәтен күзәтеп торалар иде. Менә ул икенче катның дәү тәрәзәсендә күренде, кесәсеннән өтерге чыгарып, рам җегенә кысылышып торган пыяла калдыкларын кырып төшерде. Бер читтә кыяр-кыймасрак каранып торган Һади, иптәшләрен ерып, уртага керде. Ул пыялачыга да, аны алып кайткан әнисенә дә үтә ачулы иде. Торсын иде җил өреп ватык тәрәзәдән! Көзгә, кышка кадәр буш торсын иде, Өммегөлсемнәрнең ватык тәрәзәдән күренеп торган тәти шкафларына, чуар келәмнәренә яңгыр, кар кереп тулсын иде. Үзләре катып үлсеннәр иде!

Пыялачы нидер үлчәде, маңгаен кашып торды һәм

күздән югалды. Аска төшкәч тартмасыннан бер табак пыяла алып какшау аяклы өстәлгә куйды. Үлчәде, кесәсеннән шомарып беткән күн савытка салынган бер әйбер тартып чыгаргач, иң алга чыгып баскан Һади:

— Алмаз, алмаз! — дип пышылдады.

Пыялачы, малайларга көлемсерәп карап, калын тавыш белән:

— Кайсыгыз ватты? — дип сорады.

Һади йомылып артка ташланды, хыянәтче иптәшләре аны боҗрадан чыгармадылар, күкрәкләре белән алга, пыялачыга таба эттеләр:

— Менә, менә ул ватты!

Пыялачы да кыйнарга җыенмый икән, ул сүзсез генә башын чайкады һәм кисәргә әзерләнде. Шул чагында гына Һади аның сул кулының юклыгын күреп алды. Менә ул кисек беләге белән пыяланы кысты, чак кына уңга янтайды һәм төзек кулындагы алмаз белән «чыж-ж» иттереп йөртеп алды. Күз дә иярмәде аның хәрәкәтенә, пыяла керт итеп күңелле генә сынып төшкәч, Һади җиңел сулады.

Тагын бер эздән керт иттергәч, пыялачы алмазын яшерде һәм, пыяла өлгене тотып, икенче катка менеп китте. Малайлар аны өер булып тышкы ишеккә хәтле озаттылар. Һади, бу юлы иптәшләрен төрткәләп, аның үкчәсенә басардай булып барды. Пыялачы күздән югалуга, малайлар дәррәү артка чигенделәр. Башта Һадиның күзе гел пыялачыда булды, тора бара ул Өммегөлсемнәрнең өй эчен, радиоалгыч янына баскан олы малайларын күрде. Ул да Һадины күрде, таный икән, телен чыгарып күрсәтте. Теле дәү, кәнфит суырып зурайгандыр инде, Һадиның ямаулы кызыл бияләе хәтле бар икән теле... Улының кем белән булашуын күргәч, Өммегөлсем сукрана-сукрана пәрдәләрен тартып куйды.

Ул арада ишектә пыялачы күренде, буш чиләк тоткан Мәһирә аңа ияргән иде. Ул «Абзый!» дип пыялачыга эндәште һәм, авыр сулап, алъяпкыч кесәсеннән унлык акча чыгарды. Пыялачы акчаны алгач, кая куярга аптыраган шикелле, кулында әвәләгән арада, Мәһирә япа-ялгыз яшәвен, үзенең трамвайда кондуктор булып эшләвен, малайны көндезләрен генә түгел, төннәрен дә ялгыз калдырырга туры килүен, ата кулы җитмәвен сөйләп, зарланып алды.

Тормышта бик сирәк зарлана торган әнисенең бөтенләй чит-ят кешегә, җитмәсә, пыялачыга, үз нужасын сөйләвен ишетеп үртәлгән Һади бер читкәрәк китте. Әнисенә карамаска тырышты ул. Өй кыегына кунган күгәрченнәргә күз салган булды, дүрткел бәләкәй күк йөзеннән үтеп барган сыек болытларга үрелеп карады.

Ул борылып караганда, пыялачы эшен бетереп, корал-

ларын җыештырып тора, әнисе сыңар чиләк белән бөгеләсыгыла су күтәреп кереп бара иде. Менә Маһирә чая Һадины кысрыклаган почмакка җитте. Эсседән эреп, түбәдән аккан сумалалар чуарлаган шома ташлар арасында зәңгәр сәдәфне күреп алды. Ул чиләген куймыйча гына сәдәфкә үрелде, вакытсызрак өлкәнлек өретелгән йөзенә саран гына кызыллык йөгерде. Тол хатынның күңеле тулды, ул каптыр-кыптыр атлый-атлый тар ишеккә кереп югалды...

Бу бәләкәй сәдәфнең Маһирә өчен зур тарихы бар.

Өйләнешкән елны ук ире Әхтәри сигезенче мартка дип Маһирәгә зәңгәр күлмәк бүләк иткән иде. Шул күлмәкнең җиң очында иде инде ул сәдәф. «Бигрәк яратам, карчык, шушы күлмәгеңне!» дия торган иде Әхтәри. Ләкин аларның бергә яшәү гомерләре аз булды. Әхтәри сугышка китеп барды. Маһирә сугыш елларында күп кыенлыклар, кысанлыклар кичереп, артык-портык әйберләрен генә түгел, рәешкә асраган кием-салымын базарга илтсә дә, зәңгәр күлмәген бик кадерләп саклады. Ел саен яз да, көз дә җилләтеп алып керде. Әхтәридән дүрт ел эчендә сирәк кенә килеп торган өчпочмаклы кадерле хатлар белән саклады ул аны.

Кырык дүртнең көзендә яраланган Әхтәри тылдагы госпитальдән фронтка үтеп барышлый туган шәһәрендә бераз кунак булып чыкты.

Ире кайткан көннәрдә, Маһирә, зәңгәр күлмәген киеп, җиңеләеп, яшәреп йөрде... Төш кебек кенә булып калган бу кыска очрашуның өн икәнлеген раслап, аларның уллары Һади туды. Үзе кебек үк зур күзле, олырак авызлы, томрап торган улы дөньяга килгәндә, Әхтәри Берлин янында, бәләкәй генә зиратта, чит илнең салкын туфрагында ята иде инде...

Озак көтте Маһирә ирен. Зәңгәр күлмәген әллә ничә яз җилләре, көзнең саран кояшлары киптерделәр. Кояшяңгырдан уңып беткән кырык төенле кер бавында җилләтергә соңгы елларда нибары шул зәңгәр күлмәк кенә калды. Түзмәде Маһирә, соңгы өметләрен яндырып, ул күлмәген дә кия башлады. «Исән-аман кайтып җитсә, әллә нинди күлмәкләр юнәтә торган ир әле!» дип юатты ул үзен. Зәңгәр күлмәк тузып, итәкләре, җиңнәре сизери башлагач, Маһирә аңардан вак-вак капчыклар текте. Әхтәри ранный булып ятмыймы, берәр җирдән хәбәре килмәсме дип соңгы акчаларына сатып алып шул капчыкларга кипкән өрекләр, урман чикләвекләре тутырып тотты.

Өрекләр ашалды, чикләвекләрнең истәлеге булып урындык башларында бәләкәй чокырлар калды. Чикләвекләр белән тәгәрәп Маһирәнең улы үсте. Зәңгәр капчыклар тузып, өстәл сөрткеч тастымалларга әйләнделәр.

Тик җиң очындагы сәдәфләрне саклый иде Мәһирә. Улы үсә төшкәч, күз алдында булсын дип, аның күлмәк изүенә таккан иде ул аларны. Бала ананы аңлыймыни соң ул?! Әнә бит, югарыга караган да каткан... Мәһирәнең улына рәнҗисе бик килде, тик теле әйләнмәде, ул, күлмәк итәкләренә су чайпалта-чайпалта, ачы кәбестә исе аңкыган ярым караңгы коридорлар, кухнялар аша үтеп бүлмәсенә кереп югалды.

Пыялачы эшен бетергәч, йөнтәс кашларын күтәреп, малайларга карап торды. Аннары ишегалдына күз салды. Тар иде ишегалды, ә малайлар бик күп, артык күп иде...

Авыр тимер капкалары як-якка кыйшайган таш баганалар янына барып җиткәч, пыялачы тагын артына борылып карады. Башка балалар кайсы кая таралышканнар, нидер кычкырышып уйнап маташалар, борыны купшакланган, дәү күзле, олырак авызлы малай гына, кулын зурларча артка куеп, аңа карап тора иде. Ямаулы күлмәгенең ачык изүеннән ябык күкрәк сөякләре күренеп тора.

— Әй, малай! Монда кил әле!

Һади сәерсенеп як-ягына каранып алды.

— Син инде, син!

Капка янына килгәч, пыялачы күрде: малайның аяклары тояктай каткан. Пыялачы тын гына аңа карап торды да бая Мәһирәдән алган унлыкны кире суздым:

— Бар, әниеңә кертеп бир.

— Кирәкми, абый.

— Ал инде, ал!

— Алмыйм. Мин озакламый үзем эшли башлыйм.

Пыялачы көчләп диярлек малайга унлыкны тоттырды һәм кабаланып урамдагы кешеләр арасына кереп югалды. Ара-тирә аның киң җилкәсенә җай гына атланган дәү тартма гына күренеп китте.

Унлыкны учына йомарлап, малай шактый озак басып торды. Кызган ташлар кайракланган аяк табаннарын рәхәт кенә иркәлиләр иде. Ул Сәйфуллиннар турысына күз салды, тузан кунарга өлгермәгән яңа өлге ялтырап, башкалардан аерылып тора иде.

Ул ишегалдына атлауга, ачык тәрәзәләрдән шөпшә кебек озын бармаклар сузылдылар:

— Әнә сугыш чукмары кайтып бара!

— Әнә тәрәзә ватучы!..

Дәшми-тынмый гына үтеп китәргә уйлаган Һади ике кызны комга төртеп екты, алар акыра башлагач, унлыкны кысып тотып, чатыр-чотыр чабып бүлмәләренә кереп китте.

Бусагада юаш кына басып торган улын Мәһирә кочаклап ук алды. Шелтәләргә теләде, булдыра алмады. Муенына тамган кайнар тамчылардан сискәнеп китте малай.

— Җылама, әни! Моннан болай ватмам шуларның тәрәзәләрен,— диде ул.

— Әй, улым, улым! Бигрәк тар шул уйнар урыннарыгыз...

Маһирәнең күзе улының аягы янында яткан унлыкка төште.

— Бу нәрсә тагын?

— Теге абый бирде.

Таный аны Маһирә, таный... Шул унлык икән шул...

Ананың күңеле тагын да нечкәрә төште, ул Һадины тагын да кысыбрак кочаклады:

— Алай шукланырга ярамый бит, улым... Ярамый. Әтиең дә яратмас!

Кояшның чыгуын да, баюын да ишегалдында бер чагында да күреп булмый. Әмма караңгылык бер ашыкса, бик тиз иңеп, тәрәзәдән тәрәзәгә йөреп утлар алдыра. Кемнәрдер эштән кайталар, кемнәрдер эшкә бара, ишегалдында зурлар хәрәкәте.

Кич җитүгә, Маһирәнең тынычсызлыгы арта төшә: баланың өстеннән бикләп, төнге сменага эшкә барырга кирәк. Ул шыпырт кына аңа ашарга-эчәргә әзерли, саран гына сүзләр белән аны үгетләргә керешә:

— Ары-бире сугылма, тамагыңа аша да ятып йокла!

Әнисенең аяк тавышлары тынуга, Һади ипи белән сөтне ялт иттерде дә салкын су белән генә чынаяк чокырын юып куйды. Шуның белән эш, мавыгулар бетеп тә китте. Ул әрле-бирле йөренде, карават астыннан тычкан тәбесе тартып чыгарды, кире куйды һәм урынга менеп ятты.

Кайдадыр еракта зыңгылдап трамвайлар узды. Күкне шаулатып самолет үтте. Әмма ул арыган иде, авызын тәмләп чәпелдәтә-чәпелдәтә җәйрәп, рәхәтләнеп йокыга да китте.

Шәһәр уртасына утырган ишле кешеле бу йортның башка тәрәзәләрендә дә берәм-берәм утлар сүнде. Доминочылар китүгә, ишегалдына парлылар кайтты. Алар караңгырак почмакларга, аулаграк урыннарга басып үбешәләр. Ап-ак пәрдәләр эленгән тәрәзәләр аларга кул болгый. Белеп кенә булмый, хуплыйлармы алар парлыларны, әллә ашыкмаска өндәп кисәтәләрме? Егет кызны ныграк кочаклый һәм тәрәзәләр ишетмәслек итеп кенә:

— Бүлмә тапкач та өйләнешәбез, җаным! — дип пышылдый...

## 2

Һади кызган май исенә уянып китте. Яп-якты! Әнисе, эштән кайтып, майлы таба тирәсендә булаша. Малай сикереп торган уңайга бер-ике коймакны элдерде дә томырылып баскычтан урамга атылды. Күрше карчыгы су

алып керә икән, җан-фәрманга атылып барган Һади бүксәсе белән чиләккә бәрелде. Карчык сукранып тормады, ябык йодрыгы белән малайның җилкәсенә кундырды. Һади шул шәпкә ишегалдына очты.

Тик юеш чалбар белән кеше күзенә күренергә ярамый... Ул тиз генә Сәйфуллиннар тәрәзәсен карап килергә һәм өйгә керергә ниятләде. Ишегалды уртасына җитүгә, аның күзе кичтән доминочылардан калган таякка төште. Юан, шоп-шома, әйбәт таяк... Тукта әле. Бу таяктан уенчык тәрәзә рамы ясап җибәрсәң!.. Пыяла да тапсаң...

Ул як-ягына каранды да, таякны элдереп, һәрвакыт ачык авызлы ишеккә чумды. Коймак тирәсендә әвәрә булып йөрүче Маһирә күрми дә калды, малай таякны ялт итеп караватастына шудырды. Күрмәве хәерлерәк, йә ачулана башлар... Тәрәзәне Һади әнисе югында ясап куяр... Соңыннан, әзер булгач кына күрсәтер. Менә мактар инде әнисе!

Ашап-эчеп алгач, Маһирә йокларга ятты. Шуны гына көтеп торган Һади таякка ябышты, тырышып-тырмашып аны дүрткә ярды һәм эшкә керešте.

Дөп-дөп йөргән аяк тавышлары Маһирәне тәмле йокысыннан уяттылар. Күзен ачса, бусага янында дүрт-биш кеше басып тора. Идәндә йомычкаларга, чыраларга күмелеп, киселгән чәнчә бармагын кысып улы Һади утыра.

— Менә күр инде!

— Шул малай актыгы алгандыр дип әйттемме мин сезгә?

— Нәрсә булды тагын? — дип сорады Маһирә, карават башындагы яулыкка үрелеп.

— Нәрсә булсын! Менә Сәмигулла абзый таягын ишегалдында калдырган. Синең малаең шуны урлаган.

Юаш, басынкы Сәмигулла карт бер читтәрәк тора һәм бу шау-шуны кузгатуына үкенгән сыман сакалын тарткалый иде.

— Син, Өммегөлсем килен, алай димә әле... Сабый кызыккандыр да алгандыр диген.

— Мин тәрәзә ясыйм, — диде малай, зур күзләрен мөлдерәтеп.

Өммегөлсем дәррәү чәрелдәп кычкырды:

— Ясый, һе, кара әле берәүләрне!

— Син тәрәзәләрне вата гына беләсең!

— Синең ишеләрдән гомергә игелек буласы юк!

Ачык тәрәзә турысына бөтен ишегалды җыелды. Сәмигулла акрын гына Маһирәләрдән чыгып китсә дә, ярсыган хатыннар тиз генә тыела алмадылар. Малай, әнисенең яшь белән чыланган яңакларына карап, калтыравыклы тавыш белән:

— Мин чыннан да тәрәзә ясыйм, әни. Менә рамнары. Менә...— диде.

Ниһаять, бүлмә тын кала. Маһирә улының киселгән бармагын ак чүпрәк белән бәйли, аның яшь тулы күзләрен күреп кочаклап үзе дә елап җибәрә:

— Алай ярамый бит инде, улым! Ярамый...

Кич белән Маһирә тагын эшкә китә. Малай аның җыенуын сүзсез генә күзәтеп торды да:

— Әни, бүген ишекне бикләмә инде. Мин ишегалдында аз гына уйныйм да керәм,— диде.

— Ярамый, улым.

Маһирә бер шешә сөт белән бер кисәк ипине сумкасына салды.

— Әни...

— Ярамый, улым...

— Печтик кенә, нәни генә уйныйм.

— Азга гына түз инде. Менә ике көннән көндезге сменага күчәм. Үзеңне ботан бакчасына алып барырмын. Арысланнар китергәннәр, ди.

— Арысланнар? Әй, читлектә бит алар!

Малай, өметсезләнеп, ишеккә карый, нәни йодрыкларын йомарлап күз тирәләрен уа. Менә теге якта йозак чылтырый һәм Маһирә апа соңгы кат улына эндәшә:

— Улым, әйбәт кенә бул.

Менә ул почмактагы ярыкка ачкычны яшерә, иске туфлиләре ямьсез шыгырдыйлар.

Ишегалдына чыккач, Маһирә тәрәзәгә борылып карады. Юк, Һади үпкәләгән, күренми...

Күңелсез кич җитә. Һади әйләнә, тулгана, мендәрен изеп бетерә, тик йокы һаман килми. Урамда чыр-чу, зыңгылдап трамвайлар үтеп китә. Менә күрше карчыгы да кереп килә. Малай атылып ишек янына бара.

— Апа-у!

— Нәрсә бар? — дип сорый кырыс тавыш.

— Почмакта, примус астындагы ярыкта ачкыч бар. Ишекне генә ач инде, апа.

— Кая барасың?

— Монда гына, монда гына, апа!

Аяк тавышлары ерагая:

— Өеңдә генә утыр!

Малай, кеше үткәнен көтеп, колагын ишек ярыгына куеп бик озак бусагада утыра. Тырнаклары белән ишекне тырнап, чиртеп карый.

Тәрәзәдән айлы төн бүлмәгә карый. Тамчылы гөлнең хисапсыз күп алкалары көмештән коелгандай ялтырыйлар. Шундый көмеш алкаларың булсын икән дә, шуларны әниеңә бүләк итсәң икән!.. Малай, бер тамчыны өзеп

алып, учында уып карый. Аннары гөл чүлмәкләрен бер кырыйга этеп, түше белән тәрәзә төбенә ята.

Тәрәзәләрдә бер-бер артлы утлар сүнәләр. Почмакларда егетләр, кызлар тора. Малайның дәрте, теләкләре күкрәгенә сыймый, аның бу тәрәзәләр белән чуарланган ишег-алдыннан читкә, еракка китәсе, теләгәнчә уйныйсы, чабасы, йөгерәсе килә. Ашыгып ишеккә килә, ябык иңнәре белән этеп карый. Аннары, ачуы кабарып, мич алдыннан ярты кирпеч табып ала, тәрәзә каршысына килә. Каршыдагы сары тәрәзәдә кемнәрнеңдер шәүләләре уйный. Малай тешләрен кыса да бар көченә кирпеч кисәген тәрәзәгә тондыра... Шәүләләр куркышып сикерәләр...

«Челтер-р!» иттереп пыяла коелган тавыш яңгырый. Кемнәрдер тап-топ чаба башлыйлар. Ярты сәгать үтәр-үтмәстән ишег алдында милиция сыбызгысы яңгырый.

Малай карават астында бөгәрләнеп ята. Ишек бикле шул, ача алмыйсыз!.. Ә ачкычның кайда икәнен ул сезгә гомергә дә әйтмәс!..

## 3

Маһирә икенче көнне улын урамга бөтенләй чыгармады. Ана баласы өчен чын-чынлап куркуга төште. Әллә ишегалдындагыларның сүзе раска чыгамы, хулиган, башкисәр булып үсәме әллә аның улы? Өй эчендә ифрат тыңлаулы, хәленнән килгәнчә әнисенә булышып, ярдәмләшеп йөрүче бала ишегалдына чыккач нигә үзгәрә?..

Балалар бакчасына урнаштыра алмады шул ул аны! Яңа квартира да кайчан бирерләр әле. Ни дисәң дә, кысан булса да, торыр куышыгыз бар, диләр...

Ә тол калып, мең хәсрәт белән күз текәп үстергән бердәнбереңюньсез булып чыкса нишләрсең? Нинди чараларын күрергә, нишләргә инде ялгыз анага?..

Һади, әнисе алдында гаебен сизенеп, тын гына юнышып утыра. Утыра торгач, аның түземе бетеп китте, малай киерелгәләде, сузылгалады, тәрәзә яныннан әйләнеп килде. Каршыдагы квартирага пыялачының килүен көтә иде ул. Әллә аның оста кулы, әллә аталарча ягымлы карашы малайның йөрәгенә төшеп калган иде.

Пыялачы төш вакытында гына килде. Каршы квартирада хәрәкәт башлануыннан сизде моны малай. Әнисе ял итәргә яткан иде. Ул, аңа сиздермәскә тырышып, тәрәзә янына килде һәм пәрдә почмагын ачып күзәтә башлады. Менә тәрәзә ачылды, менә ике кул сузылды. Менә пыялачының башы күренде. Ул түгел лә бу!

Малайга кинәт кенә күңелсез булып китте. Кичәге абый нигә килмәгән инде? Ай-яй оста эшли иде. Моны-

сы аның кебек үк булдыра алмый торгандыр әле, мөгаен. Берәр почмакта ярык калдырыр да китәр әле менә. Монысының да алмазы шулай ялтырый микән? Юк, кичәге абый кебек керт итеп кенә кисеп төшерә алмас бу, тотынуы ук башка бит тегенең. Их, шул абыйга ияреп йорттан йортка пыяла куеп йөрисе иде!

Үз башына килгән бу дуамал фикердән малай тынычлыгын җуйды. Гөл сабакларын сындыра-сындыра тәрәзә төбенә үк менеп, пыялачының ялтыр-йолтыр маташканын карап тора башлады. Теге абый ник килмәде дип кычкырыргамы әллә? Әнисе уяныр инде...

Пыялачы эшен бетереп, тәрәзәне ябып куйды. Һадига кызык та бетте. Ул яңадан чыралары, йомычкалары янына килеп утырды. Аның эче поша, кулы кычыта, аяк табаннары кымырҗып тора иде. Ул, нәүмизләнеп, ишеккә карап алды. Әнисе иртән: «Ишетсен колагың, бусаганы атлап чыгасы булма!» — дип кисәткән иде.

Ялт итеп кенә чыгып, теге абый турында сорашып керсә? Әнисе сизми дә кала ич!

Һоп лә! Баскыч араталары шыгырдарга да өлгерми калдылар. Һади бала-чага өерен ерып уртагарак чыкты да күрше кызыннан:

— Пыялачы абый сездә чәй эчеп утырамы әллә? — дип сорады.

— Белдең,— диде кыз.— Ул әллә кайчан китте инде.

Малай бер секунд уйланып тормастан капкага йөгерде. Пыялачы урамда да күренмәде. Сорап кала алмавына әрнегән малай кичәге абый киткән якка карап чаба башлады.

Сулуы кабынды, урам ташлары ялан тәпине чагып авырттырдылар. Һади әллә никадәр абыйларны, апаларны куып узды, тик җилкәсенә агач тартма утырткан кеше күренмәде.

Бер бакча янындагы су сатучы янына җиткәч, малай туктады. Кипшергән иреннәрен ялаштырып карап торды да кеше юграк вакытта су сатучы янына килде.

— Апа, пыялачылар кайда эшли, белмисезме?

— Нинди пыялачылар?

— Тәрәзә пыяласы куючылар.

— Каян белим ди мин? Әнә тегендә йортлар салалар, шунда эшлиләрдер.

Малай башын иеп борынын тартты:

— Апа, буямыйча гына бер стакан су эчерт әле.

— Акчаң бармы?

— Юк.

Хатын, сыек кына кызартып, малайга бер стакан су сузды.

— Әтиеңнән алгач килеп түләрсең.

Малай йотлыгып суны эчеп бетерде:

— Озакламый үзем эшли башлыйм мин!

— Әллә?

— Рәхмәт!

Һади чаба-чаба тукталышка килеп җитте.

Иң кирәген — йортлар сала торган җиргә трамвай белән барып булуын ул белеп алган иде инде.

Шактый бардылар. Вагондагы кешеләр әллә ничә кат алышындылар. Ахыргы тукталышта Һади төшеп калды. Зур-зур күтәрү краннарын, дәү-дәү йортларны, әллә нинди машиналарны күргәч, малай авызын ачып катты да калды.

Йортларның инде салынып бетеп килгәннәре дә, ярты юлдагылары да бар иде. Машинага төялгән кызлар Һадига кул болгап кычкырып уздылар. Йортлардагы йөзләрчә тәрәзәләрне күргәч, ул бөтенләй югалып калды. Тәрәзәләрдә кешеләр, өстә кешеләр, аста кешеләр... Исемен белмәгән килеш пыялачыны каян эзләп табасың монда? Былтыр ботан бакчасында әнисеннән аерылып калып та аһ иткән иде.

Һади кая барып керергә белмичә ары-бире сугылды, экскаваторның җир казыганын күзәтеп торды. Якында гына үз исемен ишеткәч сискәнеп китте.

— Һадимы? Нишлисең монда?

Күр син аны, былтыр көз генә Һадилар йортының икенче катына күчеп килгән Зиннур абый монда эшли икән. Малай, күзен елтыратып, кача башлаган иде, Зиннур аның җилкәсеннән элеп алды.

— Тукта, тукта! Кая качасың, җүләр? Мондарак кил. Кемне эзлисең? Әйт!

Малай ык-мык итте дә сөйләп бирде. Аның йомышын ишегалдында үтә коры, усал күренгән Зиннур елмаеп тыңлады, аннары аңлатып бирде. Шәһәр уртасында «Ремстройконтора» дигән җир бар икән, ватык өлгеләрне шундагы пыялачылар куя икән. Зиннур төшендереп кенә калмады, малайның аркасын сөеп, трамвайчыларга атап салына торган йортны күрсәтте, соңыннан, кирпеч китергән машинаны туктатып, малайны кабинага утыртып җибәрде.

Һадига да бәхетле көн килер икән! Шофер да егет кеше икән, аны выжт иттереп алып барды, тиешле урында төшереп калдырды. Кызганыч, малайлар күрмәде, сөйләсәң... валлаһи, ышанмаслар! Зиннур абыйсы аның тәрәзә кырып йөрүен дә белә икән, саубуллашканда:

— Син алай тәрәзә кырып йөрмә! Дәү үскәнсең инде,— дип калды.— Контора бусагасын үтүгә, аны тәбәнәк кенә бабай туктатты:

— Әй, малай, ник ураласың монда?
— Пыялачы абыйны эзлим.
— Тәрәзәгезне ваттыңмы?
— Юк ла, болай кирәк иде.
Карт шунда ук кырысланды:
— Болай монда килеп йөрмиләр. Бар, бар, чык! — диде.
Һади киреләнде:
— Чыкты диярләр. Миңа пыялачы абый кирәк!
— Ват Ходай кошы! Кайсысы кирәк? Алар монда унлап, йөзләп!

Карт бераз гына арттыра иде. Малай пыялачының кыяфәтен сөйләп биргәч, ул башын чайкады һәм ачы төтенле челемен суыра-суыра уңга кереп китте. Бераздан кире чыкты һәм эндәшмичә генә үз урынына — барьер артына кереп утырды. Малай сораулы күзләре белән аңа текәлде.

— Юк ул бүген. Килмәгән. Килми дә. Ишеттеңме? Фәхриев абыең була инде ул.
— Кайда соң ул?
— Больницага кергән.
— Больницага?
— Әйе. Пыяла куярга барган икән дә, синең кебек бер тузга язмаганы ул менгән баскычны аударып җибәргән. Аягын сындырган Фәхриев.
— Бабай,— диде Һади, еламсырап,— кайсы больницада икән?
— Мин каян белим.
— Бабакай...
— Бар, бар, мыек чуалтып йөрмә әле монда.

Карт, ачуланып, аралыгына кереп китте. Аралык артындагы гыжылдавык сәгать дүртне сукты! Сәгать дүрт! Әнисенең эшкә китәр чагы җитә! Һади баскан урынында тыпырчынды.

— Китмәдеңмени әле син?

Малайның яшьле күзләрен күреп, карт сукрана-сукрана тагын уңга кереп китте.

— Җиденче больницада. Беләсеңме, теге Чкалов урамында. Очучы Чкаловны беләсеңме?..

Больницада Һадины бөтенләй санга алмадылар. Керту кая ул, якын да җибәрмиләр, усал-усал апалар куып ук чыгардылар. Тагын әйләнеп керде Һади. Апалар бу юлы кумадылар, аның чебиле аякларын бер-берсенә күрсәтә-күрсәтә көлештеләр. Кемең ул Фәхриев, этиеңме, фәлән-фәсмәтән дип сораштылар. Ул арада эчке бүлмәләрнең берсеннән өлкәнрәк хатын чыкты. Аны күргәч, мондагылар авызларын җыйдылар. Шул апа Һадины Фәхриев янына кертергә кушты.

Бүлмәдә иң элек ул зуп-зур тәрәзәләрне күрде. Ай-

яй олы! Ишегалды ап-ачык күренеп тора! Ишегалдында агачлар, чәчәк түтәлләре.

Ә менә Фәхриев абый да монда! Ул аркасын мендәргә терәп яткан да елмаеп карап тора. Бер аягын әллә ниләр белән бәйләп, урап бетергәннәр.

— Бер малай дигәч, кем икән дип аптыраган идем. Син икәнсең,— диде ул, исе китмичә генә.

Ул, кар кебек ак җәймәләр арасыннан кытыршы, дәү кулын чыгарып, малайның кояшта уңган җитү чәчен сыйпады.

— Килдеңме?

— Килдем.

Малай кат-кат борынын тартып куйды.

— Ни атлы әле син?

— Һади.

Малай пыялачыга туп-туры карады.

— Ә син Фәхриев абый.

Пыялачы тагын көлемсерәде.

— Авыртамы, абый?

— Печтик кенә. Кул ныграк авырткан иде.

— Анысын кайда кистеләр?

— Анысын... Берлин янында.

Малай, Берлин дигәнен ишеткәч, тагын ишегалды якка карады. Анда, түтәлләр арасында, ак халат кигән хатыннар йөриләр иде. Баягылар түгелме? Күреп, Һадины ачуланмаслармы?

— Ай-яй тәрәзәләре зур! — диде малай, шаккатып.— Нигә болай олы иткәннәр инде?

— Зур,— диде пыялачы, малайның башыннан сыйпап.— Сиңа ошамыймы әллә? Яратмыйсыңмы?

Малай, яратмавын раслап, башын чайкады. Аларның ишег алдында мондый зур тәрәзәләр булса, бөтенләй аптыраш булыр иде. Пыялачы исә үз янында кечкенә малай утырганын онытып җибәрдеме, әллә уйланып яткан фикерләрен әйтергә җай чыктымы, тәрәзәләргә карап сөйли башлады:

— Әйбәт ул зур тәрәзәләр!.. Бүлмәләр якты була. Аннары тыш та ап-ачык күренеп тора. Тәрәзә каршында бакча да булса, ә, Һади!.. Кешене тышкы дөнья белән бәйли бит ул тәрәзә... Шуның өчен зур булсыннар алар. Тәрәзә алларында бакчалар, гөлләр булсын...

Малай эндәшмәде, ул, мышык-мышык борынын тартып, пыялачыдан күзен алмый иде. Менә пыялачы тумбочка өстеннән бер телем ипи алып аңа тоттырды:

— Аша, ачыккансыңдыр.

Һади, ап-ак тешләрен икмәккә батырып:

— Тәмле! — диде.

Икмәк телеме күз ачып йомганчы юк булды.

Пыялачы җылы кулы белән аның башыннан сыйпады.

— Ә хәзер бар, өеңә кайт. Әниең борчыла торгандыр. Син аны борчымаска тырыш, сакла. Син ир-ат!

— Иртәгә тагын килимме? Минем синең белән эшлисем килә, Фәхриев абый. Күп итеп акча аласым килә.

— Акча белән нишләр идең? — дип кызыксынды Фәхриев.

— Әнигә зәңгәр күлмәк алыр идем... Күчтәнәчләр.

Пыялачы сүзсез генә башын иде. Һади, халат итәгенә уралып, коридорга ташланды. Әнисе югалткандыр инде аны! Зәңгәр күлмәк хакында белгәч, әй сөенер инде!

Фәхриев абыйсы:

— Ишек пыялаларын ватма! — дип кычкырып калды.

Малай, халык белән кысыла-кысыла, вагонга керде, кондуктор билет алырга кушкач, эре генә:

— Минем әни үзе кондуктор! — дип җибәрде.

Аңа тимәделәр. Ул вагон почмагынарак басты да әнисен дә, тизрәк кайтырга кирәклеген дә онытып, ике яклап артта кала торган йортларга карады. Үзе дә сизмәстән йорт тәрәзәләрен санарга кереште. Бара-бара тәрәзәләрнең чутына чыгарлык түгел. Кинәт аның теле тотлыкты, саннары буталды, ул чәнечкеле тимерчыбык белән уратылып алынган ике катлы төссез йорт тәрәзәләренә карады. Төрмә тәрәзәләре тышкы яктан такта козыреклар белән томаланган иде. А-а, күпме алар... Такталар артында пыяла тәрәзәләр булса да, алар урамны да, кешеләрне дә күрсәтмиләр булыр. Томаланган тәрәзәләр, сукыр тәрәзәләр...

Әгәр Һади Һашимны белсә, ул аның нык-нык басып, туп-туры карап төрмә капкасыннан чыгып килүен күрер иде. Һашим шушы йомык күзле төрмәдә утыз өч ел гомерен калдырып пенсиягә чыккан иде...

*1960, Казан*

# Өч тәгәрмәчле арба

## 1

Рәшат, өчәр аратаны берьюлы сикерә-сикерә, ә дигәнче икенче катка менеп җитте. Үз квартирасының ишеге төбендә звонок төймәсенә басып торучы хатын-кызны күргәч, сискәнеп шып туктады.

Бер кулына җыйнак кына чемодан тоткан хатын озын буйлы иде. Ул, Рәшатның аяк тавышын ишетеп, борылып карады, аннары иренеп кенә тагын төймәгә үрелде.

— Әллә өйдә юклар инде,— диде ул, тагын Рәшатка таба әйләнеп. Хатынның кара-кучкыл битенә арыганлык, талчыгу чыккан иде.

— Сезгә... сезгә кем кирәк соң? — диде Рәшат, тотлыгып.

— Сәләевкә телеграмма,— диде хатын, шактый җансыз тавыш белән.

— Сәләев мин булам! — диде Рәшат, җиңеләеп.— Рәшат Сәләев!

Хатын аска төшеп киткәч тә, Рәшат беравык хәл алып торды. Бераз җиңеләйгәч, ул ишек ачарга тотынды, ачкыч тишеген таба алмый йөдәде, тапкач, ачкычын кирегә борып маташты, кергәч, ишек катындагы башмакларга абынды. Үз хәләте көлке кебек күренде, елмайды, телеграмма гына эчне пошырып өстәлдә ята иде.

Ул тагын авыр сулады.

Бүген беркемнән дә телеграмма аласы, үзен башка дөнья, башка кешеләр, аларның кайгы яки шатлыклары белән бәйлисе килми иде аның. Бәйрәм-сәйрәм дә түгел, туган көне дә бик ерак, килү-китү дә көтелми иде, кемнән булыр икән бу кирәксез хәбәр?

Теге озынча буйлы, кара тутлы йөзле хатынны кинәт күреп өрекмәгән булса, телеграммага һич тә исе китмәс иде аның. Ниләр булмый бу дөньяда? Таныш-белешләре, бергә укыган иптәшләре, дус-ишләре азмы әллә аның?

Йомыш төшкәндә, барысы да Рәшат дип килеп-китеп торалар ич...

Уф, теге апа аны нык кына куркытты!.. Тәмам хәле китте.

Рәшат графиннан җылымса, тәмсез су салып эчте, якасын чишеп, күлмәк изүе белән җилләнеп алды. Йонлач, таза күкрәкләре тирләгән иде. Астан:

— Рәшат! — дип кычкырган уенчак тавыш килде.

Ул шунда гына телеграмманы сүтеп карады.

*«Уналтынчы майда сезнең шәһәрдә булам. Өйдәрәк торырга тырыш. Сине күрәсем бар. Әниең».*

Баягы тавыш тагын да иркәләбрәк:

— Рәшат! — дип кычкырды.

Егет, телеграмма кәгазен селкә-селкә каударланып, бер ишеккә, бер тәрәзә янына килде:

— Хәзер, хәзер чыгам! — дип кычкырды.

Ә үзе ашыкмады, урындыкка утырды, тагын бер кат телеграмманы укып чыкты, адресын карады, кайсы шәһәрдән, кайсы вакытта бирелүен тикшерде. Барысы да дөрес иде...

— Рәшат, Рәшат!

Ул әйләнеп чыкканда, Луиза беренче кат белән икенчесе арасындагы баскыч мәйданчыгына менеп җитеп, бик гаҗәпләнеп өскә карап тора иде. Ярым караңгыда кыз искиткеч матур булып күренде Рәшатка. Аның очлырак нәфис ияген чак кына алгарак сузып, башын артка чөеп кыланыбрак торуында ниндидер яшерен чакыру, дулкынландыргыч ымнар бар иде. Юка күлмәге аның йопйомры иңбашларын, күңелгә кытык атып торучы калку күкрәкләрен аермачык белдереп тора.

Егет, кызның чибәрлеген менә әле генә бәяләп бер мизгел аңсыз-өнсез карап торды да, акрын-акрын аска төшә башлады. Луиза янына җиткәч, Рәшат авыр гына көрсенде. Луиза исә, рәхәтләнеп, көлеп алды.

— Нигә плащыңны калдырмадың, Рәшат? Әллә радиодан тагын яңгыр вәгъдә иттеләрме?

Җавап урынына егет кызга телеграмманы тоттырды.

— Телеграмма? Кемнән?

— Укы,— диде егет, кырыс кына.

Кыз бераз гына күрә карау булса да, «йөзне боза» дип, күзлек кими иде. Ул, озын керфекләр белән каймаланган үтә ялтыравыклы соры күзләрен кыса төшеп, телеграмманы укып чыкты.

— Синең белешләрең арасында да наяннар бар икән! — диде Луиза, яратмыйча.

— Нигә?
— Тапканнар инде шаярыр сүз!
— Шаяру юк монда.
— Ничек?!
— Шулай. Барысы да дөрес.
Алар җитәкләшеп аска төштеләр, ишегалды бакчасына чыктылар. Көн сокланырлык дәрәҗәдә әйбәт иде. Әле кичәле-бүгенле генә ачылып маташкан яфраклар чипчиста, нәфис иделәр. Сукмакларга әле генә сибелгән ком, алтын сыман, сап-сары иде. Сукмак кырларына куелган утыргычларның зәңгәр лагы кояшта ялтырый, кызның кибән ясап куйган мул, матур чәчләре нур төшеп янып тора. Луиза дулкынлана, ләкин, читкә караган булып, үз хәлен егеткә белдермәскә тырыша иде.
Нигә шушы кадәр сылу соң бу Луиза, дип зарланды Рәшат эченнән генә. Утызга җитеп килә торган, акыл утырткан, төчесенә караганда тормышның ачысын мулрак эләктергән егет, башкалар чуар күңелле җилбәзәк дип санаган, куркыныч матурлыкка ия булган шушы кыз белән ничек таныша, дуслаша алды икән?
Башка вакытларда Луизаның күзгә бәрелеп торган чибәрлеге белән эчтән генә горурлана торган егет бүген кызның үтә күркәм булуыннан шүрләп калды.
Ни булды әле аңа? Нигә шулай телсез-өнсез җебеп төште? Луиза аннан нидер көтә ич. Бер атлый да борылып астан гына аңа күз сала. Сүз көтә, аңлату көтә, аңлашу көтә! Рәшат, кыюланып, аңа таба атлады.
— Луиза, без соңга калабыз.
Кыз, егет күрсен өчен юри кискен хәрәкәтләр ясап, кулындагы кино билетларын вак-вак кисәкләргә ертып һавага чөеп җибәрде, учы белән күзен кояштан каплап, чуар күбәләкләрнең талгын гына җиргә төшүләрен карап торды.
— Мин синең белән беркая да бармыйм.
— Алайса шушында утырып торыйк.
Кыз нидер уйлап алды да алгарак чыкты, кырыйдагы аулак эскәмияне сайлап шуңа барып утырды. Буяулы такта җып-җылы иде.
— Йә, әйт, нигә яшердең син аны миннән? — диде Луиза, тиз-тиз. Тирә-якта кеше юклыгына ышангач, шактый кычкырып өстәде. —Нигә яшердең?
Рәшат аптыраашта иде, бердән, әнисенең телеграммасы аны куаштса, икенчедән, кызның көтмәгәндә үзгәрүе, усалланып зәһәрләнүе аны гаҗәпләндерде.
— Әниеңә күрсәтерлек кыз түгел дип санийсыңмы мине? Җилбәзәк күбәләк дип уйлыйсыңмы?

— Нинди күбәләк? — диде егет, ифрат дәрәҗәдә уңайсызланып.— Ни сөйлисең син, Луиза?

Кыз сикереп үк торды.

— Утыр әле, зинһар, кузгалма.

— Утырмыйм.

Егет тә аягүрә басты, алар, бер-берсенә текәлешеп, беренче кат очрашкан ят кешеләр кебек, сынашып тордылар. Рәшат, ымсынып, кыздан ягымлы сүз, теләктәшлек көтә иде, ә Луизаның күзләрендә чамасыз ачу гына кайный иде.

Нигә Луиза үзе турында гына уйлый әле, дип эчтән хафаланды егет. Телеграмманың Рәшат тормышына да турыдан-туры кагылуын сизенмиме әллә ул?..

— Әниеңнең дөньяда барлыгын гына булса да белергә хаклы идемме? — диде кыз, нервланып.

— Әгәр минем сүзләремә ышансаң, дус итеп санасаң, бервакытта да аның хакында сорама! — диде егет, тыныч булырга тырышып.

— Ул чагында телеграмманы нигә күрсәттең?

— Үзем дә сизми калдым.

— Ха,— диде кыз, тагын кабынып,— менә ничек икән!

— Шулай килешик,— диде егет, кызга кулын сузып.

— Башта әйт: нигә миңа белергә ярамый? Безнең арада яшерен сер бармыни?

— Сорама, Луиза, газаплама мине.

Кыз, беравык тынычланып, уйлап торды:

— Ичмасам, шунысын әйт: кем гаепле монда? Әниеңме, минме?

Егет, карашын җирдән чак кына күтәреп, башын чайкады:

— Сорама, Луиза,— диде.

Луизаның йөзе агарып китте:

— Аңлашылды,— диде ул, егетнең сузылган кулын читкә кагып.— Миндә икән ич гаеп!.. Ә мин җүләр шуны аңышмый да торам. Ике ел синең белән дус булып йөрдем, өемә алып бардым, түремә утырттым. Атам, анам белән таныштырдым... Син бит аларга да: «Атам-анам юк, абый тәрбиясендә үстем»,— дидең.

— Абый тәрбиясендә үсүем дөрес.

— Ә телеграмма? — дип сорады кыз, өметләнеп.

— Ул да дөрес.

Кыз тәмам аптыраштa калды. Үртәлеп, гарьләнеп елап җибәрде. Иң гаҗәбе, башка вакытта сак күңелле Рәшат бүген аны тынычландырырга ашыкмый, кызның яшь коеп бәргәләнгәнен тын гына карап утыра иде.

— Зинһар, мине интектермә, газаплама, Рәшат. Ялганмы ул телеграмма?

Рәшат аның алдау көтүен, шуны теләвен, ялган сорап ялваруын сизде. Чынлыкны көтәргә, аны аңларга, аның, ачы хакыйкатен бүлешергә кызның теләге дә, сабыры да, көче дә юк иде. Луизаның сабырсызлыгы Рәшатны сизелерлек усалландырды.

— Юк, телеграмма дөрес,— диде ул, салкын гына.

— Дөньяда мин барлыкны әниең беләме? — дип сорады кыз, артка чигенә-чигенә.

— Юк.

— Алайса хуш!

— Луиза, Луиза! Ул мин барын да белми иде бит! Луиза!

Кыз егетнең соңгы сүзләрен ишетмәде, йөгереп агачлар арасына кереп китте, аның кибән кебек өеп куйган җирән чәчләренә батып барган кояш кунып барды, таза аксыл балтырлары сәрви куаклары арасыннан елык-ялык күренеп калды.

Чибәр иде Луиза, куркыныч бер дәрәҗәдә чибәр иде.

## 2

Моңарчы аларның мөнәсәбәтләрендә бер генә караңгы тап та, яшертен почмак та юк иде. Холкы кыркурак булган Луиза гел-гел басымчаклык күрсәтеп килде. Монда ата-анасының үгет-нәсихәтләре, бигрәк тә әнкәсенең тәэсире аз булмады.

— Тормыш болганчык су белән бер... Ата-ана балага юл күрсәтеп бирергә тиеш. Егет менә дигән. Биш бармак кебек һәр ягы килгән. Ата-анасы юк... Каенананың аруыннан да козгын тавышы чыга, диләр... Эш урыны әйбәт. Егерме алтыда группа җитәкчесе. Утызда бюро башлыгы булачак. Өйләнмәс борын квартира бирделәр үзенә. Бу бәхет кемгә тия? Син дә төшеп калганнардан түгел, нәсел-нәсәбеңне генә кара...

Кыз башта Рәшатны бөтенләй сөйми иде. Тирә-якта шома таралган чәчле, соңгы мода буенча киенгән озын, зифа егет асыллары барында төссез, моңарчы кызлар кулы тотып та карамаган Рәшат нәрсәгә ул?

Шулай да кыз ата-анасының сүзеннән чыкмады, Рәшатка ярарга тырышып йөрде. Егет артында үзенең иптәш кызлары белән аның гади кыяфәтеннән, сәеррәк гадәтләреннән, сөйләгән сүзләреннән мәсхәрәләп көлсә дә, аны «картлач» дип кенә атаса да, Луиза Рәшат алдында үзен тыя алды, тотнаклы, аз сүзле, сабыр кыз булып күренде.

Моңарчы бер егет белән йөргән иде инде ул. Бик яратып, тәмам шашып, ышанып, бөтен барлыгын биреп йөргән иде. Егет тотты да башка кызга өйләнде, хәзер очраганда мыек астыннан гына көлеп үтә...

Авызы чамасыз нык пешкән иде Луизаның. Салкын суны да өреп кабарга әзер иде ул, һәм аның салкын су дигәне шушы Рәшат иде.

Егет беркатлы, ни әйтсәң дә ышана, йомыкый гына (ничек группа җитәкчесе итеп күтәргәннәрдер аны!), тып-тыныч, салкын табигатьле, акча туздырмый торган саранрак бер кеше булып тоела иде Луизага.

Үткәндәге ачы тәҗрибәсеннән чыгып, кыз бу юлы бик сак кыланды. Үз яшендәгеләрдән соң үсеп җиткән миндаль күзле, озын аяклы кызларны ул бик яхшы күрә иде. Рәшат та аларны күргәләгәнче, егетне эләктереп калырга кирәклеген ул тәне белән дә, җаны белән дә сизенә иде. Шуңа күрә Луиза тыйнак та, акыллы да, сак та була белде.

Тик Рәшат теле белән дә, кулы белән дә тупас хәрәкәтләр ясамады. Кызның саклык чаралары уйлап куюы юкка гына булды. Ике ел дус булып йөреп, Луизаның Рәшат бүлмәсенә кергәне юк. Башта ул үзе аяк терәп каршы килде, соңра егет, кызның сафлыгына, ныклыгына хәйран канәгать булып, аны чакырмас булды.

Егет чын мәгънәсендә бәхетле иде. Аның бәхетен күрү кызга да тәэсир итте. Ул бәхетле итте бит аны, ул! Ничек кенә күңеле карышмасын, аның акылы Рәшатка буйсынды, акыл артыннан хис тә иярде. Аныңча уйлый, аныңча сөйләшә, ул яраткан киноларны ярата, ул сөймәгән кешеләрне күралмас булды.

Тик элекке гөнаһлары кызны артык юашландырды, куркакка әйләндерде. Ул егет киткәндә: «Миннән соң тагын берәрсе янына бармыйммы?» — дип, Рәшатны икешәр-өчәр квартал кача-поса сагалап озата бара иде.

Кыз күңеле теләп, ашкынып, яшерен өметләр белән егеттән бер сүз, чакыру көтте. Әмма егет ашыкмады. Яше дә җиткән, квартирасы да бар, тик аны нидер тота, ычкындырмый иде. Ул еш кына дәшми-нитми кызга озак-озак җентекләп карап тора, нидер үлчи, акылы белән хисен көрәштереп карый иде. Аның әзләнүен күреп, башта Луизаның коты чыга иде, тора-бара күнекте, егет аңа текәлгән чакларда ул гөнаһсыз, сабый күзләре белән аңа карап тора башлады.

Рәшатның эшне шулай озын-озакка сузып куюы кайчагында кызның җен ачуларын чыгара иде. Нигә сүз башламый инде, нигә кулын биреп, аны гомер юлына иптәшлеккә чакырмый?

Кыз үзе көтә, эти-әнисе көтә, иптәшләре, агай-энеләре көтә. Әтиләренең туй турында сөйләшә башлауларына әллә кайчан инде!..

Һәм, һич тә көтмәгәндә, кыз егетнең ялганын тотты. Кызның моңарчы тыелып килгән күңеле тулып ташты, егетнең ялганын тоту аңа көч бирде. Гел-гел Луиза гына үзен түбәнсетеп, баш иеп, үткәннәре өчен куркынып йөрмәсен әле. Егетнең дә яшерен эшләре бар икән!..

Чынын гына әйткәндә, егетнең әнисе бар булу Луизаны бер тамчы да борчымады. Табылдык әни кыз өчен минутлык тантанага сәбәп кенә булды. Рәшатның кызарынып-бөртенеп, мескен бер хәлдә эскәмиядә утырып калуы Луизага бик ошады.

Инде хәзер өйгә кайтырга да әнисеннән бераз үч алырга кирәк. Үзенең вак, эчпошыргыч вәгазьләре белән ул да бик туйдырды инде... Акыллы кешеләр туйдырды, аларның чама белән, сак кына яшәүләре туйдырды...

Һәм Луиза керә-керешкә кычкырып елап җибәрде.

Әнисе, Сәрвәр ханым, керләр үтүкләп йөри иде. Өй тирәсе эшләренә алар авылдан килгән ерак кардәшләре Нурҗиһан апаны тотсалар да, кадерлерәк керләрен Сәрвәр ханым берәүгә дә ышанып тапшырмый иде. Кызының елап кайтып керүен күргәч, аның йөрәге өзелеп төшкән кебек булды:

— Нәрсә булды тагын, багалмам? — диде ул, аңа каршы килеп.

— Нәрсә булсын, сезнең менә дигән «баш бармагыгыз» мине алдаган!

Әнисенең калтыранган кулларын күреп, Луиза чак кына шаркылдап җибәрмәде.

— Өйләнгәнме? — диде көч-хәл белән Сәрвәр ханым.

Өйгә көек исе чыкты, үтүк астында калган эчке күлмәк исе иде бу.

— Өйләнү тагын аңа!.. Әнисе бар икән, шул килә...

— Фу, котымны калдырмадың, мәхәббәтсез... Ай, күлмәгем яна түгелме?..

Сәрвәр ханым үтүккә ташланды, күлмәкне тартып алып бармакларын юешләп баскаларга, тигезләргә тотынды.

— Әрәм иттең күлмәгемне, мәхәббәтсез кыз!

— Ну, үзен дә кызык иттем, катты да калды, әйтер сүзе дә юк...

Сизгер ана кызының арттыруын, егет белән ике арада искитәрлек әллә нәрсә юклыгын аңлады. Тик шулай да үтүкне кер өстендә артык тотарга ярамый, исе чыгар!.. Егет белән кыз арасындагы дуслык җепләре өстенә шик-шөбһә очкыны төшмәсен...

— Нурҗиһан апа, Нурҗиһан апа! — диде ул, кухня ягына карап.— Коймак пешереп җибәр. Суыткычтан әфлисун алып куй. Чия вареньесының банкасын ачтыңмы әле?

Кызын бик әйбәтләп сыйлагач, ул җай белән генә сораштыра-сораштыра барын да белде. Иң соңыннан болай диде:

— Гомер-гомергә, борыннан бирле шулай килгән, ата-ана сүзеннән чыккан балага бәхет насыйп булмаган.

— Ә Рәшат? — дип сорады кыз, әфлисунны бүлемнәргә ваклап утырган җиреннән.— Аның әти-әнисе булмаган ич.

— Рәшатның йомыкыйлыгы каян килә дисең? Барына да шул ятим үсүе гаепле.

— Әнисе бар икән лә аның.

— Шуны ачыкларга түземең җитмәгән синең, кызым.

— Хәзер нишләргә тиеш инде мин?

Кыз нишләргә кирәклеген күптән уйлап куйса да, күптәннән килгән гаилә гадәте буенча, яхшы атланып әнисеннән киңәш сорады. Сәрвәр ханым, тастымал чите белән авыз читләрен иплəп кенә сөртә-сөртә:

— Урыныңнан торырга, юынырга, әйбәт күлмәгеңне киярга, туп-туры Рәшат янына барырга тиеш. Иелгән башны бервакытта да кылыч кисми.

— Иелгән баш йолдыз да күрми! Үзе ялынып килсен!

Кыз үзенең карарын капылтрак әйтеп ташлады, Сәрвәр ханымның тавышы шундук кисkенләште:

— Үзе дә ялынып килер, әмма тиешле вакытында син дә бара бел. Шундый чакта егетне ташлап китәләрме? Бәлки, аңа берәр бәхетсезлек килгәндер? — диде ул.— Акыллы бул!

Әнисенең «акыллы бул» дигән сүзе Луизага ни өчендер «хәйләкәр бул» дигән кебек ишетелде. Шуңа күрә ул бүген аны тыңламаска булды, өстәл яныннан кузгалды да караватка менеп ятты. Әнисе бүлмәдән чыгып китте, кем беләндер телефоннан сөйләште, тагын әйләнеп керде һәм ягымлы, йомшак тавыш белән:

— Тор, ялкау,— диде.

— Ялкау ятар, бәхете артыр,— диде Луиза, түшәмгә карап көлеп.

— Тор! — диде ачу белән Сәрвәр ханым.

Луиза чәчрәп торды да көзге каршысына барып чәчләрен рәтләде.

— Бер минут тормый Рәшат янына кит.

— Өйдә юктыр ул,— диде егет белән күрешүдән куркынып Луиза.

— Өйдә булмаса, ишек төпләрендә утыр.

— Бүлмәсенә керергә дә рөхсәтме?

— Кирәк икән — кер! Син бүген мин-минлегеңне онытып тор... Тик, кара, сак бул. Уйлап эшлә. Язмышыңны хәл итә торган көннәр килеп җиткәндер.

Сәрвәр ханымның аз гына пудраланган бите буйлап яшь бөртекләре тәгәрәде. Луизага әнисе кызганыч булып тоелды, ул, тиз-тиз киенеп, урамга чыкты...

Урамда әле җәй эсселәре башланмаганга, бераз салкынча иде. Ләкин Луизага һаман эссе сыман тоелды... Уф, ниһаять, аңа егет бүлмәсенә керергә рөхсәт. Барысына рөхсәт!.. Рәшат үзен ничегрәк тотар икән? Кочаклармы, әллә элекке кебек күзен челәйтеп сөйләшеп кенә утырырмы?

Луизаның тәне кызыша ук башлады. Таксига утырырга теләде, тирә-якта бер генә буш машина да күренмәде. Такси караштырып бара торгач, ярты юлны үтте, аннары кыз җәяү генә барырга булды. Бик ашыксаң да, акча җирдә аунап ятмый!

Авызының тәме юк иде, гастрономга кереп, «Алтын ачкыч» ирисе сатып алды, шуны суырды. Бәләкәй бакча аша үткәндә, тирда мылтык атып торучы үсмерләргә күз салды. Тегеләр дә бер-берсенең касыкларына төртешеп, хихылдашып, аны күз белән озатып калдылар.

Менә Рәшатлар йорты. Туп-туры барып керергәме? Юк, Луиза иң элек тәрәзәләр ягына чыкты. Рәшатның тәрәзәсе ачык, әмма бүлмәдә ут янмый. Кыз, кулларын авызы янында кушлап, әче тавыш белән:

— Рәшат! — дип кычкырды.

Тәрәзәдә кеше заты күренмәде. Ул тагын да ныграк итеп:

— Рә-ә-шат! — дип кычкырып карады.

Күршедәге ачык тәрәзәләргә берничә кеше тыгылды, тик егет күренмәде. Бер ханым, Луизага кул изәп:

— Өйдә ул, өйдә. Йоклап ятадыр, мөгаен,— диде.

Яңадан кычкырып тормады Луиза, үртәлеп тагын эскәмиягә барып утырды, калган «Алтын ачкыч»ын суырып бетерде. Аннары мәйданга чыкты һәм беренче очраган таксига утырып кайтып китте.

Сәрвәр ханым керфек тә какмыйча аны көтеп тора иде. Кызының сүрән чыраен күргәч, ул бер сүз дә әйтмәде. Эндәшмичә генә кызының чишенүен карап торды.

Әтисе командировкада иде, ялгызлыкның рәхәтен тоеп, Луиза, алсу, түгәрәк күкрәкләрен тирбәтә-тирбәтә, үз сынына үзе сокланып, бүлмәдә шактый озак булашты. Нечкә биленә кулларын куеп торды, йомры артын боргалап көзге каршында әйләнгәләде. «Юк, дип уйла-

ды ул, мондый матурлыкны, камиллекне ялынып барып Рәшатның аяк астына ташламыйча яхшы итте. Рәшатың хет әллә кем булсын. Акыл белән матурлык берберсен эзлиләр, диләр. Нигә гел-гел матурлык эзләргә тиеш? Акыл да уйлансын, ялынып үзе килсен!»

Сәрвәр ханым кызының нәрсә уйлавын төшенде, ләкин хупламады, башын чайкап күрше бүлмәгә чыгып китте.

Рәшат исә чыннан да өйдә иде. Ул, кулларын башы астына куеп, караватта чалкан ята, бик каты уйга чумган иде. Ул кызның тавышын ишетмәде. Егетнең өстәлендә кат-кат укудан мунчалаланып беткән телеграмма ауный иде. Әмма телеграмма тудырган яңа уйлар, яңа хисләр тоткынлыгында да егет әнисе турында түгел, Луиза хакында уйлый иде.

Хатын-кызларны аңлау кыен, бик кыен!

## 3

Алар икесе дә бер заводта эшлиләр. Луиза көндезге аш вакытында Рәшат эшли торган лабораториягә йөгереп кенә кереп чыга иде. Алар бергәләп буфетка төшәләр, аннары Рәшат кызны цехка кадәр озата бара. Бусы иң күңеллесе иде. Үткән-сүткәндә чибәр кызларны сүз белән чеметеп калырга яратучы алтынчы цех малайлары күрсеннәр: Луизаны заводның иң атаклы инженер-конструкторы озатып куя!

Эштән кайтканда, алар капка янында очрашалар...

Ике ел эчендә шулай гадәткә кергән иде...

Тиздән-тиздән алар шушы капкадан чыгып бер сукмакка кереп китәргә тиешләр иде...

Ә бүген Луиза әбәт вакытында чыгып йөгермәде.

Иптәш кызлары гаҗәпләнделәр:

— Ни булды сиңа?

Рәшат группасындагы егетләр дә гадәт бозылуга игътибар иттеләр.

— Кояш кире яктан чыкмагандыр бит?

Егет үзе дә гаҗәпләнде, ул Луизаны бик көтә иде. Кичә дулкынланудан ул барын да төшенеп бетмәде. Иртән автоматтан өйләренә шалтыратты, трубканы алмадылар. Көндез тизрәк очрашырга, аңлашырга кирәк иде.

Кыз килмәде, егет, аны көтеп, ял вакытын пошынып үткәрде.

Эштән соң Рәшат туп-туры өенә чапты. Троллейбуска кергәч, телеграмманы тагын бер кат укып карады...

Луиза курка-курка гына завод капкасы төбенә җитте һәм Рәшатның гадәттәге урында юклыгын күргәч, соң

дәрәҗәдә үпкәләде, кызды. Өйләренә таба борылды һәм борчылып туктады. Әтисе бүген командировкадан кайтырга тиеш. Әнисе кичәге хәлләрне бәйнә-бәйнә сөйләп биргәндер, гадәтенчә, нык кына арттыргандыр да... Вәгазьләү, үгетләү ягына килгәндә, әтисе әнисенең кубызына бии... Үгетләп кешене үзгәртеп була дип беләләр, ахры... Димәк, ашыгып кайтудан мәгънә юк... Көтә-көтә бераз көчсезләнсеннәр әле!

Япа-ялгыз басып торуын алтынчы цех егетләре күрмәсен өчен, ул тиз-тиз атлап китеп барды, аулаграк тыкрыкка күзе төшеп, шунда борылды.

Иптәшләреннән ансат ычкынды, уйларыннан котыла алмады...

Рәшатның әнисе килдеме икән? Әгәр телеграмма Луизаны үчекләү, аннан баш тарту өчен генә эшләнгән хәйлә булса?

Кыз, тыны кысылып, туктап калды. Йа Ходай, колагына берәр яман сүз кердеме әллә?.. Юк, юк, бу мөмкин түгел, ишетмәгәндер. Аңа һични ишеттерергә, белдерергә ярамый... Инде бергә яши башлагач, башка мәсьәлә, яшьлек хатасы булган бер егетне гафу итәр әле...

Тротуарда көяз генә бер егет басып тора. Луиза борчулы уйлар кочагында барса да, егеткә мәгънәле караш ташламыйча үтә алмады. Бераздан әйләнеп караса, теге егет моның артыннан бастырып килә.

— Сезне озатып куярга рөхсәтме?

Егетнең юаш кына арттан ияреп килүе, кызарынып басып торуы Луизаның күңелен җылытты:

— Озаерга иртәрәк әле,— диде ул.

— Алайса, әйдәгез, киного керәбез.

Өченче цехта эшләүче бу инженер Луизага күптәннән күз атып йөри иде. Луизага да ошый иде егет. Хәтта ул аның уенын карарга баскетбол ярышларына да барып йөрде. Рәшатны да үзенә ияртkән иде. Ут күзле, озын сыйраклы, пөхтә соры костюм кигән егет кызлар ярата торган зат иде...

Луиза сәгатенә карады. Кичә дә карый алмаганнар иде бу атаклы швед картинасын...

— Билет табып булмас,— диде ул.

— Анысы минем бурыч. Башымны кисәргә бирәм,— диде егет, кайнарланып.

— Бик арзан икән башыгыз,— дип чытлыкланды Луиза.

— Мин аны сезгә бирәм бит,— диде егет, Луизаның кулын тотып,— билетка өстәп тагын берәр нәрсә сорармын әле.

— Юньсез,— дип, Луиза көлеп куйды.

Моңарчы Луизага якынаерга куркыбрак йөргән егет кинәт үзләшеп китте, йомшак кына итеп беләгеннән эләктереп алды. Тик көпә-көндез култыклашып, шәһәр кинотеатры янына барырга курыкты Луиза. Касса янына алар очраклы гына күрешкән танышлар кебек бер-берсеннән шактый еракта торып кына килделәр...

Кинога керүеннән бик канәгать булды Луиза. Онытылып ял итте, әйбәт картина икән! Бер яшь кенә сылу егет матур кыз өчен һәлак булды.

Кинодан чыккач, ул бик бирелеп сөйләп барды:

— Заманалар булган инде. Кызлар өчен сугыша, үлә белгәннәр. Хәзерге заман яшьләренең каннары суынгандыр, ахры... Ә теге егет, сез игътибар иттегезме икән, бер минут икеләнеп тормады, бер минут!.. Никадәрле кайнарлык, хис, дәрт... Башын корбан итте, әмма үзенекен эшләде...

— Кызы да чибәр,— диде егет.— Фамилиясе ничек әле?

— Хат язарга уйлыйсызмы? — диде көнләшеп Луиза.

Залда утырганда да үз тезе өстендә егетнең кулына бер-ике тапкыр чапылдатса да, Луиза урамга чыккач шактый иркенгә куйды. Егет йонлач кулын аның иңбашына салды:

— Луиза, мин сине күптәннән яратып йөрим,— диде.

Кыз дәшмәгәч, тупас көчле бармаклары белән түш ерыгына керә башлады. Сагынылган икән, кызга бусы бик рәхәт кебек тоелды. Луиза сизелмәслек хәрәкәт белән күлмәк якасын бушатып алды, кул түшкә кадәр төшеп җитте...

— Сөям сине, Луиза!

Луизалар урамына җиткәч, бәләкәй бакчага кереп, алар озак кына үбештеләр. Егет үзе белән бер урынга барырга бик кыстаса да, Луиза ризалашмады, иреннәрен егеттән аермыйча, күзен йомган килеш баш тартты.

Аның бармаслыгына ышангач, егет ашыга башлады, сәгатенә карап саубуллашты. Луизадан аерылгач та, пыр тузып йөгерергә тотынды. Кичке тугызда аның свиданиесе бар иде...

Ишек төпләренә кайтып җиткәч, Луиза тукталып калды. Сумкасыннан кызыл иннек чыгарып, иреннәрен буяды.

Әнисе көтеп утырадыр, мөгаен...

Кызык инде бу дөнья хәлләре!

Оста үбә теге егет... Урыс егетләре куштанрак булалар инде, остарак үбешәләр. Әнә Флера Юрага кияүгә

чыккан иде, мактап бетерә алмый. Ашны үзе пешерә, идәнне дә үзе юа, ди, җитмәсә, яндырып-яндырып үбә, имеш... Рәшат түгел инде...

Бүген кая алып бармакчы булды икән? Иптәшләре янынадыр инде. Мондый егетнең иптәшләре белән аралашсаң да кызыктыр ичмасам... Рәшат кебек йомыкый түгелдер алар...

Теге егет турында наз белән уйласа да, Луиза һаман Рәшатны оныта алмый, тора-тора уйлары барыбер аңа әйләнеп кайта иде. Ишек төбендә бераз җилләнеп басып торгач, теге озын җен калдырып киткән дулкыннар басылгач, хәле киткән аяклары йөрерлек булгач, Луиза Рәшатны күрмичә өенә керә алмаячагын аңлап алды. Әнисе дә дау куптарачак, үзенең күңеле дә тыныч түгел: нәрсә булды икән? Нишли икән?

— Такси, такси!

Яшел ут күренүгә, ул, чабып, урамның аръягына чыкты.

Тәбикмәк төсле киң кырыйлы картуз кигән, бәләкәй генә кара мыеклы, алтын тешле таксист көзгесен кузгатып куйды.

Чыштырдап, урыннан кузгалдылар.

— Чкалов урамына.

Таксист, борыла-борыла, Луизага карап елмая иде.

— Киче бик матур бит, әллә бер яры урап киләбезме, туташ?

— Әрсезләнмә,— дип кырт кисте аны кыз.

Таксист тагын берничә кат сүз кушып карады, тик Луизаның ачуын гына кабартты. Кыз, кырт-кырт кына егетнең сүзләрен кисеп, тәрәзәгә карап барды...

Луиза иң элек тәрәзәләр ягына чыкты. Рәшатның бүлмәсендә дә, кухнясында да яп-якты ут яна иде. Кыз ни уйларга да белмичә, баскыч буйлап менеп китте. Звонокка басыйм дигәндә, ишекнең ачык икәнлеген чамалап туры эчкә үтте.

Кыз иң элек Рәшатны күреп алды.

Егет өстәл янына баскан да зур ачылган күзләре белән туп-туры ишеккә карап тора иде.

Луиза ап-ачык күрде: бүлмәдә башка берәү дә юк иде.

## 4

Бераз баш-күз алгач, Луиза бүлмәнең гаҗәп чисталыгын, диван-караватка җыеп куелган урын-җирләрнең пөхтәлеген абайлады. Бер як стенадагы стеллажларга китаплар тезелгән. Калын-калын китаплар... Бүлмәне тутырып тавык шулпасы исе таралган. Димәк, әнисе килгән!

Менә Рәшат та аңышып урыныннан купты, аңа якын килде, нык, таза куллары белән аны иңнәреннән кочып алды, иреннәренә иелде.

— Буяулы бит, Рәшат.

— Булсын!

Луиза, күзләрен йомып, Рәшатның иреннәренә сеңде.

— Гафу ит мине, Рәшат.

— Син үзең мине гафу ит, кичер. Кичә әллә ничек аңлаша алмадык... Мин гаепле...

Шактый вакыт үтте. Луиза күзләрен ачканда, Рәшат, башын бераз читкә алып, нидер тыңлана иде. Кыз, сумкасыннан юка, нәфис кулъяулыгы чыгарып, иркәләп егетнең буяуга манчылган калынча иреннәрен, яңакларын сөртте.

— Ай, Рәшат, артист булгансың!..

— Рәхмәт сиңа, Луиза,— диде Рәшат, дулкынланып.— Син бик вакытлы килеп җиттең.

— Тукта, менә монда кызыл калган.

— Кайда?

— Колагыңда...

Нәфис кулъяулыгы, борынны иркәли торган ис таратып, һаман егетнең битендә йөрде, колак яннарын сыйпады, муенны кытыклады. Рәшат, күзләрен йома төшеп, кызның назына баш биреп торды.

— Әниең кайда, Рәшат?

Егет сискәнеп китте:

— Килмәде.

Кыз егетнең күзләренә карады:

— Син пешергәнсең, ахры,— диде ул, иснәнеп.

— Әни килергә тиеш бит... Хәтерем алдамаса, ул тавык шулпасын бик ярата иде. Иртән каймак белән чәй эчә торган иде. Әти иртән-иртүк кибеткә чаба, күпереп торган җылы күмәч алып кайта... Әй, бу онытылып беткән хәлләр сиңа нигә кирәк?..

Луиза егет белән килеште, башын иеп кенә ризалыгын белдерде һәм өстәл өстендәге кардай ак ашъяулыкны күтәреп карады:

— Боларның барын да үзең әзерләдеңме? — диде ул, авыз суын көч-хәл белән тыеп. Кичке ашны ашамаган ашказаны котырып китте.

— Үзем,— диде егет, азрак мактанып.

«Әзерләшергә мин сине көткән идем» димәкче иде дә, нигәдер тыелып тукталды.

— Рәшат,— диде Луиза, сокланып,— синең хатының дөньяда иң бәхетле зат булачак! Нинди табын әзерләгәнсең!

Кыз үзе әйтте, үзе кызарынды, кинәтрәк сүз ычкындырып ташлавына уңайсызланды, өстәлдәге ризыклар белән мавыккан булып иелде, ике ботын да югары чөеп яткан табыктан тырнак очы белән эләктереп ит капты.

— Ай-яй тәмле!

— Тәмлеме? — диде Рәшат, балаларча куанып.— Сиңа шалтыратырга да вакыт җитмәде. Кайттым да кибеткә чаптым. Бөтен җирдә чират.

Луиза, йөрәксенеп, егетне үбеп алды.

— Рәшат, мин сине генә, бары сине генә яратам.

— Луиза, чынмы бу, дөресме?

— Дөрес, минем җүләрем, дөрес. Чын!

Алар бер-берсенә сырыштылар.

Кинәт сискәнедереп һәм куркытып звонок шалтырады.

— Килде! — диде кинәт агарынып Рәшат.

Луизаның куллары һавада асылынып калдылар.

— Әниеңме?

— Луиза, Луиза,— диде егет, бер ишеккә, бер кызга карап,— син китеп тор инде, яме.

— Җүләрләнмә,— диде кыз, кинәт турсаеп.

— Китеп тор, кадерлем,— диде егет, ялынып.

— Нигә?

Егет кызның кулларын нык итеп кысты.

— Син мине куасыңмы?

— Бу очрашуны сиңа күрсәтәсем килми... Тормышның күңелсез якларын сиңа белдертәсем килми... Үзем интеккән дә җитәр. Луиза, тыңла мине, кит! — диде егет, тиз-тиз.

Звонок таләпчән генә тагын бер кат шалтырады. Рәшат каударланып ишеккә ташланды, Луиза аңа иярде.

## 5

Кулына җыйнак кына чемодан тоткан, кара, кучкыл битле озынча хатын ишектән килеп керде. Рәшат та, хатын да бер-берсенә карашып тордылар. Хатынның да улына куркып каравын, каушап агарынуын күреп, Луиза сискәнеп китте. Бер мәлгә генә аңа куркыныч булып тоелды. Ул, Рәшатка якынаеп, терсәге белән җиңел генә кагып алды. Бу аның «Нигә шулай катып торасың?» дигән ымы иде.

Тик ана да, бала да бер-берсенең кочакларына атылмадылар, кул да сузмадылар. Бөтенләй ят кешеләр сыман баш иешеп кенә исәнләштеләр. Хатын җыларга да, җыламаска да белмәстән аякларын алыштырып басып тора иде. Луиза алгарак чыкты:

— Чемоданыгызны бирегез әле, апа,— диде ул.

Хатын шулчак кына аны күрде, аның карашы җылынды, ул таянырга терәк тапкан сыман Луизага эндәште:

— Рәхмәт, акыллым.

Үзе чемоданын бирмәде, идәнгә куйды, кулындагы саргылт плащын ишек янындагы чөйгә элде. Өчәүләшеп зал ягына чыктылар. Луизаның колаклары ут кебек яна иде.

Яшьләр ашъяулыкны ябарга онытканнар иде, хатын, өстәлдәге әзерлекне күреп, сүрән генә елмайгандай итте, тәкъдим-фәлән дә көтмичә урындыкка утырды, бөгелә төшеп, күлмәк итәген рәтләде, башын борып бүлмәне айкап чыкты. Луиза Рәшатка карап торды. Егет ничектер кинәт олыгаеп, картаеп китте, күз тирәсенә пәрәвездәй вак җыерчыклар сибелде, гомергә сабыр гына елмаеп торган күзләренә курку-каушау тулды. Ана да Рәшатка карап-карап торды, үзе:

— Сез Рәшатның хатыны буласызмы? — дип, Луизага сорау бирде.

— Юк,— диде кыз, уңайсызланып.— Без бер заводта эшлибез. Дуслар.

Хатын ышанмады, ышанмавын ниндидер ирен хәрәкәте белән сиздерде, Луизага әрсезләнебрәк карады.

— Ничек яшисең, Рәшат?

— Әйбәт.

— Эшеңдә ул-бу юктыр бит?

— Юк.

— Тазалыгың?

— Әйбәт.

Ана белән бала арасында барган бу әңгәмәне тыңлап Луиза нишләргә белмәде... Ярый, Рәшат шундый туң түмәр булсын да ди, ул гомергә шулай инде... Ә энисе? Нигә шулай кыргый ул? Әллә бөтен нәсел-нәсәпләре белән шундыйлармы?.. Рәшат хәтта аларны таныштырмады да. Хатынның юлдан килгәне күренеп тора, ул вакыт-вакыт авыр сулап куя. Нигә өстәл тирәсенә утырмаска, чәйне кузгатмаска? Мөнәсәбәтләр җылынып, сүз җайланып китәр иде. Әмма башлап сүз кузгатырга Луизаның кыюлыгы җитмәде. Ул, сәерсенеп, авызын ачып әле Рәшатка, әле аның әнкәсенә карап утыра иде.

— Әтиең турындагы хәбәрне укыдыңмы? — дип сорады хатын.

— Укыдым.

— Әйбәт тә язганнар инде! Йа Хода, нинди изге күңелле кешеләр була бит.

Рәшат урынында тик кенә утыра алмый, әле бер тезен, әле икенчесен өскә куя иде.

— Менә мин дә япа-ялгызым яшәп ятам. Былтыр пенсиягә чыктым,— диде хатын, идәнгә текәлеп.

— Ялгыз? Ә ирегез? — диде хырылдап Рәшат.

— Ирем юк... Моннан биш ел элек үлде инде.

Луиза барын да аңлаган кебек булды, җиңеләеп урыныннан купты, кухняга керде, кайнап утырган җиреннән чәйнекне алды. Зал якка чыкты да, хуш-ис таратып, чынаякларга чәй агызды.

— Утырыгыз, апа, ачыгып килгәнсездер.

— Рәхмәт, рәхмәт, эчмим. Самолет соңга калды. Мин иртәрәк килергә тиеш идем... Аэропортта ашап алдым. Әллә өендә була, дим, әллә юк...

— Нигә кунакны кыстамыйсың, Рәшат? Яхшы түгел бит.

Тик егет кызның киңәшен тотмады, өч чынаяк пар бөркеп өстәлнең өч ягында утырып калдылар, Рәшат, күзен күтәрергә дә куркып, тын гына нидер тыңлана иде.

Хатын йөткергәләп, кулъяулыгы белән авызын сөртте, тамагын кырды һәм Рәшатка табарак борылып:

— Рәшат... Мин синең янга зур йомыш белән килдем,— диде.

## 6

Рәшат шушы сорауны көтә иде.

Ул хатынның бу йорт бусагасын җиңел генә атлап кермәвен сизә, әмма ни өчен килүен һич тә аңлый алмый иде. Нигә килде икән? Акча-фәлән кирәк булса, үзе килеп йөрмәс, хат кына салыр иде. Димәк, монда ул күздә дә тотмаган олырак берәр нәрсә бар!

— Нинди йомышыгыз булыр икән? — диде кинәт егет.

Луиза коелып төште. Улының тупаслыгына хатынның исе китмәде, ахры, башын күтәреп тә карамады.

— Рәшат, акыллырак бул,— диде кыз, түзмичә.

Бу кисәтү Рәшатка ошамады, ул:

— Мөмкин булса, тыңлап кына утыр, Луиза,— диде.

Үпкәләде Луиза, каны кайнады, күзенә яшькелт яшеннәр чыкты, тик тыелды, керфекләре белән күзен каплап, Рәшатка яны белән борылды.

— Рәшат,— диде хатын, учлары белән тезләрен уып.— Син күп нәрсәләрне белеп тә бетермисеңдер. Белгәннәрең онытылгандыр. Яшь идең шул әле син. Без әтиең белән бик матур еллар үткәрдек.

— Әти исемен телгә алмагыз! — дип кычкырды Рәшат, тыела алмыйча.

Луизаның мондый ярсулы тавышны ишеткәне юк иде, кабаланып сикереп торды, хатын исә гүя улының кисәтүен ишетмәде дә, аның яңак җәяләре тартышып кына алды, ул калтыравыклы, кызганыч тавыш белән сүзен дәвам иттерде:

— Гомеремнең иң матур чакларын мин аның белән үткәрдем. Яратып чыктым, яратып яшәдем. Әгәр дөньялар үзгәрмәгән булса...

Бу урында хатынның чыдамы беткәндәй булды, ул сумкасыннан кулъяулыгы чыгарып күзләрен каплады. Луиза бер секунд эчендә хатынның Рәшатка кадап карап алганын да, күз чокырларының коп-коры икәнен дә күреп калды — аның шик-шөбһәләре арта гына барды.

Рәшат һаман сүзсез, өнсез иде әле. Ул, сул кулын чалбар кесәсенә тыгып, тәрәзә яңагына килеп сөялде. Ачык тәрәзә аша аска, электр нурларында сихри төсләргә манчылган агач яфракларына карап тора башлады. Уйлары белән йөгереп кенә үткәннәргә, балачагына кайтып килде, хәзергесен аңларга тырышты, тик аңа җиңеллек килмәде.

— Хәерле булсын алайса! — диде хатын, көрсенеп.— Усаллангансың син, улым.

Хатын беренче тапкыр «улым!» дип эндәште, моны ишеткәч, Рәшатның йөзенә кан йөгерде.

— И бала, бала! Ана йөрәген аңлый торган бала булмадың шул син!

— Минме? Мин шундый баламы?

— Атаң мәрхүм дә шундый каты бәгырьле иде!

— Сез әтинең кем икәнен бер чакта да белмәдегез, аңламадыгыз! — дип кычкырды Рәшат, Луизаны тагын бер кат куркытып.

— Рәшат, кычкырма алай! — дип инәлде кыз.

Хәзер Рәшатны туктату, тыю мөмкин түгел иде инде, ул әнисе каршысына ук килде, ике кулы белән урындык аркасын эләктереп алып, урындык аяклары белән идәнне төя-төя сөйләргә кереште:

— Сез... аны бервакытта да аңламадыгыз! Хәтерегездәме, әтине төрмәгә алып китәргә килгән кешеләр бусага төбенә җиткәч нәрсә диделәр? «Атла, атла, халык дошманы!» дип кычкырды арадан берәү... Җиде яшьлек нарасый идем мин ул чагында. Сез аларның сүзләренә шундук ышандыгыз, «чыннан да дошманмы ул?» дип сорадыгыз. Нигә шулай дип сорадыгыз алардан? Әгәр сез әтине белсәгез, үзегез хәзер раслаганча аны яратсагыз, аңа ышансагыз, гомерлек юлдашыгызны шулай ансат кына биреп җибәрер идегезме?.. Кап-караңгы төн иде. Май төне... Нәкъ моннан егерме ике ел элек. Без зур, өч

бүлмәле квартирада яши идек. Шулчак сез бүлмәләр буйлап йөреп, «Халык дошманы, халык, дошманы! Ничек моңарчы мин моны белмәгәнмен? Ничек?!» дип кабатладыгыз. Иң беренче эш итеп телефон шнурын өзеп ташладыгыз.

Йоп-йомшак күңелле, шат әтинең дошман булуын мин сабый һич тә аңламый идем. Нинди дошман булсын ди ул?! Кичтән генә мин аның тезенә утырып торган идем. Ул бик тырышып миңа уенчык арба ясаган иде. Шул чагында бик җитди итеп: «Улым, гомер менә шулай уза, иң элек син менә шушы уенчык арбага утырып юлга чыгарсың, аннан машиналарга күчеп язмыш капкаңны кагарсың, поезд-самолетларда илләр гизәрсең, күп кешеләр белән аралашырсың, берәүләр белән дуслашырсың, икенчеләреннән читтәрәк йөрергә тырышырсың. Һәрчак гадел, саф күңелле, чиста булып кал!» — дигән иде... Сүзләре бүтән булгандыр, әмма әтинең уе әнә шундый иде. Арбага өч тәгәрмәч куйгач, без йокларга яттык. Мин шунда әтигә: «Тәгәрмәче өч кенә булгач мин ничек юлга чыгыйм соң?» — дидем. Ул мине кочаклады да: «Юк, улым! Юк, балам, сине өч тәгәрмәчле арбага утыртып дөньяга чыгараммы соң? Сине өч тәгәрмәчле генә арбага утыртырга һич ярамый, дөнья хәтәр, тормыш давыллы, малай кешеләр нык булырга, нык утырырга тиешләр!» — дигән иде... Төрмәчеләр төрткәләп этине ишек катына алып килеп җиткергәч, чыдамадым: «Әти! Ә арба! Аның тәгәрмәче җитми бит!» — дип үксеп-үксеп җыладым. Хәтерегездәме, ул миңа таба борылып көлде дә болай диде: «Улым, балам! Кайтам әле мин, арбаңа дүртенче тәгәрмәчне куяр өчен кайтам!» — диде.

Рәшат, Луизаны бер кырыйгарак кагып, өстәл тартмасын ачты һәм аннан яргаланып, тузып беткән, пәке белән юнып ясалган өч тәгәрмәчле арба тартып чыгарды.

— Менә ул арба. Исән. Дүртенче тәгәрмәче генә юк.

Хатын бу юлы чынлап торып мышык-мышык җылый, Луиза, нидер әйтергә теләгәндәй, өстәлгә таянып, арбага иелеп карап тора, Рәшатның арбаны сыйпаган куллары калтырый иде. Ул арбаны сыйпаштырып бераз сүзсез торды да йөзен читкә борды.

— Шушы арба әтинең миндә сакланган бердәнбер истәлеге.

— Рәшат, улым,— дип, чын-чыннан өзгәләнде теге хатын.

— Бәлки, сүзләре бүтәнчә булгандыр аның, әмма сөйләвенең мәгънәсен, ишек катына җиткәч көлеп җибәргәнен һич онытасым юк!.. Әйе, еллар үткәч, без, өч тәгәр-

мәчле арбаларда утырып калган дошман балалары, мең афәт татыгач, исәйгәч, этиләребезне эзли башладык. Кыен, куркыныч чаклар иде! Ә мин этиемне барыбер эзләдем! Кешеләр аның исемен ишетүгә куркышып качалар иде! Ә мин барыбер эзләдем! Һәм аны төрмә камераларында очраткан, белгән кешеләргә юлыктым... Нәкъ менә шундый май төнендә аның белән бер төрмә камерасында утырган кеше очрады. Этине дөмбәсләп-кыйнап алар янына илтеп тыкканнар. Саргайган йөзле, кыйналган, җәфаланган ач тоткыннарны күргәч эти елмайган, тынычландырырга, юатырга теләгән. «Егетләр, күрәм, хәлегез яман! Таң гына атсын, минем хатын килеп җитәр, ул минем гаепсез икәнемне белә, ул ашарга да, тартырга да алып килер!» дигән. Камерадагылар шикләнгәч, сезне якларга керешкән: «Минем хатын мондый таш стеналарны гына түгел, корыч крепостьларны да үтеп чыга торган!» — дип өстәгән. Бер көн көткән ул, ике көн, атна узган, унынчы көн дигәндә идәнгә чүгеп төшкән дә кычкырып җылап җибәргән. Шуннан ары алар күрешмәгәннәр...

— Рәшат, кирәкми андый сүзләр! Ул чагында мин берни дә белми идем бит, — диде хатын, җыламсырап.

— Белмәгәч, нигә белергә тырышмадыгыз! — дип әлдереп алды Рәшат. — Нигә читләр сүзенә шулай ансат ышандыгыз? Үз балагызның эткәсе кыенлыкка төшүгә нигә шулай ашыгып аны оныттыгыз?!

— Мин йөрсәм ни файда булыр иде икән? Барыбер йолып ала торган түгел иде бит!

— Сезнең этине юллап йөрүегез миңа кирәк иде, ахыр чиктә, миңа кирәк иде! Мин бит өч тәгәрмәчле ярык арба янында утырып калган җиде яшьлек сабый! Сезнең аңа ышануыгыз миңа кирәк иде! Ул көннәрдә ни уйлап яшәвегезне мин үсә төшкәч кенә аңладым. Хәтерегездәме, сез бервакыт соң гына кайтып кердегез. Өй салкын, ягылмаган, тәрәзә пыялалары шыкраеп каткан. Мин юрганга аякларымны ныгытып төрәм дә тәрәз бозын ялыйм, нәни генә күз ясап сезнең кайтканны көтәм! Куркуданмы, суыктанмы бөтен тәнем дер-дер килә. Тешләр тешкә тия! Сез, лап-лоп атлап, кайтып кердегез, ут кабыздыгыз, минем йокламыйча сезне сагынып көтүемне күргәч: «У-у, бәләкәй ерткыч, тач халык дошманы инде!» — дидегез. Бу сүзләрнең мәгънәсен ул чакта ук яхшы белә идем мин! Мәктәптәге усалрак малайлар минем күземне ачырмыйлар иде: «Троцкийчы малае, троцкийчы малае!» — дип кенә үртиләр иде. Бүтән сүз юк иде миңа мәктәптә! Мин ярсып, йодрыкларымны

йомарлап аларга ташлана, әтиемне яклый идем. Алар җыйнаулашып мине тукмыйлар, эчемә тибәләр, битемне ерталар иде. Битемне ерттырасым килми иде минем, әтигә охшаудан туктармын, җәрәхәтле бит белән аңа охшамам дип, бик курка идем...

Хәтерегездәме, сез әтинең истәлекләрен ничек юкка чыгардыгыз?!

Иң элек альбом битләреннән аның фотолары югалды. Бергәләп төшкәннәрдән сез аның башын кисеп алдыгыз. Җыйдыгыз, җыйдыгыз да мичкә илтеп яктыгыз! Өй сап-салкын, ә мичтә әтинең йөзләп башы яна! Барыбер җылынмаган иде өй!

Аннары әтинең кием-салымнарын чыгарып саттыгыз. Ул укыган китапларга чират җитте. Мин үземнең өч тәгәрмәчле арбамны чормага менгереп куйдым. Аны яктырасым килмәде. Әти көннәрдән бер көнне кайтып килер дә аңа дүртенче тәгәрмәчне ясап бирер кебек иде...

Озакламый сугыш башланды...

Күп әтиләр фронтларга киттеләр. Бик күп малайлар ясап бетермәгән өч тәгәрмәчле арбалар янында утырып калды. Байтак әтиләр әйләнеп кайтмады, ил ятимнәр белән тулды. Сугыштан соңгы ять-яшь җинаятьчеләр, укып һөнәр ала алмаган сукбайлар әнә шулар арасыннан чыкты. Минем әтием дә кайтмады, эзсез югалды. Сез мине Нурулла абыйларга илтеп ташладыгыз. Көз иде, суык, минем өстә сүсәргән иске бишмәт. Култык астыма шушы арбамны кыстырып, мин аларның биш баласы арасына барып кердем. Дөрес, Нурулла абый әтинең иң якын кардәше иде. Ул мин ятимне үз баласыдай каршы алды. Юлда барганда сез: «Ташласана ул чүбеңне, адәм көлдереп йөрмә!» — дидегез. Нурулла абыйларга барып кергәч тә шул сүзләрне кабатладыгыз. «Ташламыйм, аны миңа әти ясап бирде!» — дигәч, Нурулла абый кочагына алып иркәләде. Әгәр шул минутта сез арбаны миннән тартып алырга маташсагыз... иң зур җинаятьләргә дә әзер идем мин! Кулыгызны шунда тешләгән идем, онытмадыгызмы?

Хатын уң кулын артына тиз-тиз яшерде һәм инәлеп:

— Рәшат, шәфкатьлерәк бул! — диде.— Мин бит синең анаң. Ул вакыттагы хәлләрне уйлап кара: мин бит чыннан да әтиең халык дошманы дип ышанган идем. Мин аннан баш тартмыйча булдыра алмадым, коммунист ич мин!

— Ярый, сезнеңчә ул дошман да булсын, ди. Халык дошманы. Ә мин кем дошманы идем?! Мин!

Ана белән улдан һаман ерагая төшкән Луиза, хәленнән

килсә, менә шушы почмакка кереп сеңәр иде. Ул, Рәшат тәмам кызып җитәр дә, бүлмәдә булган кешеләрнең һәммәсен тукмап ташлар дип шигәя иде. Аннары ни кылырсың?! Суд бусагаларын таптан йөрергә калса ни кылырсың? Уф, нигә бу ике арага килеп кысылды соң ул?! Рәшат кыстаганда ник чыгып китмәде икән?! Хәзер бер-бер сүз әйтсәче соң Рәшаты!.. «Бар, кайт, көтәләрдер!» дисә, озатуы да, ние дә кирәкми.

— Шул кышны сез кияүгә чыктыгыз... Ирегезне күрсәттегез! Мин аны таныдым! Әтине алып киткән өч кешенең берсе иде ул!.. Озакламый Нурулла абыйны да сугышка алдылар. Гөлсем апа алты бала кочаклап калды. Ә сез ул вакытта минем хәлне белергә дә кереп чыкмадыгыз.

— Улым, кызган!

— Рәшат, җитәр, җитәр! —дип ялынды Луиза.

Рәшат, өч тәгәрмәчле арбасын ак кәгазьгә төреп, өстәл тартмасына салып куйды.

Өй эче тынып калды. Өстәлдә, ике ботын күккә чөеп, симез тавык ята. Өч чынаякның өчесендә дә суынган чәй. Хатын үзенә китәргә вакыт җиткәнлеген аңлады. Хәерле булсын! Ул Рәшатта бернинди фото да, истәлек тә юклыгын бик яхшы белә иде. Ире аклангач, аның гадел хезмәтләре дөньяга фаш булгач, аның өчен пенсия алырга мөмкинлек бар, диделәр. Рәшатка пенсия бирмәячәкләр, аңа кирәк тә түгелдер. Ә аңа бирүләре ихтимал! Һәм, гомумән, әгәр Рәшат аны әнисе дип, хаксызга гаепләнгән кешенең тугры хатыны дип таныса... Тормышы нык ук җиңеләеп китәчәк иде хатынның! Ул озак әзерләнде, улымның күңелен нинди юллар белән табыйм икән дип, көн-төн баш ватты, юристларга барып киңәште... Тик барып чыкмады... Хәерле булсын!

Ул ишеккә таба атлады, көрсенде. Луиза менә-менә Рәшат әнисен туктатыр, гафу үтенер дип көтте. Кичерер! Үткәндәге гаепләр өчен шулай каты күңелле булырга ярыймыни?! Тик Рәшат кузгалмады, ул, көчле кулларын күкрәгендә баглап, тып-тын гына тәрәзәгә карап тора иде. Тәрәзәдән бер күбәләк очып керде һәм түшәм уты тирәсендә очып әйләнә башлады.

Хатын чемоданын кулына алды, чемоданга тотынгач хәлләнеп киткәндәй булды, гәүдәсе турайды, башы күтәрелде. Саубуллашмады, тавышсыз адымнар белән ишекне ачык калдырып чыгып китте.

Луиза тагын да ныграк курыкты: әгәр Рәшат аның бүгенниләр эшләп йөргәнен, кылган, кыла язган гамәлләрен белсә? Элек аның ниләр кыйратканын кайчан исә

бер ишетә калса?! Хәзер ул Луизаның якасыннан алып сүгәргә тотынса?! Юк, юк, ярамый...

Кыз арты белән ишеккә чигенде, Рәшат, нидер сизеп, капылт аңа таба борылды:

— Луиза!

— Якын килмә! — дип чәрелдәде кыз, шашынып.— Синнән куркам мин, Рәшат! Дөресрәге, үземнән куркам... Юк, үткәннәремнән куркам!

Егет аның сүзләрен ишетсә дә аңламады, ул:

— Мин сине сөям, Луиза! — дип кат-кат кабатлады.

— Кирәкми, Рәшат. Зинһар, онытъ. Мин синең сөюеңнән дә, нәфрәтеңнән дә бик куркам. Мин дөресен әйтәм: куркам, куркам! Оныт син мине! Эзләмә!.. Кирәкми. Безгә очрашырга да ярамый!..

Ул, егетне читкә тибәрергә теләгәндәй, кулларын бутый-бутый арты белән ишек яңагына килеп бәрелде һәм күз ачып йомганчы юк булды.

Рәшатның:

— Луиза-а! — дип, җан ачысы белән кычкыруыннан бакча эчендәге парлылар сискәнеп күтәрелделәр һәм ут яктысы төшкән бердәнбер тәрәзә астына җыелдылар. Тик тавыш яңадан ишетелмәде, яп-якты бүлмәдән, күңелләрне шикләндереп, шомлы тынлык кына ага иде.

*Апрель — октябрь, 1965 ел,*
*Кисловодск — Казан*

## *Уналты яшь*

Кыз, җомга көн иртәнчәк чыгып китеп, әлегәчә өенә кайтмаган икән... Күргәннәр, аның зәңгәр чуклы букчасын иңенә салып, гадәтенчә төп-төз басып, туп-туры алдына карап, һич кабаланмыйча, капкаларыннан чыгып барганын күрше-күлән күреп калган. Атын төнгелеккә Аклан чирәменә тышаулаган сыңар күз Миннәхмәт кызның сөзәк тау сукмагыннан ашыкмый гына менеп баруын да абайлаган. «Таң тишегеннән кая бара икән бу кызый актыгы?» — дип мыгырданган әле Миннәхмәт. Кызның тау маңгаена менеп җитеп тукталганын, түбәнгә, иртәнге сыек томан таралгач ачылып киткән урамнарга, көлтә-көлтә нурын таратырга ашыккан кояшка, тау итәкбилләрен чуарлаган юл-сукмакларга текәлеп карап торуын күрүчеләр табылган. Шуннан арысын беркем дә белми калган. Тау башына килеп тоташкан чытырманлы кара урманга кереп киткәнме, әллә иртәнге сәфәрен түбәтәй-түбәтәй калкулыклар аша дәвам иткәнме, белүче юк. Югалган кыз.

Көн үткән, июль азагы, эшнең иң кызган чагы, кемнең кемдә гаме бар, кызның юклыгын өендә дә искәрмәгәннәр, инде төн уртасында да кайтып кермәгәч, хафага төшкәннәр. Әнисе, ирен биш ел элек җирләгән тол хатын, тынсыз-өнсез калып, авыл советы рәисенең тәрәзәсен каккан. Икенче шөбһәле таң яралган, тау битләрендә, үзәннәрдә телсез кылганнар тирбәлгән, Аксу авылы өстеннән сүзсез ак болытлар аккан, кыз күренмәгән. Суга төшкәндәй гаип булган кыз.

Икенче көнне, әбәттән соң, Хәлил Казаннан кайтышлый олы юлдан машинадан төшеп калгач ук, авыл тирәсендә мөшкел бер хәл барын абайлап алды. Юл белән авыл арасы ерак түгел, ике чакрым булса булыр, бер атлап ике сикерсәң, кайтып та җитәсең. Авыл юлына борылып керүгә, егетне атлы милиционер туктатты. «Ерактан кайтасыңмы?» дип сорады ул, котсыз коры

тавыш белән. Егет аңлатып тормады. Ул сул иңбашын кагып: «Моннан күренми!»— дип мыгырданды да юлында булды.

Казан кадәр Казаннан җеназадан кайтып килүче егетнең беркем белән дә сөйләшәсе килми иде. Милиционер артыгын төпченмәсә дә, егетнең киеренке күңеленә шом оеткысы салды. Аллы-артлы ике машина узды, алар егетне куе тузанга коендырып үттеләр. Ике әрҗәдә дә егетҗилән, кыз-кыркын шыплап тулган иде. Каршы яктан килүче ике егет Аксу авылында бер кызның югалуын, эзләп-эзләп тә табылмавын әйтеп уздылар.

Ике төн йокы күрмәгән, юл газапларыннан җыгы чыккан егет, хафалы хәбәрне ишеткәч, үз арганлыгын онытып ашыга-кабалана башлады. Ике иңен басып торган кайгысы болай да зур иде, «югалган!» дигән дәһшәтле сүз аны тәмам изеп ташлады. Егет кем югалганын «ә» дигәнче чамалады һәм ялгышмады. Кызның кемлегендә аның һичбер шиге юк иде.

Язга чыгарак Аксу авылына кайтып төшеп урнашканнан бирле, Әфган сугышларында көн-төн газап йоткан, мең төрле гарасат арасында җанын тере саклап алып калган егет әз-мәз тынычланган иде шикелле. Әфганнан сеңеп кайткан шомлы төшләр, дәһшәтле өннәр әзгә генә онытылып, аннан читтәрәк йөри башлаган иде. Язмыш тагын кире ягы белән борылды: иптәшен җирләп кайтканда кайгыга кайгы өстәлде, җаны тәнен бимазалап, тәне җанын талап, бөтен дөнья каралып зыр-зыр әйләнде. «Шушы гына җитмәгән иде!» дип ыңгырашты кайгы белән тулы күңеле. Тормышым җылы бер эзен таба дигәндә, шушы өметле эзгә алып кереп барган кыз югалсын инде!

Әфганстанда тоташ ике ел! Ике ел эчендә алган яраларны әз-мәз төзәтү, ябыштыру өчен тагын бер ел гомер кирәк булыр!.. Әле аннан соң да күпме җәбер-җафалар, кичерешләр. Әфганнан ул этисе йортына, район үзәгенә кайтып төште. Тоташтан ял, даими тәрбия кирәклеген белсә дә, ата йортында озак юана алмады. Һәр иртәдә, Ходаның бирмеш һәр көнендә, үзенә текәлгән кызганулы карашларны күтәрә алмадымы, әллә эткәсенең ялтырап торган майор погоннары туктаусыз үртәдеме, ай дигәндә эткә-әнкәсенең ай-ваена карамыйча, чыгып качкандай, өен ташлап китте. Китүенең сәбәбен аңлатып тормады, онытылып беткән туган-тумачаларының адресларын белеште. «Берсенә сыймасам, икенчесенә...» дип уйлады эченнән генә. Анда барып карады — җаны җай таба алмады. Монда сугылды — күңел сыя торган юмарт поч-

мак анда да юк иде. Егетнең тәне кат-кат туралганын, рухы сынып ярты мәет хәлендә кайтып егылганын беләләр, белмәгәннәр ил мисалында чамалыйлар иде. Аны сак хөрмәт белән каршыладылар, җанын аяп, йогышсыз сораулар белән интектермәделәр, җаеннан гына торырга тырыштылар. Ул кунак булып төшкән йортларда хәл тиз-тиз үзгәрә иде. Егетнең елмаюны оныткан сүрән чырае, сөйләр сүзләренең бик сирәк кенә, анда да ярым-йорты җөмләләр белән телдән ычкынгалавы хуҗаларның олысын-кечесен сискәндерә, һәр өй түрендә гадәти булмаган авыр һава ярала иде. Егет үзенең яшәеше белән ерак туганнарына сөенеч түгел, хәсрәт китерүен бик яхшы аңлый, бу исә аның җан газапларын тагын да арттыра иде. Хуҗалар, аерата хатын-кызлар, аның җәрәхәт җөйләрен ялгыш кына күреп калганда да тыела алмыйлар, күз яшьләре елга булып ага... Иртәгесен егет яңа сәфәрләргә, яңа урыннарга ихтыяри-мәҗбүри чыгып китә иде. Мәчеләр дә аның халәтен сизенә, мырлый-мырлый аның тез өстенә менеп сузылмыйлар, аның авыр күз карашыннан курыккан этләр дә, үткер теш-тырнакларын яшереп, авызларын йомалар. Ул урам якка чыгып, капка баганасына сөялсә, баганалар уфылдап, ыңгырашып ала...

Татарстанның иң читендә, ерак районнарның берсендә, әткәсенең абзасы Җиһанша яши иде. Ара ерак, әткәсе туганлык җепләрен ялгаштырырга әвәс түгел, военком бит, татар түрә булса, чабатасын һичшиксез түргә элә, егет үзен белә белгәннән бирле Җиһанша абзалары белән бик сирәк, анда да ялгыш юл төшкәндә генә очрашалар иде. Шул юмарт күңелле йорт исенә төште егетнең. Каядыр үтешли ата йортына кагылып, әнкәсе белән чак кына ачылып китеп сөйләшкәндә, «шул тирәгә барасым килә!» дип ычкындырды. Әтисе күтәрелеп бәрелде: «Менә анда инде сине көтеп алыр кеше юк... Ашыкма, уйла, үлчә, кар китеп юллар төшсен, көннәр җылынсын, Җиһанша абзаң вафат, карчыгы да дөнья куйган. Йортта яшәр кеше калмаган. Тәрәзәләре кадаклы, ишекләре бикле. Сине көтеп торучы да, сагынучы да юк анда»,— диде. Егет башын гына чайкады, балачак хатирәләрендә Аксу авылы зәңгәр, татлы томаннарга өрелеп, күңеленең иң эчкәрге тартмасында саклана икән. «Барам. Карыйм. Торыр чама юк икән берәр яры китәрмен»,— диде ул, гадәттәгедән озынрак сөйләп. Җиһанша абзасының саф көмештән койган сакалы, кычкырып дога укыган тантаналы мизгелләр һәм рәт-рәт тезелеп утырган умарталар Хәлилнең исенә төште. Марҗа биле юанлыгы кышлау

умарталар, шул умарталарны кысып кочаклаган дәү-дәү каеннарны да хәтерләде. Җиһанша бабасының умарта менеп, бала учы-бала учы ап-ак кәрәзләрне аның кулына тоттырганы исенә төшеп, авызыннан сулар килде.

Китте. Районнан Аксуга юл һаман салынмаган икән. Ни чана, ни арба дигәндәй, ике араны егет шактый озак үтте, таеп китеп, мыштым чокырга тулган мәкерле суда ике аягын да чылатты. Әйткән сүзеннән кайтканы юк иде, күз бәйләнә башлаганда Аксуга барып керде, Җиһаншаның какшау капкасын киереп ачты. Бүктәрен болдырга куеп, йөткергәләп, лапас астындагы кузланы кузгаткалап тавышланган арада, күрше-тирәдән ике-өч кеше күренеп, ары-бире сүз алышып танышкач, алар балтапычкы, көрәк-мазар алып керделәр, болдырга җил тутырган чүп-чарларны, пәҗеп укмашкан карлы-бозлы яфракларны җәһәт-җәһәт чистарттылар, күгәргән йозакны җылатып ачтылар, тәрәзә капкачларын як-якка тарттырдылар. Егет Җиһанша агасының үксез түренә кичке салкын эңгерне ияртеп керде. Ил төкерсә, күл булыр, кем мич казнасыннан алып чыра телде, кем әвеслектә ятып муртайган усак яркаларын кертеп өйде. Чәйне казанда кайнаттылар. Өйгә ялкау, сүрән җылы төште. Җиде-сигез тустаган чәй эчеп кайнарланган егетнең аңа гына исе китмәде! Ул дымлы түшәк-ястыкларны җылы йөгерә башлаган мич кабыргаларына терәп куеп, үзе как сәкегә сузылып ятты, адәм балаларының иң кадерле мендәре булган кулларына башын салды. Әфган тәмугының җиде катын үткән солдатның йокысы ястык тели димени?! Ятты да сеңде.

Озак йокламады. Иртәне ул түземсезләнеп көтеп алды, мәшрикъ ягы аллана башлауга болдырга чыкты, төнлә чираган сулар чуар көзгеләр булып, төрле рәвешләргә кереп ишегалдын бизәгәннәр. Сыек томан агач кайрыларының әчкелтем исләрен уятып, агач бөреләренең һәрберенә нидер пышылдап, татлы исләрен куертып, бөтен дөньяга терелек төсмере керткән иде. Агачлар әкияти баһадирлар, татарның бик еракта калган, онытылган Алып батырлары булып күренделәр. Ул, әсәренеп, тау ягына карады, анда-санда үскән агачлар таудан ташкын булып төшеп килүче Болгар атлылары булып тоелдылар... Ул, шәүләсен йотарга маташкан челтәр бозларны чак-чак кына ватып, ихатаны әллә ничә кат урады...

Ихатаны, йортны онытмаган икән әле! Сөенде. Сабый чагын оныткан бәндә — бәхетсез, чөнки иң гөнаһсыз, иң газиз хатирәләр бары тик сабый чактан гына сеңеп кала... Әгәр кыйналган җаныңны шулар белән дә җылыта ал-

мыйсың икән, тагын нинди заман хатирәләре белән юансын кеше! Җиһанша абзасы авылның бөтен йортларыннан да югарыракка, тау биленә үрмәләгән, бүтәннәрнең ындыр-бакчалары йорт артында булса, ул каралтыларын өскәрәк салган да, бәрәңге ызаннарына, түтәлләргә урынны өй каршысында калдырган иде. Тау белән йорт-кура арасында алма-чия агачлары, юкә белән каен алмаш-тилмәш үскән чаукалык... Умарталар калмаган, кышлау умарталарның череп таралган сөякләре уйдык-уйдык чәчелеп ята. Такта умарталарны бер читкә өеп куйганнар, ятим калган казыклар, дүртәр-дүртәр тезелгән бичара солдатлар булып, шыраеп утыралар. Йорт әле таза диярлек. Түбәсе кыйшайган, почмагы янтайган мунча да исән икән. Кәҗә-сарыкларның исен таратып бетермәгән мал абзары да эшкә яраклык... Йорт-кураның авыл арасыннан шактый читтә булуы да, өч зуп-зур тәрәзәнең нәкъ кояш чыгышына карап торуы да ошады Хәлилгә. Егет шул иртәдә үк үзе өчен бер яңалык ачты: моңарчы ул кая гына бармасын, нинди хәлләргә генә төшмәсен, юлының дәвамы хакында уйлый да, күз алдына китерә дә алмый иде. Әфганнан соңгы һәр көне шул көн белән генә тәмамлана, ул бары тик үзен чолгаган бер көнлек мохиттә генә яши ала иде. Шушы җимерелә башлаган моңсу ихата. Юаш кына ары-бире сузылган муртайган киртә-читәннәр, тормышның бөтен вакыйгаларын күңеленә салып та аумаган капка, лапас өрлегенә бәйләнгән бозау муенчагы. Күгәрә төшсә дә, йөзеннән яктылыгы китмәгән чалгылар, баш-башлары уем-уем яргаланган улаклар. Колашалар. Абзарның җир идәнендә җуелмаган хайван эзләре, каен белән бик югарыга үрләгән ватык-потык сыерчык оясы, тәрәзәләрне уятып өлгергән кояш нурлары егетне алга, иртәгәгә ашыктырмасалар да, аны үткәннәргә — сабый чагына алып киттеләр. Ул сөенде: җанның хәрәкәттә булуы — бәхет! Иртәгәгә ашыгасыңмы син, үткәннәргә таба агасыңмы — синең җаның тере. Ул сиңа хәрәкәтләнергә боера. Әнә шул җуелмас балачак хәрәкәтләре арасыннан ул яңалык нурларын да шәйли, бүген яралып уянган хисләр Әфганнан кайтканнан бирле барлыгы да беленмәгән берсекөнгә чакыралар, яктылыкка өндиләр иде!

Барыннан да бигрәк аңа кураның исе ошады. Балачактан ук искә җәһәт иде егет. Әфганнан соң исләр аның яшәешенә өзлексез тәэсир итә торган көчкә әйләнделәр. «Африка мәетләренең исе Россия мәетләренекеннән нык аерыла»,— дип язган иде берзаман Ремарк. Дөнья сугышларына, халыкларның бер-берсен аяусыз кырулары-

на бөек отчетлар язган Ремарк әфган сугышының исләре хакында ни язар иде икән?! Моны анда булганнар гына белә, тик алар белсәләр дә сөйләмиләр. Хәлил кайтканнан бирле тирә-ягындагы йогышсыз исләрдән җәфалана, юл, шпал, вагоннарга сеңгән Рәчәй исләре аны җәһәннәми шашындыргыч мохиткә сөйрәп алып кереп китәләр иде. Тәне күтәрә алмаслык яралардан соң, аны Таҗикстанның аулак бер төбәгендәге госпитальгә алып кайтып салдылар. Тән, гәүдә рәвешен җыеп тотарлык егәр калмаган иде егеттә. Ел дәвамында әллә ничә кат тураn, сүтеп-ялгап, җеген җеккә туры китерергә тырышып тегеп ел дәвамында ремонтлаганнан соң, икенче группа инвалидлык биреп, туган төягенә озаттылар. Вагонга кереп утыргач, ул кесәсеннән Кызыл Йолдыз ордены һәм «Батырлык өчен» медале тартып чыгарды һәм бәдрәфкә барып бүләкләрен су белән юдыртып җибәрде. Күз күнеккәндәй булды, әгъзаларының сызлау-сызлануларына да ияләнгәндәй итте, әмма истән куркудан котыла алмады. Менә шунда, Җиһанша абзасыннан калган курада, аның чүл комнарында куышып, ташлы кыяларга сеңеп, дәһшәтле әфган җилләренә каршы тора алган, сыдырылган, канаган, туналган күкрәк читлегенә туган төягенең җылы дым тибрәлгән һавасы кереп тулды. Озаккамы?

«Озакка!» дип кабатлады ул, яшерен ышаныч белән. «Озакка!» дип ышандырды үзен шул иртәдә. Һәм моңарчы шул ышанычын какшатырлык бер генә вакыйга да булмады. Кая ул, булмады! Ә ышанычын арттырган вакыйгалар килә-китә тордылар, аңа көч өстәгән адәм балалары очраштырды. Йорт-кураны иплэп кенә рәткә китерде егет, чистартты, себерде, юды. Госпитальдән кайтканнан бирле бер эшкә кулы бармады. Бер шөгыльгә дә күңеле ятмаган егет хәзер иртәгәдә нинди эшләр башкарасын кичтән үк уйлап куя торган булып китте.

Аксу авылыннан аяк атлап чыгып йөргәне юк иде, җеназага барып, соңгы ике көн эчендә ул байтак ара үтте, әйләнеп кайткач ияләнгән кадерле Аксу авылын танымады. Бүгенге ят хәрәкәт, аның күңелен каралтырга тырышкан машина исләре, адәмнәрнең бер-берсенә ямьсез кычкырып эндәшүләре, аңа төбәлгән ярым рәнҗүле күз карашлары моңарчы ак юл булып сузылып яткан сукмакны, җылы эңгер бер чакта да эреп бетмәгән шәфкатьле каралты-кураларны; йорт, кое, абзар, мунча ияләренә өн биргән ярым караңгы чормаларны, хәтта моңа кадәр иркәләп аккан нур тасмаларын да үзгәрткән иде.

Кыз җомга көн иртәнчәк ашыгып чыгып киткән дә,

кайтмаган... Югалган кыз. Тулы бер көн, тоташ бер төн узган, көннең икенчесе кимеп бара, кайтканы юк. Эзләгәннәр, авыл халкы урманның иң ерак, иң аулак шырлыкларын, чокыр-чакырларны, елга-күл тирәләрен айкап чыккан. Көн уртасында ике вертолет килеп урманның кояш нуры төшеп җитә алмас куелыкларын аркылыга-буйга иңләгән, кошлар, ояларын ташлап, пыр-пыр очканнар, бурсыклар, төлкеләр текә ярлы ермакларга чумганнар. Кошлар күргән, җәнлекләр куркып ары-бире чапканнар, урманда адашса кыз күрми калыр идеме?..

Якын-тирә авыллардан, аэропорт, пристань тирәләреннән хәбәрләр килеп ирешкән, телефоннар өзлексез зыңлап торган: «юк... юк... андый кызның күзгә-башка күренгәне юк».

Кызның тауга менүе расланган. Нигә шушы юлсыз якны сайлаган ул? Тау өстендәге урман шактый калын, иңе-буе җиде-сигез чакрым, диләр. Таулы, чокыр-чакырлы серле урман. Адашкан дияр идең, баш очында кояш эленеп торганда ничек адашмак кирәк? Нигә әнисенә берни сиздермәгән? Моңарчы гаҗәеп тату, дус яшәгәннәр ич алар! Нигә япа-ялгызы чыгып киткән? Кая юл тоткан? Дөрес, андый-мондый бәла-казага баш бирерлек кыз түгел, исәү, нык, җитез бала. Чаңгыда җилләр белән янәшә чаба, дулкыннарны иңләп йөзә... Кичә, җомга көн кызга уналты яшь тулды.

Уе шушы урынга чабып барып җиткәч сөрлекте, егет утка пешкәндәй сикереп торды. Әйе. Алар җомга иртәсендә очрашырга сүз беркеткәннәр иде. Кыз: «Хәлил, мин сезне Каракүл янында көтәрмен»,— диде. Егет нәрсәнедер ошатмады: «Нигә аеры-чайры йөрергә? Урман уртасы дисең икән, бергәләп барыйк!»— дип карышты. Кызның ал битләре тәмам яна башлады. «Юк,— диде ул әчке наз белән,— иртәгә минем сезне көтеп аласым килә!» Егет әченнән генә: «Син барып җиткәләгәнче мин әллә кайчан анда булырмын әле»,— дип уйлады.

Хәлилдән башка берәү дә кызның ник чыгып киткәнен дә, кая барырга исәп тотуын да белми булса кирәк... Кем уйлаган вакыйгаларның бөтенләй башка якка борылып кереп китәсен!..

Пәнҗешәмбе кичендә, кыздан аерылып киткәч, җылы уйлар дулкынында иплэп кенә, кабаланмыйча кайтты егет. Нәсимәнең соңгы тәкъдиме серле дә, рәхәт тә иде. Аңламассың аны! Күңелендәгесе тел тирәсенә килеп җиткәнче әллә никадәр чуалышларны үтә!.. Алай да, алай да... Каракүл янында очрашу... Әле хәзерге заманда да яшәп калган икән борынгы китаплардагы кызлар... Кыз

моңа кадәр дә һәр очрашуда аның һушын ала торган гамәлләр ясап куя иде. Соңгы сүзе исә егетнең йөрәгенә сары май булып ятты. Йортына якынлашкан саен ул үзе дә сизмичә ашыга башлады һәм болдыр баскычына җитәрәк тагын да кызулады... Ишек келәсенә эленгән ак кәгазь почмагын ул ерактан күреп алды. Күрүгә, күкрәк читлеген кысып шом агыла башлады. Тормышы җай гына барган мәлдә ул бер яңалык та: яхшысын да, яманын да көтми иде!..

Кып-кыска телеграммалар да еш кына дәһшәтле сүзләрне сыйдыра. «Урал үз-үзенә кул салган. Җомга көн җирлибез».

Урал, Урал... Әфганлы Казан егете...

Ул үзен җылытып торган дөнья, үзен чолгаган ару кешеләр күрмәсен дигәндәй, калтыранган куллары белән кәгазьне дүрткә бөкләде дә куен кесәсенә йөрәге турына шудырды. Һәм җәһәт-җәһәт әзерләнә башлады. «Сигезенче солдат!» диде ул, куркыныч уйларын арлы-бирле куалап. Татарстанга егерме ике солдат бергә кайтканнар иде. Юл ерак, солдатларның күбесе электән таныш. Лаеш шулпасының иң әчесен бергә-бергә эчкән чордашлар. Бик җентекләп адресларын алыштылар, аерылмаска сүз берkеттеләр. Егерме икедән сигезенче егет үз ихтыяры белән бу дөньядан китеп бара. Зәй ягы егете, гармунчы, җырчы Вәдүтне тышка чыккан җиреннән әфганлылар урлап китәләр һәм ирлегеннән мәхрүм итеп кайтаралар. Корбаннарның беренчесе ул булды. Туган төягенә кайткан Вәдүт, кардәш-ыруларын, якыннарын йөреп чыккан, әбибабасы рухына Коръән укыткан, ятим-ялпы карчык-корчыкларга садака биргән. «*Ходама рәхмәтлемен, соңгы иң зур теләгем кабул булды, газиз әткә-әнкәмне, туганнарымны күрү бәхетенә ирештем. Инде бүген бер теләгем дә калмады*»,— дип язып калдырган да карурман уртасындагы иң карт имәнгә элмәкле бавын салган. Егетнең кырыгы үтәр-үтмәстә Исмәгыйль исемле Тау ягы егете ак серкә эчеп, интегеп, бәргәләнә-бәргәләнә кемнедер каргап китеп барды. Ул Әфган җәһәннәмендә җәфа чиккәндә, вәгъдәләшкән наян кызы шәһәрдән икмәк ташырга кайткан шоферның муенына асылынып китеп барган икән. Өч кенә көн таныш булганнар кияү белән кәләш. Әнә шул дорфа кинәтлек, һичкемгә аңлашылмаган шыксыз ашыгу алып киткән егетне...

Татарстанның кайгысы китеп тормады, мәңгегә серле цинк табутлар янәшәсенә берән-сәрән солдатлар да үз ихтыярлары белән барып ята тордылар, быел яздан, Хәлил Җиһанша абзасының бәрәкәтле ихатасына аяк баскан-

нан бирле матәм чылбыры өзелде. Кыйналып-җәфаланып үз сукмакларын тилмереп эзләгән әфганлылар, ниһаять, урнаштылар дигәндә, Урал китеп барган. Урал, Урал! Хәлилнең бөтен әфганлы солдатларын сыйдыра алган нәзек җанында ефәк кыл зыңгылдап өзелде: егерме ике егет арасында Урал бәхетлеләрдән санала иде. Ходаем, мәүләм! Дүрт саны исән килеш кайтты, үз аягы белән әнкәсе бәгыре алдына килеп басты. Күзләрен тутырып туган шәһәренең Әфган төшләренә кереп йөдәткән урамтыкрыкларын, Идел буйларын күреп сөенә алды. Балта остасы булып төзелешкә эшкә урнашты. О, бәхет! Күпме җимергәннән соң, ничаклы тар-мар китергәннән соң ул төзи башлады... Өйләнде! Фатир алды! Ниһаять, улы туды, улы! Сөя алу, ир булу, бала әтисе булу әфганлыларның бик күбесенә тәтеми торган бәхет иде. Һәр әфганлының иң яшертен хыялы шул түгелмени?.. Әллә нинди газ сөремнәре белән агуланган, кортлы сулар эчеп әгъзаларын бозып бетергән солдатлар әти булу бәхетенә ирешкәч, мәрхәмәтле Хода кодрәте белән изге җаннарга әйләнәләр дип исәпли иде Хәлил...

Көтелмәгәндә ялгызак тормышының тоньк офыгында кыз шәүләсе пәйда булып, Нәсимә белән очрашкалый башлагач, Хәлил, әз-мәз терелеп, җанланып китте, пәнҗешәмбе кичендә бәйрәм төсе алган сүзләр, бирелгән вәгъдә кайнарлыгы егет йөрәге түрендә бөреләнә башлаган яшерен өметләрне ныгытканда гына, арага шомлы сәмум җиле булып, Урал килеп керде. Керде дә бер селтәнүдә якты өметләрне сөремгә салып каралтты, егет чыраена сизелерсизелмәс сибелә башлаган нурларны күренмәс итте.

Ни сәбәп булды Уралның үлеменә?! Соңгы сәламне тапшырырга да, Уралның үзеннән соң калдырган кайгының тамырын ачыкларга Казанга барырга кирәк иде...

Солдат җеназасының үз кануннары бар. Монда да шул булды. Комсомоллар дөнья буржуазиясен каһәрләп майлы иреннәрен җәя-җәя ут чәчтеләр. Тирән базда үргән бәрәңге сабаклары төсле ак чырайлы, җеп сыйраклы пионеркалар соңгы тамчы канга кадәр империалистлар белән көрәшергә чакырып, ал галстукларын җилфердәттеләр. Зиратның аулакка, сагышлы тынлыкка гадәтләнгән кошларын куркытып залп тавышы яңгырады. Дары исе килеп торган ак кашлы солдатларны һәм чыра-сузан прапорщикны төяп машина китеп баргач, дөньядан вакытсыз күчәргә мәҗбүр ителгән солдат рухына дога укылды. Солдат әнкәсен кабер өстеннән көчкә кубарып алдылар.

Егет, анага ияреп, алар фатирына кайтты. Сорашырга,

ачык яраны тырнап канатырга ярамаса да, Хәлил сак кына, сүзләрнең җиңелләрен эзли-эзли сораша башлады: ничек? Нигә? Ни сәбәп?.. «Нишләмәк кирәк, тормыш кануннары аяусыз»,— дип, ул ананың кан качкан чыраена, зәңгәрле йомык сызыкка әйләнгән иреннәренә карады.

«Улым-баламны сау-сәламәт килеш күргәч җылый да алмадым,— дип сүзен башлады ана, бераз тынычланган-дай булгач.— Ул шул Алла каргаган илдә чакта һәркөн җылап күз яшьләремнең тамыры корыган идеме?.. Карадым да каттым... Кайткан шәпкә авыз ачып берни сөйләмәде, балакаем. Елмайганын көтәм, юк, чырае гел сүрән, карашы суык, караңгы. Әллә балакаемны алмаштырып җибәрделәрме дип борчылам. Күргән-кичергәннәрен гел бикләп тотты, бәгырькәем... Өстәп тагын ни әйтә алам? Сорашырга да базмадым, кайчагында артык төпчену адәмнең җанын изә!.. Эшкә урнашкач, әз генә чырае яктыргандай булды. Өйләнгәч үзгәрерме дип көтәм... Юк! Хатыны: «Нигә бер сүз дә әйтмисең, дип өзгәләнә, улым дәшми. Инде үз улы, Мараты тугач, ачылырмы дия-дия көтәм... Гитарасын ала да улының баш очына килеп утыра, тын гына чиртә, моң гына нидер шыңшый... Җыры аша да серен ачмады бичара. Бәхете шул булды, улының «Әти!» дигәнен ишетеп куана алды... Шул кичне үзем гел-гел әйтә торган куаныч сүзләрен кабатладым, «и, улым, балам» дидем! «Әби-бабаңнарның хәер-фатихасы аркасында булгандыр, Ходаның күзе сиңа якты булды, шул гарасаттан исән-аман кайттың бит!» дидем. Улым озак кына миңа карап торды да, ят, сагышлы тавыш белән: «Әни, әни... Азагы ни белән бетәрен кем белгән әле аның?!» — диде. Бүтәнен ачыкламады, ачылмады. Ялгыз калудан курыкты. Сиздермәскә бик тырышса да, сизелми каламы соң? Унар көн авызга кайнар аш кермәгәч, каты-коты ашап тешләре коелып беткән иде. Чәрдәкләнгән тешләре. Тамыры гына калган. «Врачка карал» дибез, бармады, йөрмәде...

Үләсе көнгә кадәр зур үзгәрешләр шәйләмәдем улымда... Шул булды, хатыны бәбәен күтәреп авылга кайтып киткән иде. Тормыш бит, әткә-әнкәсен сагынгандыр... Улым ит турап аш салган, кәстрүлен утка куйган, өй тәрәзәләрен киереп ачкан да... ичмасам бер-бер язу калдырган булсачы!.. Әҗәленең сәбәбе аңлашылыр иде ичмасам. Болай үземне гаеплим... Килен кайтып китмәгән булсачы дип аңа да рәнҗим... Уйлары үзе белән китте, безгә өем-өем кара хәсрәте генә калды...»

Бөтен тәрәзәләрне ачып куюына, мөгаен, Хәлилдән башка игътибар итүче дә булмагандыр... Көйгән ит исе!..

Ис! Каһәр төшкән ис! Әфганда мәетләрнең үзенә генә хас авырсы, борынга керү генә түгел, яңакларга, тәнгә, култык асларына сылана торган явыз хасияте бар. Чәч араларына кереп оялый бу авырсы ис, бугазны томалый, борын тишекләренә сөрем булып кереп тула, тынны буа. Исендә Хәлилнең, алар, чолганыштан котылып, биш кеше чыгып киләләр иде. Сукмак тар тарлавыкка кергәч, аларга шунда тукталырга, качар урын хәстәрләп, төнне көтәргә боерык алынды. Яктыра башлаган иде шул, ятып кына өлгерделәр, төрле яктан выж да выж пулялар оча башлады, якында гына ухылдап мина ярылды. Кызулык белән чамалап өлгермәгәннәр икән, атыш бераз тынгач үзләренең нинди яман тәбегә төшүләрен аңладылар. Тарлавыкта кичә-бүген каты бәрелеш булып узган икән. Анда да, монда да мәетләр таралып ята иде. Ачык авызларына, тирән яраларга, күз чокырларына ком тулып тыгызланган. Җил йөри алмый торган тарлавыкка адәм чыдамаслык исләр сеңгән иде. Егетләр моннан чыгып ычкынырга маташып карадылар. Атыш көчәйде, рациядә рота командирының янаулы тавышы ишетелде: «Кузгалмаска! Кыймшанмаска!» Әфганнар да тарлавыкны нык күзәтә иде, ахрысы, егетләр чак кына кыймылдауга, пулялар яңгыр булып ява башлый. Бер-бер артлы ике мина төшеп шартлап инде мәңгегә тынган мәетләрне тураклап, һавага чөеп тараттылар. Кичкә биш солдатның икесе исән калды... Эңгер-меңгер куерып, инде котылырбыз дип, бер-берсенә куәт биргәндә, янәшәдә генә тагын мина ярылды... Аркасын мина ярчыклары чәрдәкләгән Хәлилне аннан-моннан бәйләштереп, ике автоматны уң җилкәсенә салып, сулына егетне кочтырып Урал тарлавыктан ничек котылып чыга алгандыр, анысын бер Хода белә...

Булды инде хәлләр, күрде башлар, аларны бүтәннәр дә аңларлык, кабул итәрлек дәрәҗәдә сөйләрлек сүзләр телләрдә юк шул, юк... Әфганнан һәр солдат үзенчә кайта, үзенчә яши. Хәлил тоташ ялгызлыкка омтылды, Урал исә ялгыз калырга теләмәгән, кешеләргә тартылган...

Тарлавыкта үткән төннән соң, телләрен тешләделәрме егетләр, әллә бүтән бер вакыйгадан соңмы?.. Ротаны төн уртасында кузгаттылар. Якын кышлакка Әфган солдатлары кереп тулды, дигән хәбәр алынды. Рота, кышлакны өч яктан урап алып, һөҗүм башлады. Хәлил уң флангта, янәшәсендә тәбәнәк, базык гәүдәле искиткеч моңлы дала баласы казакъ Кунакбай. Дөм караңгы, төрле якта атыш, кычкырыш, тәбәнәк балчык коймалар артында суеш. Менә Кунакбай, сәер дуга ясап, алга омтылды да автоматы кулыннан ычкынып өскә очты, үзе уң кулын алга таш-

лап, җиргә барып сеңде. Хәлил аны чалкан әйләндергәндә, Кунакбай җанын биргән иде инде. Йөрәге усалланып какканын да, тешләренең ямьсез шыгырдавын да шушы мең төрле тавышлар укмашкан мизгелдә ишетте Хәлил, комташтан өелгән дувалны ничек сикереп чыкканын да, түбәдән кара төтен урләгән кура арасына ничек бәреп кергәнен дә абайламады, ура дип тә кычкырды бугай. Куркыныч кызгылт шәүләләр, комсыз өрәк булып елтыраган ялкын телләре арасында җан ияләре аның ихтыярын ялмап йотты, ул, автоматын ике куллап тотып, патроннары беткәнче шул тирәгә ут яудырды. Эшен беткәнгә санап каралты-кураны әйләнеп кенә чыгасы да бит, ниндидер яшерен ым аны алга өндәде, Хәлил Кунакбайны атып еккан дошманнарын күреп, тантана итәргә теләдеме, кура астынарак керде. Курку хисе каядыр качкан иде бу мизгелдә. Балчык дивар янында ике сабыен ике ягына кочкан яшь кенә хатын ята иде. Ана каны балалары каны белән аралашып, нәни ермак ясап, аның аяк очына агып килеп җиткәндә генә Хәлил аңына килде... Кайнар кан — ана белән бала каны — аның җанын куырды...

* * *

Гел-гел үткәннәр белән яшәп булмый, Җиһанша абзасының якты рухы тәэсир иттеме, Аксу авылына күчеп килгәннән бирле, авыр хатирәләр читкәрәк киткәндәй булдылар. Абзасыннан калган эш кораллары: үткер балта-пычкылар, өтергеләр, ышкылар һәммәсе эшкә ярады. Ул иплэп-иплэп балта эшенә өйрәнде, әүвәл башлап умарта ясарга тотынды...

Монда күчеп утырганчы, тагын бер күңелсезлек ияреп йөрде егеткә. Кайткан шәпкә, кайсы тарафларга барып урнашса да, аны чая, шактый әрсез, йомры гәүдәле бер калыпка сугылган клуб кызлары йөдәтеп бетерделәр. Итәкләрен җилфердәтеп, француз хушбуе исен таратып киләләр дә керәләр, көн дип тормыйлар, төн димиләр, халык алдында чыгыш ясарга чакыралар. Егетнең орден-медальләр белән бүләкләнүе якын-тирә районнарга да килеп ирешкән. Күрер күзгә сау-сәламәт, әфганнар аның биек, зифа буен сындыра алмадылар, алга чыгыбрак торган нык ияк тә зарарланмады, гайрәтле ирләргә генә хас калынча дәү борын да урынында калды. Бер килеп карадылар егет янына, икешәре-өчәре озак-озак үгетләделәр, майлы күзләрен уйнатып, күз төшүгә ир-

атларның дәртен котырта торган түгәрәк артларын боргаладылар. Егет башта бик читенсенеп кенә баш тарткан иде, кызларның һөҗүме активлаша төшеп, кайберәүләре кичке чәйгә аулакка ук дәшә башлагач, ул илчеләрнең авызы ачылуга очрашулардан кискен баш тартты. Каян шушы кадәр гүзәлләрне җыялар да шушы мәдәният институтына, ничекләр итеп һәммәсенә сандугач теле куеп чыгаралар?.. Егет озата чыкса — бетте, бер алдына, биш артына төшәләр егетнең, ялгыш таеп киткән булып, аһылдап кочагына авып төшәләр, ут атып торган түшләре белән аңа ут төртергә һәм көлгә әйләнгәнче яндырырга телиләр. Әрсез кызыкайлар егетне шиккә төшерде: хатын-кызга тартылмый икән аның мең ямау күргән тәне. Аның, Әфганның сәмум җилләрендә иң нәзек күзәнәкләре коелып бетеп, сугарылган корычка әверелгән җанын дөньяның бар назларын үзенә җыйган хатын-кыз тәне дә уята, җылыта алмый икән. Якыннары аның тоташтан бәргәләнгәнен чамалап димләп карадылар, «фәләннәрнең кызы ничек булыр икән?» дип сүз башладылар, әмма егет сүз ияләренә шундый итеп карады, тегеләр, авыр күз карашын күтәрә алмыйча, бөгелеп тындылар. Хатын-кыз дигәндә әфганлы солдатның күз алдына ике сабыен ике ягына кочып алган яшь хатын килә торган иде.

Аксу авылы шул ягы белән дә ошады егеткә, авыл халкы сораулар биреп бер чакта да борчымады. Гомумән, бу авыл кешеләре сүзне иң кирәк чагында гына, анда да сайлап, һәр сүзнең кадерен белеп кенә авыздан чыгаралар иде. Белә егет, артта күзе булмаса да күрә (әфган гадәте: артыңда ни барын күрергә өйрәнмәсәң — эшең харап!) — ул үтеп киткәч, кызлар борылып-борылып карыйлар, кайчагында озаклап карап та торалар. Ләкин кызларның сер ташып торган мәхәббәтле күз карашлары да аның кырык тапкыр иләнгән тән тиресенә үтеп керә алмадылар...

Ул Уралның чуар хатирәләрен юлда чәчә-чәчә шактый кайтты, районара автобустан төшкәч озак кына машина көтте, гасабиланып, ашыгып, ярсый-ярсый сәгатенә карап көтте. Гомернең тыгыз мизгелләре була, күңел өзек-өзек килгән уйларны барлап җыя алмый, уйлар дуамал, күз ачып йомган арада әллә ниләр баш миендә айкалалар. Егетнең хәзер шундый чагы иде. Уйлар әле Казанга әйләнеп кайтты, әле Нәсимә янына ашкынып аны әрлебирле сөйрәп йөртте... Ярты юлны үттем дигәндә, күңелнең чайкалган диңгезе уртасында яшел утрау булып бары ул гына калды. Бүген шимбә. Кичә алар карурман уртасында, Каракүл янында, күрешергә тиешләр иде...

Танышуларына күпме вакыт булды инде?..

Хәлил беренче мәртәбә су керергә инешкә төште. Су әле җылынмаган иде, кулын тыгып су чәчрәтеп уйнагач, ул суыксып куырылып алды. Нәкъ шул чакта, инеш аръягындагы чуаклыктан, күке кычкырып сәлам бирде. Санамады ул күке тавышын, гомеренең күпме калуы белән дә кызыксынмады, озак яшәсә ни дә, кыска гомерле булса ни?! Алай дип тә уйламады, әле ул бу дөнья гамәлләренә ифрат дәрәҗәдә битараф иде. Озак кына аккан суга карап торды, уймакланып аккан инеш, бормадагы тын тугайда йөзгән каз бәбкәләре, сөзәк яр буена сибелгән сап-сары кимәшә башлары, тал чәчкәләрендә күңелле выжлаган бал кортлары, иренеп кенә уянып тәнен иркәләгән талгын җил аның күңелен дә җилкетә, билгесез көч каядыр дәшә, чакыра иде. Ул бал кортлары сарган талны кочаклардай булды. Ярда маяк булып ялтырып яткан ап-ак шома ташка басып тагын су болгатты, бу юлы су шактый җылы кебек тоелды. Ул башта күлмәген салып ташлады, мул коелган кояш нурларында коенды, аннан, чалбарын салып ташлап, тез тиңентен суга керде. Меңләгән энҗе бөртекләрен чәчрәтеп чирканчык алды, аннан үзен кочып-көтеп алган инеш агымына түше белән ятты. Су, тәнне иркәләп, аның култык астына менеп җитте. Егет кинәт җиңеләеп китте, көнтөн тәнне зынҗырлардан ычкындырмаган сызлануларны Аксу авылының инеше юып алып китте, ул күптән татымаган бар рәхәтлекне татып, кинәнеп озак кына коенды. Туңмады, су салкынын сизмәде, якынрак агачларга күчкән күке яр балчыгына бармак эзләреннән чәчәк сурәтләре ясап, судан чыгучы егетне куанып каршылады. Бу юлы да алдагы гомерен санамады егет. Дөньяга сүлпәнлек, язмышка битарафлык бөтенләй үк китеп бетмәгән иде, алай да аңа рәхәт, бик рәхәт булып калды. Сөлге алып төшкән булса да, егет тәнен корытмады, күлмәген дә киеп тормады, сөлгесен беләгенә салып ярдан өскә атлады. Каршысына тавык йомыркасы хәтле ак ташның йөгереп төшкәнен күреп, күзен күтәреп югарыга карады: ярда, сукмак уртасында, бер кыз басып тора иде. Егет яр күләгәсендә булганга, ул нурга коенган кызны аермачык күрә дә алмады бугай. Шушы биек-биек бик киң зәңгәр гөмбәзнең бар нурын үзенә җыйган фәрештә идеме ярда, егет бер мәлгә сукырайды. Бу сәер халәтеннән котылмак өчен, ул йодрыгы белән күзен уып карады, сәерлек югалмады, дөньяның үзәгендә нур көлтәсе булып ул гына басып тора иде. Баш очында изгелек билгесе — алтын кояш яна! Ул тиз-тиз менеп җитте

һәм кызны читләтеп үтәргә җыенды. Кызның ягымлы карашы туктаттымы аны, тыенкы гына көлеп куюы сискәндердеме?! Хәлил кыз янында туктап калды. Алар урыннарын алмаштылар, кыз инеш ягына чыкты, ул кояшка аркасы белән борылды. Үзенең шәрә тән икәнлеген абайлап, капыл-копыл күлмәген киярга итенде, җиңнәрен таба алмыйча югалып калды. Озын сөлге кулыннан ычкынып очып китте һәм кызның аягына төшеп ятты. Ул ихтыярсыздан кыз алдында иелде, кызның озын торыклы булуын искәрде. «Сөртенмәгез,— диде кыз аның юеш җилкәсенә сокланып карап,— тәнегездәге һәр тамчыга берәр кояш сыйган». Аннары өстәп куйды: «Сез кояштан тукып ясалган шикелле». Кызның горур, озын муены... «Нәкъ Нефертети!» дип уйлап алды егет көтмәгәндә, ике иңенә яткан калын коңгырт толымнары, кабарынкы-тулышкан уймак иреннәре күзе ачыла барган саен, аны ныграк җәлеп итә тордылар. Кызның мул чәчләре толымнарга сыймаганнар, аннан да моннан да килешле чуклар булып матур бөтеркәле колак тирәләрен, ап-ак маңгаен бизәп таралып ятканнар, бу тараулык та аңа килешә, кызны бизи, тагын да сылурак итеп күрсәтә иде. Кыз егетнең җилкә ягына чыкты һәм нәфис, озынча бармаклары белән аның тәненә сарган тамчыларны җыя башлады. Егет уңайсызланып читкәрәк тартылды, кыз моңлы күкрәк тавышы белән: «Кояшларны миннән кызганасызмы?»— дип сорады. Егет аптырабрак башын чайкады һәм кыюланып үзенә якынайган күзләргә тутырып карады. Башта ул кызның каш-керфекләренең төсен аермады. Кызның күз читләрендә балкыган шаян ут ноктаcларын гына күрде. Аның озын керфекләр белән мул каймаланган күзләре нур белән дә, наз белән дә туп-тулы иде.

«Мондый илаһи пәри кызы каян килеп чыккан монда?» дип уйлады егет, әмма сорау бирергә ашыкмады. Кыз, озын аякларын еш-еш алыштырып, егет тирәсендә әйләнеп чыкты, егетне сихри гөлләрдә генә була торган хуш ис болыты эчендә калдырды. Иң актыктан гына ул кызның ап-ак күлмәгенә сер өстәп калкынган нәни, гөнаһсыз күкрәкләренә күз йөгертте. Карашының тыелган зонага юнәлүен абайлап читкә борылды, шул мизгелдән файдаланып күлмәген киде. «Сезнең бер сәдәфегез төшкән»,— диде кыз, аннан күзен алмыйча. Зур кимчелекне дә әйтмәде кыз, сәдәф төшкәнгә исе китмәде Хәлилнең, алай да кайтыр юлга атлады. Кыз аңа иярде, алар Җиһанша карт ихатасына кадәр сөйләшмичә кайттылар. Юл-сукмак тар, бара-бара ул бөтенләй тараеп куя, кыз-

ның шәрә беләге аңа тиеп-тиеп китә, иң гаҗәбе, егет сискәнеп-куркып кыздан читкә тартылмый, табышмаклы сәфәргә тарыган сизгер йөрәге генә сулкылдап, кысылып куя. Капка белән инеш арасы шактый булса да, ул нибарысы кызның Нәсимә исемле икәнен, аның быел унынчы классны тәмамлап килүен белеп алды. Озакламый аңа уналты яшь тула икән... Кызга уналты, ә Хәлилгә көзен егерме дүрт тулачак. Моңарчы яше хакында да уйлаганы юк иде аның, бүген сызланып уйлады. Сәбәбе генә билгесез. Анык түгел иде.

Егетнең даими боек күңеленә иң әүвәл кызыксыну иңде. Ул инеш ярларына яратып, ашкынып йөри башлады. Су буена төшсә дә, яр астында күмелергә ашыкмый. Һаман-һаман борыла-борыла сукмакка текәлә. Күз төпләренә дым җыелганчы көтә кызны... Шулай, телләр ачлыр чак җитә дигәндә генә, кыз инеш ягасына төшмәде. Бер көн күренмәде, ике көн. Өченче көн уртасында егетне шик болытлары урады. Алай да кыз хакында берәүдән дә сорашмады, сорарга да җыенмады. Тәки бер тәмсез сүз әйтеп әкияти тәэсирләрен бозарлар! Хәлилнең кыз хакындагы кайнар фикерен бер дә үзгәртәсе килми иде. Инде яңадан күрешү насыйп та булмас дип уйлаганда, алар тагын очраштылар. Юк, бу юлы инеш ярына барып җитмәгәннәр иде әле, егет шунда барырга җыенып чыкса, кыз аны капка төбендә көтеп тора! Кыз белән танышлыкның азагын кат-кат күз алдына китереп, аның күзгә күренмәвенә күнегә вә ризалаша башлаган егет аптырап китте. «Нигә килеп йөри? Боз явып сүндергән учактан җылы табып буламыни? Аңа уналты булса, миңа егерме, дүрт!.. Кат-кат телгәләнгән, йөз кат ямалган тәнемне күрде ич!.. Инвалид!..»

Хәтсез вакыт көткән кыз, капка баганасы тирәсенә туфля үкчәләре белән кытай иероглифларына охшатып нидер язган. Эх, беләсе иде бу чуар эзләргә яшерелгән серләрне! Дөрес, кызның юкка көтмәгәнен егет аның зур ачылган коңгырт күзләреннән дә күрә. Каушаганмы бүген кыз, гайбәт җиле кагылып егып киткәнме, куе, озын керфекләре өзлексез тирбәлә. «Йөреп киләбезме?» диде кыз, басынкы гына. Инде үзләренеке булып килгән тар сукмактан алар тауга менә башладылар. Кыз сөйләргә дә, сораштырырга да ашыкмады. Атлыйлар, атлыйлар, сәер тынлык та алардан калмый, кыз иелебрәк атлыйатлый да текә муенын капылт борып, егеткә карап ала. Егетнең күз алдында яшен уйнаган кебек, яктысы килеп җитә, яшен уйнаткан болытлары гына таралмый! Нурга манчылган күзләр егетнең бәгырен суыралар, кыз

ягыннан моңсу ишарәләр, җылы дустанә ымнар ага. Тик нигә шушы кадәр моңсу ул бүген? Кыз егетнең соравын аңлаган кебек: «Ә мине районга алып киттеләр. Иртәдән кичкә кадәр шунда тоттылар»,— диде. Егет кызның тавышында тәшвишле аһәң ишетеп туктап калды. «Без иреклe темага сочинение язган идек,— диде кыз, толым очын бөтергәләп,— мин «Без нигә Әфганстан җиренә барып кердек?» дигән теманы сайладым». Егетнең аркасын чуарлаган яра җөйләре чымыр-чымыр килде. «Каян килде синең яшь башыңа андый сорау?!» дип кычкыруын сизми дә калды. Кыз егетнең күзләренә керердәй булып төбәп карады: «Миңамы?.. Яшьтәш, классташ малайларга карый-карый уйладым мин ул хакта... Бик курыктым! Ике елдан аларның да билләренә каеш салып, Әфганга алып китәчәкләр бит! Сабыйлар! Буыннары ныгымаган малайлар!.. Немецларга каршы сугышны аңлыйм мин! Дошман илгә ябырылып кергәндә, сугышмый хәлең юк... Ә монда кемне яклап сугышабыз без? Кемнәр ихтыярына буйсынып авылларга бер-бер артлы цинк табутлар кайта? Рәҗәп авылына туганнан туышканым Әнәс шулай кайтты... Вагыйз абыйны күрсәгез иде сез... Мин аның хакында да яздым... Мәктәпкә инспектор килгән иде, мин язганнарга күзе төшкән тегенең! Үзе белән алып та киткән. Шул. Чакырдылар мине. «Каян өйрәндең син мондый сүзләрне? Кемнән отып алдың?» дип сорадылар. Сезнең хакта да төпчентеләр. Аның күкрәгенә әле әрнү, әле усаллык, әле кемнәндер үч алу тойгылары алмаш-тилмәш тула торды, йөрәге какты. Ул үләннәр куерак кабарган урынны күрсәтте дә, кыздан алда үзе барып утырды. «Сиңа чыннан да уналты гына туламы?» дип сорады. Кыз егетне нинди уйхисләр җиргә тартканын аңлады шикелле, элеккедән дә якын итеп аны күз нурлары белән иркәләде. Егет, тирләгән маңгаендагы җыерчыкларны җыярга теләгәндәй, учы белән маңгаен кат-кат сыпырды. Кинәт карлыккан тавыш белән аска, авыл өстендә тирбәлгән зәңгәрсу рәшәгә карап сөйләп китте. «Адәм җаны һичвакыт югалмый икән... Ул берәүләрдән берәүгә күчеп йөри, имеш. Сиңа үтә сизгер җан күчкәндер, Нәсимә!» «Нигә? — дип борчылды кыз.— Сүзләремнән гаеп таптыгызмы? Сез дә сугышка унсигездә барып кергәнсездер ич?» «Юк, юк! Яшь ягыннан шактый зур идем инде мин! Акыл ягына килсәк... дивана, шыр тиле булганмын! Ишәк улы ишәк! Эти военком минем, хәзер дә шунда утыра. Ул мине яшьтәшләрем белән армияга җибәрмәде, укырга кертте. Алабугада пединститутта укып йөрим!

Әнием райкомда, гомере буе партия учеты бүлегендә эшләде! Кызыл авыз! «Егет кеше — ил сакчысы! Ватанны саклау уртак бурычыбыз!» Былбыл булып сайрый!.. Җүләр баш мин, тиле сөяк!.. «Әфганстан халкын кырып ничекләр Ватанны сакламак кирәк?» дип сорыйсы гына бит... Юк! Гариза арты гариза язып, Әфганга җибәрүләрен сорыйм! Әти йодрык күрсәтә, әни мактый!»

Егет, кызның күз нуры көлтәсенә эләкмәскә тырышып, иягеп күкрәгенә тидереп озак кына сүзсез утырды. Тордылар. Кузгалдылар. Өскә таба атладылар. Кыз хәзер терәлеп диярлек бара, бара-бара да адымнарын тыеп, йомшак үтә сизгер учы белән юка күлмәге аша егетнең җәрәхәт җөйләренә кагылып-кагылып ала.

Хушлашып, кызның сихри гәүдәсе эреп ерагайганда, сөйләшенгәннәрне яңа баштан акыл иләгендә кат-кат иләп, гамәлләренә хисап биреп караватында ятканда да егет үкенмәде. Томаналык хурлыгын, әтәчләнеп үзе теләп сәкарьгә барып керүен, Әфганстанны басып алуның кемнәргә кирәклеген бик тиз аңлап алуы хакында кемгәдер сөйләргә, күңелен бушатырга, ачылырга тиеш иде ул! Әфганстандагы беренче ай әтәчнең кызарган кикриген тиз шиңдерде! Анда чакта ук эч серләрен кемгәдер сөйләп бушанасы килгән мәлләре булды, тик кемгә сөйлисең? Үзең шикелле үк тездән канда йөзгән уртак язмыш иярәренә чишелүдән ни файда? Сине ул юатсынмы, син анымы? Кызга эчке ышану, тирән хөрмәт аны азаккача ачылырга мәҗбүр итте. Үкенмәде егет. Очрашкан саен аралар якынайды. Егетнең яшәве күңеллерәк, өметлерәк була барды.

Авыл арасында хәбәрләр, морҗалардан чыккан төтен сыман, һәр тарафка тарала, егет хакында фаразлар, юраулар телдән телгә йөрсә дә, сүзләрнең уңын да, сулын да Хәлилгә җиткергән кеше булмады. Аның Әфганстаннан каты яраланып кайтуын авыл халкы белә иде инде.

Җиһанша абзасының ятим яткан эш кораллары хутка китте. Лапас түбәсеннән ырмаулы такталар килеп чыкты. Егет умарта ясарга кереште. Өлгене иске умарталардан алды. Пычкы гөжләде, Җир шарының бу ноктасында тереклек барын раслап, юныш балтасы тукылдады, күп тә үтмәде, бакча түренә ике умарта чыгып утырды. Егет күчнең берсен сатып алды, икенчесен ерак кардәшләренең берсе китерде. Кардәш белән күчне икәүләп яптылар, кыз бер адым читтәрәк иелеп, егеттән күзләрен ала алмыйча күзәтеп торды.

Аралар нык якынайса да, кызның сәерлеге бетмәде, «Хәлил абый!» дип егетнең исемен атап эндәшмәде, һаман «сез» дип эндәшүе калды.

Ниһаять, бәрәкәтле июль азагы җитте. Кыз егеткә яңа хәбәр җиткерде. «Моңарчы туган көнем хакында уйлаганым булмады,— диде ул, кыенсынуын көчкә җиңеп.— Урыс гадәте, татарларга йогышмый торган йола итеп санадым. Өебездә төчеләнү, юхалану юк, әни дә, апа да шактый кырыс кешеләр... Сезне белә башлагач күңел әллә нишли... Тормышның кадере арттымы, белмим. Мәгәр бер нәрсәне — адәм баласының уналты-унсигезләрдә генә үз-үзенә хуҗа була алуын аңладым. Көлмисезме? Минем уналты яшь тулган көнемне билгеләп үтәсем килә». Иртәгә уналты тула дигән көнне алар тагын очраштылар. «Истә калсын иде минем бу көнем! Икәүдән-икәү генә, мәңге онытылмаслык итеп үткәрикче!» диде кыз, дулкынланып. Егетнең теленнән: «Кайда?» дигән сүз ычкынды. Кызның җавабы әзер икән: «Таң белән карурман уртасындагы Каракүл ярына барабыз. Ялкыны күкләргә үрелердәй дәү учак ягабыз... Тик авылдан аерым-аерым чыгыйк, яме. Ишетелер. Әни сүз әйтмәсә дә, апа рәнҗер! Мин сезне тау өстендә көтеп торырмын. Килерсезме?» «Киләм!» диде егет, сак елмаюын учына яшереп.

Буласы булды, сабыйлык сафлыгы чыгып бетмәгән кыз бала җиту егетне бөтереп йотты. Күрешкән саен егетнең аңа соклануы арта торды: каян килгән кызга шушы кадәр сизгер акыл? Язмышының көтелмәгән куанычлы бүләген егет сөенә-сөенә кабул итеп алды, кыз аның суына төшкән җанына рух өрде. Бер уй гына тынгы бирмәде: үз бәясен белеп олыларча җитди фикер йөртү, тиңдәшсез күңел бөтенлеге кайсы буын татарларыннан күчкән Нәсимәгә? Бу төбәк кешеләре арасында борынгы Бикчура хан токымнары очрый дип яза Сарман галимнәре. Ялгышмыйлардыр. Ничәмә-ничә буын татарлар изелеп, сытылып гомер кичерсәләр дә, татарлардагы тарихи олылык, олпатлык бөтенләй үк югалып бетмәгәндер ич?.. Ханның асыл токымнары, акыл-фигыльләре белән татарны татар итеп яшәткән асыл затларның эзләре юкмыни безнең араларда! Кыз, мөгаен, шундыйларның берсе булса кирәк. Сирәк очрый торган иң затлысы.

Димәк, ул җомга иртәсендә нәни юбилеен уздырырга чыгып киткән дә әйләнеп кайта алмаган... Тәвәккәллеге, кайнарлыгы аркасында баш китәрлек бер-бер бәлагә тарыганмы?.. Урал җеназасына чыгып китәр алдыннан егет кызның өенә кагылып үткән булса соң!.. Әнисе, апасы күреп, белеп торсын иде: алар арасында ямьсезлек юк, икесе дә былбыл балаларына тиң гөнаһсызлар иде. Кыз — Хәлилнең фәрештәсе, Хәлил — фәрештәнең тугры сакчысы иде. Яшьләр шундый мөнәсәбәттә булганда гына

ике арада тиңсез бөек мәхәббәт ярала ала. Яраттымы ул Нәсимәне? Моңарчы ул хакта өзеп уйлаганы булмады егетнең, андый нәтиҗә ясап язмышын өркетергә базмады. Әйе, хагы шул, госпитальдән чыкканнан бирле хатын-кызга теләге уянмады аның. Үзенең тышкы кыяфәтенә күз карашларыннан, сыгылып торган билләрдән, тирбәлеп-дулкынланып торган күкрәкләрдән әллә нинди вәгъдәләр сизгәндә дә эреп-мәмрәп төшмәде ул. Очраштырды, сылудан-сылу кызлар (бигрәк тә марҗалар!) аның кочагына кереп югалырга әзер икәнлекләрен туп-туры белдерделәр. Кызлардагы дәрт-дәрман үлгәннәрне сикертеп торгызырлык дәрәҗәдә булгандыр. Егет андый чакларда да башын җуймады, исермәде. Ишеттерделәр: «Бәхетсез турсык, Әфган корбаны!» — дип, соңгы катгый хөкем чыгарган кызлар да булган... Бар иде, үсмер чакта, институтта укыган елларда, айлы сихри кичләрдә егетнең кыз-кыркынны күзе белән ашаган чаклары да, сөеп, ими төймәләрен сизеп-капшап сихерләнгән мизгелләре дә бар иде. Бии-бии, таңнар тәнгә, ботлар ботка тиеп очкын сибелгән мәлләрдә тәүге мәртәбә егет белән якынайган тәҗрибәсез кызларның берсе: «Син нигә чалбар кесәңә таш тыгып йөрисең?» — дип сораштырып, самими эчкерсезлеге белән егетне таң калдырган иде. Әфганнан соң да һәммәсе тәртиптә кебек үзе, мәгәр егетнең «кесәсендәге ташның» чынлап торып җанланганы, аны каядыр, кызларның иң сихри тамгаларына өндәгәне юк.

Нәсимәгә уналты яшь тулган көн ике арага яңалык өстәргә, инде ике араны җилемләгән фикерләргә тулы мәгънә кертергә тиеш иде. Тиеш иде дә күрешү насыйп булмады. Кыз, егетнең иптәше җеназасына чыгып китәр дип уйламагандыр, дөнья ваемын онытып, Каракүл янына баргандыр. Күз нурларын коеп, ул килер юлларны яктыртып, ымсынып-сөенеп, җаны-тәне белән егетне көткәндер бичара.

Озыннардан озын бер көнне үткәргәндер... Егет килмәгән... Рәнҗеп, үпкәләп берәр яры китеп бардымы?.. Озын булмаса да, көтү газаплары белән авырайган төнне кайда үткәрде икән?..Инде озыннардан да озайган тагын бер рәхимсез көн үтеп бара. Ә кыз юк та юк... Әгәр ул көн-төн Каракүл тирәсендә уралган булса? Усаллар килеп чыгып мәк чәчәгедәй кызны изеп-таптап китмәделәрме? Явызларга тап булдымы кыз бала? Явызлыкның җирдә кимегәне юк, аның кулы аулак җәйләүдә яшәп яткан Аксу авылына да барып җитә ала.

Әле авылда Хәлилдән башка берәү дә җомга иртәсендә пакь җанлы кызның кая омтылганын, максатын белми. Серле вә шөбһәле язмыш йомгагының очы аңарда...

Казан сәфәреннән җаны ватылып кайтып килгәндә, егетнең алдагы сәгатьләре ап-ачык иде: әз-мәз баш-күз алыр да Нәсимәләр өенә чабар. Хәзер дөнья буталып, җирнең асты-өскә килгәч, язмыш арбасы тагын дөбердәп егетне таптап үткәч, ул исәнгерәп, аңгыраланып калды. Тәне сызлады, башы авыртты. Тик озак уйлап, акыллы нәтиҗәләр эзләп маташа торган чак түгел иде: кызны эзли чыгарга кирәк!.. Кайгы томанын сызлаган күкрәге белән таратырга тырышып, тауга менеп барганда, уйлар буталып бер-берсен тыгызлап ми тартмасында өелгәндә, ул бер нәрсәне генә ачыклады: кызны үлеп ярата икән Хәлил! Бу зур бәхет иде, сынган күңелне бер ноктага җыярлык олы сөенеч иде. Егеттә ярату хисе сакланган икән, ул яшәргә тиеш, яши ала. Тормышта ямь, тәм таба ала. Ишеткәне бар, дөнья йөзендә кешеләрнең сиксән проценты мәхәббәтнең татлы назын, татлы газабын татымыйча теге дөньяга китеп баралар икән. Димәк, адәм уллары тулы бәхетле була алмыйча дөнья куялар... Инде шушы кара язмыш аны да ялмап йота дигәндә, фәрештә кыз аның юлына килеп чыкты да... Ярата ич аны Хәлил, өзелеп сөя... Тик нигә бу бәхетле уй аның башына бүген, кызның эзләре җуелган чакта килде соң? Бәлки кыз, да аны сөйгәндер? Нигә ичмасам шушы хакта бер тапкыр булса да ачылып фикерләшмәделәр икән? Нигә ул, егерме дүрт яшьлек күсәк, чиле-пешле кабартма, җир җимерерлек тавыш белән «Кызый, мин сине яратам!» дип әйтмәде икән?..

Тауга болай озак менгәне юк иде егетнең. Бүтән чакларда күзгә күренмәгән ак ташлар сукмак уртасына чыгып әрсезләнеп, таралып ятканнар. Атлаган саен ботинка башы аларга тиеп китә дә ташлар шыбыр-шыбыр түбәнгә агалар, тәгәриләр. Кипшергән эт эчәгеләре талган балтырларга урала. Аяк табаннары уттай кызган, сөзәк җирдә дә таеп-таеп китә егет... Кыз исән-аман күзенә күренсәме... егет дөнья ярып кайнар, шашкан гыйшкын белдерер... Исән генә була күрсен берүк!.. Берүк, берүк... Дөрес, Уралның көтелмәгән һәлакәтеннән соң егетнең алдагы көннәргә ышанычы чак-чак кына какшады. Алай да, алай да... Кыз исән-аман булса, ул дөньяның бар бәхетсезлеген дә җиңеп чыгачак...

Егет тау башына тиргә манчылып, мышкылдап менеп җитте. Көн нык ук кичкә авышса да, чамасыз кыздыра, алҗыта. Аның тамагы янды, игәүдәй кытыршы теле тәмсез аңкауларына ычкынмаска ябышты. Ул, дөньясын онытып, соры тузанга әйләнгән җиргә утырды. Омтылып карый, күтәрелә алмый. Аякларга авыр-авыр герләр тагылган, җилкәгә автомат дисклары тутырылган

яшел капчык эленгән... Тирдән дымланган җәрәхәт җөйләре әчетеп сызлый. Әче тир керфекләрне чеметә, күзне сукырайта... Егет үзенә дә сиздермәскә тырышып, үксеп-үксеп җылый иде. Ниһаять, баш вата торгач, ул бер нәтиҗәгә килде. Кыз яшәргә тиеш, яшәргә... Әгәр кызны тере дип уйламаса, егет хәрәкәтсез, җансыз түмрәнгә әйләнеп юкка чыгачак. Ни үкенеч, ул кызга иң кадерле сүзен әйтергә өлгермәде, аннан җавап сүзе ишетмәде...

Ул үзен урыннан торырга мәҗбүр итте, мүкәләде, шактый араны шуышып дигәндәй барды, кысылган иреннәрен көчкә язып: «Кыз исән! Исән! Ул Каракүл янында мине көтә!»— дип кабатлады.

Урман аның җанын мәңгелек сер дулкыннары белән каршылады. Көнозын кояш нурында назланган түгәрәк аланнар, уңга-сулга каерылган шүрәле сукмаклары, әкияти тирән чокырлар, күзгә тартым мизгелдә сирәгәйгән кошлар чыр-чуы аңа хәл кертте. Тар юлда җиләс, салкынча иде, егетнең утлы сулышы тигезләнде, тире катты. Күзе ачылып, колагы аермачык ишетә башлады. Барыннан да бигрәк аны хуш исләр терелтте бугай... Ачык урыннарда, аулак кашлакларда мәмрәп кызарып чыпчык башы-чыпчык башы каен җиләкләре озатып калдылар. Тукталып торырга ярамый иде, көн ашыгып кичегә бара. Кинәт җәй җиле йөгереп узды, агач аралары сизелерлек караңгыланды. Болытларның иләмсез күләгәсе аны эңгер-меңгергә коендырып үтте. Кызның балдай татлы исемен атап кычкырасы килде егетнең, тавышы чыкмады. Кемдер аның баш очында: «Кыз исән! Исән!»— дип пышылдагандай булды. Уйга уй өстәлде: «Исән кыз. Исән! Ул сине күл янында көтеп тора».

Егет сүзендә тора алмады, вәгъдәсез булып чыкты...

Уйлар, бер-берсен уятып, бер-берсен ашыктырып актылар. Әйе, кызлар уналты яшьтә чәчкә аталар, дип уйлады Хәлил. Татар «уналтыды-унҗидедә кызның матур чаклары» дип тиктәскә җырламаган шул. Кайсыбер тарафларда «татарның акылы төштән соң» булса да, гыйшык-гашрәт җәһәтендә аларның күзе үткен булган. Егетнең дә уналты яшьлек җилбәзәк чагы бар иде. Акыл читтән йөри иде ул дәвердә! Уналты яшьлек кызлар да пешеп өлгергәндер, югыйсә тик яшьтәш егетләр яшьтәш кызларының нинди бөек гүзәллеккә ия булуларын аңламыйлар. Хәлилнең күңеленә дә үзеннән ике-өч яшькә олы, озын буйлырак, чандыр кызлар ошый иде шикелле. Нәсимә аны акылга утыртты, Ходайның иң мөккәмәл гүзәллекне уналты яшьлек кызларга һәдия итүен төшендерде. Йа Тәңрем! Илаһым! Әле бит алмалары язын ярал-

ган яфраклардай чеп-чиста... Табигать яратканча. Керфекләргә, кашларга кара кунмаган. Мәк чәчәгедәй саф иреннәрне кызыл бозмаган... Күрче, күрче, бер төртке, бер сызык имгәтмәгән ап-ачык маңгайдан акыл, нәзәкәт бөркелә!.. Горур башның көчен саклаган мәгъруро, озынча муен! Мәхәббәт арканнары булып сузылган калын толымнар. Кызның кай тарафына күз салсаң да, җан ял итә, аның гүзәллегеннән аерылып булмый. Әле артыкпортык ит кунмаган нәзкәй бил... Изге фәрештәләрдән гайре беркем дә кагылмаган йомры иңбашлары... Иңнәр, бил тирәсендә кыю гына йөгергән күз карашы, ниһаять, аскарак та төшеп китә. Нәзкәй бил дугайланып ике якка тарала да, сихри калкулыклар тудырып, астарак тагын җыела. Сылу гәүдәне төз аяклар, йомыры тез башлары тотып тора. Тик егетнең күз карашы, бу сафлык аңкып торган серле борылышлар, калкулыклар тирәсендә озак туктап тора алмый, күз туктый-туктыйрак булса да кабаттан өскә менә һәм дөньяның бар хикмәте, сихере, ымы, ишарәләре мөлдерәп торган күзләргә карап туктала... Әйтер сүзләре нигә иреннәренә ябышып калды икән егетнең?.. Кыз Хәлилнең мәхәббәтен белгән булса, килми калганы өчен рәнҗемәс тә, ашыгып ялгышлар да ясамас иде...

Егет урман уртасына җитәрәк йөгерә үк башлады һәм, кулларын алга сузып, аңа каршы йөгергән кызны күреп ыңгырашып җибәрде.

* * *

Каян килеп чыкты кыз, алга сузылган куллары ни әйтте, күз яшьләре ташкынын тыеп торган керфекләре ни аңлатты — егет боларны бәяләрлек хәлдә түгел иде. Хисләр, акылны да аста калдырып, егетнең күзен сукырайткан, акылын томалаган бермәл иде. Ул исән, ул бар, аның барлыгын, берлеген раслап калтыраган куллар бербересенә тоташтылар, изге ымнар белән ашыгып-кабаланып бер-берсенә нидер аңлаттылар, юаттылар, сөенделәр. Аһ, кыз кулларының нинди татлы хасиятләре барын егет моңарчы белгән булса!.. Чынлап торып сөяргә дә базмый йөрде ич ул исәр! Куллар кыска гына арада бер-берсенә мең хәбәр җитештереп өлгерделәр. Тәннәр аша гөнаһсыз ут күзәнәкләре йөреп торды. Ниһаять, чират телләргә җитте. Кыз бер җөмләне өч тапкыр рәттән кабатлады. «Мин сезне өзелеп көттем!» диде. Шушы әз сүзләрдән оешкан җөмләне кемнәр нинди тарафларда гына әйтмәгәннәрдер? Инеш-елга буйларында, арыш арасыннан үткән тар сукмакларда, ботак саен былбыллар эленеп торган әрәмәләрдә, Идел җиленә буйсынып аккан ал

җилкәнле көймәләрдә... Кайларда, нинди шартларда гына әйтелмәгәндер мәхәббәтнең тәмле сүзләре?! Әмма егет шушы үтә кыска җөмләгә бөек, чиксез бәхетле хисләр сыя алуын кыз авызыннан ишеткәч кенә аңлады. Моңарчы, кешелек мең вә миллион еллар яшәсә дә, бу сүзләргә шушы кадәр көч-егәр, кайнар ярату,чынлык өстәп бирәү дә әйтә алмагандыр... Болай итеп егетне ике көн, бер төн өзелеп көткән кыз гына әйтә алгандыр.

«Ничек моңарчы түздең, төнне ничек чыктың, курыкмадыңмы?» дип төпченмәде егет, кызның нәкъ менә шул көчле сүзләрне, шушы истәлекле урында, үзенә уналты яшь тулган көндә әйтергә җыенганын аңлады ул. А-а, бер төн түгел өчне, дүртне үткәзеп җибәрәчәк ул, төнге караңгылыкка да түзәчәк, юлдашы булып күл, күл тирәли сакка баскан ап-ак каеннар барында куркамы соң?! Авылдашларыңны сискәндереп куркыттың, тирә-якка шом салдың, нишләдең син башсыз кыз дип тә әйтмәде егет. Белерләр, алар мәхәббәтенең тирәнлеген аңлагач, кичерерләр. Уналты яшьтә кыз күңеленә чын мәхәббәт иңә икән, аны тыяр, чикли, буйсындыра торган кодрәт юк. Чөнки мәхәббәт үзе тиңсез кодрәт иясе!.. Ник шул карурман уртасындагы Каракүл тирәсенә ач бүреләр ыжгырып килми, агачларны ега-ега гарасат давылы үтеп китми, уналты яшьлек күңелгә мәхәббәт ялкыны кабынган икән, аны сүндерер әмәл юк. Мәхәббәтнең тиңсез олысы, иң сафы, иң татлысы кызлар уналтыда чакта гына була...

Куллар аңыштымы, күзләр серләштеме, ак каеннар пышылдаштымы. Егет шулай дип уйлады. Алар шулай кулга-кул тотынышып, аерылырга, ерагаерга куркып шактый озак тордылар. Әллә алай озак та тормадылармы?.. Кай арада урман ешлыгын сискәндереп, көчле җил исте, кызның ап-ак күлмәк итәген җилфердәтеп, күл көзгесен шадраландырып үтеп китте җил. Табигатьнең ымы идеме бу, боерыгымы. Тынгысыз авылдан китергән хәбәре идеме?.. Әйе, ашыгырга, ил-көн күзенә күренергә, Аксу авылына иминлек хәбәре җиткерергә кирәк иде. Җиңел җилкәнле болытлар, әле куерып та өлгермәгән күк хәбәрчеләре гөрелдәп аларга нидер дәште. Алар җитәкләшеп иң якындагы куе ябалдашлы, тубырлы кабыклы имән астына йөгерделәр. Кыз «Һай!» дип бер кычкырды да имән астыннан атылып чыгып, куе абагалар арасына иелде. Борылып килгәндә аның кулында җиләкләр бар иде. «Менә! — диде ул, горур тантана белән.— Җиләкләр дә сезне көтеп торды. Җиләк ашадым да җиләк ашадым, телем әчетә башлады. Аннары сарана казыдым... Төне буе керфек тә какмадым. Көттем, көттем... Куркам

да, курыкмыйм да... Әле имән кәүсәсенә барып терәләм, әле каенга!.. Җып-җылы агачлар... Миңа нидер сөйлиләр, иркәлиләр, юаталар... Ашагыз, аша... Быел җәй явымлы да, эссе дә булды. Җиләкләрнең тәме!.. Исләре дә!» Кыз, сабыйларча куанып, чиксез сөенеп аның җиләкләрне берәм-берәм өзеп капканын күзәтеп торды. «Мин килә алмадым»,— диде егет, килмәвенең сәбәбен кызга аңлатырга җыенып. «Кирәкми»,— диде кыз, җиләк исе килеп торган юеш куллары белән аның иреннәренә кагылып алды. Килә алмаган икән, егетнең сәбәбе чамадан тыш җитди дигән сүз. Кыз бу җәһәттән тамчы да шикләнми иде. Утырып кына җылы яңгыр ява башлады. Яңгыр, күл өстен алкалар белән бизәп, йокымсыраган урманны уятты. Алар яңгыр үтмәслек куелык эзләп бер-берсенә тартылдылар, гәүдә гәүдәгә тиеп тора башлады. Ява яңгыр, коя, җәйге юка күлмәкләр тиз-тиз биреште, кызның ак күлмәге тәненә сеңеп, аңа яңа төсмерләр өстәде. Чыланган толымнарга сыешмаган чәч учмалары маңгаена, муенына сибелеп сыландылар. Ул, дымлы иреннәрен ялаштырганда, тел очы күренеп-күренеп китте. Егет кызның иң башларын урап үзенә тартты, тәннәр бер-берсен эзләп тапты... Бераздан кызның тыенкы гына көлгәне ишетелде, ул бер җөмләне тагын ике тапкыр кабатлады: «Сез...мине кытыклыйсыз!»— диде. Егетнең куыгы кабарып, чалбарында таучык ясаган икән. Ул читенсенеп һәм сөенеп кызны читкәрәк этәрде. Кыз аңа йөзе белән борылды һәм Хәлилнең егетлеге нык беленгән урынга да күз сирпеп алырга да өлгерде. Икәүләшеп көлеп җибәрделәр дә агач асты ышыгыннан атылып чыктылар. Юеш ботаклардан, сүрелгән күктән коелган җылы тамчыларга куана-куана йөгерә башладылар. Күл ярында җиләк исе, бәрәкәтле яңгыр исе һәм күлдә шашып-шашып биегән тамчылар гына калды.

*1993*

## ПОВЕСТЬЛАР

# *Качак*

### 1

Кече якта, караваттагы колак мендәренә капланып, Тәнзилә елый. Күңеле тулган икән кызыйның. Батист кулъяулыгы гына түгел, мендәр тышлыгы да күз яшеннән сыгарлык булган.

Ул кычкырып еламый. Сабыр холкы елаганда да аны шулай тыйнак иткән. Андый кеше шулай була бит ул. Шыпырт кына йөри-йөри дә,— мә сиңа,— җылы яңгырдан соңгы язгы боз кебек кузгалып китә.

Тәрәзә төбендәге кына гөле чүлмәге янында, бөгәрләнеп, чуар песи Куштый йоклый. Ачык тәрәзәдән бакчада сәрви куаклары арасында тырманган тавыкларның аратирә бер-берен чукып, кыркылдашып куюлары ишетелә.

Тәнзиләгә фермага төшәргә күптән вакыт. Кичке савымга кырга — туплауга барырга кирәк. Иптәш кызлары көтә торганнардыр.

Көтсеннәр! Бер сәгать түгел, ике сәгать көтсеннәр. Җитәр! Эш дип, ферма дип, әле дә түзеп киленгән инде. Үзең хакында, гомер хакында уйланырга вакыт та калмаган. Уйлап карасаң, тәмам һушың китәр, валлаһи! Ни гомер кичке уенга чыкканы юк Тәнзиләнең, кино карамаганга да күпме инде. Бик кызык китап дип ишеткәч, Тургеневның «Ася»сын алып кайткан иде. Ул да ике бите генә укылган килеш ята. Кисеп куйган крепдешин күлмәкнең кисәкләре, өлгеләре таралып, югалып бара. Берсенә дә кул җитми, һаман эш тә эш. Эшенең мәгънәсе булса икән, Ходаем. Район газеты килсә, укырга оят, колхозың, арттан караганда, иң алдынгылар рәтендә...

Җитәр! Көтсеннәр, ачулансыннар, Тәнзилә бүген сыерлар янына аяк та басачак түгел. Саварлар әле. Кирәк булса, кешесен дә табарлар! Әнә колхоз председателенең

хатыны Гөлҗиһан тик ята, хисапчының Нурдидәсе дә кибет төбен, базар юлын таптаудан бушамый. Алар да эшләсеннәр. Гөлҗиһан, Тәнзилә кебек, өч ел сыер савып карасын әле.

Гаҗәп, иптәш кызлары Гөлҗиһан белән Нурдидәне әрләгәндә: беренчесенең бала-чагасы күп, икенчесе саулыкка туймый икән дип яклап чыга торган Тәнзилә бүген үзе аларны тотып ашардай хәлгә килгән иде.

Нигә, алар да эшләсеннәр!

Өч ел... Аккан су кебек үткән дә киткән. Тәнзиләгә егерме тулган. Егерме яшь... Гомер юлының уртасы кайчан башлануын беркем дә белми бит. Бәлки, аның яртысы үтеп тә киткәндер. Унынчы классны тәмамлаганга өч ел. Тфү! Чәчәк кебек гомерең ферма өендә каравылчы Минәч картның сасы тунын иснәп үтсен инде!..

Әле иртән генә Тәнзилә ваемсыз һәм көләч кыз иде. Бүген иртәнге савым тәмамлангач, ул иптәшләре белән сыер абзарларын сыларга калмады. Каладан айлык ялга кайткан апасы Гөләндәмне озатасы бар иде аның.

Гөләндәм Тәнзиләнең бертуганы булса да, төсе-башы белән дә, холкы-фигыле белән дә сеңелесенә охшамаган иде. Ул, сигезенче классны бетерер-бетермәстән укуын ташлап, колхозда эшли башлады. Анда да бер кыш ерак урманга агач кисәргә барып, колхоз эшеннән тәмам туеп, усалланып кайтты. Кайтты да:

— Бер капчык арыш өчен бил бөкрәйтеп, күз чекрәйтеп, эшләп йөрисем юк, калага китәм,— диде.

Кызының холкын яхшы белгән Мәгъмүрә апа каршы килеп маташмады. Колхоз председателе Бикбулат кына:

— Китсәң кит, ак юл үзеңә, тик язу бирмим,— дип кырт кисте.

Гөләндәм сынмады, колхоз идарәсендә күтәргән давын район үзәгенә алып барып, җәнҗал итеп бетерде. Прокурорга кадәр керде:

— Кешечә яшисем килә. Безнең колхозда яшәү түгел, тын алырга иркенлек юк,— дип дулады.

Председатель Бикбулат, эченнән сызланса да, язу бирергә мәҗбүр булды. «Ичмасам, колагым тынар» дип, Гөләндәмне станциягә кадәр ат белән илттерде.

Гөләндәм кала тирәсендәге бер төзелешкә барып урнашты. Балчыкның бал, дөньяның ал түгеллеген тиз аңлады ул. Ипинең беркайда да ансат кына бирелмәвен, аны тир түгеп табарга кирәклеген шунда төшенде. Авыр чакларда барысын да ташлап авылга, әнисе янына кайтып китәргә теләгән вакытлары да булгалады. Тора-бара күнекте, үҗәтләнеп тешен кыса-кыса эшләде. Завод төзе-

леп беткәч, шунда ук эшкә калды. Шунда гомергә төпләндем дип уйлады. Акчаны да шактый төшерә башлады. Күптәнге нәзерен үтәп, әнисенә оренбур шәл, сеңелесе Тәнзиләгә күлмәклек ефәк җибәрде. Һәр елны ялга мул итеп кипкән өреген, йөземен, кара җимешен алып кайтты. Күчтәнәчтән күрше-коланга гына түгел, чыбык очы агай-энеләргә дә өлеш чыккач, авылда: «Гөләндәм бик баеп кайткан, акчаны көрәп ала булыр. Дистәләп күлмәге генә бар икән»,— дип сөйләнделәр.

Тормышның тәмен белеп, куанып яши башлаганда гына ирдән калган, ятим-ялпы булып гомергә китек тереклек иткән Мәгъмүрә апага бу сүзләрне ишетү бик рәхәт булды. Үзе яныннан бик җиңел генә чыгып киткәнгә рәнҗегән ана күңеле Гөләндәмне берьюлы гафу иткән иде. Ул эченнән генә Гөләндәмнең шул завод тирәсендә кияүгә чыгуын тели. Башка яктан олы кызының тормышы түгәрәкләнгән дип исәпли иде.

Тәнзиләгә апасының кайтуы бер елны да әллә ни искитәрлек тәэсир итмәде. Яшь аралары зур булмаса да, характерлары белән төрле-төрле булганлыктан, туганнар арасында артык якынлык юк иде. Ул апасының завод, кала хакында онытылып сөйләгәннәрен колак очыннан гына үткәреп җибәрә иде. Ефәк яулыклар, капроннар да аның исен китәрә алмады. Ул кадәресен генә әнисе ярдәмендә ул монда да бөтәйткән иде. Кинотеатрның матурлыгы, шәплеге турындагы хәбәрләр дә аны кызыктырмады. Һәркемнең үз тормышы, үз рәхәте бар дип саный иде ул. Гөләндәмгә шәһәр ошаган, ә менә Тәнзиләгә шушы авыл кадерле. Ипине икесе дә эшләп ашыйлар. Дөрес, соңгы елларда Гөләндәм азрак көч түгеп, тәмлерәк ипи ашый. Тәнзилә күбрәк көч куеп, ачырак ипи ашый икән, берни эшләр хәлең юк. Колхозың бай булмагач, аягыңны әллә ни киереп суза алмассың.

Гөләндәмне быел да хәл кадәренчә кунак иттеләр. Кайтуына йомыркасын күрше keләте астына салырга гадәтләнгән бүрекле тавыкны суйган булсалар, китәренә ун көн калды дигәндә тәкә суйдылар. Өстәлдән катык, май өзелмәде. Гөләндәм авылдан чын-чынлап ял итеп, тазарып, чибәрләнеп китте.

Тәнзилә бала вакытта елак кына, усал гына, нечкә сыйраклы, юка гәүдәле бер кызчык иде. Усаллыгыннан бигрәк килелеге, үзсүзлелеге белән ул гаиләдәгеләрнең җыгын чыгара. Ни генә әйтсәң дә:

— Сез әтине дә күргән, минем күргәнем юк. Мине кимсетмәгез,— дип, аяк тибә-тибә елый иде ул.

Әтисе сугышка киткәндә сабый гына булып калган

Тәнзилә исә, аңлый төшкәч, ятимлекне бик авыр кичерде. Күрше кызы Гөлсинәнең әтисе армиядән кайткач:

— Минем әтием кайда? — дип кереп әнисенең үзәген өзгән иде. Юатмакчы булып Мәгъмүрә апа гадәттәгечә Тәнзиләгә әтисенең карточкасын күрсәтте. Тәнзилә карточканы атып бәрде:

— Миңа мондый әти кирәкми, миңа сөйләшә торган әти кирәк. Гөлсинәнең әтисе төсле булсын, кулы-аягы булсын, миңа прәннек алып кайтсын! — дип үрсәләнеп-үрсәләнеп елады.

Тора-бара ятимлеккә дә күнегәсең икән. Әтисенең кайда, ничек югалуын аңлагач, Тәнзилә дә үзгәрде. Үскән саен сабырлана-тыйнаклана барды. Урта мәктәпне тәмамлаганда, ул матур ал яңаклы, сөрмәле коңгырт күзле уйчан гына кыз иде инде.

Апасы кече яшьтән үк уеннарны, җыр-биюләрне яратканга, өй эшләрен бик яшьләй Тәнзилә карады. Әнкәсе эштә булса, мал-туарны ул барлады. Гөләндәмнең читкә китүенә берсүзсез риза булган Тәнзилә үзе кайчан да булса авылны, карчык әнисен ташлап китә алырмын дип уйламады. Әллә нинди язылмаган законнар белән Тәнзиләнең йортта калуы хәл ителгән булып чыкты. Мәгъмүрә апа да моны шулай дип белә, сүз кузгалганы булмаса да, Тәнзилә үз хәле белән ризалашкан иде.

Шуңа күрә урта мәктәпне бетергәндә, Тәнзилә хыял канатларына талпынырга ирек бирмәде. Кайбер иптәшләре кебек, кая барыйм, укыйм микән, юкмы икән, вузга керә алмасам нишләрмен дип, тыз-быз чабарга туры килмәде аңа. Сынаулар беткәч үк, күңел ачу булсын дип, күрше авылдагы әбиләренә бер атнага утырмага барды. Шунда да авылны, әнисен сагынып кайтты. Ике кулыңа бер эш, төпле урын дип, фермага урнашты.

Бер ел бозау карады.

Икенче елны яңа кешегә яңа сыерлар, баштан ук үз көеңне өйрәтерсең дип, унике башмак тананы җыеп, Тәнзиләгә тапшырдылар. Шулай итеп, Тәнзилә сыер савучы булып китте.

Үз эшен болай яраткан кебек иде ул. Ферма мөдире ач яңаклы, какча гәүдәле, кыдрач Гайфулла колхоз председателе Бикбулатка:

— Кызыйның менә дигәне эләкте. Телле-тешле түгел. Кая җибәрсәң, шунда бара, шәп кыз,— дип мактаган иде.

Сыерлар фермасы салам түбәле иске бер бинага урнашкан. Язын-көзен түбәдән су үтеп интектерә, кышын исә юка стеналар аша кергән суык сыерларны да, саву-

чыларны да җәфалый. Ятим үсеп, үз хуҗалыгында да әллә ни муллыкны күрмәгән Тәнзилә азга да канәгать булды. Аның күңеле, Гайфулла әйтмешли, яхшыны күреп бозылмаган иде әле. Башкалар эш шартларының начарлыгыннан зарланганда да, Тәнзилә катнашмады. Савучыларга тиешле өстәмә түләү үз вакытында бирелмәсә дә, башкалар кебек, идарәгә барып җәнҗал куптарып йөрмәде. Кара таңнан кичкә кадәр фермада булды. Вакыты җиткәч, яңа биналар да салыныр, өстәмә түләве дә качмас, колхозның чыгымы бер без генәме әллә дип йөрде ул. Кышларын терлек азыгы җитмәгәндә, үз өеннән бәрәңге ташып сыерларына ашатты.

Шыпырт кына эшләде Тәнзилә. Иптәш кызлары аның эш сөючәнлеген, тыйнаклыгын яратсалар да, үзен хаксызга кимсеткәндә дәшми калуын ошатмыйлар, мөдиргә ярарга тырыша дип уйлыйлар иде. Мөдир Гайфулла исә үзенең кыек-мыек эшләрен Тәнзиләгә күрсәтмәскәрәк тырышты. Ул да аңардан шүрли, бу кыз председательнең фермадагы күз-колагы түгелме дип сагая иде.

Шулай итеп, фермада эшләсә дә, Тәнзилә, ничектер, аның чын хәленнән, ыгы-зыгысыннан читтә яшәде. Былтыр сөт ташучы малайның аз-мазлап каймак чиртүе ачылгач, ул бөтенләй исе китеп, шаккатып калган иде. Гайфуллага да шул каймактан бераз өлеш чыгуын ишетсә, Тәнзилә ышанмас иде...

Тәнзилә ел да Гөләндәмне авылдан гына озатып кала торган иде. Быел әллә Гөләндәм кузгаттымы, әллә үзе башлап авыз ачтымы, ул апасы белән станциягә кадәр барырга булды. Мәгъмүрә апа да:

— Бер ирек ачып кайтырсың, бар,— дип, кызының фикерен хуплады.

Ул фермадагы эшләрен мөмкин кадәр тиз тотарга тырышты. Алай да ул кайтканда, Мәгъмүрә апа белән Гөләндәм урамга ук чыгып басканнар иде инде. Тәнзиләне күргәч, Гөләндәмнең чырае ачылып китте.

— Соңга каласың дип торам. Белешеп кайттым, машина хәзер килә,— диде ул.

Тәнзилә өс-башларын алыштыргалаганчы, түбән очтан тузан туздырып менүче машина күренде. Тәнзилә йөгереп чыкты. Кабинада шофер белән янәшә утырган колхоз председателен күргәч, ул кызарып китте.

Төенчекләрен машина өстенә урнаштыргач, Гөләндәм әнисе белән саубуллашты:

— Хуш инде, әнием. Кыр эшләре беткәч, минем янга калага килеп чык,— диде.

Мәгъмүрә апа елап җибәрде:

— Кая инде ул миңа? Менә сеңелең җитешеп чыга алса, бик ярар иде дә, булмас шул,— диде.

Бикбулатның ашыкканлыгы күренеп тора: ул, йә, тиз буласызмы дигән сыман, кабина тәрәзәсеннән башын сузып Гөләндәмне озатырга чыккан күрше-коланга кырын күзе белән генә карый иде. Шул чагында ул йөк өстенә менеп утырган Тәнзиләне шәйләп, кырыс тавыш белән:

— Ә син кая җыендың? — дип сорады.

— Нигә? Апаны озатам.

Бикбулат дәшмәде. Калын кашларын җыерып, шоферга борылды:

— Әйдә, үрләт. Поездга соңга калмыйк,— диде.

Бикбулатка кардәшләреннән берсе: «Кунакка киләм, каршыла»,— дип, телеграмма суккан икән. Мондый кызу эш өстендә йөргән кунакларны, шәһәр кешеләрен Бикбулат яратмаса да, кунакны үзе каршыларга булды. Заготзерного да керәсе бар иде, ике йомышны бер итеп юлга чыкты.

Авыл очына чыгуга, машина туктады. Бикбулат, кабина ишегеннән үрелеп:

— Йә, Тәнзилә, син төшәрсең инде,— диде.

— Мин станциягә кадәр барам,— диде Тәнзилә.

— Эшеңне кем эшләр?

— Бүгенгә кызлар үзләре генә маташырлар инде. Кичке савымга кайтып җитәм ич. Без үзара сөйләшкән идек.

— Ә миннән рөхсәт сорадыңмы соң?

Тәнзилә бурлат төсле булды:

— Станция ерак түгел ич, Бикбулат абзый,— дип мыгырданды ул.

— Ераклыгын-якынлыгын үзем дә беләм. Апаңны барыбер алып кала алмассың. Шушында гына хушлаш та бетер. Барып йөрергә миннән рөхсәт юк. Эш вакыты,— дип, Бикбулат кабина ишеген шап иттереп ябып куйды.

— Рөхсәтеңнең кирәге дә юк,— диде Гөләндәм, кабынып.— Оҗмах каравылчысы булдыңмы әллә?

Ул, бик ачуы килеп, соры күзләрен кыса төшеп, сөйләшү ни белән бетәр икән дип көтеп торды. Тәнзиләнең җиңелүен, төшәргә дип итәкләрен җыештыруын күргәч, тәмам ярсып:

— Кая барасың? — дип кычкырды.

— Менә... күрәсең ич... эш...

Гөләндәм кул селтәде.

— Их син, арыш боламыгы! Шул Кара Нурыйның колы булгансың. Боргычлар идем мин аны! Кешемени

син! — диде ул, бик ачуланып, һәм, тузан үтмәсен дип кысып бәйләгән яулыгын чишеп ташлап, сикереп үк торды.

Председатель сүзенә карышырга Тәнзилә кыймады, төшеп калды. Гөләндәм кабина ягына таба суганлап-борычлап берничә сүз әйтте дә сеңелесенә карады. Ул, күчәр башлары эләгеп, ашалып, кыегаеп беткән басу капкасының баганалары арасында, зәңгәр яулыгын күкрәгенә кысып, юаш кына басып калды.

Тәнзилә беренче мәртәбә апасыннан көнләште. Күңеленә Гөләндәм сөйләгән зур шәһәрләр, мәһабәт театрлар, киң урамнар, бакчалар килде. Канатлары яньчелеп, буявы уңып бетсә дә, шушы машина Гөләндәмне шул шәп, әкият дөньясына алып китте бит! Ә Тәнзилә? Аның әнә шул зәңгәр офыкта яткан станциягә барырга да хакы юк. Нигә? Гөләндәм бер ай ял итте. Теләгән җиренә барды, теләгән кешесен күрде. Тәнзиләгә ике сәгатькә генә эштән аерылырга ярамыймыни? Бәйрәмнәрдә дә юньләп ял иткәне юк ич аның. Ә ул кемнән ким? Шул ук ил кешесе, урта белемле...

Тәнзиләгә дөнья тар, үзе бик кечкенә, хыяллары өтек булып тоелды. Ул, гарьләнеп, яулыгын учы белән йомарлады. Машина күздән югалганчы, капка янында каккан казык кебек катып торды.

Ындыр киртәсе буйлап тар сукмактан велосипедка атланган бер малай бозау куып килә. Бозау, велосипедтан куркып, койрыгын чәнчеп-чәнчеп чаба да борылып малайны көтеп тора. Тәнзилә янына килеп җиткәч, бозау туктады һәм, бер дә шикләнмичә, кытыршы, юеш борынын аның кулына төртте. Бүтән чакта хайван киң күңелле кешене әллә каян сизә дип куана торган Тәнзилә бүген бозауны тибеп кенә очырды.

Машина күздән югалды.

Машинага утырып Гөләндәм китте.

Ул поездларга утырыр, теләгән эшен эшләр, йөрер, күрер. Әйе, китте. Тәнзиләнең күңелен тутырып китте. Менә кызның калку күкрәге еш-еш күтәрелә башлады, керфекләре чыланды. Ул, елавын кеше күрүеннән куркып, тешләрен кысты, йодрыкларын йомарлап бәрәңге бакчалары артыннан өйләренә йөгерде. Итәгенә тигәнәкләр ябышты, туфлие эченә туфрак тулды. Күңел тулганда, алар күзгә күренәмени?

Ул көч-хәл белән өйләренә кайтып җитте. Бикле ишекне ачып, кабалана-кабалана кече якка үтте. Караватка капланды.

Күптәннән елаганы юк иде аның.

## 2

Мәгъмүрә апа Гөләндәмне озаткач беравык өйдә ямансулап утырды да аргы очтагы кодачаларына китте. Күп-күп күчтәнәчләр алып кайткан, каланың үзендә оя корып маташкан кызы хакында тагын кем белән булса да уйларын бүлешәсе дә килде аның.

Өй аулак булгач, Тәнзиләгә дә комачаулаучы булмады. Ул күңеле бушаганчы елады. Елап арыгач, караваттан торды. Гәүдәсе кыйнап ташланган кебек авырайган, озату уңае белән киелгән әйбәт күлмәк таушалган, Тәнзилә үзе бер-ике яшькә олыгайган кебек күренә иде.

Әле торганда башындагы фикерләре бер юнәлеш алып оешмаган булса да, Тәнзиләнең нидер эшлисе, үзенең ямьсез тормышын ватасы килде.

Ул тәрәзә янына килеп басты һәм тузан белән капланган сәрви яфракларына, коймага карап тора башлады. Күңелендә ап-ачык булып бер фикер калыкты: әйе, авылдан китәргә кирәк.

Тәнзилә әле кая китәсен дә, кайчан китәсен дә уйлап бетермәде. Авылга үпкәсе шулкадәр көчле иде аның, кая гына китсә дә, мондагыдан рәхәтрәк булыр, күңеллерәк булыр кебек тоела иде. Читкә киткән иптәш кызлары берәм-берәм аның күз алдыннан уздылар. Тәнзиләнең күңеленә ни өчендер аларның авылга, ялга кайткан чаклары гына килде. Бәхетле кызлар бар соң дөньяда! Үз бәяләрен ничек иртә аңлап алганнар. Читтән кайткан кызлар тирәсендә егетләрнең ничек бөтерелүләре дә искә төшкәч, Тәнзилә бөтенләй кәефсезләнде. Чат Шәрәфинең җибәргән Әсмасы да, Ярославльда торфта эшләп кайткач, кем булып шәбәеп, һаваланып йөргән иде. Хакы булган икән. Ул бит Тәнзилә күрмәгәнне күргән, Тәнзилә белмәгәнне белгән. Ирекле булуның тәменә төшенгән.

Өс-башын да алышмыйча, таушалган күлмәктән, йомарланып беткән яулыгын кулына тотып, Тәнзилә идарәгә юнәлде.

Председатель булмаса, хисапчыга сөйләр. Башта берәр йомыш тапкан булыр. Менә урам коеларын күмдерергә кирәк. Ир-ат булмагач, караучы да юк. Өсте ачылып, үткән көз бер сарык төшеп үлде инде... Күмдерергә риза булмасалар, сүз башларга җиңелрәк булыр.

Урам тар, йортлар тәбәнәк, шыксыз булып күренделәр Тәнзиләгә. Юл тузаны да гадәттәгедән калынрак иде, ахры. Бәләкәй генә җил иссә дә, ул бөтерелеп уйный башлый, күзгә керә, борынны кытыклый, теш араларына үтеп чытырдый.

Ертылып беткән стена газетасы эленгән идарә ишегендә йозак-фәлән булмаса да, эчтә беркем дә юк. Председательнең өйдә юклыгыннан файдаланып, хисапчы үз өенә салкын әйрән эчәргә киткән, ахры.

Букәненә йозак эленгән стена сәгатен күргәч, Тәнзилә усал гына көлемсерәп куйды. Йозакны букәнне авырайту өчен түгел, сәгатьне бикләп кую өчен элгәннәр кебек. Чөнки ул йөрми дә, шылт та итми.

Хисапчы урындыгы турысына гына стенага атаклы сыер савучы Чүпрәле кызы Фирдания Гафурованың рәсемен элгәннәр. Рәсем астына эре хәрефләр белән «Үрнәк алыгыз!», дип язганнар. Моны күргәч, Тәнзиләнең бөтенләй авызы чалышайды. Үрнәк, имеш. Тишек-тошык абзарларда ел буе бата-чума йөреп интегеп кара. Үрнәк дип, бик авызыңны ачарсың! Иң элек үрнәк итәрлек каралтылар сал, азыгын бир, аннары сөйләшеп карарга мөмкин булыр.

Идарәнең ишек яңагына терәп үк зур зәңгәрсу кәгазь кадакланган. Яшь кенә кызлар ак халатлар киеп алганнар да авызларын ерып торалар. Ермыйча, «Көчле ирек» колхозының иң яхшы сыер савучылары дип язып куйганнар шул кәгазьнең өстенә. Гап-гади кызлар. Тәнзиләнең яшьтәшләредер әле җитмәсә. Димәк, тормышта аның яшьтәшләре дә, аның чордашлары да күренекле урын ала баралар. Ә ул кем? Кешеләр тирә-юньдә шундый шәп тормыш иткәндә, син исемсез, билгесез бер кеше булып яшә инде. Хәтта синең апаңны станциягә озатырга да хакың булмасын. Яшәүмени бу, тормышмыни?

Нигә идарәдә шулай озак беркем дә юк? Тәнзиләгә ифрат күңелсез була башлады. Шул арада телефон шалтырады. Тәнзилә як-ягына каранып алды һәм, беркем дә күренмәгәч, трубкага тотынды.

— Әйе, «Үзәк» колхозы тыңлый,— диде ул, ят тавыш белән. Трубкадан «кем тыңлый» дип сорагач, ул аптырап калды. Кем дип әйтергә? Сыер савучы дип әйтергә теле әйләнмәде аның, ничектер үзен-үзе кимсетү кебек тоелды. Трубкадан ашыктыра башладылар. Таләпчән хатынкыз тавышы: «Шул колхозданмы соң син?» — дип сорады. Тәнзилә көч-хәл белән: «Әйе»,— дигәч, тавыш кәгазь, каләм алырга һәм телефонограмма кабул итәргә кушты.

Хисапчы өстәленнән табылган эре шакмаклы калын сары кәгазьгә Тәнзилә түбәндәге сүзләрне язып алды: «Колхоз председателе Сибгатуллинга. Комсомол оешмасы секретаре Таҗетдиновка. Алдынгыларның эш тәҗрибәләрен өйрәнү өчен сыер савучыларның, дуңгыз, бозау караучыларның иртәгә «Көчле ирек» колхозына баруын

тәэмин итегез. Бу эшне ике мәртәбә өзүегезне истә тотып, җаваплылыкның тулаем сезнең өскә төшәчәген искәртәбез. Райком секретаре Сафин».

Тәнзилә трубканы куйгач, үзе язганга үзе ышанмыйча, телефонограмманы бер кат күздән кичерде. «Ике мәртәбә өзүегезне» дигән сүзләргә җиткәч, ул трубканы яңадан алып: «Алло-алло!» — дип кычкырып карады, җавап булмады. Телефон чыбыклары моңлы гына чыжылдадылар, каяндыр радио тавышлары ишетелеп калды. Әллә кайдан шат күңелле кешеләр җыр җырлап, Тәнзиләне үзләренә чакыралар кебек тоелды. Салкынча, җансыз трубка Тәнзиләнең колагына «әйдә, әйдә!» дип пышылдаган кебек булды.

Тыңлау белән мавыгып, ул ишек ачылуын да абайламый калды. Керүче Нәби Таҗетдинов, үзе үк клуб мөдире, үзе үк комсомол башлыгы, үзе үк җырчы да, биюче дә һәм, атказанмаса да, сәнгать эшлеклесе дә иде. Ул Тәнзиләне идарәдә очратуына гаҗәпләнде. Бер сүз дәшмичә, иң өсләрен сикертте, арыслан ялыдай озын чәчле башын селкеп артка чөйде. Кечкенә курнос борынына тартылыбрак, кара мыек шытып торган өске иренен кыймылдатып кына елмайган булды.

Тәнзилә аның соравын аңламады.

— Нәрсә-ә?

— Җанаш белән сөйләшергә килгәнсеңдер инде, әйбәт күлмәк кигәнсең. Ә күзләрең... Абау, карамачы шулай усал итеп!

Нәби укчәсе өстендә бөтерелеп алды.

— Җанаш тагын... Менә телефонограмма яздырдылар. Сиңа да кагыла бугай.

Таҗетдинов, телефонограмма дигәч тә, җитди кыяфәткә керде. Чәчләрен тагын бер мәртәбә артка чөеп җибәрде. Бик яхшы күрсә дә, кәгазьне юри күзеннән еракта тотып кыланып укып чыкты.

— Сиңа да кагыла әле бу, Тәнзилә туташкаем.

— Юк, миңа кагылмый,— диде нык итеп Тәнзилә.

— Нигә, монда сыер савучылар диелгән бит.

— Ышансаң, анда өченче мәртәбә кушабыз да диелгән. Баштагы икесенең кагылганын ничектер сизми калдым мин.

Таҗетдинов берьюлы, кырау тигән яфрак кебек, шиңеп китте. Йөзендә елмаю югалуга, авыз читләрендә, күз төпләрендә сизелер-сизелмәс кенә җыерчыклар күренде. Ул яшел тавыш белән:

— Миндәмени гаеп? Бикбулат абый карышып каткан бит. Юк эш артыннан машина йөртергә, дип кенә куя.

— Ат белән барыр идек.
— Куйсана, хәзерге заманда кем ат белән йөри! «Көчле ирек»тә егылып көләрләр.
— Көлмәсләр. Әнә районда безнең колхозны ташбакага да атландырып куйганнар, ди әле анда.
— Ул бит колхозны, ә монда яшьләр.
— Картлар да бар ич безнең арада.
— Картларга ни калган анда! Юк, Тәнзилә! — Нәби озынча яссы учларын угалап алды.— Бу юлы алып барам үзегезне. Ант әгәр, исемем Нәби булмасын! Былтыр сабан туенда булдым мин анда. Вәт авы-ыл!..
Таҗетдинов авызын бер ачса, йома белми иде. Шуңа күрә Тәнзилә капылт кына ишеккә борылды.
— Тыңлап бетер инде. Шулчак...
— Ниен тыңлыйсың аның?.. Синең сабан туенда булуыңнан миңа ни файда да, ни зыян? Минем «Көчле ирек»кә барганым юк, барасым юк, кирәге дә юк!
Тәнзиләдән мондый катылыкны көтмәгән Таҗетдинов, яңа уянган кеше сыман, күзләрен челт-челт йомып аптырап калды:
— Ни булды сиңа?
— Миңамы? Миңа ни булмас?
Таҗетдинов чын-чынлап хәйран калды. Башын кашып алды. Эченнән: «Нишләгән бу кызый, апасы китә дип, бераз төшергәнме әллә?» — дип уйлады. Фикерен кычкырып әйтергә базмады, сүзне җай белән генә икенчегә борып җибәрде:
— Кырынды өстендәге бодайны ура башладылар микән? — дигән булды.
Тәнзилә бу кармакка да эләкмәде, ачылып китмәде.
Нәби болай чыгып китүне яхшысынмады. Комсомол секретаре ич ул! Каршысында килделе-киттеле сөйләшеп, комсомол кыз утыра. Тиешсез вакытта идарәдә бер ялгызы. Кергәч тә, кемне көтәсең дип сорашасы калган. Үзе үк бөтенесен сөйләп бирер иде. Тәнзиләнең елаудан ныграк беленеп торган сөрмәләренә карап Таҗетдинов фикерләренә җавап эзләде. Ул өстәл янына килеп, «барабан сугып» алды, аннан күтәренке тавыш белән:
— Син чыннан да иртәгә «Көчле ирек»кә бармыйсыңмы? — дип сорады.
— Әллә сез барасыз?
— Барабыз, ант әгәр! Мин Бикбулат абыйдан куркып кына дәшми йөри идем. Бүген комсомол җыелышы җыеп, Бикбулат абыйның үзен шунда чакырам.
— Барыгыз,— диде Тәнзилә, төшенке генә.— Мин, Нәби, бара алмам!

— Нигә? Менә җүләр!

Шаярып, җиңел генә әйтелгән «җүләр» сүзеннән Тәнзиләнең тәшвишләнгән йөрәге бөрешеп китте. Ул, күзләрен аска яшереп, өзек-өзек тавыш белән:

— Җүләр булганмын шул моңарчы. Мин, Нәби, колхоздан китәргә булдым,— диде.

Таҗетдиновның күзләре шарайды:

— Китәсең, кая?

— Кая булса да,— дип, кулын селекте Тәнзилә.

— Бакчачылар курсына бер кеше кирәк дигән иде Бикбулат абый. Ике электрик...

Тәнзилә аны бүлде:

— Нәрсәгә ул электрик безгә? Борчак каравылларгамы?

— Яңа елга электр керә ич! Дусай гидростанциясеннән.

— Юк, мин бакчачы да, электрик та булырга җыенмыйм. Мин колхоздан китәм.

Тәнзиләнең кабат-кабат китәм диюе, шул вакыттагы аның сәер кыланышлары Таҗетдиновның җитдилеген җуйды. Аның күзләре кысылды, авызы җәелде. Ниһаять, түземлеге бетеп, ул шаркылдап көлеп җибәрде.

— Көлмә кешедән,— диде Тәнзилә.

— Авызың өшегән,— дип, һаман елмая бирде Таҗетдинов.

— Көлсәң дә ярый синең ишедән диясең килә инде синең, Нәби, ә?

— Ник алай дим, Тәнзилә? Болай гына көләм, кызык булып китте.

— Ә, кызыкмы? Башкалар киткәндә бер дә көлмәгәнсеңдер әле. Мин китәм дигәч тә, авыз ерасың. Таптың кызык! — дип кычкырды Тәнзилә. Аның алсу борын яфраклары дерелдәде, ирен читләре калтыранды, ул тиз-тиз генә идарәдән чыгып китте.

Таҗетдинов, сыер дуласа, аттан яман, нинди корт чакты икән бу кызыйны дип уйлап, сискәнеп китте, үзен сыер белән чагыштырганны Тәнзилә сизенә күрмәсен тагын, болай да кызган. Тыя алмассың. Кызу белән кыз сүзе бер тамырдан, ахры. Хатын сүзе салкын белән бер ояданмы икән? Тфү! Тәмам башны бутады бу кызый, культура бүлегенә шалтыратырга килгән иде бит әле ул. Чакырып кәгазь җибәрсеннәр. Районга барып кайтасы килә башлады.

Шулчак Таҗетдиновның хәтеренә телефонограмма төшеп, ул колхоз партоешмасы секретаре Миңлегалин янына барырга булды.

Ул чыкканда, Тәнзилә болдырда басып тора иде. Кыз

Таҗетдинов белән кабат очрашырга теләмәде. Ишек тавышын ишетүгә, җиргә төште һәм, җәһәт-җәһәт атлап, өйләренә юнәлде.

### 3

Чыгып киткәндә, Мәгъмүрә апа өйалды ишеген бикләгән кебек булган иде. Кайтса, ишек шар ачык тора. Йозак ачкычы белән бергә өйалды өстәлендә ята. Мәгъмүрә апа гаҗәпләнмәде, кабаланудан ишегемне дә бикләмәгәнмен, менә карга дип, үзен-үзе тиргәп алды, бер кат өй эченә күз йөгертеп чыкты.

Сул якта бикле кием шкафы. Аннан ары авыл паласы җәелгән диван. Түр почмактагы борынгы шарлы шкафта савыт-сабалар, чынаяк-чәшкеләр, тәтәй тиеннәр, болannар (Гөләндәм бик ярата шундыйларны). Түрдә өстәл. Өстәл белән кече як бүлмәсе арасында зур сандык. Тәнзиләнең сандыгы, Мәгъмүрә апа күңеленнән: «Аллага шөкер»,— дип, берничә мәртәбә кабатлады да тиз-тиз генә өстен-башын алыштырды.

Кодачаларында яңа гына чәй эчеп чыккан булса да, ничектер күңеле уйнап тора иде аның. Берәр коры-сары әмәлләсәң дә ярар иде. Тәнзилә дә станциядән ачыгып кайтыр, булмаса, аш салырга кирәк. Кунак арасында гел итле аш булганга, Мәгъмүрә апа тансыкка дип, сөтле өйрә генә пешерергә булды.

Тәнзилә идарәдән кайтып кергәндә, ишегалдына сөтле өйрә исе таралган иде. Җиңнәрен кайтарып куйган Мәгъмүрә апа балта белән утын ваклап маташа.

— Бәй, кызым, кайтып та җиттеңмени? — дип сорады ул. Тәнзиләнең эндәшми торуын күргәч: — Исән-сау гына китә алдымы соң? Поездга өлгердегезме, билет булдымы? — дип, кызын сораулар белән күмеп ташлады.

— Утын ярырга тотынма дип, ничә мәртәбә әйттем инде, әнкәй,— диде Тәнзилә.

— Кече учакка гына бу, ботак-сатак кирәк булды да, чыккан идем.

Аналы-кызлы өйгә керделәр. Мәгъмүрә апа, саклык белән генә кочагындагы утыннарын мич алдына бушатып, Тәнзиләгә борылды:

— Кызым! Апаң хакында нигә бер сүз дә сөйләмисең? Әллә юлда телгә килдегезме? Үпкәләгән кебек күренәсең.

Җаны теләмәсә дә, басу капкасы төбендә булган хәлләрне сөйләп бирергә туры килде. Тәнзилә әнкәсе дә үзе кебек кызар, Бикбулатны әрләр дип көткән иде. Мәгъмүрә апа кызмады:

— Һе, кара син, җибәрсә, әйбәт буласы икән дә, җибәрмәгән икән. Эш вакыты бит, күңелемә килгән иде аны,— дип кенә куйды.

Тәнзилә анның җыерчыклы, җилдә каралган йөзендә әллә ни борчылу күрмәгәч, түзмәде:

— Бер тамчы да горурлыгың юкмыни синең, әнкәй! — дип, ярым еламсырап кычкырып җибәрде.

— Ник алай дисең, кызым?

— Мине кимсеттеләр, хур иттеләр, ә син...

— Нинди хур итү булсын ул, ни сөйлисең син? Аллага шөкер, кеше арасында ким-хур булганыбыз юк. Җаным күбәләк, тормышым түгәрәк дигәндәй, икегезне дә карадым, үстердем, укыттым,— диде аптырау катнаш гаҗәпләнеп Мәгъмүрә апа.

Тәнзиләнең тел очында усал сүзләр булса да, тыелып калды. Икесе дә бераз дәшми тордылар.

— Кешелеккә дигән күлмәгеңне эшкә киләскә иде. Таушалтып бетергәнсең,— диде Мәгъмүрә апа, кызын шелтәләп.

— Минем эшкә барганым юк әле.

— Кайда гына йөрдең соң?

— Болай, урамда гына.

— Сүз булмасын, кара аны, балакаем.

— Булса ни...

_ Алай димә, эшләгән иптәшләрең белән әчелешле булырга ярамый. Дөнья болай да мәшәкатьле. Әле ызгышмыйча тату гына яшәгәндә дә җитәрлек картайта ул.

— Кеше көен көйләп кенә булмас инде.

Өйрә пешеп, буларын бөркә-бөркә өстәлгә менеп утырганчы, алар берни дә сөйләшмәделәр. Ашарга утыргач кына, Тәнзилә баядан бирле күңелен кытыклап торган сүзне әйтеп салды:

— Әнкәй, мин читкә китәргә уйладым.

Әллә Мәгъмүрә апа бу сүзнең буласын алдан ук көтеп йөргән, ул Тәнзилә уйлаганча сискәнеп тә китмәде, каушап та калмады. Кызыл ашъяулык өстеннән иләп кенә алъяпкычына ипи валчыкларын сыпырып төшерде. Аның яргаланып беткән сөялле бармаклары сизелер-сизелмәс кенә калтыранды. Ул озак кына билгесез бер ноктага карап торды.

Тәнзилә, әллә ишетмәдеме дип, сораулы күзләрен әнкәсеннән алмады. Юк, ишеткән икән.

— Читкә дисең инде? Кая?

— Белмим әле. Кая булса да.

— Ул «кая»ны күргәнең бармы соң синең? Яратырсыңмы син аны?

Мәгъмүрә апа сүзне бөтенләй Тәнзилә көтмәгән якка алып китте. Нәрсә булган бүген аңа? Ялгыз калам дип елар, үпкәләр, ачуланыр дип көткәндә, берни дә булмаган кебек, аш ашый һәм «яратырсыңмы?» дип төпченә.

Тәнзилә үзенә күрә җавап та әзерләп куйган иде. «Китеп бераз торгач, сине дә алдырырмын»,— димәкче иде ул.

— Әтиең, мәрхүм, гомере буе чит дип саташты. Берәр җиргә барып кайттымы, колак итемне кимерергә тотына иде. Чаллыга икмәк илтергә барган бер заман. Шунда өй килешеп кайткан бит, рәхмәт яугыры. Яр өстендә, ди, такта түбәле, ди, пароходлар үткәндә, тәрәзә ачып яулык болгап калырсың, ди. Әткәңнең талканы коры булганга, башта аны-моны дәшмәдем. Күчәм дип пыр тузып йөри инде бу. Нигә шулкадәр китәсең килә, мин әйтәм. Авызын тутырып: «Авылны яратмыйм»,— димәсенме.

Мәгъмүрә апа суынган өйрәсен тиз генә ашап бетерде, алъяпкыч итәге белән ирен кырыйларын сөртеп алды:

— Сугыштан әнә шул сүзе генә кайтармады аны. Читчит дигән иде, менә кайтмады.

Ананың күзләре яшьләнделәр, ул алъяпкычы белән күзләрен сөртте. Бармаклары арасыннан идәнгә ипи валчыклары тәгәрәде. Тәнзилә чит дип авыз ачмаса, ул гомергә дә үз йөрәгендә сакланган шикне әйтмәс иде. Ул үзе генә моңланган чакларында, Гарәфи ата-баба нигезеннән олы булды, шуңа күрә гәүдәсен чит җир тартты, дип уйлана иде.

Әтисенең исемен ишеткәч, Тәнзилә юашланып калды. Үзе көне буе диярлек елагач, әнисенең күз яшьләрен бер дә күрәсе килми иде аның.

— Мин бит гомергә димим.

Мәгъмүрә апаның сүзе бетмәгән иде:

— Шулай ул тузынып йөри, мин әллә ни дәшмим, күрше Миннисалар Чаллыдан кунакка кайттылар. Безне дә ашка өндәделәр. Кердек. Әй, туганым апа, ди Миннисα, авылның кадерен белеп яши күрегез, ди. Тилмерәбез инде шул ком базында, ди. Мин әткәңнең кабыргасына төртәм, күз кысам. Исендә дә юк, рәхмәт яугырының, Минниса белән әрепләшепме-әрепләшә. Шулай да Миннисаларның кайтуы ару булды, мин җиңдем. Бәлки, киткән булыр иде, икенче елны ук сугыш башланды.

— Әткәй дөнья күргән кеше булган, шуңа күрә китәргә ашкынган.

— Күргән булса! Бер нужа чигеп, Лаеш шулпасын эчеп кайтса, китәм дигән тыны булмас иде.

— Апа яши бит.

— Яши. Әллә авылны сагынмый дисеңме? Менә элек-

трлар керсен әле, менә әзрәк байыйк, апаң да ялт итеп кайтып килер.

— Кайтмас, әни, ялгышасың. Гөләндәм минем кебек арыш боламыгы түгел ул. Нәрсәгә кызыгып кайтсын, нәрсәгә?

Кызмыйм дисә дә, Тәнзилә кызып китте. Укыганда күңеллерәк иде, авылның ямьсез икәнлеге дә сизелмәде, әмма гомер буе авылда гына торырга димәгән бит дип зарланды. Мәгъмүрә апа Тәнзиләне бүлдермәде. Кызы, бөтенләй ычкынып китеп, ферманы, аз сөт биреп җан көйдергән кәҗә хәтле сыерларны телгә алгач кына:

— Анысы шулай инде,— дип җөпләп куйды. Аннары, сүзең беттеме дигән сыман, төпчегенә карап торды. Авылны яманлаганны бер дә яратмый иде Мәгъмүрә апа. Шуны белгән Тәнзилә башка яктан суктырмакчы булды:

— Былтыр хезмәт көненә алтмыш тиен бүлделәр. Ничек эшләмәк кирәк тә, ничек җаның түзеп ятмак кирәк! Чыдар әмәлем калмады,— диде ул, ярсып.

Ул арада кич булды. Урамда басудан кайтучы арбалар шыгырдап узды. Сөйләшә-сөйләшә өй турысыннан әрле-бирле кешеләр үтте. Тузан койрыгын селкә-селкә машина чабып узды. Көтү кайтты. Урамга шау-шу, аннан соң сөт исе таралды. Ачык тәрәзәләрдән кичке ашка тезелешкән кешеләр күренде. Әби-чәбиләр чиләк-чүлмәкләргә, иске тасларга тутырылган, көне буе кояшта торып җылынган суларны сапсыз чүмечләр белән кыяр түтәлләренә сибә башладылар.

Тәнзиләләр өендә бүген күңелсез иде. Әнисе сыер савып керде. Кар базына төшеп менде.

— Салкын әйрән эчмисеңме, кызым? Күңелең ачылып китәр,— диде ул.

Салкын әйрән генә ачса икән күңелне! Алай гына булмый икән шул. Үзеңдә барлыгын да белми йөргән хисләр дулап уянганда, корсакка чүлмәк белән генә түгел, чиләге белән әйрән койсаң да ни файда? Шулай да сөт исе Тәнзиләнең борынын кытыклады, ваемсыз көннәрне хәтерләтте. Тик ул көннәрне сагынырга исәбе юк иде аның. Буш, кызыксыз үткән, заяга киткән еллар дип саный иде ул аларны.

Тәрәзә шакыдылар. Йомышчы Бәдриҗамал, очлы борынын пыялага терәп:

— Мәгъмүрә-әү! Тәнзиләне кәнсәләргә чакырдылар. Бикбулат әйтә, ыштубыты килеп җитсен, вәжни йомыш бар, ди,— дип кычкырды.

Менә, менә! Тәнзилә дә кирәк булдымыни? Өч ел эшләп кәнсәләргә чакыручы, хәлең ничек, тормышыңда моң-

зар юкмы дип, бер кызыксынучы да булмады. Бер кич эшкә бармаган икән, Бикбулаты да ишеткән, йомышчысы да килеп җиткән. Анысы мөһим эш икән. Өч ел эшләү, көне-төне фермада яту мөһим булмаган, күрәсең. Идарәдә үз исеменең еш кына телгә алынуын Тәнзилә белми иде, әлбәттә. Чакырган диген. Кеше кадерен беләме соң ул Бикбулат!

Мәгъмүрә апа бакча капкасын бикләп, кар базын ябып, ишегалдындагы кечке эшләрне бетереп, өйгә керде. Кулын иягенә терәп моңаеп утырган Тәнзиләгә карап:

— Кызым, барып кайт. Бәдриҗамалны кат-кат йөртмә. Чакырган җиргә бар, куган җирдән кит, диләр бит. Яхшы түгел,— диде.

Ул нәрсәне яхшы түгел дигәндер, Тәнзилә аңламады.

— Китәм дисәң дә, Бикбулат абыеңнан башка бер эш тә чыкмас. Бар, күңелеңдәген әйт тә кайт,— диде.

Әнкәсенең йомшак кына итеп әйткән сүзләре Тәнзиләне җиңеләйтеп җибәрде. Чыннан да, баш ярылып күз чыкмаган бит! Барырга да аяк терәп сөйләшергә. Кемнән ким ул? Эшләмәсә бер хәер иде, өч ел эшләде, ләм-мим димәде. Әгәр рәтләп сөйләшмиләр икән, Тәнзилә дә рәтен белә бит! Төкерер колхозына, Бикбулатына, чыгар да китәр. Илдә чыпчык үлми, ул да үлмәс.

Битен-күзен юарга дип, Тәнзилә мич арасына керде. Мич арасында идәндә тас тора. Таста җиз комган, стенада сәгать. Бу сәгать бик әрсез булды. Еллар буе туктамый йөри, минут та артта калмый. Тик файдасы гына юк. Олы якка зур сәгать алгач, чормада күгәрә дип, бу сәгатьне Гарәфи мич арасына корыга элгән иде. Шуннан бирле йөри дә йөри ул. Юынырга кергәндә, Мәгъмүрә апа аның бүкәннәрен күтәрә, елга бер мәртәбә, өй юганда тузанын сөртә, канат очына керосин тигезеп шөрепләрен майлый.

Юынырга кергәч, Тәнзилә сәгатькә сәерсенеп карады. Нигә йөри инде ул? Ул бармагы белән басып сәгатьне туктатты. Мич арасында тынлык урнашты. Тәнзилә, мөмкин кадәр азрак тавышланырга тырышып, озак кына юынды, тешләрен чистартты. Су каты сымак тоелды аңа, күзенә сабын кереп интектерде.

Әнкәсе аңа:

— Кешеләр белән сүзгә килмә, кызым. Тел астында бал да, агу да була,— дип кычкырып калды. Тәнзилә нигәдер авырайган аякларын чак кыймылдатып урамга чыкты. Капка әрсез генә шыгырдап ябылды. Тәнзилә беравык басып торды, уңга карады, сулга. Караңгы урамнар кешесез һәм шыксыз иделәр.

Ул барып кергәндә, идарәдә халык шактый иде. Бу Тәнзиләнең юлдагы батырлыгын берьюлы челпәрәмә китерде. Ул оялып кына исәнләште һәм, күрмәсәләр ярар иде дигән сыман, почмактагы буш урындыкка утырды. Урындыкка кемдер сулы кружка куйган булса кирәк, ул, ботларына үтеп кергән дымны тоеп, кып-кызыл булды. Урыннан торырга гына туры килмәсә ярар иде, тәмам көлкегә калам дип, бик борчылды Тәнзилә.

Ике җирдә унлы лампалар янгангамы, идарәдә көндезге шыксызлык сизелми, киресенчә, ул бик жанлы, эшлекле кешеләр җыелган урынга охшаган иде. Күз иялләнә төшкәч, Тәнзилә башта бер булып тоелган кешеләрне аерым-аерым күрә башлады.

Арифмометрын тавышландырып әйләндерә-әйләндерә, кукраеп кына хисапчы Нурислам утыра. Аны биш бригадир сырып алган. Хуҗалык мөдире — майга буялып беткән плащын эссе көнне дә салмый торган озын Сәлахетдин — катыргы тышлы кенәгәсен тезенә куеп нидер яза. Шәмәхә карандаштан аның тешләре генә түгел, ияге дә буялып беткән. Өстәлдә аңа урын калмаган. Шунда ук өч-дүрт кеше яңа газеталарны караштыра. Ишек төбендәге озынча эскәмиягә нәрәт биргәнне тыңларга килгән агайлар тезелешкән. Берәү буралык агачын китермәкче була — ат кирәк; икенчесе юллар коры чакта түбә ябып аласы иде — салам булмасмы дип килгән.

Тәнзилә урыннан уңмады. Янәшә урындыкка куелган калай бактан су эчәргә килгән берсе аңа сүз кушкан була, яшьрәкләр күз кысып азапланалар, тел шартлаталар. Күп кеше тузанлы эш киемнәреннән туп-туры ындырдан монда килгәннәр, ахры.

Идарәдә гел ирләр генә булуына Тәнзилә башта игътибар итмәгән иде. Абайлагач, әткәй сау булса, мин дә болай йөрмәс идем дип әрнеп алды. Башына килгән икенче фикер: «Һәммәсенең мөһим эше, йомышы бар» булды. Үзенең уйлары кечкенә, әһәмиятсез булып калдылар. Күңеленең кайсы почмагындадыр: «Син дә йөрисең инде баш бутап, китсәң ни дә, калсаң ни? Кем син?» — дигән уй калыкты. Шул ук вакытта көндезге үпкә үзен һаман белдереп тора, идарәдәгеләр хакында, болар ашыйсын ашаган, яшисен яшәгән кешеләр, боларга ике дөнья бер хәзер дип уйлысы килә иде. Аларга күңелсез дә түгелдер. Балчыклыдан бик канәгатьләрдер кебек тоела иде. Тәнзиләдәге кебек нечкә хис, сизгер йөрәк юк шул аларда. Булса да алар шунда буразнада аунап, калын тирегә әйләнгәннәр, йөрәкләрен мүк баскан. Романтиканы беләләрмени алар?

Шушы сүз хәтеренә килгәч, Тәнзиләгә күңелсез булып китте. Тузанлы киемле, шау-гөр килеп утырган төркемне урындыкка басып, югарыдан карыйсы килде. «Сезнең берегез дә шул сүзнең мәгънәсен белми бит»,— дип кычкырасы иде!

Ындыр бригадиры Кыям белән Бикбулат килеп кергәч, шау-шу басыла төште. Кемдер, өстәл артыннан торып, Бикбулатка урын бирде. Төннең кыскалыгын, эшнең тыгызлыгын искәртеп, Бикбулат өстәл тартмасыннан дәфтәр чыгарды. Бригадирлар да таушалып беткән куен дәфтәрләренә тотындылар.

Нәрәт бирүне гомерендә бер мәртәбә дә күрмәгән Тәнзилә кызыксынып кешеләрне күзәтергә керешге.

Бикбулат өр-яңа толстовкасының якаларын ычкындырып җибәрде. Пеләшләнгән зур башын учы белән сыпырды.

Бригадирлар берәм-берәм сөйләп чыктылар. Алар ниндидер саннарны онытып торсалар, Нурислам тиз-тиз генә кәгазьләрен актарырга керешә һәм шунда ук әйтеп җибәрә. Кешеләрнең тышкы кыяфәтләрен ныграк күзәткәнгә, сөйләнгән сүзләр Тәнзиләнең бер колагыннан кереп икенчесеннән чыга барды.

Бикбулат үзе сөйли башлагач, ишек төбендәгеләр дә өстәл янына тартылдылар. Иртәгә эшләр язылганда, һәркем үз йомышын әйтеп калырга ашыкты. Бикбулат тартырга теләк белдергәч, аңа өч-дүрт яктан папирос каплары сузылды. Ул Нурислам кабыннан бер «Беломор» алып капты. Кат-кат суырды һәм төтен алкаларын өстәл өстенә өреп җибәрде. Тагын шаулаша, гөрләшә башладылар.

Чират Тәнзиләгә җиткәндә, идарәдә ике-өч кеше генә калган иде. Нәрәт биргәндә үк Бикбулатның үзенә күтәрелеп караштыргалавын шәйләгән Тәнзиләнең йөрәге кешеләр азайган саен ныграк тибә башлады. Ул ник килгәненә үкенә иде. Иртәгә көн булмас идеме? Тагын сүгелергә, йөрәкне авырттырырга туры килә. Бер көн өчен күбрәк була түгелме соң? Аһ, килмәгән булса! Болай да кырыс чырайлы Бикбулат тагын да усаллангган, хәзер иң әшәке сүзләрне әйтә-әйтә кычкыра башлар кебек тоела иде.

Көтмәгәндә бик ягымлы тавыш белән Бикбулат Тәнзиләгә эндәште:

— Үзем сезгә керергә уйлаган идем дә, сеңелем, яхшысынмадым. Апаңны бик әйбәтләп утыртып җибәрдем. Әйберләрен вагонга кертештем.

Тәнзиләнең каты сүз әйтергә дип ачылган авызы рәхмәт әйткәч, Бикбулатның кырыс йөзе ачылып киткән

кебек булды. Күз төпләренә төйнәлгән җыерчыклары бу кырыслыкны үзләренә йоттылар, ахры.

— Мин, Бикбулат абый...— диде дә Тәнзилә туктап калды. Аңа сүзләр җитмәде. Ул ничек, каян башларга икән дип председательгә күтәрелеп карады.

— Син миңа ачуланма инде, сеңелем. Үзеңне станциягә алып барганда да ярыйсы булган икән.

— Барасы килгән иде...

— Апаң мине бик ачуланды. Ул авылдан читләшкән шул, белми. Белү өчен авылда туу гына җитми, анда үсәргә кирәк, яшәргә. Эшләргә кирәк. Син кадерләрлек нәрсә булмаганда, авылны сүгәргә була. Гөләндәм күмәчнең ничек үскәнен оныта башлаган. Ял бирмисез, фиргавен токымы син дип сүгү читен түгел ул! Мин аңа бер сүз дә әйтмәдем. Холкы шундый аның, авылны яратмый.

Сүзсез утырырга яхшысынмаган Тәнзилә:

— Шулай шул,— дигән булды. Үзенен фикерләре Бикбулат фикерләре белән буталдылар. Кайсы үз фикере икәнлеген дә аермачык белеп булмый иде.

— Үпкәләмә инде, сеңелем, станциягә дә барган чакларың булыр әле,— диде ул. Тәнзилә аны-моны әйтергә өлгергәнче: — Иртәгә «Көчле ирек»кә барып кайтырсыз. Синең һаман беркая да чыкканың юк. Район киңәшмәсенә җибәрикме әллә бер дигән идек, яшьрәк әле, эшләсен, диделәр. Менә бер күреп кайт инде,— дип өстәде.

Менә сиңа мә! Тагын теле әйләнмәде Тәнзиләнең. Бикбулат, җавап көткән кебек, аңа карап-карап торды да, идарәдәгеләр белән хушлашып, ишеккә юнәлде. Тәнзилә үртәлеп, үз-үзен ачуланып, председательне куып җитәргә теләп, болдырга чыкты. Идарә алдындагы бүрәнәдә берничә тәмәке уты елтырый. Идарәдә эш беткәч, кешеләр көндәлек эшләрен шунда йомгаклыйлар. Көне буе эшләп арымаганнар икән, дип уйлап алды Тәнзилә. Төркемгә Бикбулат якынлашкач, сөйләшүләр берьюлы тынып калды. Тик председатель тукталып тормады, кемнәндер папирос сорап алды да өенә юнәлде. Ул ерагаюга, бүрәнә өстендә пышылдашулар башланды:

— Ашыга...

— Кунаклар килгән...

— Хатынының абзалары кайткан...

Янгын сараенда эшләүче Лотфулла, утыз-утыз биш яшьләрдәге күкрәп торган таза ир, карлыккан калын тавыш белән баягы әңгәмәне дәвам итте булса кирәк:

— Юк инде, җәмәгать, әйтергә оят. Бикбулаттан эш чыга торган булмады. Ипи дә ашата алмады, авылны да

бөтәйтмәде. Менә урамдагы күперне генә алыйк. Ике генә такта саласы бар, шуны эшләтә алмый бит. Яңгыр яуды исә тагын машиналар чокырда ятачак,— дип сөйләп китте. Кемдер Лотфуллага каршы төште, кемдер яклады, бәхәс купты. Кем Бикбулатны яклый, кем сүгә, аерып булмый.

Тәнзилә башта, председатель кешеләр яныннан китсен, дип көтте. Бикбулат ерагаюга, ул үзенең гаҗәп арыганлыгын, йокысы килүен сизде. Бөтенесен дә ташлап тагын ялгыз гына каласы килде. Болдырда басып тыңлаган сүзләр буш һәм тозсыз, йокы калдырып лыгырдап утыручы кешеләр мәгънәсез булып тоелдылар.

Ул кайтыр юлга чыкты. Лотфулланың карлыккан тавышы:

— Германны аны Америка котырта,— дигән сүзләре аермачык ишетелде.

«Менә кая барып җиткәннәр!» — дип көлемсерәде Тәнзилә.

Урам караңгы. Тик бу урамнан Тәнзилә егерме ел көндез дә, төнлә дә йөргән. Аның киртә-корталары, тубырланган кабыклы карт өянкеләре генә түгел, анда-санда аунаган ак ташлары да, малайлар кәшәкәле уйнаганда казыган аткүз чокырларына кадәр таныш.

Менә Лотфулла әйткән күпер. Авылны кап урталай телеп, сай гына коры елга үтә. Елганың ике як яры буйлап карга оялары белән чуарланган карт каеннар тезелгән. Кичке һава елгадан тәмле су исен китерә.

Күпергә кергәндә Тәнзилә сискәнеп китте, аяк астыннан гына гөберле бака сикереп чыкты.

Күпердән ерак та түгел янгын каланчасы. Каланча янындагы лапаста Лотфулла көне буе корсак кыздырып ята. Аның яңа гына табадан төшкән коймак төсле майлы битен кояшка кыздырып йоклаганын Тәнзиләнең әллә ничә кат күргәне бар. Идарә алдына барып гайбәт сатып утырганчы, шушы күперне үзе төзәтеп куйса, кулы калыр идеме икән?

Бу фикер Тәнзилә өчен шулкадәр көтелмәгән булды, ул баскан урынында катып калды. Бикбулатка, үзенә ачуланып, авыз турсайтып барганда, нигә күпер хакында уйлый башлады әле ул? Бу сорауга җавап табылмады. Каен башында каргалар карылдашып куйды, кайдадыр эт һаулап алды. Тәнзилә, авыр уйларын ташлаган кебек, кулын селкеде һәм, ашыгып-кабаланып, урам буйлап китте.

Мәгъмүрә апа кызының сүзләрен чынга алмады. Кыз кешенең тормышында булып ала торган бик табигый дуамаллык дип кабул итте ул аны. Әмма ананың тынгысызлык белән тулы йөрәгендә саңгырау бер авырту хасил

булды. Менә Тәнзилә ташлап китәр, ялгыз калырмын дип уйламады ул. Үзе өчен борчылудан узган иде Мәгъмүрә апа. Кызы өчен борчылды, аның өчен пошынды. Аның күңелен кузгаткан сәбәпләрне эзләп карады. Апасы кызыктырган дисәң, моңарчы бер дә ул-бу сизелмәде. Өсте бөтен, тамагы тук, эше дә ул кадәр ким-хур булырлык түгел. Төсе-бите Аллага шөкер («үземә охшаган»). Егетләр дә күз салмый түгел үзенә. Аргы оч Тәхәветдин төпчегенең бөгелә-сыгыла сәлам биреп йөрүе юкка гына түгелдер. Күрше Нурҗамал, ерак булса да, агай-энеләре. Бер дә аның алдында төчеләнеп маташмый. Беркөн ашлык суырганда гел минем тирәдә кайнашты. Тик Тәнзилә генә... Егете ярамаслык түгел... Тәнзилә генә... Ни булды икән аңа, Ходаем? Җиткән кызның анасы булудан да авыррак нәрсә бармы бу дөньяда? Бигрәк тә син аңа ана да, ата да булганда.

Нәрсә булды икән? Тиктомалга гына дуамалланмас инде дуамаллануын. Ана төрле йомгакларны сүтеп карады, тик берсенең дә очына чыга алмады. Уй җепләре төрле якларга китеп чәбәләнделәр. Ул Тәнзиләнең кайтуын ут сүндерми көтеп торды. Аяк тавышы ишетелгән саен, тәрәзә пәрдәсен күтәреп, урамны күзәтте. Тышкы яктан бүлмәгә төн карады. Төнне ай яктыртыр. Кеше күңелендә ай юк шул, шуңа күрә егерме ел йөрәге янында йөрткән кешенең күңеле дә Мәгъмүрә апа өчен табышмак иде.

Тәнзилә кайтып та аны куандырмады, Гөләндәмнең китү хәбәрен әйтте дә кече якка чыкты. Әнисенең:

— Сөйләштегезме соң? — дип соравына:

— Булмады әле,— дип кыска гына җавап бирде.

Икесе ике җирдә дәшми-тынмый гына чишенеп яттылар. Мәгъмүрә апа пошынган, Тәнзилә уйчан иде.

Кунакчадан тавык егылып төште, сыер, өй почмагына килеп, озак кына кашынып торды. Кайдадыр сузып-сузып гармун уйнадылар. Ана белән кыз арасына ниндидер ят күләгә кергән, моны икесе дә сизәләр. Әмма нинди күләгә икәнлеген Мәгъмүрә апа түгел, Тәнзилә үзе дә тәгаен ачыкламаган иде. Ул акылы белән әнкәсен юатырга, бала чактагы кебек аның куенына кереп, тынычланып, изелеп йокларга теләде. Әмма хисләр үртәлгән, йөрәк ярсыган, акыл авырайган иде. Кыз бармады, озак көтте аны ана. Төнге тынлыкны бозып, әтәчләр кычкырды.

Тәнзилә төне буе диярлек йокламады, борчылып ятты. Үзенең егерме еллык гомеренә башыннан ахырына кадәр кат-кат күз йөгертеп чыкты.

Ярый, унынчы классны бетергәнче гомер үзенә күрә

кызыклы гына булды, ди. Анда да атасыз бала булу, иптәшләрең арасында начаррак кием-салымың белән аерылып тору газаплары булмадымы әллә? Мәктәп елларының үзенә күрә яме дә булган, тәме дә. Тормышның ачык бер максаты булган: укып бетерү. Аннан соңгы өч елны хәтерләгәндә генә Тәнзиләнең йөрәге кысылып-кысылып куйды. Ничек шулай ваемсыз яшәгән ул? Ферма, өй эшләре аның яшьлеген талаганнар ич! Әнисе олыгаеп килсә дә: «Чуттан чыкканым юк әле, үз минимумымны үзем тутырам»,— дип кенә тора. Тәнзилә ял вакытлары исәбенә тары утарга йөри, киндер йолкырга...

Уйлана торгач, Тәнзилә эшнең тагын бер җайсыз ягын тапты. Ярый, унынчы классны бетергәч, күңеленә хуш килгән, дәрәҗәсенә лаек булган эшне тапты, ди. Күңеленә тәмам хуш килерлек нинди эш бар соң дөньяда? Нәрсә эшләргә өйрәттеләр аны ун ел буена? Алар мәктәптә язын аз-маз көл җыйнадылар. Ул да мәктәп сарае янында ятты-ятты да кар сулары белән агып бетте. Көз көне башак җыйдылар. Кем җыйды, кем кәлтә елан куып йөрде. Колхозның бөтен олы эшләре укучылардан читтә булды. Илле өченче елгы бәрәкәтле борылышны да алар газеталардан укыштыргалап кына белделәр. Күздән кичерделәр, ә күңелләренә барып җитмәде.

Тәнзилә төне буе менә шуларны кайта-кайта күңеленнән кичерде. Дәрте булса да, дәрман ягының сай икәнлеген, теләге булса да, үзенең бер эшне дә төпле итеп белмәвен, егерме яшьлек күсәк булуын шунда аңлады ул. Димәк, читкә китсәң дә, әле беразга бик кыен булачак. Гөләндәм әйтмешли, борының белән җир сөрмичә эш чыкмаячак. Ул да беренче айларын төрле эштә тачка белән балчык ташып үткәргән бит...

Шулай да бер кузгалган бозны туктату җиңел генә булмады. Тәнзилә иртән фермага төшкәндә ят кеше кебек йөрде. Сыерларын да иркәләмәде, иптәш кызларына да килде-киттеле генә җаваплар бирде.

Йөрәге янында нәрсәдер юк иде...

## 4

Кайсы якка гына карасаң да, күз күреме кадәр җирләрдә иген кырлары. Алтын алкалы солылар, чыршы күркәсе кебек эре башаклы бодайлар берсен-берсе чиратлап әле уңга, әле сулга җәелгәннәр. Яшел ефәк тасмалар белән бизәлгән кырлар патшасы кукуруз да каракучкылланды, бәләкәй урман кебек гөжләп утыра.

Басулар уртасыннан борыла-сарыла юл үткән. Шушы

юлдан бөтен дөньяны онытып, автомашинада җилдереп бару искиткеч рәхәт һәм хозур. Гүя син колак яныннан выжлап үткән җилгә каршы машинада бармыйсың, гүя синең үзеңә канатлар үскән һәм гүя син очасың. Менә юл бодай арасыннан чыгып, таш юлга тоташа. Машина шәбрәк бара башлый. Аста елан кабыгы төсле чуар, шома юл, юл читендә зәңгәр тубал булып кияү камчылары, зәңгәр күзләр, аклы-сарылы яулык бөркәнгән ромашкалар кала.

Ай рәхәт! Күкрәкләр киңәя, сулыш алуы җиңеләя. Җырлыйсы, үзеңне-үзең белештермичә тилереп җырлыйсы килә. Шушы җыр белән, моң белән мөлдерәмә тулган табигатьне күкрәгең белән ярып барганда, кемнең генә күңел кыллары тибрәнми калыр икән?

Бикбулат машинаны алай-болайга гына тоттырып чыгармый шул. Ике машинаның икесе дә агач, икмәк, яшелчә ташудан кайтып керми диярлек. Бай колхозлардагы яшьләр кебек Тәнзиләләр район үзәгенә театрга да, күрше авылларга сабан туйларына да йөри алмыйлар. Чөнки машиналар бәйрәмдә дә бушамый. Биш бригадалы зур бер авылга ике машина бик аз шул. Ел килешләре быел шулай ару торса, көзгә тагын ике машина кайтартабыз, ди председатель. Аңа ни, бик ышанып та бетеп булмый. Артезиан коесы казытты да, хутка җибәртмәде. Суны һаман чыгырлы коедан алалар. Бозаулар абзарының түбәсе ябылмаган, шифер көтәләр. Кукуруз силосына дигән унике чокырның да стеналары эчләнмәгән. Шуның өстенә ничәмә-ничә гектар җирнең иген-таруын җыйнап аласы бар. Исәпләсәң, бер кеше башы гына чыдарлыкмы бу эшкә? Колхоз быел тракторлар, комбайннар сатып алды. Күпме акча китте аларга? Автомашиналарга һаман чират тигәне юк. Ат белән йөрүнең соңгы елларда даны төште. Карт-коры гына, кунакка-мазарга барганда, чуар паласлы тарантасларда теркелдәгән була. Утыртырсың син хәзерге заман яшь-җилкенчәген тарантаска!

Бикбулаттан бүген машина алу өчен, Нәби ниләр генә эшләмәде. Ялынды, ялварды, ике мәртәбә өенә барды. Хатыны, кунаклары аркылы әйттерде. Райкомга Сафинга шалтыратты.

Бик хаҗәт эшләрне бүләргә, Нәбине канәгатьләндерергә туры килде. Комсомол секретаренең мондый һөҗүмен күрмәгән Бикбулат шикләнеп кенә машинаны биреп торырга риза булды.

Әрҗәсе вак йомычкалар, салам-соламнар белән чүпләнгән машина сигез кызны, Нәби Таҗетдиновны һәм ферма мөдире Гайфулланы алып юлга чыкты. Председатель сыер савучыларның барысын да җибәрергә риза бул-

мады. Яңа абзарны салып бетерү тиз генә булырга охшамаган, димәк, яңгырлар, салкыннар башланганчы, булганын бер кат карап, сылап чыгасы бар. Аны сыер савучылар карамаса, кем карар? Тишек-тошыкны да яхшырак беләләр, үзләре өчен булгач, тырышыбрак та эшләрләр. Бикбулат шулай диде. Аның сүзе сүз, карышуның файдасы юк.

Машинага утыру, кыр юлы, алда торган сәфәрнең кызыклыгы председатель белән булган бәхәсләрне оныттырды. Байлыгы, иркен тормышы белән сугышка кадәр үк тирә-юньдә данлыклы бер авыл булган «Көчле ирек»кә кызлар беренче мәртәбә баралар. Атаклы авыл. Сабан туйларында кем юртаклары узган дисәң, шуннан булыр. Йөгерешчеләре, берәүгә дә бил бирми торган көрәшчеләре дә бар ул авылның. Ул авылга килен булып төшү кызлар өчен аерым бер шөһрәт санала.

Димәк, алар шул авылны күрәчәкләр, танышачаклар. Максатлары тәҗрибә алу булса да, кызлар ни эшләргә кирәклеген күз алдына китермиләр. Башка вакытта такылдарга яраткан Нәби дә юлга чыккач тынды һәм рәхәтлектән йөзләре килгән кызларга каш сикерткәләп бара башлады. Гайфулла, арада иң олы начальник буларак, шофер янына утырган иде. Үзе күренмәсә дә, вакыт-вакыт кабинадан түтәл тәмәкесе исе килә һәм Тәнзиләгә ферманың бер кисәге үзләре белән «Көчле ирек»кә бара кебек тоела иде.

Машина тузан туздырып, дөбердәп зур бер авылга килеп кергәч, Тәнзилә айнып китте һәм:

— Бәй, килеп тә җиттекмени әле? — дип сорады.

Челтәр рәшәткәле болдыры урамга караган бик биек агач йорт янына килеп туктагач кына Нәби Тәнзиләнең соравына җавап бирде:

— Күрдегезме? Килеп тә җиттек. Бу аларның идарәләре. Райком йорты дип белерсең. Шәп бит,— дип такылдарга тотынды.

Шыбырдашып машинадан коелдылар.

«Көчле ирек»тә аларны көтеп торалар икән. Машина тавышына идарәдән тәбәнәк кенә, юантык кына, ләкин төсе-бите бик чибәр бер кыз чыкты.

— Балчыклыданмы? — дип сорады ул һәм кычкырып көлеп җибәрде. Килүчеләр бер-берсенә караштылар һәм чыдый алмыйча кызга ияреп шаркылдый башладылар.

— Сезне Балчыклыдан килгән дип әйтерлек бар икән шул,— диде кыз, көлеп туктагач.— Әйдәгез, алайса, программага үзгәреш кертик. Иң элек юынып алыйк.

— Иң элек танышыйк,— диде Нәби, кыланып.

— Гафу сорыйм. Мин Бибинур булам. Комсомол секретаре.

Кызлар күрешергә дә өлгерә алмый калдылар. Нәби, атылып, Бибинур янына килеп басты:

— Сезмени инде ул атаклы Сәйфуллина?

— Сәйфуллинасын Сәйфуллина, ләкин атаклы түгел,— диде Бибинур, кызарып.

— Сезне Балчыклыда беләләр,— диде Нәби, мәгънәле генә күз кысып.

— Сезне дә «Көчле ирек»тә беләләр.

Нәби шакмаклы кепкасын кулына тотты, чәчләрен артка чөеп, кызларга карады.

— Сабан туена килгәч, бик озак биеп ялыктырып бетергән идегез,— диде Бибинур.

Кызлар тагын шаркылдап көлеп җибәрделәр. Нәби аз гына да уңайсызланмады:

— Хәтерлисезмени? Мин дә сезне күргән кебек булам,— диде.

Танышу юлда булды. Бибинурларның өе идарәдән ерак түгел икән, ул килүчеләрне юынырга шунда алып кайтты.

Җыйнаулашып нык, таза такталардан ясалган биек урыс капканы үтеп, киң генә ишегалдына барып керделәр. Ишегалды ялт итеп себерелгән. Түрдә лапас-куралар, уңда алты почмаклы өй, сулда җимеш бакчасы. Вак талчыбыкларыннан үрелгән утыртма читән өстеннән ишегалдына сузылган ботакларда зур-зур алмалар күренә. Алма мул сырган ботаклар астан җәпле таяклар белән терәтеп куелган.

Боларны күргәч, кызлар «аһ» дип куйдылар. Гайфулла телен шартлатты:

— Вәт бакча дисәң дә бакча!

Нәби:

— Миңа калса, мин шушы бакчадагы эш тәҗрибәләре белән канәгатьләнер идем,— дип күз кысты.

— Күрмәгәндәй кыланмагыз сана! — диде Тәнзилә, ачуланып.

— Бакчага чакырмыйм, анысы соңрак булыр. Әйдәгез, юыныгыз элек,— дип, Бибинур кунакларны кое янына алып килде.— Кое суыбыз бик йомшак безнең, бер дә инешнекеннән аермасы юк.

Кунакларның кое янындагы соры таштан чокып ясалган ялгашларны, һәр җирдә күзгә ташланган җыйнаклыкны абайлавын күргәч, Бибинур аңлатып бирде:

— Әткәй эше.

Тәнзиләне нидер чәнчеп алган кебек булды.

Юл тузаннарын кагынып, бит-күзне юып, әл-хәл ал-

гач, кем кая барырга тиеш дип киңәшә башладылар. Гайфулла:

— Барыбыз да бергә йөрик, айры-чайры йөрүнең мәгънәсе юк,— дисә дә, сыер савучы Шәмсеҗиһан исемле кара тутлы йөзле, усал гына яшь хатын:

— Өер булып йөрмик әле. Атна ятарга килмәгән. Бер көн эчендә барын да күреп, карап буламы? — диде.

Шәмсеҗиһанның тел төбе кая барганын, аның, Гайфулладан аерылып, үзбаш йөреп калырга теләвен сизсә дә, Тәнзилә бүленүне, һәркемнең үз һөнәрдәшләре янына баруны хуплады.

Гайфулла:

— Машина бар ич безнең, әйләнәбез дә чыгабыз,— дисә дә, Шәмсеҗиһан:

— Авылда да баш әйләндерәсең, монда да тинтерәтмә әле,— дип карулашты.

...Шулай аерым-аерым йөрергә карар кылдылар. Сыер савучылар Бибинурга иярде, дуңгыз караучыларны юл уңаена фермада калдырып чыгарга булдылар. Гайфулла, колхоз председателен һәм ферма мөдирен эзләп табам, алар белән сөйләшәм, дип китеп барды. Киткәндә:

— Фермаларда мин дә булырмын. Әйбәт йөрегез. Килүнең файдасы булсын. Аяк талдырып йөрүнең пычагыма да кирәге, юк,— диде.

— Ә мин? — диде кинәт кенә Нәби.

— Нәрсә син?

— Мин кая барырга тиеш?

Бибинур башта бик уңайсызланды, Нәбинең клуб мөдире һәм комсомол секретаре икәнен белгәч:

— Сезгә барлык төркемнәрдә дә булырга туры килә алайса,— диде.

Нәби көлеп җибәрде:

— Ярар инде, үпкәләмим. Маршрутны үземә үзем билгеләргә туры килер. Иң элек, исән-сау килеп җиттек дип, райкомга, Бикбулат абыйга шалтыратырга кирәк. Аннан күз күрер,— диде ул һәм Гайфулла артыннан кызу-кызу чыгып китте.

Кызларның чәч белән, күлмәкләре белән озак мавыгулары Тәнзиләнең җенен чыгарды. Ул иптәшләрен ашыктыра башлады:

— Җәһәтрәк булыгыз инде. Кояш төшлеккә җитә бит!

Яңадан идарә яныннан уздылар. Шофер Миңнулла машинасын күләгәгә куйган да, кабинасында бөгәрләнеп ятып, борын сызгырта. Аны кызгандылар, уятмадылар.

## 5

Бергә җыелып барганда сүз әллә ни куермаса да, Бибинур янында өч сыер савучы гына калгач, кунаклар сизелерлек җанландылар. Бигрәк тә Шәмсеҗиһан иркенәеп китте. Бибинурның әти-әниләре, кайда укуы, ничек укуы хакында бик төпченеп сорашып барды.

Сүз арасында Бибинур үзенең дә сыер савучы булып эшләвен әйткәч, Тәнзилә:

— Таптым! — дип кычкырып җибәрде.— Сине кайда күргәнем бар дип килә идем. Рәсемеңне күрдем ич! Идарә стенасында!

Шәмсеҗиһан Бибинурның комсомол җитәкчесе дә булып эшләвенә шикләнде.

Тәнзилә дә:

— Ничек өлгерәсең? Безнең авылда секретарь итеп йә китапханәче, йә клуб мөдире сайлана. Взнос җыярга да вакыты иркен. Эш кешесе булмагач, районга да теләгән вакытында бара ала. Безнең Бикбулат абый тик кенә йөргәнне бер дә яратмый,— диде.

— Кем ул Бикбулат?

— Председателебез лә!

— Безнең председатель дә тик йөргәнне яратмый! — диде Бибинур. «Алай эшлекле председателегез булгач, нигә колхозыгыз бик артта соң?» дип сорамакчы иде, әле уңайсызрак булыр дип, кыймады.

«Көчле ирек» районда иң алдынгы колхозларның берсе булганлыктан, тәҗрибә уртаклашучылар булып-булып киткәлиләр иде. Дөресен әйткәндә, Бибинур алардан ялыгырга да өлгерде. Шул ук беркатлы сораулар, шул ук апачык ярылып яткан хакыйкатьне белергә тырышулар: «Сөт алуда, имеш, ничек мондый зур уңышларга ирештегез?» Җавап биреп кара инде син! Үзләренең эшен бер дә югары нокта дип карамаганга, сауган сөтләрен азсынып йөргән Бибинур андый чакларда ни әйтергә дә белми аптырап кала. Сыерның сөте телендә дип кенә котылып буламыни! Килүчеләр китапларда язылмаган, бер кеше дә белмәгән ысулларны сөйләүне таләп итәләр. Бибинур сихерче түгел лә! Хәер, фермалар, көтүлекләр белән танышып, кыш көне сыерларның нинди тәрбиядә торуларын белгәч, кешеләрнең күзләре ачыла.

Балчыклы сыер савучылары аңа ошады. Ул, гадәттәгечә, унбиш-егерме кеше булыр дип көткән иде. Өчәү генә килделәр. Өченең берсе Шәмсеҗиһан гына күбрәк сөйләшә. Ул урамнан үткәндә шәбрәк йорт, яхшырак каралты-кура күрсә:

— Бу кем йорты? Ай-яй шәп. Мөгаен, председательнекедер әле,— дип куя.

Йортның йә көтүченеке, йә яшелчә бригадасында эшләүче тол хатынныкы икәнлеген белгәч тә тынмый, озак кына телен шартлата:

— Яши беләләр соң, агай, кешеләр,— дип гаҗәпләнүдән туктамый.

Өченче сыер савучы — Зөбәрҗәт исемле, зәп-зәңгәр күзле, очлы иягенә матур гына миң кунган басынкы кыз — Шәмсеҗиһанның гел чит авылны гына мактап баруын, Балчыклыны яманлавын ошатмады:

— Моның ише генә йортларның үзебездә дә бетәсе юк инде, Шәмсеҗиһан апа,— диде.

— Күрше тавыгы күркә булып күренәдер инде,— диде Бибинур.

— Алай була күрмәсен! Тавыгыгыз күркә булып күренсә, сыерлары фил хәтле икән дип кайтып китәр ул,— дип көлде Зөбәрҗәт.

Шәмсеҗиһан ирләрчә эре-эре атлап барган җиреннән Зөбәрҗәткә борылды:

— Юк инде, гөлкәем! Мондый өйләрдә торып булмады. Бикбулатның кәҗә сарае да шифер белән ябылган, өй базларына кадәр таш белән эчләнгән икән, аннан миңа ни куаныч? — диде ул, ачуланып. Аннан Бибинурга карап: — Безнең эшебез ул кадәр үк мөшкел дип уйлый күрмә син, тел очына килгәнне генә әйтеп җибәрдем. Тормышыбыз ару безнең. Сезнең белән үк тиңләшә алмасак та, бик ару! — диде. Үзе Тәнзилә белән Зөбәрҗәткә борылып: «Тутагыз сөйләшә белә ул!»— дигән кебек каш сикертте.

Урамның ике ягында да зур-зур топольләр үскән. Аларның җир өстенә чыккан чатлы-ботлы тамырлары арасында тавыклар коена. Тавыклар янында ук колак тишекләренә шалкан чәчәрлек булган, пычранып беткән ике-өч яшьлек малай утыра. Ул учы белән һавага туфрак чөеп җибәрә дә:

— Яңгыр яудырам, яңгыр! — дип рәхәтләнеп көлә.

Бибинур малай янына килеп җиткәч, иелеп аны җирдән күтәрде:

— Кем малае син, ә?

— Әни малае.

— Әниең кем?

— Әсхәпҗамал түти! — диде малай, борынын тартып.

— Әсхәпҗамал түти булса, бар, йөгереп кайт та битеңне ю. Болай туфракка батып йөрмә.

Малай көлмәк итәген бөтерә башлады. Итәк астын-

нан шактый зур бүксә һәм чыпчык башы кадәр кендек килеп чакты.

Шәмсеҗиһан:

— Сезнең авыл малайлары да нәкъ бездәгеләр кебек икән,— диде.

— Бала кайда да бер инде, — диде Бибинур. Малай яргаланып беткән кара үкчәләрен ялтыратып капкага йөгергәч, өстәп куйды: — Нигә яслегә илтми торганнардыр. Ясле дисәң, кайберәүләр карышалар да каталар.

— Сездә дә артта калучылар бармыни? — диде Тәнзилә. Ул артта калучылар дияргә теләмәгән иде.

Бибинур аңлады. Көлеп куйды:

— Әллә тагын! Төрлесе бар инде,— диде.

Тәнзилә ни өчендер топольләргә аерата игътибар итте. Аларның күплеге, дәүлеге аның исен китәрде.

Авылны чыктылар. Авыл очындагы бушлыкта җидесигез бураны күргәч, Бибинур адымын акрынайтты.

— Күрәсезме? Төзиләр. Дүртесе каладан кайтты. Авылдашлар, механизаторлар. Колхозга кабул иттек үзләрен,— диде ул, бераз тантаналы төс белән. Тәнзиләгә Бибинур моңарчы ошап килгән иде, соңгы сүзләрен ишеткәч, аңа Бибинурның кай җиредер ошамады. «Мактана» дип уйлады ул. Бибинур исә, бер дә аны-моны уйламыйча, үз авылларына кайткан якташларын бик яхшы каршылауларын, аларның хәзергә мәктәп интернатында яшәүләрен сөйләп бирде. Ындырлар буйлап түбән төшә башладылар. Сәфәрчеләр алдында искиткеч бер күренеш ачылып, Шәмсеҗиһан да, Зөбәрҗәт тә, Тәнзилә дә авызларын ачып катып калдылар. Сөзәк ярлы күлдә меңләгән ап-ак үрдәкләр мыж киләләр, бакылдыйлар, чумалар. Кошлар базарымыни?! Зөбәрҗәт кулларын чәбәкләде.

— Әнекәем лә! Менә байлык!

Кинәт килеп чыккан бу күренешнең тәэсирен алдан ук көткән Бибинур, бик канәгатьләнеп:

— Ошыймы? — дип сорады.

— Искиткеч! Бу кадәр үрдәкне гомеремдә дә күргәнем юк иде, ант әгәр,— диде Зөбәрҗәт.

— Менә күр инде алайса!

— Синең гомердә дә әллә ниләр булыр әле, Зөбәрҗәт,— диде Шәмсеҗиһан, күлдән күзен алмыйча.

Дүртесе дә күл ярына килеп бастылар.

— Пекин токымы! Икенче ел үрчетәбез. Сара апа карый үзләрен. Беләсезме сез безнең Сара апаны? — диде Бибинур.

— Мин әле сездә үрдәкләр барын да белми идем.

— Сара апа элек тавыклар карый иде. Аның турында газеталарга да бик күп яздылар. Карт коммунист. Улын кулаклар үтергән. Хәтәр хатын. Кулакларның да кирәген биргән үзе! Хәзер менә үрдәкләр карый.

— Ай-яй симезләр!

— Кызыгам мин үрдәк үстерергә! Беләсезме, үрдәк асрау сыер асрауга караганда файдалырак бит! — диде Бибинур.

— Булса, икесе дә кирәк инде аның,— диде Зөбәрҗәт.

— Анысы дөрес. Әмма кошлар тиз дә үрчиләр инде! Аларның саны бер елда икеләтә, өчләтә арта бит. Алты-җиде айда бәбкә зур үрдәк булып үсеп җитә. Үзе талымсыз, ни бирсәң, шуны ашый. Бер кило бозау итен алу өчен ике мәртәбә күбрәк азык кирәк. Үрдәк ите бик арзанга төшә! Ә тәме? Ә көзен үрдәк өмәләре?

Бибинурның болай да алсу йөзе тагын да янып китте. Тәнзилә аңардан: «Ә син боларны каян беләсең?» — дип сорамакчы иде, читенсенеп тыелып калды.

— Шушы үрдәкләрне күрсәм, йөрәгем кузгала.

— Үрдәге әйбәт, тик бездә аның күле юк. Бер корышса корыша бит ул,— диде Шәмсеҗиһан, чын күңеленнән офтанып.

— Күле бездә дә юк иде. Трактор белән казыттык та су җибәрдек.

— Тавыгын да җүнләп асрый алмаган кешегә үрдәк тагын,— диде Тәнзилә, теш арасыннан гына.

Күлне әйләнеп үтеп, үргә менә башладылар. Бибинур күлне ничек ясауларын, таудагы чишмәдән торбалар белән су җибәрүләрен, бик күңелле булуын тәмләп кенә сөйләп барды да кинәт:

— Үрдәкләр юк дисез инде. Ә тавыкларыгыз уңганнармы соң? Ничәшәр күкәй салалар? — дип сорады.

Кунаклар бер-берсенә караштылар. Алар берсе дә күпме тавык барын да, йомырка санын да белми иделәр. Бибинур сүзне икенчегә борып алып китте. Әмма кунаклар үз колхозлары хакында җәелеп сөйли алмадылар. Шәмсеҗиһан олырак хатын, ул белмәсә дә гаеп түгел дип уйлый иде Бибинур, ә бу икесе... Яшьләр бит... үз хуҗалыклары белән кызыксынмыйлар да икән.

Тәнзиләнең унынчыны бетергәннән соң фермага керүен ишеткәч, Бибинурның күңелендә аңа карата хөрмәт уянган иде. Күрер күзгә тыйнаклыгы, чибәрлеге, акыллы-акыллы гына сораулар бирүе, күл буена килгәч янып торган күзләре өчен Бибинур Тәнзиләне яратып та өлгергән кебек булды. Ихтимал, бик яхшы кыздыр бу Тәнзилә дип уйлап куйган иде ул. Әмма йөргән саен

Тәнзиләнең күңелсезләнә баруы, ап-ачык беленеп торган таркаулыгы, урынлы-урынсыз биргән сораулары бер Бибинурны гына түгел, Шәмсеҗиһан белән Зөбәрҗәтне дә хәйранга калдырды. Шәмсеҗиһан түзмәде:

— Сиңа ни булды, наныем? Укаң коелган кеше сыман йөрисең? — дип сорады.

Сөзәк үргә менеп баралар иде. Тирә-якта бәбкә үләннәрен йолкып, төркем-төркем казлар йөри. Алачыкны әйләндереп алган койма күләгәсендә эсселектән гаҗиз булган ике бозау пуф-пуф килеп мышнап ята. Алачык эченнән мотор гөрләве һәм чакы-чокы бәрелгән тимер тавышы ишетелә. Дегет исе, күмер исе, тагын әллә нинди исләр килә.

Алачыктан бер-ике җир буе китүгә, зур гына иңкүлектә тигез рәтләр булып төрле зурлыкта ферма биналары тезелгән.

— Фермаларыгыз үзе бер шәһәр икән,— дигән булып, Шәмсеҗиһан Бибинурның beләгенә ябышты.

Яралы бармак кая сузсаң да бәрелүчән була бит. «Шәһәр» диюгә яшен тизлеге белән Тәнзиләнең күз алдына Гөләндәмнең мыскыллап елмаюы килде. Чын шәһәрне күргәнең дә юк ич, сөйләнгән буласың тагын, дигән кебек булды ул.

Кайвакытта шулай була бит: бер дә көтмәгәндә генә кәефең кырыла. Аның нилектән кырылганын да белми каласың.

Тәнзилә дә, кәефе киткәч, сәбәбен эзләп озак кына баш ватты. Ни булды соң әле аңа? Танышу әйбәт кенә бара ич. Ул яңа авыл, яңа кешеләр күрә. Бер тапкыр да йөрмәгән юллардан, сукмаклардан йөри. Ә ул шат түгел. Эзләнә торгач тапты Тәнзилә: тавыкларның ничә йомырка салуларын белмәгәнгә кәефе кырылган икән аның.

Сәбәпне табуның да файдасы булмады, Тәнзиләнең бер кузгалган күңеле урынына утырмады. Ярый, Тәнзилә белми, ди. Тавыкларны Фәйрүзә апа карый, ди. Ә нигә Бибинур үз колхозындагы тавыкларның хәлен белә? Сыерлар турында белүе гаҗәп түгел инде аның. Тәҗрибә уртаклашырга, өйрәтергә дигәч, аз-маз китабын да карагандыр. Үз фермаларындагы хәлне Тәнзилә дә биш бармагы кебек белә ич аңа калса. Тукта әле, беләме соң? Нигә Бибинур хәзергесе көнне һәр сыердан егерме дүрт литр сава да, Тәнзилә сигез-ун литр белән ияк сыпырып кала?! Тәнзиләнең аркасына тир чыккан кебек булды. Әгәр серен белсә, Тәнзилә дә чиләкләп савар иде, белми шул. Ул күңелендә көнләшүгә охшаган бер хисне сизеп калтырап китте. Тирә-юньдәге бар матурлык аның өчен

ямен җуйды. Соры ташлардан салынган дүрт рәтле сыерлар абзарына кергәч тә, ул Шәмсеҗиһан кебек автоэчергечләргә ташланмады, Зөбәрҗәт кебек шаккатып та калмады, астыртын гына Бибинурга күз төшерде. Аннары яратмыйча йөзен чытты. Теге әшәке уй тагын күңеленә килде: «Менә сине безнең колхозга, утырган эт биеклеге фермаларга китерәсе иде. Авызыңны ерыр идеңме, әллә утырып елар идеңме? Рекордларың очар иде, фьют!»

Тәнзилә үз фермаларын уйлап алды. Өч ел йөреп, күреп күнегелгән урыннар бөтен ваклыклары, су тамып торган юкә такта түшәмнәре, кыйшайган яңаклы ишекләре һәм саламнары бүселеп-бүселеп торган түбәләре белән күңелдә калыктылар. Шул фәкыйрьлек уртасына Бибинурны бастырып куйгач, һич тә көтмәгәндә Тәнзиләнең күңеле күтәрелде. Аның йөзенә усал тантана итү галәмәтләре чыкты.

Эче акшар белән ап-ак итеп буялган, чиста, шома идәнле, әчкелтем дару исе килеп торган бозаулар торагыннан чыкканда, Тәнзилә белән Бибинурның күз карашлары очрашты. Бер-берсен өйрәнгәндәй текәлеп-текәлеп карадылар алар. Тәнзилә беренче булып керфекләрен түбән төшерде. Бибинур аның әшәке фикерләрен белә, төшенә торгандыр, ул юри генә шулай ягымлы булып кыланадыр кебек тоелды.

Әшәке кеше кешеләрдән үзенә охшаган яман якларын эзли, дигән хакыйкать исенә төшеп, Тәнзилә күңелендәге начар фикерләрне онытырга, Зөбәрҗәт кебек йотылып Бибинурны тыңларга, аның кебек сокланырга, мактарга теләде. Теле әйләнмәде. Елмаерга азапланды, авызы ерылды, ә күзләре тонык һәм җансыз иделәр. Ул үз күңелен чишә алмады. Кая гына бармасын, нәрсә генә күрмәсен, аның көнчелек тамырлары бүрткәннән-бүртә барды. Җене кузгалды. «Нәрсәгә мактаган булалар икән боларны? Мондый мөмкинлекләр булганда, мин сынатыр идемме? Сөтне умырыр идем!» — дип уйлады ул.

Тәнзилә кинәт сискәнеп китте. Шәмсеҗиһан, аның кабыргасына төртеп:

— Тораташ каттыңмы? Вәт кеше ничек эшли! Мин мондый колхозларны кинода гына була дип белә идем,— диде. Шәмсеҗиһанның йодрыгы, кечкенә булса да, саллы гына иде. Шаярып кына төрткән булса да, Тәнзиләнең кабыргасы шактый авыртып торды.

Азык-төлек складын, кухняны карап үткәч, кунаклар бәләкәй ябалдашлы топольләр үсеп утырган кечкенә бакчага чыктылар. Бакча эчендә такта түбәле җыйнак кына өй күренә иде.

— Терлекчеләр өе, безнең өй. Агачларын да без утырттык. Матур бит, ә? — диде Бибинур.

Кеше булмагач, өйгә кереп тормадылар. Тәрәзә каршындагы түтәлләрдәге шау чәчәктә утырган үрмә гөлләрне, кашкарыйларны гына карадылар да бакчадан чыктылар, Зөбәрҗәт мәк чәчәгенә дә, күбәләк канатына да охшаган бер чәчәкне өзеп түшенә кадады.

Тәнзилә бу чәчәкнең дә исемен белми иде, тагын кәефе кырылды. Җитмәсә, сул аягын туфлие кыса башлады. Үтереп-үтереп кыса. Ул, иптәшләреннән арттарак калып, туфлиен салды. Чәнчә бармагы кура җиләге төсле кып-кызыл булган. Елга бер-ике мәртәбә генә адәм рәтле аяк киеме кия башласаң, шул булмый, ни булсын!

Фермалар янындагы чирәмлеккә чыккач, Бибинур тагын да җанлана төште. Ул Шәмсеҗиһан белән Зөбәрҗәтне култыклап алды, әле берсенә, әле икенчесенә борыла-борыла сөйли башлады.

Башка вакытларда да Бибинурга кунаклар белән йөрергә туры килә иде. Әмма аларның күп булулары комачауладымы, ул бервакытта да бүгенге кебек ачылып китә алмады. Бүген исә аңа бик рәхәт иде.

— Менә кыш көне иркенләп, өч-дүрт көнгә килегез. Безнең кызлар белән танышырсыз. Шундый кызлар бар бездә...— диде ул, Зөбәрҗәткә чын күңеленнән.

— Шәпләрме? — дип сорады Шәмсеҗиһан.

— Искиткеч. Без кыш буе җыелып китаплар укыйбыз. Гөлчәһрә исемле бер кызыбыз бар. Тавышы шундый матур. Күбрәк ул укый. Гыйнварда институтка китәбез аның белән.

— Ничә ел укыйсың бар әле?

— Уһу, күп әле. Өч ел.

— Институттан соң кая китәсең?

— Кая китим,— диде Бибинур, гаҗәпләнеп,— беркая да китмим. Югары белем белән сыер савасым килә.

Шәмсеҗиһан телен шартлатты...

Фермалар артта калды. Бибинур кунакларга көтүлекләрне, җәйге туплау урыннарын — җәйләүне һәм иптәшләрен күрсәтмәкче булды. Алар сөйләшә-сөйләшә тау битеннән бара башладылар. Көтүчеләрнең берсе үз энесе булуын, икенчесенең дә яшь бер егет икәнлеген әйткәч, Бибинур шыпырт кына көлеп куйды. Шәмсеҗиһан, Тәнзиләнең авызыннан өзеп алып:

— Үзе чибәр дәме? — дип сорады.

— Чибәр дә. Безнең авылда бөтен кеше дә чибәр. Күрерсез әле.

— Әллә ни күрә алмабыз инде, вакытның бик җайсыз чагы,— диде уфылдап Шәмсеҗиһан.

Алар коры бер ермакка җиттеләр. Бибинур ермак буйлап өскә күтәрелгән тар сукмакка борылды.

— Өстәнрәк барыйк әле, күңеллерәк булыр,— диде ул.

Тауга менгән саен, офык киңәя барды. Өйләр, агачлар кечерәйде. Авыл үзенең тыкрыклары, шакмак-шакмак бәрәңге, алма бакчалары, тигез рәткә тезелгән өйләре белән урман аланындагы умарталыкка охшап калды. Агачлыкка күмелгән яшел калай түбәле мәктәп тирәсендә нindидер карамчыклар мәш киләләр.

Тауның нәкъ уртасыннан диярлек киртләчләнеп юл үткән. Аны буйдан-буйга яңгыр яргалаган: әллә күптән кеше йөрмәгәнгә, вак таш, ком күмеп киткән.

— Байлар юлы,— дип аңлатты Бибинур, шунда менеп җиткәч.— Байлар бу юлдан йөргәннәрдерме, юктырмы, анысын белмим, ә ярлылар йөргән. Алар, әнә анда зират артындагы таудан таш чыгарып, шушы юлдан Дусай алпавытына таш ташыганнар. Бу юлда хәзер кәҗәләр генә йөри,— диде.

Зөбәрҗәт, көлеп:

— Без дә кәҗәгә әйләндекмени, Бибинур? — дип сорады.

— Арада кәҗәләребез дә бар ич,— дип кашын сикертте Шәмсеҗиһан.

Сүзнең үзе хакында барганын аңлаган Тәнзилә сер бирмәскә тырышты:

— Нигә бәйләнәсез әле миңа? Кәҗәләнеп нишләгәнем бар? — диде.

Көлештеләр дә бу сүзне бетерделәр. Юл урыны-урыны белән тар булганга, казлар кебек бер рәткә тезелеп бара башладылар.

Көн кызганнан-кыза иде. Тәнзиләнең сул аягы һаман сызлый. Ә Зөбәрҗәт белән Шәмсеҗиһанның исләрендә дә юк. Вак атласа да, бик җәһәт барган Бибинурның итәгенә тагылганнар да мөгезсез сыер кебек баралар да баралар. Җитмәсә, Зөбәрҗәте:

— Шулай да нигә Байлар юлы дип атаганнар икән? — дип төпченеп бара.

Бибинур җавап бирә алмады:

— Без ташны бу юлдан ташымадык,— дип кенә куйды.

— Сез бик байлар түгел алайса,— диде Шәмсеҗиһан.

— Ул вакытта байлар түгел идек.

— Ә ничек мондый шәп фермалар җиткердегез, нәселле сыерлар булдырдыгыз?

Бибинур тауда йөрүдән кабынган сулышын бүлә-бүлә яшьләрнең ничек таш чыгаруларын, Чаллыдагы шефларның аны ташып бирүен, цемент, шифер таба алмыйча

интегүләрен, бик аптырагач, Казанга, депутатка барып җитүләрен бәйнә-бәйнә сөйләде.

— Төзеп бетергәч кенә матур ул. Болай шактый интерәтте,— диде ахырда.

Тәнзилә Бибинурның сүзләрен ишетмәде. Ул чатанлап барды-барды да адымнарын акрынайтты, бераздан бөтенләй туктады. Түбәнгә карады, ял итәсе килеп китте. Ул тау киртләченә утырды. Аста күңелле, бик матур күренеш ачылды.

Авыл сул кул якта, артта калган. Ул чалбар балаклары кебек икегә аерылып яшеллеккә төренгән. Үрдәкле күл. Күлдән терекөмеш җепсә кебек кенә булып кеч-кенә инеш агып чыга. Инеш боргалана-боргалана бер күренә, бер югала, мондагы тау турысына ук килеп җитә дә таллар куелыгына кереп югала. Үзе күренмәсә дә, тирә-ягындагы яшеллегеннән, болыннарыннан аны сизеп була. Болын аръягында кырлар, салам эскертләре, телеграм баганалары. Тәнзилә баганаларның чыжлавын ишеткән кебек булды. Әллә тау итәгендәге таллар гына гөжлиме? Җил дә юк шикелле. Ап-ак мендәрләр булып анда-санда гына болыт кисәкләре йөзә. Шуларның берсен җиргә төшерәсе иде дә менә шунда кипшергән җиләк яфраклары, сарутлар, ыңгырчак биеклеге генә ак әремнәр өстендә кабартып рәхәтләнеп ятасы иде. Бер гамьсез, хәсрәтсез озак-озак итеп ятасы иде. Бикбулат та күрмәс, сүз әйтүче дә булмас иде.

Ә менә Бибинур теләгән җирендә теләгәнчә йөри торгандыр. Аңа беркем дә сүз әйтмидер. Ул алдынгы, атаклы кеше. Читтән торып укыйм, ди. Ничек өлгерә икән? Аның сыер тизәген салам белән катыштырып абзар сылап йөрисе юк шул. Андый фермаларга Бибинур эшкә дә кермәс, әллә кайчан йә Мәскәүгә, йә Казанга сызар иде. Кара инде, ә үзе нинди яшь, үзе тормыштан канәгать. Егете дә бар. Кешеләр ничек шулай тормышларын оста көйлиләр икән?

— Тәнзилә, әйдә, каласың ич!

Ул куркып китте. «Каласың ич» каяндыр күктән иңгән кодрәтле аваз кебек аны бик җитди рәвештә искәртә сыман тоелды.

Шәмсеҗиһан белән Зөбәрҗәт аңа, кычкырып, кул болгыйлар икән. Тәнзилә туфлиләрен салып кулына тотты һәм, сакланып кына кайнар туфракка баса-баса, иптәшләре янына китте.

— Кызыкларны ишетмәдең дә. Вәт ничек җиткергәннәр алар ферманы,— диде Шәмсеҗиһан, Тәнзиләне шелтәләп.

— Аңа сүз әйтмәгез, Шәмсеҗиһан апа,— диде Бибинур, Тәнзиләне яклап.— Мин үзем дә, берәр яры барсам, дөньяның матурлыгына карап туя алмыйм. Мәскәү фестивалендә дә булдым бит әле мин.

Кызлар «аһ» иттеләр.

Бибинур иң өстендәге ефәк яулыгын алып күрсәтте:

— Шуның истәлеге. Бер япон егете бүләк итте. Адресымны алып калып хат та язган иде. Укып булмады: японча язылган. Ахырдагы: «*Карошо, друг, мир*» дигән өч сүзен генә аңладым. Менә Мәскәүдә күңелле булды, ичмасам!

— Ә авылыгызда ничек, күңеллеме? — дип сорады Тәнзилә. Ул Мәскәүне аркылыга-буйга йөргән, япон егетләре белән хат алышкан кыз авыл тормышын пыр туздырыр дип көткән иде. Алай булып чыкмады. Бибинур:

— Кемгә ничектер, әмма мин үзебезнең авылда йөрәккә ятышлы бер ямь табам. Монда мин белмәгән бер генә түмгәк тә юк. Түмгәк арасындагы тәкәрлекләренә кадәр таныш. Таныш һәм җанга якын. Авыл да, матур җыр кебек, ялыктырмый бит,— диде.

— Авыл якын була ла инде ул күңелгә,— диде Шәмсеҗиһан.

Тәнзиләнең Шәмсеҗиһанга ачуы килде. Ат дагалаганда бака ботын кыстырган кебек, алап кадәр авызын тутырып сөйләнгән була, тәмле сүзнең ямен җибәрә. «Көчле ирек» хакында сүз бара лабаса! Балчыклыда торыр иде синең Бибинурың!

Тәнзилә чыраендагы үзгәрешне Бибинур тагын абайлады. Ул кызарып китте. Фестиваль, тәкәрлек оялары хакында сөйләргә бөтенләй җыенмаган иде ич ул! Хәзер мактанган сыман килеп чыкты. Кичә кич колхоз председателе:

— Кара аны, ишетсен колагың, сак сөйләш. Мактаналар икән болар дип китмәсеннәр, яхшылыкның, байлыкның чиге юк аның. Безнең дә килмәгән җирләребез күп, булганын күрсәт, артыгын кубарылма,— дип кисәткән иде.

Хәер, Бибинур үзе турында сөйләгәндә генә искә алды ла тәкәрлекләрне. Зөбәрҗәт белән Шәмсеҗиһанда бу сөйләшү Бибинурга булган хөрмәтне генә арттырды. Тик менә бу борчак чәчәге төсле яшел бизәк төшкән, ябык изүле, кыска җиңле күлмәк кигән, сөрмәле күзле Тәнзилә генә...

Юл тау бите буйлап барды да барды. Байтак юл алгач, сәфәрчеләрнең игътибарын тау кашындагы дәү-дәү комташ кантарлары җәлеп итте. Трактор вагоны дәүле-

ге таш кисәкләре, бер иңнәре белән тау эченә кереп, катлам-катлам өелеп яталар. Ташларның кояш һәм җил шомарткан ягы меңнәрчә исемнәр, цифрлар белән чуарланган. Гарәпчәләп тә, латин хәрефләре белән дә, яңачалап та, кыеклап-мыеклап бик күп кешеләр үз истәлекләрен калдырганнар. Аерата тырышлары хисләрен җыр итеп, шигырь өзеге итеп таш битенә чокып күчергәннәр. Менә яңа язу:

*«Былбыл булып, гөлгә кунып*
*Керәсең төшләремә.*
*Галия, Тәлгать».*

— Үзенә күрә тарихи урын. Сабантуе көннәрендә монда яшьләр җыела,— дип аңлатты Бибинур.

— Бибинур, әз генә хәл алыйк әле шушында,— диде Тәнзилә кинәт.

Бибинур каршы килер кебек түгел иде, әмма Шәмсеҗиһан белән Зөбәрҗәт беравыздан:

— Нинди хәл җыю тагын? Килгәч килгәч, барын да күреп китик инде. Сыерларын күрмә, җәйләүләрен күрмә, килеп йөрисе дә калмаган! — дип кырт кистеләр.

Башым авырта, бармагым сызлый дип тә карады Тәнзилә, аны тыңламадылар. Ахыр чиктә ул иреннәрен кысты һәм катгый итеп:

— Барыгыз алайса! Сыер тизәге иснәргә ашыгасым юк әле. Барыгыз, куып җитәрмен,— диде. Аның кыяфәтенә: «Сез кушасыз, ә мин тыңламыйм. Мин беркемне дә тыңламыйм»,— дигән төс чыккан иде.

— Ярар, Шәмсеҗиһан апа,— диде аларны килештерергә теләп Бибинур,— безнең җәйләү ерак түгел. Тау башындагы ялгыз караманы күрәсезме? Әнә шуңа җиткәч тә, туп-туры түбәнгә төшәргә. Тәнзиләнең аягы авырта бугай. Чатанлап килүен бая ук сизгән идем. Бераз гына хәл алыйк булмаса.

Кояшта кызган ташларга тезелешеп утырдылар. Тәнзилә чуп-чуар, кәкре-бөкре язуларга тагын карады. Баягы җыр күзгә чалынды:

*«Былбыл булып, гөлгә кунып...»*

Кемнәр икән ул Галия белән Тәлгать? Нинди моң яисә нинди хәсрәт бу искиткеч җырны ташка чокытып яздырды икән аларга? Бәлки, балаларча шукланганнардыр алар? Нигә Тәнзиләнең гомерендә шундый минутлар булмады икән?! Сабан туеннан соң Балчыклы яшьләре дә урманнарга, аклан чирәменә китәләр иде бит. Нигә Тәнзилә болай йокымсырап яшәде икән? Ул бит шундый ташта гына булса да, үз исемен калдыра алмаган әле. Нигә? Бәлки, шәхси тормышында гына түгел, эшендә дә артык ваем-

сыздыр? Галия үз мәхәббәтен тапкан, Бибинурда мәхәббәт тә, дан да бар... Нигә боларның, берсе дә юк Тәнзиләдә?

Ул каш астыннан гына иптәшләренә карап алды. Бибинурның нәрсә уйлаганын белү кыен түгел: ул ярым елмаеп түбәнгә, зәңгәр рәшә дерелдәгән җирләргә карап тора. Шәмсеҗиһанның чырае кырыс, Зөбәрҗәт ашыгуын һичкемнән дә яшерми иде шикелле. Ул, авыр сулап, әле Бибинурга, әле Тәнзиләгә карап ала.

— Китәбезме?

Зөбәрҗәт, Тәнзиләнең күз карашы белән очрашуга, сикереп торды.

Байлар юлы белән байтак кына баргач, Тәнзилә борылып карады: соры ташлар әллә нинди сихри төсләргә кереп нидер ымлыйлар, аңа дәшәләр кебек тоелды. Ашыктырган өчен ул Зөбәрҗәткә ачулана иде. «Тәҗрибә алу дигән булып, укыганын сөйләр инде, әллә Тәнзилә Бибинур укыган китапларны гына укый алмасмы? Бибинурның да әллә ни кырганы күренми әле. Әйбәт болыннары, көтүлекләре булмаса, алырлар иде сөтне, пычагым. Шул инде, бер мактарга тотынсалар, егылганчы мактыйлар».

Бара-бара Тәнзилә үзенең көнләшүен, усал каенана кебек, юк сәбәпләрне бар итеп Бибинурдан гаеп-кыек эзләп баруын сизенде. Аның бөтен нәрсәне онытасы, кемгәдер сыенасы, иркәләнәсе килде. Тик кемгә сыенсын, кемгә иркәләнсен ул? Күңелендә кузгалган көнләшү корты тагын акрын гына кыймыл-кыймыл килергә тотынды.

## 6

Алар Бибинурга ияреп җәйләүгә килеп җиткәндә, «Көчле ирек»нең ферма мөдире белән Гайфулла да шунда барып чыкканнар иде. «Көчле ирек»нең ферма мөдире — таза гына гәүдәле, кара, үткен күзле, сыңар куллы Мөнәвир исемле ир уртасы кеше кунакларны тактадан гына ясалган булса да, шактый күркәм, дүрт тәрәзәле өйгә дәште. Үзе, калын мыекларын исән калган кулы белән сыпыра-сыпыра:

— Рәхим итегез, кадерле кунаклар, безнең штаб җәен менә шушында инде,— диде.

Эсседә йөреп бик арылган иде. Шәмсеҗиһан белән Зөбәрҗәт күләгәгә керү белән рәхәтләнеп киттеләр. Гайфулла, Тәнзиләнең төкселәнеп торуын яратмыйча, хуҗалар сизмәслек кенә итеп күз кысып алды. Шәмсеҗиһан:

— Нәбине күрмәдеңме? — дип сорады.
Гайфулла:
— Айры-чөйре йөрмик, дидем мин. Менә хәзер Нәбиеңне эзләп тап инде,— дип зарланырга кереште.
Сап-сары итеп кырып юылган өстәл тирәсенә утырыштылар. Мөнәвир шкафтан ике дәфтәр алды. Берсен Бибинурга бирде. Җыйнаулашып сөйләшә башладылар.
Сүз шактый озакка тартылды. Бибинур сыерларны ел буе ничек ашатуларын, ничек тәрбия итүләрен сөйләп чыкты. Шәмсеҗиһан сорашып торды. Зөбәрҗәт кирәк дип тапканнарын язып та алды. Байтак вакыт үтте. Нәби һаман күренмәде, Гайфулла тагын тузынды.
Районның төрле почмакларына таралган таныш-белешләре белән багланышны Нәби бервакытта да өзмәде. Якын-тирәдәге авылларда бер генә сабан туе да, көзге бәйрәмнәр дә Нәбисез узмаганга, аның һәр җирдә туганым апалары да, үз апамнары да, ерак җиңгиләре дә тулып ята иде.
«Көчле ирек»кә килгәч тә, ул үзен бер кунак кына итеп сизде. «Эшем кешеләре йөрсеннәр, оештырып алып килдем, күрсеннәр, ә мин үземчә булыйм әле»,— дип уйлады ул.
Авыл буш иде. Нәби арлы-бирле сугылды, ишеге ачык булгач, медпунктка барып керде. Фельдшер кыз да кырга ашыга икән. Ул, гафу үтенеп, ишекне бикләп китеп барды.
Нәби, ярылганчы алма ашарга ниятләп, колхоз бакчасына барырга уйлаган иде, бакчаның шактый ераклыгын хәтерләп, ул уеннан кире кайтты. Бу эсседә алма дип, җәһәннәм астына барып йөрмәс инде. Ахырда ул аргы урамдагы апаларына кагылырга булды.
Бибинур, кичке савымга кадәр калыгыз дип, бик каты үтенгәч, кунаклар калыр кебек тә булганнар иде, Гайфулланың кәҗәсе килде. Ул: «Менә сыерларыгызны гына карап киләбез, безнең дә кырык эшебез кырылып ята. Кылны кырыкка яра торган көннәребез»,— дип, кызларга карап куйды. «Калабыз дип авыз ачасы булмагыз, сезне дә сыерларыгыз көтә!» — дигән сүз иде бу. Шәмсеҗиһан аңлап ияген какты, Тәнзилә дәшмәде.
Утлауга барып эре сөякле, салмак хәрәкәтле чуар сыерларны карап кайттылар. Сыерлар яңа урылган арыш җирендәге билчән калдыклары белән шулкадәр мавыкканнар иде, кунакларга күтәрелеп тә карамадылар. Елкылдап торган нәсел үгезе генә нигәдер ятсынды, күзенең агын әйләндереп, һаваны иснәштереп Тәнзиләләр ягына сузылып торды.

Кайтышлый яңадан лагерьга кагылдылар. Анда шул ук рәхәт тынлык хөкем сөрә, кипкән печән һәм сөт исе килә иде. Өй күләгәсендә яңа чабылган үлән чемчекләп, такта арбага җиккән алаша тора. Бөрчек-бөрчек бизәкле ситсы күлмәк кигән, түгәрәк алъяпкыч бәйләгән чандыр гына карчык ат янына басып, бәләкәй учын кашы өстенә куеп, килүчеләргә җитди генә карап тора иде.

— Җамал әби! Тагын үзең киләсе иттеңмени? — дип кычкырды Бибинур аны күргәч.

Карчыкны үзенә таба юнәлгән Бибинурдан бигрәк кунаклар кызыксындырды, ахры. Ул җавап бирмәде, иң элек:

— Кунакларың кайсы якныкы? — дип сорады. Аннан соң гына: — Бер дә киләсе түгел идем, эше дә муеннан. Теге Нурулла сөтле ашны бик ярата. Бүген сөтле аш пешерермен дип әйтеп җибәргән идем. Кайната башласам, эреде дә китте. Килми хәлем калмады,— диде.

Җамал әби интернатта яшәүче механизаторларга ашсу пешерүче икән. Лагерь янындагы подвалдан сөт чыгарган арада, ул Тәнзилә янына килеп сораша башлады.

Тәнзиләнең сөйләшәсе килми иде. Ул бер-ике авыз сүз белән карчыктан котылмакчы булып, кыска-кыска гына итеп җавап биргәләде дә читкәрәк китте. Тик карчыклардан алай тиз ычкынып буламыни? Җамал Шәмсеҗиһан янына барды. Алар бик тиз уртак тел таптылар, авыл, тирә-юнь яңалыкларын бик тиз бер-берсенә бушатырга тотындылар.

Җамал Балчыклыда үзенең ерак кардәше булуын, аның сугышта үлеп калганын, хатыны, бала-чагалары исәнлеген, тик алар белән йөрешә алмауларын сөйләде. Тәнзиләнең шул ерак кардәше Гарәфи кызы икәнлеген белгәч, Җамал ни өчен килүен дә онытып, тәмләп, тәфсилләп сорашырга кереште. Килмәүләре өчен үпкәләде. Инде килеп кермичә китүләре өчен бөтенләй әрләп ташлады.

— Килгәнсең, бик әйбәт булган. Инде берне кунмыйча җибәрмим! Юк-юк! Үлгәч тә кырык көнлек эш кала! Мөдирең белән дә үзем сөйләшәм, бер кичтән әллә ни булмас әле. Әткәң мәрхүмне искә төшереп сөйләшеп утырырбыз,— диде ул. Тәнзилә аның янына кермичә китмәскә вәгъдә биргәч кенә, Җамал арбасына менеп утырды, ике куллап дилбегәгә чытырдап ябышты һәм кипшергән иреннәрен очлайтып:

— Нө-ө! — дип алашаны куа башлады.

Тәнзиләнең хәтеренә кайчандыр әнисе сөйләгән сүзләр төште. «Көчле ирек»тә апаңнар бар дигән иде бугай ул. Тик нигә китәр алдыннан бер сүз дә әйтмәде соң әле ул?

Мәгъмүрә апа исә Тәнзиләнең кичәге сүзләреннән айнып җитә алмаганга, хәтере чуалып, Җамал карчык турында бөтенләй онытып җибәргән иде.

Мөнәвиргә бик зур рәхмәт әйттеләр. Ул: «Тагын килегез. Менә кышның көне кыскарак булса да, иркенрәк чак була. Куна-нитә ятарсыз»,— дип озатып калды.

Кайтышлый сүз әллә ни куермады. Күргән нәрсәләр хәтсез күп, ишеткәннәр шактый катлаулы булып, аларны хәтер сандыгына салу өчен яңа килеш барлап куярга кирәк иде. Шәмсеҗиһан гына тынмады. Ул бара-бара да әле башын чайкый, әле телен шартлатып ала:

— Һе, бакчы ничек, ә!

Аның кыланышы Тәнзиләнең ачуын китерә башлады. Ул башта Бибинурдан уңайсызланып дәшми барды. Түзде-түзде дә чыдамы бетте:

— Бер дә күкләргә сикерер җирләре юк инде анысы, Шәмсеҗиһан апа!

Тәнзилә бу сүзләрне Бибинурга төрттеребрәк әйткән иде, аның бер дә исе китмәде:

— Яле алайса, сөйләп җибәр. Нәрсәбез начар безнең?

— Начар түгел, бик әйбәт сездә. Тик мондагы кебек шартлар тудырылса, теләсә кем рекорд бирә ала. Әллә мин дүрт мең литр сөт алмас идемме?

— Кояштыр алмас идең! — диде Шәмсеҗиһан.

— Фи-и! Ние бар аның?

— Әнә шул «ние» бар шул. Синең белән мин шул «ниен» тапмаганга чиләнеп ятабыз, мең ярым белән ияк сыпырып калабыз. Ние булмаса, син дә, мин дә, Мөхәммәтәмин дә савар иде аны!

Тәнзиләнең кызарынып-бүртенеп баруыннан Бибинур рәхәтләнеп көлеп җибәрде:

— Әйдә, сынап карыйбыз, Тәнзилә! Минем белән ярышка чыгасыңмы?

Тәнзилә беравык дәшми барды.

— Чыкмыйм. Безнең колхоз болай да адәм көлкесенә калган, инде синең белән дә ярышам дип бөтенләйгә хур буласы килми.

Гайфулла, машинаны кабыза торырбыз дип, алданрак киткән иде. Ул Тәнзиләнең бу сүзләрен ишетсә, ни эшләр иде икән, анысын әйтүе кыен, әмма тын гына кайткан Шәмсеҗиһан белән Зөбәрҗәткә җитә калды. Ничек адәм көлкесе?! Уйнап сөйләшәме, уйлапмы Тәнзилә бүген?

Тәнзилә күп сүзләрне кузгатса да, үзе бәхәскә катышмады. Сөйләгез әйдә, сөйләгез, дигәндәй, кулын гына селкеде. Үзе: «Их, мөмкинлекләр булсын иде дә,

күрсәтәсе иде сөтне ничек саварга кирәклеген!» — дип уйлап куйды.

Аның бармаклары кымырҗып китте.

Ләкин ул ашкыну озакка бармады. Зур топольләргә күмелгән авыл урамына барып кергәч, баганаларда электр лампалары күргәч, тагын Балчыклының калын тузан каплаган урамнары, салам түбәле фермалары хәтергә төште. Тагын үз авылы фәкыйрь, кешеләре мескен, хәлләре мөшкел булып тоелды Тәнзиләгә.

Кызлар кайтып җиткәндә, иптәшләре барысы да машина янына җыйналган иде. Чирәм өстендә керт-керт итеп, вак-вак кабып, ямь-яшел дәү кыяр ашап утырган Нәбине Гайфулла пыр туздырып орыша иде.

Бибинурларга кереп, кәрәзле бал белән чәй эчеп чыктылар. Алма белән сыйландылар. Бибинур, күчтәнәч булыр дип, иң эреләрен генә сайлап, бер бәләкәй капчыкка алма да тутырып бирде.

Кузгалабыз гына дигәндә, кызлар Җамалның үтенүен искә төшерделәр. Тәнзилә вәгъдәсен онытмаган булса да, Гайфулладан читенсенеп, үзе сүз кузгатырга кыймый тора иде. Кызлар башлап җибәргәч, ул калырга рөхсәт сорады.

— Каласың килә икән, кал, сыерларыңны үзебез карарбыз,— диделәр Зөбәрҗәт белән Шәмсеҗиһан беравыздан. Теләр-теләмәс кенә Гайфулла да ризалык бирде.

— Утырмага калдырмыйбыз, иртәгә иртүк кайтып җиткән бул, ишетсен колагың,— дип ныгытты ул.

Машина тирәсенә малай-шалай җыелды. Идарәдән хисапчы, тагын берничә кеше чыгып, озату беркадәр тантаналырак төс алды.

Зөбәрҗәт Бибинурны кунакка чакырды:

— Кил, яме, Бибинур!

— Килермен, үзегез дә безне онытмагыз!

Интернат дигәннәре өч бүлмәле, зур-зур тәрәзәле, бакча эчендә утырган агач йорт булып чыкты. Ике бүлмәсендә механизаторлар — комбайнчылар, тракторчылар тора икән. Өченче бүлмәгә Җамал карчык урнашкан. Бибинур Тәнзиләне шунда озатып куйды.

Җамал карчыкның үз йорты аргы очта ук булганга, ул монда куна-ята тора иде. Кайбер көннәрне генә карты Сәхәп тузынып килеп, аны кунарга алып киткәли. Ә болай күбрәк вакыты интернатта үтә. Аш пешерә, кер юа. Суны мәктәп балалары ташып бирә. Аларның берничәсе шушында, мәктәп бакчасында, даими кизү торалар икән. Кура җиләге җыялар, карлыган, чия. Алма юк, агачлары әле үсеп кенә килә.

Бераз бөкрәйгән гәүдәле булса да, күрер күзгә шактый таза Җамал карчык Тәнзиләнең килүенә бик куанып, боларны бик тәмләп, ваклыклары белән сөйләп чыкты. Шул арада ул әллә никадәр эш эшләп алды. Почмакта зур кисмәктә торган гөлгә су сипте. Агач бадьянга өстендә майлары йөзеп йөргән тәмле исле кәбестә ашы салып, Тәнзиләне ашарга кыстады. Яңа гына чәй эчкән булса да, Тәнзилә ашны ялт иттерде. Өйләрендә кәбестә ашы пешермиләр иде алар.

Карчык, электр лампочкасын кабызып, җиң очларын кайтара-кайтара Тәнзилә янына килеп утырды. Хәл-әхвәл сорашты.

Башта кыяр-кыймасрак утырган Тәнзиләнең теле ачылып китте. Ул бөтен булган зарларын, фермаларының әшәкелеген, председательләре Бикбулатның аны станциягә җибәрмәвен, җае чыкса, колхоздан китәргә дә уе барлыгын сөйләде. Җамал әбисенең аны бүлдермичә генә тыңлавы, аны хуплаган сыман ияк кагып куюлары Тәнзиләнең күңелен җиңеләйтеп җибәрде.

— Алай икән, алай икән. Менә бармагач-күрмәгәч, белешмичә дә ятабыз бит. Хәлләрегез бик үк шәптән түгел икән шул. Безнең авылны ошаттыңмы соң?

Кинәт бирелгән бу сорауга Тәнзилә кыска гына җавап бирде:

— Бик.

— Алай икән,— диде карчык яңадан. Ул, нәрсәдер әйтергә теләп тә базмыйчарак торган кеше сыман, бер Тәнзиләгә, бер кичке караңгылык иңеп барган тәрәзәләргә карады.

— Кызым, әллә бөтенләйгә бездә генә каласыңмы?

— Ничек сездә?

— Безнең колхозда, дим. Авылыбыз бик әйбәт безнең. Кешеләре дә бик ару. Үзең күргәнсеңдер инде. Башка авыллардан килеп төпләнүчеләр күп булды инде бездә. Сыер савучыларга урын табылыр иде әле. Председатель белән үзем сөйләшеп карармын. Каласыңмы?

Җамал, Тәнзиләнең икеләнүен күреп, кыстарга, үгетләргә, кызыктырырга кереште:

— Ошаса, үзебездә торырсың. Безнең бер улыбыз — төпчегебез генә яныбызда. Менә монда интернатта торырга да була. Яратмасаң, фатирга чыгарсың, барыбер китәм дисең бит.

Чыннан да, әллә тәвәккәлләргәме? Тик бигрәк кинәт була түгелме соң бу? Тәвәккәлләгән — таш йоткан, диләр диюен! Җае чыкканда... Балчыклыга кендегебереркмәгән ич аның. Китәм дип тә уйлагач... Бәлки, бәхете шушын-

дадыр? Әнкәсе, ул читне күргәнең бармы соң, дип сораган иде. Менә күрде ич, ошады. Бер ияләнгән эш тә булса. Төпләнеп калса, әнкәсен дә монда алдырыр. Алманы бик ярата бит. Ә монда колхоз хезмәт көненә алма да өләшә икән. Бикбулатның авызы чалышаер иде. Менә шунда Бибинур белән дә ярышып күрсәтер иде ул. Әллә йөрәкләнергәме?..

Ул арада бакча ягында ниндидер шау-шу купты. Җамал карчык сикереп торды, каударланып ишекле-түрле йөреп алды:

— Ай Аллам, тагын Латыйплар кәҗәседер инде. Корытты инде бакчабызны,ләгыйнь!

Тәнзилә, Җамалга ияреп, ишегалдына чыкты.

Шомырт агачлары арасында алама, мүкләк кәҗә күренде. Аның артыннан ук яланаяк, күлмәкчән генә ике малай элдерәләр иде. Агачлыктан:

— Мин күрмәсәм, әллә кунарга каласы тагын! Бакча корыткыч! Сез дә, шәп егетләр, шуны күрмәгәнсез,— дигән сүзләр ишетелде.

— Ә-ә, Бибисара! Ярый, ул күргән икән әле мур кыргырын,— диде Җамал карчык һәм, Тәнзиләгә борылып: — Син безнең Бибисараны беләсеңме? Ул үрдәкләр карый,— диде.

— Юк, белмим.

— Берүк ялгышып аңа әби диеп дәшә күрмә. Сара апа гына диген. Кич утырырга килә ул безгә.

Кәҗә «үзенә кирәкне» алды, ахры. Тыкрыктан бик әче итеп мәэлдәгән аваз килде. Бибисара:

— Койрыгын кыл белән буарга кирәк ул явызның. Латыйпны әйтер идем, ир башы белән кәҗә асрамаса,— дип кычкыра иде.

Ниһаять, барысы да тынды. Бибисара Тәнзиләләр янына килде. Өчәүләшеп өйгә керделәр. Җамал:

— Аш ашыйсыңмы, Бибисара? — дип сорады.— Бик тәмле кәбестә ашы пешергән идем.

— Ашамыйм, кәбестә ашы эчне авырттыра. Токмачың булса, әллә берәр тәлинкәсен чамалаган булыр идем.

— Юк шул,— диде өзгәләнеп Җамал.— Алайса менә бик тәмләп кенә чәй эчәрбез. Хәзер кайнап чыга.

Тәнзилә, шундый зур җәфалар күргән кеше бик карттыр, таушалгандыр дип уйласа, Бибисара әле шактый нык күренә иде.

Җамал Бибисараның бүлмәдәге чит кешене бөтенләй күрмәмешкә салышуын яратмады.

— Менә, Бибисара, бу Тәнзилә була инде. Безнең кардәш тиешле кыз.

— Ә-ә, алаймыни әле? Мин бер-бер юлаучымы әллә дип торам. Шәһәрдән килдеңме?
— Юк, авылдан...
— Кайсы авылдан?
— Балчыклыдан.
— Ә-ә, күл буенда сез йөргәнсез икән инде алайса.
— Йөргән идек шул.
— Нигә килдегез соң сез?
— Танышырга, тәҗрибә алырга.
— Таныштыгызмы соң?
— Таныштык.
— Сара апагызны күрдегезме?
— Күрмәдек.
— Танышу шулай буламыни? Их сез, кычыткан чыпчыклары, йөргәнсездер инде юкны бушка авыштырып. Кем күрсәтеп йөрде?
— Бибинур.
— Ә, алайса ярый. Төпле кыз.
Мич янында самовар җырлый, күрше бүлмәдән радио тавышы ишетелә башлады. Бибисара озак кына бер ноктага текәлеп дәшми утырды. Колагы янындагы усал төк белән капланган чикләвек дәүлеге миңе генә селкенгәләп куя иде.
— Ә син? — дип сорады ул, ялт итеп Тәнзиләгә таба борылып.
— Менә кунакка килдем әле, Җамал апа...
— Кунак буласың килде алайса? Ярый, ярый!..
Сүзгә Җамал катышып китте. Ул Бибисараның кәефен табарга теләгәндәй тәмләп, сузып-сузып сөйли башлады:
— Бер киңәш бар әле монда, Бибисара. Тәнзиләне әллә үзебездә генә каласыңмы дип димлим.
— Ничек үзебездә?
— Балчыклыда хәлләре бик мөшкел икән аларның.
— Ә безнең хәлләр аңа ошаганмы?
Бибисара соңгы сорауны Тәнзиләгә карап әйткәч, ул җавап бирде:
— Сездә әйбәт, миңа бик ошады,— диде Тәнзилә, ни әйтергә белмичә. Хисләрең әле урынына утырмаганда, мәсьәлә әле үзең өчен дә бик ачык булмаганда, кешегә аңлату кыен шул.
— Сездә начар инде? — диде тынарга исәбе булмаган Бибисара.
— Начар булмый ни, фермаларыбыз хан заманыннан калган иске, салам түбәле. Сезнең терлекчеләр өе оҗмах кебек, ә безнекеннән куркып качарсың. Миче агартыл-

маган, тәрәзәсеннән җил өрә. Колхоз председателенең ике ятып бер төшенә дә керми.

— Җил өрә, ә? — Бибисара тагын дәшми торды.— Шуның өчен китәргә булдыңмы?

— Аның өчен генә дип түгел... Әле китүем дә...

Их бу Җамал әбине! Нигә телен тыймаган инде. Үзләре сөйләшкән, киңәшкән генә җитмәгән, чит кешене дә арага китереп кыстырды. Тәнзилә бөтенләй югалып калды. Бибисараның яңа сораулар әзерләгәне күренеп тора. Сөйләгәндә аның сул кашы сикереп-сикереп китә, күзләре ялтырый.

— Син боларны райкомга барып сөйләгәнсеңдер, шәт? Председателегез шуңа сине яратмагандыр.

— Юк, сөйләмәдем. Председательнең алай кубарылып бер сүз дә әйткәне юк.

— Синең әйткәнең бармы соң? Председательгә дим?

— Юк, әйткәнем юк.

Тәнзилә сорауларның күплегеннән гаҗиз булып, үз җавапларының бик беркатлы икәнлеген аермый башлады. Ул Бибисараның тел төбендә нәрсә ятканын сизде.

— Сөйләшмәдем дисең инде?

— Ниен сөйлисең аның? Ни файда? Иптәш кызларым җыелышларда әйтеп карадылар, стенага борчак сипкән кебек кенә.

Бибисара, җәһәт кенә, Тәнзиләгә борылды:

— Ә син койрыгыңны кыстыңмы? Комсомол башың белән әнә значогың таккансың ич... Ничек намусың җитеп үз колхозыңны чуттан чыгарып утырасың син? Ничек качарга йөрәгең җитә синең?!

— Мин качмадым...

Җамал нишләргә дә белмәде, аның тизрәк бу гауганы бетерәсе килә иде. Ул Бибисараның әле бер ягына, әле икенче ягына чыкты:

— Ай Аллам, Бибисара, куйчы, менә чәең суына. Әле бит китәм дигән сүзе юк, киңәш-табыш итешү генә...

— Юк, Җамал, син куй димә әле. Нигә без колхоздан качмадык икән заманында? Колхозга керсәң, кафер буласың, иманың бугазыңа аркылы килә, диләр иде безгә. Чаттан торып саклыйлар, аталар иде. Арык ат, агач тырма, бер тәрәнле сабан белән җир ертып интеккәндә, нигә качмадык икән без? Кая ул фермалар, урта мәктәпләр, клублар. Нигә болай бозылды яшьләр? Без бит, яшьләр менә бу ефәк күлмәкләрне кисен, әйбәт туфлиләрдән йөрсен, тормыш яхшырсын дип тырыштык. Кан койдык.

Бибисараның тавышы кинәт йомшарды, ул, укынган кебек чал чәчле башын селкә-селкә, беравык сүзсез калды.

Тәнзилә бу газаплы минутларның тизрәк үтеп китүен теләде. Ул, үзенең дәлилләренең бу карчык сүзләре алдында бик көчсез, зәгыйфь икәнлеген сизеп, дәшми утырды. Аннары карт кешенең акылы да инде аның. Әле кызарлык, тузынырлык берни дә булмаган ич! Менә Җамал әби дә кеше ләбаса, ул бер дә тузынмады, әйбәт кенә тыңлады, хәтта калырга киңәш бирде. Тәнзиләнең башына да килмәс иде әле бу фикер.

Бибисара яңадан кабынды:

— «Көчле ирек» колхозында эшләр һәрвакыт ал да гөл булды дип уйлыйсыңмы? Алайса, ни шайтаныма тәҗрибә алырга дип сине монда җибәрделәр?! Сугыштан соң килеп кара идең син монда. Фермада тездән саз. Атлар булмагач, өч-дүрт ел тирес чыгарылмаган. Сөт түгел, чуртым да юк иде. Әгәр шунда барысы да качып киткән булсалар. Качучылар да булды...

Җамал да, Бибисараны җөпләп, ияк кагып утыра башлады.

— Хәтерлисеңме, Җамал, минем тавыкларым читәнчыбыктан үргән бер кетәктә яшиләр иде. Шул чакта райкомнан берәү килеп төште. «Апа, сез тавыклар карыйсызмы?» — ди. «Юк, мин әйтәм, карамыйм, карасаң да күреп булмый аларны. Кетәкнең тәрәзәсе юк, ишеге юк». Без качмадык. Күңелебезгә дә кереп карамады ул уй. Әкренләп барын да үзебез төзәттек, үзебез булдырдык. Әзергә бәзер генә килеп утырырга барың да оста!

— Әйе, әйе, хәлебез бик мөшкел иде ул чагында.

Барысы да тын калдылар. Бибисара китәргә җыенды. Җамал никадәр генә кыстаса да, чәй эчәргә калмады. Саубуллашмыйча гына, кемгәдер рәнҗегән төс белән, авыр-авыр атлап чыгып китте.

Тәнзиләнең иң кыен имтиханнарны биргәндә дә болай таушалганы юк иде. Ул, сулкылдаган чигәләрен кысып, Җамал әбисе күрсәткән урынга барып ятты. Тәмле көн исе килеп торган одеялны иягенә кадәр тартып, күзләрен йомды. Башы әйләнә иде аның. Борчылулы уйлар аның арыган тәнен һаман тормыш ыгы-зыгысы дулкыннарында тирбәтәләр. Әйе, тормыш менә шундый икән ул. Кемнәрдер синнән җавап таләп итәләр, кызалар, синең өчен дә чын күңелдән борчылалар икән.

Бибисараны озаткач, песи кебек йомшак кына басып, Җамал әби кире керде. Мич тирәсендә кайнашты. Озак кына итеп ипи кисте. Тәрәзә янына барып тыңлап торды. Сәгатькә карады.

Тәнзиләнең йокламаганын белә ич, нигә бер сүз дә дәшми?

Бакчада эт өрде. Кемнәрдер мыдыр-мыдыр сөйләшеп

алдылар. Ишек шыгырдады. Күрше бүлмәгә берьюлы икеөч ир кеше килеп керде. Җамал алар янына чыкты.

Тәнзилә аз гына йокымсырап китте, ахрысы. Ул карчыкның аш бүлүен дә, ипине, самоварны алып чыгып китүен дә сизми калды.

Теге якта кашык-тәлинкә шалтыравы ишетелде. Ишек ябылып ук бетмәгән иде. Кайтучыларның калын гына тавышлысы нидер сөйли дә, калган ике тавыш озак итеп, рәхәтләнеп көләләр:

— Койрыгын кыл белән буыгыз, диме?

— Бибисара әйтер ул.

— Кем кәҗәсе соң ул, Җамал апа?

— Булды инде бер җәфа авылыбызга. Качак Латыйп дигән кешене беләсезме? Тыкрык буендагы бәләкәй өйдә торалар. Шул юньсезнең мур кыргырысы инде.

— Кәҗәсе дә хуҗасына охшаган икән!

Бу юлы Җамал карчык рәхәтләнеп көлеп җибәрде.

— Сезнең авылда кушаматлар бетмәгән икән әле,— диде калын тавыш.

— Соңгы елларда бер кешегә дә кушамат такмыйлар инде тагуын, бу Латыйп белән әллә нәрсә булды инде менә. Ходайның хикмәте дигәндәй, бик әшәке кушамат ябыштырып куйдылар үзенә.

— Нигә качак дип атадылар соң аны? — диде яшь тавыш.

Җамал карчык бераз уйланып торды.

— Юньсез кеше булып чыкты ла ул Латыйп. Сугыш беткәч, ир-ат колхозда бик кадерле чакта, авылыбызны ташлады да качты ул. Өен сатты, сыеры бар иде, анысын суйды. Имеш, авылдагы нигезен бетереп мәңгегә китә. Китмәгән кая! Бер заман әйләнеп кайтмасынмы Латыйбың! Ялыныпмы-ялынып колхозга алуны сорый, ата-бабасын исенә төшергән. Беләбез инде кемне исенә төшергәнен. Ул елны һәркем олау-олау икмәк, учы-учы белән акча алган иде. Каян ишеткәндер, кайтып та җиткән качкының. Нишлисең, колхозга алдылар. Нигезен бирделәр. Кечкенә булса да, өй торгыздылар. Менә ару гына эшләп маташа. Тик качак дигән кушаматы гына калды.

Калын тавышлы тагын нидер әйтте. Өчәүләшеп бүлмәне яңгыратып көлеп җибәрделәр. Җамал карчыкның:

— Чү, оланнар, артык каты көлмәгез, минем якта кунак кыз йоклый,— дигәне ишетелде.

Яшь тавыш:

— Нинди кыз ул, әби? — дип сорады.

Тәнзилә, сагаеп, урыныннан күтәрелә төште. Җамал

карчык нигәдер ашыкмады, бүлмә ягыннан кашык-тәлинкә тавышлары гына килеп торды.

— Ул ни... бер кыз инде. Балчыклыдан. Безгә туган тиешлерәк була. Монда танышырга килгәннәр. Колхозыбызның эше рәтсез, ди. Китәргә йөри икән.

— Теге Латыйп кебек качыпмы? — дип сорады яшь тавыш.

Тәнзилә одеялын атып бәрде. Сикереп торып караватына утырды. Башка сүзләр ишетелмәде, кайсыдыр ишекне кысып куйды. Бүлмәдән шаркылдап көлгән тавышлар гына килде. Җамал әби Тәнзиләнең гайбәтен сата, ахры. Менә ничек! Качып бөтен авылга хурлыклы даны таралган алама кәҗәле Латыйп кебек. Ул кыен вакытта авылдашларын, ата-бабасының нигезен ташлап киткән. Иртәгә үк бөтен кеше шушы хурлыклы исем белән Тәнзиләне атый башласа? Ни өчен? Кемгә начарлыгы тиде аның? Ул бит үзенең эш күрсәтә алуын, булдыра алуын гына расларга тели.

Ә теге бүлмәдә һаман көләләр. Тәнзилә берәр җинаять эшләгәнме әллә? Хаталык кылганмы? Латыйп та, аның кебек, колхозларын сүгеп зарланып йөргәндер. Бибисара апа аның белән бер табынга утырып чәй дә эчмәде бит. Чыннан да... Күперне төзәтмәгән өчен Лотфулланы үзе дә сүккән иде бит. Ә үзе... Бибисара дөрес сөйли түгелме соң? Йокымсырап дәшми яшәү, риза булып тору ни дигән сүз ул?.. Яхшы тормыш өчен көрәшергә, аны төзү өчен җаныңны аямаска дип укытканнар иде бит аны мәктәптә... Төзедеме ул?.. Көрәштеме? Ә ул Бибинурлардан кимме әллә?! Тырышса, Балчыклыны да рәткә салып була торгандыр ич. Шәмсеҗиһаннар ничек кайтып җитте икән? Тәнзилә ике көн инде сыерлары янында булмады. Мүкләге берәүгә дә баш бирми иде, сөтен төшерә микән?

Нигә монда ята соң әле ул?

Бераздан интернат тәрәзәсе тавышсыз гына ачылды, бакчага бер күләгә сикерде. Эт өрде. Күләгә бакчалар артыннан олы юлга таба чыгып китте.

Бераздан Җамал карчык керде. Караватка күз салды, тәрәзәгә. Дәшмәде, елмайды гына. Идәндәге гөл чүлмәген кире тәрәзә төбенә куйыйм дип үрелсә, исе китте:

— Сөбханалла, төн гөле чәчәк аткан!

*1959, Казан*

# Дуртәү

1944 елның көзе иде.

Көзге кыр эшләре башлану белән үк бозылган һаваның рәтсезлеге бик озакка тартылды. Атна буе пыскаклап яуган яңгырлар, әрле-бирле үтеп торган атлылар безнең кечкенә генә авыл урамын чупырдаган әшәке сазлыкка әйләндерделәр.

Көнбатышта каты сугышлар бара. Дошманны тәмам кыйнап бетерү өчен фронт һәм дәүләт бездән икмәк таләп итә. Ә монда атлар кырылган, кешеләр җитми, шуның өстәвенә елак көз иген-таруны бердәм генә җыеп алырга ирек бирми. Көн дә эштә кешеләр, төн дә...

Кичләрен авыл урамнары бигрәк тә күңелсез була. Көне буе әвен сугып, сушилкаларда ашлык болгатып арган кешеләр, эштән кайтуга ук, карават, сәкеләргә ташланалар да, болай да буш авыл тагын да шыксызрак булып кала. Ләкин озаккамы?!

Менә тәрәзә каккан тавыш килә:

— Мәрфугаттәй! Әү! Мәрфугаттәй! Ындырдагы тары көшеле кыза башлаган.

Шакучы — кулсыз Фәхри абый, бригадир, артык бер сүз дә дәшми. Юаш кына лептердәгән яңгыр тавышы астында да аның сак колагы сәке шыгырдаганын ишетеп кала. Сугышта разведчик булып йөргән кешегә күп кирәкме әллә, Фәхри абыйга шул җиткән. Аннары Мәрфугаттәйнең дәшмәячәген дә ачык белә ул. Һәм Фәхри абый, күрше йортларга китеп, бердәй пошаманлык белән йокымсыраган ямаулы тәрәзәләргә хәвефле хәбәрне сала башлый.

Тары көшеле — ул уен түгел.

Мәрфугаттәй дә, башкалар да моны бик яхшы беләләр. Бер кыза башласа, янып китәргә дә күп сорамый ул.

Тәрәзәләрдә тычкан уты кебек кенә чепи күзле сукыр лампалар җемелди башлый. Киптерергә дип салкын мич алдына элеп куйган оеклар, юеш күлмәкләр киелә.

Кемнәрдер мыдыр-мыдыр сөйләшеп алалар, комганнар шылтырый. Кешеләр йокысызлыктан сызлаган чигәләрен салкын су белән чылаталар да, авыр гына атлап, урамга чыгалар. Алар күп түгел, бу өйдән берәү, тегеннән икәү. Күпер төбе Сәрвәр апа гына, өч кызын ияртеп, кечкенә төркем булып чыга.

Безнең бәләкәй авыл урамын җанландырырга шул да җитә. Ләкин ул җанлылык ничектер моңлы, хәсрәтле. Шуны сизептерме, кешеләр бер-берсенә дәшмиләр. Бары тик авылның аргы очында Фәхри абыйның карлыккан һәм бераз шөбһәле тавыш белән:

— Гыйльмениса! Әү-ү! — дип кычкыруы ишетелә. Ә бу очта урам сазы, шактый күп чабаталар астында калып, лач-лоч килә.

Хатыннар атлыйлар, дәшмиләр. Ни әйтсеннәр? Юеш бишмәтләрдән, сырмалардан саз исе, күл исе килә. Итәкләрдән, нәзек җепләр булып, су тама.

Авыл башындагы зират өстендә ак каеннар акрын гына еламсырыйлар. Ике ел инде бу зиратка ир затыннан бер кешенең дә күмелгәне юк. Ә шушы ике ел эчендә күпме хатыннар тол, күпме яшь кызлар ярсыз, күпме карчыклар йокысыз һәм улсыз калдылар. Зират янында төркем тыгызлана, чирәмгә чыккач, атлап бару да бераз җиңеләеп киткән кебек була. Юл буенда котырып үскән әрсез тигәнәкләр генә арзанлы ситсыдан тегелгән, кояш һәм яңгыр астында уңып, сизерәп беткән күлмәк итәкләреннән эләктереп, җеп кисәкләре йолкып калырга тырышалар.

Ындырда тары яна...

Телем-телем телгәләнгән күлмәк итәкләре шуңа күрә җәһәтрәк җилфердиләр. Арык атлар белән җир тырмап чәчеп, сугыш елларында әрсезләнеп киткән әрем-билчәннәр, шайтан таяклары белән куллар канланганчы, тырнаклар купканчы сугыша-сугыша саклап калган, ниһаять, бөртекләп, кадерләп җыйган тары бит ул. Инде урылгач, сугылгач, дәүләт келәтләренә керә дип торганда гына мондый күңелсез хәл кешеләрне тетрәтеп җибәрде.

Шуның өчен әнкәйнең берсүзсез җыенуына да, төн уртасында чыгып баруына да гаҗәпләнмәдем. Йокыга китәргә өлгермәгән идем әле. Көне буе көлтә ташыганга билем сызлый, кендегем, каядыр, култык астына шуышып күчкән кебек тоела иде. Әнкәй чыгып киткәч торып утырдым, юеш тәрәзәгә маңгаемны терәп, аның ишегалдыннан үтеп китүен күрергә тырыштым. Күренмәде. Яңгырда бөрешеп беткән, ышыкланырга дип өй нигезенә сыенган кәҗә бәтиенең ябык, дерелдәгән гәүдәсе

генә күземә чалынды. Олы кәҗәбезне күптән түгел генә саткан идек. Әнисе бар чакта алар икәүләп өйалды астына кереп йоклыйлар иде. Үзе генә калгач керми, әллә курка, әллә нәрсә. Төн йокысын бүлеп чыгып киткән энкәм белән шушы бәти арасында ниндидер бер охшашлык тоеп, мин аларның икесен дә бик кызгандым.

Каралты түбәсен кышын яккан идек, әле яңадан ябарга чират та тигәне юк, салам да таба алмыйбыз. Көзе болай елак торса, яба алмый да калырсың әле, саламың кырда ук череп бетәр. Шуларны уйлап, хәсрәтләнеп, торып ук бастым.

Кәҗә бәтие кызганыч аваз белән мәэлдәп куйды. Яңгыр астыннан бер карамчык чыгып тәрәзәгә якынайды. Суланып бүрткән рамнарны ике куллап этә торгач, тәрәзәне ачып җибәрдем.

— Ә, син йокламыйсың да икән...

Килүче Фәхри абый иде. Ул сакал баскан бәләкәй йөзен тәрәзәгә суза, ияген тәрәзә төбенә терәп, дәшмитынмый озак кына карап тора.

— Юк әле, йокламадым. Менә, энкәйне озаттым.

Мин дә башка сүз әйтмим. Бу сүзсезлекнең юкка гына түгеллеген аңлыйм, ни әйтер икән дип, Фәхри абыйга карап торам. Ниһаять, түзмим:

— Ничек сала... Күкнең төбе тишелгән, ахры,— дим.

Фәхри абый дөм караңгы күккә борыла, нидер күргән сыман башын чайкый:

— Сала салуын, тик озакка бармас инде! Туктар. Моннан бер ун еллар элек нәкъ шушындый хәл булган иде. И яуды, и яуды, күперләрне агызды, буаларны ерды. Кар базларына су тулып бетте, коеларга бау-мазар кирәкми башлады: иел дә чумырып кына ал. Яуды, яуды да торабара аязды тагын. Шундый матур көз килде соңыннан, мин сиңа әйтим, уҗым өстендә әңгерә шалкан чәчәк атты, умартачылар, яңадан рамнар куеп, бал суырттылар. Чын, валлаһи шулай булды. Быел да аязыр, энекәш. Менә тәннәрем җиңеләеп, сөякләрем нығып киткән кебек күренә.

Мин, тәрәзә кашагасына сөялеп, Фәхри абзыйның эчкә баткан күзләренә, чәбәләнгән сакалына карап торам. Тавышы күтәренке булса да, йөзе сүрән, арган. Үзе нигәдер мине дәртләндерергә теләп сөйли дә сөйли. Әллә көне буе йомып йөргән авызы сөйләшүне сагынганмы? Кинәт Фәхри абыйның тавышы ерагайганнан-ерагая башлый, күз кабакларым авыраеп йомылалар, аякларым йомшара...

Бригадирның буылып-буылып йөткергәне генә мине сискәндереп, уятып җибәрә:

— Сезгә дә юлга чыгу яхшы булмас идеме икән?

Шулчак Фәхри абыйны кызганып куйдым. Ул, үзенә хас ныклык белән, безне, һичшиксез, юлга чыгарырга дип килгән инде, ә үзе киңәш иткән кебек кенә әйтеп алды. Мин рәхимсез караңгылыкка текәлеп беравык дәшми торам. Аның «юлга чыгарга» дигән сүзе күңелгә үк барып җитмәгән әле, бимазалап, колак төбендә генә чыңлый. Авыр, газаплы юлга чыгу күңелне куркытканга, аны күз алдына китермәскә тырышу балалык булгандыр инде.

— Кайчан чыгарга?

Фәхри абыйның чырае аз гына яктырып киткәндәй булды.

— Хәзер үк дип торам. Иртәгә кичке якка барып җитә алсагыз, шәп булыр иде. Бу бишкөнлектә юньләп җибәрә алганыбыз да юк. Безгә моның өчен рәхмәт әйтмәсләр. Атлар да хәл алды, яңгыр да туктар сыман. Сушилкадан дүрт йөк төясәгез, тарыга да урын бушар иде. Кыза бит, әрәм була.

— Көндез үк җылына башлаган иде инде,— дидем мин.

— Йә, ярар алайса, энекәш,— диде Фәхри абый,— мин сушилкага киттем. Арба өстенә ябарга кабыкларыңны алырга онытма.

Өзлексез тыпырдап, биеп торган яңгыр тавышы Фәхри абыйның аяк чупырдатуын бик тиз ишеттермәс итә. Авылның хәсрәтен, моңын, фәкыйрьлеген яшереп торган төн эченә кереп киткән бу тынгысыз, әйбәт кешегә карата минем йөрәгемдә бер сызлану ишетелә. Көннетөнне, сәгатьләрне-минутларны күптән оныткан, һәрбер кешегә олы йөрәгеннән татлы сүз, акыллы киңәш таба белгән бу кешенең ничектер үзен иркәлисе, яратасы килә.

Кәҗә бәтие тагын кычкыра башлады, әллә елый, әллә ашарга сорый.

Юл хакында уйларга теләмәсәм дә, җыенырга вакыт. «Атлар хәл алды»,— ди Фәхри абый. Мескен, мин борчылмасын, курыкмасын, дип кенә әйтә инде ул! Без бүген ул атлар белән, тәмам күз бәйләнгәнгә кадәр, әвенлеккә көлтә ташыдык. Кузгатмыйча җирдә яткырсаң, көлтәләр үрә башлыйлар. Майланмаган арбага төялгән чи көлтәләрне пычрак басуда сөйри-сөйри атларның җыгы чыкты. Ә кешеләр? Кешеләр дигәне — без инде аның. Без дүртәү. Сугыш елларындагыча әйтсәк — зур егетләр, йорт башлары, колхозның терәкләре. Ә болай әйткәндә, безнең барыбызга да унөчәр яшь.

Вакыйф арада иң өлкәнебез, ул ел башындарак туган. Әнисе һәм әбисе белән генә торганга, тормышлары да

авылда чибәррәк, арурак иде. Шуңа күрә ул буйга да шактый калку, күрер күзгә дә таза малай булып үсте.

Ә аның белән рәхәт иде! Дөрес, ул бераз кыдрачрак булса да, малайлар арасында әтәч кушаматын тагып йөрсә дә, без аның белән шактый дус идек. Быелга кадәр җәй саен, аның белән икәүләп, безнең сарай түбәсендә печән тутырылган чанада йоклый идек. Кичке уеннан сәгать ничәдә кайтканыңны да сизмиләр. Урам буйлап яшел тавыш белән (малайларда башка тавыш була микән?) «Һаваларда йолдыз»ны сузып кайтабыз да, безнең турыга җиткәч, шып булабыз. Шым гына печәнлеккә мен дә түн! Бакчаларда кыяр-шалканнар өлгергәндә, безнең сарай түбәсе тәмам штабка әверелә иде. Керфек тә какмыйча, тынгысыз хуҗаларның йокыга китүләрен көтеп ятабыз да ярты төн авышуга, шыпырт кына бакчаларга!.. Без кыярларны сабакларын измичә генә, хуҗалар үзләре дә сизмәслек итеп өзә идек. Вакыйфларның үз бакчаларына да кергәләгән чакларыбыз булды.

Андый төннәрдә сарай түбәсендә кунарга Әкмәл белән Барый да менгәли иде. Җыйнаулап ду килә идек...

Малай чак белән егет чак чиген сизми дә калдык. Сугыш башланды. Әтиләр китеп барды, әтиләргә абыйлар иярде. Безнең җилкәгә иң элек гаилә авырлыгы, шуның белән бергә үк колхозның иң авыр эшләре өелеп калды. Ат җиккәндә, көч җитмәгәч, чөелдерек бавын өчәүләп-дүртәүләп тарта идек. Тора-бара күнегелде, әллә үзебез үстек, әллә камыт баулары, мунчала белән алышынганга, җиңелрәк тартыла башлады. Төннәрен дә бик йоклап үткәрергә туры килми хәзер...

Мин, караңгылыктан кемнедер табарга теләгәндәй, һаман ишегалдына карап торам. Киртә казыгына элеп куйган иске чүлмәк (кәҗә киткәч, аның да кирәге бетте), кешегә охшап, миңа тешен ыржайткан кебек була. Үрелеп күккә карыйм да ихтыярсыз күзләремне йомам. Өй кыегыннан чылдап аккан су күңелгә шом сала. Күктә Фәхри абый вәгъдә иткән аязуның эзе дә юк. Сукыр лампага ут кабызып саркырга куйган чабатамны мич авызыннан барып алдым. Бөтенләй эштән чыккан, мыекларын тырпайткан, өч-дүрт җирдән ялганган киндерәсе кыска гына калган. Моңа ышанып ерак юлга чыксаң, яланаяк кайтырсың. Чормага менеп, яңа чабата алып төштем. Чабаталар да аз калган, кышлык юкә дә тунаган юк әле. Бәла өстенә каза дигәндәй, эш тә эш, яңгыр да яңгыр. Чормадан төшкәндә:

Килә ява, килә ява,
Иярләнде бер болыт,—

дип, шыңшып куйдым. Әткәй шушы җырны көйләргә бик ярата иде...

Ян сәкедә изелеп йоклаган энем Тәлгатьнең өстен рәтләбрәк яптым да киенеп чыгып киттем. Дерелдәп, күшегеп беткән кәҗә бәтиен күтәреп өйалдына керттем. Әйдә, пычратсаң пычратырсың, төнеңне корыда үткәр! Мин чыланып йөргән дә бик җиткән.

Мин төшкәндә, сушилка янында ике ат бар иде инде. Яңгыр астында моңаеп кына, танауларын җиргә тидерә язып торган атлар янына мин дә үземнең Озын ялымны туктаттым. Сушилка ишеге төбендә менә сүнәм, менә сүнәм дип янган фонарь яктысында Фәхри абый басып тора иде. Ул, минем якка караштыргалап:

— Килдеңме, энекәш? Вакыйф күзеңә чалынмадымы? — дип сорады.

— Ул килмәдемени әле?

— Юк шул. Нишләп ята торгандыр. Сугылып чыгасың калган икән.

Шул вакыт ишектән Әкмәл килеп чыкты. Ул кулына нечкә генә бау тоткан, күзләре йокыдан ачылып та җитмәгән. Фәхри абыйның сүзләрен ишетеп, безнең янга килде дә черелдек нечкә тавыш белән:

— Килмәде Вакыйф һәм килмәс тә,— дип куйды.

Мин арбадан кабыклар төшереп маташа идем. Әкмәлнең сүзләренә артык исем китмәде. Кирле-мырлырак сөйләргә яратса да, Әкмәл ул юл өчен бик кешелекле, уңган иптәш. Күңеле саф, кулы эш сөючән ул малайның.

Әмма ул бүген гадәттәгедән ныграк кызган иде, ахрысы.

— Бөтен авылны әйләнеп бер аркалык таба алмадым. Ә алтмыш чакрымлык юлга чыгарга кирәк, җитмәсә, төнлә. Җиде чакрым урман үтәсе бар. Бу яңгырда сбруең түгел, муеның да чыдамас. Аркалык урынына киндерә бәйләргә кушалар,— дип сукранырга кереште ул.

— Кем куша? — дидем мин.

— Койрыклы җен! — диде Әкмәл, ачуланып.

— Алай бик барырга теләгең булмаса, мин сине көчләмим, Әкмәл,— диде Фәхри абый.— Берәр хатын-кыз табылыр әле...

Ай бу Фәхри абыйны, ничек чеметергә белә дә соң инде! Чыннан да Әкмәл коры чыбыкка төрткән ут кебек кабынып китте:

— Хатын-кыз, хатын-кыз! Тапканнар бер сүз! Тагын атка камыт суктырып кайтарыргамы? Бу юлга ышанып хатын-кызга кем ат тоттырып җибәрә! Без, тилеләр, кушкач барабыз инде, ә ул менә, аркасын мичкә терәп, җылынып ятар.

Барый ул арада арбасын сушилка янындагы кечкенә төз лапас астына кертте. Кырык ямаулы иске чыбылдыгын җәеп куйды. Җыйнаулашып аның арбасына бодай төйи башладык. Кулымны йөккә тыгып карадым. Җыпҗылы! Мондый ашлык явымлы көндә сүрәнләнеп, дымланып китә, тагын элеваторда кабул итми азапланып теңкәгә тиярләр инде. Нишлисең, көтәр хәл юк.

Әкмәл икенче булып атын кертте. Ашлык киптерүче Нурҗиһан апа аның, бер сүз дә дәшмичә, борчылып йөрүен күргәч:

— Алай чәпчергә ярамый, улым. Юлга чыгар алдыннан әйбәт булырга кирәк. Аркалыгың юк икән, нигә аны моңарчы әйтмәдең? Чоланда бер яшел тасма уралып йөрүен күргән идем. Мәрхүм Сибгатьтән үк калгандыр инде. Үтешли шуны кереп алырсың. Әнкәйгә «Нурҗиһан апа кушты» дип әйтсәң, бирер,— диде.

Ут яктысына Барый килеп чыкты.

— Нурҗиһан апа, ул тасма озынмы? — диде.

— Озын дип, бик кыска да түгел бугай.

— Ике аркалыкка җитәрме?

— Синең дә аркалыгың юкмыни?

— Бер юлга әйләнеп кайтыр кайтуын да, бик тузды.

— Икегезгә дә җитәр. Тигез итеп бүлегез,— диде Нурҗиһан апа.

Әкмәл арбасын төяргә керештек. Сушилкада шактый җылы иде. Бишмәтләребезне салып бер почмакка өеп куйдык. Без зур агач көрәкләр белән бодайны калай өстеннән ишеккә таба этәбез, Фәхри абый читләре кыршылган, чукланган тимер подауканы сыңар кулы белән генә күтәреп үлчәүгә сала. Тулгач — үзенең генә көче җитми — бергәләшеп үлчәүгә асылынабыз, шау-гөр килеп, аны янтайтабыз, һәм арбага вак кына җылы бодай ага башлый. Нурҗиһан апа лапас баганаларының берсенә күмер белән тагын бер таяк сызып куя. Яңадан көрәкләргә барып тотынабыз.

Әкмәл арбасын төяп бетергәндә, мин Фәхри абыйның тынычсызланып, авыл ягына күз салганлыгын күреп калдым. Ул, подаукасын куеп, лапасның аргы башыннан бер әйләнеп тә килде. Борчылуының сәбәбе билгеле булганга, без беребез дә дәшмәдек. Вакыйф һаман килми, килүе-килмәве дә билгеле түгел. Юлга йөри торган дүрт аттан берсенең өйдә калуына Фәхри абый һич риза булачак түгел иде. Мин Вакыйф өчен борчыла башладым. Әкмәлнең йөген төяп бетереп, чыбылдыгын шырпыладык. Өстенә кабык ябып бәйләп тә куйдык. Фәхри абыйның түземе бетте, ахры.

— Мин Вакыйф янынnan бер әйләним инде, энекәшләр,— диде,— сырхаулап-нитеп китмәдеме икән?

Моңарчы шым гына йөргән Барый, өзек-өзек кенә итеп, бераз тотлыгыбрак әйтеп куйды:

— Йөрмә, Фәхри абый! Барыбер бармас. Вакыйф кебек кире беткән нәрсә... Башка кеше тап. Берәр хатынны утырт шунда. Атын үзебез карап йөртербез.

— Нигә бармасын? — дип, мин аңа каршы төштем,— барыр.

Вакыйф хакында әйтелгән сүзләр минем йөрәгемне авырттырып, кузгатып җибәрде. Фәхри абый икеләнгән кебек тоелгач, мин түзмәдем:

— Үзем барып килим әле, Фәхри абый? — дидем.

Малайлар мыгырдашсалар да, ул берсүзсез риза булды. Озын ялымны үлчәү янына китереп, чыбылдыгымны җәеп куйдым да авылга менеп киттем.

Тәрәзәләрен озак кына шакылдатсам да, җавап бирүче булмады. Чабата үкчәсе белән бүрәнәгә дә тибеп карадым. Нигезгә сыланган юеш кызыл балчыклар гына кубып төште. Җилкапкадан кереп, ишегалды ягындагы тәрәзәләрен кагып та бер нәтиҗә чыкмагач, өйалды ишеге янына килдем. Келәсен күтәреп караган идем, юка ишек шыгырдап ачылып та китте. Кармаланып өйгә кердем. Борынга, әче катык исеме, әчкелтем-төчкелтем бер ис бәрелде. Курка-курка гына тавыш бирдем. Сәламемне алмадылар. Шулчак Вакыйфның әбисе күрше авылдагы кардәшләренә утырмага китүе хәтеремә төште. Ян сәкедә Вакыйфның тигез генә тын алуы ишетелә, мич арасында әллә кара тараканнар, әллә тычкан явызлар кыштырдый. Мин ныграк итеп:

— Вакыйф! — дип эндәштем.

Җавап булмады.

— Вакыйф! — дидем мин яңадан һәм дустымның өстеннән юрганын тартып төшердем. Уянмады. Иңбашыннан эләктереп алып, озак кына селкетеп тордым. Вакыйф, ниһаять, башын күтәрде:

— Ә-ә,— диде ул.

— Ай-яй каты йоклагансың. Өегезне күтәреп китсәң дә уяначак түгелсең. Нигә ишегеңне бикләмәдең?

— Этем керсенмени монда? Әнкәй эшкә китте, бикләп кал, дигән иде, йоклап киткәнмен.

— Йоклап киткәнсең, әйтерең бармы.

— Арылган, малай.

— Әнкәң эшкә киткән, ә син?

— Нәрсә мин! Күрәсең ич...

— Фәхри абый кердеме? — дидем мин, ачуым кила башлап.

— Кергән иде. Йокы аралаш ни сөйләгәнен дә аңламадым.

Инде чын-чыннан ачуым чыкты. Көткән булабыз тагын! Тавышымның да, сүзләремнең дә кинәт үзгәргәнлеген чамалап, Вакыйф торып ук утырды.

— Минем ни сөйләвемне аңлыйсыңмы син, әллә һаман мышлыйсыңмы?

— Аңлыйм.

— Аңласаң, менә шул, без йөкләрне төяп бетердек.

— Әкмәл дәме? — Вакыйфның соравында ниндидер бер шөбһәләнү бар иде.

— Әкмәл дә,— дидем мин.— Кая, йөгәнеңне, сбруйларыңны бир. Берәрсе барыр әле.

Караңгыда Вакыйфның күзләре ялтырап киттеләр.

— Бирмим,— диде ул, усал тавыш белән.— Ансат кына алыр идегез бугай. Мин ул сбруйларны бер ел җыйдым. Беләм, беләм, минем шлеяга, чуклы йөгәнемә күптән кызыгасыз! Барыбер сезгә тәтемәс!

— Алайса әйдә үзең төш.

— Үзем дә төшмим. Мондый төнне яхшы хуҗа этен дә ишегалдыннан кумый.

— Ә икмәк? — дидем мин, нәрсә әйтергә белмичә.

— Менә көннәр әйбәтләнер, юл саркыр. Җитешмәбезмени?

Вакыйф соңгы сүзләрен аермачык бер икеләнү белән әйтте. Торып киенә башлады һәм без, җитди уйга чумган зурлар кебек, урамга чыктык.

— Бармасаң бармассың, Фәхри абый янына төшеп үзең сөйләш,— дидем мин.

Авыл белән сушилка арасында җәен-көзен чыпчык тезеннән генә кала торган Чүке елгасы ага. Язгы кар киткәндә, явымнар күбәйгәндә, елга шәбәеп ярларыннан ташып чыга иде. Без сүзсез генә шул елгага җиттек. Болганып һәм ямьсез мыгырданып аккан су аркылы салынган иске күпер өстенә кергәч, Вакыйф туктап калды.

— Ә Нурҗиһан апа андамы? — дип сорады ул.

— Анда булмыйча кайда булсын.

— Ишеттеңме? Аларның олы малайларының үлү хәбәре килгән.

— Кичен Сәрбиҗамаллар әйтеп торганнар иде шул. Тагын беравык дәшми тордык. Аяк астыбызда һаман иске күпер калтырана, менә китәм, җимереләм дип дерелди, яр буендагы биек өянкеләрдә ялкау гына яңгыр шыбырдый. Бишмәт җиңе белән битемне сөртеп алдым да иптәшемне ашыктыра башладым:

— Фәхри абый ындырга китәм дигән иде, тизрәк булыйк.

Вакыйф авыл ягына борылды, миңа карамыйча гына төшенке тавыш белән:

— Син бар. Фәхри абыйга хәзер килә дип әйт. Мин бик тиз төшеп җитәрмен,— диде.

Мин аны-моны әйтергә дә өлгермәдем, ул авыл ягына чабып та китте. Ындырлар артыннан боргаланып үткән тар юлда аның гәүдәсе бер күренде, бер күмелде.

Сушилкага кайтып җитсәм — малайлар минем йөкне дә төяп бетергәннәр, чыбылдыкны шырпылап, кабыкларны бәйләп торалар иде. Ерык авызымны җыя алмыйча, аларга бер генә сүз ташладым.

— Килә! — дидем дә үзем Озын ялымны муеныннан сыйпап куйдым.

Вакыйф килмәгәч, бодайны үлчәү янына китерми торганнар икән, тиз-тиз генә аның эшен бетердек. Ашлыкны үлчәүгә салып, Фәхри абый тәмәке кабызгалаганчы, бөтен су буен яңгыратып сызгыра-сызгыра атын куалап, Вакыйф та килеп җитте.

Әкмәл дә Нурҗиһан апалардан ике аркалык чыгарлык бик таза, нык яшел тасманы алып кайтырга өлгергән иде.

Без Вакыйфның, соңга калуын сизмәмешкә салышып, йөген җәһәт кенә төяп тә куйдык.

Сушилка эчендә җылыда һәм корыда шактый мәж килеп, кипшереп алгач, барасы озын юл, яңгырлы кара төн хакында оныткан да идек инде.

Төн уртасында юлга чыгып киткәләгәнебез бар иде безнең. Ярты төндә кузгаласың да төн барасың, көн барасың, кичкә элеваторга да барып җитәсең. Әмма бу юлы беребез дә көтмәгән кыенлыклар килеп чыкты. Элеваторга бу баруым хәтеремдә якты да, караңгы да бер истәлек булып калды.

Колхоз бик җаваплы юлларга чыкканда гына бирә торган берәр бөтен ипине капчыкларга салып, чыланмасын өчен, кабык астына кыстырдык. Барый, юлда пешерергә дип, берәр чиләк бәрәңге дә алырга булган иде, Әкмәл:

— Юл буенда бәрәңге бетмәс әле. Атларга болай да авыр,— дип каршы төште.

— Карагыз аны, урлаша күрмәгез, алсагыз, сорап кына алырсыз,— диде Фәхри абый, үзе ындыр ягына китә башлады.

Нурҗиһан апа сушилка миченә ут ягып җибәрде. Хәзер, бәләкәй арбаларга төяп, хатыннар тары китерәчәкләр. Янгын сараена куелган, картлыктан тешләре төшеп бет-

кән, биле дугадай бөгелгән, йоны коелган Корыч исемле алашаны да Фәхри абый бүген тары ташу өчен җигәргә булды.

— Бу явымда ут-күз чыкмас әле,— диештек без.

— Чамалап йөрегез инде, егетләр. Сбруйларны да, атларны да саклагыз. Артык кумагыз. Урман чыккач, бераз хәл җыегыз. Йә, хәерле юл сезгә,— дип, Фәхри абый безнең белән саубуллашты.

— Безнең киткәнне әнкәйләргә әйт, Фәхри абый! — дип кычкырып калдык без аның артыннан.

Ниһаять, кузгалдык.

Адымы әйбәт дип Вакыйфның бурлы биясен алга куйдык. Аның артыннан Әкмәл белән Барый иярделәр. Озын ялым арттан күндәмрәк йөргәнгә, мин Барый артыннан кузгалдым. Сушилка ишеге төбендә моңаеп басып торган чал чәчле, өстенә кигән ямаулы ирләр пиджагын нечкә бау белән бәйләп куйган, кара яулыклы, корымга һәм көлгә буялып беткән хатынга карап:

— Хуш, Нурҗиһан апа,— дидем.

Ул элек сүзсез генә баш иде, җайсыз гына кулын селкеп куйды. Аннары җәһәт кенә сушилкага кереп китте. Мин, ул яңадан дәшмәс инде, дип уйлаган идем. Арттан:

— Ибраһим! — дигән тавыш килгәч, туктап калдым.

— Мә, юлда ашарсыз. Әле чи бәрәңгегә өметләнгәнче,— диде ул, килә-килә.

Аның кулында көлдә пешкән кайнар бәрәңгеләр тутырган кечкенә генә киндер капчык. Рәхмәт әйтеп алдым да капчыкны барган көйгә генә кабык астына тыгып куйдым. Нурҗиһан апа лапас янында басып карап калды. Бер-ике җир буе киткәч, борылып карадым. Сушилка да, Нурҗиһан апа да күренми иде. Тик, нигәдер, ул һаман шунда басып торадыр һәм үксеп елыйдыр кебек тоела иде.

Мин ул вакытта Нурҗиһан апаның ни өчен шулай кызганыч итеп карап калуын аңлап та бетермәдем.

Аның, шул юллардан китеп, кайдадыр еракта, сугыш кырларында мәңге кайтмаска күмелеп калган ире дә, улы да хәтеремнән чыккан иде ул вакытта. Нурҗиһан апа гына онытмаган иде аларны, күрәсең.

Менә әллә нинди шомлы караңгылыкка төренгән ярым җимерек тавык фермасы да артта калды. Төнге юлда без, дүрт малай, берьюлы кечерәеп киттек. Бу арбалар да чын түгел, атлар да уенчык кына, үзебез дә зурлар булып уйнап шаярабыздыр кебек тоелды.

Тирә-як шулкадәр караңгы иде ки, алдагы атлар миңа

юньләп күренмиләр. Барыйның, арба кырына тотынып, лачтыр-лочтыр атлавы гына ишетелә иде.

Авылдан чыккач та юл бераз түбән таба. Коры вакыт булса, хәзер арба өстенә утырып, җилдереп кенә барыр идек. Хәер, коры булса, икмәк тә әллә кайчан ташылып беткән булыр иде. Әтиләр дә шулай интегә-интегә ташыдылармы икән? Юк, ул вакытта колхозның бер автомашинасы өстенә никадәр аты булган. Әтиләр өйдә торып, автомашина да сугышка алынмаган булса... Ә без? Без мондый ямьсез төннәрдә җылы мендәрдә генә аунар идек. Әни дә ямау сырган чуар күлмәген әллә кайчан иске-москылар җыючы Кыек Шәрипкә биреп җибәргән булыр иде. Кыек Шәрип булып Кыек Шәрип тә бу арада авылда күренми. Ичмасам, берәр күмәч сагыз алып калыр идем. Менә бу озын юлларда авызыңны тутырып чәйнәп җибәрсәң!.. Корсагың буш булганда авыз алдарга ярар иде дә, юк...

Мин арбага ияреп барам, чуалчык уй җепләре, юл буена сузылып, мине көтеп торалар икән. Уйлар йөрәкне, ә котырып үскән тигәнәкләр, әремнәр ялангач тезебмне капшыйлар. Исерек арба тәгәрмәчләре бер-бер артлы чулт та чулт итеп сулы чокырларга төшә. Мин, арба кырына иңемне терәп, Озын ялыма булышам, кырык төенле тәҗе бавымны тартып карыйм. Атлар да, нәкъ кешеләр кебек, ярдәмгә килгәнне бик тиз сизәләр бит. Төннең яктырмавы, ә безнең урманга якынаюыбыз борчый башлады. Булса да була икән озын төннәр!

Яңгыр туктаган кебек булды. Әмма җир һәм һава юешлек белән шулкадәр туксырган иде, урман ягыннан искән җил кая төшәргә белмичә аптырап йөргән су тамчыларын куып китерә. Бөтен яктан яңгыр исе, саз исе, тагын әллә нинди болганчык исләр килә иде.

Кузгалып киткәч тә малайларның кайсы чөңгергәләп, кайсы сызгырып, гаярьләнеп бара башлаган иде, ниһаять, тындылар. Аклан чирәмен үтеп, басу арты юлындагы үргә менә башладык. Монда җир вак ташлык булып, юл ул кадәрле үк бозылмаган, тәгәрмәч бүкәне күмелерлек чокырлар да юк иде. Әмма үзле балчык. Ул зур-зур кантарлары белән кубып тәгәрмәчкә ябыша, тугымнар, кигиләр калынаеп резиннан эшләнгән төскә керәләр. Тик бу резин тәгәрмәчле арбаны сөйрәү атка ничек авыр икәнлеген мин үземнән үк чамалый алам. Чөнки чабаталарыма да әллә никадәр балчык сырышкан, аягым Алып батыр аягы кебек зур. Тик бу аякны кузгатырлык һәм йөртерлек көч кенә юк миндә.

Үрнең уртасына җитәрәк Озын ял авыр-авыр сулый

башлады, су исен басып, ат тире исе аңкыды. Мин буем җиткән кадәрле үрелеп атымның аркасын иркәлим. Әллә ничә потлыга әйләнгән тәгәрмәчләр теләр-теләмәс кенә тәгәриләр. Менә Озын ялның сулавы тоташ мышнауга әйләнә, ул арбаны, өзек-өзек хәрәкәтләр ясап, көчәнеп кузгата. Менә туктый, менә туктый, дип шүрләп барам. Бер туктаса, тауга каршы кузгатып җибәрү тагын да кыенрак булачак.

Дүртебезнең дә атлар көч-хәл белән кыймылдыйлар иде бугай. Үз тавышым тынып торганда, алдан, караңгылык эченнән, малайларның тирән бер борчылу белән төрле авазлап:

— Әйдә, елгыр, әйдә, калма!..

— Бара, бара...

— Һа-һа-һа,— дип кычкырынуларын ишетеп калам. Үрне дә менеп җитәбез. Атлар дәшкәнне дә көтмичә бердәм туктап калалар. Кулымдагы сигездән үргән камчымны арбага, бау астына кыстырып, ат янына барам. Аның дәү башы түбән иелгән, йоны юешләнеп, арыклыгы тагын да шыраебрак калган муены дерелдәп китә. Озын ял, кызганыч карап, мине каршы ала. Капшап карыйм: камыт тирәләре нык дымланса да, артык тирләмәгән әле. Мин аның муенын кочаклап алам, үземнең кычкырып елыйсым килә. Мескен Озын ял! Җәен дә, кышын да, көнен дә, төнен дә юлда бит ул. Үзенең шушы ябык, ач гәүдәсе белән әле арба, әле чана сөйри. Яңгырда да тышта, буранда да тышта. Чыдам ат, күндәм хайван. Берсүзсез, зарсыз эшли дә эшли. Күпме яхшылык иткән, хезмәт күрсәткән инде ул безнең кечкенә авылга! Юлга йөрерлеге калган шушы дүрт бөртек чыдам ат булмаса, без нишләр идек икән?

Иелеп, чабатама ябышкан балчыкны кырып ташладым. Тәгәрмәчкә сырышканнарын камчы сабы белән каезладым. Вак таш катышкан үзле балчык, кубарга теләмичә, кулларны авырттырып бетерде. Арба янында маташканда, борыныма бик тәмле ис бәрелде. Мин, кабык астына кулымны тыгып, капчыктан бер бәрәңге алдым. Әле суынып та өлгермәгән, йомшак бәрәңгене битемә тидереп тордым да Озын ялга илтеп каптырдым.

Аргы баштан Вакыйфның:

— Әй, кузгалабызмы?! — дигән карлыккан тавышы килде.

Мин:

— Кузгал, әйдә,— дип кычкырып җибәрдем һәм, үз тавышымнан үзем сискәнеп, куркып киттем.

Тәгәрмәчләр тагын чокыр-чакырларда күңелсез генә су ярырга керешә. Тигәнәкләр, шайтан таяклары та-

гын, безне тотып калырга теләгәндәй, чалбар балагын тешли башладылар. Тау өстендәге җир ике елдан бирле чәчелмичә, эшкәртелмичә ята. Шуңа күрә аны чүп-чар, азгын алабуталар, әрсез әремнәр басып киткән.

Күк йөзе чак кына ачылган кебек булды. Мин Барыйның аркасын гына түгел, үзен дә шактый ачык күрә башладым. Әллә ничек күңеллерәк булып китте. Эчтән генә бер көй кисәге дә шыңшып алдым. Җыр дип, болай гына инде... Җырлар килми иде күңелгә. Күңелгә тик уйлар гына килә, сүзләр килә. Аларны җыр итеп җырлап булмый. Сөйләргә дисәң, кемгә сөйлисең аларны, Озын ялгамы? Ул болай да бик яхшы аңлый, минем белән байтак юллар үткән, шактый нужа чиккән иптәш ул.

Барый артына борылып карап-карап куя, әллә әйтер сүзе бар, әллә болай гына эче поша. Аңа да ялгыз бару күңелсез иде булса кирәк.

Алда җиде чакрымлы урман. Аның тар юллары, кинәт бормалары безне шактый интектергән инде. Чокыр-чакырына төшеп, агач кәүсәләренә эләгеп, күпме тәҗе баулары, аркалыклар өздек, ничә тәгәрмәч ваттык, күчәр сындырдык инде без бу урманда! Санап бетергесез.

Барый туктап, мине көтеп алды. Икәүләп янәшә бара башладык.

— Атың бик армадымы, Барый? — дип сорадым мин.

— Ат? Ю-ук,— диде ул, сузып кына.— Беләсеңме, Ибраһим, мин куркам.

— Ә мин курыкмый дисеңме? Урман юлын үтү диләр аны. Бер Тугай суы гына да ни тора.

— Юк ла. Мин аны әйтмим, качкын-фәлән булмагае, дим.

— Качкыннар? Каян килсеннәр алар?

— Әби өченче көн генә Чыршылыдан кайтып сөйләде. Чыршылы урманында әллә ничә качкын күргәннәр...

— Хатын-кыз сүзенә ышансаң...

— Хатын-кыз түгел, әби әйтә, Җамали картка очраганнар, ди. Бөтенесе дә тимер тешле икән. Ул гел дөресен генә сөйли.

«Тимер тешлеге» кадәр минем күңелгә дә бер шом кереп бара иде, аны ишеткәч, көлеп җибәрдем. Барый үз экиятеннән үзе тагын да шүрли төште. Аның күзләре зур булып ачылдылар, бишмәт якасыннан күренеп торган озын муены төрле якка борыла, үзе һаман миңа якынрак елыша.

— Камыр тешлеләре дә булганмы соң?

— Көлмә, көлмә! Чыршылыдан бу тирәгә дә килеп чыкмаслар дисеңме? Безнең урман калынрак та, зуррак та әле. Әби әйтә: Тугай суы — качкын оясы, ди.

Бераз дәшми бардык.

— Булсалар, берәр кеше күрер иде үзләрен,— дидем мин.— Тугай суында су анасы бар, дип тә сөйлиләр. Күргән кеше юк бит. Кеше ышанмаслык сүз ул.

Су анасы турында ишеткәч, Барый тагын да шүрли төште. Аның йөзе агарынып китте. Ул, артык куркуын сиздермәскә тырышып, кулындагы сүс камчысы белән пычрак әрекмән яфракларына селтәнеп бара башлады.

— Син бик оста кыйдырасың, яле мин...

Барый камчысын бирмәде. Бала йоннары тырпайган йөзен миңа терәп диярлек үк пышылдый башлады:

— Бодайны таларга тотынсалар, нишләрбез?

— Кемнәр? Су аналарымы? Алар бодай ашамыйлар ич! — дип, мин кычкырып көлеп җибәрдем.

— Җүләр, кычкырма алай! Качкыннар,— диде Барый, тагын да шыпыртрак итеп.

Ул арада алдагы атлар да туктады. Без Әкмәлләрне куып җиттек.

— Атлар бәләкәй генә хәл алсыннар әле,— диде Вакыйф. Ул бишмәтен салып ташлаган, былтыр ялга кайтып киткән абзасының иске гимнастеркасыннан калган иде. Гимнастерка аның өчен шактый зур булса да, Вакыйфның көрлеге, тазалыгы һәм бездән калкулыгы нык сизелеп тора.

Бәләкәй чакта ук сугыш уеннарында гел узаман булып уйнарга яраткан Вакыйф бүген дә «атлар хәл алсын» дигән сүзен каршы килеп тормаслык итеп, өзеп әйтте. Хәер, беребез дә аның сүзенә каршы килергә җыенмадык. Урманга керер алдыннан аз гына хәл җыю кирәк бит.

Аркалыклары бушатылган атлар юл буендагы үләннәргә үрелделәр. Без Вакыйф арбасы янына җыелдык. Малайлар юлның начарлыгыннан, хайваннарның талчыгуларыннан зарланып алдылар.

— Менә Барый безне талый күрмәсеннәр дип курка әле,— дидем мин.

Барысы да кычкырып көлерләр дип уйлаган идем, алай булып чыкмады, бары Вакыйф кына ниндидер ясалмалык белән шаркылдарга кереште.

— Нигә көләсең? — дип, Әкмәл аңа каршы төште.— Минем күңелгә дә килде ул. Шуннан таза гына бер ир чыксын, ди, безнең бодайны берүзе көри дә алып китә бит.

— Чыгып карасын,— диде Вакыйф, эре генә.

— Нишләрсең? — диде Барый, мыскыллы тавыш белән сузып кына.

— Азау тешләрен уч төбенә тутырып җибәрермен.

— Ярый ла, син куе умач ашап үскән, синең көчең дә күп, ә без?

«Куе умач» сүзеннән, гадәттә, Вакыйфның ачуы килсә дә, «көчең күп» дигәч, аның кәефе кырылмады, ахрысы, дәшмәде.

— Их, чукмарны аласы калган икән! Шуны да хәтергә төшермәгәнсез, ичмасам,— диде ул, нык үкенеп.

Малайларның качкыннардан шүрләве миндә дә эзсез үтмәде. Юлчыларның икмәкләрен талау кебек хәбәрләрнең ишетелгәләгәне бар иде.

Вакыйф һаман:

— Ул чукмар белән минем бабай бүрегә йөргән. Бер заман аңа өч бүре ыргылган. Кырган да салган үзләрен. Шул чукмар булса, бер качкын гына түгел, унау чыксалар да йоннарын туздырыр идем,— дип сөйләнде.

Иптәшемнең шапырынуыннан юаныч бик аз булганга, мин аны бүлдереп:

— Булмаган чукмарны өйгә кайтып алып килеп булмый инде. Һич югында, имән күсәкләр кисик! — дидем.

Әкмәл юлга чыкканда арбасыннан бер дә калдырмый торган шома өрәңге саплы, кечкенә, әмма бик үткен балтасын алып килде.

Шулай карар кылдык: дүртебез дә имән күсәкләр тотып күмәкләшеп барабыз. Алдагы ат янында икебез, арттагы ат янында икебез. Бер-бер шик сизелү белән, бик тиз арада хәбәр итешергә. Качкыннар чыга калсалар, курыкмаска, иптәшеңне ярдәмсез ташламаска, бер генә бодайны да дошманга бирмәскә.

Сугышырга туры килсә, уңай булсын дип бишмәтләребезне салып, йөк өстенә ташладык. Урман авызындагы туйралыктан әчкелтем ис аңкып торган, саллы гына күсәкләр кисеп алдык. Аркалыкларны күтәрдек тә, бауларны тартып, тәгәрмәчләрне селкетеп карадык. Шуның белән әзерлек эшләре бетте. Безнең кечкенә отряд икегә бүленеп, Вакыйф белән Әкмәл алдагы ат янына киттеләр, Барый белән мин артка чыктык. Кузгалдык.

Барый качкыннар, һичшиксез, арттан һөҗүм итәрләр дип ышанганга күрә, Вакыйфка ияргә теләсә дә, Әкмәл риза булмады.

— Атларның йөрешен үзгәртмик, ничек барсалар, шулай барсыннар,— диде.

Урман. Авыл малаена никадәр кадерле ул. Яз җитеп, карлар китәр-китмәстә авыл малаен урман үз кочагына ала, каен, өрәңгеләрнең татлы сулары белән авызларны рәхәтләндерә, сусыл күкбаш белән сыйлый. Күкбаш ар-

тыннан ук көмеш сулы тугайлар янындагы уйдыкларда көпшәләр үсеп чыга, хәтфә үләнле, кояшлы аланнарда балтырганнар өлгерә. Балтырганнарга ияреп ачы какылар, кәҗә сакаллары күтәрелеп китә. Шуларны ашыйашый малайларның иреннәре иске бияләй кадәр булып күпереп бетә. Ниһаять, тау кашларында, чокыр-чакырларның кояшка караган битләрендә каен җиләкләре мәмрәп пешәләр. Аңа җир җиләге, кура җиләкләре ялганып китә. Җәй буе, көз буе урманнан кайтмый авыл баласы. Чикләвеген җыя, миләшен, баланын. Урманның байлыгы, аның бетмәс-төкәнмәс төрлелеге авыл баласы өчен шәһәрнең музейларын да, паркларын да, стадионнарын да алыштыра. Шомарып беткән тырыс яки борыны төшкән чәйнек тотып чыклы сукмаклардан ялантәпи белән җиләккә, шомыртка баруның рәхәтлеген яшьтән үк шуны күреп үскән авыл малае гына аңлый. Кояш тәме килеп торган җиләк булганда синең мороженыйларың, сиропларың нигә кирәк аңа? Ә урман чишмәләре? Арып-талып, янып-көеп, көне буе йөргәннән соң, каяндыр ташлы ярдан бәреп чыккан терекөмештәй саф, боздай салкын суны учың белән алып, чөмерә-чөмерә эчү үзе ни тора! Тирләгән изүеңне чишеп, өрәңге күләгәсендә хәл җыю, әзрәк кенә черем дә итеп алу ай-һай рәхәт тә инде. Ә төнге ат сакларга барулар, көлдә пешкән бәрәңгеләр, учаклар...

Сугыш елларында ачлыктан да, ялангачлыктан да коткарды урман. Дус булды ул безгә, якын булды. Әмма дошман да булды ул кайчакта. Үзе түгел, юллары... Без бу юллардан әтиләрне, абыйларны озаттык, күпме яшь түктек. Көзен дәүләткә икмәк ташыдык. Язын берәр капчык чәчүлек орлык салынган кечкенә арбаларны сөйрәдек ул юллардан. Карлы бураннарда, чатнама суыкларда урман кисеп, пристаньга ташыдык. Барын да эшләдек, тик юлның үзен карарга гына вакытыбыз булмады...

Һәм менә ул юллар...

Юл тарайганнан-тарая барып, без арбалар яныннан килә алмас булдык. Мин Озын ялымның йөгәненнән тотып алдан киттем. Чокыр-чакырларга мөмкин кадәр төшмәскә тырышып, әле уңга, әле сулга тартылып үттек. Барый минем яннан китәргә шүрли иде булса кирәк. Ул чокыр-фәлән шәйләсә, ботакларга сыдырыла-сыдырыла аты янына йөгереп бара да, үткәреп җибәргәч, үзе читкә чыгып, мине көтеп ала. Имән күсәген ябык иңбашына салып тагын янымнан бара башлый. Озак вакыт берни дә сөйләшмибез.

Гомумән, юлда аз сөйләшә идек без. Аның каравы тукталышларда, фатир кергән җирләрдә, алны-ялны бел-

мичә үткән юлны бөтен ваклыклары белән искә төшерә торган идек.

Ни уйлап үтә идек соң без ул юллардан? Искитәрлек берни дә уйламый идек.

Һәрберебез күчәр сындырмый, тәгәрмәчен ватмыйча, ничек урман аша үтүне генә уйлагандыр ул чакта. Авырлыкта уйлар еракка китмиләр бит.

Дүрт йөк бодай ил өчен, фронт өчен әллә нәрсә дә булмагандыр. Әмма безнең өчен дүрт йөк алтыннан да кадерлерәк иде ул. Үз авызыбыздан өзеп, аталарыбызга булсын, абыйларыбыз ашасын, дип ниятләгән бодай ич.

Аю аланына кадәр ару гына бардык. Түшәктәй кабарынып-кабарынып ишелгән болытлар аркылы таң яктысы саркылды. Малайлар да, атлар да ап-ачык күренә башладылар. Аю аланын үтеп, тагын шырлыкка барып кердек. Гомер буе кояш чыраен күрмәгән, коры елда да дымланып, мәлҗерәп торган, арба эзе араларына зәгыйфь шуышма казаяклар, бака яфраклары сырышкан юл башланды. Монда колагыңны торгызыбрак бармасаң, тәгәрмәчеңнән коры калуыңны көт тә тор. Сагаеп барган кебек булсак та, кинәт Барыйның аты шып туктап калды. Дүрт тәгәрмәченең өчесе шулпаланып беткән пычрак сулы чокырга, ипләп кенә, бүкәннәренә кадәр төшеп утырган. Аты омтылып-омтылып караса да, арба кымшанмый да, киресенчә, батканнан-бата бара иде. Менә арт күчәре бөтенләй күренмәс булды.

Мин барып аны-моны эшләгәнче Барый, атын кинәт бер якка борып, тәҗе бавын өздерде. Мин алдагыларга кычкырдым:

— Әй! Туктагыз әле!

Агачлар арасыннан Әкмәлнең чәрелдәвек тавышы ишетелде:

— Нәрсә бар?

— Монда килегез!

Байтак кына вакыт узгач, сыгылган чикләвек чыбыкларын күтәрә-күтәрә, Әкмәл белән Вакыйф килеп чыктылар.

Мин аларны беraз кытыкларга теләп:

— Уяулыгыгыз шәп икән, кычкыра-кычкыра тамагым бетте. Ә безне талый башлаган булсалар?..— дип каршылаган идем, Вакыйфның ачулы тавышы ишетелде.

— Чумдыңмы? — диде ул, калтырана-калтырана тәҗе бавын ялгап маташучы Барыйга җикеренеп.— Төнлә булса, караңгы, күрмәдем, дияр идең. Хәзер бит ярты чакрымнан юл күренеп тора. Их чепи күз, чепи күз!

Барый, акланырга теләп:

— Без Ибраһим белән артта кирә идек. Качкыннар...— дип сөйли башлаган иде, Вакыйф аны бүлдерде:

— Арбаңны үзен чыгар инде менә. Алдан ике ат үтеп китте, берсе дә батмады. Ә ул чокырны үзе эзләп тапкан диярсең. Киттек, Әкмәл!

Әкмәл, терсәгеннән пычракка буялып, тәгәрмәч кигиләренең хәлен тикшерә-тикшерә, арба тирәсендә маташа иде. Вакыйфның сүзләрен ишеткәч, ул турайды, күзенә үк төшкән фуражкасын күтәреп куйды.

— Чыгарыйк инде,— диде ул, эшлекле кыяфәт белән кулларын әрекмән яфрагына сөртеп.

— Безнең йөкләрне төяп китсәләр, бик шәп булыр алайса,— диде Вакыйф.

— Төяп китмәсеннәр өчен, тиз генә чыгарыйк та, кузгалыйк,— дип, сүзгә катыштым мин.

— Тәҗе өзелмәсә, сөйрәп чыгара иде ул аны,— диде Барый, юаш кына. Ул, без карап торгангамы, каушап калды, һич кенә дә төенен төенгә туры китерә алмый; ул кабаланган саен төен, сарык койрыгында укмашкан тигәнәк кебек, йә бик дәү, йә кырау тиеп бөршәйгән кыяр кебек кәй була иде. Әкмәл, аны тынычландырып:

— Син ашыкма, бер булгач булсын инде. Атлаган саен туктап тормабыз. Мин берәр колга кисеп алыйм әле,— диде. Үзе биленә кыстырган балтасын алып шырлыкка атлады. Вакыйф, сызгырынгалап, Барыйны күзәтә иде, мин тәҗе бавын ялгарга булыша башладым. Ул арада балта тавышы ишетелде һәм бераздан саңгырау гына дөпелдәп агач ауды.

— Күзенә генә баскансың икән сазның,— диде Вакыйф. Аның соры күзләре уйнаклап торалар, йөзендә ачу.— Авызыңны ачып йөрсәң, шулай булмый хәлең юк.

— Йә ярар, җитәр,— дидем мин.— Бәйләнергә урын юк.

— Ул йоклап барсын да, син аның өчен интек монда,— дип мыгырданды Вакыйф.

Шактый юан каен колгасы сөйрәп Әкмәл килеп чыкты. Аның тирләгән битенә яфраклар ябышкан иде. Ул, чыгу белән Вакыйфка карап:

— Шулай да беребез атлар янына кайтыйк. Бу эш тиз генә бетмәс әле,— диде.

Барый:

— Бетте инде, бетте. Ялгадым. Хәзер була,— дисә дә, Вакыйф, Әкмәл сүзен хуплап, китәргә җыенды. Мин аны:

— Әкмәл барсын. Син көчлерәк, монда булышырсың,— дип туктаттым.

Вакыйф, эреләнеп, Әкмәлгә күз ташлады:

— Ә Әкмәл нәрсә эшли ала?

— Кайда?
— Йөкләр янында.
— Тик торыр.
— Качкыннар чыкса?
— Чыкты пычагым! Тапканнар сүз! Качкыннар, имеш.
— Барсын,— диде Әкмәл.— Без аны өчәү дә чыгарабыз.

Вакыйф, яуга җыйналган батыр сыман, күсәген болгый-болгый, зур-зур атлап китеп барды.

— Азрак булышса ни булган инде! — дип сукранды Барый.

— Китсен,— диде Әкмәл,— барыбер күз көеге булып кына утыра.

Барый, тәҗесен рәтләп бетереп, атын борып куйды. Без Әкмәл белән колганы арт күчәр астына кертеп, иңнәребезгә терәдек тә арбаны кузгата башладык. Барый ат янына басты. Өчәүләшеп атны әйдәкләргә, шауларга тотындык:

— Һоп лә!
— Кузгала, кузгала!
— Китте, китте...

Кола бия, ябык сыртын турайтып, борын яфракларын дерелдәтеп, бот мускулларын кабартып тартты. Без, кызарынып, бүртенеп күтәрәбез, кычкырабыз. Колга иңбашларын авырттырып батып керә. Чыбыркысын шартлатып, Барый атын әле уңга, әле сулга борып карый. Әмма арба урыннан да кузгалмый. Хәл җыярга туктыйбыз. Атның гармун күреге кебек кабыргалары тагын да әрсезрәк булып калыкканнар, бот тирәләре сизелер-сизелмәс кенә дерелди, үзе мыш-мыш килә, Барыйның чыбыркысы артыннан әрле-бирле күзен әйләндерә. Тик Барый атка сукмый иде. Песи балаларын, адашкан көчекләрне, урамнан җыеп кайтып, ашатып йөри торган малай хайваннарга һәрвакыт күңеле нечкәреп карый. Ерактан Вакыйфның тавышы килде:

— Әй, сез! Буласызмы инде?

Без аңа дәшмәдек. Барый атының муенын сыпыра-сыпыра елап тора иде.

Мин кешеләрне юата белмим. Бигрәк тә үз иптәшем, яшьтәшем, авыз ачып елап торганда, миңа уңайсыз булып китте. Әле ярый янымда Әкмәл иде. Ул, зур зәңгәр күзләрен тутырып, мышкылдаудан кечерәеп, месkenләнеп калган Барыйга карап торды да:

— Җылама! Хәзер чыгарабыз аны! — диде.

Тагын колгага тотындык. Һай-һулап арбаны селкетә, этә һәм атны куалый башладык. Арба шыгырдап куйды,

тәҗе баулары скрипка кыллары кебек киерелделәр. Бер тартылды күндәм хайван, ике тартылды, лайда ипләнеп өлгергән тәгәрмәчләр, теләр-теләмәс кенә, урыннарыннан кузгалдылар, һәм арба каты җиргә менеп тә утырды.

Без шатланып кычкырып җибәрдек.

Бераз хәл алгач, без кузгалып киткәндә көн тәмам яктырган иде инде.

Бер атна күрми торган арада, урман шактый үзгәргән кебек тоелды. Агачлар саргайганнар, картайганнар сыман. Үләннәр шиңеп, шәлперәеп җиргә иелгәннәр. Кәүсәләренә укалы балдак кигән елан гөмбәләре генә ишле булып куак төпләренә дә, ачыклыкларга да сырышканнар. Кызарып, янып эт җиләге пешеп утыра. Ашый торган нәрсә булсалар, бу кадәрле үк уңмаслар иде, хәерсезләр. Мин ачуымнан берничә гөмбәне тибеп тә җибәрдем. Аның эшләпәсе астында гомер кичергән вак кырмыскаларны күреп кенә, тими башладым, кырмыскаларны кызгандым. Әйдә, корыда рәхәтләнеп яшәсеннәр!

Урман юлының калган өлешен без шактый шома үттек. Төп башына эләгеп Әкмәлнең чәкүшкәсе сынуын искә алмаганда, әллә ни әйтерлек вакыйга да булмады шикелле. Әмма Тугай суын — без урманның яртысы дип йөртә торган үзәнне үтүгә, атлар тәмам хәлдән тайдылар.

Үзебез дә ардык. Тик арган атлар янында үзеңнең көчсезлегеңне һич тә белдерергә ярамый. Ат шундый сизгер ул, аның белән шаярма! Һәм без тамакларыбыз карлыкса да, гайрәтләнергә, гаярьләнергә, һай-һай дип тавыш күтәрергә, сызгырырга, кыскасы, атка көч биреп барырга тиеш идек. Әле болай да алар, бер җир буе баралар да, туктыйлар. Чакрым исәбен югалтмасак та, вакыт исәбе күптән югалды, иртәме, кичме икәнен оныттык инде без.

Тизрәк урманны чыгасы иде дә, урман авызындагы аланга атларны җибәреп, ут ягасы, ашап-эчеп аласы иде. Мин юл буендагы карт имәнгә карыйм. Аның кәүсәсе әкиятләрдәге батырдай дәү, юан, кабыгы тубырланып беткән. Киң ябалдашы белән ярты күкне каплап тора. Мин бу имәннән соң, урман чыкканчы тагын нихәтле юл калганлыгын хәтерләргә тырышам. Алпан-тилпән килеп алдан баручы Барый да чыбыркы сабы белән изәп имәнгә ишарәли, күрдеңме, янәсе. Күрдем инде, күрдем, күрмәсәм әйбәтрәк тә булыр иде. Тагын ике чакрым барасы бар әле. Имәнне үткәч, чит-читенә шомырт агачлары үскән кечкенә генә, түгәрәк кенә аланга чыгабыз. Сугышка кадәр яшь наратлар утыртылган бу алан хәзер сарут, күзлут, алабута һәм саргайган кыяк үләннәр белән

күмелеп калган. Берән-сәрән генә утырган нарат үсентеләре һаман бирешмәгәннәр әле, тереклек итеп азапланалар. Наратлар булгач аланның печәнен чаптырмыйлар. Үткән-сүткән юлаучылар гына анда бер кишәрлек, монда бер уйдык табып, арба төбенә салып киткәлиләр.

Аланны үтүгә, атлар тагын туктадылар. Мин, Барый янына килеп:

— Тугарып, бер ашатабызмы әллә? — дидем.

Барыйның эчкә баткан, йокысызлыктан кызарган күзләрендә ниндидер бер очкын кабынган кебек булды.

— Миңа калса, хәзер үк шушында ятып үләр идем,— диде ул,— карын ачты, ардым, йокы килә, баш авырта, эч авырта, җеп өзәр хәлем юк, билләһи.

Вакыйф белән Әкмәл дә безнең янга килделәр. Әкмәл, безнең тукталырга теләгебез барын белгәч, ак кашларын җыерып, зурларча уйланып торды. Бер болытлар агылган соры күккә, бер юлга карап алды, башын чайкады:

— Ярамый. Барган шәпкә барырга тырышыйк инде. Бер тукталгач, кузгалу кыен булыр. Өстән яумаганда урманны чыгып калыйк. Аннары ничек тә Куян авылына кадәр тырышырбыз. Куян авылыннан соң таш юл. Караңгыга калсак та, куркыныч түгел.

Аның сүзе белән килешмичә булмый инде. Ничек кенә арган булсак та, урман уртасында ат ашатканыбыз юк иде әле безнең. Кузгалырга, кыен булса да, урманны үтмичә тукталмаска дип таралыштык.

Атлар да безнең теләкне сизгән сыман, яхшы ук күндәм атлый башладылар. Без тагын аларга иярдек. Кичә көлтә кертергә барганда әнкәй кесәмә салган төче катлама хәтеремә килде. Яшен тизлеге белән кесәмә тыгылдым һәм ярты уч чамасы күмәч валчыгы җыеп чыгардым. Күземне йомып катлама валчыкларын тел өстенә салып җибәрдем. Катламадан да тәмле әйбер бар микән дөньяда! Ул бүген миңа салкын каз итеннән дә тәмлерәк тоелды. Тагын юкмы икән дип башка кесәләремне дә караштырдым. Берсеннән ит налогын түләү турында квитанция (әнкәйгә бирергә онытылган), икенчесеннән чиккән кулъяулык (сугышка киткән абыйның иске чалбары кесәсеннән тапкан идем), чакматашы килеп чыкты. Әмма катлама юк иде.

Чама белән урман кырыена ерак та калмый дип барганда, Әкмәл кинәт кычкырып җибәрде.

— Кыр күркәсе!

Кычкырып та җибәрде, балтасын эләктереп, йөгереп куаклыкка кереп тә китте. Чыннан да, чикләвек чыбыклары арасыннан олы гәүдәле, чуп-чуар бер кош йөгерә, аның артыннан җан-фәрманга Әкмәл томыла иде.

Кыр күркәсе! Шәп булыр иде үзен тотып алсаң! Безнең ару да, ачыгу да онытылды, дилбегәләребезне ыргыттык та Әкмәл артыннан чатыр-чотыр чаба башладык. Ботакка эләгеп чалбарым ертылды, битләрем сыдырылып бетте. Берни күрмим, алдымда ялт-йолт чагылып киткән Әкмәлне тизрәк куып җитәсем һәм күркәне үземнең тотып аласым килә. Менә күркә ачыклыкка чыкты да аршын ярымлы канатларын җилпеп, күккә күтәрелде, очып та китте. Күркә дигәнебезнең, «трыйлик» дип соңгы сәламен биргәч кенә, гап-гади бер торна икәнлегенә төшендек. Сулуларыбыз кабынып, Әкмәл янына җыйналдык. Әмма ул безне күрми дә иде. Аның аучылык дәрте кузгалган, зәңгәр күзләре кысылып ут булып яна, ак кашлары өстенә учын куеп, һаман өзелеп-өзелеп торнага карап тора иде. Торна урманны яңгыратып тагын аваз салды. Әкмәлнең кайнарланып киңәйгән алсу борын яфрагына эләгеп торган тир бөртекләре дерелдәп киттеләр.

Без барыбыз да аннан көлә башладык. Ә ул һаман күккә текәлгән килеш:

— Ну бер сыйлый идем үзегезне! Буксәләрегез кап булганчы ашата идем,— диде.

— Кыр күркәсе, имеш.

— Әй йөгергән була, әй балтасын селтәгән була.

— Төпкә абынмаган булсам, кояштыр, куып җитә идем үзен!

— Җитә идең! Менә мин элек күргән булсам, ычкындырмас идем. Юлына төшәргә, ачыклыкка чыгармаска кирәк иде аны,— диде Вакыйф.

— Очып китәр дип кем белгән аны? Мин күркә дип торам бит.

— Ә кыр күркәсе буламы, малайлар?

Бусын беребез дә белми идек.

Арбалар ягына борылдык. Күңелләребез ачылып киткән, аруларыбыз онытылгандай булды, юеш, ябышмак сәрдәләрне яра-яра барабыз. Йөгергәндә сизмәсәк тә, юлдан шактый ерагайганбыз икән. Бара торгач Әкмәл кесәсен капшап карады.

— Чакма тимерен төшереп калдырганмын,— диде ул, каушап.

Чакматашы — ул чакта авыл халкы арасында «Катюша» дип исем алган әйбер — безнең кебек шәбәргән һәм күшеккән юлчылар өчен иң кирәк нәрсә. Ташы таш инде аның, бер җирдә булмаса, икенче җирдән табыла, менә тимере генә... Үткер кырлы чуерташка бәрә-бәрә шомарып беткән, тимерчеләр, иске чалгы бизен бөгеп, суга-

рып, чыныктырып биргән корыч кисәген югалту — бу бөтен юл буена утсыз-учаксыз калу дигән сүз. Дүртебезнең дә торна куып җәелгән авызларыбыз кинәт чалышаеп китте.

Торна куган өчен Әкмәлне әле генә шаярткан булсак, хәзер чын-чынлап әрли башладык. Ул, ак керфекләрен челт-челт йомып, эчкерсез зәңгәр күзләре белән безгә карарга оялып, мескенләнеп калды.

— Үзем теләп югалтмадым мин аны, кесәдән сикереп төшкәндер. Әрләүдән файда юк, эзләп карыйк,— диде ул.

Торна очып киткән аланга яңадан барып, эз белән кире кайтырга булдык. Дүртебез дә килгән юлны мүкәләп диярлек әрле-бирле үтсәк тә, җир мае дип аталган сасы исле, агулы гөмбәдән, ике тузгактан һәм кипшерә башлаган бер-ике бөрлегәннән башка берни дә тапмадык.

Юлга чыкканда барыбыз да ачулы идек.

Күркә, чакма тимере белән мавыгып, без атларны хәтердән дә чыгарып җибәргәнбез. Юл өстендә, үзебезнең йөкләр янында, җиңел генә такта арбага җигелгән, ару гына көрлектәге тимер-күк айгырны күргәч, без гаҗәпләнеп киттек. Кем булыр икән бу? Бер мәлгә айгырның хуҗасын, Әкмәл арбасы янына килеп, чыбылдыкның бер башын чишеп маташучы хатынны да күрми тордык. Хатын үзе безне бик тиз күреп алды, яшен тизлеге белән кыска, юан бармакларын чыбылдыктан ычкындырды, бур мәченеке кебек сыгылган карсак гәүдәсен кинәт турайтты. Яшелле-зәңгәрле утлар уйнаган итләч кабаклы кеч кенә күзләрендә елмаюга охшаган бер нәрсә күренде.

Көпә-көндез булган бу эштән хәйран калып, телләребезне йоттык та басып тора идек, кинәт барыбыз да берьюлы исебезгә килдек, Әкмәл очып диярлек арбасы янына барып җитте. Хатын хәйләкәр генә елмая иде.

— Син монда нишлисең? — диде Әкмәл, ярсып.

— Әллә күрмисеңме? Басып торам,— диде хатын, борчылу галәмәте күрсәтмичә.

— Әле генә нишләдең?

— Минме? Иа Ходай! Нишләдең, имеш. Беләсең килмәени? Үзегез монда булсагыз, йөгегездә нәрсә дип сораган булыр идем. Көттем, көттем дә, берегез дә күренмәгәч, үзем ачып карадым. Бодай алып барасыз икән.

Хатынның тавышы матур иде. Ул, үз тавышына колак сала-сала, җырлаган кебек итеп сузып сөйли. Күзләре белән ашардай булып әле беребезгә, әле икенчебезгә карый.

Миңа бик уңайсыз булып китте. «Кыр күркәсе, имеш,

бер йөк бодаеңны төяп киткән булсалар, күрер идең күркәңне!» дип уйладым мин. Әкмәл, ачуыннан буыла язып, йөкнең ачылып калган өлешен чыбылдыгы белән каплады.

— Ә бодай булса нәрсә булган?

Хатын аңа җавап бирмәде. Күз алмаларын уйнатып:

— Сез Караталдан, ахры? — диде.

— Караталдан булсак, һәрбер үткән-сүткәнгә безнең йөкне ачып карарга ярый дип беләсеңме? — дип кызды Әкмәл.

— Ай Алла! Нәрсәгә орышынасың? Мин бит, мондый чибәр егетләр Караталда гына булса булыр, димәкче идем. Яшь чагымда Караталда егетем бар иде әле. Вәдүтне беләсезме?

Вәдүт Барыйның абыйсы иде. Моны ишеткәч, хатын бөтенләй ачылып китте, безне бик кызганды, юеш киемнәребезне тотып карады. Симез үрдәкне хәтерләткән бу хатында күңелгә йогышсыз ниндидер бер нәрсә бар иде.

Вакыйф:

— Күркәдән үрдәккә каптык,— дип астыртын гына көлеп тә алды.

Хатынның жәлләп әйткән тәмле сүзләре күңелне бераз йомшартса да, арба төбендәге букчасыннан зур гына түтәрәм каз ите тартып чыгаргач, ул безне сагаерга мәҗбүр итте. Хатын каз итен безгә күрсәтә-күрсәтә:

— Майлары тамып тора! Эчегезгә салкын төшеп беткәндер инде сезнең, балакайлар. Ашап алсагыз, җылынып китәрсез. Менә. Бигрәк нык интеккәнсез шул, бичаралар. Апамнарга күчтәнәчкә дип алган идем. Әйдә, сез ашагыз, шундый яхшы егетләргә жәл түгел! — дип сөйләнде.

Без, төкерекләребезне йота-йота, каз итеннән баш тартык.

— Түләргә акчабыз юк,— дидек.

— Кая ул!

Акча сүзен ишеткәч, хатынның күз алмалары тагын уйнаклый башлады. Ул букчасыннан изелеп, майланып беткән бер төргәк иллелекләр, йөзлекләр тартып чыгарды:

— Нигә миңа акча? Акча безнең үзебездә дә бер букча. Мин үзем сезгә акча бирәм әле...— Бу урында хатын як-ягына каранып алды.— Ә сез миңа бераз гына...— Ул йөкләргә ымлап күрсәтте.

— Нәрсә, бодаймы? Безнең бодаебыз юк,— дидем мин.

— Ә йөгегездә?

— Ул бит дәүләткә дигән.

— Мин дә чит илдән, Әмерикәдән килмәгән ләбаса. Үз кешегез! Мин сезгә бик күп акча бирермен. Урман

аулак, эт тә юк. Арбама бер-ике капчык саласыз да, мин сезне белмим, сез мине белмисез.

Хатын арбасындагы печән астыннан ике зур-зур кычыткан капчык чыгарды.

Без бу оятсызлыктан исебез китеп дәшми тора идек. Хатын ашыктыра ук башлады:

— Йә, нәрсә җебедегез? Акчалы буласыгыз килмиме әллә? Потын ничәшәрдән куясыз?

— Юк ла, нәрсә сатулашасың, сатлык бодай юк дип әйттем ич инде,— диде Әкмәл.

Хатынның маңгаена ике тирән сызык ятты:

— Авызыгызга чәйнәп каптырганны йотарга теләмисезме? Мин сезне егет малайлар дип торам. Сез яшелләр икән әле!

Бусы инде чиктән ашты. Без бердәм ачулана, шаулаша башладык.

— Кузгалдык әйдә, аның әкияте бетмәс. Бодай... Тотмыйсыңмы капчыгыңны!

— Бирсәң, капчыгын тоткан инде ул!

— Оста икән!

Ачулану белән эшнең барып чыкмаячагына төшенде хатын. Ул, капчыкларын арбасына кире ыргытып, минем янга килде. Без, атларыбыз янына таралышып, кузгалырга тора идек. Чит арбага рөхсәтсез тыгылганы өчен ул хатынны бик каты ачуланырга теләсәк тә, үз гаебебезне тою безне сабырландыра һәм тиктомалга гына җәнҗал да күтәрәсебез килми иде. Йөкләрне үзебез караусыз калдырдык бит!

Хатын, миңа якын ук килеп, серле кыяфәт белән:

— Бәлки, акча сиңа кирәктер. Атың иң артта бит. Бербер сәбәп табып кал. Ике капчык бодайны иптәшләрең дә сизмәс,— дип сөйләнергә кереште.

— Юк, юк, апа, сорама да, үгетләмә дә.

— Менә җүләр!

Ачуым килеп кычкырып җибәрдем:

— Вакыйф, шайтан, кузгал! Нәрсә баттың анда.

Хатын һаман китмәде. Аның яшькелт күзләре ут булып яна иде.

— Кал инде!

— Кала алмыйм! Күрәсеңме, без дүртәү! Без бер-беребездән калмыйбыз.

Хатын, ачуына тулышып, юлда басып калды.

Бераз киткәч кылт итеп исемә чакма тимере килеп төште.

— Әй, апа, шырпың юкмы синең?

Хатынның чыраена мыскыллы елмаю чыкты.

— Шырпы? Нигә булмасын? Менә сезгә шырпы! — дип, ул итләч йодрыгын селкеде.

— Тапты шырпы сорар кеше,— дип сукранды Барый.

Тагын лай ярып, сүрән чырай белән алга атладык. Атларның корсаклары тагын да шиңеп, алар тагын да ябыграк, кечкенәрәк булып калдылар.

Һәркем беравык үз уйлары белән генә барды. Бераздан Әкмәл түзмәде, җыелышта чыгыш ясагандай кычкырып, кулларын бутый-бутый:

— Мин бу хатынны беләм! Чокырлы авылыннан. Анда алар берничә хатын «ит комбинаты» оештырганнар. Төнлә тавыклар, сарыклар урлап суялар икән дә көндезен алыпсатып йөриләр икән,— диде.

Хатынга ачуланасы урынга ни өчендер Әкмәлнең үзен тиргисе килде. Беләм, имеш, тагын азрак күркә куып йөрсәң, бер йөк бодаең квитанциясез-нисез генә «ит комбинатына» китәр иде.

Беребездә дә ут булмау эчне бик пошыра иде. Мондый әшәке юеш көндә утың да булмаса, юлда йөрмә инде син!

Мин кемнең дә булса очравын тели башладым. Йә берәрсе куып җитәр, йә каршы очрар дип артка да, алга да караштырып барам. Әмма кырыйлары алтынсыман яфраклы чикләвек агачлары белән шыпланган кечкенә, аулак урман юлында без һаман дүртәү генә. Ерактан кыр тавыгы гөлдердәгән тавыш килде. Мин исемнәрен белми торган бик күп кошлар чыркылдаштылар. Шушы җиде чакрымлы урманны үткәнче, мин беренче мәртәбә кошлар барын абайладым. Моңарчы аларның барлыгы да сизелмәгән, тавышлары да ишетелмәгән иде.

Ниһаять, кыр күренде. Малайлар «ура» кычкырып йөгереп киттеләр. Арбалар да ягымлырак шыгырдый башлады, атлар да җитезрәк атладылар. Без, артык җәфа күрмичә, исән-сау килеш урманны чыктык. Туктарга, атларны ял иттерергә, күптән корсакны кытыклап барган бәрәңге белән исәп-хисапны өзәргә мөмкинлек булачак.

Карыныбыз бик ачса да, иске гадәт буенча, урманны чыкканчы ашау юк иде. Урман үзебезнеке, үз өеңнән чыгып җитмәс борын ашарга тотыну — бу әйбәт эш түгел. Димәк, сине өеңнән кадерсезләп, ашатмыйча җибәргәннәр була.

Күңелемә тагын өй, кечкенә энемнең быел яз көне: «Их, җилпуч, җилпуч, оның да бетте, кая барырсың?» дигән сүзләре искә төште. Җилпуч кече як стенасында — эленеп тора да тора. Әмма без ач корсакларыбызны күтәреп һаман йөрибез, һаман барабыз.

Монда чит авылның билчән баскан кырлары. Димәк,

син үз өеңдә түгел, чит җирдә. Ашасаң да өйне кадерсезләү булмый.

Арбаларны урман авызындагы аланлыкта янәшә куеп, атларны тугарып, тышаулап җибәргәч, үзебез нишләргә белми аптырап калдык. Башка вакытларда тизрәк корысары җыештырып учак яндырып җибәрә, көлдә бәрәңге пешерә идек. Учак янында бәрәңге генә түгел, сүзләр дә тәмле була.

Вакыйфның йөге өстеннән иске кожанын алып җиргә җәйдек — бусы табын һәм ашъяулык булды. Иң тәмле, иң затлы сыйлардан булган бәрәңге белән ипине уртага куйдык. Сөйләшүләр, шаярулар бетте.

Без, игенченең борыны белән җир сөреп чәчкән, тырнагы белән җир тырнап үстергән изге икмәкне ничек олылавын күреп үскәнгәме, икмәк алга килгәч, берьюлы олыланып, җитдиләнеп киттек.

Их, тоз да булса! Тик тоз юк иде. Әле аяк асты коры торганда авыл хатыннары пристаньга барган чакта, кеч-кенә янчыкларга салгалап булса да, тоз алып кайталар иде. Бу арада ул эш өзелеп торганга, без барыбыз да юлга тозсыз чыккан идек.

Авыз тутырып ипи белән бәрәңге чәйнәгәндә тозның юклыгы әллә ни сизелми сизелүен. Бәрәңгене дә әрчеп тору юк, чалбар балагына ышкып, көлен генә кагып төшерәсең дә, әйдә аша!

Ажгырып торган дүрт малайга бәрәңге җитәме соң? Рәхәтлек тиз бетте. Ипинең бер өлешен генә ашадык. Әле алда олы юл ята, озак барасы бар әле.

Бераз ял итеп алгач, якындагы елгага алып төшеп, атларны сугардык. Әллә үлән бик чыклы булганга, алар аз эчтеләр. Үзебез исә су буенда рәхәтләндек, бит-кулларыбызны юып алдык, тәмам кеше төсенә кердек. Әгәр атлар армаган булса, кузгалырга да каршы килмәс кебек идек. Арбалар янына кайтып чүмәшкәч, арганлык үзенекен сиздерде тагын. Ботлар сызлый, тез башлары авырта, иң әшәкесе, үтереп-үтереп йокы килә. Янган учак янында утка аркан ятып, озак, бик озак итеп йоклыйсы иде!

Мин, күзләрем йомылса да, сер бирмәскә тырышып, йөреп килгән булдым. Ерак түгел аланда утлаган бахбайларга дәштем. Үзем атлыйм, үземнең бер аягым тирән чокырга төшеп киткән кебек була. Иптәшләр дә утырган җирдән авып-түнеп китәләр иде.

— Болай булмый, малайлар, атлар ашаганчы бәләкәй генә черем итми ярамас,— дидем мин.

— Ә йөкләр? — дип сорады Әкмәл, күзләрен йодрыгы белән уа-уа.

— Көне авыр бүген, елак көн. Югыйсә минем дүрт көн йокламыйча юлда барганым бар,— дип киерелде Вакыйф.

— Йокларне чиратлап саклрбыз. Без Барый белән, сез икәү.

— Тотышабызмы?

— Тотышабыз.

Вакыйфның чыбыркы сабын тотыша башлыйбыз.

— Очка чыккан — иптәше белән алдан йоклый.

Вакыйф очка чыкты. Барый, ачуланып:

— Син чыбыркыңны чамалап куйгансың! Хәрәм бу, хәрәмләү! Яңадан тотышабыз,— дип кычкырып караса да, булмады.

Без, йоклап китмәс өчен, аягүрә басабыз. Әкмәл белән Вакыйф, бишмәтләренә төренеп, җылырак булсын дип аркаларын аркага терәп, арба астына тәгәриләр.

Әйе, көн салынкы шул бүген, күк йөзе һаман ачылмый. Куе төтенгә охшаган саргылт болытлар көзге тут төшкән урман өстендә тияр-тимәс кенә йөзәләр. Җил дә бар югыйсә, тик ул да болытларны сөреп алып китми, безнең түбәдә генә болгандырып йөртә. Ялтырап бер кояш чыкса соң инде! Бар да җанланыр иде: урман да, үләннәр дә, юл да. Без дә канатланыр идек. Шул болытларны да җиңә алмаган җил белән кояшка ачу килә.

Барый мыгырданып Вакыйфны сүгә, гомере буе хәрәмләп яшәде, дип зарлана. Үзенең күзләре йомык.

— Барый! — дим мин аңа.— Йөкләрне үзем карармын, әйдә син дә йокла!

Ул миңа ышанмыйча, бер-бер хәйлә юкмы монда дигәндәй, сәерсенеп карый. Аннары елмаеп җиргә тәгәри һәм шунда ук йокыга китә.

Мин атларны карап килдем, бөрлегән эзләдем, ләкин таба алмадым. Дөресен әйткәндә, чын-чынлап эзләмәдем дә, иелергә, җентекләп карарга да иренә идем. Иптәшләр янына килеп, арба өстенә менеп утырдым. Күзләрем йомыла башлагач, күңелгә килгән бер көйне сызгырырга тотындым. Җыр да шыңшып карадым. Әмма арганлык үзенекен иткән: мин арба өстенә авып төшкәнмен һәм изелеп йокыга киткәнмен...

Күпме йоклаганмындыр, белмим, берәү бик каты төрткәли башлагач, уянып киттем. Уянсам — каршымда Әкмәл тора. Ул каяндыр йөгереп килгәнгә охшый, борын тишекләре әрлән чокыры кебек киңәйгән, күзләре зур булып ачылган, үзе сүзен дә әйтә алмыйча мыш-мыш тын алып тора.

Менә ул мине бик кызганган төс белән, башкаларны да уятырга курыккандай, шыпырт кына:

— Озын ялың баткан...— дип пышылдады.

Йөрәгем жу итеп китте. Арбадан сикереп төшүемне дә, Әкмәлне чак кына төртеп екмый калуымны да хәтерләмим. Йөрәктән чыккан әрнүле аваз белән:

— Чынмы?! — дип кычкырып җибәрдем.

Әкмәл артык бер сүз дә әйтмәде, ияген генә кагып куйды. Мин аның киң ачылган күзләренә, дерелдәп торган авыз читләренә карап, коточкыч бер бәхетсезлеккә дучар булуымны аңлап алдым.

Кулыма ничек, каян эләккәндер, белмим, Әкмәл белән урман буйлап чабып барганда гына дилбегә тотып йөгерүемне абайладым.

Җәй башындарак чабылып, яңгырлар белән күпереп киткән курпы каплаган ямь-яшел аланда өч ат утлап йөри. Һәммәсенең дә тышавы бар. Чатор-чотыр чабып чыгуыбызга, алар ашауларыннан туктап, шомраеп, сагаеп калдылар. Минем Озын ялым гына юк. Йөрәгем урыныннан чыгардай булып тибә башлады. Күз алларым караңгыланды. Ялгыш Әкмәлнең үкчәсенә басканмын икән, ул куак арасына мәтәлеп китте. Башка вакыт булса ачуланыр да иде, бүген дәшмәде, егылган урынына чырт иттереп бер төкерде дә тагын чаба башлады.

Без үзәнлеккә төшә идек. Бу үзәнлектә Чуал суы дигән кечкенә генә инеш ага. Сугышка кадәр аның берничә җиренә буалар, күлләр ясап мунчала төшерергә кабык салалар иде. Яңгырлар башланса, иске чокырларга су тула, ярлары җеби, йомшара һәм тәкәрлек оялары, бәләкәй түмгәкләр белән капланган бу үзән бака ефәгенә киенгән быкырдык сазлыкка әйләнә иде. Озын ял, мөгаен, шунда барып эләккәндер. Ләкин ничек? Тышавын салды микәнни? Өзеп киткәндер дип уйламадым, сүстән ишкән өр-яңа дип әйтерлек аркан белән тышаулаган идем.

Әкмәл белән бер сүз дә сөйләшмибез, ул чаба, мин чабам. Йә ул узып китә, йә мин алга чыгам. Яфрак белән капланган су ятмаларының күзенә генә басабыз. Андый урыннар барган саен ешрак очрый башлады, без юлдан чыктык. Түмгәктән түмгәккә сикереп, бер кырыйга чыгабыз. Ничек монда кергән ул, ничек кергән?!

Түмгәк кырыйларында кәкре-бөкре кәрлә каеннар үсеп утыра. Зирек, тал куаклары арасыннан боргаланып-боргаланып Чуал ага.

Озын ял ярдан ерак та түгел, кайчандыр күл булып, хәзер кыяк үлән үскән чокырга кереп баткан иде. Аның аяклары бөтенләй күренми, корсагы җиргә җитеп терәлгән, су салкыныннан янбашлары тартышып, дерелдәп китә. Корсагы суырылып эчкә кергән, пычранган, бичаракай.

— Менә,— диде Әкмәл, килеп җиткәч.

Кызгануым бер генә минутка ачу белән алышынды.

— Ни пычагыма монда килеп кердең син? — дип кычкырып җибәрдем. Озын ялымны кулларым талганчы кыйныйсым, үч аласым килде.

— Уянып китсәм, барыгыз да йоклап ятасыз. Йөкләр дә урынында, сбруйлар да. Чаптым атлар янына. Барсам, синең ат юк. Бер кырыйда тышау ята. Төшергән ул аны,— диде Әкмәл.

Мин елап җибәрдем:

— Башымның бетүләре шушы юлларда булган икән!

Әкмәл мине юатырга тотынды. Елаудан файда юклыгын мин үзем дә яхшы белә идем, ләкин нишләргә?

— Малайларны җыеп киләм дә, тартабыз да чыгарабыз аны,— диде Әкмәл.

Ул китте, мин ат янында ялгыз калдым.

Берәр кеше читкә китеп үлсә, туфрагы тарткан, диләр. Шуның кебек Озын ялны да бу сазлык тарткан булса, ул үлсә... Бүгенге минем йөкне малайларга бүлеп салырбыз. Ә иртәгә? Ә берсекөнгә? Ат бәясен кем түләр? Әткәй кайтуына дип саклап торкан кәҗә бәрәнен бирербез инде. Тагын ни бирербез? Әнкәй ни әйтер, кешеләр нәрсә диярләр? Фәхри абый, Нурҗиһан апалар, үзе йоклап ятып, атын батырып үтергән, диярләрме?

Нишләргә инде, нишләргә?

Атның койрыгыннан тартып та, куалап та карадым, чыбык белән суктым. Суккан саен аның арт саны дерелдәп куя. Үзе, «син нишлисең, күрмисеңмени, мин болай да интегәм» дигәндәй, акыллы күзләрен мөлдерәтеп миңа карый иде.

Озакламый дилбегәләр, баулар тотып, Әкмәл белән Барый да килеп җитте.

— Вакыйф кайда? — дип сорадым мин.

— Килми,— диде Әкмәл, күңелсез генә.

— Нигә?

— Арбаларны кешесез калдырмыйм, авызы белән кош тотып йөрмәсен,— ди. Сүгенә. Әй, аны... үзебез дә чыгарырбыз әле.

Барый, авызына бармагын кабып, исе китеп, басып тора. Әкмәл, чыгарабыз, ди. Ләкин ничек?

Өчебез дә ат янына барып тезелдек. Мин Вакыйфка булган ачуымны малайларга сиздермәм дигән идем. Түзә алмадым, эшнең өметсез, үзебезнең көчсез икәнлегебезне күрү белән Вакыйфны тирги башладым.

— Сүгенеп эш чыкмас, малайлар,— диде Әкмәл бераздан,— дилбегәләрне корсак астыннан үткәрик тә сөйрәп карыйк.

— Шулай да! Килсә ни булган инде!

— Үзенең дә күрәсе алда әле!
— Бир дилбегәңне.
— Астан керт...
— Суы салкын, малай...
Дилбегәне үткәрә алмыйча шактый азапландык. Балчык казый-казый тырнак асларыбыз канап бетте. Бишмәтләребезне салып ташласак та, тиргә баттык. Күлмәкләребез манма су булды. Озак маташа торгач, ал санны да, арт санны да тартырлык булсын дип, ат аяклары яныннан ике җирдән дилбегә үткәрдек.
Бау үткәргәнче, җегәрле генә, җитез генә кыланган идек, соңра гайрәтебез шиңде дә куйды. Чөнки бездә атны тартып чыгару түгел, кузгатырлык та көч калмаган иде. Авыр да соң үз көчсезлегеңне тою!
Ә ат аның саен тирәнрәк баткан кебек, аның дерелдәп китүләре өзлексез калтырауга әйләнде. Менә ул башын түмгәккә куйды, күзләрен йомды.
— Үлә бит инде, үлә!
— Үлүен үлмәс, шулай да озак яткырырга ярамас, үпкәсе шешә диләр аның.
— Үпкәсе шешсә, үлде дигән сүз инде ул. Әллә котылыр дисеңме?
Нишләргә? Мин малайларга карыйм, алар миңа. Җитмәсә тагын яңгыр сибәләргә тотынды. Әллә нинди ямьсез болытлар, безне үчекләгәндәй, болганып, бөтерелеп баш очыбызда гына актылар. Яныбыздагы зирек куагы моңлы гына шыбырдарга тотынды. Дөнья шулкадәр ямьсез, шулкадәр өметсез иде минем өчен, карашымны кая юнәлтергә белмичә күзләремне чытырдатып йомдым. Күз яшем яңгыр суы белән кушылып акканга, малайлар елавымны сизмәделәр дә. Сизсәләр дә ни файда?.. Йә, ярый, кызгандылар, ди. Кызгануларга да, юатуларга да мохтаҗ түгел идем мин ул вакытта. Миңа ярдәм генә кирәк иде. Ярдәм кулын суза алмаган шыксыз дөньяны, мәлҗерәп киткән йокы капчыгы үземне каргарга дип авызымны ачыйм дисәм, урман ягыннан акрын гына атлап килүче бер картны күрдем.
Ул, капчыкка төргән озынча әйберен күкрәгенә кысып, мәзәк кенә итеп, түмгәктән түмгәккә сикерә. Сикерә дә туктый, катырак, корырак урынны сайлап каранып тора. Тагын сикерә-сикерә безгә якыная иде. Кулындагы әйберен бик кадерләп тотуын абайлап мин, тагын сәүдәгәрдер инде, бодайга алыштыру өчен берәр нәрсә алып киләдер дип уйладым. Якыная башлагач мин аның аксак икәнлеген һәм киң, җәлпәк борынына кысасы тузып, җеп белән уратылып беткән күзлек элгән булуын күреп алдым.

Без, ул килеп җиткәнче, бер сүз дә эндәшмәдек. Килүче алтмыш яшьләрдәге, кырыс, түгәрәк йөзле, яргаланып беткән иренле, сирәк кенә ак сакаллы, ямьсез генә бер карт иде. Ул томанлы пыялалар астына качкан усал күзләре белән иң элек атны карый башлады, оядагы ана каз кебек, баскан урынында таптанып алды. Аннан соң гына безгә күтәрелеп:

— Батырдыгызмы? — дип сорады.

Тавышы бераз карлыккан булса да, шактый нык һәм ачулы иде картның. Безнең йомык авызларыбызга карый-карый ул кулындагы озынча төенен зирек куагы төбенә илтеп куйды.

Козырегы җебеп, чалышаеп беткән киң читле фуражкасы белән маңгаен сөртә-сөртә:

— Йә, нишләргә уйлыйсыз? — диде.

— Белмибез,— дип мыгырдандык без куркып кына. Аның күзләре ачулы ялтырап киттеләр.

— Ә, белмисезме? Батыра белгәнсез, чыгара белмисезме?

— Бабай, ул үзе баткан.

— Карап торалар аны, батырмыйлар. Уңмаган киленнең бәлеше кебек изелеп, йоклап ятмыйлар.

Карт Вакыйф янында булган, безнең хәлләрне ишеткәч, монда килгән икән. Без сөенеп киттек.

— Йә, миңа үпкәләп, борыннарыгызны салындырмагыз. Чыгару әмәлен табарга кирәк. Дөньяда төрле хәлләр очрый. Тик уяу булырга, чамалап йөрергә кирәк.

— Без чамалаган идек тә...

— Чамагыз чамага туры килмәдеме? — Картның йөзе искиткеч җитдиләнде, ул безнең барлыкны да оныткандай, томанлы күзлеге белән әллә кайларга карый-карый бер читкә китте. Чабата үкчәсе белән җиргә тибә-тибә нидер караштыра башлады. Тал чыбыгы сындырып алып, берничә урынга төртеп-төртеп үтте. Әле бер якка, әле икенче якка чыкты. Күккә күтәрелеп карады. Ниһаять, бер урында таптанып уйга батып торды. Аның яргаланган иреннәре кыймылдадылар. Карт көйләгән кебек сузып кына:

Алай икән, алай икән...
Самовары калай икән...
Борыннары җиз икән...
Сөйләшүе тиз икән...—

дип шыңшып алды да, безгә борылды:

— Кайсыгызның аты?

— Минем ат,— дидем мин.

Карт, Әкмәл белән Барыйга ишарәләп:

— Алайса сез икегез дә барыгыз, үз атларыгызны җитәкләп монда килегез,— диде.— Малайлар бер-берсенә карашып алдылар.

— Әйдә, күп уйлап тормагыз. Әллә үзебез тартып чыгара алырбыз, дисезме? Булган бауларыгызны, дилбегәләрегезне дә әләктерегез. Йөгерегез.

— Безнең атлар да кереп батса, нишләрбез?

— Батмаслар,— диде карт, ышаныч белән.— Әнә тегеннән, куаклыктан әйләнеп үтәрсез. Анда юл сымак нәрсә бар. Шулай да абай булыгыз. Күзегез колак артында түгел, маңгаегызда булсын.

Малайлар киттеләр, без бабай белән икәү генә калдык.

Кинәт картның күзләре дымланган кебек булды. Ул, искиткеч ягымлы тавыш белән сөйләнә-сөйләнә, Озын ялның муенын сыйпый иде:

— Түз, хайван, түз! Ни күрсә дә ир башы белән ат башы күрә инде ул, түз! Озак интектермәбез.

— Тышавын салган,— дидем мин.

— Эчертмәгән булгансыздыр.

— Эчерткән идек.

— Алай икән, алай икән,— дия-дия, карт кесәсеннән икмәк кыерчыгы чыгарып, атның калтыранган иреннәре арасына көчләп диярлек тыкты. Озын ял икмәкне капкач, йотаргамы-йотмаскамы дигән сыман, бераз аптырап торды.

Карт миңа борылды:

— Туйдан кайтып киләм. Дусайга барган идем. Скрипкачы Хафиз булам мин. Ишеткәнең бармы?

Хафиз бабай турында ишеткән булмыйммы соң. Менә очрашу дисәң дә, очрашу! Мин аның калын иреннәренә, берьюлы ягымлыланып киткән йөзенә исем китеп карап торам.

— Солдат кайткан,— дип дәвам итте ул.— Килә алмас микән, дип чакыру җибәргәннәр. Өйләнгән, төнәгеп туе булды. Бүген үзен яңадан озаттык. Менә бит ул тормыш ничек була. Ә син алай дисең.

— Алай димим лә, Хафиз бабай.

— Димисең, алайса! Йә, ярар, борчылма, атыңны чыгарабыз да, чак кына йөртеп алырсың, кунарга да туры килмәгәе әле.

— Кичкә кадәр ял итәр әле.

Карт көлемсерәде, маңгаен җыерып офыкка күз салды, дәшмәде.

Без аның белән урын рәтли башладык. Малайларның атларын кая бастырып тарттырырга кирәклеген чамаладык, исәпләдек, хисапладык. Ул арада Барый белән Әкмәл дә, атларын җитәкләп, килеп җиттеләр.

— Нигә бик озак тордыгыз?

— Вакыйф дилбегәсен бирми торды, өздерәсез, ди.

Мин ачуымнан тешләремне кыстым. Ни әйтерсең бу Вакыйфның кыланышына! Гарьләнеп үләрсең!

Бауларны бәйләү һәм көйләү эшен Хафиз бабай башкарды. Ул шундый җитез хәрәкәтләнде ки, баулар, дилбегә очлары уйнап кына тордылар, без аның аксак икәнен дә, карт кеше икәнен дә онытып җибәрдек.

— Төенең катынша булмасын, нык булсын, егетләрски. Диңгез төене ясап җибәрсәң дә ярый...

Бауларны үз дигәнчә көйләп бетергәч, Хафиз бабай күзләре белән безнең өчебезне дә үлчәп карады да, Әкмәлгә тукталып:

— Син, энекәш, ике атның да нукталарыннан тот. Без көч биргәндә берьюлы тарттырырга тырыш. Кинәтләп бауларны өздермә,— диде.

— Ат башыннан Барый тотсын!

— Кем тотса да ярамыймыни?

— Минем көч күбрәк, күтәрешәсем килә.

— Әл-лә, көчле кеше килгән,— дип мыгырданды Барый.

Әкмәлгә ат башына барудан башка чара калмады.

Барый, Хафиз бабай һәм мин өзлексез калтырап ята торган, хәлсезләнгән Озын ялның койрыгына барып ябыштык.

— Хәере белән булсын, тотындык, егетләр.

Хафиз бабай чөңгереп атларга кузгалырга боерды. Без өчебез дә, кура җиләге төсенә кереп, муен тамырларыбызны тал чыбыгы юанлыгы кабартып, шаулашып тарта башладык. Озын ялның койрык төбе шытырдап китте. Атлар бар көчләренә тартылдылар, йомшак җирдә тояклары күренмәс булды. Әкмәл атын бәйләгән дилбегә, мунчалага кыл кушып ишкән булса да, өзелеп китте.

Барый ачуланып төкереп куйды.

— Булмады инде!

— Чү, чү, энекәш, кызма! — диде Хафиз бабай,— болай булгач булды инде, барып чыкты. Күрмәдегезмени, ат урыныннан кузгалды!

Дилбегәне ялгап тагын эшкә керештек. Кулбашларыбыз авыртканчы көчәндек. Кинәт Озын ял кымшанып куйды, селкенде, баулар кысуына ыңгырашып җибәрде, күзләре йомылды.

— Бара, бара-а! Һоп! Һоп!

Ниһаять, ат баткан урында болганчык әшәке су тулган дүрт чокыр гына калды. Малкаем дер-дер калтырап чирәмдә ята, без, ашыга-ашыга, борын буйлап тәгәрәгән тирләребезне сөртәбез.

Озын ял әле тора алмый.

— Суык йөгергән, мескенгә,— дип аңлатты Хафиз бабай.

Без дүртебез дә, берәр уч печән тотып, ат янына иелдек тә, аның тәнен уарга керештек. Озакламый атның дерелдәве кими төште, ул үрелеп үлән капкан булды. Минем эчкә җылы кереп китте. Сөенечемнән Хафиз бабайны үбәсем, кочаклыйсым килә иде. Ә ул бер кырыйга баскан да елмаеп тик тора. Сукно пинжәге астыннан бүселеп килеп чыккан зәңгәр сатин күлмәге пычранып беткән, тезләренә кабартма-кабартма булып лай ябышкан. Әллә юешлектән, әллә болай арып, нечкә, ябык бармаклары сизелер-сизелмәс кенә калтырыйлар иде.

— Әйдәкләп кара, энекәш, кузгалмасмы,— диде ул миңа.

Мин атымны әйдәкләдем, малайлар эткәли-төрткәли башладылар. Озын ял, яңа туган бозау кебек, авырлык белән генә аякларына басты, чайкалып китте. Егылмады, хәтта көчсез генә итеп кешнәп тә җибәрде.

Без Әкмәлләр килгән юлдан арбалар янына юнәлдек, Хафиз бабай озынча төргәген күкрәгенә кыса-кыса безгә иярде.

Без алҗыдык, безне көтә-көтә Вакыйф тагын да ыграк арган булып чыкты. Ул атын җигеп куйган, бишмәтен кигән һәм, кашларын җыерып, йөк өстендә утыра иде. Безгә кырын күзе белән карап алганның соңында ул:

— Чыгардыгызмыни, әйбәт булган,— дигән булды. Аннары чыбыркы сабы белән юлга күрсәтте:

— Әйдәгез, кузгалабыз.

Мин аптырап киттем. Ничек дию юк, хәл белешү юк, тот та кузгалабыз дип авыз күтәреп утыр!

Хафиз бабай хәлне аңлады булса кирәк, миңа сүз әйтергә дә ирек бирмичә:

— Ашыкма, энекәш. Шундый җайсыз эш килеп чыккан икән инде, кабаланудан мәгънә юк. Ашыкма, өлгерерсең, югыйсә кеше көлдерерсең! — диде.

Әкмәл белән Барый да картның сүзен куәтләделәр:

— Озын ял хәл алсын инде бераз.

— Юл да сарка төшсен.

Вакыйфның чырае һаман үзгәрмәде, ул һаман чыбыркы сабы белән уйнап:

— Сезнең белән юлга чыксаң, адәм көлкесенә калмый хәлең юк. Алтмыш чакрым юлны алты көн үтәрсең,— дип чырт иттереп җиргә төкерде.

Хафиз бабайның да йөзенә кырыслык чыкты.

— Әгәр үзеңнең атың баткан булса, ни әйтер идең икән син?

— Минеке батмас,— диде Вакыйф, горурланып,— мин үзем генә булсам әллә кайчан элеваторга барып җиткән булыр идем инде. Әле атлары бата, әле тәҗеләре өзелә, әле куркә куалар.

Әкмәл черелдәп кычкырып җибәрде:

— Үзең генә кит алай булгач! Нигә безгә ияреп йөрисең?

— Сезгә ияреп? Сез хәчтерүшләргә иярепме? Сез үзегез миннән башка бер адым да атларга куркасыз!

— Бик куркабыз инде.

— Мин булмасам сезгә ат та, икмәк тә ышандырып чыгармыйлар ич.

Малайлар чынлап торып кыздылар. Сөзешергә ниятләнгән яшь кәҗә тәкәләре сыман, бер-берсенә астан-астан гына карап, бөтен тамакларына кычкыралар иде.

— Җитәр, малайлар,— диде Хафиз бабай, нык тавыш белән.— Юкка талашасыз. Юлга чыккач, бер-береңне ташларга ярамый, ошамаганны сөйләмәгез.

— Ә мин китәм,— диде Вакыйф, нindидер масаючан кирелек белән.— Минем күләгәгә генә ышыкланып йөрмәсеннәр әле.

— Китеп кая хәтле барырсың икән?

— Абзар артына!

— Китсен, китсен...

— Китәм шул! Сез кузгалганчы әйләнеп тә кайтам.

Вакыйф соңгы сүзләрен аркалыгын күтәрә-күтәрә әйтте. Ул беркемгә дә карамыйча, арбасына менеп утырды да миңа борылып тупас кына:

— Бир накладнойны! — диде.

Дүрт йөк тә бер кәгазьгә язылып, ул кәгазь миндә саклана иде.

— Бирмим. Китәсең икән алдыңнан артың матур.

— Алдыңа-артыңа иске чабата,— дип өстәде Әкмәл. Вакыйф ачуыннан кып-кызыл булды. Ул кабарынды, иреннәрен кысты:

— Ә-ә, бирмисеңме? Мәлҗерәп йоклап ат үтерүеңне белерләр дип шүрлисеңме? Барыбер сөйләрмен.

Хафиз бабай өметсезләнеп кулын селтәде:

— Тыңлама шуны! Атыңны йөртеп кил. Аяклары язылсын.

Мин, Хафиз бабайны китә икән дип уйлап, аңа рәхмәт укырга тотындым:

— Бик рәхмәт инде сиңа, Хафиз бабай! Син булмасаң...

— Куйсана,— дип, ул мине бүлдерде.— Әле мин китмим. Әллә нәрсә арып торам. Бар, бар, атыңны йөрт! Җылынсын!

Вакыйф бездән шундый кискенлек көтмәгән иде, ахрысы. Ул, үпкәләгән бала төсле иреннәрен турсайтып, йөк өстендә утыра, бер дә кирәксезгә камчы сабы белән чабата мөгезенә суккалый иде. Элеваторга накладнойсыз баруның файдасы юклыгын ул яхшы белә. Ә бәлки, башка нәрсә аны тоткарлагандыр, ул кузгалырга базмады.

Мин атымның тезгененнән тотып, урман буеннан гына, үргә таба менеп киттем.

Уңайсыз иде миңа! Йоклап китүем өчен дә, атым батып никадәр алтын вакытны әрәм итүем өчен дә йөрәгем гарьләнеп, үрсәләнеп авырта иде. Бәхетсез юлларга чыкканмын икән дип борчыла идем. Шуңа күрә малайлар Вакыйф белән бәхәсләшкәндә мин катнашмадым да. Аның сүзләрендә хаклык та бар лабаса!

Дымлы үләннәр арасыннан, канатларын көчкә-көчкә генә хәрәкәтләндереп, хәтфә төсле зур бер күбәләк очып чыкты. Утырган җиреннән аны әллә ат куркыттымы, әллә үзе шундый бер саташкан нәрсә идеме, әмма аның шушындый шыксыз, елак көндә тереклек итеп маташуына сәерсендем. Ул каядыр очып китәргә җыена иде, ахрысы, талпынып-талпынып кузгалып китә, агачлар өстенә күтәрелә алмыйча бер-ике әйләнә дә, хәле бетеп, яңадан җиргә куна.

Җентекләбрәк карагач, күбәләкнең бөрчекле-бөрчекле хәтфә канатлары чит-читләреннән кителгән, чыланган булуын абайладым. Үзем дә шушы күбәләккә охшыймдыр, дигән уй башыма килеп китте. Бер мәлгә генә бугазыма күз яшьләрем килеп тыгылды.

Озын ял тернәкләнгән кебек күренә иде. Мин аны җитәкләдем дә йөкләр ягына юнәлдем.

Борыныма тәмле төтен исе килеп бәрелде. Коймак исе дә килгәндәй булды, иреннәремне ялап куйдым.

Карыйм, йөкләрдән ерак та түгел шактый зур учак яна. Малайларның тәмам авызы ерылган. Аякларын чишенеп ташлаганнар. Учак янындагы казыкларга эленгән чолгаулар, чабаталар, үкчәләренә кара ямау салынган ак йон оекбашлар парланып торалар.

Әллә кайчан киселеп, тамырлары череп беткән, кабыгы кубып кибә-кибә тәмам сөяккә әйләнгән юкә төбе янында Әкмәл маташа. Барый учакка утын өстәп тора. Вакыйф булып Вакыйф та азрак җанланган кебек, ул атын тугарып җибәргән, чалгы пәке белән таяк юнып утыручы Хафиз бабай белән килешле генә сөйләшә. Әкмәл, мине күргәч, учакка ишарәләп:

— Әле сине чакырырга тора идек. Күрдеңме? Сал аякларыңны. Күз ачып йомганчы кибә,— диде.

Мин атымны янымнан җибәрергә курка идем. Хафиз бабай моны сизеп алды:

— Җибәр син аны. Курыкма. Китми инде ул. Батканын бер дә онытмый ул ат. Әле беркавым елгадан эчерә алмый да интегерсең,— диде.

— Коры печән булса иде аңа,— диде Әкмәл.

— Көлтә дә ярый,— дип каршы төште Хафиз бабай.— Җан кергән инде. Ашасын бераз.

Тезгенен муенына гына урап, Озын ялымны арба янына җибәрдем. Арба өстеннән бер солы көлтәсе алып алдына салдым. Үзем, чабаталарымны чишенеп ташлап, чолгауларымны казыкка элдем. Эсселектән алар шул минутта ук пар төтәргә керештеләр. Үзем көне-төне суда йөргәнгә күгәрчен тәпие кебек күп-күмгәк булып беткән аякларымны җылыта башладым. Әкмәл кубарып алган юкә төбен шау күмер булган учак өстенә китереп утыртты. Ут беразга гына сүрелгән кебек булды да, ялкын телләре төпнең яңгыр үтмәгән эченнән ялманып өскә үрләделәр. Хафиз бабай, күзләрен кыса төшеп, сокланып, ялкын телләренә рәхәтләнеп карап тора иде.

— Яратам учакны, тәнне генә түгел, җанны да җылыта. Һай, яратам! Яшь чагымда ат сакларга барганнарда зур учаклар дөрләтә идек. Бер чакрымнан янына килерлек булмый, йоклап китеп чәчләр, кашлар көя торган иде. Барыбер яга идек.

— Мин дә зур учакларны яратам,— диде Вакыйф, кулларын уа-уа.

— Бигрәк тә кеше яккан учакны! — дип мыскыллы гына елмайды Әкмәл.

— Алла, берәүләр бер черек төп кубарып килгәннәр икән!

— Берәүләр аны да кубармаганнар бит әле.

— Тукта әле. Син нәрсә гел миңа бәйләнергә генә торасың? — Вакыйф, кашларын җыерып, Әкмәлгә борылды.

— Син кызма әле, Вакыйф,— диде Хафиз бабай, хәйләкәр генә елмаеп,— бәйләнә икән, монда ниндидер мәгънә бар дигән сүз! Кызмыйча гына уйлап кара: берәр җирдә хаксызлык, ялгышлык эшләп ташламадыңмы?

— Көне-төне теш ыржайтуда нинди мәгънә булсын.

— Ай, алай димә! Кеше фигыле шундый ул, кайчагында үз сукмагыңның дөресме-түгелме икәнлеген белмисең. Мәсәлән, син таныш булмаган урман юлының кая барып чыгасын, кайда нинди чокыр көткәнлеген беләсеңме әллә? Ә шул яңа юлдан, серле юлдан бара башлагач, үз-үзеңне күзәтергә вакытың да калмый. Кызма гына син, энекәш.

Вакыйф еларга җитешеп, үпкәләгән кыяфәттә Хафиз бабайның авызына текәлгән иде:

— Ярый, бүген төп кубарып килгән ди ул, янәсе. Нигә аның белән мактана инде! Башка вакытта эшнең иң авыры минем җилкәгә төшә бит. Минем аркада гына кеше булып йөриләр бит алар. Мин мактанмыйм ич.

— Кара, кара, мактанасың бит! — диде Барый.

— Мактанмыйм, дөресен сөйлим! Өченче ел мунчала төшергәндә, кабыкларны кем бәйләп торды? Шул шул! Бер дә сезгә кушмадылар. Берегез ат белән йөрдегез, икегезне кызлар белән мунчала тунарга куйдылар.

— Мунчала тунау җиңел эшме әллә?

— Хатын-кыз эше!

— Сине дә шунда куйганнар иде, сыртың түзмәгәнгә качып киттең!

— Ышанма, Хафиз бабай, Әкмәлне аны безнең авылда алдар таз дип йөртәләр.

— Ә сине кыдрач этәч диләр!

Хафиз бабайның күзләре кысылган, ул, учын авызына якын китереп, кет-кет көлә иде.

— Әй, малайлар, малайлар,— диде ул, көлеп туйгач.— Үзегез атлы эштә йөрисез, кем күрсә — егет кисәкләре. Үзегез чыннан да яшь этәчләр кебек эләгешергә генә торасыз.

— Алар бүген генә шулай ачылып киттеләр әле,— дип, мин дә сүзгә катыштым.

— Вакыйфның калай этәчләнеп йөрүе бер бүген генәме? — диде Әкмәл.

Хафиз бабай, күкрәк кесәсеннән дүрт-бишкә бөкләнгән ап-ак кулъяулыгы чыгарып, бик сакланып кына күзлек пыялаларын сөртә башлады.

— Сезне күргәч яшь чакларым искә төште әле. Без дә нәкъ сезнең кебек бер урамда дүрт малай идек,— диде ул.

Төрле тарихларны, әкиятләрне искиткеч яраткан Әкмәлгә шушы сүзләр җитә калды. Ул, тезләрен кочаклап, Хафиз бабайга елыша төште, аның күзләренә өмсенеп карап:

— Синең гомердә күп кызыклар булгандыр инде, Хафиз бабай? — диде.

Карт яратмыйча кулын селкеде:

— Нәрсә ул кызык? Гыйбрәтле хәлләр диген син, энекәш. Кызыклар булалар да онытылалар.

— Сөйлә әле, бабай!

Карт беравык дәшми торды. Аның күзлек пыялаларында ялкын шәүләләре уйный. Менә ул күтәрелеп күккә карады, утлап йөргән атларга ишарәләп:

— Атлар хәл алганчы берәр нәрсә сөйлимме әллә? Үземнең дә аякларыма көч керсен дип утырам,— диде.

Без барыбыз да учак янына тезелештек. Хафиз бабай

башы юнылган таягын атып бәрде. Анык кызган кисәүләр өстенә ничек барып төшүенә, ничек яна башлавына сүзсез генә карап торды да, борылып, барыбызга да берәм-берәм карап чыкты. Безнең тыңларга әзерләнүебездән канәгать булды, ахрысы, җыерчык белән уелган ямьсез чырае яктырып, чибәрләнеп китте.

— Моннан мең еллар чамасы элек менә бу урыннарда Алып батыр кебек таза гәүдәле, батыр йөрәкле халык яшәгән. Бу җирләр ул заманнарда калын кара урманнар белән капланган икән. Кешеләр шул урманнарда гомер сөргәннәр, аюга йөргәннәр, бал ашаганнар. Аланнарга бодай чәчкәннәр, көмеш сулы елгалардан балык сөзгәннәр.

Бер заманны бу җирләргә яу килгән. Ил өстенә, сукыр черкидән дә әрсезрәк булып, дошман ябырылган. Яше-карты, ук-җәясен тотып, сөңгесен төбәп, сугышка чыккан. Урман кешеләре арысландай көрәшкәннәр, туган йортларына яуны җибәрмәгәннәр. Дошманны кырып салганнар, үзләре дә бик күп һәлак булганнар. Сөңге, чукмар тотып атка менгән ир-егетләр үзләренең яралы тәннәрен дошман гәүдәләре белән күмгәннәр.

Ике атнадан соң шау-шу тынган. Күк белән җирне тоташтырган тузан басылган, кояш күренгән. Ил тагын йортта исән калганнарын яу урынына өндәгән. Нәниләрен күкрәкләренә кыскан хатыннар, ат-ат уйнар яшендәге сабыйлар, карчык-корчыклар җыелып яу урынына килгәннәр. Илбасарларның кырылып беткәнен күргәннәр. Ил егетләренең соңгылары сугыш кырында җан биреп яталар икән. Бик каты елашкан халык, елау тавышы күкләргә ингән. Кояш булып кояш та бу хәлгә түзмәгән, офыктан кара япанчасын тартып алып, битен каплаган.

Исән калганнар төне буе елаганнар да, иртән торып, дошман гәүдәләре арасыннан үз улларын, ирләрен, якыннарын эзләп алганнар.

Әкмәл китергән төп бөтен яктан дөрли-дөрли яна иде. Хафиз бабай кулларын учак ягына сузган көе, озынча, ябык бармакларын җылытып, озак кына дәшми торды.

— Әнә күрәсезме? — диде ул, шулай бераз утыргач, горур һәм биек наратлар белән капланган зәңгәрсу тауга күрсәтеп.— Батырларны әнә шунда күмгәннәр, һәм аларның җаннарыннан менә шундый нык, биек, таза наратлар үсеп чыккан. Бусы соңыннан була инде. Ә ил халкы теге вакытта тәмам аптырашта калган. Иген басулары тапталган, бал кортлары таланган, аюлар качып киткәннәр. Көз якынайган. Урман юллары үтәрлек түгел. Сулар пычранган.

Менә, ак ялларын селкә-селкә, ак койрыгын болгый-

болгый, җил-бураннарын ияртеп, кыш патшасы килә. Җирне кар белән күмә, су-чишмәләрне бикләп, ачкычын кесәсенә сала. Урман арасында калган ятимнәр, зур бер йорт салып, һәммәсе бер гаилә, бер җан, бер тән булып шунда яшиләр. Араларында иң өлкәннәре бер дөм сукыр аксакал була. Ил өлкәне булып яуга да йөри алмый ул, ауга да. Әмма халык аның үзен чиксез ярата торган була. Картның зирәк акылы, тәмле теле, киң күңеле була. Өстәвенә скрипканы да бик моңлы уйный икән.

— Әллә ул заманда да скрипкалар булган? — диде Әкмәл, түземсезләнеп.

Хафиз бабай үзен бүлдерүгә бөтенләй әһәмият бирмичә сүзен дәвам итте:

— Кышкы караңгы төннәрдә тешен шыгырдатып ишек төбендә торган ачлыкның тавышын халык ишетмәсен өчен, ул кичтән алып таңгача уйный да уйный икән. Моң астында сабыйлар да изрәп йоклаганнар, өлкәннәр дә сабырланганнар. Тәрәзәләрдән усал кыш патша үзенең бозлы кулларын сузганда да, карт уйнавын куймаган. Бармаклары өшеп, тырнаклары төшеп беткән аның. Скрипка кыллары кычкырып елаганнар, көлгәннәр, шаярганнар. Моң йортның иң караңгы почмакларына да үтеп кергән...

Менә кояш кунакка киткән ягыннан әйләнеп кайткан. Кыш патшаның ак кикрикләре шиңгән, ул мыштым гына сыза башлаган. Ачуланып, гөрләп тә караган, шулай да чокыр-чакырларда гына утырып кала алган. Кояш аны куган да куган. Җир өстенә учлап-учлап умырзаялар, ландышлар чәчкән, тапталган кырдагы уҗымнарны тергезгән, чәчәк келәмнәре җәеп бал кортларын чакырган. Елгалар чистартылган, мыжлап балыклар йөзә башлаган. Ил халкы сөенеченнән нишләргә дә белмичә, скрипкачы карт янына килгән. Аны сөйгәннәр, үпкәннәр, яратканнар, «коткаручыбыз» дип атаганнар. Җылы урамга, кояш нурына алып чыкканнар. Скрипкачы бармак битләре белән яшел тоҗымнарны капшап караган, учы белән чүмереп чишмә суын эчкән дә җиргә ятып, тыныч күңел белән җан биргән. Җылына алмаган ул, чөнки кыш буе кешеләргә бирә-бирә тәнендә җылы калмаган икән. Картны ил өчен һәлак булган батырлар тавына күмгәннәр.

Халык тагын үз җаена яши башлаган, иген иккән, балык тоткан, батырларын да онытмаган. Аларга истәлек итеп иң биек тау өстенә ак мәрмәрдән йорт салган. Йорт эченә батырларның кылычларын, сөңгеләрен куйганнар. Шушы дәһшәтле кораллар арасында иң мактаулы урынны

скрипка алган. Аңа хәтфәдән махсус савыт эшләгәннәр, мәрмәр таш багана өстенә урнаштырганнар. Халык ел саен шушы йортка килеп, батырларын искә ала икән.

Хәтфә савыт эчендәге скрипка кыллары көннәрдән бер көнне телгә килгәннәр һәм үзара сөйләшә башлаганнар:

— Минем аркада сез шундый хөрмәткә лаек булдыгыз,— ди икән беренче кыл.— Мин бит таулар-ташлар җимерелү авазын, корыч калканнар шыңгылдавын, күк күкрәвен, язгы ташкыннар гөрләвен отып алып, кешеләргә җиткердем. Аларның исән калуына, авырлыкларны җиңеп чыгуына минем тавышым ярдәм итте.

Икенче кыл моңа риза булмаган:

— Юк инде, агай-эне,— дигән ул,— мин булмасам сезгә бу көннәрне күрү тими иде. Мин, ичмасам, карт имәннәрнең гөжләвен, юлдан үткән гаскәр тавышларын отып алган кыл. Кешеләр минем моңымны яраттылар!

Өченче кыл түзмәгән, болай дигән:

— Нәрсә ул тимер-томыр тавышы? Абзагызга күз салыгыз: камыш булып шаулый алам, сыерчык булып сызгырам, таңгы җил кебек моңаям, чишмә кебек чылтырыйм. Менә нәрсә өчен эләкте сезгә бу дан, бу кадер!

Дүртенче кыл көлгән-көлгән дә сөйләп киткән:

— Мин — сандугач! Мин булат кылыч булып чыңлыйм, кеше күңелендәге иң нечкә урыннарын беләм, кояш нуры белән дә дусмын. Ләйсән яңгыры да була алам, таң булып та сызылам. Мин булмасам, сез күгәреп чормада, пәрәвез арасында аунар идегез,— дигән ул.

Көн бәхәсләшкәннәр кыллар, төн бәхәсләшкәннәр. Ярсудан бер-берсенә иң әшәке сүзләрне әйткәннәр. Тик бер карарга килә алмаганнар. Көннәрнең берендә, ачуланышулары иң шәбәйгән чакта, хәтфә савытларыннан чыкканнар да кешеләрне таң калдырырга теләп, берәм-берәм китеп барганнар.

Кешеләр ил яраларын төзәтү белән мәшгуль булганнар. Менә беренче кыл тау куеныннан ак таш казучы баһадир егетләр янына килгән. Таш арасына урнашкан да бөтен көченә чыңларга тотынган бу. Чыңлаган да чыңлаган. Башта ташчылар аңа игътибар бирмәгәннәр, соңыннан колакларын тотканнар.

— Бу нинди ярык барабан тавышы соң? — дигәннәр алар.

Беренче кыл, гарьләнеп, ташчылар тирәсеннән кырчылар янына киткән. Барса, бодай камылы арасында елап утырган икенче кылны күргән. Икенче кылның моңын ишеткән игенчеләр: «Майламаган арба тавышы»,— дип көлгәннәр икән.

— Кешеләр безне аңламас хәлгә килгәннәр,— дип зарланышканнар алар.

Өченче кыл алма бакчасына барган. Сыерчыкларны уздырырга теләп сызгырган, чыңлаган. Бакчадагы егет белән кыз:

— Бу нинди әшәке җил исә? — дип чыгып киткәннәр.

Дүртенче кыл яшь кыз бүлмәсенә тап булган. Ул кәефләнеп мыекларын бөтергән, биленә таянган да чыңлап җибәргән. Кызның йөзе агарып киткән, ул хыялыннан бүленеп, бу шыксыз тавышлы кылны өзләргә тотынган һәм, бик тиз табып алып, чормага ыргыткан.

Кешеләр яңадан скрипка янына баш ияргә килгәннәр икән. Буш калган скрипка кысасы аларга кылларының фаҗигасен сөйләп биргән...

Хафиз бабай сүзен бетергәч, ниндидер ләззәтле хыялларга чумгандай, озак кына учакка карап торды. Без дә тәэсирләнүдән сүз әйтергә дә базмадык. Шулай бераз утыргач:

— Карагыз әле, нинди матур кояш! — дип кинәт кенә Әкмәл кычкырып җибәрде.

Барыбыз да борылып карадык. Офык өстеннән берике тәртә биеклегендә, болытларның ачылып киткән җиреннән, кояш карап тора иде. Җир өсте рәхәт җылылык белән тулды. Без иркәләнеп күзләребезне йомдык.

— Иртәгә көн әйбәт булачак, аяз көн,— диде Хафиз бабай.— Кузгалдык, егетләр, әкият бетте.

— Менә бу әкият дисәң дә әкият! — диде Әкмәл, гашыйк күзләрен Хафиз бабайдан ала алмыйча.

Учак төтенсез генә яна да яна. Без киенеп атларыбызны җиккәнче, Хафиз бабай аны туфрак белән күмеп ташлады.

— Йә, балакайлар, ак юл сезгә, кайчагында минем әкиятне дә онытмагыз,— диде ул.— Бигрәк тә син, Вакыйф улым!

Ярдәме һәм киңәше өчен без аңа мең рәхмәт әйттек.

Яңадан юлда. Офыкта болытлар тартылган, тик бер бәйләм нур һаман җанны җылытып, күренеп тора иде. Бер бәйләм нур! Димәк, болытлар артында җылы да, якты да бар. Иртәгә көн әйбәт булачак, ди Хафиз бабай. Мин, артыма борылып, чатанлый-чатанлый ерагаеп барган якын кешегә кул изим. Ул да изи.

*1958, Казан*

# Өч аршын җир

## 1

Ерак Көнчыгыштан килүче унсигезенче номерлы поездның дүртенче вагонында ниндидер хәвефле, мөшкел хәл булуын пассажирлар берьюлы белделәр. Юлда үзеңне ничек-ничек тотарга, тәмле суларга алданып станцаларда адашып калмас өчен, абай булырга кирәклеген, шактый гыжылдавык тавыш белән кат-кат, вәзенләп сөйләп ялыктырып бетергән поезд радисты, төче һәм мәгънәсез бер җыр тапшыруын бүлеп, әллә ничә кат:

— Пассажирлар арасында врач яки фельдшер булса, тизлек белән дүртенче вагонга килүен үтенәбез! — дип белдерү ясады.

Беренче мәртәбәсендә халык радистның сүзенә әллә ни игътибар итмәде; гомере буе саргайган кәгазьләрдән кагыйдәләр, боерыклар ише чит кеше сүзләрен укып, үзе әйткәнен үзе ишетмәс хәлгә килгән радист, ниһаять, бер тапкыр кешелекле һәм тормышчан нәрсә турында сөйләвенә шатланып, хәбәрне аерым бер тантана белән, һәрбер сүзенә сөенечле басым ясап әйтеп салган иде. Аның бәйрәмчә тавышы шөбһәле сүзләренә ятышмады, кешеләр әле берни дә аңламый калдылар...

Менә аның тавышы тантанадан шөбһәгә әйләнде, ул сүзләрен бутап, кабалана-кабалана, инде сагайган юлчылар арасыннан «медицинага берәр төрле мөнәсәбәте бар булган кешене» ашыктыра ук башлады:

— Дүртенче вагонга... дүртенче!

Юл ерак, поездда барганда тел тукталмый, сөйләшергә сүзең генә җитсен!

Купе, коридорларда гәп кузгалды: барысы да мәж килделәр.

— Ни булды икән?

— Һәй, берәр мәгънәсезе поездга кысылгандыр әле.

— Юк ла, йөкле хатыннар утырганын күргән идем, шуларның берәрсе бәбәйгә кысталгандыр!

— Сезнең теге озын, кәпрәйгән кешегез врач түгелме соң?

— Түгел лә, прокурор гына бит ул!..

Хәвефле сүз, чатырдап янган камыл кебек, җиңел генә сикерә-сикерә дүртенче вагоннан чыгып китеп, йөкле хатыннарга, прокурорларга, юлда очраган төрле маҗараларга күчте...

«Медицинага мөнәсәбәте булган» бердәнбер кеше, шактый өлкән яшьләрдәге фельдшер хатын, поездның нәкъ койрыгында — унөченче вагонда Сочига бер айлык ялга китеп бара иде. Ул, үзенең мәшәкатьле хезмәтеннән котылуына сөенеп, тынычлыкка, рәхәткә чыгуына кинәнеп туя алмыйча, тәмле төшләр күрә-күрә, изелеп, үз урынында йоклап ята иде. Радистның шөбһәле тавышы аның купедашларына — карт кына ике ир кешегә һәм нечкә буйлы, сөрмәле күзле яшь кызга кыюлык бирде: алар башта кыяр-кыймас кына, аннан соң шактый йолыккалап ханымны уята башладылар:

— Торыгыз әле, зинһар, торыгыз!

Ханым тиешле-тиешсез вакытта уятуларга күнеккән иде, ахры, бер дә сискәнмичә генә торып утырды, исе китмичә генә тәрәзәгә, тәрәзә артында тезелешеп калган яшь, купшы наратларга карап:

— Казанга җитәбезме әллә? — дип сорады.

Зур шәһәрләргә җиткәндә, ул үзен уятырга кушкан иде.

— Казанга ерак бугай әле, — диделәр аңа. — Тик менә бәла чыккан...

Бераз тынып торган радио тагын кыштырдады, һәм ханым да радистның курку катыш ялынулы тавышын ишетте:

— Дүртенче вагонга!.. Дүртенче вагонга!..

— Ни булган анда?

Ханым, авызын учы белән каплап, рәхәтләнеп киерелде.

— Белмим. Сез фельдшер булып эшлим дигән идегез. Шуңа уяттык та...

Ханым аякларын төреп утырган җәймәне шактый җитез генә бер якка алып ташлады, җәлт иттереп идәнгә сикереп төште, элгечтән ап-ак яулык алып бәйләде, көзгегә күз салды, ашыкмыйча гына изүен рәтләде, аннан соң гына тасраеп үзенә карап торган ирләргә борылды:

— Шулай да нәрсә булды икән?

Аңа беркем дә җавап бирмәде, сүзсез генә бер-берсенә караштылар. Ул коридорга чыкты. Урта мәктәп бетереп, Казанга укырга керергә баручы кыз бик кызыксынып һәм сокланып аңа иярмәкче булган иде, юлдашлары аны туктаттылар:

— Йөрмә!

— Ни калган анда? Яшь кеше ич син! Йә чире йога торган булыр...

Карышырга ниятләп авызын ачкан кыз, радио тагын

чыштырдагач, аяк очларына басып репродуктор тирәсенәрәк килде.

— Дүртенче вагонга... дүртенче вагонга...

Кат-кат чакырып та врач яисә фельдшер табылмагач, болай да шактый кызган поезд бригадиры һәм проводниклар дүртенче вагон коридорында тәмәке тартып торучы ир янынарак тартылдылар. Вагондагы хәл аларның күңелләрен шактый ярсыткан, инде ярдәм итә алмагач, алар хәзер ачуланып булса да тынычланырга, бераз суынырга телиләр иде. Иң элек бригадир сүзгә кереште:

— Соң, туганкай, өч көн киләбез бит инде! Өч көн! Күпме шәһәрләр үттек, менә дигән больницалар, шәпшәп врачлар калды. Хатыным авырый дип килеп әйтсәң, телең корышыр идеме?

Барысыннан да бигрәк дүртенче вагон проводнигы — туп кебек түгәрәк юантык хатын кызган иде:

— Әйтер! Көт син аннан! Барып әйткән өчен дә, пыр тузып, мине орышып маташа. Хатыны үләргә ята, ә аның гамендә дә юк, иртә таңнан чыга да, үзен-үзе кочаклап, тәмәке пыскыта. Бөтен вагонны сасытып бетерде.

Ирнең исеме Мирвәли иде. Ул байтактан бирле коридорда тимер юлчылар арасында басып торса да, берәүгә дә эндәшмәде, папиросын тартып бетерде дә, шырпы кабызып тормыйча, икенчесенә шуннан ук ут элдертте. Ул җыелганнарның чыр-чуын зәһәр мыскыллау белән иреннәрен чалышайтып тыңлый, артык якын килеп кычкыра башласалар, сул кулы белән колагын томалый иде. Аның шулай сүзсез, мукләк сыер кебек карышып, үҗәтләнеп баруы халыкны тагын да кыздыра, кешеләр аннан җавап таләп итәләр; берни дә ала алмагач, тагын да шәбрәк ярсып, бер-берсен котыртып кычкыралар иде.

— Хатыны бит, хатыны!

— Җаны юктыр моның! Таштыр ул...

Ул «хатыны» дигән кешегә борылып карады, аның куерып кушылган кашлары хәрәкәтләнделәр, аз гына бөдрәләнеп торган ап-ак чигә сакалларына ут капкан кебек сыек зәңгәр төтен белән капланды. Кешеләр, ниһаять, кычкыруның файдасыз икәнлеген аңлап, тындылар. Шул чагында Мирвәлинең каты, калын тавышы ишетелде:

— Юкка шаулыйсыз бит!

Шуны гына көтеп торган кебек, поезд бригадиры кулларын җәеп җибәрде:

— Шаулау гына аз монда! Монда беләсеңме нишләргә кирәк?! Без бит җанлы кешеләр, гражданнар. Чирле икәнен белә торып, хатыныңны өч тәүлеклек юлга алып чыкансың. Монда исән кешегә дә аруга килә әле!

Халык дулкынланды, болай да тыгын коридор, күрше

вагоннардан берән-сәрән вәкилләр өстәлеп торганга, кысанланып тәмам тулды.

— Ни җаның белән алып чыктың аны? — дип чәрелдәде проводник хатын, зур, сыек күкрәкләрен атындырып.

— Үзе теләде.

— Беләбез без сезне, ирләрне! Һәрвакыт үзе теләде, дисез! Менә мин яшьрәк чакта...

Бригадир аны ишарә белән тукатты да Мирвәлине үгетли башлады:

— Болай ярамый инде, туганкай, бераз әдәплерәк булырга кирәк. Синең өчен борчылабыз кана. Вакытында белдерсәң, әллә кайчан берәр больницада калдырган була идек.

— Тизрәк котыласыгыз киләме?

Мирвәлинең калын иреннәре, бригадирны мыскыллап, чалышайды.

— Менә кешегә санап сөйләш аның белән! — дип, тагын чәрелдәде проводник.

— Кем чакырган сезне? — диде Мирвәли, кистереп. — Сөйләшәсе юк. Нигә миңа бәйләнәсез? Үзеннән сорагыз. Нигә чыкты икән ул бу юлга? Әллә бик...

— Кем кемне алып кайта соң монда? — дип кычкырды бригадир.

— Кем кемне алып кайтамы? — Мирвәлинең күзләре утлы күмер кебек яна иде.— Башта ук шуны сорыйлар аны!

Фельдшер ханым, кырыкмаса кырык ишекне ачып-ябып, ниһаять, дүртенче вагонга килеп җитте. Ике кулын да йомарлап түшенә куеп, нык-нык атларга тырышып килүеннән үк җыелган халык аның бу минутта иң кирәкле кеше булуын төшенеп алды. Кысылышып аңа юл бирделәр. Ул, әйләнә-тирәсенә күз йөртеп:

— Фельдшер мин. Авыру кайда? — дип сорады.

Бригадир, алгарак чыгып, аның кулын әләктереп алды һәм:

— Инде, туганкай, бөтен өметне югалткан идек! — дип, кат-кат кабатлады.

— Авыру кайда?

— Менә монда ул. Ята.

— Нәрсә булды? Кем ул? Күптәнме? — дип сорады ханым, ишек тоткасына ябышып.

— Менә ул белергә тиеш, — диде бригадир, Мирвәлине күрсәтеп. — Аның хатыны.

— Үзеннән сорагыз,— диде Мирвәли, фельдшерны баштанаяк сөзеп чыккач. — Үзе монда ята ич!

Кирәкле җавапны ала алмаслыгына төшенгән ханым, көч белән тартып, ишекне ачты.

Сулда, стенага йөзе белән борылып, ак җәймә ябынган авыру хатын ята иде. Аның чаларган юка чәчләре мендәр өстенә тәртипсез чәбәләнеп таралганнар. Ишек тавышына ул чак кына башын калкытты һәм татарча:

— Мирвәли, Казанга еракмы әле? — дип сорады.

Ханым рус иде, шуңа күрә аның ни әйтүен аңламады:

— Сез кемгә дәшәсез, кадерлем? Фельдшер мин,— диде ул.

— Ирем керде дип торам, — диде хатын, саф рус телендә. Ул авырлык белән генә, тешен кыса-кыса, фельдшерга борылды.

— Ул монда, коридорда гына. Кирәкме әллә?

— Кирәкми.

Шактый еллар больницада эшләп күзе үткенләнгән фельдшер мондагы хәлнең шәптән түгеллеген бер караудa ук сизенде. Бу шау-шуда, авыр һавалы купеда бару авыру өчен әҗәл булырга тиеш! Өстәлдә ризыклар янында дару шешәләре, бәләкәй кәгазь тартмалар тезелгән. Валидол гына түгел, валокордин да бар монда... Ябык та соң! Димәк, ул күптән авырый...

Ике ят хатын юлда очрашкач, сүзсез булмый, алар төрле юк-барлардан башлап озын юлның мәшәкатеннән зарланышып алдылар. Фельдшер, гадәти әдәп сүзләреннән соң, кыю гына аның янына килеп утырды, авыруның дымлы, кайнар учын үз кулына алды.

— Кайсы төшегез авырта соң сезнең?

Хатын авыр сулады һәм, түшәмгә карап, башын чайкады:

— Бер җирем дә авыртмый. — Үз сүзләренә үзен ышандырырга теләгәндәй, бераз торгач, тагын кабатлады. — Бер җирем дә.

Икесе дә тынып калдылар. Шактый вакыттан соң авыру тәрәзәгә карады һәм күңелсез генә:

— Тәрәзәне ачасы иде, — диде. — Мирвәли каршы... Иремне әйтәм... Төтен тула дип ачтырмый... Тулса соң?

Фельдшер төтен, сөрем тиеп тоныкланган калын пыялага күз салды. Төтен боҗралары торымнан-торымга хәзер дә тәрәзәгә килеп сыланалар иде.

— Ачарлык түгел шул, паровозы бигрәк әшәке төти.

— Тын бетә, — дип ыңгырашты хатын бераздан. — Һава җитми. Коридорга чыгып йөрер идем, әллә нигә аягымның җегәре бетеп китте. Юл авырайттымы шунда, балтырларым камыр кебек изелеп тора.

Кемдер тормозга бастымы, фельдшер аңламый да калды, шәп кенә барган поезд бер секундка гына тартылып алды. Өстәлдәге банкалар, бер-берсенә бәрелеп, чыңладылар, өске полкадан зур салам эшләпә идәнгә тәгәрәде.

Кырыйга ук килеп яткан авыру чак кына егылып төшмәде, ул, күзләрен йомып, ике кулы белән чытырдатып җәймәгәябышты.

— Хәлегез ничек?

Авыру һуштан язган иде. Фельдшер сикереп торды, өстәлдәге шешәдән стаканга су агызды, валокордин тамызды... Бер, ике... Хатынның күзләре һаман йомык иде. Фельдшер аның изүен чишеп күкрәге өстенә ятты. Вагон тәгәрмәчләре өзлексез тыкылдыйлар, ул никадәрле тырышса да, аның йөрәк тибешен ишетә алмады. Кулын тотты, азапланып кына тамырын эзләп тапты. Тамыр «менә туктыйм, менә туктыйм» дигән кебек, өзек-өзек кенә тибә иде...

Фельдшер, кыска аякларын тиз-тиз йөртеп, коридорга чыкты һәм бригадирга борылды:

— Аны больницага салырга кирәк. Бер минут та кичектерергә ярамый, — диде.

Фельдшер табылгач тынычлана төшкән бригадир аның бу сүзләрен ишетеп шаккатты:

— Ничек, ничек?

— Хәзер үк. Шушы минутта ук... Бер секунд та көтеп булмый.

Кыен чакларда да үзеннән түбәннәргә аны-моны сиздермәскә күнеккән бригадир, аптырап, тирә-яктагыларга карады, нидер әйтергә теләгәндәй тәрәзәгә, тәрәзә артында бер-берсен кочаклашып авып калган агачларга ымлады. Ханым шунда гына бригадирның ни өчен тотлыгуын төшенде: ыжгырып барган поездда ич алар!

— Казанга барып җитмичә берни эшләп булмый,— диде бригадир. — Аңа кадәр тукталыш юк.

— Казан еракмы соң?

— Ерак түгел! Ике сәгатьтән анда булабыз!

— Ике сәгать?!

— Аннан да алда барып булмый. Расписание.

— Ике сәгатьтән соң булачак. Аны беренче очраган станциядә үк больницага салырга кирәк. Тынычлык кирәк аңа, һава кирәк.

Тимер юлчылар тиз генә киңәшеп алдылар.

— Хәле шулай авыр икән, Кыек Урман станцасында туктыйбыз, шунда калдырабыз.

— Анда больница бармы соң?

— Үзендә юк икән, якында булыр әле! — Бригадир җиңеләеп китә үк башлады. Поездны туктатырга, аның өчен машинистка боерык бирергә, Кыек Урманга хәбәр итәргә кирәк иде. Бригадирның ашыгып кузгалуын күреп, Мирвәли аңа якынрак килде.

— Ничек уйлаштыгыз?

— Ничек, ничек... Туктыйбыз да калдырабыз!

— Ул үзе шулай куштымы?
— Кем?
— Шәмсегаян.
— Нинди Шәмсегаян?
— Минем хатын.
— Мин шулай куштым,— диде фельдшер, сүзгә катышып.
— Аны больницага салырга ярамый! Калдырырга ярамый!
— Нинди кыргыйлык бу? — дип кычкырды фельдшер, көчкә сүзен табып.
Бригадир да аптырап калды.
— Иң элек үзеннән сорагыз. Югыйсә, тавыш-гауга кубачак.
— Нинди тавыш? Нинди гауга?
— Ул больницада ятарга теләми. Ул Карачурага кайтып җитәргә ашыга. Авылга.
— Ул авылга кайтып җитә алмаячак, — диде түземенең соңгы чиге җиткән фельдшер.
Проводниклар йөгерешергә тотындылар:
— Кыек Урманга җитәбез!
Бригадир өметләнеп тагын бер мәртәбә Мирвәлигә карады да, кулын селкеп, машинист янына ашыкты.
Мирвәлинең калын иреннәре дерелдәде, ул, бала башы кадәр йодрыгын йомарлап, нәфрәт белән фельдшерга карап тора иде:
— Сез үзегезне берәр нәрсә беләм дип уйлыйсыз инде, әҗәл тагарагы! Беләсез пычагымны... Ярдәм кирәк, имеш... Врач кисәге! Әллә мине бу юлга бик теләп чыккан дисезме? Үзен төшереп калдырырга теләүләрен ишетсен генә, күрерсез әле! Барыбер калмый ул, мүкәләп булса да, поезд артыннан китәчәк...
Станциягә барып туктауга, җиргә иң элек бригадир сикереп төште. Унсигезенче поездда көтелмәгән хәл килеп чыкканын ишетеп өлгергән станция хезмәткәрләре, китель төймәләрен эләктерә-эләктерә, төрлесе төрле яктан поездга таба йөгерешәләр иде.
Ул арада фельдшер да төште, кемнәрдер ак бидоннарын тотып, куе агачлар эченнән күренеп торган кое сиртмәсенә таба томылдылар. Дежурный мышкылдап килеп җитүгә, бригадир аңа кулын сузды, һәм:
— Больница еракмы? — дип сорады.
— Сигез чакрым, — диде дежурный, соңгы төймәсен эләктерә алмыйча азапланып.
— Шулай еракмы?
Бригадир тагын өметсезләнеп як-ягына карады, фельдшерны күргәч:

— Нишлибез хәзер? — дип кычкырды.

— Калдырабыз, — диде фельдшер, ышаныч белән.

— Әйтергә җиңел! — диде шелтәләп бригадир.— Сигез чакрым, ди... Калдырып китәрсең, ә ул юлда үлсә? Кем җавап бирер? Әҗәл ягасында торган кешене калдырып киттем, дип гомер буе вөҗдан газабы белән интегергәме?

— Аны моннан алып китәргә ярамый,— диде фельдшер ныкышып.— Тәрәзәне ачтым... барыбер һушына килмәгән.

— Сигез чакрым ерак ара түгел,— дип, дежурный бәхәскә катышты. — Алай каты авырмаса, ат белән дә илтергә була.

— Атын каян аласыз?

— Ат бар. Ат монда гына. Караталлар сельпога товарга бара. Белеш егетләр.

Бригадир икеләнә иде. Фельдшер аны үгетли үк башлады. Ашыктырып машинист гудок бирде. Ниһаять, бригадир да күнде.

Дежурный ат алып килергә станция ашханәсе янына чапты, бригадир белән фельдшер, сүзсез генә, дүртенче вагонга таба ашыктылар. Алар каршысына баскычтан Мирвәли сикереп төште:

— Аны монда калдырырга ярамый. Булмый, ишетәсезме?

Бригадирның ачуы соңгы ноктасына җитте, ул аңлатып торуны артыкка санап, Мирвәлине юлдан этеп җибәрергә булды. Ике кулын да сузган иде, аның таштай нык тәненә, корычтай каты иңбашларына кулы кагылгач, сискәнеп, ул ниятеннән кире кайтты. Бу тексә, сүзсез кеше таш кыя кебек нык иде, күлмәге астында корыч калкан бар кебек иде. Буйлары бер чама булса да, бригадир бу сәер кеше янында чебештәй зәгыйфь, көчсез кеше икәнлеген тойды. Бу тою аның ачуын басмады, киресенчә, ул үзе дә сизмәстән, бәбәкләрен акайтып, акырып җибәрде:

— Кит юлдан! Мин сине судка бирермен!

Суд сүзен ишеткәч, Мирвәлинең кояшта янган каракучкыл йөзе тартышып, агарынып китте, дәү куллары салынып төште, ул, ачу ташып торган күзләре белән бригадирны ашардай булып, читкә тайпылды, аңа юл бирде.

— Эх, кешеләр!.. Яхшылык теләп йөргән буласыз тагын!

Биш-алты кеше җәймәләргә төреп күтәреп Шәмсегаянны вагоннан алып чыктылар. Нindидер боерыклар бирә-бирә фельдшер да, кыбырсып, алар артыннан төште.

Мирвәли Шәмсегаян дулап урыныннан күтәрелер, тавыш-гаугa кубар, монда җыелган ят кешеләргә бөтенләй кирәкмәгән сүзләр әйтер дип бик курыккан иде. Хаты-

нының шым гына яткан җансыз гәүдәсен күргәч, аңа күңелсез, бик күңелсез булып китте. Кыен булса да, поездда кайтканда ул үз хәленә күнегә, иярәнә төшкән иде. Хәзер барысы да яңача булачак. Ләкин ничек?!

Дежурный ашханә янында торган атларның берсен һәм аның хуҗасын, аксыл кашлы, кызыл киң йөзле, зур күзле авыл егетен алып килде. Алар такта арба төбендәге шиңә башлаган сарутларны, тукранбашларны кабарткалап тараттылар, егет печән өстенә шактый кыршылган кожанын җәйде. Шәмсегаянны салабыз дигәндә генә дүртенче вагон проводнигы:

— Җәймәне дә алыгыз, уңайрак булыр,— диде.

Фельдшер каударланып йөри, әле кожанның сырларын тигезли, әле печәнне баш очынарак тартып өя иде. Ул кинәт кенә:

— Мин аны больницага кадәр озата барам, — диде.

Күңел капкасын ачып, кешеләргә үзен күрсәтергә яратмый иде Мирвәли. Үзенең читкә кагылып бер кырыйда торуы, монда җыелганнарның аның шәхси тормышына катнашып, тыгылып йөрүләре болай да аның саруын кайнаткан иде, фельдшерның сүзләре исә утлы күмергә сипкән керосин гына булды:

— Бик кирәгең бар иде!.. Мин карый алмыйммы аны?.. Беркем дә кирәкми аңа, беркем дә! Алла-фәрештәләр җыелып килсә дә, мичкә-мичкә терек суы тәкъдим итсәләр дә, кирәкләре юк... Әллә больницалар күрмәгән дисеңме аны? Авыру икәнлеген белмәгән дисеңме? Барын да белә... Белә иде! Белә генәме?.. Юлга чыгарга да үзе теләде, врачлар чакырмаска да үзе кушты!

Бригадир һаман өметләнә икән әле, ул, шыпырт кына, фельдшерга дәште:

— Кара әле, бәлки, Казанга кадәр чыдар иде?.. Моның янында калдырып...

— Булмый,— дип, баш чайкады фельдшер. — Аңа тынычлык, һава кирәк. Ял кирәк.

Кемнәрдер Мирвәлиләрнең багажын — ике дәү генә чемоданны, Шәмсегаянның сумкасын һәм зур гына төенне алып чыгып арбага куйдылар. Олаучы егет, эшлекле генә төс белән, кулларын төкереклəп, аларны арбага урнаштырды, үрәчәгә ураган сүс бауны сүтеп, әйбер-караларны бәйләде.

— Исән-аман барып җитегез инде,— дип теләде бригадир.

Фельдшер исә Мирвәлигә әллә никадәр киңәшләр бирде. Аның сүзләре Мирвәлинең бер колагыннан кереп, икенчесеннән чыга торсалар да, ул ризалашкан төс белән ым кагып, башын селкеп торды. Кирәккә дә, кирәкмәскә дә:

— Ярар, ярар... Шулай итәрбез,— дип пичәт сукты.

Поезд белән ат бервакытта диярлек кузгалдылар, һәм күпмедер юлны янәшә бардылар. Менә поезд үтеп китте, соңгы тапкыр яңгыратып гудок бирде, үргә менеп сулга борылды. Рельслар озак кына гүелдәп, сызланып тордылар.

Киң каеш эшлеяләр белән матурлап җигелгән көр ат арбаны уйнаклатып кына, «әһ» тә итмичә, җиңел генә тартып бара. Олаучы әле ат янына алга чыга, әле арба белән янәшә бара, Шәмсегаянга уңайсыз түгелме икән дип борчылып печәнне, җәймәне рәтли.

Дежурный тимер юлны аркылы чыкканчы аларны озата барды һәм, аерылып калырга уңайсызланып, бер урында таптанып торды:

— Хәзер кайтам да телефоннан хәбәр итәм... Бик хаҗәт эшләре булмаса, каршы чыгып та алырлар әле, машиналары бар аларның,— диде ул, хушлашып.

Олаучы аңа кулын бирде, Мирвәли бер сүз дә эндәшмәде.

Кузгалдылар. Олаучы арба тирәли бер-ике әйләнде дә Мирвәлигә борылды:

— Кайсы төше авырта аның? — дип сорады, шыпырт кына.

— Белмим... Әйтүе дә кыен...

Тимер юл буена киң тасма итеп каен катыш сәрви агачлары утыртылган иде. Шул чуар кишәрлекне үтеп чыгуга, юл арыш басуына барып керде. Тигез рәтләр булып серкә очырып утырган арышларга карап, ниндидер гаеп, күзгә күренерлек хата эзләде Мирвәли. Тик тапмады. Җирне кадерләп, төпченеп, юлга кадәр үк китереп чәчкәннәр. Кырга нык куллы кешеләр хуҗа икәне күренеп тора... Урыны-урыны белән генә машиналар, арыш арасына кереп, бер-берсенә юл сапканнар, кап-кара ике эз салып, тугаерга торган башакларны көрән җир белән бергә бутап, изеп бетергәннәр иде. Тирән уелган куш эзләрне, вакытсыз саргайган, юкарган башакларны күреп, Мирвәли вагондагы төсле итеп зәһәр генә көлемсерәде. Әһә!

Олаучы да шуны күзәтеп бара икән.

— Бар бит юньсез бәндәләр! — дип телен шартлатты ул, тапталган игенне күрсәтеп.

Мирвәли шоферларны акларга тотынды:

— Юл тар! Шуңа күрә таптатканнар... Юл тар!

Олаучы кулларын артына куеп, Мирвәли белән янәшә бара башлады:

— Тар дип, ашлык ердырып булмый ич инде!.. Киң урыннары да җитәрлек! Каршыңда машина күрдең исә, чак кына көт, юл сап, янып килми ич.

— Көтеп торып булмый шул кайчагында!.. Тар икән, таптыйсың да китәсең,— диде Мирвәли, киная белән.

Басуга кергәннән бирле Мирвәлинең колак төбендә бер чың тора иде. Ул, адымнарын акрынайтып, ни чыңлаганын белергә азапланды. Озак кына интегеп баргач, үзенең тирә-ягында тынлык чыңлавын аңлады. Өч тәүлек вагон тәгәрмәчләренең шакы-шокысын тыңлап барып, шау-шуга, өзлексез тавышка күнеккән колак тынлыктан котылырга тырыша, тилмереп, үзенә авазлар, шау-гөр эзли иде.

Кырда тавыш мул иде мулын: арыш арасында чикерткәләр чырылдый иде. Ләкин өч тәүлек эчендә ыжгырып барган поездга күнеккән колакка нәрсә ул чикерткә сайравы?!

Юл туп-туры, кыр тип-тигез иде. Әнә шул тигезлек, турылык Мирвәлинең теңкәсенә тиеп, ялыктырып, борчып тора иде. Җитмәсә, шул туры, тигез юл мичтән яңа чыккан бодай катламасы кебек кетердәп, аның чигәсен дә сыкрата иде. Күптән түгел генә яңгыр булган, ахрысы...

Кинәт аның исенә поезд, дүртенче вагон, пассажирлар килеп төште. Аның да башкалар кебек ваемсыз гына карта уйнап, домино сугып, кайгысыз-хәсрәтсез генә әллә кайларга, Кара диңгез буйларына, ак түбәле Кавказ тауларына китәсе килде. Боларның һәммәсенең мөмкин түгеллеген уйлап, ул йөгәнсез хыялын, авызлыклап, үз буразнасына кертергә тырышты.

Ләкин күз алдында озын, туры юл, тирә-ягында әллә кайларга җәелгән тип-тигез кырлар булганда хыялны, йөгерек уйны йөгәнләп буламы соң? Ул әллә кайларга шашып чаба, тегендә дә, монда да боргалана, нәтиҗәдә, күңелнең иң тирән, иң яшерен җиреннән әлеге дә баягы аяусыз сорауны сөйрәп чыгара: «Кая барасың син болай, Мирвәли? Кая кайтасың?!»

Мирвәли сискәнеп, тетрәнеп алды: арбада тирбәлеп кенә йокымсырап барган Шәмсегаян кинәт күзләрен ачты.

Кая баралар алар болай? Арба урәчәсенә тотынып баручы олы күзле кеше кем ул? Каян килгән?..

Менә ул терсәкләренә таянды, калкынды, Мирвәлине күрде. Иреннәрен кыймылдатты. Олаучы борчылып Мирвәли янына ашыкты.

— Су сорый бугай...

Тик ул су сорамады. Аның чак кына селкенгән җансыз иреннәреннән Мирвәли сүзләрен өзеп алып аңлады. Аңлагач, йодрыкларын төйнәп, ачу тулы күзләрен Шәмсегаянга акайтып, эчтән генә суганлап-борычлап сүгенде. Олаучының борчылуы артты гына.

— Нәрсә диде ул?

— Ишетмәдеңмени?

— Ишетсәм дә, аңлап бетермәдем.

— Ул... Карачурага еракмы әле дип сорады.

— Ера-ак! — дип сузды олаучы.— Кыек Урманга алтмыш биш чакрым дип йөртәләр.

Ул сүз җае чыгуга бик шатланып, май таплары белән чуарланган киң козыреклы фуражкасын баш түбәсенәрәк этәрде, фуражка астыннан аксыл салам төсле йомшак чәчләре килеп чыкты.

— Булганым бар! — диде ул, үзенең дөнья күрүе белән ачыктан-ачык мактанып.— Әле быел яз да үтеп киттек. Зур авыл, бик зур авыл. Ә кәкже!

Мирвәли юри Шәмсегаянга карамаска тырыша иде. Нигә поездда түгел соң без дип сорамады, әйберләрнең барын да төйнәдеңме дип кызыксынмады, һаман бетмәс балык башы — Карачура! Күпме чәйнәргә мөмкин шул бер үк чүбекне? Юлга чыкканнар икән, кайтып җитәрләр әле! Әнә бит, олаучы әйтеп тора. Карачура урынында, ди, җир йотмаган үзен, яшен дә сукмаган!..

Ул шулай ачуына буылып барганда, Шәмсегаянның иреннәре тагын кыймылдадылар, бу юлы аның сүзләрен олаучы да аңлады:

— Юкка курыктылар алар... поездда, дим... Карачурага кайтып җитмичә үлмим әле мин. Үлмим!

Бусы инде чиктән ашты!.. Җитмәсә, олаучысы да, саксыз сорау биреп, аның болай да шашып типкән йөрәгенә пычак кадагандай итте:

— Карачурга кайтып барышмыни?

Һич тә уйламаганда бу сорауга Шәмсегаян җавап бирде:

— Әйе, без шунда кайтып барабыз.

Олаучы сүзсезлектән гаҗиз булып бара иде, Шәмсегаянның җавабы аның телен ачты:

— Каян ук кайтасыз соң сез? Ерактанмы? Озаккамы? — дип бер-бер артлы сорау тезеп китте.

Шәмсегаянның сүзгә катышуыннан курыккан Мирвәли ашыга-ашыга үзе җавап бирде:

— Бик ерактан, тегеннән! — диде ул, каядыр иңбашы аша артка ымлап.

Мирвәли поездан төшкәннән бирле кечкенә йомыш белән кысталып бара иде. Тегендә станция якын, уңайсыз дип түзеп килде, хәзер юл аулак булса да, олаучы белән Шәмсегаянны икесен генә калдырып торырга курыкты. Әллә нәрсә сорап ташлар, тегесе әллә ни дип җавап бирер. Ярамый!.. Юл буе кыңгырау кагып кайтмый торсыннар әле!

Аның куркыныч шикләрен раслагандай, Шәмсегаян тагын кузгалды, терсәкләренә таянып торып утырды, йөзен кояшка таба борып, рәхәт итеп елмайды. Аның

вак җыерчыклар белән бизәлгән чыраена сыек кына кызыллык йөгерде. Мирвәлинең исе китте: яздан бирле хасталанып урын өстеннән тормаган хатыны, аның, Шәмсегаяны, рәхәт итеп, күкрәк тавышы белән, нәкъ яшь кызлар кебек, гөлдердәтеп көлеп җибәрде:

— Мирвәли... Ишетәсеңме, тургай! Сабан тургае! Безнең як тургае!

Ул беренче мәртәбә күтәрелеп күккә карады. Кояшның якты нурлары күк гөмбәзен шулкадәр югары күтәргәннәр иде, ул никадәр тырышса да, тургайларны күрә алмады. Күк зәп-зәңгәр!.. Анда-санда гына болытлар йөзә, тик алары да сабый бала хәсрәте кебек юка, җиңел иделәр, күләгәләре дә, җиргә төшеп җитә алмыйча, эреп бетә иде. Шулай да тургайлар тавышын ишетте Мирвәли. Сайрый икән, берәү генә түгел, икәү, өчәү, бик күп!..

Олаучы да, киң учларын кашы өстендә кушлап куеп, тургайларны эзли иде:

— Тургайлар мыж! — диде ул, юлдашларын сүзгә чакырып.

Тик тешләкләнеп килгән Мирвәлидән тургайлар да сүз тартып ала алмадылар... Ул арада алгы тәгәрмәчләрнең берсе ямьсез генә шыгырдый башлады. Олаучы, уңайсызланып, күн итек үкчәсе белән тәгәрмәч бүкәненә тибеп карады, кулларын дегеткә буяп, чәкүшкәне кузгатты, ләкин шыгырдау туктамады. Шәмсегаян, аның кызарган йөзенә карап:

— Тимә, шыгырдасын!.. Бигрәк матур бит,— дип ялынды.

Акрынлап кыр тавышларына күнегә бардылар. Арба туктаусыз шыгырдады, тургайлар өзлексез сайрадылар, чикерткәләр бер-берсен уздырырга тырышып чырылдадылар...

Олаучы Мирвәлигә тәмам үпкәләде: сөйләшмәсәң, ялынган кеше бармы әллә? Тел төбеңә мүк үскән икән, бар әйдә кара бүкәй булып!

Шәмсегаян бөтен нәрсәсен онытып, сихерләнгән кебек, кырлар өстеннән күзен алмады.

— Арыш исе! — диде ул, сокланып бераздан.— Сулавы ук рәхәт! Ай, бәхетле кешеләр бар инде дөньяда! Шәһәрләрең бер якта торсын!..

Аның күп сөйләшүе Мирвәлигә ошамады:

— Тагын өзлегерсең әле, — диде ул, кырыс кына.

Шәмсегаян ягымлы көлемсерәде:

— Хәзер юк! Өзлекмим... Монда кайтып җиткәч өзлегеп яталармы? Юк! Тик менә күккүзләрне бетергәннәр. Элек, безнең заманда, арыш арасында күккүзләр була торган иде.

Олаучы кигәвен куарга ак әрем сабагы сындырып алган иде, шуны арыш арасына ыргытты да сүзгә катышты:

— Хәзер дә бар алар!.. Трактор тирән сөрә сөрүен, чүпчарга көн бетеп килә, тик күккүзләр хәзер дә очраштыра.

Мирвәли дә, олаучы да юл буйларын күзәтеп бара башладылар. Бераз баргач, олаучы шатланып кычкырып җибәрде:

— Әйттем бит! Әнә!

Ул, бер төптән әллә ничә сабак чыгарып, мул чәчәктә утырган күккүзләрне йолкып Шәмсегаянга сузды:

— Мәгез, апа.

Шәмсегаян чәчәкләрне алды, олаучыга рәхмәт әйтте, һәм, аз гына бал исе, яшькелт үлән исе, дымлы җир исе килеп торган күккүзләрне йөзенә каплады. Түзмәде, елап җибәрде.

Кыр чәчәкләре арасыннан сытылып чыккан күз яшьләрен күргәч, Мирвәлинең суык күңелендә җылы бер өмет уянды: тукта, димәк, Шәмсегаян Карачурага шушылар өчен ашыккан икән!.. Өлгергән арыш исен иснәргә, тургайлар тавышын йотылып тыңларга, күккүзләргә битен куеп торырга ашкынган!.. Димәк, хәзер алар Шәмсегаян белән тавыш-гаугасыз гына килешә алырлар... Карачурага бөтенләй кайтып та тормаслар!.. Больницага барып аз-маз хәл алырлар да, борылып кайтып та китәрләр!.. Нигә Карачурага кадәр кайтып, интегеп йөрергә?.. Анда да шундый ук кырлар инде, тургайлары да шул ук... Чыр да чыр! Колакны тондыралар...

Казанга кайтып җиткәч, берәр сәбәп табып анда калырга, Карачурага, һич булмаса, Шәмсегаянның үзен генә кайтарып җибәрергә дип, өч көн буе поездда корган планнары чәлпәрәмә килде дип пошынып барган Мирвәли, башына шушы соңгы уй төшкәч, үзгәреп китте. Өмет уянды да аны кыюландырды, ул арттарак калып бик иркенләп йомышын үтәде. Рәхәтләнеп тәмәке тартып алды. Җиңеләеп калгач, шәп-шәп атлап, олаучыны куып җитте һәм аның аркасына дәү учы белән шукланып сугып алды:

— Йә, ничек? Больница дигәннәре еракмы әле?

— Әнә теге борылмадан дүрт чакрым чамасы булыр. Әһә, эчпошыргыч туры юл борылырга да тиеш икән әле! Тик Мирвәлигә юл бормалары белән юанырга язмаган икән. Борылмага барып җитәбез дигәндә генә, алар каршысына ашыгыч ярдәм машинасы килеп туктады. Кабинадан озын буйлы, нечкә гәүдәле яшь кенә врач төште, ашыга-ашыга арба янына килде...

Шәмсегаян: «Миңа арбада рәхәтрәк, машинага кермим»,— дип карышса да, аңа аттан төшәргә туры килде...

Әллә каян гына талгын җил чыкты. Акрын гына тирбәлгән тоташ кыр уртасында, яргаланган кулларын аксыл кашлары өстенә куеп, ялгыз олаучы гына торып калды. Форсаттан файдаланган җирән бия, юл читенә тартылып кереп, йомшак иреннәрен селкетә-селкетә, сусыл арыш башларын ашап маташа иде. Башка вакытта бер башак өчен дау куптара торган олаучы бүген бер сүз дә дәшмәде, биянең муенын сыйпап, күзләре белән машинаны бик озакка кадәр озатып калды. Менә борылманы үтте машина, үр менә башлады, күмелде... Кыр өстендә ят, чит булып, бензин белән дару катнаш ачы бер ис калды...

Тургайлар зәңгәр гөмбәзле киң өйләрендә рәхәтләнеп чырылдыйлар, кыр өстеннән арыш серкәләрен очыртып рәхәт, йомшак җил исә иде...

## 2

Авыл больницасында кечкенә генә хәбәр дә бик тиз урамга чыга: тәгәрмәч шиннары ашалып шомарган аксыл машина дулап капкадан кайтып кердеме, бел дә тор, менә бу юка пәрдәләр белән томаланган тәрәзәләр артында кемдер явыз үлем белән тартыша, кемнеңдер язмышы үлчәү табасына куелган... Кайсы як җиңәр...

Мондый вакытларда больница урамы хатыннары өйдәге шау-шу чыкмасын өчен тәрәзәләрен ныклап ябалар, больница урамы малайлары су буйларына, ераккарак китеп уйныйлар. Машина куптарган тузан утырып та бетми, урамнар тынып, сагаеп кала...

Шәмсегаян үләргә ята...

Байтактан бирле больница ишеге алдындагы лапаста утырган Мирвәли моны белми әле. Ул әледән-әле башын калкытып ишеккә, тәрәзәләргә карый... Шәмсегаян үз аягы белән килер дә чыгар төсле тоела аңа...

Аны бераз шикләндергән нәрсә шул булды: ишегалдында хәрәкәт тукталды. Чуар, алама койрыклы этен ияртеп җиде яшьләрдәге сипкелле бер малай кергән иде, алар да монда юанырлык ямь тапмадылар. Малай, сүз катарга теләп, Мирвәли тирәсендә бер-ике әйләнде дә, кара бармагы белән борынын казып, каш астыннан гына бу йөнтәс, дәү кешегә ятсынып карап тора башлады. Эт тә, сыенырга чамалап, аның тез башларына бәрелеп үтте, юл тузаны сарып соры төскә кергән күн итеген иснәде. Мирвәли малайга күтәрелеп тә карамады, эткә усал сүгенеп, аяк тибеп куйды:

— Пшол!

Ни мыштырдыйлар икән инде анда?..

Шәмсегаянны алып кереп киткәндә ул врачка:

— Тизрәк хәл итегез, — дип калган иде.

Ә алар ашыкмыйлар, күрәсең... Аларның ашыгырлык эшләре юк, ә Мирвәлинең... Бая күңелгә килеп утырган фикерне тизрәк Шәмсегаян белән уртаклашырга, аның ризалыгын алырга һәм тынычланырга тели иде ул... Югыйсә уйларның күплегеннән акылдан шашарлык!..

Утыра торгач аның тәмәкесе бетте, ул иләмсез дәү учлары белән ертырдай булып ярсып, кесәләрен актарды, поезд билетлары килеп чыккач, ачу белән аларны җиргә бәрде.

Кинәт кенә аның борынына бик таныш, бик тәмле, ләкин онытылып барган ис килеп бәрелде. Ул юан, түгәрәк муенын сузып, киң борын тишекләрен киереп, һава сөзде. Лапасның ар башыннан килә! Ул башны җирдән түшәмгә кадәр тыгыз такта койма белән томалаганнар иде. Ул, үзе утырган муртайган кискәсеннән торып, чайкала-чайкала шунда таба китте. Бер-берсенә ырып кертеп койган такталарны караштырып чыккач, ул бер урында, аста, үгез күзе хәтле генә йомры тишек күреп алды һәм, калак сөякләрен шыгырдатып, шунда иелде. Теге якта түтәл-түтәл итеп, бакча тутырып төн миләүшәләре утырткannар иде. Кояштан оялып керфекләрен йома торган бу гаҗәеп чәчәкләр әле ачылып бетмәгәннәр, лапас янындагылары күләгәгә эләгеп, шыпырт кына ачылып маташалар һәм үзләренең куе, тәмле исләрен таратып та өлгергәннәр. Әллә иелеп торганга, әллә чәчәк исенә Мирвәлинең кинәт башы әйләнде. Ул, колачын киң җәеп, тактага ябышты һәм күзләрен чытырдатып йомды...

Өйләнешкән елларында Мирвәли бала бик көткән иде. Һәм кыз булса Миләүшә исемен куярбыз дип, Шәмсегаянына ычкындырып та ташлаган иде. Шуннан соң Шәмсегаян, әллә кайлардан эзләтеп, миләүшә орлыгы кайтартты һәм ел саен тәрәзә каршындагы бәләкәй бакчага гөлчәчәкләр утырта торган булды... Алтын шарлар, пигәмбәр тырнагы һәм миләүшәләр... Ул аларны су сибеп, утап, туфракларын кабартып, сөеп үстерә иде... Әйе... Миләүшәләр ел саен үстеләр, чәчкә аттылар, тик нәни Миләүшә генә, аларнын хыялында әллә кайчан бар, тере кыз, төймә күзләрен елтыратып, түтәлләр арасында тып та тып чабып йөргән тере Миләүшә генә юк иде...

Ул сискәнеп башын күтәрде. Больница болдырына чыгып баскан яшь кенә кыз аңа эндәшә икән.

— Абый, килегез әле монда!

— Нәрсә бар?

— Абый, без бик тәмле ботка пешердек. Юлда килеп карыныгыз ачкандыр...

Мирвәли җирәнеп борынын җыерды: «Чирлеләр боткасы!» Һәм баш тартты:

— Ашыйсым килми,— диде.

Ни кыландыралар икән алар анда?

Шәмсегаян үләргә ята...

Авыл больницасының яшь, үз эшенә чамасыз бирелгән врачы гына моның белән килешергә теләми. Дөрес, Шәмсегаян авыр, фаҗигале тормыш кичергән булса кирәк, аның йөрәге таланган, искергән, көрәшергә көче җитми, әмма ул аңа ярдәм итәргә тиеш! Усал, әрсез үлемне көрәшеп кенә җиңеп була!.. Кешенең бөтен гомере үлем белән көрәшүдән гыйбарәт. Көрәшергә, көрәшергә! Врач шулай уйлый. Врач шулай яши...

Ул үләргә ята...

Аның хәле авыр икәнлекне Мирвәлигә генә әйтмиләр. Берсенең дә бу хәбәрне аңа җиткерәсе килми. Сөенечле хәбәрнең генә аяклары җиңел ләбаса!

Көтеп күпме газапланырга мөмкин?! Тизрәк, тизрәк Шәмсегаян белән сөйләшергә кирәк!..

Мирвәлинең күңелендә бер генә уй иде. Менә Шәмсегаянның хәле аруланыр, алар кара-каршы утырып сөйләшерләр. (Югыйсә кара-каршы утырып сөйләшмисең дип, гел үпкәләп йөри!) Аңлашырлар... Күрә торып Мирвәлине җәһәннәмгә илтеп кертергә риза булмас Шәмсегаян... Аз гына хәл керсен иде үзенә, терелеп китсен иде... Моннан, бу яклардан исән-аман ычкынырга гына иде... Юл борчыды ла аны!.. Үз аягы белән поездга кергән кеше ич!.. Терелсен генә, ул аның белән сөйләшә белер!.. Җитәр, булды... Татарстан туфрагын күрделәр, таныш якларга кайттылар, шул җитмәгәнме әллә аңа? Карачурага сөйрәлеп барып йөрүдән ни файда? Янып көтеп торган агай-энеләре бармы? Бар ди сиңа, коймак пешереп, табагачларын юллыкка тыгып болгап чакырып торалар! Бар да чыбык очы тал башы!.. Алары да исәнме әле, белгән юк, язмыш әллә кайларга таратып бетергәндер үзләрен... Юк! Кирәк икән шушы авылда фатир алып бер-ике көн, инде ул гына җитмәсә, атнасы белән торырлар, әмма Мирвәли моннан ары бер адым да атламаячак! Бер адым да! Шәмсегаянны да Карачурага җибәрмәячәк! Булды, булып ашты. Җитте! Күңеленең йомшак чагында кайтырга ризалашкан икән, аның күңеле, солы кесәле сыман, һәрвакыт йомшап торырга тиешме әллә?!

Кинәт аның башына саллы имән күсәк белән суккан кебек булдылар, ул берьюлы исәнгерәп, миңгерәүләнеп калды: әгәр Шәмсегаян үлсә?!

Хатынының авыру икәнен белсә дә, моңарчы Мирвәлинең күңеленә курку-фәлән килмәде. Киресенчә, Карачурага кайтырга хәйләләп кенә чирлегә сабышып маташмыймы бу хатын, дип уйлый иде ул ара-тирә. Менә

алар Казанга кайтып җитәрләр дә Шәмсегаян урыныннан сикереп торыр, көлә-көлә каршысына килеп басар: менә күрдеңме инде, мин юри-марый гына яттым бит, дияр. Мирвәли шулай дип тә уйлый иде...

Чыннан да, әгәр ул үлсә?!

Кызганмады Мирвәли хатынын, киресенчә, аның күңелендәге шик усаллык белән алышынды: «Ни пычагыма сөйрәлеп монда кайтырга иде алайса?! Үлгәч кайда аунасаң да барыбер түгелмени?!»

Ул, тып итеп, аягына басты, җыерылган күн итек кунычларын тартты һәм, эре-эре атлап, ишеккә таба китте.

«Юк, монда үләргә ярамый! Һич!.. Врач белән дә, Шәмсегаян белән дә өзеп сөйләшергә кирәк!»

Болдырга барып җиткәндә генә ишекне томалаган марляның бер чите күтәрелде, иелеп баягы кыз килеп чыкты:

— Абый... Хатыныгыз сезне чакыра... Врач та, керсен, диде...

Чакыра? Врач та ризалаштымы? Үзе бит «керергә ярамый, аңа тулы тынычлык кирәк» дигән иде? Яхшы... Мирвәлинең хатынына сүзе барын белгән диярсең!.. Керер Мирвәли, Шәмсегаянга бирешмәскә, нык булырга кушып чыгар. Терелсен!

Эх, ялгыз гына сөйләшеп булса иде! Бу кызый да ияреп керә торгандыр әле, врач та күзен тасрайтып карап торса?.. Юк, Мирвәли аларга чыгып торырга кушар. Җитәр! Өч тәүлек инде ул хатыны белән ялгыз гына кала алмый... Хатыны белән кеше алдында сөйләшергә өйрәнмәгән Мирвәли... Инде бүген, шундый чуалчык уйлар ураганда, үзара гына сүз алышырга ярыйдыр бит аларга?!

Тукта, ә ул Мирвәлине нигә чакыра соң әле?! Ни булды, нинди сүзләр әзерләде икән?

— Абый, ишетмәдегезме әллә сез?

Ул, болдыр култыксасына ябышып, шактый вакыт уйга батып торды.

— Ишеттем, ишеттем!

Алар бергәләп эчкә керделәр.

Ярым караңгы, салкынча коридорда соры халатлар кигән берән-сәрән авырулар күренде. Яңа гына юып чыгарган сап-сары идән Мирвәли басканда шыгырдап, сыгылып калды. Кыз сәерсенеп артына борылып карады. Аның чынаяк тәлинкәсе кебек зуп-зур күзләрендә ниндидер моң, хәвеф бар иде. Мирвәли, идәнне шыгырдатмаска тырышып, саграк атлый башлады. Буявы купшакланган тар ишеккә җиттеләр, кыз ишек янындагы кадактан ак халат алып аны сүзсез генә Мирвәлигә бирде. Иңнәре бик тар, җиңнәре курач иде халатның.

— Менә монда.

Мирвәли кечкенә генә бүлмәгә барып керде. Бүлмәдәге бердәнбер караватта, аркасы белән мендәргә сөялеп, кызарган йөзле, ябәреп, чибәрләнеп киткән Шәмсегаян утыра иде. Караваты янында шул ук озын буйлы, нәзек врач басып тора һәм йомшак кына тавыш белән Шәмсегаянны тыныч булырга, азрак сөйләшергә үгетли иде. Шәмсегаян исә, ире кергәнне күрсә дә, сүзләренең тәменнән аерыла алмыйча, һаман сөйләнә иде:

— Безнең халыкның борын-борыннан җир инде аның!.. Үзем дә менә яшь чагымда кыр эше өчен үлә идем!.. Яз җитсә, өйгә керәсе дә килми иде. Кыен бит үзе, авыр... Урак өстендә унсигезешәр көн оекны салырга вакыт булмый иде... Эштән кайтасың да авасың! Барыбер күңелле иде... Ул сабан ураклары әйтсәңме?.. Юкка гына безнең бабайлар иң яраткан кошларын сабан тургае дип, иң кадерле, күңелле бәйрәмнәрен Сабан туе дип атамаганнар шул... Һай, күңелле уза торган иде шул Сабан туйлары!..

Врач тагын аны бүлдерде, бер-ике сүз белән генә сабан туйларының хәзер дә әйбәт узуын, тик элгәрге елларга караганда күпкә кайтышрак икәнлеген әйтеп алды да Мирвәлине чакырды.

— Мондарак килегез, якынрак. Тик озак сөйләшмәгез, ярыймы? Аңа хәзер ял кирәк, ял!

Ул авыр күз кабакларын кагып кына артык күп сөйләшмәскә ризалашты һәм Шәмсегаянга якынрак килде. Хатыны күңелсез генә аңа күтәрелеп карады, рәхәт минутлардан аерыла алмыйча, юк җирдән сүз табып, әле тәрәзә каршысындагы алмагачлар турында, әле урамнан тын гына узып киткән малайлар хакында сорашкалап, врачны шактый вакыт үз яныннан җибәрмичә торды. Врач та аны ташлап чыгарга уңайсызлана, бер-ике сүз белән генә җайлап сөйләшүне ялгап бара иде.

Менә бүлмә тынды. Врач, ишек төбендә күләгәдәй шым торган кызны ияртеп чыгып китте. Бусагага баскач, ул тагын Мирвәлигә эндәште:

— Зинһар, озак юанмагыз, ярыймы?

Ниһаять, алар бүлмәдә икәүдән-икәү генә калдылар. Мирвәли авыр сулап куйды, чигәсен кашыды, җилкәсен җыерды, сүз таба алмады. Авыруларга бердәнбер дәва, гади кешеләр тәкъдим итә ала торган иң шифалы даруның тәмле тел, дәртләндерү, юату икәнлеген Мирвәли бик яхшы белә иде. Тик тәмле сүзләр әйтергә аның теле әйләнмәде, андый сүзләрне ул әллә кайчан оныткан иде. Карады да катты. Алайга китсә, үзе чакырды бит, үзе дәшсен!..

Тик Шәмсегаян да дәшми, почмакка, почмактагы такта тумбочкага, тумбочка өстендә гади пыяла шешәгә утырткан чәчәкләргә озак кына карап тора... Уйлый, уй-

лый... Фикерен җиңел генә, кыска гына аңлатырлык җайлы сүзләр эзли...

Сүзен таба алмагач, ул авыр гына күтәрелеп карады, күзенә ниндидер моңсу шәүлә төшкән кебек булды, ул бик гади генә итеп:

— Мирвәли, мин үләм,— диде.

Чалт аяз көнне шартлап киткән яшен кебек, бу сүзләр Мирвәлине лып иттереп урындыкка утырттылар. Ул, тонык, сүнгән күзләрен Шәмсегаянга текәп, бу сүзләрнең мәгънәсен аларга тырышты: шаяртасыңмы син? Ничек була инде бу? Үлмим, үлмим дип ышандырып кайт та, мә сиңа! Нәрсә дигән сүз инде бу? Аңлатып бир!..

— Сакалың бик җиткән, әйбәтләп кырын... Яшел чемоданда яңа чалбарың... Буй-буй күлмәгең белән шуны киярсең... Каткан өс белән йөрмә... Күмәчләр искергәндер инде... Читкә ташлама, синең андый гадәтсезлегең бар... Атлары бардыр әле... Үзең карарсың тагын...

Аңлатуың шушы булдымы, Шәмсегаян юньсез?! Үләм диген дә — сакал... күлмәк... Күмәчләр! Чәнчелеп, кырылып бетсен алары!

Шулай уйласа да, Мирвәли хатынына бу юлы уйлаганын әйтә алмады.

— Ни сөйлисең син, Шәмсегаян?

— Кирәген сөйлим.

— Ни сөйлисең?!

— Сөйләшәсе иде дә... Мирвәли... Сүзләр юк! Шунысы аяныч... Гомереңнең бер саплам җеп кебек кыска калганын сизәсең, ә сүзләр юк... Синең белән сөйләшү дә онытылган, үпкәләмә!

Ул тынды, ике кулы белән ботларын, янбашларын тотып карады.

— Ничек булып чыга соң инде бу?!

Шәмсегаян җавап бирмәде, кулы белән Мирвәлигә үзе янында, караватта урын күрсәтте:

— Утыр әле шунда... Мондарак кил... Мин чирли башлаганнан бирле минем яныма килгәнең дә юк... Ябыкканмынмы?.. Әйе... Вагоннан да чит куллар күтәреп чыкты... Ә син...

Карават йомшак, Шәмсегаянның тәне кайнар, ут кебек яна иде.

— Тагын үпкәләргә тотынасың!..

Шәмсегаян аның соңгы сүзләренә бөтенләй игътибар итмәде.

— Мирвәли,— диде ул, үтә йомшак, үтә җылы итеп. — Соңгы сүзем, васыятем шул: мине Карачурага алып кайтып күм.

— Карачурага? — диде Мирвәли, коты чыгып.

— Әйе... Каңгырап, читсенеп җитәрлек йөрдек. Һай, адәм күңеле түзсә дә түзә икән.

— Юк сүзләрең белән нигә җанны кыйныйсың әле син?.. Кыяфәтең бөтенләй үзгәргән, менә ныгып китәрсең әле, савыгырсың... Мин бит синең янга бөтенләй башка нәрсәләр хакында сөйләшергә кергән идем.

— Нәрсә хакында ул, Мирвәли? — диде Шәмсегаян, сагаеп.

Ул бераз уйланып торды да, әйтмәскә булды:

— Терелгәч инде, терелгәч! — дип кенә котылды.

Шәмсегаян, көлемсерәп, башын чайкады һәм бая әйткән сүзләрен кабатлады:

— Карачурага алып кайт! Үзең дә шунда кал!..

— Үзем дә?!

— Авылдашлар икебезне дә сыендырырлар әле... Минем турыда аларга күп итеп сөйләрсең... Ташка язган исемем дә кеше күзенә күренеп торырлык булсын! Кара аны, иренмә, һәммәсен җиренә җиткереп эшлә. Онытмаганнардыр әле. Гәрчә бик күптән бит инде... Утыз ел! Утыз ел күп гомер бит, ә, Мирвәли? Җиргә яңа буын килгәндер... Синең белән мин күрми дә калдык аларны... Күп гомер...

— Бик күп...

Сак кына итеп ишек шакыдылар, Мирвәли борылып карады: тар гына ачылган ишектә теге кызның зур күзләре яна иде.

— Чыкма әле,— диде Шәмсегаян. Мирвәли кызга ияк какты да Шәмсегаянга текәлде. Ул, ниндидер көч, терәк эзләгән кебек, аның кул аркаларын сыйпады һәм аңа таба елышып:

— Зыяратта Имән урамы ягындагы почмакта нарат белән кочаклашып үскән каен бар... Дәү нарат, тармаклы! Риза булсалар, мине шунда җирләрсез... Әле Карачурада чакта, зыярат яныннан үткәндә, мин гел шуларга карый идем. Дәү наратка сыенып үскән каен... Без икәү шулар кебек яшәрбез дип уйлый идем мин...

— Врач нәрсә диде соң?

Мирвәли каушады, изүен ычкындырып, көрсенеп куйды.

— Нәрсә әйтсен, — диде Шәмсегаян, маңгаен җыерып.— Ул тырыша инде. Юата! Дарулар бирде, уколлар кадады... Тәнне түгел, җанны дәваларга кирәк минем... Киләчәктә җан авырулары булмас, диләр... Кем белсен... Булмасын иде дип телим... Карачурага үз аягым белән кайтып сәлам бирә алмадым. Хушлашмыйча чыгып киткән идек бит... Бүреләр төсле, кара төнне, качып... Әрнерлек тә бар бит!

Тагын ишек шакыдылар.

Әдәп белеп, йомшак кына кагылып киткәннәр иде, Мирвәли чәчрәп, сискәнеп китте.

— Чыкма әле, — дип ялынды Шәмсегаян.

— Күптән булган хәлләрне искә аласың син бүген,— диде Мирвәли, аптырап.

— Әйе, күптән... Ләкин булган хәлләр бит! Шуңа күрә син кайтып безнең уртак гаепне йол: агай-энеләрне барлап йөреп чык, берсен дә онытма, һәммәсенә сәлам тапшыр... Шәмсегаян бик сагынды диген, бик! Күчтәнәчләр чемоданда, үзең белеп өләш... Бала-чаганы мәхрүм итә күрмә... Ә хәзер пәрдәне тарт әле, Мирвәли...

Ул урыныннан торып, пәрдәне бер якка тарта башлады, җил кагып ачмасын өчен астан да кадак белән беркетелгән юка батист ертылып ук чыкты. Ире артыннан күзәтеп торган Шәмсегаян, яратмыйча, башын чайкады:

— Ертып ук чыгардың... Кулың каты шул синең, чытырман кул, тотсаң — өзәсең...

Пәрдә артында уйнап торган наян нурлар бүлмәгә кереп тулды.

— Карачурада да шундый ук көндер... Борчак алырга әзерләнәләр булыр... Уракка төшәргә... Шәмсегаян кайтыр дип берәү дә көтмидер, берәү дә исенә кертмидер!.. Сагынып та тормыйлардыр... Яшәмәгән дә кебек! Адәм баласы сулы чиләк кебек, ава да китә... Юк, Мирвәли, без синең белән артык аяусыз, кадерсез булганбыз...

Гомере буе хатыны белән болай сөйләшмәгән Мирвәли, сәерсенеп кенә, аны тыңлый, аның нидер эшлисе, менә шушы авыр, ялыктыргыч минутларны өзәрлек берәр ысул уйлап табасы килә. Ичмасам, врач керсен иде, яисә теге кыз! Ишекне булса да шакысыннар иде, бүлдерсеннәр иде!..

— Карачураны менә шушы якта диде врач... Мин сораштым инде! — диде ярым пышылдап Шәмсегаян, һәм Мирвәлигә мөмкин кадәр якынрак килергә тырышты. Карават тар иде, уңайсыз иде. — Кара, мине монда калдырма... Карачурага алып кайт, үзең дә шунда кал... Сукбай кебек япа-ялгызың читтә йөрмәссең инде... Синең тамырың анда, туган җирең, нигезең... Илле сигез генә чакрым, диләр!.. Әнә шунда гына ич ул!..

Шәмсегаянның көчсез, каны качкан ак кулы аюдай дәү Мирвәлине урыныннан куптарды, ул тәрәзә яңагына килеп сөялде, еракка, урам аша күренеп торган кырларга карады. Шактый басып торды ул, шактый... Аннан җәһәт кенә артына борылды.

— Шәмсегаян!.. Мин анда кайта алмыйм! Ярамый. Кыстама, көчләмә мине... Ярамый!

Шәмсегаян, сәер генә озынаеп, тар караватка сузылган иде, эндәшмәде.

— Шәмсегаян!

Дөбер-дөбер килеп, больница каршысына автомашина килеп туктады. Аннан ашыга-ашыга ак халатлы кешеләр төште. Районнан килгән врачлар иң каты авырулар ята торган бәләкәй палатага кергәндә, Шәмсегаян дөньядан киткән иде инде...

Сүзсез, күз яшьсез катып калган Мирвәлине, ике ягыннан җитәкләп, көчләп диярлек, ишегалдына алып чыктылар. Районнан килүчеләргә яшь врач белән бергәләп үлемнең кайчан, ни сәбәпле килеп чыгуын ачыклаудан һәм күмәргә рөхсәт бирүдән башка эш калмаган иде инде...

Мирвәли, канаты талган карт бөркет сыман, озак кына баягы кискә өстендә утырды. Халатын салгач, тагын да озынаеп киткән яшь врач аның янына килде.

— Абый...

— Ә?.. Нәрсә бар?

— Безнекеләр районга кайталар. Әйләнеч булса да, алар мәрхүмәне Карачурага озатып куярлар. Без килешендек.

— Карачурага дисең инде?.. Син дә шуны тәкрарлыйсың!

— Шунда кайтабыз дигән иде ул...

— Шунда шундасын. Тик мин алар белән кайтмыйм.

— Нигә?

— Шулай.

— Алайса үзебезнең машина белән озатабыз.

— Синең машинаң да кирәкми.

— Нигә?

— Ат бир син миңа, ат!.. Инде гомерен азга гына саклап кала алмагансыз икән, хет атыңны кызганма!

Врач беравык кына уйланып торды.

— Олаучы да, ат та бирербез.

— Олаучың да кирәкми... Ялгыз алып кайтам мин аны! Курыкма, атыңны урламам.

— Курыкмыйм мин.

— Кирәк дисәң документларымны калдырам... Аңла, хәзергә тере кешеләрне күрәсем килми минем... Курыкма, атыңны үтешли кертеп чыгармын. Озакка кайтмыйм мин анда! Тиз борылырмын, бик тиз. Шулай тиз кирәк! Ә хәзер озат мине!.. Безне... Тартырга тәмәке тап та озат... Атыңны бая күргән идем... Акбүз ат... Чибәр ат!

Врач чалбар кесәсеннән бер кап папирос чыгарып бирде һәм, документ кирәк түгеллеген аңлатып, баш чайкады...

Капка төбендә баягы алама койрыклы эт янына утырып чебиле аяклы, сипкелле битле малай елый...

Борчак чәчәге төшкән бизәкле күлмәк кигән яшь кызның чынаяк тәлинкәсе кебек зур күзләреннән эре-эре яшь бөртекләре тама...

Ишегалдын иңләп искән җил, миләүшә чәчәкләрен кочаклап, аларның хуш исләрен урамга таратырга чыга...

Йомшак печән, куккүзләр, тукранбашлар, сарутлар тутырылган арбада җәйрәп, йомык күзләре белән туган җиренең зәңгәрсу-кызыл күгенә карап, Шәмсегаян ята...

Мәет барын сизенгән акбүз ат пошкыра, тоягы белән җирне казый, вак-вак кара җир кисәкләре куркынган кошлар кебек аның аяк астыннан атылып чыга...

Кояш кыздырып җылыткан капка баганасына тотынып, озын врач, санитарлар озатып калалар. Арба тәгәрмәчләре урам буйлап тигез генә, сүзсез генә тәгәриләр. Ямь-яшел йомшак чирәмдә тезелешкән ап-ак казлар өстеннән Мирвәлинең дәү, кап-кара күләгәсе үтеп китә...

## 3

Иң элек урам-тыкрыклар ясап тигезле-тигезсез дә, аркылы-торкылы да сузылган киртә-корталар, башларына балчык чүлмәкләр, бала чүпрәкләре, иске ураклар эленгән, колмаклар сарылган читәннәр күздән югалдылар; аннан уңган кызыл флаг эленгән, муртайган такталы янгын каланчасы һәм эше юклыктан моңаеп, терсәкләре белән яңагына таянып торучы пожарник күренмәс булды; иң соңыннан гына авылның төрле почмакларында — буа ярларында, күпер төпләрендә уйдык-уйдык утырган эре сөякле, юан кәүсәле тупыллар кичке дымсу рәшәгә уралып беттеләр.

Авыл артта калды...

Ул, исемен дә сорарга оныткан авылны чыкканнан соң, бер мәртәбә дә артына борылмады. Алай гынамы, кешеләр очраганда, кызыксынучан күзләре белән аның буй-сынын, арбасындагы сәер йөкне капшаганда ул күтәрелеп тә карамады, аларның кыяр-кыймас биргән сәламнәрен дә алмады. Кемдер, көчле рухлы берәү, аны туктатыр да, болай да тәнендә чак эләгеп, дерелдәп торган җанын өшетерлек итеп нык, усал тавыш белән:

— Әй, кая барасың син болай? Кем син?! — дип кычкырыр төсле иде.

Туктатмасыннар гына, сорамасыннар гына!..

Ләкин берәү дә кычкырмады, беркем дә аны туктатырга маташмады, һәркем үзенең кичке эшен тәмамларга ашыга, кешеләр бер минутка гына тукталалар, Мирвәлигә карыйлар һәм үз юлларына китәләр иде. Ат юл тузанын кагып, шапы-шопы китереп күндәм генә атлый, аның эре адымыннан калышмас өчен, Мирвәли ике кулы белән дә арбаның шомарып, ялтырап беткән сөяк төсле арт карамасына ябышып бара иде.

Ат та, ул да көнбатышка, Карачурага атлыйлар...
Карачурага илле сигез чакрым, диделәр...
Яшел чемоданда яңа чалбары... Иске чемоданда күчтәнәчләр...
Алда билгесезлек. Алда илле сигез чакрым.
Күпме бу? Ерак арамы? Зур санмы илле сигез? Илле сигез...
Быел аларның икесенә дә: Шәмсегаянга да, Мирвәлигә дә илле сигез яшь тулды...
Илле сигез чакрым күбрәкме, илле сигез елмы? Чагыштырып карап буламы аларны?.. Илле сигез чакрымны, шәп барганда, бер төндә үтеп булыр... Авылны тиз чыктылар бит, атның адымы шәп... Менә ул артта ук калды... Авыл... Больница... Болдыр култыксасына кемдер пәке белән чокып «сөям» дип язган... Нигә миләүшәләр төнлә генә ачылалар икән? Эштән ватылып кайткан кешеләрнең арыган күңелләренә аз булса да шифа, бәрәкәт булсын өченме? Бәлки, гашыйклар куанычынадыр?..
Илле сигез чакрым... Менә шулай артыңа борылып карамыйча да, башыңны күтәрмичә дә үтеп була инде аны...
Илле сигез ел... Нигә, Мирвәли илле сигез еллык гомерен дә артына борылып карамыйча үткәрә алды ич! Нигә борылып карамады икән ул? Илле сигез тулуын да нигә менә бүген генә, шушы урында, япан кырда исенә төшерде?.. Нигә артына борылып карарга шүрли соң ул? Кем сагалый аны?.. Нәрсә?.. Кайчан башланды соң бу курку?..
Ул да әнә теге чуар атка төялеп көлешә-көлешә кайтучы малайлар кебек үк шук, наян бер малай иде ләбаса!
Ул да менә шушы тузанланган киемнәр кисәләр дә чибәрлекләрен бер дә җуймаган сылу егетләр кебек кискәдәй нык зифа егет иде бит!
Һәм нигә ул печән өеп кайтып килүче хуш ис аңкып торган менә шушы авыл картлары, чордаш ил агалары кебек көләч һәм ваемсыз шат түгел?
Нигә?
Илле сигез чакрымны үтәргә кирәк, ә илле сигез ел артта калган. Ул, ярым пышылдап, «илле сигез, илле сигез!» дип кабатлый башлады. Бу сан күңелдәге бар уйларны, хисләрне кысрыклап чыгарды. Башын калкытты исә ул күз алдында уйнаган бишле һәм сигезле цифрларны гына күрде... Ат дугасын да сигезле итеп бөккәннәр, юл буендагы үләннәр дә йә бишле, йә сигезле булып бөкрәйгәннәр... Ул күзләрен йомды һәм баш-башлары сигезле итеп бөгеп кадакланган арба карамасына ябышты...
Бәләкәй генә үр төштеләр. Ат терек-терек юртып алды,

шулай да ул Мирвәлигә артык акрын бара кебек тоелды. Ул күзләрен йомган килеш кенә атка эндәште.

— На, бахбай!

Юл бәрәңге җирен телеп барды-барды да бодай басуына килеп керде.

Юл, борыла-сарыла үзәннәрне, чокыр-чакырларны, таучыкларны үтте. Үзәннәр буйлап саз исе аңкытып, җылы, дымсу җил ага иде. Әле бик бәләкәй чагында, кичләрен кырдан эштән кайтканда шундый җылы агымга килеп кергәч, әтисе аңа: «Бу җылы будыргыч һаваны шайтаннар җибәрә. Алар, колакларын шәңкәйтеп, әнә теге тирән чокырда утыралар да иманлы кешеләрне күргәндә көрсенәләр. Бу аларның тыны. Шуңа күрә авызыңны бик ачып иснәп барма, фу-у, җылың үзеңә булсын! дип кире өр»,— дип аңлаткан иде.

Бәләкәй чак бар иде бит. Әтисе дә бар иде. Каян искә төштеләр әле болар? Күңел почмакларында юылып бетмәгәннәрмени ул хатирәләр?..

Үз-үзенә гаҗәпләнеп, ул баралмас булды, тукталды. Уйларына аз гына ачыклык, тәртип кертүгә, үткәннәр искә төшә башлады. Нигә алай?..

Бөтен гомерен артына карамыйча, Аллага мең шөкер, әле иртәгә дә көн бар, ул көн дә тулаем безнеке, гомер алда әле дип яшәгән кеше — Мирвәли үткәннәрен искә төшерәме?..

Гаҗәп хәл иде бу, бик сәер хәл иде, үтә сәер.

Барыр урынның — Карачураның да, юлның да билгесезлеге, иртәгәсе көн хакында, авылдашлары хакында уйлаудан куркып кына, артына борылып карарга һәм үткәннәрне казып чыгарырга мәҗбүр булды түгелме соң ул бүген?.. Бу күнегелмәгән ят халәт, ят хис үзеннән агып килгән җылы, куе һава кебек аны сарып, чолгап алды, ул барган саен хатирәләр болытына тирәнрәк күмелде, уралды, һәм менә шунда гына үзе өчен коточкыч бер хакыйкатьне ачты Мирвәли: инде курыкмыйм, теге чакларда җанны биләгән шүрләү, шигәюләр тәмам һәм мәңгегә онытылды, хәзер мин җир җимертеп яшим дип, үзен-үзе ышандырулары бары да сабын куыгы кебек шартларга гына торган икән! Йөрәк кагып яшим дип, үзен-үзе сабыйларча юаткан Мирвәли, артына, гомереңең үзе кечкән ягына борылып карауга ук куркып, имәнеп китте...

Үзе белән үзе беренче тапкыр очрашу куркытты аны! Үткән гомере караңгы әрем сабаклары артында посып торган шөкәтсез өрәк, букәй кебек нурсыз, куркыныч, шыксыз булып күренде аңа.

Каны туңып, тәне куырылды...

Илле сигез еллык гомереңне илле сигез чакрым арада гына як-ягыңа таратып үтеп булмый икән.

Моңарчы Мирвәли, нинди дә булса кирәксез уй миеңне томалый икән, андый чакта шул уйны бик ныгытып, тоташтан уйларга кирәк, шунсыз аннан котылу әмәле юк дип, инанып яши иде... Хәзер исә, менә онытам, менә котылам, бөртеген дә хәтер сандыгында калдырмыйм, барын уйлап бетерәм дип, никадәрле чәбәләнсә дә, тыпырчынса да, үткәннәр аның якасыннан чормап тоттылар да, үзләре белән ияртеп, сөйрәп артка киттеләр.

Ул, дерелдәп, кипшергән иреннәрен ялады. Ерак юлларда адашып, кара төннәрдә саташып, төшләнеп беткән, телдән калган сырхау, бәхетсез кеше итеп тойды ул үзен. Һәм курка-курка гына, кан калтырап, күңеленә килгән беренче сүзне кычкырып әйтеп карады.

— Шәмсегаян...

Ат, миңа дәшәсеңме син, сәер юлчы, дигән сыман күзен кырынайтты, юлда утырган кош, сискәндереп, пырылдап кыр өстенә очты. Дәү, иләмсез канатларын тавышсыз гына кагып-кагып яркантлар бөтерелде. Тау бармы әллә биредә? Каян килеп чыкканнар алар яркантлар? Ничә чакрым үтелде икән?

Ул тагын:

— Шәмсегаян! — дип эндәште һәм үз тавышын үзе танымады. Ниндидер моңарчы сизелмәгән сагыш, кимсенү, түбәнсенү, юксыну бар иде анда. Ул кинәт кенә башын артка чөйде һәм, ап-ак җәймәгә төренеп, арбада шым гына яткан хатынына таба иелде.

— Шәмсегаян!..

Табигый буларак, үткән көннәр белән күңелгә хатыны килде: гомеренең иң зур өлеше аның белән үтелгән, бергә кичелгән иде...

— Карачурага кайт, дисең син... Шунда кал, дисең, Шәмсегаян... Менә кайтып барабыз... Кайчан исә бу юлларны үтәрмен дә Карачурага кайтырмын дип һич тә уйламый идем инде мин. Күрәсеңме, кич булды... Иртәгә дә көн чалт аяз булыр, боерган булса. Кояш бик кызарып, моңаеп баеды... Ут кебек яна иде ул, сизденме икән син?.. Без барасы юллар әнә шунда, кояш баешында инде... Шунда, диделәр... Карачура... Хәтерендәме, син авылның иң матур, иң сылу кызы идең... Мин Нөркәй ярминкәсенә киткәч, сине Түбән авыл егетләре урларга йөри икән, дигән хәбәр ишеттерделәр. Шуны ишеткәч эткәйнең, акбүз айгырына менеп алдым да ярминкәне ташлап авылга чаптым! Ничек? Мирвәлидән узып кыз алыргамы?.. Булмый торсын әле! Дус егетләр белән Түбән авылларның тәҗе, камыт бауларын тураклап бетереп,

үзләрен җир күмере ясап тукмап җибәргән идек без. Мирвәли юлына аркылы төшәргә йөрмәгез яңадан!.. Хәтереңдәме, тәртә араларына үзләре җигелеп трантасларын сөйрәп, авыл буйлап ничек керегә чапканнар иде алар! Адәм көлкесенә калганнар иде! Әй-й-й, Мирвәлигә каршы чыгарлык егет бар идеме әллә авылда?.. Авылда гынамы?.. Тирә-якта бер иде шул ул... Сабан туе батыры иде... Исеңдәме икән, икенче көнне син тутаңнарга, Имән урамына чыгып бара идең. Кулыңда бәләкәй генә төенчек, ярминкә күчтәнәче, имеш... Башыңда бөрчекле яулык, өстеңдә бәбәй итәкле яшел күлмәк иде... Безнең тыкрыкка җитүгә, мин сине, күтәреп алып, үзебезгә алып кергән идем... Син бер дә карышмаган идең, Шәмсегаян. Әткәмәнкәм рәнҗер дип кенә үксеп-үксеп елаган идең... Әнкәй сине юатып, кәрәзле бал белән чәй эчерткән иде... Онытмадыңмы икән, ул кичне мин капканы арба кендеге белән бикләгән идем, этне бәйдән ычкындырып, ак келәткә, үзебезнең янга, корулы мылтык алып кергән идем. Мылтык атарга да, эттән талатырга да туры килмәде... Кызганыч! Ә мин кемнәрнеңдер, Түбән авыл егетләренең, бөтен туган-тумачаңның сине йолып алып китәргә тырышып, җыелып, коралланып килүен бик, бик теләгән идем. Мирвәлинең беркемнән дә курыкмавын, аның кем икәнлеген нәкъ менә сиңа бик тә күрсәтәсем килгән иде ул чакта!..

Тик ул төнне безне берәү дә борчымады... Келәт почмагында тычкан кыштырдагач кына: «Мирвәли җаным, нидер кыштырдый, тычканмы шунда, куркам!» — дип, таң алдыннан мине уяткан идең... «Ха-ха-ха дип озак көлгән идем мин». «Син тычканнан куркасыңмы? Тычкан түгел, арысланнар, өере белән ач юлбарыслар килсен, курыкма!» — дип ярыла-ярыла шаркылдаган идем мин... Оныткансыңдыр да инде, этиең карт иртә таңнан, көтү куыга безгә килеп җиткән иде. Бүгенгедәй күз алдымда, аягында иске чабата, мескен бүрек, өстендәге киеменең элә-танагы калмаган иде. Юк, сугышырга килмәгән иде ул, ызгышырга да нияте юк иде... Йөзлектә озак кына оеп утырган иде, мескен... Хәле калмаган иде... Язмыштан узмыш юктыр, Мирвәли кияү, кызыбыз бер генә, Алла хәерле итсен, синең өчен дә бердәнбер булсын, кадерләп кенә тот, зинһар, дип ялынган иде, бахыр...

Мирвәли тынып калды, кара-кучкыл күләгәләр тирбәгән кыр өстендә шашып-шашып бытбылдыклар кычкыра иде. Биектә, күгелҗем күк белән кара җир тоташып, юка пәрдә эленгән урында, утлы күзләре белән кырны капшап бер машина чыкты да тиз үк эреп югалды. Кайсы яктадыр иренеп кенә этләр өрәләр иде. Юлның бер ягында тау иде, ахрысы, өем-өем торган таш-

лар һәм алар янында куерып үскән үлән тубаллары карaеп калды...

Шәмсегаянның этисе, авызындагы кара канны йотып булса да, ризалашты, тик менә Мирвәлинең үз этисе... Шәйхразый бай...

Ярминкәне ташлап киткән өчен болай да Мирвәлигә кызып кайткан Шәйхразый, улының авылда иң ярлы кешенең кызын алуын, аны да ябыштырып чыгаруын ишеткәч, иң элек, бисмилласы дип хатынының яңагына берне чалтыратты да Мирвәлине чакыртты.

— Сиңа ике генә юл: йә уйнашчы өтегеңне бүген үк талаклап аерасың, йә аның белән өйдән чыгып китәсең! Китәсең икән, бел: күзеңә кырып салырга бер мыскал байлык бирәчәк түгелмен!

Сүзе кыска иде карун картның...

Мирвәлинең җавабы аннан битәр кыска булды:

— Ярар!

Ул Шәмсегаянны ияртте дә авыл читенә, япа-ялгыздан ничарадан бичара тереклек кылып азапланган ятим карчык Таифә йортына барып урнашты. Шәйхразый йортыннан сыңар җеп тә алып чыкмады Мирвәли. Юк, аламы соң! Горур иде ул, егет кеше иде!..

Яшь кияү белән яшь кәләшнең, бәләкәй генә төенчек тотып (Шәмсегаянның күлмәк-күнчеге иде төенчектә!), бай капкасыннан текә генә чыгып китүләрен әнкәсе үкереп, эткәсе тешен кысып, янап, каргап, тәрәзәдән карап калдылар.

Шәйхразый бай йортыннан чыгып китүләренә Шәмсегаян чиксез шатланды, чамасыз сөенде, куанды! Ярата иде шул ул Мирвәлине! Таза, көчле егет иде Мирвәли... Чибәр иде! Аның ярты арба печәнне өч җәпле агач сәнәк белән элдереп алып, күз дә йоммыйча, биек кибән очына чөюләрен күрсәң... Бай йортында үссә дә, кечкенәдән эш арасында уралып, хезмәтне сөя иде ул, бер генә минут та тынмый иде. Өй арасында урала, кыр эшеннән башы чыкмый, өмәләргә, күрше-күләнгә ярдәмгә дә беренче булып барып җитә иде. Сүгә иде, эт итә иде андый чакларда улын эткәсе!

Шәмсегаян эш арасында мәхәббәт, куаныч тулы күзләрен иреннән ала алмый, алсу бармак очлары белән генә аның янып торган кайнар беләгенә кагыла. Иреннәре ят колаклар ишетмәслек итеп сак кына пышылдыйлар:

— Синең кебек үк баһадир улым булсын иде минем, Мирвәли!

Мирвәли ап-ак тешләрен күрсәтеп елмая һәм хатынын тәмам оялтып, кешеләргә ишеттереп, аның сүзләрен куәтли:

— Нәкъ синең кебек үк сылу, зур кара күзле кызым булсын иде минем, Шәмсегаян...

Карун, холыксыз атасы йортыннан китүгә Мирвәли үзе дә куанмадымы әллә?..

Ничек матур, һәйбәт яшәп киттеләр алар Таифә йортында! Иң элек карчыкның өен сипләделәр. Чуал буеннан бәрмәнчекле тал чыбыгы ташып, өйалды үрделәр, аны кызыл балчык сылап җылыттылар. Бәләкәй генә лапас-кура әтмәлләделәр. Сәке такталарын яңага алыштырдылар. Беркөнне Мирвәли чормадан иске кабык бишек табып төште. Аны чистартып юып, кагып, ямаштырып көлешә-көлешә урынына менгереп куйдылар: «Көтеп ятсын әйдә!» Дөньядагы үзгәрешләргә, авылдагы имеш-мимешләргә әллә ни колак салмыйча гына, үз хәлләреннән бик канәгать, риза булып, икесенең дә күңелләренә мөлдерәмә тулган мәхәббәтне юмарт бүлешеп, кайгы-хәсрәтсез яшәделәр алар...

Йортлы-җирле, атлы-тунлы гаиләдә туып, иркенлектә-муллыкта үскән Мирвәли кәҗә савып кына яшәргә риза булырмы дип, Шәмсегаян башта эчтән сызып, көеп йөргән иде, хәвефләнүләре юкка булды, ире, авызын ачып, бер мәртәбә дә зарланмады.

Балалары гына булмады аларның!

Моның өчен үзен гаепле санаган Шәмсегаян борлыгып, бәргәләнеп яшәде. Ул, Мирвәлигә әйтмичә генә, күрәзә карчыклар янына барды. Күзләреннән кайнар яшьләре акса акты, әни буласы килеп, ирен сабый белән куандырырга омтылып, толыпка төренеп усак гөмбәсе ысы астында сәгатьләр буе буылып ютәлли-ютәлли тиргә манчылып утырды... Боларның барын да белеп йөрде Мирвәли, әмма хатынына каршы килмәде, бала булуны ул да бик тели иде. Шәйхразый карт, мин каргадым аларны, хатыны шуңа күрә балага узмый дип яман хәбәр таратты...

Дөнья, вакыт, гомер, чор төшенчәләре, заманның катлаулы язмышы, каты көрәш-бәрелешләре, бу гашыйклардан читтә иде әлегә! Дөнья мәшәкатьләренә дикъкать биреп торырга алар бер-бере белән артык бәхетле иделәр. Бәхетсезлек уйны йөгертә, бәхет күп чакта ваемсызлык! Ләкин вакыт-патша, тормышның астына ут ягып, аны кайнатып кына торды. Замана дулкыннары олы юллардан читтә, аулак бер куентыкта яткан Карачурага да килеп бәрелделәр. Кич-көндезләрен сыңар күзе белән генә дөньяга карап торган кырык терәүле тәбәнәк өйне дә ялмадылар алар. Дулкын Таифә карчыкның җәй көне дә чыптасы кубарылмаган юка ишеген киереп ачып түргә узды, буталды, өерелде... Дулкын бәхетле Шәмсегаян белән бәхетле Мирвәлине дә кайнар түшәктән күтәреп алды, ваемсыз Шәмсегаян белән ваемсыз Мирвәлине дә чай-

калдырып үзе белән алга әйдәп алып китте, әллә кайсы ярларга илтеп сылады, тагын күтәреп алды, тагын бәрде...

Менә шул вакыйгаларга утыз ел вакыт үткән...

Шәфәкъ Мирвәлинең күз алдында янып, сүнеп бетте. Күктә сүрән моңсу йолдызлар арта торды. Йолдызларның саран гына сирпелгән тоныкяктысында алда кара бау шәйләнде. Аяк астында гына вак ташлар чыштырдады, бара-бара кара бау урманга әйләнде һәм алар озакламый агачлар арасына барып та керделәр. Урман йокламаган иде әле. Кичне зарыгып көтеп тамак ялгарга чыккан вак-төяк җәнлекләр посып кына кыштырдыйлар, агач аралары сак тынлык һәм шом белән туп-тулы иде. Моны Мирвәли генә түгел, акбүз ат та сизде, башын күтәреп, колакларын ялт-йолт уйнатып, кара күләгәләр куерып эреп яткан куак асларына шомраеп карап бара башлады. Мирвәли тәмәке кабызды, йотлыгып-йотлыгып ачы төтенне йотты һәм арбага ныграк ябышты. Әйбәт бөкләнмәгән кадак очлары аның учларын чәнчеп авырттырдылар, әмма ул аларга игътибар итмәде. Нечкә кулларын юлга ук чыгарып сузган чикләвек куаклары салкын, чалгы янавычы кебек кытыршы яфраклары белән аның бөдрә сакаллы битен сыйпадылар.

Урманга кергәч тә аның уйларында курку өстенлек алган иде, тора-бара бу хис кимеде, шүрләү югалды, аның урынына баягы истәлекләр күңелдә яңардылар. Ул аларны, онытырга тырышып, җырлап та карады:

Карада гы-най урма-а-ан, караңгы-ы-ы тө-ө-өн...
Яхшый-ы-ый атлар кирәк үтәргә-ә-ә-әй!

Болганчык күңелне моңлы борынгы җыр да тынычландыра алмады, ул гаҗиз булып, интегеп тагын хатынына эндәште.

— Илле сигез чакрым... Якын ара түгел ул, Шәмсегаян... Илле сигез ел гомер азмы әллә?.. Безнең икебезгә дә быел яз илле сигез тулган икән. Кайсы айда тугансың әле син, нинди көндә? Хәтерләмим... Нигә бер мәртәбә дә туган көнеңне үткәрмәдек икән без? Нигә сиңа атап бер бүләк тә алмадым икән мин? Безнең халыкка ят гадәт дияр идем, кешеләрнең үз бәйрәмнәре булу, ул бәйрәмдә бер-береңә кадер-хөрмәт күрсәтү нигә ят булсын? Белә идем, күрә идем ләбаса, кешеләр үз бәйрәмнәрен — туган, өйләнешкән көннәрен аерата кадерләп, башка бәйрәмнәрдә булмый торган самими җылылык белән үткәрәләр иде. Нигә безнең генә үз бәйрәмнәребез булмады икән! Нигә?!

Ул тәмам ачыкланган, айнык акылы белән Таифәләрдән киткәннән соң булган утыз еллык гомер юлына кайтты, карманып, аһ, менә бу минем бәхетле көнем, иң рәхәт

минутларым минем менә шул чакта булган дип әйтерлек мизгелләр эзләде... Утыз еллык озын гомереннән бәхетле айлар-атналар түгел, минутлар, мизгелләр эзләде! Эзләгән саен аның маңгаена салкын тир мулрак чыга барды. Чөнки андый минутлары юк, аларны хәтер сакламаган иде.

Балачак... Балачакның шатлыгы гына истә кала, бар кайгы-хәсрәте онытыла. Олыгайгач исә затлык тизрәк онытыла, йөрәктә шыткан кайгы, әрсез эт эчәгәсе кебек, тамырларын бик тирәнгә җибәреп, мәңге онытылмый... Шулай да әгәр Мирвәли куана белгән булса, үзенә дә, кешеләргә дә бәхетле минутлар алып килгән көннәрен хәтерендә саклар иде!.. Ичмасам, беркөнне!

Балачак...

Үсмерчак...

Егет чак...

Әллә булмадылармы алар? Бәлки, Мирвәли шушы якты дөньяга, зәп-зәңгәр күкле, сихри сабан тургайлы дөньяга, ут-кояш янына, энҗе йолдызларга иптәшкә авыр аяклы, җәфаланган, таланган йөрәкле, йончыган күңелле булып тугандыр?! Тугандыр да балачак, үсмерчак, егет чак дигән матур, илаһи төшләр күреп кенә ымсынып, кызыгып, нәүмизләнеп калгандыр?.. Югыйсә бәхет, шатлык, сөенечтән бер мәртәбә туя авыз иткәне булса, соңгы утыз ел буена шуларның берсен дә тулаем татымыйча, җир тудырган бәхет-сәгадәттән өлеш алмыйча яши алыр идеме?!

Юк, юк... Булды бәхет, булды! Төш кенә түгел иде бит алар!

— Юк, юк, Шәмсегаян, — диде ул, кабаланып. — Төш кенә түгел ич, син барын да беләсең!.. Югыйсә син, Карачураның иң сылу кызы, авыл егетләренең генә түгел, тирә-як егетләренең дә күңелләрен тартып торган кәгъбә, мине яратыр идеңме? Сөя идең бит син мине!.. Тиңдәшсез бәхет булган ич синең мәхәббәтең!.. Бүгенгедәй хәтеремдә, Өч кое янында ал читле яулык бүләк иткән идең... Сабан туйларында көрәшләрдә синең күз карашыңны тотып алсам, арысландай гайрәтләнә идем мин... Ничек өздереп карый белә идең син, Шәмсегаян!.. Болар барысы да яратканга бит, сөйгәнгә!..

Ни өчен яратты икән ул изге, саф күңел аны? Ул яратырлык, аның тирән күңелен җәлеп итәрлек асыл кешелек сыйфатларын, сафлыгын, камил матурлыгын тормышның кайсы сикәлтәләрендә сарыф итеп, әрәм-шәрәмгә таратып бетерде икән Мирвәли?!

Сөя иде бит Шәмсегаян!

Сөймәсә, ябышып чыгар идеме?

Сөймәсә, аның белән Таифә карчыкларга күчеп китәр идеме?

Сөймәсә, аның белән авылны ташлап, җиде ят җирләргә чыгып олагыр идеме?! Туган туфрагын ташлап, ата-анасыннан фатиха сорарга онытып, суга йөргән коечишмәләрен, инеш буендагы еламсар талларны ташлап... Барын ташлап билгесезлеккә чумды... Теге дәһшәтле төнне, аларның гомер юлын кырт иттереп урталайга кискән салкын төнне...

Салкын иде ул төн, буранлы иде... Зәһәр буранлы! Станцага барып җиткәнче алар икесе дә шыкранлап катканнар иде. Шунда, станцага җитәрәк, Шәмсегаян Мирвәлигә җылы шәлен салып биргән иде...

— Мә, Мирвәли, эчеңне суык алды, син бигрәк ык туңдың! Муеныңа ура... Җылын! Җылын да уйла! — дигән иде.

Нигә Мирвәли шул чакта аның шәлен алды икән? Аның үзенә дә салкын булгандыр бит! Нигә шунда, юлда чакта, йолдызлы күк астында, буранлы җир өстендә япаялгыз, икәүдән-икәү генә калганда аңа бер җылы сүз дә әйтмәде икән? «Ике көн юлда, буранда килеп туңмадыңмы, Шәмсегаян?» — дип кенә сораган булсачы!

Тәнен генә түгел, күңелен дә бераз җылытсын дип салып биргән иде бит ул җылы шәлен!.. Кая ул күңелен җылыту!..

— Уйланган! Кискән дә каплаган! — дип усалланып җавап биргән иде ул.

— Уйла, Мирвәли, — дип кабатлаган иде Шәмсегаян. — Әле борылып кайтырга да соң түгел, күңелгә мондый йөк салып ерак юлга чыгуның хәере булырмы?..

Чыннан да, әгәр ул шул чагында Шәмсегаянның акыллы киңәшен тоткан булса?.. Барысы да башкача юл алыр иде бит!.. Ләкин ничек булыр иде икән ул «башкача»? Кем белсен...

— Салкын, зәһәр кыш иде ул, Шәмсегаян, исеңдәме икән? Аннан соң мондый үзәккә үткеч салкыннарны күргән булмады. Гел елак кышлар китте. Язда гына була торган сыерчык бураннары гыйнварда да улады, агачлар сыларын елына әллә ничә кат чыгардылар... Ә ул кыш салкын иде! Күп юллар үттек без ул чагында синең белән!.. Борылып кайтырга ярамый иде, кайтыр юлларның барын кисеп бетергән идем мин!.. Әй-й-й, ниләр күрмәде безнең башлар? Кунмаган вокзал, кагылмаган шәһәр аз калгандыр... Синең җылы шәлеңә төренеп, азмы йокладык без... Нигә шул чакларда бер мәртәбә дә зарланмадың син?

Шәмсегаянның зарланмавын ул беренче мәртәбә хәтеренә төшерде һәм хатынының сабырлыгына хәйран калды... Үзенә оят, уңайсыз һәм читен булып китте, һәм ул

хатирәләрнең бу кишәрлеген тизрәк, абына-сөртенә булса да, капыл-копыл узып китәргә ашыкты...

Суык кышны юлда, сәфәрдә уздырып, язга алар көнчыгышның аулак, кечкенә бер шәһәрендә тукталдылар, бар булган акчаларына җыйнак кына йорт сатып алдылар. Йорт нәни иде: ике тәрәзәсе ишегалдына караган — анда мескен генә утын сарае, җилкапка күренә. Урам якка ни өчендер бер тәрәзә генә уйганнар. Бәлки, йортны да Мирвәли кебек абынып шушы якларга килеп сөрлеккән адәм салгандыр?..

Урнаштылар, ләкин Мирвәлинең күңеле утырмады. Ары-бире мәгънәсезгә сугылып көннәрен үткәрде ул, шыпырт кына, яшереп кенә эчә башлады. Шәмсегаяннең тизрәк аны эшкә кертәсе, нәрсә беләндер мавыктырасы, онытылырга булышасы килә иде. Озак интектерде аны Мәрвәли, бер эшкә дә кулы бармады, ниһаять, бер кичне онга манчылып кайтып керде дә:

— Колак итемне ашаудан туктарсың бит? Тегермәнгә эшкә урнаштым,— диде.

Шәмсегаян төшкә кадәр ишегалды тәрәзәсен күзәтә, һава ничек бүген, яңгыр яумыймы, кар?.. Төштән соң урам яктан күзен алмый: Мирвәлие эштән, тегермәннән кайтып килмиме?

Аның тегермәнгә эшкә керүен Шәмсегаян башта ук өнәмәде: пычрак, тузан арасы; юньле алы-ялы юк, эшче куллар кайда да кадерле чакта тегермәндә бурсаеп ятудан ни ямь табасың, дип еш кына үпкәләп, әрләп тә карады. Ул чакта Мирвәли тегермәнгә эшкә керүенең сәбәбен яшергән иде, хәзер түзмәде, үзе үк сөйләп бирде.

— Нигә кердең, дигән идең син, Шәмсегаян... Шулай! Сере бар иде аның!.. Сере! Каңгырып эшсез йөргән бер-көнне адашып кына тегермән янына барып чыктым... Карыйм, олаулар тора... Иген исе килә!.. Бодай исе!.. Күкрәкләр киңәеп китте... Кыр эшен ярата идем бит мин, гомерем иген игеп үтәр дип уйлый идем. Инде тегендә, туган җирдә, мине мәхрүм иткәннәр икән, ичмасам монда ашлык арасында булыйм дип кердем мин тегермәнгә! Гел ашлык арасында!.. Килүчеләрнең дәү, буаз капчыкларын киң арбалардан бушатып эчкә ташырга, ташып бетергәч мунчала бауны чишеп беләгемә кадәр бодайга тыгылырга ярата идем мин! Кыр исе килә иде бодайдан! Ындыр исе! Арбалар исе, ат исе!.. Көлтәләр, иген тузаны исе, көзге келәтләр исе аңкый иде аннан... Тагын бер сәбәбе бар иде, Шәмсегаян... Үтелгән юллар ерак, кичергән хәлләр авыр иде... Безнең арттан байтак кара сулар аккан иде бит! Ә тегермәндә нибарысы өчәү

эшлибез!.. Каян килдең син, нигә килдең, кем син дип төпченүче юк, сорашучы юк иде. Барыбыз да бердәйләр идек... Тегермән ташы барын да онга әйләндерә!

Мирвәли авыр сулады... Тагын тәмәке кабызды... Шәмсегаянга серен, ачкан саен ул үзенең бушаныбрак калганын сизә, күңелендәге бушлыкка бүгенге көннең авыр, салмак хәсрәте кереп тула бара, һәм бу яңа хисләр күңел төбендә, моңарчы берәүнең дә күзе җитмәгән почмакларында сүнеп яткан хатирәләрне уятып кысрыклап чыгаралар иде... Ләкин ниндидер бер көч Мирвәлине тыеп тора, ул барын да ачып салырга әле дә курка, Шәмсегаян белән барын да уртаклашудан тартына иде. Мәсәлән, шул чагында, тегермәндә тыгыз капчыклар күтәргәндә, «Карачура кырларында үскән бодай түгелме икән болары?» дип еш-еш уйлауларын, юрауларын әйтергә базамы соң ул бүген?! Кая ул!.. Әйтү түгел, уйлаганы өчен дә үзен-үзе сүгеп, әрләп йөргән иде бит ул заманында!..

— Шәмсегаян, синең хакта бик аз, аз уйлый идем мин... Сине дә онытырга тырыша идем. Ни өчен? Бәлки, син Карачураны гел-гел искә төшереп торучы бердәнбер тере шаһит булгангадыр? Үзем дә белмим... Авылдан алып чыккан аз-маз әйберләрең акрынлап тузды, намазлыкларны бозып миңа ыштан иттең. Теге шәлең дә мич арасында песи түшәгенә әйләнде... Ә син, ничә карасаң да, һаман Карачураны хәтергә төшерә идең! Ә минем аны мәңгегә онытасым, күңелемнән бөтенләй сызып ташлыйсым килә иде. Шул авыл искә төшкән көннәремне каргалган көннәр дип исәпли идем мин. Һич онытып булмады башта аны... Яши-яши онытылган кебек булды... Тик шул авыл белән бергә сине дә хәтеремнән чыгардым, ахрысы... Ачулангансыңдыр инде миңа... Барын да сизеп, аңлап йөргәнсеңдер!.. Сизми буламы соң? Нечкә күңелле идең бит син, Шәмсегаян! Ачуланма мине, яме?..

Ул таза, нык тешләрен көлгә әйләндерергә теләгәндәй шыгырдатып кысты, ыңгырашып җибәрде, аның ярым улау тавышына охшаган бу ыңгырашында чиксез үкенү, тирән, авыр сагыш бар иде. Ул менә хәзер генә, хатынының мәете салмак кына аккан арбага ябышып кайтканда гына, үзенең өйдән читләшүе хатынын нинди зур рәнҗетү булуын аңлый алды!.. Шул читләшүе белән аны шикләнергә, икеләнергә, кайгырырга мәҗбүр иткән бит ул!.. Сүзсез генә аның йөрәген даим талап яшәгән икән! Аның йөрәген, Шәмсегаянның...

Тегермәнче дуслары белән акрын-акрын шешәдәшләргә әйләнеп, исереп үткәргән көннәрен хәтерләде Мирвәли...

Исереп үткән көннәр, кичләр, төннәр... Баш авыртулы

иртәләр... Димәк, ул көннәрдә аның уйлау сәләте булмаган, тәрәзә алдында үскән миләүшәләрнең татлы-тәмле исләрен сизмәгән, төнге тынлыкка хәйран булып күккә — ука читле Киек Каз Юлына күтәрелеп карамаган. Димәк, ул көннәрдә Мирвәли бөтенләй яшәмәгән!.. Ә Шәмсегаян? Яшәгәнме ул?..

Илле сигез ел дөньяда тордым дип әйтү генә ансат... Илле сигез елның күпме көннәрен аңсыз, хиссез, мәхәббәтсез, күңелең нурсыз килеш, җаның булганга гына кыймылдап, шуышып, газапланып үткәрде икән ул!.. Бик күп көннәрен, айларын, елларын... Атна ахырында тегермән каравылчысы зур арыш капчыгы белән кибеткә буш шешәләр төяп китә иде. Әй-й! Мирвәли ул капчыкларда үзенең кадерле, санап кына бирелгән гомеренең иң матур көннәре урланып китүен белгән булса!.. Әй-й-й!.. Шул ук капчыкларда Шәмсегаянның, аның йөрәк парәсенең, кадерле минутлары да китә торган лабаса!

Киң дөнья хакында, кешеләр хакында, алай гынамы, үзең белән бергә утыз елдан артык бергә, бер караватта тән җылыңны тоеп, мәхәббәт бүлешеп гомер иткән хатының хакында онытып яшә инде! Онытып, аның да кеше икәнлеген хәтердән чыгарып, аның сиңа нур, тынычлык биргән күзләренең төсен онытып, кайчандыр үзең үк сөеклем дип атаган кешеңнең кулларын, күкрәкләрен, билләрен бер назламыйча яшә инде!

Нинди кызганыч иде бит аларның сөйләшкән сүзләре!

— Мин киттем...

— Соңгарак калып кайтырмын...

— Токмач пешер әле бүген...

— Менә сиңа акча. Азмы? Җитәрме? Җиткер!

— Күн итек алдым...

Көне буе күрешмәскә аерылган кешеләр менә шул сүзләр белән хушлашалар... Кайбер көннәрдә Шәмсегаянга ул сүзләр дә эләкми... Бара-тора андый көннәр һаман ишәяләр. Атналар буена бер сүз дәшми Мирвәли!..

...Ул китә. Шәмсегаян аны болдырга озата чыга, өсбашын күздән кичерә.

...Ул һәр көн соңгарак калып кайта... Иртәрәк кайтса, кояш исе килеп торган ап-ак күлмәк кигән, җыйнак, түгәрәк алъяпкыч бәйләгән хатынының кешесез урам чатында үзен көтеп торганын күрә. Төнгә калса, капка чак кына шыгырдауга Шәмсегаян атылып ишегалдына йөгереп чыга, караңгыда янып торган төпсез күзләрен текәп аннан бер сүз, бер булса да ягымлы сүз көтә. Тилмереп көтә!

Токмач пешә, ләкин Мирвәлине көтә-көтә суынып, изелеп бетә. Төн уртасында гына кайткан Мирвәли, борынын җыерып, мыркылдап кына ашый.

...Акча. Ике арада татулык, аңлашу юк икән, нәрсә соң ул акча?! Шәмсегаян булганын чамалап, сак тота белә. Үзенә арзанлы, җыйнак кием-салымнар гына ала...

— Ничек яшәдең син, Шәмсегаян?! Ничек моңарчы чыдадың?!

Нинди ягымлы итеп озата белә иде ул! Мөлаем итеп, әйтеп тә булмый торган эчке җылылык белән каршы ала иде! Мирвәлинең кәефе, кайткан саен, кырыкка үзгәрә: төксе дә ул, шатрак та, кай арада болытлы көн кебек бөтенләй җимерелгән... Ә ул... һәрвакыт бердәй ягымлы, кече күңелле, мөлаем генә елмаеп, сабыр гына көтеп тора. Ничә кайтсаң да шулай, кайчан кайтсаң да шулай, ничек кайтсаң да шулай... Нинди сүзләр әйтә иде соң әле ул шул чакларда?..

Мирвәлинең маңгай сырлары тирәнәйделәр, ул көчәнеп-көчәнеп үзенең хәтер сандыгын актарырга тотынды; тик аннан чүп-чар: вак-төяк истәлекләр, тегермәндә ирләр әзмәз сөйләшкән оятсыз такмазалар, анекдотлар, анда җырланган кабахәт җырлар гына килеп чыкты. Хәтернең тегермән чоры чүплек башына әйләнгән икән! Шәмсегаянның аны кадерләп әйткән җылы сүзләре сакланмаган, алары онытылган... Мирвәли ачуына, сагышына буылып бөтен урманны яңгыратып кычкырып җибәрде:

— Әй-й-й!

Тын гына изри башлаган урман сискәнеп уянды, телсез агачлар үзара кысылышып шыбырдаштылар һәм, бербереенә иелеп, шомлы «әй-й-й»не әллә кайларга, шома көпшәләр, кырлыкуралар куерып үскән тын, аулак тугайларга илтеп җиткерделәр. Көне буе җилдә чайкалып әле дә хәлгә килеп бетмәгән шыгырдавык билле ярык усак тавышланып алды, аланда чабып йөргән тычкан баласын сагалап утырган мәче башлы ябалак, Мирвәлинең зарында аваздашлык ишетеп, яшь бала кебек үксеп елап җибәрде. Кара тәңкәләр таккан миләш куагында төннең сихри өненнән йокыга китә алмыйча иза чиккән ятим бер кош ефәк кебек нәзек тавыш белән һаваны һәм Мирвәлинең сагыш тәбесендә тыпырчынган йөрәген парә-парә телде...

Йа Ходай! Теле шулай ярлы булганмы аның? Якты кояшлы, яшел үләнле, шәл чукларын тирбәндереп утырган шомыртлы җирдә туып, Шәмсегаянның йөрәгенә ял булырлык сүзләр тапмаганмы ул?! Бодай басуында хәер сорашып утырган бытбылдык кебек, һаман-һаман бер үк сүзләрне генә такылдап яшәгәнме ул?! Һаман шул Карачураны хәтергә алырга куркып, үткән, үзе кылган эшләреннән өркеп шундый ярым-йорты тел белән калганмы ул?!

Урман әллә нинди серле күрсенүләр белән туп-тулы

кебек иде. Әллә каян гына, бакалар кычкырышкан яктан, җылы һава агымы килеп чыгып, Мирвәлинең муенына уралды, гәүдәсенә сарылды. Аның иманга килеп баруын сазлыктагы җеннәр дә сизенәме әллә? Ошатмыйлармы? Ул сискәнеп, нәкъ малай чактагы кебек итеп, кат-кат:

— Фу-у, җылың үзеңә булсын! — дип пышылдады.

Җылың... Шәмсегаян сап-салкындыр инде хәзер... Ул үз җылысын аңа — Мирвәлигә биреп китте. Ни өчен яшәде ул? Кем өчен? Мирвәли өченме?.. Мөгаен, шулайдыр. Ә Мирвәли ни өчен яшәде?..

Ничек яшәде соң Шәмсегаян? Ничек чыдады?!

Карачурада, Таифәләр йортында чакта, ул еш кына җырлый иде. Тавышы матур, моңлы иде аның. Нинди куаныч, мактаныч белән тыңлый торган иде аны Мирвәли. Нигә соңгы вакытларда җырламады икән ул? Нигә Мирвәли бервакытта да: «Җырла әле, Шәмсегаян!» — дип әйтмәде икән? Һаман шул каһәр суккан авылны хәтергә төшермәс өченме? Җырының да ире күңеленә хуш килмәслеген Шәмсегаян сизгәндер, белгәндер, мөгаен. Нинди җырлар ярата иде соң әле ул? «Кызыл төлке»-не... «Гөлҗамал»ны... Тагын «Сәгать чылбыры»н...

Бу көйләр берәм-берәм дә, тоташ чыңлап та аның хәтеренә кайттылар һәм бугазга кайнар төен булып утырдылар. Озакламый кап-караңгы урман юлында сәер бер авазлар чылбыры ишетелде.

Югалттым мин сәгать чылбырым-ым-ым...
Тапмадыңмы-ы, сары былбы-ы-ылым-м...

Соңгы сүзләргә ияреп аның ике күзеннән дә эре-эре тамчылар сытылып чыкты, күз яшьләре кыюланып юл яргач, бертуктаусыз түбәнгә, сап-салкын бака яфраклары түшәлгән урман юлына тамдылар.

Мирвәли үз гомерендә беренче мәртәбә оялмыйча, чын кешеләрчә, үксеп-ярсып, үрсәләнеп бәргәләнә-бәргәләнә елады. Елау катыш аның кайнар бугазыннан, ниләрдер ияртеп, укмашкан тавыш ургылып чыга иде, инде көен дә, сүзен дә аңларлык түгел, ул үкси-үкси дә, бертуктаусыз «сары былбылым, сары былбылым!» дип кабатлый башлый, күккүзләр, тукранбашлар, яшел сарутлар өстендә җәйрәп яткан Шәмсегаянның сап-салкын, боздай аякларын ике кулы белән дә өзгәләнеп сөя, сыйпый иде...

Әйе... Шәмсегаян Карачурадан киткәч бер генә мәртәбә дә туган як җырларын җырламады. Бер тапкыр да!

Җырлау гынамы сиңа, туган авылын бер тапкыр да теленә кертмәде... Аның сизгер йөрәге барын аңлады. Ул Мирвәлинең йөрәгендәге тирән яраның йомылып, җөйләнеп бетүен көтте. Ләкин Сабан туе көннәре җитсә, Шәмсегаян

да түзә алмый, өйне әйбәтләп җыештырып чыгара, шулпалы бәлеш пешерә һәм шул яхшылыклары белән Мирвәлинең чытык йөрәгенә ачуташ кырып салып тора иде...

Тора-бара Мирвәли боларның берсенә дә игътибар итми иде инде, һәм ул Шәмсегаян каһәрләнгән шул авылны хәтереннән чыгарып ташлады дип юанып яши башлады... Ә үзе?.. Оныттымы ул Карачураны?.. Байтак еллар үтте бит инде. Алар килеп аяк басканда нәни генә, җыйнак кына булган кала зураеп, шәбәеп чын шәһәргә әйләнде, автобуслар йөри башлады. Ул эшли торган бәләкәч тегермән дә зуп-зур он комбинатына әверелеп, Мирвәлигә яңа квартира да биреп куйдылар. Шәһәр уртасындагы дүрт катлы йортка урнаштылар алар. Бүлмәләре икәү аларның, тәрәзәләре дүртәү! Берсе бакчага караган, өчесе урамга. Күршеләрдә кешеләр!.. Бихисап!.. Шәмсегаян яңа йортта күзгә күренеп үзгәрде. Үзенчә ямь табып, юанып, мавыгып яши башлады...

Бер көн эштән кайтуына стенада чиккән сөлге күреп, Мирвәли куркынып китте.

— Каян бу? Берәрсе килдеме әллә?!

Сөлгеләрне мондый бизәкләр белән алар ягында гына чигәләр иде, Карачурада, Сабан туе батыры Мирвәли бик яхшы, бик шәп хәтерли!..

— Үзем чиктем. Матурмы?

— Үзең?.. Матур... Тик моннан ары андый нәрсәләреңне күземә күрсәтәсе булма!

Шәмсегаянның куе, авыр керфекләре дымланды.

— Ә мин... миңа... ялгыз башыма кыен бит! Тирәякта тормыш!

Ул артык бер сүз дә әйтмәде, сөлгене чөйдән алды һәм, кече якка чыгарып, сандык төбенә үк салып куйды.

Ниләр уйлап шундый сөлге чикте икән? Ни әйтергә теләде?..

Бер атнадан Мирвәли тәрәзә төбендә китаплар күрде.

— Русча укыйсыңмы? — дип сорады ул, китапларның татарча булмавына куанып.

— Русча.

— Укы, укы... Китаплар ярый. Боларыннан зыян юк! Үз телендә укыса, туган якларны тагын исенә төшерер дип уйлады ул. Шул көннән алар өендә китап өзелмәде. Шактый вакыт үткәч Шәмсегаян дөньяда барлыгын тагын сиздерде.

Ул көнне дә гадәтенчә ирен мөлаем итеп каршы алды Шәмсегаян, чиста ашъяулык өстенә аш дирбияләре китереп тезде. Мирвәлинең юынып килеп утыруын сабыр гына көтте һәм гади генә иттереп:

— Мирвәли, мин эшкә керергә булдым, — диде.

— Эшкә? Мин тапкан гына җитмиме?

— Корсагымнан тыш җаным да бар бит әле. Бик ясканып кына итле шулпа ашарга керешкән иде Мирвәли, хатынының соңгы сүзләре аңа үтә кызык тоелды, ул кашыгын куеп, яргаланган җилпуч учы белән майлы иреннәрен сөртте.

— Нинди эшне җан азыгы дип саныйсың инде син?

— Балалар бакчасына керәм.

Мирвәли, ашлы тәлинкәсен чайпалдырып, өстәл уртасынарак этте һәм урындыгын аударып аягына басты.

— Үзең бәбәй таба алмагач, кеше балаларын багарга булдың алайса?!

Ул шушы сүзләрен хатынының җәберләнгән чыраена лач иттереп атты да шап-шоп басып чыгып китте. Ике көн кайтмады ул, он капчыклары арасында аунап тегермәндә куныл йөрде. Ялгызлык газабы иренең ачуыннан көчлерәк булып чыкты: ул кайтканда Шәмсегаян эшкә кергән иде инде...

Мирвәли бара-бара тагын Шәмсегаянга эндәште:

— Нигә синең, минем эш хакында бер дә сөйләшмәдек икән без?! Аның шатлыклы, кайгылы чаклары да булгандыр лабаса?.. Балалар сине яраталар иде анда! Беләм! Яшертен генә, мин өйдә юкта синең янга күрше балаларының кереп йөрүен дә сизә идем. Мин кайта башласам, син аларны ашыга-ашыга озата идең. Ә алар чыгалар иде дә күзләрен зур ачып баскыч почмагыннан мине күзәтәләр иде. Мине яманлап берәр сүз әйтә идеңме әллә син аларга?.. Юк, юк, булмас! Мине яманлап сөйләмәгәнсеңдер... Синең сак күңелең миннән һаман берәр яхшылык көткәндер, өметләнгәндер... Нигә шул балаларның берәрсен күтәреп сөймәгән инде мин? Үчти-үчти итеп кулда тотмаган!..

Сугыш еллары килеп җитте. Мирвәли тегермәндә сул кулын имгәтеп чулакланып калган иде. Тешәгәндә таш чәчрәп, сул күзе дә зәгыйфьләнгән иде. Чулак дип аны армиягә алмадылар. Эшче куллар азаеп калганда Мирвәли кебек корычтай нык эшчене комбинат җитәкчеләренең дә җибәрәсе килмәде... Җиде кешелек эшли иде Мирвәли ул чагында!

Гомере буе армиягә бармый калуына астыртын гына куанып йөргән Мирвәли бүген чын күңеленнән үкенә, кыйнала иде.

— Нигә мине сугышка алмадылар икән, Шәмсегаян! Ичмасам тормышым азрак үзгәргән булыр иде. Акныкарадан аерырга өйрәнеп кайтыр идем... Югыйсә без, тормыш үзгәрми, үзгәрми дип лаф орабыз, баксаң, тормыш әллә кайчан алмашынып, үзгәреп беткән була, без

үзебез генә тораташ катып, мүкләнеп, һаман искечә яшәп азапланабыз икән! Ә сугыш — олы сынау. Ул күпләрне үзгәртте, чыныктырды, кеше ясады. Төрлесе булгандыр булуын... Нигә мине дә дөбердәтеп сугышка алып китмәделәр икән?.. Мин дә үзгәргән булыр идем. Минем күзләрем синең күзләрең йомылганчы ук ачылган булыр иде...

Ул, әйтергәме-юкмы дигән сыман, башын түбән иеп озак кына тып-тын барды. Авыр сулады, тәмәке кабызды...

— Ә беркөнне минем күңелгә сәер бер уй төште, Шәмсегаян. Үзем дә шаккатып калдым... Сугышка барасым килде минем! Барасым килде, шунда дошман белән алышта, авыр окоплар арасында Карачура кешеләре, авылдаш егетләр белән очрашасым килде. Атна буе хәрби комиссариатка барып йөрдем, ялындым, ялвардым... Җибәрмәделәр! Гаризаларым кире кайтты. Шул якты теләгемне дә синең белән ул чакта уртаклаша алмаганмын бит, сары былбылым!.. Юк, ул чагында син сары түгел идең, һич!.. Син яшь имән кебек саргаймыйча озак-озак тордың да, кинәт яфракларыңны коярга тотындың... Нык селкетте сине тормыш җиле, кайгы-хәсрәт дулкыннары нык чайкалтты... Ялгыз агачка җил ныграк берелә, ә мин синең таянычың, шыгың, тотанагың була алмадым... Сугыштан җиңүче булып кайтсам, без башка кешеләр булып очрашыр идек... Анысы да язмаган иде безгә, җанашым!..

Илле сигез чакрым...

Кырларны, үзәннәрне, болыннарны, урманнарны телеп бара да бара юл, ул уй кебек үк өзлексез, уй кебек үк чуалчык һәм озын. Күпмесе үтелде икән?

Сәгать ничә? Кесәсендә сәгате бар иде аның барын, тик дүртенче көн борганы гына юк. Тормыш җебе кулыңнан ычкынганда, атна, көн, сәгать дигән вак-төяк төшенчәләрнең әһәмияте югала икән. Болай, чама белән әйткәндә, шактый юл алдылар шикелле инде. Урман эчләп кенә күпме бардылар... Зур икән, калын икән бу як урманнары, кисеп бетермәгәннәр!..

Көн яктыра кебек тоелды аңа. Башта ул урман чыкканга гына шулайдыр дип уйлаган иде, аның сүзен раслагандай, кинәт кенә караңгыланып та алды. Әмма ул караңгылык, кемнәндер курыккан сыман, җәһәт-җәһәт эри башлады, офыклар киңәеп, ераккарак киттеләр... Бердәм биегәйгән күк гөмбәзе сыек алсулыкка манчылды, киң яфраклы аю табаннарына көмеш сыман чык йөгертеп, салкынча таң җиле исте...

Яңа көн туды!..

Больницадан ат сораганда, Мирвәлинең планы бик аңла-

ешлы иде: инде башыңа төшкән икән, маңгаең белән киртә җимереп булмый, Карачурага кайтырга кирәк... Менә ул тып-тын гына, төнлә генә, ындыр артлатып кына, шыпан-шыпан авылга кайтып керә. Төнлә чыгып киткәннәр иде, кайтып керүләре да караңгыда булсын! Урамнар буп-буш чакны чамаларга кирәк, бер адәм заты күрмәсен аларны!..

Шуларны уйлап ул Шәмсегаянны машина белән алып кайтудан баш тартты, ярты чакрымнан тавышың ишетелеп торыр, больница машинасы янына бөтен авыл җыелыр дип курыкты. Сиздермичә генә кайтып төшәргә ниятләп олаучыны да ияртмәде.

Көннең болай ашыгып яктыруы аның кәефен кырды, ул атны әйди, атлата башлады, үзе арба карамасына ябышып тыр-тыр йөгерә һәм башына төшкән авыр хәсрәтне бүлешергә һаман аңа, Шәмсегаянга мөрәҗәгать итә иде.

— Менә яңа көн килде!.. Көн аяз... Әйттем бит... Кояш кызарып баеса көт тә тор! На, на, бахбай! Атла әйдә!.. Әйе, Шәмсегаян... Син Карачураны тәмам онытты дип юкка гына алданып йөргәнмен икән!.. Гомерең буе шуны сагынып, шуңа талпынып яшәгәнсең икән лә син! Син урасы арышларны күзге җилләр койдымы икән, әллә аларны ызанда калдырырга жәлләп чит куллар урдымы?.. Син эчәсе татлы суларны кояш ялап киптердеме, әллә алар сине эзләп инешкә төштеләрме, таллы ярлар белән хушлаша-хушлаша, синең арттан идел-диңгезләргә чыгып киттеләрме?.. Син карап куанасы, син өзәсе гөлчәчкәләр пәҗеп шиңгәннәрдер... Вакытка нәфис чәчкәләр генә түгел, кешеләр дә чыдамыйлар... Рәнҗемә син миңа, Шәмсегаян! На, бахбай, атла, тукталма, на!..

Карачураны сагынып яшәвен Шәмсегаян, теле белән әйтеп җибәреп, Мирвәлине шаккатырды...

Быел яз нык кына авырып китте ул. Больницада ятып чыкты, зур шәһәрдән килгән белгечләргә күренде, мантый алмады, бетеренгәннән-бетеренде... Йөрәге зәгыйфьләнгән, диделәр.

Мирвәли каты бәгырьле кеше иде, үзе төшкән кәҗә сукмагыннан һаман чыкмады, һаман соңга калып кайтты, азрак төшереп, азрак буталып, карта сугып йөргәләде...

Беркөнне, ял көне иде, иренең гөлләргә су сибеп йөрүен күргәч, Шәмсегаян түзмәде, күңеле тулды һәм күптәннән тел очында кызышып йөргән сүзләрен әйтеп салды.

— Мирвәли, — диде ул. — Больница исен иснәп ялыктым. Күпме түзәргә мөмкин?.. Врачлар һаман чир эзлиләр, дәвалыйлар, тырышалар. Ләкин минем хастам алар бетерә торган түгел!.. Ана кеше күзе үтеп керә алмый... Алып кайт мине Карачурага! Шунда арыш басуларында бер йөрсәм, әле үлмәм, яшәрмен, бик озак яшәрмен төсле тоям.

Көтелмәгән, һич уйда-истә булмаган сүз иде. Мирвәли исәнгерәп, миңгерәүләнеп калды.

— Нәрсә? Карачурага? Онытмадыңмыни әле син ул исемне? — диде ул, кипкән иреннәрен чак кыймылдатып.

Шәмсегаян күзләрен тутырып иренә карады.

— Ә син, Мирвәли?.. Оныттыңмы син аны?

Ул сискәнеп китте. Аның баш очыннан гына пар күгәрчен пырлап үтте, алар кыеклап аннан алдарак кына юлга төштеләр һәм гөлдердәп шаяра-уйный башладылар. Юл сөзәк тау күкрәген урап бара иде. Аста, вак куаклар белән мул сарылган үзәндә, көмеш сыман елга ялтырый. Ике үсмер, чыклы үләннәрне яра-яра, һау-һаулап ат көтүе куып кайталар. Елга аръягындагы юлдан дөнья яңгыратып җырлап җайдак егет бара.

Тау кыры... Аста елга... Тал, зирек агачлары белән үз юлын бизәп-билгеләп борыла-сарыла инеш ага... Йа Ходай! Таныш җирләр ич болар! Бу урыннарда булганы бар ич Мирвәлинең!.. Әнә тегендә тауда таш базлары. Алар әтисе белән шунда таш чыгарганнар иде. Менә бу таллыкта ат сугарырга йөри иде ул, менә монда, җәенке үзәндә, чишмә янында төн куналар иде. Күрше Хәйдәр абзый таудагы чаукалыктан коры төпләр сөйрәп төшереп учак яга иде. Аларның учагы якын бармаслык эссе һәм дәү була торган иде...

Димәк... алар чыннан да Карачурага кайтып баралар!

Кинәт Мирвәлинең колак төбендә генә кемдер пышылдады: «Ә син, Мирвәли, оныттыңмы Карачураны?!»

— Тпру! Туктал, нәләт!

Акбүз ат туктады һәм, озын ялын селкетеп, башын чайкап кешнәп җибәрде. Аръякта баручы кардәше аңа сузып, яңгыратып җавап бирде. Җайдак егет Мирвәлигә кул болгады.

«Кая барасың син, җүләр!» — дип пышылдады баягы тавыш. Мирвәли ялт иттереп артына борылып карады. Юл буп-буш, баягы күгәрченнәр генә парлашып юлда йөренәләр, гөлдер-гөлдер килеп җим чүплиләр иде. Мирвәли, чык кунып дымланган арбага ябышып, озак кына каранып торды, күрсенде. Нишләргә, кая барырга?..

Ул атны кузгатты һәм, аптырагач, тагын хатынына эндәште:

— Кая алып кайтасың син мине, Шәмсегаян? Кая... Нигә ашыктырасың болай?.. Тыңла мине, китик без моннан! Кайтмыйк. Теге вакытта берсүзсез китәргә риза булган идең ич!.. Синең белән миңа күп кирәкме әллә?.. Авылга кайтып сәлам бирүләр ниемә хаҗәт? Кемгә кирәк?.. Кешегә аңа өч аршын җир дә җитә. Ә аны теләсә кайдан табып була. Дөнья киң ул, җирнең чиге-чамасы

юк. Өч көндә генә күпме юл үттек!.. Һә-й-й, өч аршын җир, күпме генә ул? Башкасы кирәкми дә... Мәгънәсез нәрсә икән ул тормыш, Шәмсегаян. Без аны, өч аршын җирне, дим, теләсә каян табабыз! Китик без моннан! Миңа анда кайтырга ярамый, ишетәсеңме, ярамый!..

Аяклары карышып, тукталырга, кирегә борылырга тели, әмма арбага чалкан яткан Шәмсегаян тау бите буйлап акрын гына тәгәри, Мирвәли сихерләнгән сыман аннан күзен алмый, тукталмый, һаман бара да бара иде. Шәмсегаян: «Минем турыда аларга сөйләрсең... кара аны, иренмә!»— дип әйди-әйди аны үз артыннан чакыра. Ә аның аяклары Карачура якынайганны белепме, авырайганнан-авырая баралар.

Нигә шушы коточкыч юлга чыкты ул?

Күңеленең нинди иләс-миләс чагында ризалашты?

Гомере буе иренә авыр сүз әйтмәгән, юаш, басынкы хатыны ул көнне йокыдан уянган вулкан кебек дулаган иде:

— Нигә шулкадәр куркасың син Карачурадан? Телгә алып сөйләшү түгел, уйларга да, искә алырга да базмыйсың. Нигә?.. Беләм, теге елны ялгыз гына чыгып китеп, син шунда кайттың. Ниятең яхшылыкта түгел иде синең! Ләкин туган җиреңә мәңге кичермәслек үк җинаять эшләгәнсеңдер дип уйламыйм мин. Әгәр шулай икән, минем гомер бигрәк аяныч, кызганыч һәм бушка узган булыр иде... Үкенече икеләтә зуррак булыр иде. Син яхшы идең бит, Мирвәли! Инде сакалың чаларып килә, гөнаһларыңны вакыт җиле уңдыргандыр... Теләсәң нишлә, әмма мин, җегәрем барында, туган җиремне күреп калырга телим. Үз җиребезгә, йомшак бишегем Карачурага сәлам бирмичә кала алмыйм... Авылдашлар күңелендә, әгәр алар онытып бетермәсәләр, качып киткән әшәке сукбай булып калу аяныч... Гомер аз калды бит, Мирвәли. Шактый яшәлде... Яхшымы, яманмы, кирәккәме, кирәкмәскәме, яшәлде!.. Күңелдә яман шеш асрап яшәдек без, яман шешкә дә түздек. Шул мине йончытты. Арыдым мин, Мирвәли. Таянып ил итәр урын юк монда. Үземне су белән, кояш, ризык белән авызландырган һәм син каргап киткән җирне сагындым. Әгәр куян йөрәк икәнсең, монда кал!.. Авыру килеш үзем генә дә чыгып китәрмен. Намус белән гомер итүемне, илбасар түгеллегемне үз телем белән кешеләргә әйтеп калдырырга өлгерим, дим... Кеше үлсә дә, кеше күңеленнән югалмый ул... Кеше күңеленең дә йомшак, әйбәт яртысында калсын иде минем исемем. Йөземнең ак икәнлеген аларга да күрсәтеп, үзем сөенергә телим!.. Син акылга килерсең дә, Карачурага кайтып баш орырсың дип бик озак көттем. Озак көттем!.. Чамасыз озак!

Карачурадан курыктымы Мирвәли? Әллә куркуга караганда нәфрәте көчлерәк идеме?!

Төп гаеп кемдә иде соң? Мирвәлинең үзендәме?

Кайда, кичермәслек нинди ялгыш ясады ул?

Гөнаһсыз Шәмсегаянның да язмышын учында кысып тотып, ул юлга кереп китәргә ярамагандыр, бәлки? Аның гомерен дә үзенеке янына — үлчәү табасына салырга ярамагандыр?!

Таифәләр йортында бәхетле, тыныч гомер сөрделәр алар. Берсеннән-берсе риза булып, яратышып, яшьлеккә генә хас ваемсызлык, куаныч белән, юктан да тәм, ямь табып яшәделәр. Тик кыска, бик кыска булды аларның ямьле гомерләре...

Күзләрнең берсендә Мирвәлинең әнкәсе үлеп китте. Аны җирләп, кырыгын үткәрергә дә өлгермәделәр, Шәйхразый кулак, Мирвәлинең әтисе, авылны дер селкетеп торган имәндәй нык, егәрле кеше дөнья куйды...

Истә-оста югында Мирвәли, Шәмсегаянны да ияртеп, атасы йортына кайтты. Башта нык кына киреләнсә дә, Шәмсегаян Мирвәлине җиңде: алар үз яннарына Таифә карчыкны да сыйдырдылар.

Шәйхразый карт нинди хәйлә, елгырлык белән шушы чуалчык елларда да байлыгын саклап кала алгандыр, әмма амбар-келәтләрне йөреп, барлап чыккач, Мирвәли бот чабып көлде:

— Болар барысы да безнекеме?..

Көлде дә маңгаен җыерып уйга калды: әйе, теләсәтеләмәсә хәзер ул монда хуҗа, төрле юллар белән бай йортына аккан мал-мөлкәтнең бердәнбер һәм законлы хуҗасы...

Шәйхразый көзге салкыннарда, беренче кырпак төшкәч вафат булган иде, кышкы чатлама суыклар башлангач, төннәрнең берендә Мирвәлиләргә күршесе Хәйдәр карт килеп керде.

Соң иде инде, алар йокларга әзерләнәләр иде.

Шәйхразый йортыннан Мирвәлине элек-электән якын күрә иде Хәйдәр карт. Шәмсегаянның әтисе белән дә алар яшьтәшләр, ахири дуслар иделәр. Шуңа күрә Таифәләргә күчеп киткәч тә ул аларны чит итмәде, юл төшкәндә кагылып, хәл-әхвәл белешеп торды. Шуңа күрә аның болай соң килеп керүенә гаҗәпләнмәделәр...

Һәм төн уртасында сулуы кабып килеп кергән юаш карт Мирвәлинең гомер юлына балта чапты.

— Мирвәли күрше,— диде ул.— Җыелыштан кайтып килешем. Кулакларның малларын тартып алырга, үзләрен авылдан сөрергә булдылар. Синең хакта да шактый сүзләр купты анда! Син җыйган байлык түгел, соңгы

елларда эткәң хуҗалыгына кулың бөтенләй кермәде. Элек тә хезмәтче, кендекче итеп тотты ул сине! Яшьтән үк эштән аерылмадың! Моны барыбыз да беләбез. Шуның өстенә ятим карчыкны үз яныңа сыйдырдың. Әгәр дә мәгәр атаң малыннан үзең теләп баш тартсаң, сиңа җил-яңгыр кагылмас. Ахыр чиктә шулай дип сөйләштек. Байлык — бер айлык, кешелек — мәңгелек. Үзең уйла... Атаң малын хөкүмәткә тапшыр да...

— Үзең ямаулы капчык тотып хәер сорашырга чык дисеңме? — дип, Мирвәли картны бүлдерде.

— Егәрең бар, тернәкләнерсең! Без дә ата малы белән башламаган!

— Эш анда гынамы?

— Бирәбез, бирәбез!.. Безгә аның бер кирәге дә юк,— дип кыбырсынды сөенеп Шәмсегаян.

— Юк!

Атасы йортына хуҗа булып кайткач, үз байлыгын күреп көлемсерәгән, шаярып йөргән Мирвәли авыл халкының хөкемен ишеткәч кара көйде...

Моннан берничә көн элек кенә аны авыл советына чакырып кылын тартып караганнар иде инде. Ул чагында сөйләшенгән сүзләрнең мәгънәсен аңлап бетермәгән иде Мирвәли... Димәк, эшне шулайга борганнар икән! Күрче син аларны, акыллы башларны: бөтен нәрсәне —мал-мөлкәтне, мал-туарны тапшырып, шыпшыр йортта калырга! Аның үзе белән ачыктан-ачык сөйләшергә тиеш дип тә тапмаганнар!

— Юк!!!

— Бер мәртәбә син барын да ташлап чыктың ич! — Шәмсегаян да сүзгә катнашып карады. Мирвәлине игә китерә алмадылар. Яшь күршесенең мондый гадәте булырын бөтенләй уйламаган Хәйдәр карт, хәйран калып, ник кергәненә ачыктан-ачык үкенеп чыгып китте.

Йокы качты, тынычлык югалды. Өйнең бар почмакларына шом керде. Табан асларына ут капкан Мирвәли ишегалдын, капка төпләрен әллә ничә кат урап керде. Тәмәкене җен урынына күрә торган кеше, чоланнан тәмәке табып кереп, бөтен өйне сасытты. Советка барырга уйлады, бармады... Сүзләреннән кире кайта торган егетләр түгел анда!

Кайсы почмакка гына барып төртелмәсен, аның йөрәге, горурлыгы бәрелеп сызлады: аның үзеннән — хуҗадан башка барын да ничек хәл иткәннәр?!

Аның ятларга бөгелергә теләмәгән горур, кире башында усал уйлар кайнады: киңәшмичә, сорашмыйча эшләгәннәр! Кеше түгелме әллә Мирвәли?!

Тышта төн. Кырда буран. Өйдә шом... Урамга баш тыгарлык түгел: себерә... Кулына фонарь тоткан Мирвәли,

тыныч кына күшәп яткан мал-туарны өркетеп, абзар белән өй арасын бетереп йөрде. Бер керде, бер чыкты.

Кече якта Таифә карчык әллә ничә мәртәбә намазлык өстенә оялады, Алладан җәннәт, кешеләрдән тынычлык сорап мыдыр-мыдыр нидер укынды... Олы якта сүрән янган ут яктысында, иңбашына үзе бәйләгән җылы шәлен ябынып, Мирвәлине сагалап Шәмсегаян утырды... Арыпталып, ватылып урынга яттылар... Таң алдыннан ул сикереп торды.

— Кая барасың?

— Җибәр!

— Мирвәли, җаным... Нигә бу байлык безгә? Үзебез тир түгеп тапкан малмы әллә?.. Күпме кеше бил бөгеп, кан-яшь түгеп җыйналган хәрәм йорт-җир... Барын ташлыйк та чыгыйк. Советта дөрес уйлаганнар. Таифә әбиләр нигезе безнең нигез булыр.

— Булмый торсын әле!

— Чыгармыйм! Тик ят!.. Тышта төн... Төн усал уйлар уята... Таң атканын көт ичмасам!.. Кая барасың?!

— Минем беркая да барасым килми. Беркая да, ишетәсеңме?.. Байлык миңа гына түгел, аларга да кирәк! Миңа кирәкмиме ул? Минем дә азрак кешечә яшисем килә... Алар байлыкны алырга, миннән котылырга телиләр. Җибәрәселәре, олактырасылары килә! Сизәм, аңлыйм мин!..

Ул тамырлары бүрткән муеныннан Шәмсегаянның кайнар кулларын алып ташлады, үзен этеп җибәрде һәм, аннан-моннан киенеп, ишегалдына чыкты. Күккә карады — караңгы! Вакыт бар әле...

Йозакларны шылтыратмаска тырышып амбарны, келәтләрне ачты, эленеп торган тун-толыпларны, сандык-сандык, тартма-тартма кием-салымнарны, өшәнчекләрне, күзенә ни күренсә, шуларны кочагына төяп, лапаска — ит чаба торган бүкән янына ташыды. Яланөс йөгереп чыккан Шәмсегаянны әрләп куып кертте:

— Йөрмә!..

Караңгыда да тонык кына ялтырап торган ит чаба торган киң йөзле балта белән юан, имән бүкәнгә салып турады ул кием-салымнарны. Тук мәче кебек мырлыймырлый чапты, бүкән янында чүмәлә-чүмәлә булып ямаулыкка да ярарлыгы калмаган төргәк-төргәк ситсалар, чаршаулар өелде...

— Этләргә танау сөртерлеге дә калмасын!

Киемнәрдән соң чират игеннәргә барып җитте. Ул бура-бура торган бодай өстенә, лар тулы арышларга дегет мичкәсен кертеп аударды. Лапастагы колашада көз буе җыелган көлне он белән бергә бутады, борчак, ясмык өстенә шешә-шешә керосин, пычрак су кертеп тутырды.

— Ашаган кешенең эчәгесе әйләнеп чыксын, ашказаны бөрешсен!

Аның аяк тавышына уянып мөгердәп, меркелдәп, ишетелер-ишетелмәс кенә кенәп торган хайваннарга агу кертеп бирде.

— Куанычка булмадыгыз, этләргә дә калмасын!

Шырпы тотып йортка чыга башлаган иренә Шәмсегаян барып асылынды.

— Тагын нишлисең?! Җитмәдеме әллә?.. Авыл бар, күршеләр якында гына! Аларны да харап итәсең киләме?.. Иртәгә кеше күзенә ничек күренерсең? Инде болай да...

— Күрми торсыннар әле! Күрмәсләр! Җыен!

Шәмсегаян куркынып артка чигенде...

Алар, шомлы кара күләгәләр булып, авылдан икәүләшеп чыгып киттеләр...

Салкын иде ул төн, ямьсез иде... Каршы яктан искән җил, аларның бишмәт чабуларыннан сөйрәп, авылга таба тарткалады, итек куनычларына, куеннарына учы-учы белән ярма кар тутырды. Әмма алар үрмәли-үрмәли алга омтылдылар. Чөнки артка борылырга ярамый иде. Ишекләр шар ачык калган өйдә Таифә карчык туңып уянды һәм тирә-ягынданиләр булганын чамалап сөрән салды, күршеләрне җыйды...

Япан кыр уртасында, буран эчендә Мирвәли күккә карады: нәкъ аларның баш очында дәү сорау галәмәте булып Җидегән йолдыз яна иде...

О, ул авыл!.. Үзенең йолдызлы төннәре, җиләс таңнары белән Мирвәлинең төшенә кереп, аны ел буе газаплады, китмәс бизгәк булды. Тып-тын таңнарда, ат кешнәгән тавыш ишетеп, Мирвәли җылы ятагыннан сикереп тора иде. Сикереп тора да идәндә яланаяк чаба башлый, тешләрен шыгырдатып ыңгыраша... Кешеләр бәхет бүлешә торган, мәхәббәтне уртак итә торган сихри таңнарда ул, авыр йодрыгын йомарлап, кемнәргәдер янап, бүлмә буйлап бәрелеп-сугылып йөри...

Шәмсегаян зирәк күңелле иде, ул ирен нинди уйлар сикертеп торгызуын аңлый, Мирвәли шашып-шашып өзгәләнә башласа, акрын гына аның артыннан килә, иркәли, сөя, тәрәзәләрне ачып җибәрә, бүлмәне иртәнге мәхәббәтле һава, йолдызларның сүрән яктысы белән тутыра. Ире артык кайгырмасын өчен үз хәсрәтен эченә йотып, үз моңын күңелендә бикләп яши иде...

Икенче җәйне, урак өсте алдыннан Мирвәли аерата тилереп, шашынып китте. Капылт кына урыныннан сикереп тора да бер ноктага озак карап тора. Тора, тора, керфек тә какмый. Андый вакытларда Шәмсегаян өзелеп-тилмереп сорый торган иде:

— Ни уйлыйсың син? Ни җитми сиңа бу дөньяда?..

Ачулана иде Мирвәли, уйларын тырышып-тырышып яшерә иде.

Бүген дә үз-үзе белән көрәшеп, барын да сөйләп бетермәскә тырышып шактый газапланып кайтты ул... Бара-бара түзмәде, хисләр сүзләргә әйләнеп телгә керделәр...

— Шәмсегаян... Ни уйлыйсың, дип сорап ачуымны кабарта идең! Белә идең ич инде үзең дә! Күңелемдә бер генә уй иде минем: дөнья нигә болай көйсез яратылган? Әллә мин үзем яши белмәдемме?.. Кай җирдә аягымны каймыктырып чатан-ботан атлап киттем мин?.. Йортлы-җирле, атлы-тунлы бала идем, кулымнан эш килә иде, нигә болай сукбай булып җиде ят җирләрдә нужа куам?.. Мине җылы түшәгемнән торгызып, салкын урамга куып чыгарырга кемнең хакы бар иде?.. Кулак малае булып тууыма мин гаепләме?! Кулакның хезмәтчесе идем ич мин! Унбер яшьтән мин аңа бил бөктем!.. Шулай дип уйлый идем мин. Ярый, байлыкны алырга да карар кылсыннар, ди... Тик нигә мине чакырмадылар алар?.. Нигә?.. Үзем уйлыйм, үземнең сыңар күз белән генә булса да, Карачураны күрәсем килә... Үземне сукбай ясаган кешеләрнең эшен, тормышын күзлисем килә иде. Ничектер аларның эше дә минеке кебек үк уңайсыз барадыр, үзара сугышып беткәннәрдер сыман тоела иде миңа! Аларның да яшерен кайгылары бардыр, бу шыксыз дөнья аларга да җайсыз, ямь юктыр кебек иде. Болай уйларга бернинди нигезем булмаса да, кимсетелгән сынык күңелем шулай уйлап юана иде!.. Ул чагында мин боларның берсен дә сиңа сөйли алмадым, Шәмсегаян!.. Кыеп ничек сөйлисең? Үзеңнең сукыр килеш тормыш тәгәрмәче астына килеп кереп аксак чеби хәлендә калуыңны хатыныңа ничек танасың!.. Миңа да тернәкләнеп гомер итәргә бер таянычлы уй, юаныч кирәк иде ләбаса! Кеше шунсыз яши алмый. Бигрәк тә ир кеше. Бәләкәй генә өемдә, аулак ишегалдымда мин нәни генә булсам да патша идем, хуҗа идем. Бөтен дөньяга ачуланып, күңелемдәге ачу-үч тойгылары әчеп, агуга әйләнеп күлмәгемә сыймастай чакларымда өйгә кайтып кергәч, синең юаш, басымчак кыяфәтеңне күрсәм, авырайган аякларым җиңеләя, иелгән, буйсынган гәүдәм турая иде. Кеше бил бөгеп кенә яши алмый, ул кем янындадыр тураерга да тиеш бит!..

Ә күңелне бетмәс уй кыра: «Карачура... Карачура...»

Бер яктан аны онытырга, сиңа оныттырырга тырышам. Ә үзем уйлыйм да уйлыйм. Болай күпме яшәргә мөмкин иде соң?.. Нинди чаралар белән, ничек итеп үткән тарихны мәңгегә онытырга, башкалар кебек эш тәмен

тоеп, бәхет белән янәшә яши башларга? Ничек итеп?.. Ничек котылырга ул авыр йөктән?..

Җәй, эссе җәй иде... Мирвәли ул көнне эштән иртәрәк кайтты. Ишегалдында ашык-пошык кына юынды, таза беләкләрен бер ышкуда корытып, болдырга утырды. Аш өлгергәнен белсә дә, ул ашыкмады. Аяк астында ята-ята шомарып беткән бозау башы зурлыгы таштан күзен алмады... Шәмсегаян аны чакырып-чакырып карады да, Мирвәли кермәгәч, аның янына болдырга чыгып утырды.

— Шәмсегаян, мин китәм.

— Кая?

— Күңел ачылып китмәсме, дим... Тутыгылды... Курыкма, мин озакка түгел.

— Озаклыгы куркытмый. Мине синең уйларың борчый.

— Ни беләсең син алар хакында?

— Беләм...

— Саташып, төштә берәр нәрсә лыгырдадыммы әллә?

— Күңелем сизә...

— Синең күңелең сизсә, минеке тели! Юлга чыгарга кирәк миңа. Куркып, ярыкка поскан таракан булып яши алмыйм мин. Күпме интегергә мөмкин?.. Дөнья мине чишендерде, мин шып-шыр, анадан тума ялангач калдым... Исемем дә, туган туфрагым да, йорт-җирем дә юк. Сукбай, хәерче мин... Тик, сукбайның күңеле бар! Күңелемдә өзмәс сызлану!.. Нидер авырта! Мин шул авыруны кисеп ташларга телим. Һич югында, үземнең кем икәнлегемне ачыкларга телим... Ялгыштыммы, түгелме?.. Шуңа китәм дә... Билет кесәдә!

— Кая кадәр ул, Мирвәли?

— Бик еракка!

— Кайтыр юлларыңа билет ала алырсыңмы? Ару юлларга чыгасыңмы икән инде, Ходаем...

— Кайтыр юл — таныш юл...

— Мирвәли, акыл өйрәтә дип уйлама...

— Дөнья җитәрлек өйрәтте!

— Шулай да тыңла: заман үзгәрде... Күреп торасың! Нигә кешеләрдән олы, алардан аеры булырга? Әйбәт кенә эшлисең, үз тормышыңны рәтләп киләсең, әллә сиңа азмы бу? Әйтергә базмый йөри идем, Карачурадан шулай китеп бер ялгыштык, шундый кыек адымны кабатлый күрмә. Яхшы агымга каршы йөзүдән ни файда?.. Гомерең укенечле булыр, Мирвәли!

Кан бәреп торган тулы иреннәрен чалышайтып, Мирвәли Шәмсегаянга карап утырды.

— Курыкма, асарга да, таларга да җыенмыйм... Бер җилләнеп кайтасым гына килә!

— Мин дә синнән калмыйм, Мирвәли, — диде ул бераздан, нык итеп.

— Кая барасың?

— Синең белән. Ялгызым калырга куркам.

— Күрше карчыгын чакыр.

— Миңа син кирәк.

— Ә менә миңа син генә аз!.. Миңа тагын нидер җитми... Сорашма, төпченмә. Нәрсә кирәген тәгаен белсәм, үзем дә болай интегер идемме?..

Иртәгесен болдыр буенда, шома ак таш өстенә басып Шәмсегаян илереп-елап калды. Ул, очып китәргә талпынган җәрәхәтле кош кебек, Мирвәлигә омтылып каткат инәлде:

— Үкенерлек юлга чыгып, гаеп-кыек ясый күрмә берүк!.. Туган җиреңнән олы була алмассың! Сак йөр!.. Кыңгыр эш, кыңгыр эш...

Мирвәли, зифа буен бәйрәмчә туп-туры тотып, горур башын югары күтәреп, балчык түбәле тәбәнәк йортлар арасына кереп югалды...

Ике атна торып әйләнеп кайтты ул. Сакалы җиткән иде аның, ияк астында бөдрәләнеп тора, киемнәре пычранган, теткәләнеп беткән. Ул кулын бирмичә генә хатыны белән исәнләште дә, өйалдында ук анадан тума чишенеп ташлады. Тир исе, әллә кайсы якларның ят исе аңкыган күлмәк-ыштаннарын төреп чормага ыргытты. Шәмсегаянның: «Кайларда йөрдең син, Мирвәли?!» дигән инәлүле карашын санга сукмыйча биш тәлинкә аш ашады һәм иртәгесен таңнан торып тегермәнгә китте...

Шул көнне Шәмсегаян лампа куыгын төшереп ватты...

Суган тураганда бармагын кисте...

Шул көннән Шәмсегаян янында икенче Мирвәли яши башлаган кебек булды. Икенче Мирвәлинең кыланышгадәтләрен аңлап бетерү тагын да кыен, ул серле дә, ят та, сәер дә иде...

Шәмсегаян сорау тулы күзләре белән һәр көн аны озатып кала: «Кайларда, нинди ерак сукмакларда йөрдең икән син, Мирвәли?»

Хатынының чәнечкеле, таләпчән карашын күргән минутларында аның җене котыра, сүзсез булса да, төпченгәне өчен Шәмсегаянны пыр туздырып әрлисе килә. Кичләрнең берсендә шактый төшереп, кызмача кайтты Мирвәли...

— Ни беләсең килә синең?! — дип кычкырды ул, күзләрен акайтып.— Йә әйт, ни? Теге дөньяда нәнкир-мөнкирләр белән очрашып, аларга да җавап бирәсе бар әле. Анда инде нибуч!.. Ләхетең тар, чыгып ычкына алмассың!.. Ә бу киң дөньяда, якты дөньяда, мине хөкем итәрлек

кеше юк! Берәүдән дә курыкмыйм!.. Берәү дә мине хөкем итә алмас. Мин үземә-үзем судья! Башкалар юк... Юк! Син дә! Карама миңа шулай итеп! Сорама да! Белдеңме?!

Шушы ике атна...

Шәмсегаянның борчулы көннәре, куркыныч төннәре... Тычкан кыштырдавына да сискәнеп уянып, газапланып, көеп, интегеп, билгесезлек сагышында кибеп яшәгән ике атна!.. Ул хакта алар телләре белән яңадан сөйләшмәсәләр дә, икесенең дә күңелләрендә мәңгегә уелып калды. Илле сигез елның иң куркынычлы ике атнасы! Ире өчен куркып яши башлады Шәмсегаян. Мич арасында нәни кыштырдау ишетсә дә, ул тизрәк Мирвәлине уята иде.

— Җаным, тычкан кыштырдыймы, мин куркам!

Мирвәли, читкәрәк тартылып, йокы аралаш мыгырдый:

— Кыштырдамасын өчен майлый алмыйм бит мин аны!..

Илле сигез чакрым! Шактый ерак ара икәнсең син... Алар һаман юлда... Көн кыздыра да башлады. Ат өстендә яшел, дәү кигәвеннәр бызылдады. Ат бара-бара да шарт-шорт итеп тәртәгә тибә иде. Аны бераз ашатып алырга кирәк булса да, Мирвәли ул турыда уйлый алмады... Ул арт карамага ике куллап ябышкан килеш һаман тыптын бара иде...

Юк, инде калган серләрен берчакта да сөйләмәс Мирвәли! Бетте, җитте... Илле сигез түгел, йөз илле сигезне үтсәләр дә, теге ике атнаның тарихын ачмас!.. Аны хөкем итәрлек кеше тумаган әле!

Иреннәрен тешләп шактый барды Мирвәли, авыр сулады, тәмәке кабызды һәм, үзе дә сизмәстән, тагын сөйләп китте.

— Теге вакытта инәлүеңне сизсәм дә, сөйләмәгән идем, Шәмсегаян!.. Эземне чуалтып, ят станцалар аша Карачурага кайттым мин ул чакта... Арып-талып Кызыл яр өстендәге урманга кайтып егылдым. Бер көн, бер төн баш күтәрмичә йокладым... Уяндым да, урман кырына юнәлдем... Озак-озак итеп авылга карап яттым... Тормыш бара иде анда! Урамнан атлылар узып китә, уралып-сугылып алачык янында кешеләр йөри, тимер чүкиләр, кабаланалар... Җанлылык, хәрәкәт! Син, мин дип тормаган тормыш, һаман алга аккан икән. Яңа буралар күренә, инеш аша яңа басма салганнар. Казлар каңгылдый... Шунда минем башыма коточкыч бер ачыш килде: әгәр дә мин моннан ел ярым элек үлгән булсам?.. Әнә теге, синең белән чыгып киткән төнне! Үлгән булсам, үлгән булсам!.. Гел шул турыда уйлап ятам!.. Һич тынгылык тапмыйм. Мин үлгән булсам

да, тормыш шулай ук кайнап торыр иде. Барысы да искечә яшәрләр, шаярырлар, көлешерләр, эшләрләр иде. Димәк, мин бик кечкенә, әһәмиятсез зат икәнмен? Кирәгем шулкадәр генә икән! Алай булгач, табигать мине ник яраткан? Күрергә күз, үкенергә, газапланырга күңел биргән?.. Беләгемдәге көч нигә? Аякларымдагы егәр нигә?..

Шунда, Кызыл яр өстендәге урман авызында, мин үземнең япа-ялгыз калган, кирәксез, кечкенә бер бәндәчек икәнлегемне төшендем! Дөнья да, Карачура да минем барлыгыма да, юклыгыма да дикъкать итмичә рәхәтләнеп яши алалар икән. Яшиләр дә!.. Алайса мин нигә яшим?.. Шунда болай дип аңладым: әгәр мин авылдашлар белән бергә булып, тормыш казанында кайнасам, эшләсәм, эшемнән тәм тапсам, көрәшсәм, мондый газаплы сораулар белән җанымны интектермәс идем!.. Ялгызлык — җәза икән!.. Тик алар белән бергә булырга да ярамый иде инде миңа!..

Миңа күңелсез, искиткеч күңелсез булып китте... Әһә, алаймы, дип ярсыдым мин... Димәк, мин үлгән булсам, әгәр мин салкын җир куенында яткан булсам... Менә шул-чак минем күңелгә әшәке уй төште, Шәмсегаян! Мирвәли үлмәгән, ул тере әле, яши, ышанмыйсызмы, дип кычкырасым килде. Йодрыгым белән ут тулы күкрәгемне төеп җан авазы белән акырырга теләдем мин! Күңелемдәге усаллык кабара, арта барды, Шәмсегаян, ышанасыңмы?! Берсеннән-берсе әшәкерәк уйлар биләде мине... Карачураны җир йотуын теләп, Ходайга ялвардым мин!.. Җир йотмагач, болай дип уйладым... Янәсе, мин җил чыкканны гына көтеп торам... Янәсе, менә кичкә таба җил күтәрелә. Мин шуышып кына авылга юнәләм! Безнең йортта колхоз идарәсе, янәсе... Булсын! Миңа шул кирәк тә! Арт капканы ачам да ишегалдына керәм!.. Караңгы, шылт иткән тавыш юк. Җил генә улый. Барысы да йоклыйлар! Карачураның бәхетле кешеләре йоклыйлар! Караңгылыкның горур патшасы булып ишегалды уртасында мин басып торам! Мин! Мин исән! Мин яшим, янәсе!.. Җил!.. Урый-урый исә хәзер, түбәләрне йолкый! Сызгыра... Мин кәефләнеп лапаска таба атлыйм. Минем шырпыдан чыккан зәгыйфь утны көчле куллары белән җил эләктереп ала да коры лапаслар буйлап йөгереп китә, юан өрлекләрне, бастырыкларны ялмап өскә ыргыла... Салам түбәләргә менеп шатыр-шотыр бии башлый!.. Шәп!.. Иң элек Хәйдәр карт уяна!.. Күршедә генә бит!.. Ак күлмәк-ыштаннан чабып чыга да капканы тибеп ача... Карый: күрә!.. Ишегалды уртасында ялкын телләренә уралып мин басып торам!..

— Мирвәли, нишләп торасың? Янасың бит!

Шул чагында мин бер сүз белән тегенең авызын томалыйм:

— Янсын!

Хәйдәр карт нәзек тавышы белән: «Пожар, пожар!» — дип кычкырып урам буйлап йөгерә башлый...

Ә мин, ука күлмәкләр киеп, алтын-көмешкә бизәлеп ут патшасы кебек карап торам:

— Янсын! Нигезе калмасын бу йортның!.. Этләргә кара күмере дә булмасын! Тамыры корсын!

Хәйдәр карт кешеләр җыя... Чабалар, ашыгалар. Чиләкләр шылтырый... Йорт янына киләләр дә ишегалды уртасында эре генә тәмәке тартып торучы мине күргәч ләхәүләләрен укып кире чигенәләр... Мине теге дөньядан кайткан җан алучы газраил дип уйлыйлар. Үч ала дип куркалар! Ә мин?.. Мин! Көләм генә тегеләрдән!

— Ха-ха-ха!

Шаркылдап көләм!

Түбә ишелеп төшә. Ут күрше йортларга сикерә. Карачураны тоташ ут, ялкын чолгап ала! Юк Карачура! Бетте Карачура!.. Мин, канәгатьләнеп, сызгыра-сызгыра кырга чыгам... Сыза буеннан үзебезнең җирне эзләп табам. Бер учма салам җыеп алам да ут кабызып кыр өстенә чәчеп җибәрәм! Ялкын телләре шаярышып бии-бии басу өсләп чабып китәләр... Тычкан балалары чыелдый. Куркынган бытбылдыклар, тургайлар пырылдап кара һавага күтәреләләр. Басу түре ут белән тула, авыл дөрли-дөрли яна!.. Мин Кызыл тауга менеп җиткәнче авылга борылып карамыйм!.. Тиз-тиз менәм! Өстән иркенләп, озаклап авылга карап торам. Ул дәү учак кебек дөрләп минем күзләремне иркәли, шунда мин кап-кара йодрыгымны йомарлап селки-селки иң актыккы сүзләремне җил иркене тапшырам:

— Янамы? Беттеме Карачура?! Күрдегезме Мирвәлинең кем икәнен?! Ансат кына Мирвәлине Җир йөзеннән югалтырга уйладыгызмы?.. Ә-ә-ә!

— Тпру... тпру, бахбай!

Ул, ярга ыргытылган балык кебек авызын зур-зур ачып, өзек-өзек тын алып торды. Йөрәге дөп-дөп тибә, баш очында гына өздереп-өздереп сабан тургае сайрый иде. Алда гына урман... Таныш урман кебек... Шулмы-юкмы?.. Әнә аерым тырлау булып, тал әрәмәсе утыра... Арырак киткәч урман тигез почмак ясап борылып киткән... Шул, шул!. Юлы да, урманы да шул. Урман чыгуга, Кызыл яр... Кызыл яр астында Карачура!..

— Зур авыл ул Карачура!.. Булган бар, ә кәкже!

Кем әйткән иде соң әле күңел өшетерлек бу сүзләрне?! Олаучы бит!.. Теге аксыл кашлы, аңгыра кыяфәтле егет...

Мирвәли, орлыгы агып беткән тишек капчык кебек, акрын гына җиргә иңде, арба янына тезләнде һәм дегет белән каралган араталарга җыерчыклы маңгаен бәрә-бәрә ялына башлады:

— Шәмсегаян, җаным!.. Кая алып кайтасың мине?

Ишетәсеңме син?.. Тыңла, зинһар! Кайта алмыйм мин анда, ярамый! Сиңа барын да сөйләп бирдем инде. Күңелемдә берни калмады. Син хәзер барын да беләсең... Тик син теге кышкы төнне генә хәтерлисең!.. Ә Кызыл яр өстендә ятканда... Мин бит чынлап торып авыл-кырны яндырырга ниятләдем! Кулым белән булдыра алмасам да, күңелем белән күптән яндырдым мин Карачураны! Биш көн буе җилле төн көтеп яттым мин тау өстендә!.. Әллә ничек, акылыма килеп кенә, кире кайтып киттем...

Тик Шәмсегаян дәшми, акрын гына искән кыр җиле аның җәймә кырыйларын җилфердәтә, аның балавыздай йөзен азга гына ача да тагын каплый...

Аңа барыбер... Дөнья бармы, тармы ул, киңме, ыгы-зыгылымы, аңа барыбер... Мирвәли җилкәсенә төшәчәк яңа хәсрәтләр авырмы-җиңелме, аңа барыбер...

Юк, юк! Карачурага кайтырга ярамый. Ирекле баштан үзең җәза сорап барып керергәме?.. «Авылдашлар, мин гаепле сезнең алда! Үземнең дә, аның да гомерен агулап, үчемә буылып яшәдем!» — дип баш орыргамы?! Юк!..

Ул ялт итеп сикереп торды, Шәмсегаянны бер кырый-гарак күчерде, җитез генә арбага менеп утырды һәм сүс дилбегәне кагып атка эндәште:

— На-а!

Арба тәгәрмәчләре, юлдагы вак ташларны сикертеп, күндәм генә тәгәрәргә тотындылар, төне буе акрын килеп үшәнләнгән ат пошкыра-пошкыра аякларын як-якка чөебрәк юртып китте.

— На, на!

Урман тиз-тиз аларга каршы чаба башлады, ук кебек сузылып яткан киң юл буп-буш иде. Мирвәли әле артына борылып карады, әле як-ягына күз төшергәләде. Бер җирдә дә кеше заты күренмәде. Шактый баргач ул атны кинәт кенә уңга борды. Алар ташландык иске юлга барып керделәр. Арба тәгәрмәчләре астында коры чыбыклар шытырдап сынды, күчәр башлары юлга ук чыгып яңарган усак үсентеләрен иеп, кырмыска ояларын сыдырып, тигезләп үттеләр. Мирвәли, бер кулы белән Шәмсегаянны ныгытып тотып, һаман атны каулый иде:

— На, на, на!

Таныш юл... Ул тирән чокырга чыгарга тиеш... Аулак урын. Урман уртасы... Бала-чага да килеп йөрми, карчык-корчык кызыгырлык җиләкле аланнар да юк. Чаукалык, вак урман... Аннан шырлыклар башлана. Чытырманлыклар... Пәри өне! Элек шулай иде. Барган саен юл тарайды, юлга ук чыгып торган коры ботаклар Мирвәлинең манма су булган күлмәген әләктереп ерттылар. Күлмәк астыннан кояш күрмәгән ап-ак тән килеп чыкты...

Чокырга җитәрәк ул атны юлсыз җиргә борып кертте. Бик кыенлык белән генә агач арасына үтә алган ат, арбаны көч-хәл белән тартып, шарт та шорт ботаклар сындырып, Мирвәлине сискәндереп бара иде. Шырлыкка кергәч, Мирвәли арбадан сикереп төште. Куе агачлыкта үлән үсмәгән диярлек, ара-тирә аксыл, сусыл сәрдәләр генә кояш эзләп төрле якка сузылганнар. Тып-тын... Күләгә... Ул һич көтмәгәндә, «Акчарлактан да кара күләгә төшә!» дип уйлап алды, ары-бире карангач, агачлар юграк урынны чамалап җиргә чүгәләде... Шунда аяк астында аунап яткан коры ботакны алып кабыгыннан арчыды, җиргә батырды... Җир йоп-йомшак, казыр өчен бик уңай иде...

Черегән яфрак катламын күтәрүгә, астан вак кына кызыл кырмыскалар йөгерешеп чыктылар, аның тузанлы итеге буйлап тиз-тиз өскә күтәрелделәр, муенга, аркага кереп тулдылар. Кайнар тир исе җәлеп итте, ахрысы, аларны. Мирвәли аларның аяусызланып, авырттырып тешләүләрен бөтенләй сизмәде, кулларын төкерекли-төкерекли очлы таяк белән йомшак җирне чокыды... Нәзек, әмма нык, сыгылмалы агач тамырларын сындырганда тырнак төпләре канады. Тамырлар бер-берсе белән тоташып, чәбәләнеп беткәннәр иде.

Кинәт аның баш очында гына нидер кыштырдады, ул сискәнеп күтәрелеп карады һәм үзе янына килеп җиткән акбүз атның моңлы, зур күзләре белән очрашты... Ат, чебен-черкигә түзә алмыйча, шырлыкка ерып кергән һәм Мирвәли янына ук килеп җиткән иде.

Ул куркып китте. Хәле бетеп, буыннары изелеп чокырдан чыкты һәм гөрселдәп җылы җиргә капланды...

Качарга кирәк! Барын ташларга да ычкынырга моннан! Атны юлга чыгарырга, чыбык белән берне ныгытып сыптырырга!.. Китсен!.. Качарга!

Ул тир ачысыннан сызлаган күз тирәсен пычрак кул аркасы белән уа-уа мүкәли, үрмәли башлады. Бите-кулы сыдырылып бетте аның, өс-башы таланды... Шактый озак үрмәләгән кебек тоелды, ул борылып карады: башын чайкый-чайкый көч-хәл белән арбаны сөйрәп, ат та аңа ияреп килә иде... Ул ашыгыбрак шуыша башлады, тирән чокыр янына барып җитте һәм, хәле бетеп, җирне кочаклап озак кына исәнгерәп ятты. Җирдән яшел үлән исе, тереклек исе, кояш исе, туклык исе килә иде. Чокыр төбендә, ташлы ярлар арасында, нәзек кенә моңлы тавыш белән чишмә чылтырый... Ул аягына басып тормады, яр балчыгын ишә-ишә түше белән шуышып аска, чокыр төбенә төште һәм тонганын да көтмичә, эре йотымнар белән салкын, болганчык суны эчте. Ком, балчык кисәкләре аның эре тешләре арасында көлгә әйләнеп шытырдадылар, тирләгән бите буйлап әллә күз яше, әллә чишмә суы акты.

Ул көч-хәл белән тырмашып аягына басты, үрмәләп диярлек текә сукмак буйлап өскә менде. Ат сак кына кешнәп, тавыш биреп аны каршы алды. Мирвәли, алпан-тилпән атлап, арба янына килде, аратага ябышып тезләнде һәм:

— Ачуланма мине, Шәмсегаян, — дип пышылдады. — Мин сине ташлап, үзем кылган һәм ниятләгән эшләремне ташлап беркая да китә алмыйм икән инде! Булмый... Кичер мине!..

Борырга теләгән иде, ат борылмады, колакларын уйнатып һаман чокыр ягына карап торды, борын тишекләрен дерелдәтеп тавыш бирде. Мирвәли шул чакта гына аны тугарырга вакыт икәнен, хайванкайны төне буе ашатмыйча-эчертмичә куып кайтуын хәтеренә төшерде. Ул каты куллары белән биянең йомшак яңагын сөйде, сыйпады... Нишләргә? Атны чокырга төшереп булмый, сукмагы бик текә, ярлар биек, су алып менәргә савыт-саба да юк. Ул уйланып торды да, фуражкасын салып, аның эченә өрәңге яфраклары түшәде. Бер менеп, бер төшеп су ташыды, аягының җегәре тәмам бетте, атны тәмам туйганчы эчертте. Сумкадан күмәч сыныклары алды да берәм-берәм атның калтырап торган йомшак иреннәренә кыстырды...

* * *

Урамның нәкъ уртасында туктаган атны, арба янында юаш кына, мескен генә басып торган ап-ак чәчле, җиту сакаллы, таланган өс-башлы, киң җилкәле, баһадир гәүдәле картны бик тиз абайлап алдылар. Берән-сәрәнләп тә, аннан күпләп-күпләп халык урамга йөгерде. Кешеләр арасында шөбһәле сүзләр ишетелде:

— И-и бичара, берсе үлгән түгелме соң?

Мирвәли бер сүз дә дәшә алмады, ул күз яшьләре ташкынын чак тыеп тора, аның аскы ирене дерелди, күмәч-күмәч балчык каткан тезләре тыелгысыз калтырыйлар иде.

— Кая барасың болай? Кем син?!

## 4

Шәмсегаянны зур кадер-хөрмәт белән авыл зиратына, үзе теләгән почмакка, каен белән нарат кочаклашып үскән урынга күмделәр...

Аның якын кардәшләре дә, дуслары да, ахирәтләре дә табылды. Бик якын агай-энеләреннән дә шактый кеше исән икән, алар берсе дә Шәмсегаянны онытмаганнар иде. Карачура кешеләре тетрәнерлек үткән хәлләрне искә төшереп, белмәгәннәргә сөйләп, якынлык хисләре күрсәтеп, Шәмсегаянны үз яннарына кабул иттеләр — зиратларыннан урын бирделәр... Авылның бик борынгы гадәте буен-

ча чардуган торгызып, аның дүрт почмагына дүрт сыерчык оясы куярга булып, агай-эне үзара почмакларны бүлешеп тә алды.

Карачурада гадәтләр һаман шул икән әле. Кеше үлсә аның чардуганының дүрт почмагына да колгалар кадап, сыерчык оялары куялар. Язгы җылы җилләр белән көньяктан Карачурага әллә никадәр сыерчык очып килә. Алар күнегелгән тын зиратта оялыйлар, бала чыгаралар. Апак шомырт, miләш чәчәкләренә төренгән зиратта яз буе кошлар моңы яңгырап тора. Якыннарың никадәр күп булса, дусларыңның хисе никадәр көчле булса, синең истәлегең алар өчен никадәр якты булса, оялар шулкадәр озаграк торалар. Карачуралар аларны барлап, ел саен караштырып, төзәтеп куялар. «Аның баш очында бер кош та оя типми бит!» — бу Карачуралар өчен иң аяусыз сүз!

Әйе, Карачура һаман бар икән! Үзгәргән дә, үзгәрмәгән дә!..

Авыл шул ук: инеш белән бергә ике борма ясап сузылган Олы урам. Түбән очта, ыштан балаклары булып, Олы урам икегә тармаклана. Уңга киткәне Кәҗә башы, сулга, күпер аша чыгып үргә менгәч, Имән урамы башлана... Кәҗә башы урамы элекке кебек үк яшеллеккә төренгән. Шәмсегаяннарның нигез-йорты шунда иде...

Инеш тә шул ук: каз-үрдәкләр мыжылдап тора үзендә, ыштан балакларын бот тиңентен сызганган сипкелле малайлар агач дөмбе белән комырыклардан вак чабакларны, этлиләрне пыркытып чыгарып җилгәргеч иләгеннән бозып ясалган бәләкәй җәтмәләр белән балык сөзәләр... Ярларында таллар... Тал араларында бозау көтүе утлап йөри...

Инеш аръягында үзгәреш!.. Таллык белән тау арасында Мирвәли исемнәрен дә белмәгән әллә нихәтле машиналар канатларын, яңакларын ялтыратып тезелешеп торалар. Авылның механизациясе шунда икән. Хәзергә алар ял итә. Арырак бензин баклары, әллә нинди подваллар, сарайлар... Хуҗалык үскән, димәк!

Йортлар да үзгәргән: элек салам түбәле кырык тәрәҗеле мескен өйләр арасыннан ара-тирә генә такта түбә кукраеп чыгып тора иде. Хәзер салам түбәләр бер-ике җирдә генә калган...

Ә кешеләр?..

Кешеләр әллә ниндиләр... Мирвәли авылдашларының күбесен танымый, бик күпләр аның үзен танымыйлар... Башта бу хәл куандырса да, тора-бара бик читен нәрсәгә әйләнде. Берәрсе килеп Шәмсегаянны сораштыра башласа, бигрәк тә уңайсыз иде аңа!.. Аны белә, димәк, Мирвәлине юри-марый гына танымаган булып маташа... Шәмсегаянның күп еллар тоташ балалар бакчасында эшләвен,

Карачураны сагынуын, бер генә көн дә, минут та онытмавын ишеткәч, сорашучыларның күзләре яшьләнә, барысы да аны бик кызганалар, офтаналар иде.

Аны кызганалар, ә Мирвәлине?..

Нигә берәү дә аның хәлен сорашмый, аның чал башына кинәт ябырылып төшкән хәсрәтен бүлешергә ашыкмый?.. Нигә?.. Ул да шушы авыл кешесе ләбаса, шунда туган, шунда үскән!

Мәрхүмәне олылап җиргә иңдергәч, аны бөтенләй оныттылар...

Башта төркем-төркем, аннан берәмләп халык зираттан таралып бетте. Беркем дә кабер янында чүгәләп утырган Мирвәлигә күз салмады, үзе белән чакырмады: «Безгә кагыл, кереп чык», — дип эндәшмәде... Ичмасам, берәрсе: «Хәзер нишлисең, кая барасың инде?» — дип сорасачы!..

Гомер буе юатып түгел, кеше кайгыртып түгел, юанып, иркәләнеп яшәргә өйрәнгән Мирвәлигә болай бердәм рәвештә һәм ачыктан-ачык үзен үгәйсетүләрен, санга сукмауларын күтәрү бик авыр, үтә кыен иде. Ул агай-энеләренә, авылдашларына, танышларына чын күңелдән рәнҗи, үзен санламауларын күреп, аның болай да сынык күңеле тагын да сүрәнләнә, мескенләнә бара иде...

Зираттан чыгып баручыларның акрын гына сөйләшкән сүзләре дә аның йөрәгенә туп-туры утлы ук булып кадала, җыела-бөялә иде.

— Туган җире тарткан икән бичараны!

— Әй, уңган да хатын иде инде!..

— Аның урак урулары...

— Печән чабуын әйт син!

— Аш-суга гаҗәп оста иде...

— Ярдәмчел, кече күңелле...

— Шул Мирвәли олактырды инде аның башын...

— Теге Мирвәлиме инде бу?

— Үзе инде, үзе!..

Чүгәләгән иде Мирвәли, җиргә үк утырды. Үзе хакында әйтелгән сүзләрне күтәреп торырлык түгел иде...

Ә зиратта мул булып үлән калкынган! Сусыл сабаклы эниселәр чәчәк аткан. Койма буенда күпереп утырган баллы бабай чәчәкләре өстендә алтын суы йөгерткән төклетуралар, бал кортлары оча... Выж да выж... Җил, каен яфракларын лепердәтеп, җирдә шадраланган күләгәләрне туктаусыз уйната... Мирвәли үзе дә сизмәстән җирдән, үлән арасыннан кытыршы, иске нарат күркәсе алып чалбар кесәсенә тыкты...

Күтәрелеп тә карыйсы килми аның хәзер...

Карарга кыймый!

Кая карап күзне ял иттерәсе? Төне буе атлап арыган

аякларны, ватылган тәнне ял иттерерлек тыныч почмакны каян табарга?!

Бер Шәмсегаян гына: «Монда кал!» — диде.

Бер ул гына...

Монда... Карачурада...

Калыргамы? Менә шушы үтә кырыс кыяфәтле авылдашлары белән аны бәйли торган берәр нәрсә калганмы соң?..

Бүген ул үзе туып-үскән нигез яныннан да үтеп китте. Нигезе буш... Берәү дә кыеп анда йорт тергезеп җибәрмәгән... Бакчасы өстеннән тыкрык ясаганнар. Өй урынын уртада калдырып, ике яклап үтеп йөриләр икән... Яшел таплы җир өстендә күгәргән, мүкләнгән нигез ташлары арасыннан юан сабаклы алабуталар, карга борыннары, сукыр кычытканнар үсеп чыккан. Кемдер, үлән арасыннан кереп, йорт турына муртаеп беткән шәп-шәрә усак казык каккан.

Бүген, ул кайткач кына какканнармы әллә?..

Тыкрыкның ике ягында да дәү-дәү өйләр.

Дәү-дәү өйләрдә яңа кешеләр...

Мирвәли заманында туып кына килгән яңа буынның үз бала-чагалары үсеп беткән...

Уйлар аның башын җирдән күтәрделәр, ул томанлы күзләре белән авыл урамнарын капшый башлады...

Урамнар элеккечә... Урамнарның ике ягыннан да баганалар тезелешкән. Мирвәли бик бәләкәй чагында, «чыжым баганалары» дип йөртәләр иде аларны...

Өйләр...

Өч кое!

Хәйдәр карт казыган коелар... Аның өч улы гражданнар сугышыннан кайтмады. Шулар истәлеге итеп өч кое казыган иде ул... Шәмсегаян белән алар шунда очрашалар иде. Өч кое янында тугыз тирәк. Хәзер дә исән икән әле алар...

Имән урамы... Мирвәлинең бабасы: «Без бәләкәй чакларда Бөгелмәгә олау йөртә идек. Имән урамыннан чыгуга, карурман башлана иде. Барып җиткәнче гел урман эчләп үтә идек»,— дип сөйли иде.

Әйе... Монда аның ерак бабалары туган. Авылның нигезен салган кара Чура үзе дә аның ерак бабасыдыр әле... Бу зиратта аның әтисе ята, әнкәсе... Монда Шәмсегаян...

Калыргамы монда?..

— Хуш, Шәмсегаян!..

Оешып каткан аякларын сыкрый-сыкрый язып ул урыныннан купты, Шәмсегаяны белән кат-кат саубуллашты...

Урамнан кайтырга базмады ул, ындыр артлатып туп-

туры Шәрифҗаннарга китте. Аның аты шуларда. Шәрифҗаннар Шәмсегаянның якын кардәшләре...

Аңа, азга гына булса да, каядыр барып сыенырга, үзен кеше итеп сизәргә кирәк иде. Шунсыз булмый! Шунсыз ул хәлсезләнеп, егылып үләчәк. Тик үзеңне кеше итеп тою өчен, башкаларның да сине үз ишләре итеп санаулары кирәк иде.

— Шәрифҗан, ә, Шәрифҗан!

Ачык тәрәзәдә, тамчылы гөлләр арасында, Шәрифҗанның юка, сары сакалы күренде.

— Нәрсә бар?

— Чык әле монда.

Шәрифҗан мыштырдап, теләр-теләмәс кенә болдырга чыкты, култыксага таянды һәм, «ни сүзең бар инде тагын?» дигән сыман, тавыш-тынсыз гына көтә башлады.

Ничек сүз башларга? Кеме ул Шәрифҗанның? Кардәшләрме алар, якыннармы? Утыз ел бер-берсен күрмәгән кешеләр арасында нинди якынлык калсын?.. Ә нигә калмасын? Бер-берсен бөтенләй белмәгән ят кешеләр дә туганлык куллары сузалар ич еш кына! Әнә, тимер юлда кайтканда... Бөтен поезд купты!.. Тик алар аның кем икәнен белмиләр иде шул! Мирвәлинең кем икәнен белсәләр, ярдәм кулы сузарлар идеме алар?

Шулай да, нигә Шәрифҗан бөтенләй ят итә әле аны?

— Ни бар, ни әйтәсең килә?

Болай сүзсез, төнтек, мокыт адәм түгел идең ләбаса син, Шәрифҗан!.. Гармунчы егет идең!.. Авылдашың Мирвәлигә бер генә дә җылы сүзең юкмыни?.. Гомер буе җир сөреп синең бармакларың тубырланып каткан, йөзеңнең кызыллыгын җил ашаган, калын тырнакларың саргаеп яргаланган... Күңелеңнең дә чишмәсе корыдымы әллә?.. Йә, дәш бер сүз, Шәрифҗан... Син югарыда, болдыр өстендә торасың... Син хуҗа... Мин аның яныннан зираттан кайттым бит... Беләсеңме, ул «кал!» диде...

Шәрифҗан авыл җанлы иде, үзенең артык корылыгын аңлап, Мирвәлине өйгә, чәйгә чакырды.

— Кер әйдә. Чәй дә кайнаган... Ачыккансыңдыр...

Ни дидең син? Чәй?.. Юк, чәй эчәсе килми Мирвәлинең, аңа хәзергә чәй кирәкми. Чәйне ул болай да өнәп бетерми, тук карынга гына эчә... Аңа бер җылы сүз генә кирәк, Шәрифҗан! Күзләреңне яшермә инде, карачы бер аның ягына!..

Ахмак галимнәр кешенең ризык капмыйча, су йотмыйча ничәшәр тәүлек җан асравын исәпләп баш ватканнар. Кыенмы әллә моны исәпләү? Син менә йомшак сүз ишетмичә, җылы караш тоймыйча ирекле адәм баласының күпме яши алуын санап кара!..

Утыз ел дәвамында ул тегендә, читтә Шәмсегаяннның назына җылынып, аның иркәләвенә сыенып яшәгән икән? Менә Шәмсегаяны юк инде! Аның белән барысы да киткән: җылы караш та, йомшак сүз дә... Ә Мирвәлигә яшәргә кирәк бит әле!..

Тирә-якта кешеләр нинди күп! Үзара алар нинди якыннар: туганнар, абыйлар, апалар, җизниләр, сеңелләр, балдызлар, кодалар, кодачалар... Йә булмаса иптәшләр, кардәшләр, яшьтәшләр, аркадашлар, юлдашлар... Нинди җылы җепләр бәйли адәми затларны якты дөньяда!

Шәрифҗан да элек Мирвәлине «җизни» дип зурлап йөртә иде. Нигә шул җылы сүзне хәзер әйтми ул? Бер мәртәбә генә, ялгыш кына авызын тутырып, «җизни!» дисәче! Шәрифҗаннар күршесендә генә Мирвәлинең кодасы тора... Кода!.. Нинди ягымлы, матур, кадерле сүз икәнсең син! Кода! Бәйрәмнәрдә ачык чырай, татлы сүз, кайнар бәлешләр, сөенечле сүзләр, хатирәләр!..

Бер мәртәбә «кода» дип әйттерер өчен Мирвәли дөнья малын, дуңгыз канын бирер иде!.. Тукта — нәрсә бирә ала соң ул? Ние калды?

Кардәш, авылдаш, яшьтәш, адаш... Нинди тирән мәгънәле, кадерле сүзләр икән болар!

Тукта! Кем эндәшә соң аңа баядан бирле? Шәрифҗан икән. Беркем дә түгел Шәрифҗан...

— Чәй эчәргә керәсеңме дигән идем?

Кемгә эндәшәсең син алай, Шәрифҗан? Мирвәлинең иңбашлары өстеннән кая карыйсың?..

— Ә? Чәй дисеңме? Эчәсем килми...

Монда озак торырга ярамый. Аяклар калтырый... Ишегалды тар, сулышны буләә... Тавыклары күп, келәт алдында үрдәкләр бакылдап җим теләнеп торалар...

Мирвәли урамга чыкты... Юллар тузанлы, машиналар үтеп-сүтеп торалар. Бәбкә үләннәре койма ышыкларында гына... Урамда кешеләр күп. Әле дә ярый, алар Мирвәлине онытканнар!..

Онытканнармы?.. Онытмаганнар!

Язулы капкалы йорт. Нәрсә бу? Колхоз идарәсе икән... Шунда кереп карарга дыр бәлки? Аякларына егылып гафу сорарга дыр?.. Шәмсегаян: «Кал!» — диде ич! Иелгән башны кылыч кисми дигән акыл да бар.

Ул идарә йортына борылды. Йорт алдындагы бәләкәй генә бакчада, буявы уңган эскәмиядә җемелдәп торган түгәрәк ак сакаллы, сул җиңен чалбарына кыстырган берәү утыра иде. Ул, сыңар кулын ак кашы өстенә куеп, Мирвәлине күтеп алды. Мирвәли дә аның яныннан үтеп китәргә яхшысынмады, сәлам биреп эскәмиягә барып утырды.

Күләгәдә җиләс, салкынча иде. Ул үзенең аз гына

тынычланганын сизеп, утырдашына сүз катарга булды. Теле әйләнмәде. Икесе дә сүзсезлекне яхшысынмыйча төрле юк-барлардан башлап киттеләр.

— Кыздыра!

— Яндыра-а!

— Әйдә, кирәк иде...

— Кирәк, әлбәттә.

Идарәдән ерак та түгел күләгәдә өч-дүрт бозау әлсерәп мышлап ята.

— Урынын тапканнар!

— Күләгәдә әйбәт шул.

Тагын тынлык урнашты. Кыекта чыпчыклар чырылдаша.

— Председатель андамы? — Мирвәли башы белән идарә тәрәзәсен күрсәтте.

— Ни калган аңа анда?

— Идарә түгелме соң бу?

— Булса ни! Тик безнең председатель идарәне сөйми. Кәнсәләрдә анда кәгазь генә була. Ә ипекәйне аны кырда үстерәләр.

Мирвәли башта утырдашын танымаган иде. Председатель хакында сүз кузгалгач, ул аны төсмерләде. Кем шулай кашларын җыерып көлемсери иде соң?! Кодамы, күршеме, кардәшме?.. Бәй, бу аның адашы ич! Күпер төбе Салих малае Мирвәли!.. Алар яшь чагында дуслар иделәр, бер-берсен «адаш» дип кенә йөртәләр иде.

— Танымый торам үзеңне, адаш, — диде ул.

— Адаш? — дип баягыча көлемсерәде икенче Мирвәли. — Адаш... Сәер булып китте. Карачурада адашлар юк хәзер... Күптән бу сүзне ишеткән юк иде!..

— Нигә юк?

— Утыз ел инде беркем дә баласына Мирвәли дигән исемне кушмый...

Мирвәлинең аркасына салкын тир бәреп чыкты.

— Нигә?

— Яратмыйлардыр, — диде туп-туры карап икенче Мирвәли.

Мирвәлинең адашы яныннан тизрәк китәсе килде, яхшысынмады. Ул, башын салындырып, тып-тын гына утыра бирде. Кайчан да бер үзенең хөкем карарын ишетергә тиеш иде ләбаса ул!.. Адашы түзмәде, аңа таба борылды.

— Председатель кирәк идемени? — дип сорады.

— Кагылып чыгыйм дигән идем шул.

— Ни йомыш бар иде соң аңарда? Мин үзем дә идарә члены.

— Йомыш дип... Авылда калыргамы әллә дигән идем...

— Бөтенләйгәме?
— Әйе, бөтенләйгә...
— Калырга? — дип кабатлады ул, Мирвәлине сискәндереп. — Калырга дисең инде син... Уйларга кирәк моны! Син миңа үпкәләмә, үткәннәрне искә төшергәнне кайчак үзем дә яратмыйм. Шулай да әйтик, авыл халкы җәберҗәфаны байтак күрде! Ул сугыштан соңгы интеккәннәрне күрсәң син! Хезмәт көненә берни бирмәделәр диярлек. Налоглар, заемнар белән җәфаладылар. Еллар буе берни бирмәделәр, еллар буе барын бездән сорадылар. Рәхмәт, ниһаять, колхозчыны кешегә саный башладылар... Күзебез ачылды, җитәкләп безне көр тормышка чыгардылар... Ә күңеле йомшак аның крестьянның! Бала туганны ишеткәндә һәркемнең күңеле йомшара. Ә крестьян һәрвакыт табигать арасында... Ул һәр яз җирдә тереклек яңаруын, тормыш тууын күреп, куанып яши. Шуңа күрә күңеле йомшак, шигъри аның... Гафу итә дә белә, кирәкмәсен оныта да! Барын кичердек, ә нинди игеннәр үстердек быел! Күрдеңме икән?.. Яшәдек, яшибез. Тик син кайтырсың һәм монда калырга уйларсың дип башыма да килгәне булмады! Үз җирен каһәрләгән кешене, өстебез ялангач чагында күпме кием-салымны тураклаган кешене, күз карасыдай кадерле игенне дегет белән аралаган кешене, күпме мал-туарын агулап киткән кешене... Гафу итәргә, сыендырырга, урын бирергә дисеңме?! Белмим, белмим...
Мирвәли ялт итеп сикереп торды да китә башлады. Бераз баргач артына борылды, идарә тәрәзәсенә карады, һәм:
— Миңа күп кирәкми инде хәзер... Күрәсең ич, картаелды. Яшәсе яшәлгән дигәндәй, миңа хәзер өч аршын җир җитә, — диде.
Адашы җиргә карап уйга калды. Мирвәли үз сүзләренә тагын нидер өстәргә, үзенең газапларының бер өлешен булса да аңа ачарга, уртаклашырга теләде. Өлгермәде.
— Өч аршын сорыйсыңмы,— диде адашы, тагын көлемсерәп. — Кадерле ул туган җир! Ай, кадерле!.. Күпме авылдашлар аның өчен башларын безнең гомердә генә чит җирләрдә салдылар. Берлинда, Будапештта. Каты бәгырьле димә, минем ул жир өчен чын-чынлап даулашырга хакым бар! Өч аршын җир!.. Күп сорыйсың син, Мирвәли!.. Хәзер менә сорыйсың! Ә нигә качтың син Карачурадан? Әйт әле?
— Кимсеттеләр мине, җәберләделәр, — дип мыгырдады ул.
— Ә безне?.. Еллар буе кара тир түгеп эшләп берни алмаган чакларыбызда безне кимсетмәделәрме? Әрнемәдекме?.. Тик туган җиребезне каһәрләп мөртәткә әйләнеп чыгып качмадык!

Юк, председатель белән очрашуның кирәге дә юк икән. Кирәкми... Барыбер аңлаша алмаслар алар!.. Ә Шәмсегаян кал диде!

Үз алдында да юкка чыккан Мирвәли алпан-тилпән атлап урам уртасыннан Шәрифҗаннарга кайтып бара.

Чыннан да, нигә киттеләр соң алар Карачурадан?.. Куркып бит! Куркып-өркеп кителде, посып яшәлде. Тукта! Инде хәзер дә хаклык белән, хөкемең белән очрашудан куркып чыгып китәргәме?.. Кочакларын җәеп, аркасыннан сыйпап каршыларлар дип өметләнеп кайтмады бит ул!

Монда калырга кирәк! Шәмсегаянга гына сөйләгән сүзләрен ул авылдашларына да җиткерергә тиеш!.. Властьлар сыйдырмаса, туганнары, агай-энеләре бар ич әле аның! Кырыс булса да, почмагын биреп торырлык Шәрифҗан бар... Әнә ич, чәйгә дәште! Гаебе зур Мирвәлинең, моннан китү ул гаепне тагын да зурайту, үстерү генә булачак... Хәзер барырга да, туганнарның аягына егылырга кирәк.

Капка төбенә кайтып җитте Мирвәли. Күн итегенең тузаннарын озаклап багана төбендәге бәбкә үләннәренә сөртеп торды. Ишегалдына керде. Һәм лапаста җигүле акбүз атны күреп коелып төште. Димәк, монда аңа урын юк!..

Үз гаебенең зурлыгы аның миенә шул чакта гына барып җитте. Аңа монда урын юк! Сыйдырмыйлар!..

Ул, хушлашырга теләп, хуҗаларны эзләде. Як-ягына каранды, берәү дә күренмәде. Сөйләшергә кирәк дип тапмаганнар!.. Ичмасам Шәмсегаянның сүзләрен әйтеп калдырырга иде... Аның соңгы сәламен тапшырырга, күчтәнәчләрне өләшергә...

Шыгырдап капка ачылды. Бер төркем кеше күренде. Кемнәр болар? Кая баралар?

Уртада Шәрифҗан килә. Төркем тын гына Мирвәли янына килеп җитте, кешеләр, ярым алка ясап, аны урап алдылар. Шәрифҗан Мирвәлигә карап бераз торды да атка ымлады.

— Больница аты, кирәк була башлар, дим.

— Әйе, әйе... Мин хәзер китәм. Кузгалам...

— Җизни!..

Мирвәли сискәнеп ап-ак агарынды! Менә аның хөкем сәгате җитте! Тик аңлагыз, авылдашлар, кыен аңа, бик кыен!.. Гаебен аңлаган саен авыррак була бара!

— Җизни... Атны илтергә кирәк... Газизҗан аны сәгатьтә эшли... Аннары без, агай-эне, монда үзаралай сөйләштек... Олы башың белән әллә кайларга китеп йөрмәссең инде, үзебездә генә калырсың...

Ярты сәгать үтәр-үтмәстә таныш юлдан Кызыл ярга бер ат менеп бара иде. Арба артыннан ике кеше атлыйлар.

Мирвәли бик арыган булса да: «Азрак озата барыйм»,— дип, Газизҗанга ияргән иде. Газизҗан Шәрифҗанның йорттагы төпчек улы икән. Ул да Мирвәлигә ике тапкыр «җизни» дип эндәште...

Менә алар тау өстенә менеп җиттеләр. Мирвәли артына борылып карады...

Аста Карачура...

Аста инеш...

Аста зират...

Мәктәп тәрәзәләренә кунып кояш ялтырый. Имән урамыннан ук башланып киткән бодай басуында болыт күләгәләре шуышалар... Бодай кырлары ындырлардан алып офыкка кадәр җәелгән... Бәлки, Бөгелмәгә кадәр үк шундый басулардыр?..

Кем белсен...

Тау сыртындагы корыган үлән чылгыйлары, корышкан абагалар арасында тынгы белмәс чикерткәләр скрипкәләрен уйныйлар. Тау итәге буйлап үзәннәрдән килгән җил, монда җитәрәк, капылт кына өскә менеп китә дә Мирвәлинең буй-буй яңа күлмәгенең ачык изүеннән үрелеп, аның йөрәген барлагандай, шунда бутала... Шунда аның йөрәге, шунда! Әнә ничек тибә... Типсен әле ул! Мирвәлигә яшәргә кирәк! Яшәргә...

Алда, тонык кына гөжләгән урман авызында, карылдашып, дәү, симез каргалар очалар...

Ул озак итеп, үзе бүген төнлә үткән юлга, аның белән соңгы кат сөйләшеп үткән юлга карады... Әгәр бу аңлашулар моннан элегрәк елларда булсаларчы! Ун ел элек, биш ел элек!..

— Йә, бар, Газизҗан улым... Врачка рәхмәт әйт. Хайванкайны рәнҗетмә!..

Кояшны каршы алырга офык артыннан чыккан юка, чуар болытлар алсу нурга манчылдылар. Ул урманга кереп барган Газизҗанга тагын бер тапкыр кулын болгады да акрын-акрын түбәнгә, кичке мәшәкать белән ыгы-зыгысы тагын да арткан зур авылга, туган авылына, ниһаять, аларның икесен дә сыендырган Карачурага таба төшеп китте...

*Октябрь — ноябрь, 1962*
*Мәскәү — Казан*

# *Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят*

## 1

Һәр авыл, зурмы, бәләкәйме — үзенә күрә бер дәүләт ул. Бар аның тарихы, урын-җире, урман-болыннарының исемнәре, үзенә хас төсмере, гореф-гадәтләре, халык арасында яшәп килүче кануннары. Бу җәһәттән караганда безнең Югары авыл бүтәннәрдән бер ягы белән дә аерылмый торгандыр. Чулман Иделенең аръягында, өч яктан карурманнар чолгаган төбәктә күп гасырлардан яшәп ятучы авылның, телләрдән телләргә күчеп килгән риваятьләре, буыннар буынга тапшыра торган гаҗәеп хәлләре, сәер вакыйгалары да юк түгел. Табигатенең гүзәл почмакларын телгә алып үтсәк, беренче нәүбәттә, Олы су башыннан ерак түгел, текә яр астыннан бәреп-ыргылып чыккан мәшһүр Аракы чишмәсен әйтергә кирәктер. Андый чишмә дөньяда бер генә!

Һәр авылдагы кебек бездә кар өстендә казан кайнатырлык уңганнар күп, ялкау-үшәннәр дә җитәрлек, тешләкләр янәшәсендә телгә беткән лыгырдыклар яши, бар астыртыннар, мүкләкләр, симез былкыннар, юан күпәшләр, аңгыра брыйлалар, колгалар, кәтәнәләр, сукыр-букырлар, колакка саңгыраулар, күрә караулар, аю табаннар, солдаткалар, толлар, тол дүдәк ирләр, гөсләчеләр, мәшһүр биючеләр, аш-су осталары, чигүчеләр, җөйчеләр, итек басучылар, тире иләүчеләр, күмер яндыручылар, кендек әбиләре, әпчи карчыклар, им-томчылар, болгардан затлы токым алып калган ак, киң маңгайлы, кыйгач кашлы сылулар, мал печүче канаваллар, сугымчылар, өй борынча биләмгә йөргән бистә бикәләре, самоварда су беткәч, подноска түгелгәнен ятып эчүче Мифтахлар, Югары очта пышылдаса, Түбән очка төшеп яңгыраган бакыр бугазлы касамаллар, бал коючылар, бер утыруда егерме

җиде дурычмак, утыз ике өчпочмак сыпырып куючы бирән корсаклар, шифыртлар, кышлау тананы эһ тә итмичә иңгә күтәрә алган баһадирлар, кыскасы, кемнәр генә булмаган да, кемнәр гомер кичми безнең Югары авылда!

Дөрес, авылда йөздән артык кына төтен икәнен искә алсак, тезеп телгә алынган бу һөнәрләрнең аерым бәндәләргә бүлеп бирелмәвен дә әйтергә кирәк, итек төзәтүче үткен Минһаҗы авылда иң шәп биюче, ул мәйдан уртасына чыгып, камаринскийга бер тыпырдасамы, авыл өстендә өермә куба. Тол дүдәк Касык Ибраһим скрипкәче. Тимерчеләр, гадәттә, мал печәләр, сугым суялар. Шадралар һәм ат караучылар көмешкә пешерергә оста булалар.

Гасырдан гасырларга Югары авыл шулай яшәгән, ир-атлар, озынмы ул, кәтәнәме, һәрберсе үз язмыш суын эчкән. Авыл хатыннары исә уртак язмыш кичергәннәр дисәк тә хата булмас. Таңнан чәчрәп торган, чишмәгә чәй суына йөгергән, учакта ут тергезгән, казан аскан, бишек тирбәткән, мунча яккан, ирен, балаларын баккан. Хатын-кыз мәшәкатен мал-туар яраткан Тимерша тавыклары да чүпләп бетерерлек булмаган...

Кешелекнең бөек могҗизасын — бәбәй тууны бары тик кендек әбиләре генә белгән. Сабан туе батырлары, бәет чыгаручылар, мөнәҗәт укучылар белән янәшә аларның абруе да ифрат югары йөргән. Аш-су тирәсендә аларның урыны түрдә булып, калҗаның симезе, бәлеш төбенең майлысы аларга эләккән. Авыл күмәк һәм ачык яшәгән, һәркемнең гомер юлы туу сәгатеннән башлап үлгәнгә кадәр авыл арасында үткән. Туалар, үсәләр, гашыйк булалар, өйләнешәләр... һәм озын, тоташ чылбырга тагын бер җанлы буын өстәлгән. Әгәр авылда берәрсенең нечкәлекләрен белергә теләп авыз ачсаң, сиңа анның ата-анасы, җиде бабасы хакында да бәйнә-бәйнә сөйләп бирәчәкләр. Авылда сер булмый, була алмый. Авылның телчән апалары синең кайсы бот төбеңә кыярак чыкканын да төп-төгәл белеп торалар. Инде яшерәм дип, бер дә юкка кылтаеп, борын күтәреп, уңмаган борай кылчыгы төсле йөри башласаң, беттең, исемеңне сасытачаклар, ата-бабаңнар ләхеттә борылып ятырлык итәрләр... Бар, сәер яшәгән, йомылып гомер иткәннәр дә очраштыра, алдарак без аларны күрербез, андыйларга авылның үз мөнәсәбәте бар... Югары авылның бик борынгыдан бозылмыйча килә торган гадәте ни дигәндә, ул — өлкәннәргә хөрмәттер. Аксакаллар урамнан үткәндә тирә-як тына, җыеннарда, бүрәнә өстендәге кичке әңгәмәләрдә олы сүз алар авызында, өйләнгән, бала-чага-

лы кеше булсаң да сүз кыстырырга ашыкма, башта тыңларга өйрән, акыл җый. Өйләнмәгәннәргә әле сан юк, андыйлар ат дагалаганда бака ботын кыстырмыйлар, хатын-кыз кавеме исә, гомер-гомергә яулык читен тешләп, күз карашын җиргә түгеп тыңларга гына өйрәнгән... Картлар сүзе — тарих белән ныгытылган ачы тәҗрибә авазы. Осталар, сабан туе батырлары, йөгерешчеләр, тегермәнчеләр, умартачылар картлардан соң сүз ала торган булганнар. Эчкечеләрне, гайбәтчеләрне, биләмчеләрне, шымчыларны, әләкчеләрне мәҗлес уртасына бер чакта да кертмәгәннәр. Ни гаҗәптер, безнең авыл арасында пожарник белән көтүчеләрне бер чыбыктан куалап бик түбәндә санап йөртәләр иде. «Һәй, кешемени алар, берсе пожар сарае сәндерәсендә, икенчесе басу түрендә куак күләгәсендә йокы бүсә!» дип кырт кисәләр сүз арасында!

Менә көне килде, сугыш чыкты, сугыш күпләрне тигезләде, чалгы бизеннән уен ясаган булат пәкесе белән малай-шалайның башын ялтыратып куючы чәчтараш Сибгат абзый да, абруйлы шадра тимерче Нурулла да, мичкә төпләүче, дуга бөгүче колга Сабир да бер көндә солдат булдылар. Кайгы-хәсрәт уртак була авылда, бүген иртә таңнан барлык морҗалардан зәңгәрсу хәсрәт төтене ага, солдатларны озаталар, басу түрендә, ындыр табакларында ир-атның көр тавышы кимеде, дилбегәне тартып тоткан егәрле куллар юк, хатын-кыз чәрелдәгәнне ишетеп сәерсенгән бахбайлар борылып-борылып карыйлар: «Тыңларгамы бу озын чәчләрне, юкмы?» — диләр бугай...

Чират көтүчеләргә дә җитте, алар да, биштәрле арык капчыкларын тар җилкәләренә элеп, авыл белән саубуллаштылар.

Алмаш тиз генә табылмады, ике көн көтү чыкмады. Ачыгудан күзләре аларган сарыклар абзар-кура арасында шашынып чаптылар да әлсерәп тындылар. Сыерлар, авылдашлар утырып киткән парахутлар сыман, сузып-сузып кычкырдылар. Мур кыргыры кәҗәләр баш бирергә теләмәделәр, теләсә кай ярыкны киңәйтеп, ян бакчаларга, ындырларга ыргылдылар, ал аяклары белән сабакларына басып өлгергән көнбагыш башларын ботарладылар. Кичкырын авыл советына ил агалары җыйналды. Нишләргә?

Инде көз кергән, сентябрь урталары, көтү ай, елы килсә, ай ярым әле кырда йөрергә тиеш, шушы кыска арага кемне ялларга? Адәм рәтле кешесе калдымыни анын? Менә сагыналар көтүчеләрне, менә мактыйлар... Алай карадылар, болай бактылар, ахыр чиктә: «Артың

киртәгә терәлгәч әллә кая барып булмас, быелга чиратлап, өй борынча малларны багыйк та, язга таба бер әмәлен табарбыз»,— диештеләр. Әйтүен әйттеләр, эш башларга дигәндә, көймә тагын комга терәлде: бүген чыгасы хуҗаның биле кузгалган, ыңгырашып ята... Күршесенең төпчеге армиягә китә, чыга алмый. Өченчесе, солдатлар озатып йөреп, бәрәңгегә кулы җитмәгән... Чираттагы өйдә чыбыркы тотарлык исәү бала юк, җыенысы аяксыздан күтсез, боларга ышанып малларны тапшырсаң, кышка итсез каласыңны көт тә тор! Әнә Фәттах малае, буйга нык үскән сөрхәнтәй, көтүе арыш уҗымына бәреп кергән дә гектар җирне кара күмер калдырып чыккан! Җитмәсә, Ишмиләр танасы бөтенләй кайтмаган... Таңнан эзләп баксалар, Миннәхмәт әрчүендә, урман авызында аяк-тоягын гына тапканнар, бүре бугазлаган икән хайванны...

Тыныч заманнарда көтү каршыларга бала-чага, бәлтерәгән әби-сәби төшә торган иде, хәзер ул да олылар эше, соңарып, аяк өсте йоклап йөрсәң сарыгыңның кай тыкрыкка кереп киткәнен күрми дә каласың, көтүне туплап алып кайту юк, алагаемга сузыла, йөр аннары төне буе ми черетеп! Җот елы килгәнен каһәр суккан бүреләр дә чамалый, көтү уртасына ыргылып керәләр дә арадан иң симез хайванны сайлап бугазлап китәләр...

Мин унынчыда укырга тиеш булсам да, әле дәресләр хакында уйларга чама юк. Мәктәптә рәт калмады, ир укытучыларны суырып алдылар, иш янына куш булмасмы дип, калган хатын-кыз янына күгәреп ялда яткан карт-корыны дәшеп китерделәр. Ничек укытырлар, белгән юк. Башта без, өлкән класслар, куна-төнә борчак эскертләдек, аннан атлы молотилкада тары суктырдык. Минем әти көзләр буе ашлык суктыра иде, йөри-йөри мин дә аннан өйрәндем, хәзер аның урынына бастым. Инде хәзер авыл белән бәрәңге алабыз. Бәрәңге ишелеп уңган, шонлык, көрәк белән чөеп җибәрәсең, бәләк-бәләк бәрәңгеләр чыга. Колхозның бердәнбер машинасын һәм егерме җиде атын армиягә алгач, эшләр гел кирегә китте. Бәрәңгене авылга кул арбалары белән ташып маташтык та хәзер бәрәңгене җирендә көшелләргә өябез. Салам, бәрәңге сабагы белән каплагандай итсәк тә, бусы беренче кырауга хәтле генә, суыклар башланса бәрәңгене ялмап йотачак. Бала-чага да моны аңлый, шуңамы бирәү дә җиренә җиткереп эшләми, алай-болай буразна арасында буталабыз, иптәшләр укытучылардан качып, кырын ятып махра тарта... Көнне үткәрер хәл юк, кояшны бер урынга кадаклаганнармыни, тора шунда чекерәеп!

Рәфгать белән киңәштек тә бүген көтү каршыларга кайтырга булдык. Безнең мүкләк сыердан да качкын мал авылда юк, сеңлем Нәсимә ничә көн инде менә көтүдән акырып елап кайтты.

Рәфгать классташым минем, иптәш егет, кулларны артка куеп, картларча ашыкмыйча гына кайтып барабыз. Иртәрәк ычкындык, көтү кайтырга әле вакыт бар, буа өстенә кергәч, Рәфгать бөтенләй туктап калды. Суда, исәйгән симез бәбәкләре белән мактанып, өер-өер казлар йөзә. Рәфгать шуларга карап-карап торды да:

— Каз бәлешеннән дә тәмле нәрсә юк инде, малай, ә? — дип, иренен ялады. Мин аның сүзен ишетмәмешкә салыштым һәм:

— Бүген көтүне кем алып чыкты икән? — дип, сүзне бүтән якка бордым.

Ул да соравымны җавапсыз калдырды.

«Каз бәлешен» каян теленә керткәнен беләм мин аның! Буа аръягында ук безнең пожар каланчасы, авылның иң биек корылмасы. Каланчага янәшә үк каравыл өе, аңа ялганып озын сарай сузыла. Бер ягы ачык сарайда атлы насос, мичкәләр саклана, багур, көрәк, лом ише нәрсәләр дә шунда. Теге башта, аерым аранда колхозның чабышкысы «Ялкын»ны асрыйлар. Айгырны рәис җиксә дә, караучысы чулак Гыйбадулла. Гыйбадулла пожарник, гомеренең күп вакытын биектә, каланчада үткәрә, бөркет күзләре белән авыл арасын, юлларны бертуктаусыз күзәтеп, тикшереп тора. Мин карамыйча да үтеп барам икән, Рәфгать туктаган, Гыйбадулла өстән безгә дәшә, кул изи.

— Әйдә, янына менәбез,— диде Рәфгать, тиз үк кызып. Минем Гыйбадулла белән борчак пешмәгәнен белә ич, нәрсәгә тагын үртәп маташкан була?

— Йомышым юк әле,— дидем мин, төксе генә.

— Кызык ич!

— Таптың кызык! Ялганчы, алдар таз, карак, төннәрен кош-корт урлап суя да үзе ише эшлексезләрне каравыл өенә чакырып сыйлый. Сиңа да каз бәлеше эләккәндер әле!

Рәфгать ачулана башласа, колагы кызара, сирәк кашлары җыерыла.

— Тоттыңмы? Күрмәгәнне сөйләмә! — дип карыша ул.

Баскыч аратасына аягын куеп, миннән сүз көтә. Мин дәшмәгәч:

— Меник инде! Ичмасам, күңел ачарбыз,— ди.

Гыйбадулла наян, күңел ачарга әзер, читтә йөреп, шомарган таш булып, кулын өздереп кайтты да янгын са-

раенда сеңде. Йон тетү машинасында, Чаллыда кулын калдырган дип сөйләделәр. Эшләгәндә барабанга кысылган, имеш. «Урлап йон саткан, шул калыккач, Гыйбадулла кулын юри өздергән»,— дигән сүзләр авыл арасында йөрде йөрүен... Кем белгән, булуы ихтимал, мут кеше Гыйбадулла өч тапкыр никахлы өйләнде, күпме яшь кызларның башына җиткәнен белсә, бер Ходай беләдер! Әләгер әләгүен бер, сумала казанында быгыр-быгыр кайнатырлар гөнаһка уралган азгын тәнен! Шул, хәер-фатыйхасыз чыгып китте, аркасына кәтилүк һәм кургаш кашык салган ямаулы капчык асып кайтып керде. Исән кулы белән озынча агач тартма кыскан иде. Тартма эчендә аның кисек кулы икән! Бу хәбәр шунда ук авыл арасына таралды, карчык-корчык шомланып укынды һәм ничә буын малайлары шул «могҗизаны» күрергә Чулак янына барып йөрделәр. Без дә бардык. Корып-кибешкән, юка сары бармакларның тырнаклары төшемә кереп йөдәтте... Биш күкәй алып килсәң, Чулак сине ярым караңгы чоланга алып керә, серле кыяфәт белән пышылдый: «Ярамый кулны күрсәтергә, һич тә ярамый! Сиңа күрсәттем исә, төн буе үтереп сызлый... Кул киселгән булса да, мин исән чакта урынына кайтып ялганырга тели... Адәм күзенә күренәсе килми аның!.. Бер сиңа гына күрсәтәм, сызласа сызлар!» Шулай диядия ул яшен тизлеге белән тартманы ачып яба.

Малайлар куркалар, төшләрендә әллә ниләр күреп кычкырып уяналар, балачак кызыксынуы барыбер куркуны җиңә, алар әниләреннән күкәй урлап, бүтән ризык белән Чулакны юмалап, үз урынына кайтып ялганырга омтылган коры кулны күрергә барып йөриләр.

Бала-чага гына түгел, яшь-җилкенчәк, олылар да каравыл өенә тартылалар, җай чыкса чыкмаса, шунда сугылалар, Чулакның тузга язмаган хәлләрне ышандырып сөйләвен яраталар. Чулак тома саңгырау әнкәсе белән байтактан тол дүдәк булып яшәп ята. Әнкәсе дә аңа үгет-нәсихәт юллап тормый, улы кайткан кыска араларда һаман бер каргышны тәкрарлый: «Кыямәт көн килер... Сират күперен кичмәк булырсың... Кылган явызлыкларың сине җәһәннәм утларына сөйрәп төшерер... Үкенергә дә өлгермәссең, затсыз!»

Чулакны алай гына куркытырмын димә. Сират күперең ни дә аңа, җәһәннәм базларың ни?! Аңа бу дөньяда рәхәт булсын! Эчә Чулак, чирек аракыны чөмереп бетерә, эчте исә, умырып ашый, симез бәрән йок та булмый бирәнгә! Каравыл өе алдын чыбык читән белән үреп алып тырлау ясады, мул итеп укроп чәчте, кыяр-кәбестә

утыртты, шешә алып килсәң, кабарга дигәнен үрелеп кенә ала... Сыңар кулы тәрәзәдә, ипи калагы хәтле саргылт тешләре ыржайган, күзләре тирән чокырларда каралып йөзәләр...

Кызыклары аның санап бетергесез! Ризыкны юмарт таба торган тагын бер әмәле бар Чулакның, шул кәсебе белән аны авылда гына түгел, ярминкәле-базарлы авылларның барысында да яхшы беләләр. Ул иң атаклы, иң мәшһүр усрагы безнең якның! Урамда очратасыңмы син аны, базар уртасындамы, аулак урман юлындамы, каравыл өен әйткән дә юк, олымы син, чәкүшкәдәй малаймы, сорасаң шартлата да бирә! Рәнҗеми, үпкәләми, бары тик: «Сиңа тавышы ныграк булсынмы, саны күбрәк булсынмы?» — дип кенә сорап ала. «Тавышы ныграк булсын, яңгырасын!» «Ярый, күк күкрәтермен, бер дистә күкәй китерергә генә онытма, матри!» «Апкиләм, апкиләм!» «Алдама!» «Теге дөньяда ялганчыларны ни көткәнен беләсеңме?!»

Гадәттә, малайлар өерләре белән булалар, Чулак дөньяны яңгыраткач, алар тамаклары карлыкканчы бәхәсләшәләр... Чулак чынлап торып шартлатамы, әллә ыштан төбенә бер-бер әкәмәт яшергәнме, дип ачыкларга тырышалар. Кем «әкәмәте бар!» ди, кем исә Чулакның «осталыгына» ышана, үтенеч белән киләләр, күңел ачалар, күкәйне өзлексез ташыйлар. Ярата Чулакның туймас корсагы тавык йомыркасын! Иртән тозсыз-нисез унны йотып куя, әбәткә тозга мана-мана унбишне ашап бетерә, чирләми, укшымый, тамагын гына кыра.

Җәен-кышын ул хәрбиләр киеменнән йөри, озын итәкле соры шинель кия, җәен-кышын шәрә башына буденный шлемын чәпи. Кызыксынып сорашсалар: «Миңа хәрби кием кушылган! Пожарниклар хәрбиләргә тиң!» — дип кенә җиффәрә. Читләр арасында бөтенләй тугарыла: «Чиктә хезмәт итә идем мин, яшерен хезмәттә... Япун шпионнары белән көрәштә, дөнья буржуазиясе белән алышканда, мин иң кадерле сыйфатымны — матурлыгымны югалттым!» — дип күкрәген төя.

Белмәгәннәр аның һәр сүзенә ышаналар, ничек ышанмыйсың ди, ул сиңа тонык-кара күзләрен кыса төшеп туп-туры карап тора, татлы теле белән әгъвәли, күз нурлары белән сихерли... Чулакның ике якка тырпайган купшы мыеклары, аның ялганын раслагандай, сөйли башлауга өзлексез тирбәләләр... Мыекның мәшәкате ифрат зур булса да, Чулак вакытын жәлләми: тонык, чебен бизәкләре белән чуарланган көзге каршысында иртән сәгатьтән артык маташа ул, юа, киптерә, сыга, каз

мае сөртә, ун төрле эскәк, биш төрле кайчы белән һәр төкне күзеннән үткәрә, иреннәрен бүлтәйтә, бүрәнкә ясый, аскы иренен йотып өскесен биниһая калкыта, ике бармагын ирен читләренә тыгып бака авызы ясый, хикмәт инде, бер дә, бер дә хикмәт!

Һич истә югында ул өй борынча авылны йөреп чыга, ябык капкаларны тибеп ача, пычрак аяклары белән түргә уза, мич арасына кысылып үтә, юантык бармаклары белән нидер капшый, иснәнә, мич кабыргасына колагын куеп тыңлый, ачуы чыкса, нидер таба, штраф түләтә. Түләүне йә каз түтәрәме, йә бер чирек көмешкә белән ала. Салган баштан абзар-кура арасына керә, мунчада хатын-кыз юынганны белсә, туп-туры шунда юргалый, керә, чинап качкан хатын-кызларны үгетли: «Ни кыланган буласыз? Дуктырларга шәрәкәй күренәсез ич, пожарниклар алардан кимме? Төтен юлларыгызны, юшкәләрне тикшерергә тиешме мин? Тиеш!» Хатыннар чыранлап кычкыралар, чиныйлар, тегенең шлемына чиләге белән кайнар су коялар, ә аңа... ике чабата бер кием!

Урамнан, сөзгәк үгез сыман, туп-туры карап бара, берәүгә дә юл сапмый, күкрәкләр күкрәккә тия язып туктый да сыңар кулы белән махраны шулай оста һәм тиз урый, искитмәле! Түтәл тәмәкесенең иң зәһәрен, ачысын тарта, ул үтеп киткәннән соң сәгать узгач та Чулакның исе танауларны кисә.

Мин баскычка аягын куйган Рәфгатьне читкә тартам, Чулакның «наянлыгын», өстән, каланча башыннан малайлар өстенә бәләкәй йомышын чәпердәтергә яратканын беләм.

— Ничегрәк анда, Гыйбадулла абый, йолдызлар күренмиме? —дип сорыйбыз без астан.

— Йолдызлар юк-югын, мөгезле шайтаннарның тузаны якынлаша. Кая китеп барыш?

— Кәҗә карар өчен менденме каланчага?

— Төш дисезме?

— Төш әйдә! Күңеллерәк булсын дисәң, берне шартлатырсың.

— Шартлатты диярләр. Бушка кинәнерләр иде бугай...

Элегерәк Чулак белән Рәфгать ахирәтләр иде, юк-бар сәбәпләр аркасында аралары суынды, Чулак моны сиздермәскә тырыша, алай да чыраеның каралыгын әллә каян күреп торам.

Сыңар кулын тиз-тиз йөртеп, ул җәлт кенә аска төшә, кул, аяк хәрәкәтләреннән аның ныклыгы, көче, тазалыгы чәчрәп күренә, берне китереп орса, җаның чыгар...

Хәрби киемнәре яңа, френч төймәләре елтырый, зәңгәрсу галифе балаклары таза ботларын кысып торалар. Җитезлегеннән, тазалыгыннан ул бик канәгать, туктаусыз елмая, шап иттереп ботына суга да чиләк тотып буа алдына бара, су чумырып, тамчысын да коймыйча сарайның аргы башына, ат аранына атлый. Без дә аңа иярдек, баргач карасак, лапас астында рәиснең трантасы да, аранда айгыр да юк.

— Юртакны кая җибәрдең, Гыйбадулла абый? — дип төпченәбез.

— Кайтып җитмәде.

Хәйләкәр Чулак туры җавап бирәме соң!

— Әллә аны да армиягә алалармы?

— Булыр, булыр... Алырлар да...

— Гыйбадулла абый!

— Йә, өйдә булса нишләр идегез? — Ул көчле кулы белән себеркесен идән тактасына терәп ышкый, ат «алмаларын» Рәфгатьнең аягына тәгәрәтә. — Көтмә! Бүген шартлату булмас!.. Ә сиңа, Искәндәр ахири, тәҗел йомышым бар!

— Нәрсә икән ул? — Мин шундук сагайдым.

— Беләсем килә, егетме син, әллә борын астың һаман җебекме?

Чулактан бер-бер яңа этлек көтеп башымны ватам: «Ни кыландыра бу явыз?»

— Абыеңнан хром итекләр калдымы?

— Калса соң?

— Яңа итекләр бит, иеме?

— Клубка чыкканда бер-ике киде бугай.

— Шундыйны эзлим дә мин! Сат син аларны миңа.

— Ә абый?

— Кайчан кайта әле ул? Хром күпкә чыдамый, абыең кайтканчы итекләр черер. Миңа таман булачак алар! Яңа галифега хром итек кирәкме? Кирәк! Абыең белән без бер үлчәүне кия идек.

— Гыйбадулла абый өйләнергә ниятлиме әллә? — диде Рәфгать, сүзне уенга алып. Чулак аны бүлдерде:

— Хәзерге заманда өйләнмәсәң дә кызлар буа буарлык... Йә, килештекме? Егетме син, юкмы, әйт тә бир! — Мин дәшмәгәч, ул ашыктыра ук башлады.— Йомышың төшәр, утын, печән китерим дисәң, миңа килерсең... Юртак кем кулында икәнен беләсең.

— Сабан туе юртагын утын арбасына җигәрсеңме? — дидем мин, кызып.

— Кемне, кая җигәргә икәнен алда күрербез!

Димәк, Ялкын, ефәк яллы аргамак ачкүз Чулак ку-

лына калган! Юкка гына киенеп-ясанмаган икән хәчтерүш! Хром итек кирәк икән күрексез гармунга! Ярсуымны көчкә тыеп аның симез, тыгыз муенына карап торам. Себеркесе белән ут уйната, ат сараеның идәне уңган киленнең сәкесе тиң елтырый. Ул гәүдәсен турайтты, маңгай дымын йонлач кул аркасы белән ашыкмыйча гына сыпырды һәм усал күзләре белән мине чәнчә-чәнчә җавап көтте.

— Сатмыйм. Абый гармунны да, итеген дә сакларга кушты. Кайта ул, кайтмыйча калмый.

— Каланчадан бөтен юллар күренә, Искәндәр энекәчем, кайтучылар юк.— Ул авыр, дымлы кулын минем иңбашына батырды.— Сатарсың, күтең түгел. Миннән башка хәзер авылда яшәү юк. Күрерсез! Минем көн килде! Үзең сатмыйсың икән, әниең китереп бирер. «Ал, зинһар» дип ялварыр.

— Кем яши алмас икән синнән башка?

— Син дә, ул да, барыгыз да. Бөтен авыл!

Ерылган буа суы булып авыл башына көтү килеп керде. Алдан тек-тек басып, сакалларын җилфердәтеп кәҗәләр килә, алар артыннан күәс-күәс җилемнәрен як-якка чайкалтып ваемсыз сыерлар атлый, сыер аяклары арасында йоннарына тузан утырган сарыклар бутала. Малларны көтеп зарыккан каршылаучылар арага кереп китәләр, берәүләр сарыгын чакыра, икенчеләре сыерга дәшә, кемдер иркәли, кемдер каргый, тавыш-гауга куба. Күрче, киләсемне алдан белгән диярсең, безнең сыер да кайтып килә, мүкләк шайтан, саумы! Нәсимә бик елагач муенына кеченә кыңгырау тагып җибәргән идем, чеңгел-чеңгел тавышы аерылып еракта ук ишетелә икән. Нәсимә дә килгән, тузанны аралап авызын ерып килеп чыкты да, кулындагы сыек чыбык белән мүкләкне куа башлады.

Рәфгатьләрнең чуар сыеры юаш, үзе кайта, мөгезе белән капкаларын ачып керә, бүген ул көтү каршыларга миңа иптәшкә генә килде. Без малларны күз белән озатабыз да, тузан басылгач, Чулак янына кире кайтабыз.

— Миннән башка яшәп карагыз,— дип кабатлый ул,— теләсәм, иртәгә үк рәис итеп куялар мине!

Икәүләшеп егылып китә яздык: дөрес сөйли бит бу чулак тәре! Ник куймасыннар, елгыр эт, районнан килгән вәкилләрне майламыйча калмый, Олы су тугайларына сөкә куя, өреле ухасын өчәр коштабак ашыйлар, аракыда йөзәләр. Үзенең сөйләгәне бар! Район башлыклары беренче кардан соң Чулак янына киләләр, ул аларны куян эзенә төшерә, буш кайтканнары юк. Көртлек аланнарын, апрельдә кыр тавыкларының гөрләгән аулак җайларын

эзләп таба, телгә үткен, оятсыз мәзәкләрен бер сөйләп җибәрсә... Кыскасы, коеп куйган рәис! Сигез класс бетергән, сугышка аласылары юк...

Рәфгатьнең кысынкырак күзләренә ут сыймый, тышка сирпелә, мин дә Чулакны чалып егарга, безне бүгеннән салып таптаганы өчен ипи шүрлегенә менеп төшәргә әзер. Чулак кына бер мәлгә безне онытты, иреннәре җәелә, эре калак тешләре батып барган кояш нурларында елтырыйлар, мыеклары кыймыл-кыймыл киләләр. Кемне күреп шулай куана дисәк, Мәүлиха апа кайтып килә! Бәй, көтүгә чыгарга бүген алар чираты икән! Аякларын көчкә сөйрәп, тигез урында да абына-сөртенә, башын иңенә кыегайтып атлап килгән җиреннән, Чулакны күрүгә, ул кинәт сискәнеп китте, төп-төз турайды, текә, мул имиләре дерелдәп, тибрәнеп куйды. Бер дә, бер дә җиде бала анасы димәссең Мәүлиха апаны! Әнкәсеннән бераз арткарак калып, табаннары белән урам тузанында эре-эре эзләр калдырып, Мәүлиханың олы кызы Кәримә килә. Әнкәсеннән бер башка озынрак, гуардин Кәримәнең әтисен авылда берәү дә белми, баш балаларын, ике кызны Мәүлиха җилдән алып кайтты. Җитеп, кияүгә чыгарга яше керүгә, Мәүлиха апаның табанына ут капкан, язын Ижауга юл тотса, кышны Яраслауда үткәргән. Бер кайтуында: «Чегәнгә кияүгә чыгам!» — дип ялганласа, икенчесендә: «Артымнан эфисәр йөри, чыксам да чыгармын шул!» — дип киткән. Кияүләр күренмәгән, бәбәйләр туган. Кәримә кайсы милләт каныдыр, озындыр буе, алагаем зурдыр аягы... «Ходаем, шул Кәримәнең аягын күрмәс өчен әллә ниләр бирер идем!» — дип куя безнең әни, гуәрдин кызның артын уйнатып тәрәзә каршысыннан үтеп киткәнен күргән чакларда. «Кәримәгә чабата ясар өчен ярты урманның юкәсен каезларга кирәк!» — дип зарлана чабатачы мәшһүр Минәчтин карт.

Чегәнгә тагылып әллә ни кинәнә алмагандыр җил итәкле Мәүлиха, эфисәр куенында рәхәт күрү дә язмаган икән аңа... Биктимер исемле үсмер егетнең әтисе, эссесенә чыдый алмыйча, мунчада җан тәслим кыла, энкәсе шул хәсрәттән дөм сукырая... Өлкәннәр, кардәшырулар хәсрәткә калалар: йорт-җирне нишләтергә, хуҗалыкны ничек алып барырга? Тоталар да үсмергә Мәүлиханы димлиләр: егет җәмәгатьле булыр, Мәүлихага да акылга утырырга вакыт! Биктимерне кәшәкәле уйнаган җиреннән дәшеп кертәләр, үкереп җылаган Мәүлиха каршысына утырталар, никах догаларын әзме-күпме сукалаган Камалетдин мәзин аларның гаиләсен беркетеп дога

кыла. Биктимер, кәшәкәсе ял иткән арада, хатынлы һәм ике кызлы булды. Эш бетеп, дога кылынгач, ул кәшәкәсен күтәреп иптәшләре янына чыкса, артыннан өермә булып хатыны килеп җитә һәм сакал-мыек урынында төк төртмәгән ирен чабаклап өенә алып кайта, чишендереп сәкегә сузып сала... Мәүлиханың холкын яшь кияү үзгәртә алмады, Биктимер дагалый алырлык хатын түгел иде ул юртак, төнлә-төнлә иске сукмакларына төште Мәүлиха, печәнлектә, арба асларында яңадан-яңа кияүләрне куенына ала торды... Чулак Гыйбадулла хәзер дә каравыл өенә чакыргалый икән дип сөйлиләр. Растыр, авыл авызында сер торамыни?!

Атлавын күр син аның, атлавын! Рәфгать тә шуңа игътибар иткән икән, касыгыма төртә, күз очлары белән ымлый, Чулакны таныйрлык түгел, тычкан күргән ата мачы сыман йомылган, хәзер сикерә!

Чулак турыннан китми дә китми Мәүлиха апа, аның артында ап-ак чакрым баганасы булып Кәримә басып тора. Ни сөйләшкәннәрен ишетәсе килә, аякларны шудыра-шудыра мыштым гына без дә аларга якынлашабыз. Чүлмәкчедән күрмәкче ике-өч хатын безгә иярде, аларга тагын ничәүдер кушылды, түгәрәкләнеп базар ясадык. Сугыш чыккан көннән бер урында ике-өч кеше төйнәлсә, якын-тирәдәгеләр иң тәҗел эшләрен дә ташлап төркемгә тартылалар, бергә булырга тырышалар: яхшы хәбәрләр ишетелмиме, сөенечләр колакка кермиме? Немец мәлгуньнең муенын сындырмаганнармы?

Бүген дә әнә эт көтүе халык җыелды, ә әңгәмәнең элә-тотанагы юк, килгәне бере Мәүлиханы мактаган була, Кәриминең салпы ягына салам кыстыра.

— Булдырасың икән Мәүлиха, ай-һай!

— Җепкә тезеп алып кайттың малкайларны!

— Иң качкын сыерларны да сихерләгәнсең, билләһи!

— Бүтән көннәрдә мал эзләп аяксыз кала идек, бүген бәйрәм!

— Мәүлиха әмәлен белә ул!

Хатыннар тәмле сүзгә зарыкканнармы, тәки мактап эреттеләр Мәүлиха апаны, авызын бәлшәйтеп, керфекләрен леп-леп йөртеп, Чулакка карап-карап торды да, буасы ерылды берзаман! Елапмы-елый, күз яшьләрен чынлап түгә! Күрмәсәң күр: чакма ташы сыман каты Мәүлиханы да мактау сүзләре йомшартты, тыела алмыйча рәхәтләнеп елады бичара...

Борынгы гореф-гадәтләр ялгыш та какшамаган безнең гаиләдә өлкәннәр Мәүлиханы, ул кылган языклы гамәлләрне үтерерлек әче сүзләр белән телгә алгалыйлар

иде. Мәүлиханың тетмәсен тетәләр дә ире Биктимерне кызганып уфылдап куялар. «Өйләрендә хатын-кыз сигез җан булса да, бар эшне Биктимер үзе башкара, бичара катынша, идән юа, суын ташый, сыер сава, он или, кызларының оегын ямау аның өстендә, кышлар буе оекбияләй бәйли, тула баса»,— дип, безнең Түбән очлар җиз поднос төсле киң битле, киң, маймыл танаулы, гаять аз сүзле юаш кешене бик кызганалар иде.

Мәүлиха апа утлы табаны, җиде кызы, җиде кызыннан да бигрәк җиде шайтанга җитәрлек ялкаулыгы белән тирә-юньдә бер, иң данлыклы хатын иде... Аның телгә беткәнлеген әйткән дә юк! Бар иде аның хәтәр чаклары! Хәтерлим әле, колхоз җыелышларына көндездән үк килеп утырыр, беркем сайламаса да, президиумга менеп кунаклар иде. Янәсе, хатын-кызлардан авыл активы! Җыелыш саен икешәр тапкыр сүз алып сөйләсә дә, гадәти тормышта телчән апа сәхнәгә менгәч, һаман бер күәстәге камырны тугылар иде:

— Без изелгән мөселман хатыннары, гомер буе ирләргә кол булып яшәдек, якты көн күрмәдек!.. Хәзер слабуды! Влач үзебезнеке! Аяк юдыра алмыйсыз хәзер бездән...

Кемдер аны төзәтергә тырышып карый, сүзнең язгы чәчү яки МОПР файдасына акча җыю турында баруын искәртә, Мәүлиха апа аны колагына да элми, үзенекен тукый:

— Әгәренки иптәш Маркс, иптәш Энгельс, иптәш Ленин, кадерле юлбашчыбыз Сталин булмаса, без бүгенгесе көндә һаман җәтмәдәге аңгыра балык хәлендә калыр идек. Коммунистларның төп китабында кат-кат әйтелгән: хатын-кызлар ирләр белән тигез хокуклы, диелгән. Әй, син! Ишек катында торучы Миннәхмәт! Ник үр-рә кычкырмыйсың? Салып кайтып катыныңны син ярасың!.. Димәк ки, эшнең зурысы ир-ат җилкәсенә төшәргә тиеш, диелгән ул китапта. Колхозны алга җибәрик и яшәсен үзебезнең кадерле совет влачы!

Ул чакта Мәүлиха апа бәбәйтәкле озын күлмәген киеп, кызыл кыйгачын җилфердәтеп, түшенә МОПР, ПВХО значоклары тагып йөри иде. Районнан килгән вәкилләр белән гәпләшергә ярата, газеталардан килгән каләм осталарын хуп күрә, ә андыйлар ул заманнарда безнең алдынгы, мактаулы авылдан китеп, өзелеп тормыйлар, нәтиҗәдә, Биктимер хатыны Мәүлиха ел аралаш йә ак чәчле кыз, йә чем-караны, бер-беренә һич охшамаган бәбәйләр алып кайта торды.

Утауда да, уракта да гел артта кала башлагач, бәрәңге кишәрлеген алабута басып киткәч, Мәүлиха апаның үзенә

дә тел-теш тидерә башладылар, идарә алдындагы баганага фанер кадаклап, ташбакага атландырып иләмсез сурәтен төшергәч, ул беравык дулап йөрде, җыелышларга бармады, идарәдә күренмәде. Аннары тагын иске гадәтен куа башлады, йодрыгын селкә-селкә сәхнәдә тел тегермәнен әйләндерде:

— Үзебезнең кадерле сәвит влачы изелгән хатыннарга якты юл ачты, ирек бирде, кадеребезне күбәйтте. Сәвит влачы биргән иректән рәхәт күреп калыйк, мәми авыз булып тормыйк!.. Без мөселман хатыннары...

Мондый минутларда Биктимер абый күзләрен чытырдатып йомып идәнгә иңә, җыелышларда ишек төбенә чүгәләп махра көйрәтүдән бушамаган Гыйбадуллалар аяк тибә-тибә кул чабалар, көләләр иде...

Мәүлиха апаның ялкаулыгын авыл-күрше әкият итеп сөйләп йөри, тирә-як авыллар базарда-фәләндә Югары авыл кешеләрен очратсалар, сүз арасында: «Ничегрәк соң анда, Мәүлиха апаң ниләр кыйрата?» — дип сорамый калмыйлар...

Имеш, килен булып төшкән елны ире Биктимер утын вакларга онытып чәчүгә чыгып киткән икән. Мәүлиха апа ары-бире караган, аш салган, ягарга утыны гына юк икән. Шуннан яшь килен түр тәрәзәне ачкан да лапас астында яткан буй-буй усак колгаларын туп-турыдан мич авызына тыга башлаган. Колга яна тора, киленебез аны эчкәрәк шудыра тора... Шулай сөйлиләр. «Маңгаендагы корымы атна буе йөри, Мәүлиха мунчадан мунчага гына битен юа», — дип тә өстиләр...

Эш шуңа барып җитте ки, берзаман клуб янына эленгән фанер тактага Мәүлиха апаның сурәтен ясап куйдылар. Дәү ташбакага ботын-чатын җәеп атландырганнар да, сул кулын күтәртеп, авызыннан чыккан куыкка «Алга барыйк, алга барыйк!» дип язып куйганнар. Монысын күтәрә алмады Мәүлиха апа, атна буе авыл арасында күренмәде, атна үткәндә клуб янына төшеп, тактаны каерып алып, язуны урам пычрагында яньчегәнче таптады. Ике атна үтәр үтмәстә яңадан трибунага түше белән менеп ятты, тамагы карлыкканчы сөйләде, туктала, тыела алмады.

— Кадерле влачыбыз көнчыгыш хатыннарына тулы ирек алып килгәндә, безнең авылның кайбер, ишетәсезме «кайбер!» эшлексезләре хатын-кызларны мыскыллыйлар... Ә төп китапта кат-кат әйтелгән, әгәренки диелгән, ирләр хатыннарны хурлый икән, өтермәнгә утыртырга, диелгән. Без мөселман хатын-кызлары... Безгә ирек кирәк!

— Син болай да тезгенсез, ирекле! — дип кычкырды кемдер арткы рәттән.

Әмма Мәүлиха апа үз тавышыннан бүтәнне ишетми башлаган көнгә ирешкән иде. Колагы ишетмәде, күзе күрмәде, ишек тирәсендә чүгәләп ояла-ояла тәмәке суырган Биктимерен дә танымады...

Әйе, сугыш чыкканнан бирле үз урынын таба алмаган, игътибарга зарыккан апа, бүгенге гади мактау сүзләреннән эреп, җебеп акты. Ирен сугышка озатырга да күрше-тирә генә керде ич Мәүлиханың! Килгән-киткән вәкилләр дә ишеген какмый башлады! Ә монда, хурланып, ачыгып көтүдән кайтып килгәндә баллы яңгырдай мактау ява!

Һәр нәрсәнең чамасын бик белеп яшәүче Мәүлиха тыелырга кирәклеген абайлады һәм, Кәримәсенә күрсәтеп:

— Кызымны мактагыз! Әгәр Кәримәм, уңганым, асыл кошым булмаса, тыяр идең бүген малларны! Аңа рәхмәт!

Кызларын мактарга тотынса, аны туктатырмын димә, ярый әле, атлы трантас килеп туктады. Трантас түренә аркасын нык терәп, ярсыган, тирләгән айгырның авызлыгын тартып тотып, нык куллы, юантык директорыбыз Зөләйха апа утыра, ә янында... Кем дип белерсез, директорга иңен куеп, туп-туры карап, ничектер төс үзгәрткән Арзу утырган. Безнең күрше Хәбибрахманның оныгы. Арзуның өр-яңа яшел бизәкле ак батист күлмәгенә шактый ук пычрак чәчрәгән...

Әллә директор ишетсен дипме, әллә Арзуны күргәнгәме, Мәүлиха апа телен туктата алмады:

— Кәримәдәй уңган бала юк инде авылда... Малларны көне буе учына урап кына тотты инде матурым,— дип сайрады ул, әле Зөләйха апага, әле Арзуга карап.

Кемдер:

— Алай уңган икән, әйдә, алсын Кәримә көтүне! Көтсен кышка кадәр. Авыл белән рәхмәт укыр идек! — дип сүз катты.

Чулак, айгырның йөгәнен эләктереп, ял астын, кайнарланган муенын шапылдатып сөйде. Хуҗаларча кылана!

— Нәрсәгә җыелыштыгыз? — дип сорады Зөләйха апа, трантастан төшә-төшә.

— Болай гына,— дип ыржайды Чулак.— Эш юктан эш табабыз.

Җыелганнар Зөләйха апаны зурлап, олылап каршыладылар, аннан да, моннан да сәламләү авазлары ишетелде.

— Көтүгә чык дип Кәримәне үгетлибез менә.

— Малларны ничек тә алып барып чыгасы иде бит!

— Бүреләр тәмамысы азынды!

— Кәримә тотынса, буе бар, бүреләрне ун чакрымнан күреп алыр!

— Белеме җитәрлек,— дип өстәде кемдер, зәһәрләнеп.

Шук сүзләр сибешкән хатыннар күмәк көлеп җибәрделәр. Мәүлиха апаның каушавын беренче тапкыр күрдем, теле тотлыкты бичараның, сүзе бетте. Трантас янына тартылдым... Арзу җиргә төшкән дә озын кунычлы, биек үкчәле ботинкаларыннан йомычка белән пычрак чистартып маташа. Бу ботинкаларын сәхнәдә бай кызларын уйнаганда гына кия иде, ни кыланган була икән бүген? Кылтайган...

Кызыксынуым шартлар дәрәҗәгә җитте.

Чулак айгырны тугарды — булышмадык, трантасны көчәнә-көчәнә тартып лапас астына кертте — ярдәмләшмәдек. Рәфгать тә, мин дә Арзудан сүз, аңлату көтә идек. Җыелганнар берәм-берәм тарала башлады, күпчелек Зөләйха ападан бер-бер яңа хәбәр көтеп туктап калды. Барган җиреннән буш кайтмагандыр ич? Арзу телен йоткан, безгә карый, елмая, дәшми!

— Рәис юртагына утырып йөри башладык диген?

Ни булган бу кызый актыгына? Кәримә дә аңа килеп ышкылды, «кая бардыгыз?» дип сорады, җавабы юк Арзуның, тиле кеше сыман басып тора, тиктомалга елмая... Хатыннар Зөләйха апаның итәгенә ябыштылар:

— Районда ни яңалыклар? Сугыш бетәргә бармыймы?

— Сугышабыз! — диде Зөләйха апа, кыска гына.— Сугыш бара!

— Сугыш барганын беләбез! Бармаса, Ибраһим малаеның үлем хәбәре килер идеме? Кайчан немецны куа башлыйбыз?

— Һәрнәрсәнең үз тәртибе бар,— диде ышаныч белән Зөләйха апа.— Куарбыз да, җиңәрбез дә. Әлегә мин сезгә яңа укытучы алып кайттым.

Мәүлиханың күзе шакмак булды:

— Кайда соң ул?

Рәфгать белән мин дә сагайдым, йөрәгем мелт итеп куйды. Югары авыл өч ай буе кешеләрне озата иде, бакчы, кемдер кайткан икән ләбаса! Кем булыр ул?

Зөләйха апа Арзуның иңен кочып алды да, иркәләп кенә:

— Менә ул безнең яңа укытучыбыз,— дип куйды.

Мәүлиха пырхылдады, чыраен сытып, Арзуга текәлде:

— Кемне укытачак инде яңа укытучы? Наданнар авылда калмады сыман. Ликбезлар бетте.

— Менә бу егетләрне укытачак,— диде директор, Рәф-

гать белән мине күрсәтеп. Зөләйха апаның уйнап сөйләшмәгәнен белмәсәк, бу хәбәргә беребез дә ышанмас иде, ышандык, көтмәгәндә уч төбем кычыта башлады. Гасабилансам, артыгын кызып китсәм гел шулай кычыта ул!

— Арзу аларга немец теле өйрәтәчәк!

Менә әкәмәт: былтыр гына унынчыны тутырган Арзу немец теле укытачак! Фи-и, Арзу да булдымы укытучы? «Апа» дип тел әйләндереп әйтәмме мин аңа? Гомергә юк! Бәләкәй чагында үзенең толымын урап тотып, кәҗә мае чыгарып, бик шәпләп «абыем-җаныем, матурым-алтыным!» дип йөз кат әйттерә торган идем, хәзер бакчы, эш кая табарак китте... Кара такта янына төз бастырып, «дер, дие, дас»ларга биетәчәк! Әйткән иде диярсез, анысын булдырыр! Тфү!

— Эшләр шулайрак,— диде Зөләйха апа, Арзуның аркасын сөеп,— сез монда көтүчене табып куйгансыз, ә мин укытучы алып кайттым. Эшләр әкренләп көйләнер. Бүтәнчә ярамый. Рәхмәт, Кәримә, җаваплы эшкә алынгансың. Сугыш вакытында һәркем хәленнән килгәнчә эшләргә, тырышырга тиеш.

— Алай икән, алай,— дип сузды көтмәгәндә Мәүлиха,— значытсы минем Кәримәм, минем матурым, авылда тиңе юк уңганым, аңгыра бәрәннәр артыннан юртып, юеш сыер койрыгына багып, таудан тауга чабачак та, шушы Арзу, суык тешләгән ләчтә кабартма, пәртфил кыстырып укытып йөрсенме? Тотмыйсызмы? Кызым, әйдә, киттек силсәвиткә! Влач үзебезнеке, крестьян кызын басарга ирек бирмәс! Төп законда андый закон юк! Әтисе солдат, фронтта. Көн кашыклы канын коя, әллә аңа «Батырлык өчен» мидәлен юкка кададылармы? Ә бу чи кабартма кем кызы? Йә, кайсыгыз әйтә: кем баласы?! Әчкече сантый, өстерәлчек кызы түгелме? Ә бабасы... мие түнгән дөя!

Зөләйха апа Арзуны кочаклап ук алды, Арзу таң калып, исе китеп Мәүлиха апага карап катты, ап-ак агарынды, аның күз чокырларына курку шәүләсе кереп тулды, өске ирене калтырады. Җыелганнар, күзләрен аска төшереп, авыз читләрен куллары белән томалап, тиз-тиз таралдылар. Әнисенең каһәрле сүзләрен Кәримә дә авыр кичердеме, буе бәләкәйләнде, Мәүлиханың артына кереп посарга теләде, әмма әнисе аның кулын каерып тоткан иде, тезе белән һаман алга этәрде.

Арзуны кызганудан мин нишләргә дә белмәдем.

Мәүлиха агулы, зәһәр сүзләрен чыгарып бетереп тынып калды. Сүзе бетте, ачуы чыгып бетмәде, янап кулларын селкеде, кичке сүрән яктылыкта аның беләгендәге

көмеш беләзекләре, бармакларына ябышкан алтын балдаклары, яшен булып елтырады.

— Кәримәне көтүче итмәкчеме?.. Булмый торсын! Моның җавабын таптырмый калмам! — дип бакырды ул, тавышы бугазына тыгылып тынды, таш кыя күк каткан Кәримәне җитәкләп-тартып, башын югары чөеп күздән югалды. Арзу тыенкы гына елый иде. Кинәт аңа каеш камчы белән китереп суктылармыни, дерт итеп сискәнеп китте, сыктаудан туктады. Китеп баручы Мәүлихага төртеп күрсәтә-күрсәтә, буа буен яңгыратып Чулак шаркылдый иде:

— Вәт кеше диген! Кем аның кызын көтүгә куа?..

Мин Арзу янына барып бастым, әгәр бу хәл кичә булса, мин нишләргә дә, ни әйтергә дә белер идем. Бүген безнең янда немец теленнән укытачак мөгаллимә басып тора, ә мин аның укучысы гына... Ул үзе дә, без дә бу яңалыкка иялэшмәгән идек, барыбыз да тирән аптыраш та калдык. Мәүлиханың ачыктан-ачык янавы безне миңгерәүләтте. Кинәт Арзу яшь аралаш елмайды:

— Кара инде... көлмәгемне... Кеше күзенә күренерлеге калмаган! — Ул сүзсез калды, беравыктан томылып өйләыренә йөгерде.

Мин аны куып җитәргә теләгән идем, Рәфгать килеп тотты:

— Тимә, тынычлансын.

Өйгә кайттым. Әни ут яндырды. Сукыр лампа. Әни керосинны күз карасыдай саклап тотарга тырыша. Аннан-моннан капкаладым да урамга чыгарга җыендым. Күңелем өйдә урын таба алмаган иде. Әни, миңа карамыйча гына:

— Тышта ни калган? Утыр өйдә! Җил котырып маташа, явымгадыр әле,— диде.

Чыннан да пыялалар зыңлый, тәрәзә капкачлары сыкрана. Кубып төшмәсәләр яратырсың, иртәгә ныгытырга булыр...

Бөтен дөньяга ачулы идем мин! Барыннан да бигрәк Арзуга үпкәләдем. Үпкәләдем дию әз, рәнҗедем, каным кайнады. Шулкадәр астыртын тешләк булса булыр икән, белмәгән идем. РОНОга барасын кичә үк белгән ич ул, дип сызланды җаным, укытырга кайтасын да әйткәннәрдер... Ярты сүз белән аңлатса ни булыр иде? Мәүлиха апага да ачуым зур иде. Әмма Арзуга булган рәнҗешем янәшәсендә ачуым нәп-нәни булып калды, уянды да сүнде. Пумала тел инде, нишләтәсең аны. Башымнан Арзу чыкмады. Эшнең болай борылуы минем алдагы планнарны тәмам чуалтты. Укытучы безнең Югары авыл-

да затлы, абруйлы кеше, аксакаллар да аның алдында бил бөгә, баш ия, япь-яшь укытучыларны да «мөгаллимә апа» дип олылап йөртәләр. Хәзер, бүгеннән Арзу да «мөгаллимә апа» булачак. Миңа кем була ул хәзер?.. Нишләргә? Бүгенгә кадәр бүгенге хәлем дә, киләчәк тормышым да аңлаешлы, ачык иде. Дөрес, моңарчы без мәхәббәт хакында өзеп сөйләшмәдек, бүтәннәр сыман капка баганасын саклап аңлашмадык, әмма мин, «Арзу минеке булыр, минеке!» дип малайларча тилелек белән ышанып йөри идем. Булыр сиңа, көт... «Мөгаллимә апа!» Немец теле дәресендә кара такта янына чакырып... Кайсы җирең кечи?!

Урамны салкынча җил яулап алган, өй араларыннан ургылып чыга да бәрә, тез аслары тирбәлеп китә. Күршебездә, Арзу белән Хәбибрахман абый яшәп яткан өйдә, ут бар-барын, әмма тыгыз пәрдәләр эчне нык томалаган. Нигез ташларына баса-баса, наличникка ике яктан ябышып өскә мендем, пәрдә өстеннән карамак булдым, ташлар урыныннан купты, сыланган коры балчык шыбырдап җиргә коелды. Дәррәү кабынган җил тавышы мине саклап калды, Арзуны чак-чак күреп өлгердем. Тагаракта ак күбек уйнатып ул кер юа иде, кыяфәте боек, йөзе үтә моңсу булып күренде. Әллә елый да инде, иңбашлары сикереп-сикереп китә...

Кая барып сугылырга белмәгәч, Түбән очка, Рәфгатьләргә таба киттем. Бергәләп буа янына атладык. Гадәттә кичен яшьләр шунда җыелалар. Барсак, озынча тәбәнәк эскәмиядә, ана канаты астындагы чебешләр булып, өчдүрт кыз утыралар. Каравыл өеннән мыдыр-мыдыр сөйләшкән тавышлар килә. Анда кереп тормадык, кызкыркын тирәсенә елыштык. Сөйләшмибез, җил, салкын, күңелсез... Бергә утырсак та, аерым-аерым өшибездер сыман тоелды.

Шыгырдап ишек ачылды, аннан сөйләшә-сөйләшә икеөч кеше чыкты. Каравыл өе баскычына басып яшертен генә нидер пышылдаштылар да яңгыратып көлеп җибәрделәр. Төркемләнеп буа өстенә таба атлаганнар арасыннан икесе аерылып, безгә таба борылды. Якынрак килгәч таныдык —Чулак белән тегермәнче Хәбиб малае күпәш Сирай икән. Чулак тып итеп каршыма килеп басты.

— Котлыйм, егет, котлыйм! — диде ул, караңгыда елмаеп.

— Сәбәбен әйтеп котла,— дидем мин, ачуымны белдермәскә тырышып. Ачу килгән чак, тәки әләгешеп китәрбез.

— Түзегез генә! — диде ул, мыскыллы көлеп.— Хәбиб-

рахман токымы, диләр аны! Текә нәсел! Койрыгыгызны борачак! Арзуны белмисез әле сез!

— Безне озакламый армиягә алалар,— дидем мин.

Сирай тыныч кына утырган кызларга бәйләнә башлады, әле чеметә, утырган урыннарыннан йолкып чыгара, ә кызлар чинапмы чиныйлар. Башта мин, аннары Рәфгать кат-кат әйтеп карадык Сирайга, ә ул аның саен котырып кызларның берсен елата ук башлады. Мин Рәфгатькә:

— Әйдә, ике күз арасына мөгез чыгарабыз! — дидем.

Чулакка шул гына кирәк, безне үртәргә, котыртырга тотынды, этә, төртә, беләкләрне капшый, үзе бертуктаусыз лыгырдый:

— Мәктәптә мәшәләнәсе килми алайса? Шәп! Армиягә китәсез! Шәп ярым! Ә беләкләр ныкмы? Кодрәт бармы? Яле, сыныйк, алышып карагыз! Бер, ике. Кара-каршы басыгыз! Немецне тукмарга кайсыгызда көч-куәт күбрәк икән? А ну!

Түбән очтан өч егет килә-килешкә Чулакка кушылып киттеләр, күмәк котырталар безне, Сирай ике-өч тапкыр нык кына минем күкрәккә төртеп алды. Җыелганнар, уч шапылдатып, ай-һайлап көч биреп торды, без уртага чыктык.

Тегермәндә күгәрчен ите ашап көрәйгән Сирай сөлек булып килеп сыланды... Бәхетсезгә вакытсыз дигәндәй, каян кичке уенга төшкәндер ябалак, югыйсә кеше арасына чыкканы, авыл урамында юньләп күренгәне юк иде моңарчы, авылдан ике чакрым түбәндә, Олы су буенда аның өне. Төп кебек юантык нәмәрсә, алагаем көчле икән үзе, алыйм дисәң, биле юк, кысыйм дисәң, муенын бирми, шамбы балыгы кебек култык астыннан шуа да чыга, эре-эре тешләрен ыржайткан, әллә көлә, әллә үчекли, белмәссең. Ә мин көрәшчеләр нәселеннән, Йосыф абыйның үзе белән дә юри-мырый гына алышкан бар, аз-маз әмәлен беләм дигәндәй, беләкләр камыр түгел, шулай да Сирай ят егет, ул мине сыный, мин аны, чабата үкчәләре белән байтак тузан кубардык, алыштык-алыштык та, ялт итеп тегене баш аркылы чөйим дип җирдән кубарып алуым булды, сул аягымның тез капкачы урыныннан купты. Оятыма каршы, сизмәстән акырып җибәрдем, авырта, «тезем, тезем, аһ!» дип аңлатып карыйм, инәләм, берәүсе ышанмый, икмәктер, Сирай билдән алган да башмак ирен-нәрен чак кыймылдатып пышылдый: «Синдә хәйлә булса, бездә көч!.. Көч, белдеңме?!» Гыйбадулла чулак әтәч сугыштырамыни, көч биреп, учларын шапы-шопы суккалап безнең тирәдә йөри. Мин аһылдыйм, тегермәнче малае форсаттан файдаланып болгап атарга маташа, үгез

күк мышный, түп-түгәрәк сары күзләре атылып чыгарга җиткән. Нишлисең, яраса-ярамаса, хәйләгә керештем, иелгән булдым да, баш түбәсе белән тегенең корсак астына берне сөздем, кагыйдәгә сыеп бетмәде бетүен, тәкмәрләп барып төште малаең, чалган дуңгыз төсле чинап җибәрде. Ятабыз икебез ике якта уфылдап. Гыйбадулла, чулак мыегын селкетә-селкетә:

— Хәрәмләште, хәрәмләште! Нәселе шундый, хәйләкәр! Хәрәмләште төлке! —дип акыра.

Ятам сызланып, тирәмдә Чулак сикергәли, шулчак, нинди кодрәт белән булгандыр, Чулак белән Сирайны аерым-аерым да, бергә килеш тә күрдем. Берсе монда — каравыл өендә, икенчесе аулакта — тегермән йортында. Кеше салган сөкәдән балык урлап маташканнарын үзем күрдем — өсләренә килеп чыктым. Боларны ни дуслаштыра дигәндә, һәммәсе ачык: бурлык, әшәкелек, явызлык... Сирай ни кылмасын, Чулак аны гел хуплап, яклап килә... Шуны аңламыйм: ник бәйләнә бу Сирай бүкән миңа? Нинди явызлык кылганым бар? Әти кайчандыр әйткән иде бер: «Бәйләнмә алар нәселенә, кара эчле алар, үчле кешеләр, кырын карашыңны кырык ел онытмаслар!»

Сирай кай арада исенә килеп сикереп торгандыр, бугазын киереп кычкырырга тотынды:

— Әллә мине тегермәнче малае дигәч тә!.. Хәрәмләшә! Янәсе, ул гына оста, белдекле! Алтынчыда өч ел утыргач та, мине адәмгә санамый, янәсе! Күрерсең әле, күрсәтермен мин сиңа!

Гыйбадулла аның саен Сирайны котыртты, кул хәрәкәтләре белән сугышырга боерды, әмма мине иң гаҗәпләндергәне Сирайның соңгы сүзләре булды:

— Бәхетең, сырт сөягеңне сындыра идем инде... Күтәрмә танавыңны, кара канга манчый идем... Карарбыз әле, күрерсең, Арзу кемгә булыр. Белербез!.. Бик теге!

Кыдрачланып якасына барып ябышыр идем, торыр хәлем юк, Рәфгать дустым читәннән бер таяк суырып чыгарды, шуңа таянып көч-хәл белән фельдшер Нәфисәләр турына барып егылдым, өйләренә керер хәлем калмады, тез капкачы дигән каһәр, судагы агач бөке кебек икән ул, бер кузгалса харап, үз сыекчасында үзе йөзә дә йөри, кот калмады.

Өйгә кайтып егылуга, Арзу кереп җиткән. «Анатомияне онытмадыңмы? Ярдәм кирәкмиме? Сугышка бармаган килеш мәҗрух булгансың икән» дигән була, көлә. Кулын

маңгаема куюга, кылт итеп Сирай ычкындырган котсыз сүзләр хәтергә төште... Тукта әле... Арзу, диде бит... Өметләнмә, диде... Каян белгән ул? Каян сизгән? Арзуны уйлап йокысыз узган төннәрем турында әлегәчә җан дустым Рәфгатькә дә сөйләгәнем юк бит! Берәүгә дә!.. Каян сизенгән ул?! Нигә янады? Әллә аның да күзе Арзуга төшеп йөриме?..

Арзуга өйләнергә нияте бармы?

— Ниләр уйлыйсың, Искәндәр? Уйга баттың...

— Болай гына... Уйларның очына чыга торган түгел.

— Зурларча сөйләшәсең...

— Читен булыр сиңа мәктәптә! — дидем мин, күземне читкә алып.

— Беләм.

— Ник ризалаштың алайса?

Арзу яулыгының чачакларын бөтерә-бөтерә шактый вакыт дәшми утырды.

— Баштарак мин фронтка китәргә ниятләдем...

— Кыз башың белән сугышка чыгып китәр идеңме?

— Хәлләремне беләсең ич, Искәндәр!.. Әткәйне зират туфрагына күмәргә дә рөхсәт итмәделәр! Мондый хәл онытыла дип уйлыйсыңмы? Кара тамга хәтердән бер чакта да юылмый. Сугышка китү минем өчен котылу булыр иде. Тик бабайны кемгә калдырасың? Чире яман аның, Искәндәр. Умарталыктан ник китте дип уйлыйсың? Бер корт чакса да, аның үлүе ихтимал, кан басымы сикереп, уйнап тора! Миңа да явызлык теләүчеләр, кара эчле бәндәләр бар. Бар, беләм. Алар теленә кермәс өчен миңа гадел яшәргә, начар сукмакларга төшмәскә, ялгыш та кыек атламаска кирәк. Шул сәбәпле мин мәктәпкә кайтырга ризалаштым да. Намуслы хезмәтем белән ата-анам өстенә ягылган гөнаһны юарга телим. Оныттырырга...

Мин сокланып, янып-көеп аның бер җылы сүзе өчен үләргә әзер булып озак кына аның күзләренә карап тордым. Ул уңайсызланды:

— Ә сез Сирай белән ни бүлешә алмадыгыз? — дип сорады.

— Юк-бардан гына эләгештек!

— Ошамый ул миңа! Аның оятсыз күзләрен күрсәм, тәнем бөрешә,— диде ул.

Көзге җил һаман басылмады, ныгыды, тәрәзәләр урыннарыннан кубарга, очып китәргә теләгәндәй шакылдыйлар, җил арасыннан, иренеп кенә кычкырган әтәчнең тавышы чак ишетелде.

## 2

Эч пошыргыч, төссез берничә көн үтте. Беркая чыгып йөри алмыйм, ишегалдында да үзем маташтырган култык таякларына таянып кына йөрештерәм. Әни мине врачларга күрсәтергә теләп нык талпынды, ат сорап рәис янына да барып кайтты, кая ул, колхозның кырык эше кырылып ятканда ат арттыра алалармы? Бәрәңге бетмәгән, чүмәләләр җыелмаган, анда да, монда да сораеп утыралар, мал-туарга хуҗа табылмады, көтү чыкса чыга, чыкмаса, сыер-сарыклар уҗымны таптыйлар, печән кибәннәрен ишеп бетерәлер. Әни Чулак янына да кереп чыккан, чаптарыңа утыртып җәһәт кенә илтеп кайт, дип ялынган... Гыйбадулланың авызы чабатадай ерылды, ди әни. «Килдеңме, көтә идем»,— дия икән. «Хром итек бирсәң, күз ачып йомганчы илтеп ташлыйм, иң яхшы духтырларга күрсәтәм»,— ди икән җирбит... Әнинең борчылуын күреп, ачуым бермә-бер артты... Эх, барып чыраена төкереп кайтырга!

Тизрәк аякка басасы иде! Шул шашкын теләгем кабул булдымы, бүген тез күмәчем урынында утыра әле, атлау да җиңелрәк. Эшкә чыга алмасам да, өй арасында мәшәкать бетәмени?.. Беренче эшем итеп сандык төбеннән абыйның хром итекләрен тартып чыгардым да лапас күләгәсенә, җиләскә чыгарып элдем. Чулакка үч итеп сакларга кирәк итекләрне! Кибеп ярылмасыннар, корт-мазар төшмәсен! Кайтыр!.. Бәй, үземә дә тамандыр болар?.. Тез төзәлсен инде, үлчәп, киеп карармын. Чулакка гына тәтемәсен!

Кулларымны юыйм дисәм, юынгычта тамчы да су юк икән, тавыкларга кайтарып аударган сары комда бармакларымны кат-кат ышкыдым да бәбкә чирәменә сөрттем: итектән йоккан дегет исе килә килүен, мәгәр түзәрлек! Үз кулым үземә ярар! Битем дә пычранмагандыр ич, әллә ничек кычытып тора.

Урам коймабыз терәлгән өй почмагында юан, җиде кыршаулы иске мичкә утыра, суы яшькелт-зәңгәр, иелеп карасаң көзгедән бер дә ким күрсәтми. Иелеп карадым, битем чип-чиста. Су өстендә канатлары сәлперәйгән тәтәй кашыклар йөзә. Фу, чәч бераз артыграк үскән икән, пумала кук, иелгәч күзгә төшә... Чәчне тимерче Йосыф ала торган иде, хәзер ул да юк. Сугыш башланган атнада ук аны да алдылар, таза, егәрле ир иде шул, безнең әти белән икесе сигезәр потлы капчыкларны иңнән-иңгә чөеп уйныйлар иде... Сабан туеннан кайтканда бер иңендә симез тәкә, икенче иңендә кәефле чырылдап хатыны

Хәтимә апа утырыр иде. Әти белән Йосыф абый бер арбага утырып чыгып киттеләр, бер үк шалонга, бер вагонга эләктек дип сөенечле хатлары килде дә, менә хәбәрләре юк, зарыктык, икесе дә тынып тора. Алар артыннан ук диярлек абыйны да алдылар, өйләнмәгән егет иде әле, ярәшелгән кызы калды. Кәҗә башы урамыннан Кайнар Бибисарасы, олырак авызлы, эре сөякле кыз. Безнең Аскы урамга төшкән саен, җаен табып мине күрми китми, чакырып чыгара да, олы авызын күрсәтергә оялгандай, яулык чите белән йөзен каплабрак:

— Нәнәм, Искәндәр, абыеңнан хәбәр юкмы? — дип сорый.— Хат-мазар алсагыз, туры безгә элдерт, сөенчегә кулъяулыгы белән бер янчык чикләвек бирермен!..

Бераздан абыйның итекләрен пөхтәләп коры чүпрәккә төрдем дә урынына — сандык төбенә кертеп салдым. Аскы урамны ярып баядан бирле берәү тимер чүки, әллә бу араларда худка киткән кул арбасына кыршау суга, әллә күчәр тимерли, чакы-чокы ямьсез тавышы колакны яра.

Чатанлап урамга ук чыктым, почта ташучы сипкелле Рузилә узар вакыт, келәт кыегының күләгәсе болдырны каплады.

Капка төбебездә иләмсез зур соры таш. Бабам алып кайтып куйган. Көчле һәм тәвәккәл кеше булган минем бабай!

Көчле димәктән, безнең авыл гомер-гомергә таш чыгарган. Сарман ягында Әчтәхи боярның аракы заводы булган, шуның озын-озын икмәк складларына дигән ташны безнең авылдашлар чыгарган. Таш базларыбыз янында шактый биек, бер-берсенә тамырлары белән береккән сигез кыя бар. Урал тауларының соңгы тамыры, диләр кешеләр. Булса да булыр. Шул кыяларның иң биегенә, «Сөңге» дип аталганына гел бөркет куна икән. Таш чыгаручылар «Тикмә таш түгелдер бу, бер-бер хикмәте бардыр» дип шигәя үк башлагач, минем бабай йөрәксенеп әйтеп салмасынмы: «Шул кыяның бөркет кунган очын ватып, капка төбебезгә алып кайтып куймасам, Җиһангир исеме миңа хәрам булсын!» Арба күчәрен тимерләгән, үрәчәләрне пеше яшь имәннән ясаган, ничәмә-ничә тәгәрмәч кырган, күпме тaҗ бавы өздергән, мәгәр берүзе менеп кыя башын китеп төшергән, берьялгызы арбага салган (башкалар тылсымлы ташка орынырга курыкканнар!), кырык потлы ташны, ике ат җигеп, исән-аман авылга алып кайтып җиткергән. Ташның өстен тигезләп шомарткан, спайлаган, шуңа калын такта ипләгән. Мин белгәндә таш базларын япканнар иде инде. Бабам карт булса да, кол-

хоз эшеннән бушамады, сабан туе тирәләрендә генә шул таш өстенә чыгып утырыр иде. Бабайны җирләп кайткан көнне әти дә беренче тапкыр шунда чыгып утырды...

Бүген мин утырам!

Ташның бер кырына очлы тимер белән тырнап, «Кәлимулла» дип язылган. Анысы шул армиядәге абыем инде, хәзер Ульянда танкистлар училищесында укый, «*озакламабыз, фронтка чыгып китәрбез, ашыктыралар*» дигән хатын Рузилә-сипкел кертеп бирде.

Кая олакты соң бүген бу сипкелле кызыкай? Көзге кояш күләгәсенә карап алдандыммы, әллә бүген почта килеп җитмәгәнме? Почта атларын да армиягә озаттылар дип сөйләгәннәр иде.

Торналар китә. Берьюлы ике көянтә. Көянтәләр берберсенә хәерле юл теләп якынлашып та куялар, җилдә тирбәлә-тирбәлә тагын ерагаялар, безнең авылның бәрәкәтле борчак басулары, эре-эре түмгәкле тын сазлыклары белән язга хәтле хушлашкан төсле, зур алка ясап урамнар өстендә әйләнеп тә алалар... Көн туды исә канлы сугыш кырларына ир-атларны озатып торган хатын-кызлар күкне моңсу сагыш белән тутырып китүче торналарга карап үксеп-үксеп җылыйлар.

Кырык беренче ел торналарын онытырлыкмы соң?!

Минем дә тамак төбе кымырҗый, тик мин җыламыйм, унынчыда укыган егеткә җылау оят...

Җитмәсә, «армиягә китәм!» дип мактанып та куйгалыйм...

Торналар ерагайды, тавышлары ишетелми. Тизрәк китүегез хәерле. Рузилә хат таратыр чак, күпме йортларда аны күз текәп көтәләрдер. Көткән чакта торна тавышыннан да ямансу, өметсез авазлар буламыни?

Ничәү булдылар икән? Ике көянтәгә... икегә... Юк, юк, торналарны санарга ярамый, санасаң, юлда алар адашалар. Югары авыллар күктәге торналарны санамыйлар, һәр язда авылыбызга кайтып, бала үстереп китүче бу искиткеч моңсу кошларны без бик яратабыз. Адашмасыннар гына! Таралмасыннар! Үзләренә ияртеп быел яз чыгарган бала торналарны да алып китәләр бит! Ерак юлларны моңарчы күрмәгән, ерак, ят илләрдә йөрмәгән балаларын!..

Ниһаять, урам башында Рузилә күренде. Кәримә, Арзулар белән ул да былтыр унынчыны тутырды, ә болай карап торышка аны үсмер кызчык дип белерсең. Буйга сузылгач иңнәре тар булып калган, йомарлам-йомарлам тез башлары алга бүлтәеп чыккан, арык... Торна

баласы диярсең. Бите бәләкәй, борыны кош томшыгы кебек нечкә, шулар өстенә бөтен битенә, маңгаена сипкелләр мул сибелгән.

Атлый, көянтәләнгән баш түбән иелгән, бер атлагач биш сөртенә. Мин аксаклый-аксаклый аңа каршы киттем (кызның безнең якка карамаска тырышканын абайласам да), аның мине күрмәмешкә салышуын җаным-тәнем белән сизәм! Әллә кайчаннан мине күреп килсә дә, каракаршы терәлә язгач кына ул кашларын югары чөйде. Кошныкы сыман түгәрәк күзләре чыланган, әллә хат букчасы авыр инде? Ә-ә, күзләрен җил кискәндер әле! Безнең капка турына кадәр янәшә атлыйбыз, ул китәргә ашыкмый, яныма, кыяташ өстенә килеп утыра. Тезләренә куйган буш букча ишелеп бөгәрләнә. Дәшмибез. Рузилә язуны абайлап ала.

— Ни язылган монда, Искәндәр?

— Менә монысы, гарәп хәрефләре белән язылганы Җиһангир бабам кулы. Бусын, табагач тамганы күрәсеңме, әти чокыган. Нәсел тамгабыз. Астагысын абый чуарлаган, аерасыңмы? «Кәлимулла» дигән. Сай ермачланган, ашыкты абый, җитешеп тирәнәйтәсе бар. Очлы кадак яисә корыч кисәге табасы булыр...

Абый исемен атагач, мин аның букчасына күземне йөгертәм, Рузилә кыска арада тәҗрибә туплаган, сүзне читкә алып китә.

— Аяк ни хәлдә?

— Күз тимәсен, арулана. Иртәгә-берсекөнгә эшкә чыгарга җыенам. Ямансу ла өйдә! Эч поша!

— Укуга кайчан?

— Уку качмас, өлгерербез.

— Әйе,— дип килеште Рузилә,— укырга беркайчан да соң түгел.

— Армиягә алып китмәсәләр, мәктәп качмас.

Нихәл итәсең, сүз чишмәсен кайсы яр арасына борып кертсәк тә, бер үк киртәгә барып төртелә. Нинди дәү һәм аяусыз сүз булды бу сугыш! Рузилә дә шул хакта уйлый, ахрысы, үкчәләренә ияргән балчык кисәкләрен кага-кага зарлана.

— Китәм мин бу эштән, Искәндәр! Кабар җирем калмады, туйдым. Әз булса да, акчасы килә дип сөенеп кергән идем эшкә. Беләсең бит, өйдә җиде бала. Йорттан йортка кереп йөри башлаганда җаным рәхәтләнә иде... Хәзер бераүгә дә керә алмыйм, күренә алмыйм... Бүген ник соңга калды дисеңме?.. Урамга керергә курыктым. Авыл башына кадәр кайтып җиттем дә әрәмәгә кереп капландым. Еладым туйганчы! Һәр капкада мине нинди күзләр

сагалаганын аңлыйсыңмы син?.. Төн буе саташам, шул ук күзләр түшәмнән карап торалар, көтәләр, ялваралар... Көндезләрен кая карап бакмыйм, шул комсыз караш белән очрашам. Күккә карарга тырышам, анда да шул. Түзә алмыйм...

— Кемдер барыбер эшләргә тиеш бит, Рузилә.

Кыз миннән нәкъ шул сүзләрне көтәме, белмим, кинәт мин үземне күпне күргән, күпне кичергән егет итеп тоя башладым, дөньяның аяусыз чынлыгы килеп кагылуга, егыла язган балага ярдәм итәсем, аны сабырлыкка өндисем килде. Сүзләрнең кайсыларын сайлаганмындыр, аңышмадым, үзем дә йомшак, бер көйгә аккан тавышымны гына ишетеп утырдым. Сүзләремнең икебезгә дә зарурлыгын тоеп, тагын да дәртләнебрәк киттем, хисләрем, тойгыларым икебезнең дә җан күзәнәкләренә җайлы гына ага иде. Аның ябык кулын, нәп-нәзек бармакларын кайнар учыма алуымны сизми дә калганмын.

— Көтүгә чыксам чыгармын, маллар арасында тынычрак булыр,— диде ул, сабырланып,— ичмасам алар зарлана белмәсләр!

— Уртак кайгыдан качар урын юк,— дидем мин, һаман аңа сабырлык өстәргә омтылып.

Ул күтәрелде, мин аның нәзек, кызганыч муенын күреп әсәрендем. Рузилә торып басты һәм көндәгечә авыр, аяусыз сүзләрен әйтте:

— Бүген дә сезгә хат юк...

Китсә китсен иде, бу сүзләрне теле белән әйтмәсен иде! Ул тагын да авырайган буш сумкасын курач иңенә элеп урам буйлап бара, әллә үзе бара, әллә аяусыз җил аны күтәреп илтә. Җанга тынычлык эзләп, мин як-ягыма карандым, нидер эшләргә, әзгә булса да онытылырга, үземә дә сабырланырга кирәк иде. Торналар белән Рузилә җанымны утка ыргыткандай булдылар.

Сизәм, мондый халәт, тойгылар бәрелеше Арзудан башланды. Чүкү тавышы тагын яңгырады, бу тәмсез тавыш чигәләремне сулкылдатты. Кем, нәрсә эшли икән анда?

### 3

Имгәнгән тез капкачымны өф-өф итеп, учым белән кысып кайда утырам, дисез инде? Соры кыя очында утырам! Көлке, гарьлек, әйтергә оят! Нинди бетмәгән тавыш булды бу? Нәкъ безнең каршыда, куе сәрви куаклары арасында тимерче Йосыф абыйларның алты почмаклы, калай түбәле өе. Колагыма таракан булып кергән тавыш шулардан килә, тагын чакылдаттылар. Урамга чыгып

капка ярыкларыннан караган идем, исем-һушым таралды: йөз яшьлек Рәхимҗан бабай тимер чөй кыстырган да пеше карама түмәрләрен ярырга маташа! Бер китереп суга да артына чүмеп китә, чак егылмый, аннары баскан килеш кенә, башын бер якка кыйгайтып хәл ала, брезент бияләйләрен салып ташлап учларын төкерекли дә эһ итеп тагын берне ора, суккан саен хәле бетеп чайкала, гел сызыклардан торган маңгаен кул аркасы белән сыпыра да уфылдап ярылмаган бүкәне өстенә утыра.

Бетеренде быел Рәхимҗан бабай! Башка елларны печәнгә төшкән көннәрдә болынга иң әүвәл, кара таңнан, ул теркелдәп барып җитә торган иде, өстендә утыртма якалы ап-ак күлмәк, җиңелчә кара камзулы җилбәгәй, дөнья мәшәкатьләрен кочып кәкрәйгән нык аякларын ерып беренче эзгә ул төшә торган иде. Болынны яңгыратып моңлы тавыш белән дога укыган чаклары исемдә... Быел тәмамысы бетәште, аклан чирәменә сабантуйга төшә алмады, тешсез авызы белән кеткелдәп капка төпләрендә утырып, авылдашларын бәйрәмгә озата калды. «Хәере белән булсын, балалар... Ходаның ризалыгы бар, азагы матур булсын!» Бүген утын ярырга ук тотынган, гаҗәп. Кереп бу түмәрләрне уңлы-суллы яргалап ыргытасы булыр... Әллә хәзер үк керим микән? Ярамас, Нәфисә кат-кат ныгытты: «Өеңдәрәк утыр, тагын бер җайсызласаң, больницага салырга туры килер»,— диде. Ну бу Сирайны! Тешләк хайван! Арзуны бүлешергә килгән бит. Котырган эт... Шушы көннәрдә, тез күмәчемне саклап ятканда, мин әлләниләр уйлап бетердем... Нәфрәт сүзенең колагыма кергәне бар иде, сүзен беләм үзен, эчке мәгънәсен аңламыйм. Шушы буладыр, мөгаен, Сирай күз алдыма килде исә, каным уйный башлый, җаным котыра...

Рәхимҗан бабайлар капкасын киң итеп ачтым да нык ук кычкырып сәлам бирдем:

— Алла куәт бирсен, Рәхимҗан бабай, исәнлекме? — дидем.

Ул баш чайкап кына сәламемне алды, тынын тигезли алмыйча мышлый-мышлый озак кына миңа карап торды, терсәкләре ямаулы зәңгәр күлмәге манма су, ачык изүеннән гадәттән тыш аксыл тәне, очлы сөякләре күренеп тора. Кимерчәктән генә торган борын очында төссез тир тамчылары асылынган. Менә ул, күлмәк итәген кайтарып, борынын сеңгерде дә кулын селтәп бүкәнгә барып утырды, тонык картлык пәрдәсе ерткан күзләрен миңа текәде.

— Авыр эшкә тотынган син, Рәхимҗан бабай.

— Җегәр бетмәгән икән әле, дим... Кем атлы соң әле син... Кәлимулласы түгел, Искәндәре бит? Искәндәрме әле? Әйе шул. Йосыф абзаң барында өй арасында да эш калмый торган иде. «Кашык тотып түрдә утыра алсаң, без шунысына бик канәгать»,— дия торган ие абзаң, хәзер күрәсең менә, тотынмый ярамас! Хәтәр килә бит мимеч, усал халык! Ундүртенче елның хәлләрен хәтерлим әле мин...

Мин төрле яктан ботак сарган пеше карама түмәрләрен кузгаткалап карадым.

— Маташма интегеп, Рәхимҗан бабай! Берара үзем кереп ваклап чыгармын!

Шулай дисәм дә, карт башын чайкады, торып басты, бияләен салып ташлап учларына төкерде, төкереге чыкмады, авызы корыган икән, коры учларын бер-берсенә ышкыды да, бер дә ычкындырмас төсле, балта сабына тотынды.

Тәгәрмәчләре үзеннән биек велосипед сөйрәп киләтләреннән Рәхимҗан бабайның иң кече оныгы, Йосыф абыйның төпчеге Илдус чыкты. Утырырга тырышып карый, велосипед малайны ияртеп дыйк итеп җиргә барып төшә. «Булышыйммы?» дип карыйм тегеңәргә, малай нәкъ Рәхимҗан бабай төсле башын чайкый, кулларын төкереклэп тезенә сөртә дә рульгә ябыша, «үзем, үзем» ди... Йосыф абый да үзсүзле кеше иде, аңа фронтта аерата кыендыр дип уйлыйм. Ул арада Илдус, кәтүк танау, чатан-потан китеп бара, чебиләп беткән кара аякларын рам арасына тыккан да педальләрне әйләндерә, авызы колакта. Китте тәки. Үз турыбызга гына канәгать түгел иде. Югары очка, үргә каршы элдергән була...

Мин аның артыннан карап калдым да үз авылыбыз урамнарын читтән килгән кеше төсле күзәтә башладым. Озын бер урам булып Югары оч төшә-төшә дә урамнар чалбар балагы кебек икегә аерылалар. Безнең Аскы урам Кәҗә башы урамына борылып китә, икенче балак очында ун-унбиш өйле Имән урамы...

Урамга чыккач, күзем уңга-сулга йөгереп кемнедер эзләде дә зарыгып, моңсуланып ауган читән торыгына җиткәч туктап калды. Атна-ун көн элек, көзнең беренче дәһшәтле сулышы безнең юаш авылны эзләп тапты, дулый-дулый җил исте. Көчле җил авылны сыный, давылда кемнең-кем икәне ачык күренә, мунча түбәңне каерып ыргыткан икән, кемлегеңә ачык мисал. Капкаңны күгәненнән кубарып чөйгән икән, ашык-пошык, чилепешле эшеңне бөтен күзләр күрә! Торыгы-ние белән читән ауган икән, җитмәсә, торык шул гомердән җирдә аунап

ята, бу нигездә кем яшәгәнен белү читен түгел. Сез дә сизенгәнсездер инде, әйе әйе, солдатка Мәүлихалар йорты бу, ауган койма да аларныкы. Шуңа эчем пошып ишегалларына кердем, өйгә үк уздым.

— Өйдәләрме болар?

Өйдә җиһаз-фәлән бик аз, бер аягы тарттырып бау белән бәйләнгәнгә генә эләгеп торган буялмаган өстәл дә түр сәке озын, шыр ян сәке. Ике-өч игезәк урындык. Мич буенда тимерле зур сандык. Сандык өстендә, ачуым да бер килмәгәе, йөз мендәр бардыр, түшәмгә кадәр сыртлап өелгән. Мендәрләр өстендә ак бастырык булып олы песи сузылып ята. Стеналар, кече як бүлмә тактасы гына түгел, түшәм матчасы да, мич кучкары да гәзит-журналлардан кисеп алынган чуар, төсле рәсемнәр белән тулган. Почмаклардан тегелгән йорт паласы дип белерсең! Кәнфит, чәй кәгазьләре белән тышланган иске чиләкләрдә гөлләр. Бихисап күп гөлләр. Тамчы, яран, песи борчагы, тагын мин белмәгән гөлләр. Өйнең әз-мәз буш калган урыннарында кызлар. Кайсы кырын ятып сагыз чәйни, кайсы тәрәшле тарагы белән шытыр-шытыр чәч тарый, ике кыз тәрәзә яктысында баш карашалар, иң кечеләре мич каршысына утырып көлдән борчак чүпли. Иң түрдә, байтак өлгеләре такта белән кадакланган ике тәрәзә арасында, күгәргән калай төсенә кергән көзге.

— Өйдә без, өйдә.

Миңа җавапны Кәримә бирде. Ул мич арасыннан ниндидер чүпрәкләр тотып чыга иде, мине күргәч, кулындагыларны артына яшерде, оста бөгәрләп аларны сәке астына тондырды. Кәримәнең башы түшәмгә тияр-тимәс ышкылып тора, бу йортның аның буена үлчәп салынмаганы күренеп тора. Елмаюым ошамадымы, Кәримә тырнакларын чыгарды:

— Искәндәр, теге көнне, «Кәримәне көтүче итик!» дип башлап син кычкырдыңмы?

— Мин бер сүз дә дәшмәдем!

— Син, син! «Арзуны укытучы итегез!» дип Зөләйха апа катына син кергәнсең! Гомергә мине яратмадың...

Көз булса да, уттай эш өсте икәнен беләм, әллә энилләре басудамы дисәм, ул да өйдә икән, кече яктан килеп чыкты, күз кабаклары шешенгән, уң як битендә кыпкызыл тирән эз — мендәр җеге эзе. Чәчендә каз мамыгы. Ул, симез артын селкеп, Кәримәне кече якка куып кертте.

— Искәндәр икән, нинди ир-ат йөри дисәм... Ни җимертеп йөрисең, апаем? Тезең рәтләнәме? Төнлә сызлап интектермиме? Төзәлмәсә пешекләп бака яфрагы капла

син аңа, апаем. Фельдшер биргәнгә ышанып ятма. Нәфисә дә булдымы дуктыр? Дуктыр, дуктыр, эче тулы... Ата-анасы ике бозауга кибәк аера белми иде, бабасы шыр дивана булды, мәчет манарасына менеп үлде. Бик аңгыра бит ул Нәфисә, иеме, җиденчене өчле-тугызлы бетерде. Мәктәп директорына алты үрдәк, ике батман бал илткәннәрен беләм, мин белмәгәннәре ничәдер әле аның!.. Шулаймы? Инде килеп, яфрак каплагач та тезен урынына утырмаса, туп-туры Дөреш күрәзәсенә бар. Кулы бик шифалы. Өч дистә күкәй, ике йомарлам маеңны җәлләмәссең бит? Нәселегез саран инде саранын, кыш уртасында кар сорап ала алмассың... Кар дигәннән, сыерыгыз бик сөтле шул сезнең, авылда бер. Мүкләк булса да, җилене кисмәк диярсең... Бозавын ни сорадым, күрше хакы, дидем, ялвардым, бирмәдегез... Менә безнең генә, имчәге коргыры... И-и, сорамый да торам: атаңның хаты киләме? Акча салам димәгәнме? Тагын ни, Кәлимуллагыз Кәҗә башының алап авыз Кайнарлар кызына язамы? Сигәк, диләр бит аны, төннәрен урыны лычма була, ди менә...

Мендәр-тау өстеннән лып итеп песи сикереп төшмәсә, белмим, Мәүлиха апа кая барып җитәр иде икән?!

Сөйли Мәүлиха апа. Ялган икәнен белә торып, рәхәтләнеп сөйли. Тирә-юньдә ул белмәгән бер генә хәбәр дә булмый. Иртән тора да өй борынча биләмгә чыгып китә, йөргән аякка йөрем, телгә сөрем иярә, диләр...

Ул сөйли тора, мин аның туктаусыз хәрәкәтләнгән авызына, селкенеп-селкенеп киткән колагына карап торам. Әллә юмаганга, әллә табигый шулай, колак эче капкараңгы икән аның, әрләнә тишеге сыман бөтерелеп тирәнгә кереп киткән. Ишеткән гайбәтләрен колак тишегенә тутырып йөриме әллә бу апа, дигән сәер уй күңелемә килде. Борыны итекче безе кебек очлы, теләсә кайсы тишеккә сыярлык, күзләре ярма бөртеге кебек түгәрәк, тере, икесе ике якка тәгәрәп тора, ямьсез дә түгел үзе, җиде бала тапса да гәүдәсе ыспай, тигез.

Нәфисәдән үлеп көнләшә Мәүлиха апа! Аның олы кызы да Нәфисә белән бергә медицина мәктәбенә укырга Минзәләгә барган иде, йомшак җирен чуан басып укуын ташлап кайтты. Кызлары да әниләре төсле ялкаулар, берсенең дә эшкә, укырга дәрте булмады...

— Ауган читәнегезне ташып бетерәләр бит,— дидем мин, ян сәкегә утырып. Песи минем янга сикереп менде, иркәләнеп алдыма сузылып ятты. — Көтү каршыларга төшкән Югары оч малайлары суырып алып киткәлиләр.

— Бетермәсләр,— диде Кәримә, исе китмичә генә.

— Әйдәгез, торгызып куйыйк.

Мәүлиха апа кызларына карады. Олы кызы:

— Әнә, Дилбәр күтәрешсен,— диде.

Тыңкыш Дилбәр чәчрәп күтәрелде, киезләнгән чәчен сынык тешле сөяк тарак белән купертә-купертә:

— Нишләп мин йөрим? — дип бик гаҗәпләнде.— Әнә Тәслия тик ята, эше юк.

Тәслия үксергә үк тотынды:

— Сабан туенда ефәк күлмәкне кемгә алдылар? Кәримәгәме? Чыксын да күтәрешсен!

— Җылак, җылак, җылкы колак! — дип үртәште Кәримә.

— Ә син авыр аяк.

— Син апара корсак!

— Ә син тыңкыш танау!

— Ә син буаз сыер күк мышлыйсың.

Дилбәр тарагын атып бәрде, идәнгә тибә-тибә чырылдады, минем алда иркәләнеп яткан песи шым гына мич арасына кереп йомылды.

— Әни-и-и, бу кумагың үртәшә!

— Җитәрегез, фу! Туктыйсызмы, юкмы? — дип яман кычкырып җибәрде Мәүлиха апа.— Егет кеше алдында оялыр идегез, ичмасам, азрак.

— Егет? Кайда ул егет кеше? — дип, борын җыерды-лар кызлар. Шулай да тиз-тиз мине чолгап алдылар.— Әтәч, Искәндәр генә ич бу! Нинди егет булсын!

Мин кычкырып көлүдән чак тыелып утырам, Мәүлиха апа алъяпкычын салып ыргытып ишеккә юнәлде.

— Тәмам адәм актыгына калганчы, әйдәгез!

Кәримә дә безгә иярде, өчәүләшеп маташа торгач, торыкны торгызып урынына бастырдык.

— Баганасы төптән чергән икән,— дидем мин.— Алыштырырга кирәк.

Алар тотып торды, мин бүселгән чыбыкларны кыстыргалаштырдым.

— Үзе кайтканчы чыдар әле, Мәүлиха апа. Ишегалларыннан чатлы таяк табып чыгып торыкны терәттем, исән баганага мунчала белән тарттырып бәйләдем, тиргә баттым.

Эш бетеп калды, Мәүлиха апа да таптанып минем янда тора, күрәм, Кәриманең дә миңа нидер әйтәсе килә, сорыйсы сүзе бармы, читән күтәрешергә дә шул сәбәпле генә чыккан бугай, куе аксыл керфекләрен уйнатып миңа күз кыса, ым сала. Мәүлиха апа, ай-ваена карамыйча, аны этеп-төртеп кертеп җибәрде, үзе шундук сорашырга керешге:

— Ничегрәк соң, апаем? Арзу апагыз дәрескә кердеме инде? Ишетмәдеңме, күпмерәк зарплата куйдылар икән? Паек та чыгачакмы аңа? Тагын укытучы кирәкмиме мәктәпкә? — Бу урында ул сүрән генә өй ягына карап алды. Без читән белән мавыкканда, тынып торган өй эчендә әллә нинди ямьсез тавышлар яңгырый башлаган иде инде.— Менә кызларым әрәм булып ята... Кәримәне генә алыйк, укыганда беренчеләрдән үк булмаса да, төшеп калган баламы ул? Төсе-бите дисеңме, уңганлыгы, холкы-фигыле... фәрештә дә фәрештә, бу аны да уздырып җибәрә. Тач үзем инде менә! Ул тырышлыгы... Сөлге чиккән әле, берәр җае чыккач, күрсәтермен. Искитмәле! Сабан туе батырына тот та бир!

Ул тагын ялт кына өй тәрәзәсенә карап алды да, мине култыклап, читкәрәк алып китте, теле һаман тукталмады:

— Гәҗитен укый, китабын. Юньле эш табылмады бит шул багалмага! Ун класс укыган башы белән калхуз эшендә йөртәсем килми. Бер кара эшкә башың чумса, беттең инде, очсызланасың. Теге Хәнәфи укытучыны сугышка алмыйлармы әле? Безнең ирләр анда чиләкләп кан койганда оялмыйча коммунист башы белән брун артына качып ничек ята диген син аны?! Сәвит влачы шуның өчен укытканмы аны? Шуның өчен акчасын, паюгын биреп торамы? Утыны бушлай, керәчине бушлай... И-и... Кәримәне урнаштырасы иде бит!.. Башкаларына түзәр дә идем...

Кәримә укыганда ук Арзудан үлеп көнләшә иде. Арзу яңа күлмәк кимәсен инде, Кәримә, үкчәсе белән идәнне төя-төя акырып жылап, бөтен Аскы урамны, Түбән очны кузгата. Тәки күлмәкне таптыра... Арзу чәчен икегә үреп салса, Кәримә дә үзенең тәрәшлесен икегә аерып тарый... Арзу тамбур белән чиккән алъяпкыч бәйләде исә, Кәримә дә кигәвен чорындагы симез тана күк безләп йөри башлый, тәки таба, тәки сатып алдыра... Икенче көнне карыйсың, аның билендә дә алъяпкыч... Алъяпкычта тамбур белән чиккән гөлҗимешләр...

Моңарчы алар гел шулай каулашып килделәр. Кәримәнең көнчелеген Арзу белми түгел, белә, белеп үчекләшкән чаклары да булгалагандыр, андый вакытларда аналы-кызлы алар шартларга җитешәләр иде.

Унынчыны бергә тутырдылар... Хәзер Арзу мәктәптә, укытучы! Әйткәнемчә, укытучы авылда иң абруйлы, иң зур хөрмәткә лаеклы кеше. Ә Кәримә аттестатын кочаклап өйдә утыра. Шуңа күрә алар бөтен өй эчләре белән Арзуны дошман күрәләр, моны яшереп тә тормыйлар...

— Йә, кайсы төшенә кызыгалар икән шул күкәйче токымының?! Немец телен беләме ул? Белде ди пычагым, татарчасын юньләп сөйләшә алмаганны... Аның ни әвтәритеты бар? Әнкәсе бер юньсез иде, атасы алабай эчепкөеп үлде... Бабасы дисәң, шыр тиле, быржин... Авылыбызда юньлерәк, күз төшәрлек кыз балалар беткән идеме? Менә мин үзем күз өстендә каш идем, ничә еллар райун эктиве булып тордым, иң кәттә начальниклар кул биреп күрешәләр иде.

Карап торам: үзенә дигәндә Мәүлиханың кермәгән тишеге, чыгалмаган ишеге юк. Ире Биктимернең «Батырлык өчен» медале белән бүләкләнү хәбәре килгәч, кайларга гына барып йөрмәде ул! «Шул медаль дигәннәренә күпмерәк жалуния чыгар икән?» дип, борчак эскертләгән җиргә, директор янына ике рәт килеп китте...

Туктар димә, Мәүлиха апа тагын Кәримәсен үтереп мактарга тотынды, кемнәрнедер эт итте, мин көләргә дә, ни әйтергә дә белмичә, башны исәргә салып туры өйгә юнәлдем. Әни кай арада эштән кайтып өлгергәндер, читән күтәрешеп йөргәнне күргән икән, коры гына:

— Түбән очка терәү терәргә тотындыңмы? — дип куйды.— Тазаргансың икән. Алай көчең ташып торгач бар, коедан су алып кер. Арып кайттым, җеп өзәргә хәлем юк. Өйдә тамчы су калмаган, тавыклар табагы мич төбе төсле кипкән... Бу күлмәгеңә каян дегет тидердең әле? И-и, бала, бала. Салып бир! Аны да юып куярмын... Ничә чуман бәрәңге генә бушатканбыздыр бүген, корыда эш итик дип азапланган көн, алар, бер әтрәт айгыр күк кызлар, өйдә бурсып яталар!..

Су беткәнгә ачуланмый әни, Мәүлиха апаларга кергәнне өнәмәгән. Кәлимулла абыйны Мәүлиха кызлары янында күрсә, дерт итеп китә торган иде, йомыш табып, шундук чакырып алыр иде...

Соңгы бер атнада ике кеше авызыннан Арзуның исемен ишеттем... Сирай да, Мәүлиха апа да аның исемен кат-кат талкыдылар... Әллә инде Мәүлиха апа да берәр нәрсә сизенәме?..

Сыңар чиләкне тоттым да урамга чыгып киттем.

## 4

Чыксам, җиде-сигез малай күршеләр каршында кәшәкәле уйнарга җыенып яталар. Кәшәкәле — шаулы уен, тавышлы-гауталы уен, шуңа күрә усал, телчән апалар яши торган йорт тирәләренә кәшәкә тотып килә алмыйсың, уен өчен басынкырак кешеләрнең өй турын сай-

лап алалар. Мәүлиха апалар капка төбенә барып уйнап кара син, кәшәкәңне тартып алып сырт буйлап берне сылар! Арзуларны да юаш дип булмый, мәгәр алар бабасы белән икәү генә яшиләр, көндезләрен өйләре буш диярлек, шуңа күрә малайлар алар турында җыйнала.

Сентябрьнең коры, мәшәкатьле көннәре тезелеп китте, һәркемнең бәрәңге аласы бар, кышка утын ташып, аны кисеп-ярып, өеп мазалананалар, малайларның уенга чыгуын сәер иттем. Үзебезнең Түбән оч малайлары быел беренче тапкыр кәшәкәле уйнарга чыкканнар...

Кое чыгырын акрын гына әйләндерәм, күзем малайларда, чылбырны тотып чиләгемне батырыйм дигән идем, чылбырым җиңеләеп китмәсенме?! Чиләкне юньләп бәйләмәгәнмен икән, төен чишелде, чиләк быгыр-быгыр суга батты... Каушап калдым, кое шактый тирән, бурасы тар, бура агачлары черек-чарык, төшкән чиләкне алу бик читен. Су төбендә чиләк калдырыр идең, әнидән яхшы түгел...

Шундый чакта ачу китереп малайлар кычкыралар:

— Искәндәр, кил!

— Сиңа чокыр калдырдык.

— Суыңны керт тә йөгер!

— Куегыз әле,— дип, кул гына селтәдем дә, кабаланып, ишегалдыбызга кердем, өй түбәсенә сөялгән багорны алыйм сиздермичә генә дисәм, өйдән әни килеп чыкты.

— Мыштырдыйсың икән, хөрәсән ялкавы,— диде ул, ачуланмыйча гына.— Кер уарга су кирәк, казаным буш, ятьрәк йөр, тик аягыңа зыян ясый күрмә!

— Хәзер, әни, хәзер,— дип мыгырдандым.

Әни артыннан ишек ябылуга, багорны эләктердем дә, титаклый-титаклый, кое янына чаптым. Тез капкачым онытылды, ашыгам! Ә малайлар уенга керештеләр, мине оныттылар, кычкыралар, сызгыралар, кыза уен!

Кояшта торып яргаланган, каралган багор сабын ныгытып чылбырга бәйләдем, ышанычлы булсын өчен чалбар каешы белән дә беркеттем, хәзер ычкынмас! Ипләп кенә аска төшердем дә салмак кына уңга-сулга йөртә башладым. Ташка бәреләме, чиләккәме, белгән юк, чакылдаган тавышлар чыга, чиләк бавы гына килеп эләкми, тирләдем, ачы тир күз кабакларын ачыттыра, ачуны китерә.

Кинәт күршеләрнең капкасы ачылды, сыңар чиләген тотып Арзу чыкты. Өстендә озын итәкле ак күлмәк, күлмәк өстеннән кигән йон кофтасын ычкындырып җибәргән, яланбаш. Кәшәкә уйнаучы малайлар янына

туктап нидер сорады, мин аны күрмәмешкә салышып, һаман кое суын бутыйм... Аяк адымнары акрын гына якынлаштылар, килеп җитте дә:

— Әллә чиләген төшергән инде? — дип куйды.

— Төште шул,— дидем, комач кебек янып. Оятымнан җир тишегенә кереп китәрдәй булдым.

— Икенче кеше чиләк төшерә инде бүген,— диде ул, ягымлы, йомшак тавыш белән.

— Кайсы җебегән кулы тагын?

— Мәүлиха апа! — диде дә Арзу, пырхылдап алды. Мәүлиха апа белән минем исемне янәшә куюлары бер дә минем файдага түгел иде, мин, маңгаема төшеп сыланган юеш чәчләрне кулым белән артка тарап, аларның өйләренә күз салдым. Урам як тәрәзәләргә кызлар сырышкан иде — безне күзәтәләр!

— Чиләкләрен алдылармы соң?

— Кемнәр?

— Мәүлиха апалар.

Арзу «Мәүлиха апаларны белмисеңме әллә син?» дигән сыман, күңелле генә көлеп куйды.

Минем каушаудан берни майтара алмаганны, кирәгеннән артык каударланганны күреп, ул кулымнан чылбырны тартып алды да, мине читкәрәк этәреп кое авызына башын тыкты. Иңенә үреп салган ике калын толымы да коега таба шуышып төште. Коедан дым исе, черек исе килә, суы бик еракта сыман тонык кына елтырый иде.

— Күрәсеңме? — диде ул, иңе белән миңа кагылып.

— Чиләкнеме? Күрмим.

— Юк ла, иң аста кое чистарткanda басып торыр өчен таш мөнбәр калдырганнар. Минем бабам эше булыр анысы. Коены синең бабаң Җиһангир белән бергә казыганнар алар.

— Минем бабайга да өлеш чыгарганың өчен рәхмәт.

— Усалланма,— диде ул калкынып, толымнарын ипләп кенә ике якка спайлап салып куйды. Матур кыз түгел Арзу, әмма гаҗәп сөйкемле. Башкалар да шулай диләр, хәтта минем әни дә. (Егет кешеләрнең әниләре, гадәттә, күрше-тирә кызларының гаеп-кыекларын күбрәк табучан була!) Гаять ипле кыз, бер чакта да юкка-барга тавыш күтәрмәс, усалланмас, башка кешеләргә четердәп ябыша торган Мәүлиха апага тиклем аның янында тыелып кала. Ата казлар таламый аны, эт тә куа чыкмый, кәҗә тәкәсе дә сөзми, бөтен авылның котын алып торучы, колхозның таудай дәү үгезе «Мирон» да Арзу очраганда сөрлегеп җир казырга тотынмый, түбәнчелек белән генә

баш иеп узып китә. Кәҗә башы урамының әпчи карчык Миңлебикә: «Хәбибрахман быржин токымы юньле булмас, сихерчедер, хайван телен сихерчеләр генә белә»,— дигән, имеш...

Ул буйга миннән шактый кечкенә, шулай да көчле, багорны кое эчендә шулап ипле йөртә, кызыгып карап торырсың! Иелеп маташа торгач, күлмәк якасының сәдәфе чишелеп китте, мин Арзуның йоп-йомры теп-тере күкрәкләрен күреп телсез калдым...

— Сине сихерче диләр бит, Арзу,— дидем тотлыгып.— Әфсенеңне укы да чиләкне ал!

— Кем сихерче ди?

Ул, чылбырны кулыннан ычкындырмыйча гына миңа карап торды.

— Кем дип, сүз иясе белән йөрми.

— Ә син иясез йөргән сүзләргә бик ышанма!

Үпкәләмәс дигән идем, әллә ачуын китердем инде?..

— Әйе,— диде ул,— бераз ачу да килә! Сугыш башланган көннән күрәзәләр, багучылар, әпчи карчыклар, ногыт борчаклары күбәеп китте. Сугыш башланасын да белгәннәр, төшләрендә күргәннәр, тегесен юрыйлар, монысын лыбырдыйлар... Курыкма, чиләгеңне сихерсез дә алабыз. Кызуы үтеп тә китте, ул тагын көлеп куйды. Борылып карасам, Мәүлиха апа кызлары тагын тәрәзәгә өелгәннәр, тасыраешып безне күзәтәләр.

— Бир әле үземә! — дидем мин, чылбырны тартып.

— Бирмим.

— Нигә?

— Сиңа ярамый. Тезеңне кузгатырсың... Эләкми бит! Болай итик, Искәндәр. Хәзер мин тазарак бер бау алып чыгам да коега төшәм!

Сүзен сүз итә торган гадәте бар инде Арзуның!

Мин ык-мык торган арада, ул, җил-җил атлап, капкаларыннан кереп китте. Әлбәттә, кәшәкә сугучы малайларның берәрсенә кушсам, сөенә-сөенә коега төшеп менә иде, әмма мин кое янында икәүдән-икәү генә шулай озак юануыбызга чамасыз шат идем, арага берәүне дә кертәсем килмәде. Кулымнан килсә, Мәүлиха апаларның өч тәрәзәләрен тиң томалап куяр идем!

Хәзер менә Арзу килеп чыгачак! Әнә!.. Мин шатлыгымны яшереп тора алмадым, көлеп җибәрдем...

Арзу алып чыккан бавының ныклыгын сынаган төсле, тартып-тартып карады да миңа тоттырды:

— Бәйлә... Чиләк янына мине төшереп җибәрә күрмә!

— Үзем төшимме әллә, Арзу?

— Сине кое чыгыры чыдатмас.

— Ә сине?

— Җиңел ич мин. Ышанмасаң, күтәреп кара!

Ул үзе дә уңайсызланды. «Сиңа ярамый, тезең авырта»,— дип кабатлады, тагын көлде. Тешләре ап-ак чынаяк кебек, иреннәре сусыл чия төсле алсу. Бер-берсеннән чак кына ераграк утырган ягымлы чем-кара күзләре дөньяга ышанып һәм ышандырып карыйлар... Аның матурлыгы күзләрендә иде бугай...

Малайлар кое янында безнең озак маташуны мәзәк иттеләр, өрәңге тубырыннан ясаган шараны юри безнең яккарак тәгәрәтәләр, ачуым килеп, шараны тибеп җибәрим дигән идем, тезем чәнчеште, ыңгырашуымны сизми дә калдым. Арзу:

— Менә, Искәндәр, кая ди сиңа төшү! — диде.

Дилбегәне чылбыр янына чыгырга ныгытып бәйләдем дә очын Арзуга тоттырдым, ул, кое бурасына сырышып үскән җылан кабыгына охшаган саргылт мүк кисәкләрен коя-коя, түбәнгә төшеп китте. Аның баш түбәсе кое авызында күмелүгә, безнең янга четердәп кычкырып Мәүлиха апа килеп җитте:

— Бетердең Арзуны! — диде ул, кулларын бутап.— Башын бетердең баланың! Әй, җебегән арыш салмасы! Иске кое бит ул, бурасы черек! Чыгыры да какшау, көчхәл белән сыңар чиләк суны чыдата иде. Ә монда кеше тиклем кешене... Әй, җебегән!..

Ни әйтим, эндәшмәдем, шулай яхшырак иде. Сүз белән мине җиңә алмаслыгын күреп, Мәүлиха апа курка-курка гына кое авызына иелде, Арзуга кычкырды:

— Бетәсең бит, бала! Үпкәңә суык тигерәсең! И-и, тилекәй!

— Тимәс,— диде Арзу, аста су чопырдатып.— Суык тисә, Дөреш күрәзәсенә барырмын! Ишетәсеңме мине-е, Мәүлиха апау, Дөреш күрәзәсенә, дим!.. Шушы араларда гына син дә барып кайттың түгелме соң?

Мәүлиха апа кинәт турайды, түшен киереп, ачуыннан калтыранып китте, төкеренде, төкереген чабата башы белән баса-баса карганды:

— Менә бит, ниләр генә уйлап чыгармыйлар? Ничек телләре корышып катмый диген? Дөрешкә бараммы мин? Миңа ни җитмәгән? Кияүгә чыгасым бармы? Өй тулы балам... Менә син агай, ә?! Районга бардым ич мин, районга!.. Кайсы тинтәге Дөреш дигән әле?

Ул күз агы белән тагын бер кат кое авызына карап алды да, тагын гаярьләнеп, түшен киерде, кояшта уңган француз яулыгын рәтләде һәм, мыдыр-мыдыр укынып, абына-сөртенә китеп барды. Бер-ике минуттан аның ачы,

зәһәр тавышы ишегалдыннан ишетелде. Ул ярсый-ярсый кызларына кычкыра, аларны өйгә куа иде:

— Нәрсә акайдыгыз? Аю биетәләрме әллә? Өйгә керегез! Җыенысгыз адәм актыгы, бәягез бер кием чабатага да тормый, барыгыз!

— У-у, суык! Су анасы ничек түзә икән монда? — диде Арзу астан.

— Йолдызлар күренәме? — дидем мин, аның күңелен күтәрергә теләп. Үзем эчтән генә: «Салкын тимәсә ярар иде»,— дип бик хафаландым.

— Бик күренми әле,— диде Арзу, көлеп. Аста тагын су чопырдады.— Караңгылама! Салкын мәгәр! Суы саеккан моның, төбе лай гына, тазартасы бар. Әйтәм җирле бик тиз болгана.

Ул аркасын бурага терәп бая үзе күрсәткән мөнбәргә — чыгып торган олы ташка баскан иде.

— Мәтәлеп китә күрмә.

— Егылмам,— дип гүләде кое, ят тавыш белән.— Таптым берсен. Таптым.

— Бәйлә!

Ул дилбегәне какты, мин чиләкне тартып чыгардым. Мәүлиха апаларныкы икән, өр-яңа чиләк. Багор йөртә-йөртә корсагына тирән генә ике эз дә сызылган. Тамга салгансыз дип дулар инде. Дилбегәне төшердем дә, караңгыламыйм дип, читтәрәк басып торам, ә малайлар уйнапмы-уйныйлар, шаралары төрле якка тәгәри генә! Нигә тынды әле бу Арзу?

— Югалдың син анда,— дидем мин, кое өстенә түшем белән ятып.

— Хәзер, хәзер... Менә... Таптым табуын!.. Монда тагын әллә нәрсә ияреп чыкты әле, багурга, дим... Күтәр, Искәндәр!

Чыгырны сыңар кул белән генә әйләндерә башлаган идем, авыр. Ике куллап ябыштым, барыбер авыр.

— Су анасын тотып бәйләдең, ахры, син, кызый. Майламаган чыгыр шыгырдый, чыгыр баганалары дер-дер киләләр, күңелемдә шатлык катыш ниндидер хафа бар. «Салкын тимәсә генә ярар иде сиңа, Арзу!» Кое авызында Арзуның башы күренгәч исем китте, мин төшергән чиләккә ияреп үзе дә менгән икән! Менә ул чиләкне җиргә ташлады да ике якка терсәкләрен терәде, калкынды һәм җитез генә җиргә сикереп төште, чайкалды, мин аның кулын тотып алдым.

— Боз булгансың, Арзу!

Аның күлмәк итәгеннән сары су тама, кул аркалары лай гына, яңакларына, чәч толымнарына чүп-чар кун-

ган. Ул иелеп күлмәген сыкты, суыксып дерелдәп китте:

— Өшетте!

— Йөгер өегезгә, кайнар чәй йот!

Мәүлиха апаларның чиләген кертеп бирим дип иелсәм, безнең чиләк янында яткан, яшь бозау чәйнәкләгән тастымал төсле җебегән зур гына чүпрәкне күреп алдым.

— Нигә алып менден бу шакшыны? — дип сорадым.

— Коеда ятсынмыни? — диде Арзу, сыккач бөгәрләнгән итәк очларын сыпыргалап.

Мин чатанлый-чатанлый Мәүлиха апаларның чиләген илтеп бирдем, борылып килсәм, Арзу кыска таяк белән баягы чүпрәкне актарып маташа иде. Тукта, тукта, чүпрәк дигәнем хатын-кыз күлмәге булып чыкты түгелме соң? Әйе, әйе, әнә бер җиңе, икенчесе, хатын-кызныкы һәм миңа шактый таныш күлмәк ич бу! Арзу күлмәге! Шуныкы! Директор Зөләйха апа белән район мәгариф бүлегеннән кайтканда аның өстендә хәзер ком төсенә кергән, ул чагында яшел бизәкле ак батист күлмәк иде бит! Шул баруыннан укытучы булып кайтты, шул күлмәкне киеп кич буе капка төпләрендә утырды, үз язмышыннан канәгать икәнлеген сиздереп, Аскы урамны тутырып көлде... Егетләр җыелган иде, мин дә чыктым... Тегермәнче Хәбиб малае Сирай өч тапкыр аны биергә чакырды... «Нигә төшкән әле бу мүкләк безнең урамга?» — дип, шул чагында уйладым бит... Кәримә дә бар иде... Әйе, әйе, бар иде, дәшми-тынмый гына утырды бугай...

Кем ташлаган аның күлмәген коега? Нигә?.. Үзе дисәң... Чиләк өчен түгел, күлмәгенең шундалыгын белеп төштеме әллә?..

Күңелемнән берсеннән-берсе шөбһәле йөз уй йөгереп узса да, анык кына бер нәтиҗәгә килә алмадым, аптырап, миннән дә ныграк аптыраган Арзу янына иелдем. Аның ике күз читеннән ике яңагына ике эз сызылган, ул бу мизгелдә күпне күргән, күпне кичергән олы кешегә охшап калган иде. Менә ул кулындагы таяк белән күлмәкнең күкрәк турын чишеп җибәрде, куркудан чак чалкан әйләнеп барып төшмәдем: төен эченнән җылан кабыгы, бака боты, әллә нинди укмашып каткан чәчләр, киселгән эре-эре сары тырнаклар, кызылга буялган әкәмтөкәм кабыклары килеп чыкты. Арзу ап-ак булды, мин дә курыктым.

— Синең күлмәк түгелме соң бу? — дидем бераздан.

— Минем күлмәк. Минеке,— диде ул.— Минеке. Юып элгән җирдән югалган иде. Яңгыр көнне Зәйгә

барып чыланып кайттым да юып элдем. Кичтән элдем, иртәнгә юк. Эзләмәгән җирем калмады, җил очырып алып киткәндер дип уйладым, эт-кош ертып бетергәндер дип тә карадым... Атна узды... Баксаң, ул мине кое төбендә көтеп ята икән.

— Кем явызлыгы булыр соң бу?

— Хат язып, имзасын калдырмаган,— диде Арзу, тураеп.

— Берәрсе белән сүзгә килдеңме әллә, Арзу? Җылан кабыгы, чәчләр... Бу бит... сихер... бозым! Сине бозарга ниятләгәннәр!

Арзу башта: «Юкны сөйләмәсәнә!» — дигән иде, үзе дә минем белән килеште:

— Шулайдыр, мөгаен... Бозымдыр... Өр-яңа күлмәгемне әрәм иткәннәр.

Малайлар уенның кирәген бирәләр генә, өзәләр! Шатлар, ваемсызлар, аларга берни дә юк кебек, сугыш та, колхозның алынмаган ярты басу бәрәңгесе дә... Нәкъ тыныч замандагы кебек шаулашалар!.. Миңа ни өчендер менә бу әшәкелек тә сугыш казасыдыр кебек тоела, әгәр сугыш булмаса, мондый күңелсезлек булмас иде дип уйлыйм...

Әни көтәдер, беләм, тик минем ачыргаланып басып торган Арзуны һич тә ялгыз калдырасым килми...

— Сөйдергеч ясатканмы әллә берәрсе? — дигән тинтәк сорау телемнән ычкынганын сизми дә калдым.

— Әкәм-төкәм кабыгын коега салып кыз яраттыралармыни? — диде ул, кискен генә. Беләм, миңа ачуланмаганын беләм, әмма бик нык кәефем кырылды. Тел төбемне Арзу аңлагандыр дип уйладым.

— Искәндәр,— диде ул, баягыдан да кискенрәк итеп,— кое авызын ябарга кирәк, хәзер үк кадакла син аны. Берәү дә су ала күрмәсен.

— Ярамасмы?

— Күрәсең ич! Анда тагын башка әйберләр дә булып, чир-чор таралса?

— Кое суын эчкән кеше юк, Арзу, йорт кирәк-ярагына гына алалар.

— Барыбер ярамас! Әллә ни булуы бар. Сугыш заманы диләр аны... Агуланган коелар, елгалар турында ишетмисеңмени?

— Күлмәкне нишләтергә?

— Бер аулакка илт тә күм. Бу турыда әлегә берәүгә ычкындырасы булма. Сүз таралыр. Сине-мине виноват ясарлар. Бел... Җае белән үзем бер очына чыгармын. Чыкмый калмам. Табармын...

Ул үтенгәнчә күлмәкне чишмә тыкрыгының иң аргы башына, куе кычытканлыкка тирән генә чокыр казып күмдем. Үзем күмәм, үземнең күңелгә: «Юк, болай гына кала торган эш түгел бу... моның белән генә бетмәс әле»,— дигән шикле уйлар килә...

Әнигә суны бик соң гына алып кайтып бирдем. Кич җитте.

— Тагын азрак эт куасың калган,— диде ул, рәнҗеп.

— Чиләк төшердем. Шуны алып маташтык.

— Авызың белән кош тотып йөрсәң, төшми ни, төшәр! Мәүлиханыкын алдыгызмы?

— Алдык.

— Анысы йөри тилереп, тавык мие эчкән нәрсә!

Әнидән бозымнар, сихерләр турында, Мәүлиха апаның ни өчен тилереп йөрүе хакында сорашасым килде, кыймадым. Безнең әни артык күп төпченгәнне яратмый: «Башың яшь, үскәч белерсең»,— дип кистереп кенә куя...

Күз бәйләнеп килгәндә лапастан калын-калын такта башлары алып чыктым да эре эшләпәле озын кадаклар белән кое өстен кадаклап куйдым. Эшем беткәч, кое өстенә менеп утырып буталчык, ят уйларга чумдым.

Арзулар тәрәзәсендә сыек кына яктылык шәйләнә, үзе бәләкәй якта, ахры, күренми...

## 5

Утыра-утыра яныма классташым Рәфгать килеп җиткәнен дә сизми калганмын, кинәт эндәшкәнгә, сискәнеп киттем.

— Нихәл? — диде ул, авызын ерып.— Иң матур чигелгән сөлгегә лаек көрәшчегә сәлам! Төзәләме аяк?

— Яхшыра сыман, ныгый,— дидем һәм ышанычлырак булсын өчен, утырган җиремнән аягымны селкедем.

— Болай булгач яхшы,— диде ул һәм минем янга утырды.

Тез капкачым кузгалуга иң нык борчылган кеше шушы Рәфгать булды, үзенә күрә моның җитди генә сәбәбе дә бар иде.

Рәфгатьнең этисе байтак еллардан мәктәптә ат караучы булып эшләгәнгә, алар мәктәп ихатасында ук торалар. Мәктәпнең атлар сарае белән Рәфгатьләр мунчасы арасындагы бушлык — безнең малай чактагы төп уен урыны булды. Әле бик бәләкәйдә тәтәйле уйнадык без анда, кузналы да, сугышлы да, үсә төшкәч «күниләк!» дип шаулыйшаулый бакыр акча чөйдек, өй почмагыннан мүк йолкып алып беренче тапкыр тәмәкене дә шунда тарттык. Тәмәке

өчен сыек тал чыбыгы да татыдык... Күпне күрде башлар!

Рәфгать белән мин — үзебезне белә-белгәннән бирле дуслар. Аның белән уйнау да, зәңгәр күккә карап чирәмдә тик яту да рәхәт. Уенда хәрәмләшмәс, җиңелсә — көлеп кенә үткәрер... Барыннан да бигрәк ул дөньяны шактый күргән егет. Аның бертуган абыйсы (әниләре генә башка) Бөгелмәдә автоинспекциядә эшли иде. Авылда машиналар санаулы гына булганга, без ул серле «автоинспекциянең ни икәнен бик үк күз алдына китереп бетерми идек, мәгәр Рәфгатьнең абыйсы — имән кискә кебек таза, кара мыеклы көләч кеше елына бер тапкыр бишекле мотоциклга утырып, шатыр-потыр Югары авылга кайтып кергәч, басу капкасы төбенә җыелган малайларга карандаш-карандаш пыяла кәнфитләр дә өләшкәч, ул абый безгә дөньядагы иң бай, иң кодрәтле һәм иң бәхетле кеше булып тоела иде. Рәфгать үзе дә ел саен аларга кунакка бара, бара да атна-ун көн торып кайта. Бишенчене тәмамлагач, олы малай сыйфатында, ул аларда озаграк торды һәм Бөгелмәдән бик шәпләп русча сүгенергә өйрәнеп кайтты. Тиз отып алдык, аты-юлы белән бәрәбез генә! Җитмәсә, сул кулының дүрт бармагына берәр хәрефтән зур итеп, «Рафа» дип тә яздырган. Бөгелмәдәге урыс малайлары аны Рафа дип йөртәләр, имеш... Авылда кушаматсыз малай-шалай буламы, Рәфгатькә «Рафа-җәфа» кушаматы тигәнәк кебек ябышты... Күзен ачырмыйлар иде малайның... Тик артык исе китми иде аның... Урыс малайларыннан калышмыйк дип, без дә иске кәвеш корымыннан тушь ясап, өч нечкә инәне бергә бәйләп, мунчада сукыр лампа яктысында сул кулларыбызга якорь, урак-чүкеч, тагын әллә ниләр кадатып бетердек. Рәфгать кадый торды, без «эш хакы» итеп әниләр күрмәгәндә аңа бер-ике күкәй чәлдереп алып килдек.

Күкәй өчен дә, якорьләр өчен дә нык кына эләкте безгә! Малайлар арасындагы хәл олылар арасында фаш булмый каламы, барысы беленде! Кулын тыймаган өчен этисе Рәфгатьне суык мунчага алып кергән дә сырты тирләгәнче солдат каешы белән нык кына каезлаган. «Мунча ташында йолдызлар күренде, малай»,— дип сөйләгәне хәтеремдә...

Алтынчы-җиденчедә без мылтык, хәнҗәр, дарылар белән мавыга башладык, зәңгәр якорьләр, кыяр бакчасына төнге сәфәрләр онытылды... Рәфгать — чос егет, каяндыр бер дистәгә якын вак калибрлы винтовка патроны кулга төшергән. «Абый алып кайткан, онытылып яткан» дигән булды булуын, аңа кайчагында ышанып бетеп тә

булмый, тиешле-тиешсез яткан әйбер-караларны оста гына «җыештырып» уза торган гадәте дә бар аның. Ярый, ни булса, шул булды, без ун патронга хуҗа идек! Авыл малае өчен бу чамасыз зур байлык иде!

Мин: «Укытучыдан мылтык сорап торыйк та каргага атыйк»,— дип кыстыйм. Рәфгать: «Карганы рогатка белән дә атып була, әйдә наган ясыйк»,— дип үгетли, һәм без наган ясап карарга булдык. Кул астындагы иң җайлы материал агач булганга, тоттык та беренче наганны агачтан ясадык. Тоткасы да бар, көпшәсе дә, бары агачтан, резин белән худланган ударнигы гына тимер, ә күрер күзгә чын наганнан бер дә ким түгел. Без аны карага буяп җибәрдек... Патронны агач оясына кертеп ипләдек тә су буена төштек, яшелчә бакчасы киртәсенә кунып, «Кар! Кар!» дип бакырып утыручы ач күз каргага атып та җибәрдек... Черт итте, шарт итмәде. «Бәхете карганың, осечка!» — дигән булды Рәфгать, кысык күзләрен тагын да кысыбрак. Тагын кордык, тагын аттык, наган тавышыннан шүрләп икебез дә күзне чытырдатып йомабыз, аның кулында атылмагач, йөрәксенеп, мин тотындым, юк, шартламый гына! Беренче патронның төбен тишеп, иләкләп бетердек, эчендәге дарысы агып чыкты, шуннан соң гына ударникның патрон читенә — нәкъ капселенә бәрергә тиешлеген аңладык. Тегеләй көйлибез, болай маташтырабыз, өй белән мунча арасында мәш киләбез, ашау-эчү онытылды. Берзаман Чүке елгасы янындагы печән кибәне төбендә наган шартлады... Атылды да, юкка да чыкты наган... Патронын да, агач көпшәне дә таба алмадык. Чәрдәкләнеп беткәндер, ахры...

Мылтыкка төшкән гыйшкыбыз моның белән генә төкәнмәде, бакыр көпшә таптык, шуның бер башын бөкләп агач сапка беркеттек, көпшәнең бөкләнгән очына игәү белән сызык тиштек. Көпшәгә мул итеп дары тутырабыз да кәгазь өстәп төябез, вак кургаш ядрәләр салабыз да мунча ишегенә күмер белән сызган түгәрәккә атып җибәрәбез. Шарт та шорт! Беркөн исә... Рәфгать көпшәгә дарыны мулрак салган булып чыкты...

Наганы уң кулында. Наганы күз турында. Наганы ишеккә төбәлгән. Шырпы кабызып сул кулына тоттырдым... Сул кулы утны акрын гына көпшәдәге сызыкка китерә...

Чамасыз каты шартлау колакларны ярды, төтен, ут арасында Рәфгать күздән югалды. Ниһаять, мылтык яңгыравы мунча-сарайларга бәрелеп тынганда, дустымның җан авазы белән кычкырганын ишеттем. «Беттем» диде ул... Карасам, ике кулы белән битен каплап Рәфгать җиргә

чүккән, бармак араларыннан кырык эз сызып кып-кызыл кан ага...

— Күзеңме, күзеңме? — дип сорыйм, инәләм, йолыккалыйм, ул дәшми, башын гына чайкый...

Җитәкләшеп абына-сөртенә медпунктка Югары очка менеп киттек. Фельдшер өйдә икән, ул Рәфгатьне караган арада, мин, дер-дер калтырап, ишек төбен сакладым. Байтак торгач, ап-ак марля арасыннан сыңар күзен елтыратып Рәфгать килеп чыкты...

Бәхете, ике күзе дә исән калган калуын, көпшә кисәге артка бәреп, малайның уң күзеннән чак кына түбәндәрәк тирән җәрәхәт ясаган икән. «Күзне фәрештәләр саклый» диеште карчык-корчык...

Каш-керфекләр көеп юкка чыккан, борын, маңгай тирәләре, яңаклар мул сибелгән дары бөртекләреннән зәңгәрсу чуар булып калган иде...

Моңарчы да Рәфгатьне алай матур дип санап булмый иде. Кара шадра иде ул. Җәенке танау, кысык күзләр, иреннәре калын...

Ат кылы кебек эре бөртекле чәчле Рәфгать, ярасы төзәлеп марляларын сүтеп ташлагач, тагын да шыксызрак, шөкәтсезрәк булып калган иде... «Рафа-җәфа»ны онытып, Рәфгатьне «Монгол баласы Дындып» дип йөртә башладылар. (Без үскәндә шундый бер китап бар иде, язучысы гына хәтердә калмаган.)

Чабата-чабата кара шадралар арасына сибелгән Киек Каз Юлы төсле зәңгәр дары бөртекләрен күргәч, чулак Гыйбадулла:

— Ныстяшний Дындып булган син, парин! — дип кычкырып җибәрде.

Без дә бурычлы булып калмадык, Гыйбадулла печәннән кайтканда арба чәкүшкәсен тартып чыгардык. Ул йөк өстендә киерелеп ятып кайта иде. Берзаман, тәгәрмәче чыгып, арба күчәре дык итеп җиргә төртелде, Гыйбадулла печән өстеннән тузанлы юлга мәтәлеп төште... Без, терекөмеш бөртекләре күк, төрле якка сибелсәк тә, танып калган икән, байтак вакыт үчегеп, сагалап йөрде...

«Ворошиловча ату ярышларын» без шуның белән тәмамладык, сыер мөгезенә тутырып качырып йөрткән дарыны чыгарып түктек... Рәфгатьнең күз төбендәге җәрәхәт бәрабәренә без акыл һәм гыйбрәт алдык. Минем тез купкач: «Аксак калмагаең»,— дип, Рәфгатьтән дә ныграк куркучы булмады. Кул-аягы исән булса да, буйга өрлектәй озын, көчле егет булса да, ул үзен азмыкүпме «гарип», «тамгалы» итеп саный, тамгасыннан хурлана, шул җәрәхәте аны иптәшләре алдында, бигрәк тә

кыз-кыркын арасында кыюсызрак тотарга мәҗбүр итә иде... Шуңа күрә һәр көн кич, бәрәңге басуыннан кайтышлый, Рәфгать безгә кагылып чыга, хәлемне белешү өстенә, үзе дә күңелен ача, серләрен уртаклаша. Беләм, басуда, эш арасында кимсенеп үк тормаса да, Рәфгать бик үк ачылып та китми...

Хәтта миннән дә читенсенә! Менә утырабыз. Икәүдән-икәү. Аны-моны сөйләшәбез. Ул: «Фронтларда ниләр бар икән?» — дип сорый. Мин: «Кырда ниләр бар?» — дим...

Күрә Рәфгать, кое өстен томалаган такталарны да күрә, кадак башлары тонык кына ялтырап торалар, янымдагы балта-чүкечне күрә, әмма сорашмый. Үзем сүз башлаганны көтәме? Сораса ни булыр иде инде?.. Көндезге хәлләрне, Арзуны бозарга теләүләрен аңа сөйлисем килә... Юк, гайбәт итеп түгел, һич! Бозымнар, сихерләр турында ишеткән булсам да, тормышта моңарчы бер дә очратканым юк иде!.. «Сугыш заманында калка инде бөтен чүпчар!» — диде әни беркөнне...

— Бәрәңге бетми дисең алайса? — дидем мин, гаҗиз булып.

— Кая бетсен? Кызлар төш авышкач кына басуга килделәр... Кар яуганчы алырга калмагае... Тагын тынлык...

— Әйбәт чыгамы?

— Ташып бетергесез. Үзе эре, үзе чиста. Шунда ызанда күче-күче белән өябез дә сабагы белән томалыйбыз. Дөнья быел бәрәңге!

Дустым, Дындып, Дындып! Рафа-җәфа!.. Кичә дә сөйләдең ич син шушы ук сүзләрне, өченче көн дә... Тик кызларның соңга калуын гына әйтмәгән идең. Ялыга башладылармы, туйдылармы?..

— Кызлар үз бәрәңгеләрен алып яталар...

— Алайса аяк төзәлсә дә, мәктәпкә бару юк икән,— дидем мин, балта-чүкечемне юри урыннан-урынга күчереп.

— Нигә?

— Кызык түгел ич. Мәктәптә, дим.

— Кызык дип...

Ул, күзләрен кысып, миңа таба иелде, менә сиңа мә, авызыннан тәмәке исе килә түгелме?

— Әйдә ташлыйбыз! Син йөрмәсәң, әнкәй мине кыстамый. Син укыганга гына йөртә ул мине. Барыбер сугышка алалар ич, иеме?

— Унынчыларга бронь чыга дип сөйлиләр.

— И-и, әбиләр сүзенә ышансаң! Әнә Кәҗә башы карчыклары «Мәһди күтәрелгән» дип тә лыгырдыйлар икән. «Туфракны ашап килә» ди...

Рәфгать авызны ерса да, мин көлмәдем. Көләрлек хәлем юк иде.

Ул тирә-юньдә таралган имеш-мимешләрдән көлә-көлә кое өстеннән сикереп төште, кесәсеннән тәмәке янчыгы, бөкләп салган газет чыгарды, эре генә кыланып төрде, кабызды, кое тирәсенә ачы ис таралды.

— Әллә пышкытырга тотынган инде?

— Әһә,— диде ул, мактанып.— Басуда укытучылар алдында көйрәтәбез. Илһам белән икебез. Көндез шырпы беткән иде. Арзудан алып тордым. Бер сүз әйтмиләр. Мә, суырып кара...

— Тәмсез,— дидем мин, йөткеренеп.— Мүк тәмлерәк иде.

— Кәнфит түгел инде! — диде Рәфгать.— Укытучыларның ник сүз әйтмәгәнен беләсеңме? Барыбер унынчыны тутыра алмыйбыз, алалар безне. Ә тәмәке тартмаган солдат буламы!.. Эх, тизрәк китәсе иде!.. Әйдә, тәвәккәллик, ә?!

Әгәр ул сугыш, китү турында кайнарланып үгетләмәсә, мин аңа ул кичтә коедан чыккан бозым турында бәйнәбәйнә сөйләп бирә идем... Бозым Арзуга турыдан-туры бәйле булганга, аның исемен дә телгә алмый калдырмас идем... Ә аның исемен телгә алгач... Юк, юк, үз күңелемдә ныгып өлгермәгән уйларны сөйли алмас идем мин Рәфгатькә! Ходаем, яратам ич мин Арзуны! Үлеп, шашып яратам!..

## 6

Иртәгесен мин түзмәдем, бәрәңге басуына барырга булдым. Кичә көнозын аяк өстендә уралдым әле, тез төнлә бераз сызлаштырып торса да, искитәрлек түгел, эшкә чыгарга кирәк!

Урамга чыксам, Гыйбадулла чулак белән Сирай кичә без аннан-моннан гына рәтләп куйган читәнне сүтеп ташлаганнар да, яңа баганалар утыртып, чыбыкларны өряңадан үреп маташалар. Сирай бишмәтен салып куйган, җиңнәрен сызганган, чыбыкларны биреп тора, Гыйбадулла җыр шыңшый-шыңшый тигез, шома итеп тезеп бара. Мине күргәч, икесе дә авыз чалшайттылар:

— Әнә, Аскы урам остасы чыкты! — диде Сирай, башын кагып.

— Әй,— дип кычкырды Гыйбадулла миңа.— Шәп ныгытасың икән син!

— Өстәл янында ныгыта торгандыр. Анысына оста,— дип, аны җупләде Сирай.

— Кызлы йортта бер-бер өмете бардыр аның, шуңа тырышкан! — дип өстәде Гыйбадулла.

Кичә ашык-пошык кына бәйләгән мунчалам җилдә җилферди, телләре тик тормаганда куллары да эшли тегеләрнең, күз иярми...

Ни әйтим? «Эшләгәнегез үзегез өчен!» — дигән булдым да сыздым, әмма җиңелүем, мәсхәрәгә калуым көн кебек ачык иде...

Сирайга моңарчы да ачулы идем, бүген тәмам ярылырдай булдым: тез капкачын куптарды. «Хәлең ничегрәк?» — дип, бер сорап куйсачы!

Басуда көн бик тиз узды. Казыдык, чүплэдек, тутырдык, буаз сыер корсагы хәтле капчыкларны Рәфгать белән Илһам көшелгә ташып торды. Мин дә ташыйсы иде дә, бүгенгә курыктым, җөгәнеп китүең бар...

Кичен кайтсам, Мәүлиха апа балта тотып чыккан да мин кадаклаган такталарны каерып азаплана. Эш тотып өйрәнгән кул булса, әллә кайчан алып ыргытыр иде, юк кына бит, алай итә, болай, балта белән кадак суырырга маташа, һич эш чыгара алмый. Ниятен белеп торсам да, башта, әдәп өчен, сәлам биргән булдым, аннары гына:

— Ударник чаклар искә төштеме әллә, Мәүлиха апа? — дидем.

Аның белән ачыктан-ачык сөйләшергә ярамаганын үзләштереп килә идем. Ул да сер бирмәскә булды, көлде дә:

— Бер нәгъләт суккыры коены томалап куйган әле менә, ни ачуы булгандыр,— диде. Ныгытыбрак суккан иде, балтасы ике такта арасында кысылып калды. Балтаны чыгарырга теләп ике арага бармагын тыкты, балта чыкты, бармак, шүрәленеке төсле, кысылып калды.

Азаплана торгач бармак та чыкты.

— Әлә-лә-лә! — дип чырылдады ул, бармагын суырасуыра.

— Киселмәгәнме? — дидем мин, көлүемне көчкә тыеп.

— Кысылган киселгәннән яман ул. Менә син дә кысылырга бик яратасың!

Менә бусы инде Мәүлиха апача! Ак дип башлады, кара дип бетерде!

— Нигә алай дисең?

— Димичә! Кулың кычытканга яптың ич син бу коены! Атна буе ялкау симертеп ятканга эчең поша! Без тол хатыннарга мәшәкать ясыйсың килгән!.. Юньле булсаң, уңай эш эшләр идең, әнә Гыйбадулла... Кулы гарип, читәнне коеп куйды! Сирайны әйт тагын, ай-һай егет икән! Эше өчен бер тиен алмады!..

Сүз озайту файдасыз иде, мин, кистереп:

— Коедан су алырга ярамый хәзер,— дидем.

— Мөгез чыгармасана! — диде ул, бармагын тач-тач суырып.— Нигә ярамасын?

— Анда песи төшеп үлгән. Коены башта нык кына тазартырга кирәк.

— Ә-ә? Песи?!

Үзе шапшак, юбалгы булса да, Мәүлиха апаның җирәнә торган холкы барын беләм, телемә килгән беренче ялганны ишетүгә аның чырае сытылды, куллары түш турына күтәрелеп, бармаклары белән куркынган хәрәкәтләр ясады, мин кое өстеннән балтаны алып, кузгатылган кадакларны яңадан каккалап куйдым.

— Песи шунда ятамы әле?

— Алуын алдык...

— Өч төсле песи идеме әллә?

— Анысы ни тагын?

— Шулдыр, ярабби, шулдыр!

Миңа кызык була башлады:

— Ничек була ул «өч төсле»? — дип сорадым. Аның чиркануы да, җирәнүе дә күз алдымда эреп юкка чыкты, йөзе эшлекле, киеренке кыяфәткә керде.

— Атна чамасы булыр, шушы кое тирәсендә ят бер песи уралганын күрдем,— дип башлады ул, иреннәрен ялап.— Әнекәй генәм, карасам... Бел — песинең юньлесе ике генә төсле була аның. Ә бу хәерсез өч төстә иде: ак та, кара да, сары да! Шундук саф күңелемә шөбһәле уй иңде бит: әһә, димен, мөгаен, юньле хәл түгел бу, казага булыр! Юраганым юш килгән икән, белми йөргәнмен!.. Шул төшеп үлгән инде алайса!

Үз сөйләгәненә шулай тирәнтен ышанып, бирелеп сөйли бу апа, ышанмас җиреңнән ышанырсың!.. Бер мәлгә минем күз алдына әнә шул чир-чор таратып йөрүче, бозымнар китереп чыгаручы өч төсле песи килеп китте... Көләсем килсә дә, җаным тыныч: хәзер безнең очның чыбыксыз телефоны бу гаҗәеп хәбәрне таратырга керешәчәк. Песинең котсыз кәкре койрыгы Югары очка җиткәнче тәртә буе үсәчәк! Кое тирәсендәге гайбәтләр аны ябылган килеш калдырачак.

Мәүлиха апа, камылдан йөгергән ут шикелле, сүздәнсүзгә җиңел күчә, ул хәзер бөтен дөньясын эттән-эткә алып сүгәргә керешә, сугыш ачкан фашистларга да эләкте, шулар аркасында авылын ташлап киткән ир-атларны да тетеп салды, монда калган «җебегән сарыклар»ны да тешләде, хатын-кыз өстенә өелеп калган кырыкмаса-кырык эштән зарланды:

— Тавык суярдай адәм калмады бит, үлсәң — үл!.. Пычак үткеннәргә кемгә барыйм? Мал-туарым курмысыз калды... Утыным китерелмәгән!.. Килгәне киселмәгән... Түремдә җиде кыз... Җитмәсә монда, коега песи төшеп үлә! Идән юарга дигән суны да инештән төшеп алыйммыни? Үзе булса, чишмәсеннән ташып куяр иде дә... Үзе юк бит! Нишлим ди мин җиде кыз белән? Нишләде бу сәвит влачы?!

«Йөрисең шунда көянтә кук гәүдәңне сузып!» дип мине ачуланды-ачуланды да тагын кызларын чәйнәргә тотынды. «Бүген бишесен тотып кияүгә бирер идем, кем алсын, ир заты корыды бит!» дип зарланды. Аннары үзенең ирсез үткән гомерен каргады... Кичә генә: «Аягың төзәләме, төзәлмәсә фәлән эшлә, күрәзәгә бар!» — дип сөйләнгән апам, бүген бөтенләй киресен сукаларга керешге: «Төзәлмәсен аягың, аксак калсаң ичмасам сугышка бармассың, Аскы урамда бер ир заты калыр. Тик юньсез хатын-кыздан сак бул. Хәзер хатын-кыз бик азынды, әнә Хәбибрахман тумасы да районда бер егет белән бик нык бутала икән», — дип сөйләп һушымны алды.

Моңарчы ни сөйләсә дә, көлемсерәп кенә тыңлаган идем, әмма Хәбибрахман тумасы дип кимсетеп, Арзуның исемен яманлап телгә алгач, ачуым кабарды:

— Йөрмә җыен юк-барны җыеп, Мәүлиха апа! — дип кырт кистем.

Әнисенең озаграк мыштырдавына эче пошкан, ахры, Кәримә тәрәзә ачып кычкырды:

— Әнкәй, кайт инде!

Мин Мәүлиха апаның канына азрак тоз сибәргә булдым:

— Кәримә нигә бәрәңге алырга бармый? — дип сорадым.

Апам шар-яшен кебек шартлап ярылды:

— Әле син чүп башың белән минем кызлардан көләргә телисеңме, аксак тәре?! Ун класс гыйлемлеге белән Кәримә тиклем Кәримә синдәй каргалар белән бәрәңге ызанында чүпләнсенме? Үз бакчамны яллап алдырачакмын, беләсең килсә! Кызларыма сыер имчәге тоттырмам, сәнәк-көрәккә якын җибәрмәм! Ефәк кебек кызларны... Сәвит влачы хатын-кызга ирекне биргәнме? Биргән! Ун классны укыган кыз ул! Элек хәреф таныганнар остабикә булып өйдән өйгә бәлеш ашап йөргән. Хәзер сәвит влачы! Арзу укытучы булып калсын, ә минем Кәримәм... Сезнең ул Арзуыгыз минем Кәримәмнең кисеп ташлаган тырнагына да тормый! Менә күрерсең, барыбер Кәримә Арзудан уздырыр...

Кәримә тагын тәрәзәне ачты, әнкәсен чакырды, мин дә арган идем, өйгә кереп аннан-моннан гына капкаладым да урынга аудым... Арзу кырдан туры мәктәпкә киткән иде... Ничек түзә икән ул? Миннән иртә кузгала, менә мин урын өстендә, ә аның кайтканы күренми...

Кое гаугасы моның белән генә бетмәде.

Берничә көн үткәч, бәрәңге басуына иртәрәк өлгерим дип, караңгылы-яктылыда урамга чыксам,— өстемдә сырма, башта тула картуз, көн кинәт суытып җибәрде, үзәккә үткеч вак яңгыр сибәли,— карыйм, кое тирәли берәү йөри. Юлаучы икән, шәбәргән аты да шунда туктаган. Чыбыркы сабы белән кое капкачын күтәреп карады да, мине абайлап (Арзу килеп чыкмасмы дип капка төбендә ышыкланып торам!):

— Киптеме әллә бу? — дип сорады.— Узган атнада гына ат сугарып узган идем.

— Суы бетте, корыды,— дидем мин, ваемсыз гына.— Бала-чага төшмәсен дип кадакладык.

Болай да кием-салымы чыланып өтекләнгән юлчым кинәт бөкерәеп, кечерәеп калды, ачык зәңгәр күзләрен чет-чет йомды, очлы вак тешләрен күрсәтеп көлеп куйды. Көләрлек бер сәбәп тә юк иде, сәерсенеп, мин аңа таба атладым, дегеткә буялган яшел бишмәтенә, эт талаган колакчын бүрегенә, юештә чәбәләнгән кызыл сакалына текәлебрәк карадым. Кызыл сакал да китәргә ашыкмый иде булса кирәк, миңа таба атлады.

— Алай! — дип сузды ул, мәгънәле генә итеп.— Бик аңлыйм... Әле менә теге яклардан килешем. Анда калхузларда мал кырыла башлаган. Чутсыз үләләр, ди. Сарыкларына әйләнчек булган. Пәтифун тәлинкәседәй зырзыр әйләнәләр ди менә! Ходай күрсәтмәсен. Көзлектә, юньле заман булса, мал кырыламы? Туклыкта, дим? Тиешме кырылырга?

Абзый әллә көлә, әллә җылый, бүрек колакчыннары дер-дер селкенә, төссез күзләреннән болганчык яшь ага.

— Җыласы урында, көләсез икән сез,— дидем мин.

— Кайгыдан көләм,— диде ул, җәлпәк борынын сеңгереп.— Кайгыдан! Бу коеның суы нигә кипкән дисең син? Уйнама! Замана авырлыгы берьюлы килә торган була. Күктән Алла хәсрәтне җиргә уртаклап җибәрә, табигать белән безнең барыбызны да тикшерә. Адәм баласын, киек-җанварларны, мал-туарны бергә сыный. Тиктомалдан сарык муры таралмы? Күлләр кибә, коелар корый. Әнә Түбән авыл күл ярына пар торна төшеп үлгән, ди.

Арзу китеп өлгергән булдымы шунда, капкалары

һаман ачылмады, вакыт иде, әмма тигәнәктәй ябышкак бу кеше янына ычкыналмыйм, ул кайсы ягы беләндер мине үзенә тарта, аның белән бәхәсләшәсем килә, бер үк вакытта аның каты, чуалчык сүзләре алдында үз дәлилләремнең йомшак, зәгыйфь булачагын да тоям.

Күз алдыма коедан чыккан хәшәрәтләр, әкәм-төкәмнәр килеп китә, телемне тешлим, көчсезләнеп калам. Көчсезлегемне сизү мине, гомумән, гарьләндерә, ярсыта. Кызып әллә ниләр, акыллы сүзләр, китап сүзләре әйтмәкче булам, зиһенем чуала, телем көрмәкләнә. Минем көчсезлегем алдында зураеп, хәтәрләнеп киткән кызыл сакал тигез, догалы тавышы белән һаман үзенең агуын чәчә:

— Шыпионнар эше бу, шыпионнар кыландыра! Килә бит мимеч, килә... Ай килә! Шыпионнар җибәрми дисеңме әллә син аны? Мин, агайне, барын белеп, күреп торам... Кыяфәткә карама син минем!.. Дөньясын авызлыклаган дәдәң булыр бу! Булгахтер ием мин...— Ул, куш бармакларын аркылы-торкылы куеп, рәшәткә ясады.— Читлеккә япмасалар арыслан-киек идек тә без... Эх-хи-хи! Томана зирәкләр! Шыпионнар эшен аера белергә кирәк. Буага яисә коега бер-ике генә бөртек терекөмеш салып кара әле менә син! И-и, вәссәлам! Суы җәһәннәмгә уба аның. Белми дисеңме мимеч шуны? Белә-ә, бик белә-ә-ә!

— Юкны һәм кирәкмәгәнне сөйлисез,— дидем мин. Ул, миңа карамыйча гына:

— Әй, бу теге, ни, пружин Хәбибрахман өе буламы? — дип сорады.

— Белмим,— дидем мин, ачуымнан шартлардай булып.

Кызыл сакал камыт бауларын тарта-тыгызлый нидер мыгырдап калды, мин юлымда булдым.

Кичен мине Арзуның бабасы Хәбибрахман карт үзләренә чакырып кертте.

Янәшә күршеләр булсак та, без аның белән күзгә-күз сирәк очрашабыз, гадәттә, очрашканда да сөйләшмибез. Мин, һәрвакыт аны олылап, башымны иеп, сәлам бирәм, ул исә сәламемне алган чакта ала, алмаганда мунчала кебек чәбәләнгән ак кашлары астына тирән, көрәнсу куркыныч чокырларга кереп поскан күзләренең кырые белән генә карап янымнан уза. Беләм, андый минутларында ул яныннан узучыларны бөтенләй күрми, мин генә түгел, өлкәнрәкләр дә аның сәламен сирәк ишетәләр, ул күбрәк вакытын без белмәгән, без аңламаган тирән, серле уйларына чумып үткәрә.

Мөнәсәбәтләребезне яхшы белгәнгә, чакыруының юньлегә түгел икәнлеген чамалап кердем.

— Песи төшеп үлгән диденме син коега? Бу инде Мәүлиха түгел, колагыңны шәңкәйтеп торсаң, бирер кирәгеңне!

— Шулайрак иде шул,— дидем мин, мөмкин хәтле гөнаһсыз күренергә тырышып.

— Ул песине кемнәр күрде?

«Каптым!» дип уйлады күңелем. Телем:

— Чиләк төшкән иде, шуңа ияреп чыкты,— дидем.

— Үләксәсен кая илттең инде син аның?

— Кая дип... күмдем...

— Үләксә базына бардыңмы?

— Юк ла, әнә тыкрык башына гына илттем.

— Песие ни төсле иде? — дип төпченде ул.

— Пычранып беткән иде, төсен аермадым,— диде ялганларга остарып барган телем.

Ул беравык миңа сынап карап торды да башын чайкады:

— Мосафирны нигә алдадың алайса? — диде.

— Кайчан? — дидем мин, ни әйтергә белмичә.

— Үзең беләсеңдер инде... Бездән «фәлән авылларда мур чире таралган» дип китте... Ә күрше авылга барган да: «Югары авылда коелар кибә»,— дип сөйләгән... Кем гаепле инде шуңа?.. Син аның кемлеген беләсеңме?

Тыңлап торганмы дисәм, урамда берәү дә юк иде бит, капкалары ачылмады, ишегалларыннан безнең сөйләшкән ишетелерлек түгел, әллә теге юньсез сакал чыннан да күрше авылларда шундый гайбәт чәчеп йөри дә башлаганмы? Аны Хәбибрахман абзый каян белгән? Кем ишеттергән?

— Мин аның кемлеген белмим, мәгәр ул сезне белә! Өегезне сорады.

Ул усал гына көлемсерәде.

— МТСта бухгалтер булып эшли иде бер заман. Хөкүмәтне имеп кенә түгел, талап та караган бәндә булыр ул! Алаканат!.. Ә син шуңа җыен юк-бар хәбәр төяп җибәргәнсең... Алдарга осталыгың бар икән... Бусын көтмәгән идем. Бабаң андый түгел иде, атаң да... Шулар хөрмәтенә генә булса да, соңгы соравыма дөресен әйт: нигә бу араларда Арзуны сагалап йөрисең?!

Коелып иңдем! Кызыл сакалның «шыпионнар эше» дигәне хәтергә төште. Хәбибрахман картның, төнге ябалакның, үз шпионнары бармы әллә? Барын белеп, сынап, күңеленә төйнәп йөри икән. Шул төене белән минем җилкәгә хәзер шундый кундырды... Шыпан-шыпан гына чыгып сыздым...

Бабасы төшенгәнне Арзу үзе әллә кайчан төшенгәндер, шиксез! Әллә бабасына үзе сөйләп бирдеме? Икәүләшеп көлешә-көлешә аңлаштылармы әллә алар?!

Соңгы көннәрдә бәрәңге басуында колхозчылар, укучылар белән бергә Зәйдән килгән промкомбинат эшчеләре — кирпеч сугучылар, мунчала кабыгы төшерүчеләр, кап сугучылар да шактый тырыштылар, эш күзгә күренеп үрчеде, алга китте, аласы җирләр кимеде, укытучылар җиңел сулыш алдылар. «Программадан тәмам артта калабыз, укытучыларның күбесе яшьләр, тәҗрибәләре юк, методиканы белмиләр, төшкә хәтле укытыйк та, төштән соң кырга чыгарбыз» дип гозерләп идарәгә бардылар. Һәм без укый башладык, табигый буларак, Арзу да чын укытучы сыйфатында беренче дәресенә керде. Ничек барып чыгар икән, беренче тапкыр класска аягын ничек басар дип шактый борчылган идем, очрашу мин көткәнгә караганда шактый шома, ботаксыз-сатаксыз узды.

Каядыр очарга җыенгандай, алга сөрлегебрәк, тиз-тиз атлап класска керде дә ишекне ипләп кенә япты Арзу, тынлык урнашканын көтәргә дә сабыры җитте, елмайды. Арткы партадан кемдер тыенкы гына сызгырды, кызлар яман чожылдап аны туктаттылар, яшь укытучыбыз каушавын сиздермичә генә һаман көлемсерәде, йомшак тавыш белән, нәкъ башка вакытларда сөйләшкән кебек, сүзен башлады:

— Укучылар, яшерене-мазары юк, немец телен үзем дә белмим мин. Унынчыны гына тутырдым. Хөснимәрдан абый сугышка алынды... Тормыш шулай куша икән, телне бергәләп өйрәник. Сез шуңа риза булсагыз, мин районда — райкомолда да, РОНОда да ризалыгымны биреп кайттым...

Дәррәү «риза!» дип кычкырганыбызны сизми дә калдык...

Бер-ике көн узгач, педсовет утырышы булды. Директор бүлмәсендә ут сүнгәнче, бакчадагы иң зур чыршы астында мин басып тордым. Вак яңгыр сибәли. Көн дә тынмый, төн дә... Суык. Укытучылардан соңгы ир кеше — завучыбыз Хәнәфи абыйга чакыру кәгазе килгәнен беләм. Повестка. Анда, педсоветта, шулай озакка калып Хәнәфи абыйның физика дәресләрен бүлешәләр. Хәнәфи абыйның китәсен ишетеп, Мәүлиха апа бүген көне буе авыл буйлап чапты, безгә дә ике-өч тапкыр кереп чыккан...

— Кәримәдән кулайны табалмаслар алар,— дип үгетли икән минем әнине.— Физиканы гына түгел, әллә нәмәрсәкәйләрне теттереп укытырлык бала... Шул Хәбибрах-

ман җенлесе генә карышса инде... Шул аяк чалса... Гомергә Кәримәдән, аның матурлыгыннан көнләшеп яшәде инде... Кәримәм урнашса, ичмасам... Җаным тыныч булыр иде!

Соңгы керүендә мин дә бар идем, әни Арзуны яклап бер-ике сүз әйтте дә тынды, Мәүлиха апа белән телгә килгәнче, чалгы янавычын ялармын дип әйткәне бар аның. Шүрли.

Мәүлиха апа Хәнәфи абыйга «юл күчтәнәче» дигән булып тавык суеп китерде, директор янына өч-дүрт тапкыр кереп чыкты. Аның шулай эшлекле төстә ашыгып йөргәнен, бөтен кешегә ягымлы эндәшкәнен гомердә күргәнем юк иде...

Чыршы карт, ботаклары куе, көн яктысында, кояшта алар миңа тередер кебек тоелалар, куе ботаклар арасында яшертен сер бардыр дип уйлыйсың; өскә үк явып тормаса да, һава барыбер дымлы, черек, борын эчен бимазалап кытыклый, туктаусыз төчкертә. Өс-баш та җиңелчәрәк, шуңамы, туңдыра башлады.

Мәктәп тәрәзәсендә күләгәләр йөри, менә кузгалдылар, утны сүндерделәр. Агач ышыгыннан чыгып койма артынарак якынайдым. Моннан ишек ерак түгел, караңгыда да кемнең кем икәнен аерып була. Директор Зөләйха апа, Хәнәфи абый һәм Арзу иң артка калып чыктылар. Тирә-як тын, башкалар озак утырып ялыкканга тиз-тиз таралыштылар, төн тынлыгын аяган яңгыр да мыштым гына сибәли, сөйләшкән сүзләренең дәвамы миңа аермачык ишетелә, директор да, Хәнәфи абый да Арзуны кызып-кызып үгетлиләр, димәк, физикадан да аңа өлеш чыгарганнар дигән сүз.

— Классыгызда беренче укучы идең,— диде Хәнәфи абый.

— Хәзер коллективта иң актыккы укытучы булачакмын. Шуны телисезме? — дип карулашты Арзу.— Болай да минем хакта юк-бар хәбәрләрне тараталар...

Мин сагайдым: ачармы серне, юкмы?

— Барыбыз да шулай курка-курка эшли башлаган,— диде Зөләйха апа.— Педучилищеның икенче курсыннан укытырга җибәрделәр мине... Кадрлар җитми иде. Өс-баш — ташка үлчим... Белем — такыр. Авылның ындыр артыннан башка дөнья күрмәгән дә... Укытасы авылга кыш уртасында барып төштем, мәктәп мөдире бер олаучыга карый, бер миңа. «Сезнең кайсыгыз укытучы соң?» дип сорый. Теләсәң егыл, теләсәң кал... Әкренләп өйрәнерсең...

Арзу зәгыйфь тавыш белән:

— Әллә Кәримәне чакырып карыйбызмы? — дип сорады.

Хәнәфи абый хатын-кызларча кеткелдәп көлеп җибәрде. Зөләйха апа, Мәүлиха ападан тамчы да курыкмый икән, калын тавышы белән ишегалдын ярды:

— Үскәнем, сөйләмәсәнә җүләр сүзне! Кәримәне унынчыдан этеп-төртеп чыгардык. Ата ялкауны мәктәпкә китерәмме? — дип ачуланырга тотынды.— Шуны да онытмыйк — хәзер һәммәбезгә дә ике, өч кеше урынына эшләргә туры киләчәк! Көчне жәлләп торыр чак түгел. Сугыш әле кызып кына бара. Комсомолка ич син! Ил алдындагы бурычыңны миннән шәбрәк аңлыйсың!

Аның соңгы сүзләре Арзуның икеләнүләренә чик куйды.

Ниһаять, алар саубуллаштылар. Таралдылар. Мин Арзу артыннан үз очыбызга кайтып барам. Ул алда, мин, адашкан кәҗә бәрәне, артта! Куып җитәсе дә култыклап аласы иде! Юк шул, булдыра алмыйм. Янәсе, ул укытучы, мин укучы. Бер караганда, бу киртәне сикереп чыгу бик ансат кебек тоеладыр, әмма мин тыйнак, әдәпле һәм чак кына куркаграк идем шул. Аннары безнең авылда укытучылар Алла ук булмасалар да, фәрештәләрдән ким саналмыйлар иде.

Дөнья дөм караңгы, күк әз-мәз ачылган кебек була да тагын томалана. Өйләрдә утлар күптән сүнгән. Анда-санда саташып-ыңгырашып ярым ач этләр һау-һаулап ала. Кайдадыр, тынлыкны сискәндереп, майламаган ишек шыгырдый, галуш чыштырдый, нидер укынган авазлар ишетелеп кала, комган шалтырый...

Арзу курка-курка бара, капка төпләрен, тыкрык авызларын уратып уза, тыкрык турына җитәрәк, урамның икенче ягына каерыла, бер-ике атлый да шып туктала, сагаеп тыңлана. Мин бер урында чак абынып егылмадым, ул шактый вакыт туктап торды.

Кинәт этләр дәррәү өрә башладылар, ярыша-ярыша өрәләр. Ни бүлде аларның йокысын? Кем? Нигә шулхәтле сагая Арзу? Ни булса да көтәме? Гомергә болай курыкканы юк иде аның. Хәтеремдә, сигезенчедә укыганда микән, кызлар белән бәхәсләшеп, төн уртасында, дөм караңгыда зират аша үтеп чыккан иде.

Хәбибрахман картның иртә-кич капка бикләгәне юк. Арзу туп-туры өйгә узды, ут кабызды. Китап-дәфтәрләрен таратып өстәл янына утырды, яңакларына таянды. Җиңел суладым. Үзебезгә таба борылдым гына, кое бурасы артында кара күләгә кыймылдагандай булды. Күңелгә

ямьсез шик йөгерде. Үз турыбызда кайда, ни ятканын беләм, иелеп саллы гына таш алып, коега таба атладым. Юк, беркем юк, кем булсын. Арзуның куркуы миңа йокты, ахрысы. Шулай да җан ачуым белән ташны бура артына, шәүлә шәйләнгән урынга тондырдым. Берни кыймылдамады, селкенмәде, бер читтәрәк мышлаган тавыш колагыма чалынды. Ныклабырак карасам, кара шәүлә йомылып кына чишмә тыкрыгына элдерә! Йөрәгем тук та тук тибә, аркам тирләп чыкты. Икенче ташны да тиз таптым табуын, бала башы хәтлесен ике куллап тотып лап-лоп баса-баса тыкрык авызына атылып кердем. Эх, Рәфгать белән бергә ясаган наган янда булса!.. Теге шәүләне өркетим дип юри катырак басам! Ташны тондырам дигәндә абынып киттем, тәкмәрләп барып тә төштем. Нык саплы, зәһәр чагучы кычытканлыкта ятам берзаман, җәһәт кенә тез капкачын тотып карадым: урынында! Соңгы котны куып кычыткалыктан песи чыгып чапты. Әллә шул песи мәлгуньне кеше шәүләсе дип уйладым инде?

Ул ара да булмады, мин бая куа башлаган карачкы кеше кыяфәтенә кереп, чишмә сукмагында пәйда булды. Яткан җирдән, ачык офыкта мин аны аермачык күрдем. Мин торып йөрәксенгәнче, ул караңгыда эреп югалды... Борылып кайтып киләм, каршы якта еламсырап капка шыгырдады. Ни булды соң? Шәүләләр икәү булып, берсе мине чалып ектымы?

Арзуны көтәләр идеме төнге кунаклар?

Дымлы капка баганасына сөялгәч кенә ике битемнең ияк астымның кызышып янганын сиздем. Дөрләп янган учакка иелдеммени, яна битем, яна.

Арзулар тәрәзәсендә әле ут сүнмәгән...

Бер мин генә түгел, тагын кемнәрдер педсоветның азагын көтмәделәрме икән?

Җылан кабыгын, кызылга манылган әкәм-төкәмнәрне күргәч тә, күңелемә Мәүлиха апа килде. Шулдыр дип уйладым, уема ышана яздым, «бозым» дип аннан бүтән кем йөрер? Мәүлиха апаның көнчелеген, көнче кешенең теләсә нинди явызлыкка маһирлыгын чамалый идем.

Һич көтмәгәндә теге кызыл сакал Хәбибрахманнар өен сорашкач, «мосафирның» кыскача тәрҗемәи хәле белән дә танышкач, Мәүлиха явыз сурәте күңелдә тоныкланды... Төгәл уйга килә алмыйм, чит-ят кешенең төн уртасы авышкач, кое тирәсендә уралуы мөмкин түгел икәнлеген генә беләм... Ә Мәүлиха апа куркак, йомыш белән лапаска да чыкмавын авылдашлар мәзәк итәләр, куян йөрәк...

Димәк, монда мин белмәгән, мин уйламаган өченче кеше булуы бик ихтимал. Әгәр алар икәү булып чыкса? Икәү... Нишләп йөрерләр алар? Кемне сагалыйлар?

Әүвәле мин берәүдә дә явыз ният бардыр дип уйламый идем. Хәзер шигем берәүдән икенчесенә ансат кына йөгерә дә, мин һәркемнән явызлык, әшәкелек эзлим. Өйгә керәсем килми, йокы бүген тансык түгел миңа. Юрган астында йодрык йомарлап яту егет кеше эшеме? Мин Мәүлихалар читәненнән чыбык суырып чыгардым да, шуңа таянып, урам буйлап киттем. Тик тормас өчен генә барам, анык максатым да, төгәл уем да юк. Хәзер, шушы мизгелдә, шушы төндә тегеләрнең берәрсен очратасы иде дә катлы-катлы серләрне каерып ачып ташлыйсы иде. Мондый хәлләр барында Арзу авылда кала алмас! Мең мәшәкать өстенә шик-шөбһәләр, бозымнар, куркытулар өстәлгәч, кемнең җаны чыдый алсын?

Атлыйм, таеп китәм, берзаман як-ягыма карасам, иске ташбазларына килеп җитә язганмын. Караңгылык кысып кочкан юкә куаклар янында басып торам. Шауламаска тырышып яңгыр сибәли. Беркайда шикле хәрәкәт, серле шәүләдер чалымланмый. Эчем поша. Яңаклар гына уттай яна, кызыша. Мин суык яңгырга әле бер яңагымны, әле икенчесен куеп торам. Яңгыр суы яка астына үтеп кергәч, лач-лач пычрак изеп, авылга кайтам. Кеше күңеленә шик кереп ояласа, аның өчен иң куркынычы — ялгызлык. Ялгыз идем мин! Күңелдә генә аңлашырлык кешем дә юк иде минем! Боларны әнигә кайтып сөйләп булмый, Арзуга ачылырга ярамый, коты калмас. Әллә Рәфгатькә кагылып чыгаргамы? Безнең авыл серләрен ачсак икәү ачарбыз! Тәк, тәк, авылда күпме кеше бар?.. Ирләр китеп бетте, монда калганнар аксак та туксак, чулак та күрә карау... Картлар, карчык-корчыклар исәпкә керми. Малайлар кала да, безнең ише самайлар кала. Алар күп түгел! Рәфгать белән берәмтекләп һәр җан иясен инә күзеннән үткәрербез...

Миңсылу апа, Рәфгатьнең әнкәсе, йокылы күзләрен йодырыгы белән уа-уа, бик гаҗәпсенеп миңа карап тора... Соравымны ишетсә дә, һич аңышмый, аңлагач куркуга төшә:

— Сез бергә түгелмени? Рәфгатьнең кайтканы юк әле.

— Кая китеп олагыр икән?

— Ашады да сезгә китте.

— Безгә?

— Бер-бер хәл булдымы әллә? — Миңсылу апаның куркуы соң дәрәҗәгә җитте.— Ярты төнме хәзер? Сәгать ничә икән? Бәла аяк астында йөри диләр шул!

Тынычландырырга, юатырга теләсәм дә, ул миңа ышанмады. Миңсылу апаны күргәч шик-шөбһәләрем бүртә төште: кайда йөрер бу Дындып? Клуб бикле, аулак өйләр юк. Каравыл өендә дисәң... Мөгаен, шулайдыр! Чулак белән тагын әшнәләр! Тагын шул шайтанның йомыш-юлына чабадыр! Көмешкә эзләргә, аракы табарга...

Ә мин шыр тиле... аны... Дындыпны җан дустым санап кайгы-шикләремне ачарга, уйларымны уртак итәргә дип, борчулы сәгатьтә эзләп киләм! Юк инде, булмый торсын! Серне үзем ачармын, шикле бәндәләрне үзем табармын! Үзем!

## 7

Арзуга мин гади күрше кызы итеп кенә карый алмый идем. Минем кыюсызлыгымның төп сәбәбе, бәлки, аның укытучылыгында да булмагандыр... Сәер яшиләр иде алар, безнеңчә түгел, авылча түгел... Хәбибрахман карт үзе дә үтә чыккан гаҗәп бер кеше иде! Фамилиясе үк кызык — Ямашев! Безнең авылда гына түгел, тирә-күршеләрдә дә Ямашев фамилияле кеше юк. Онығына — улының кызына да агай-энедә очрамаган ят исем табып — Арзу дип ул куштырган.

Заманында үтә гаярь кеше булган, диләр аны! Оренбург далаларында Дутовка каршы сугышып йөргән, яраланган, Блюхер отрядында да булган, диләр, хәзер анысын дәшмиләр. Русча укырга-язарга да шунда отрядта өйрәнгән. Ел саен өенә «Правда» алдыра. Әле районнар волость булганда ук аны авыл активы итеп санап йөрткәннәр. Югары авылда «Икмәк контрактацияләү ширкәте»нең вәкиле итеп тә аны сайлаганнар. Ул чакларда кулаклар икмәкне совет властеннан яшерә торган булганнар, икмәккә мохтаҗ яшь республика икмәк контрактацияләү өчен ширкәтләр төзегән. Хәбибрахман абзый авыл байгураларыннан (ә алар безнең кара туфраклы, урманлы-сулы Югары авылда дистәләп саналган!) дәүләт файдасына икмәк җыйган. Икмәкне байлардан алганнар да ярлы-ябагайларга чәчүлек орлык биреп торганнар, кала эшчеләренә озатканнар, пычакка-пычак килгәннәр...

Меңтугыз йөз егерме тугызынчы елда авылыбызда колхоз оешкан. Хәбибрахман абзый беренчеләрдән булып колхозга кергән, аны Чистайга колхоз оештыручылар курсына укырга җибәргәннәр, ул шунда биш-

алты ай укып кайткан. Хисапчы булып эшләгән, торабара председатель итеп сайлаганнар үзен. Ул рәис чакта авылдан кулакларны сөргәннәр, каралты-кураларын сүтеп, һәркайдагыча, авыл советы һәм идарә йорты салганнар.

Боларында бер дә сәерлек юк әлегә, заман, тарих нәрсә кушса, шуны эшләгән Хәбибрахман абзыйлар. Районда беренче сарык фермасы да безнең авылда салынган. Ферма төзегән көннәрне мин дә хәтерлим, эш тәмам булгач, бөтен авылны җыеп күмәк табын әзерләделәр, ике тана суеп борчак ашы пешерделәр. Олылардан соң йомычка җыеп йөргән малай-шалайга да, ягъни безгә дә сый эләкте, бүксәләр кап булганчы, шартлаганчы тәмле, өреле борчак эштие ашаган идек...

Утыз өченче елның унөченче маенда Казанның элеккеге цирк бинасында ударник колхозчыларның беренче республика съезды ачыла. Рәфгатьнең әнисе Миңсылу апа белән Хәбибрахман абзый шул съездга делегат булып баралар. Хәбибрахман абзыйга бүләк итеп мех бүрек белән патефон, ә Миңсылу апага әйбәт күлмәклек биргәннәр. Безнең «Ленин юлы» колхозын дүрт лобогрейка белән бүләкләгәннәр.

Утыз бишнең башында, бездән җиде генә чакрымда урнашкан Ташлы МТСның ягулык хуҗалыгы янып китте. Склад мөдире белән каравылчы «Тычкан уты» фонаре белән подвалга төшкәннәр, анда бензин газы җыйналган була, янгын чыга... Кара буран, күзачкысыз җил котырган көн була бу! Ягулык хуҗалыгы төп корылмалардан чакрым ярым читтә утырганга, беркем берни белми дә, күрми дә кала. Мөдир дә, каравылчы да эзсез югалалар...

Безнең Хәбибрахман абзыйның политбүлек начальнигы чакырып ала. «Сынадык, кулыңнан эш килә, кыюлыгың да мәгълүм. Танышлыгың да бар. Нефть хуҗалыгын ашыгыч рәвештә аякка бастырырга кирәк! Тотын шуңа. Язгы чәчүгә хәтле эш тәмамланган булсын, иптәш Ямашев»,— ди.

Рәислеген тапшырып, Хәбибрахман абзый шул эшкә күчә һәм нефть хуҗалыгын өр-яңадан тезеп, рәткә керткәч, аны мөдир итеп шунда калдыралар.

Бусына инде бөтен авыл шакката!.. Ничек инде, колхоз шулай акрынлап чәчәк атканда, нефть хуҗалыгындагы өнгә кереп бикләнә!.. Якын кешеләре беләләр, Хәбибрахман абзыйның гомер буе йөрәген талаган бер адәм була. Ул кеше — аның бердәнбер улы. Арзуның әтисе Мөлек Ямашев иде...

Яхшы хәтерлим мин ул кешене дә! Чәчен шалкан мае белән ялтыратып ике якка тарап, итәге чигелгән алсу-кызыл күлмәген чалбардан чыгарып, зәңгәр чуклы зәр белән буып йөрүче, шыгырдавыклы хром итекләрен иң эссе көннәрдә дә салмас бу шома, елгыр кешене, ничектер, мин яратып бетерми идем. Очраган саен йә кызыл билле прәннек, йә чуклы кәнфит биреп китсә дә, Мөлек абыйның төчелеген, сөрмәле читле оятсыз зәңгәр күзләрен, тук мәче төсле мырлап, авызын бөрештереп сөйләшүен бала чактан ук сөйми идем. Мөлек абый узып киткәч, җилле көн булса да, Югары авыл урамында хушбуй исе озак вакытлар аңкып тора иде. Хатын-кыз, балга ябышкан чебен күк сырыша иде Мөлек абыйга! Әле өйләнгәч тә ул юньләп өендә тормый иде, аулак өйләргә йөри, кунак кызлары белән куна, яшьрәк тол хатыннарның сукмагына үлән үстерми...

Гомере буе эштән, хезмәттән башканы белмәгән Хәбибрахман картның күңелен аңлап була! Нәселенең тоткасы, бердәнбер варисы игенче хезмәтенә хыянәт итсен әле!.. Үгетләгәндер ул аны, тик Мөлек абый атасының ай-вайларын җиргә салып, үзләренә итек басарга кергән Кужаш урысларына ияреп кәсепкә чыгып киткән. Карчыгы байтактан күкрәк бакасыннан үлгәнгә, Хәбибрахман абзый тәмамысы берьялгызы калган... Мөлекнең беренче хатыны бала тапмаган, озакламый аерылып китеп тә барган... Аның итек басучы булып китүен дә, икенче хатынлыкка күрше Түбән авылдан вак сәүдәгәр, күкәйче Гариф кызы бөдрә чәчле, ал иренле, хихахай да михахай йөрүче кынҗыр Фатиманы алып кайтуын Хәбибрахман карт бер дә, бер дә өнәмәгән! «Рәислеген ташламый иде ул, нефть базасына барып олакмый иде, әнә шул ала күзле суык аяк Фатима аркасында үз өен сөймәс булды» дип сөйлиләр иде безнең өй эчендә...

Мөлек читтә тагын да шомарган, көмешкә ярата башлаган, Фатимасы ирен әзләп чыгып йөрергә гадәтләнгән. Мөлекне эзәрлекләп барып, көннәр буе бәрәңге ызанында сагалап утырып, Кужаш марҗалары яныннан якалап та алып кайткалаган... Инде марҗалар артыннан көпә-көндез сиптерә башлагач, кемнәрдер аның сырт сөяген каезлап, икеме-өчме кабыргасын да сындырып кайтардылар. Арт саны сынган эт күк сөйрәлеп кайтса да, атна-ун көн уздымы икән, Мөлек тагын шыгырдавык итекләрен киеп алды, хушбуй исе таратып, Югары очка менеп китте һәм аны утырмага килгән кәнтәй Ләйсән яныннан чормадан тотып төштеләр...

Гомере озын булмады аның, эт кебек, чит кеше буса-

гасында, әллә кайда ар ягында, сукыр эчәгесе шартлап үлде. Аны агач табутка салып алып кайтып зиратның бер читенә, аулак почмакка күмделәр. «Табутын да ачып карамадылар, чыраен күрергә теләгәннәр булмады»,— дип, тирә-юньдә бу хәлне могҗиза итеп сөйләделәр...

Күкәйче генә булса да, Гариф хәлле, атлы-тунлы кеше иде. Бай-кулакларның теш кортына әйләнгән каенатасы Хәбибрахманны күкәйче Гариф кызы ирдәүкә Фатима, әлбәттә, яратмагандыр! Мөлек гүргә кергәч, ел ярым тордымы икән, Донбасстан сабан туена кайткан базык кына, тәбәнәк кенә көрәшче татарга ияреп китеп тә барды. Хәзер шахтерларга столовой пешерә икән, күргән-белгәннәр: «Килешкән күкәйче кызына казна камыры! Беләкләре кабартма-кабартма булган, арты тегермән ташы хәтле!»— дип, ярым шаяртып, ярым җирәнеп кайтып сөйләделәр. Фатиманы бай кызы булганы өчен дә түгел, кияүгә чыгып киткәне өчен дә түгел — бердәнбер баласы Арзуны үзе дә карауга мохтаҗ бабасында калдырып киткәне өчен әрләделәр.

Башта Арзуны алып китәргә яшь ире каршы торган. Инде ирне — шахтерны суык күлдә җебетеп, кояшта киптереп, талкышта кат-кат талкып, тәмам бау ишәрлек йомшак хәлгә китереп җиткергәч, Фатима Арзуны үз янныарына алдырырга теләгән, мәгәр, ул чагында Хәбибрахман карт аяк терәп каршы килгән. «Нәсел-нәсәбе затсыз, бер кияү белән генә гомер уздырачак түгел Фатима, минем канымны кияү саен сөйрәп йөрми торсын әле, үз сөягем үземә!»— дигән...

Кулында көч, беләгендә егәр бар чак, район каршында да абруй җитәрлек, авылда да куәтле кеше, шуларга аркалангандырмы, бирмәде әнисенә Арзуны, янында алып калды. Теге базык шахтер да мәкерле булган, кызны бирмәүләрен үтенеп картка хат язган икән, дип тә сөйләделәр.

Бар иде Хәбибрахман абзыйның төп-төз буйлы, тазаның җилкәле, җип-җирән чаклары! Хәзер бөкерәйде, йөреш-торышы үзгәрде, нәтиҗәдә, аның тезен бөкләп, алга сөрлегеп, селлин-селлин атынып йөрүен мәзәк иткән кешеләр «пружин» дигән кушамат тактылар. «Пружин» дигәннән тәм табып бетермәгән татар авызы берзаман аны «быржин» дип җайлаштырды да куйды!

Заманында авылның иң абруйлы, иң могтәбәр адәмнәреннән берсе булган Хәбибрахманның ил агасы булып утырыр көннәрдә гап-гади «быржин»га әйләнүенең ике сәбәбе бар иде. Бердән, игелексез улы башыннан кичкәннәр аны бик талады, икенчедән, ни сәбәптәндер, байтак гомер узгач, Ташлы МТСының януы тикшерү орган-

нарына яңадан әйләнеп кайтты. Хәбибрахман абзыйны зурлап эшкә чакырган политбүлек начальнигын эшеннән очырдылар, моның кара күләгәсе аңа да килеп төште... Ташлыдан әйләнеп кайткач, аны яңадан председатель итмәделәр. Басу артындагы зур чүннеккә умартачы булып керде ул. Җәй буена авылга кайтмыйча, безнең күзгә-башка күренмичә, шунда ятты. Көзен авылда: «Корт угы ярамый икән, Хәбибрахманның кан басымы бик нык күтәрелгән»,— дигән сүз таралды. Рас булды, ахры, агачлар шыбырдашып яфрак коеп утырганда, явымлы-юеш көндә кабык арбага Арзуны утыртып, Хәбибрахман авылга кайтып керде, тәрәзәсенә аркылы-торкылы кадакланган такталарны каерып ташлады, көне буе ишегалдында уралды...

Арзу белән без бала чактан бергә уралып үскәнгә, аларның авылга кайтуларына мин бик сөенгән идем!..

Хәбибрахман карт ат караучы булып керде, Арзу белән без сугыша-татулаша мәктәпкә йөри башладык...

Арзу «бабаем, бабай!» дип өзелеп торса да, Хәбибрахман карт бер чакта да аңа «кызым, балам» дип эндәшми, иркәләми, бабасының Арзуның башыннан сыйпаганын, тегендә-монда барып күчтәнәч-мазар алып кайтканын хәтерләмим...

Түбән очта Арзу бер иде! Ике яктан ятим, аз сүзле, кырыс бабасы белән генә тора, кайсы йортка барып керсә дә, аның тамагын туйдырырга тырышалар, җылы сүз әйтеп юаталар. Сабан туе көннәрендә иң күп бүләк аңа эләгә!.. Үсә төшкәч, ул матур гына җырлый башлады, аны бик теләп, чакырып җырлаталар, ул җырлаганда карчык-корчыклар шыпырт кына балавыз сыгалар. «Ятим бала шул, моңлы бала!» Әйткәнемчә, беренче башлап Мәүлиха апа аны чит итте. Үз кызлары ишәйгән, үскән саен, ул Арзуны күралмас булды. Аның сәхнәгә чыгып җырлавын «сансызлык» дип, кешеләргә ягымлылыгын «әрсезлек» дип бәяләде...

Без үсә төшкәч тә, Арзу белән дус булдык, бергә уйнадык, көтү каршысына, җиләккә бергә йөрдек. Кинәт кенә безне аерган бер вакыйга булды... Мин Арзуның үземнән бер яшькә олы булуын, җиткән кыз икәнлеген шул чакта гына аңладым... Кәлимулла абый Арзуны клубтан озатып кайта башлады... Абыең кыз белән кайтканда аңа ияреп йөреп булмый ич инде? Үзеннән-үзе аңлашылса кирәк, мин Арзудан читләштем... Кәлимулла абыйның Арзуга күзе төшкән дигән хәбәр әнигә дә килеп ишетелде, иртәләрнең берсендә ул пыр тузды. «Шома Мөлек белән кәнтәй Фатима кызын озатып йөрмәсәң, сиңа кыз беткәнме? Ул кызда безнең халыкка

хас тыйнаклык юк... Әтисе күк шалама тургай булыр, җырлап көн уздырыр... Моннан болай аның янына атлыйсы булма, матри!» диде ул, җылый-җылый... Әти дә Кәлимулла абыйны яклап сүз әйтмәде, киресенчә, күз кырые белән генә абыйга карап-карап утырды...

Әниләр сүзенә әллә ни карамаган да булыр иде, Арзу үзе яратмады минем абыйны! Буйга да кәйрәк иде шул минем абый, сүзгә дә оста түгел, котанрак та...

Менә минем эшләр шулайрак тора әле: Арзу минем укытучым. Бу — бер. Икенчедән... Хәбибрахман абзый усал карчыга кебек аны сагалый! Өченчедән... әни! Әгәр белә калса, миңа якты көн күрсәтмәячәк. Шулар өстенә тагын серле шәүләләр, бозымнар, әллә нәрсәләр килеп чыкты. Мин тәмам аптырауда калдым. Сүз башларгамы? Әйтергәме Арзуга берәр сүз?.. Ул үзе миңа ничек карар да, тирә-яктагы хәл тагын да ныграк болганып, бары челпәрәмә килеп бетмәсме?

«Фронтка китик» ди Рәфгать... Әллә барын ташлап китеп барасы инде?

Ә Арзу?

Яратам ич мин аны! Бик яратам!

## 8

Хәбибрахман абзый белән арамны якынайтырга булдым. Иң элек, нинди юллар белән булса да, аның күңелен күрергә кирәк! Беркөн сыртлап төяп утын алып кайткан иде, бушатышырга кердем, очраганда ерактан ук сәлам бирәм, сүз катып карыйм...

Шушы көннәрдә генә мин аның ялгыз, бик ялгыз икәнлеген шәйләдем. Безнең Җиһангир бабай үлгәннән соң Хәбибрахман абзыйның бер генә якыны да калмады бугай? Авылда аларның кардәш-ырулары күп түгел, иң якын кешеләре Хәбибрахман абзыйның балдызы (ягъни Арзу әбисенең сеңлесе була инде) Гайнекамал карчык та Кәҗә башы урамында. Ул да байтактан тол карчык.

Гайнекамал карчыкның улы Мирзанур комбайнда эшли башлады да тиз ара тернәкләнеп китте, өен сипләп яңартты, лапас-кура тергезде, Түбән авылдан фельдшер кыз Сәкинәне килен итеп төшерде. Сәкинә киленне Хәбибрахман абзый да бик ошатты, ахры, яшь бикәче белән Мирзанур Арзуларга чәй-коймакка килеп киткәли, аларның каладагы сыман, көпә-көндез, якты күздә култыклашып йөрүләрен күреп безнең оч җиңгиләре гаҗәпләнәләр, Мәүлиха апа исә урамга чыгып, артларыннан бот чабып кала торган иде...

Ике йорт арасындагы онытыла башлаган туганлыкны бөтенләй чит кеше — килен кеше яңартты. Килен мунча якса да, бәлеш салса да, олылап, Хәбибрахман картны дәштерә, абзыебызның өс-башы да чистарак йөри башлады, рәис чакта киеп йөргән саргылт вельвет толстовкасын яңадан иңенә салды. Сәкинә йорт эшенә дә искиткеч уңган, тегү-чигүгә дә кулы йөгерек, Арзу аны әнкәсе урынына якын күрде. Аш-суга, төче-мөче, кәлчәмәлчә пешерергә, тегәргә, ямарга, түшәм-сайгак юарга, чигү тотарга җиңгәсеннән өйрәнде...

Сугыш Гайнекамал карчыкның күз текәгәне Мирзанурны да аямады, аны да алдылар, Сәкинә килен дә иреннән калмады. «Мирзанурым белән китәм!» дигәч, Гайнекамал карчык та фатихасын бирде, военкоматта да каршы килмәделәр. «Медперсонал» дигәч, эш шома узды. Карчык улы белән киленен Бөгелмә станцасына хәтле озата барды...

Элек таза гына, чибәр генә йөргән Гайнекамал карчык, көтү каршысына кәҗәсен алырга баргач, карлы-бозлы яңгыр астында калып чыланып кайткан. Иртәгесен янып-көеп егылган. «Үпкәсе шешкән» диделәр. Мәүлиха апа: «Бозым булган Гайнекамалга гөнаһысы күп икән»,— дигән хәбәр таратты.

Хәбибрахман абзый белән Арзу алмаш-тилмәш Кәҗә башына барып йөри башладылар. Беркөнне, һич уйламаганда, Арзу безгә килеп керде. Мин яланаяк кына, чалбар балакларын сызганып идән юып маташа идем. Арзуны күргәч нишләргә белмичә, тиле кеше сыман сүзсез калдым.

— Сездә урак өсте икән,— диде ул.

— Сугыш заманасының һәр көне урак өсте дисең бит үзең!

— Эшең беткәч туп-туры безгә кер алайса. Май әбине алып кайтырга булышырсың.

Май әби дигәне шул Гайнекамал карчык була инде аның.

Миннән бигрәк аның сүзенә әни аптырады:

— И-и, Арзу, олы мәшәкать аласыз икән өстегезгә. Кайсыгыз карар соң аны? Бабай кардыдан кайтмый, үзең мәктәптә,— диде.

Арзуның җавабы әзер иде:

— Икебез дә тырышырбыз,— диде ул.— Бабай да «алып кайт» ди. Үзем дә Май әбине бик кызганам. Кәҗәсен сатарбыз. Безнең сыер бик сөтләч. Кайнар сөт эчертеп, җылыда тәрбияләргә кирәк Май әбине...

Кул арбасына мендәр-күпчеген салып, шулар өстенә

кызыл чаршауга төрелгән төене белән үзен дә утыртып куш йодрык хәтле генә калган Май әбине Кәҗә башы урамындагы суык өеннән Арзуларның җылы түренә күчереп тә куйдык. Карчык, зәгыйфь куллары белән арбага ябышып, як-ягына каранып, оялып һәм читенсенеп кайтты, туктаусыз:

— Ниләр күрми безнең башлар, ниләр күрми! — дип кабатлады.

— Бергә күрә башлар, бергә! — диде Арзу, көләч тавыш белән.

Безнең турыга җитәрәк, каршыга бер атлы очрады. Кожан башлыгын күзеннән күтәрә-күтәрә Гыйбадулла чулак килә икән, без Май әби утырган уфалла арбасын бер читкәрәк чыгарып юл саптык. Гыйбадулла атын туктатты:

— Хи-хи, Гайнекамал әби! Патша тәхетенә менгергәннәр икән сине! — дип көлде.

Май әби:

— Юлыңда бул, юлыңда, шөкәтсез! — дип караса да, Гыйбадулланың китәр исәбе күренми иде. Мин җирдән таза гына чыбык алдым да үшән генә басып торган алашаның җилкәсенә сыдырдым. Ат кушаяклап алга ыргылды, аны-моны сизенмәгән Гыйбадулла дыйк итеп арбага ауды, яман чинап җибәрде, без көлә-көлә арбаны юлга чыгардык.

— Сеңелкәшне, мәрхүмә Миңлекамалны, кияүгә сораган иде бу сасы авыз,— дип аңлатты Май әби.— Әткәй ризалашыр күк тоелгач, мин җылый-җылый ялынган идем... Тәки әрәм итмәдек кызны шушы шөкәтсезгә!.. Шуны һаман оныта алмый йөри... Хәтер бар үзендә тагын!..

Әни, төче катлама пешереп, кич белән Гайнекамал карчык янына кереп китте, чыккач озак кына офтанып утырды:

— Җәй башында орчык күк йөргән кеше коры сөяккә калган икән. Чир нишләтә адәм баласын, кимерә, көйдерә... Үзенең гомере дә бар сыман... Инде тынычланса да җылап калыр кешесе юк... Бер башы... Мирзануры кайчан кайтыр әле... Икәүләшеп җылашып утырдык... Карыйм, мөлдер-мөлдер күз яше ага әле карчыкның... Күз яше — җан тамырыннан чыга, күз яше корымаган кешенең ризыгы бетми аның. Яшәр әле, яшәр. Интегер, башкаларны да интектерер. Арзуга читенгә килер инде. Арзу дигәннән, булса да булыр икән уңган бала! Өйләрен гөл иткән, керсәң чыгасың килмәс, бар җирләреннән тәмле ис килеп кенә тора!

Арзу турында әйткәннәре күңелемә бик хуш булса да,

мин бүген әнигә карап аптырадым: кешенең тынуын ничек теләргә мөмкин? Әллә сугыш вакытында күңелләр катып китә микән? Юкса әни ул сүзне кыеп әйтә алмас иде...

Ятим карчыкны үз янына сыендыргач, Хәбибрахман абзыйга карата күңелем йомшады. Дөресен генә әйткәндә, балдыз ул кадәр үк якын кардәш түгел. Балдызларның баллы чагын — яшьлеген генә ярата җизнәләр! Чирле сөякне үз янына сыендыру, хәзерге такы-токы заманда артык тамакны табынга алу ифрат зур шәфкатьлелек. Күршетирәдә Арзуның дәрәҗәсе тагын да үсеп китте, чөнки карчыкны карауның юан башы аңа төшәчәген барыбыз да аңлый идек. Әмма Арзу исеме телгә алынуга, энәләрен тырпайта торган бер кеше бар иде безнең очта... Һәм берәү генә идеме икән?!

## 9

Кичкырын, Хәбибрахман абзый кардыга төшеп киткәч, Арзуларга кереп чыгарга булдым. Урамга чыксам, коедан ерак та түгел тагын атлы туктаган. Көн сүрән, киче караңгы, юлаучыны башта танымадым, мәгәр күңел шомланып китте. Арба янына җитәрәк таныдым — теге кызыл сакал! «Әһә,— димен эчтән генә,— хәзер миннән алай ансат кына котыла алмассың!» Ул да мине таныды:

— Нихәл? — дигән була.— Ат сугарып алырга иде исәп, коегызга су һаман кайтмаган икән.

— Абзый кеше,— дидем мин, шактый усалланып,— нишләп әле син чит авыл коеларын тикшереп йөри башладың. Кем син? Кая барасың?

Ул ике кулы белән дилбегәгә ябышкан килеш, бер дә кымшанмыйча арбасында бөкерәеп утыра иде, бүреген түбәсенә эшереп, сакалын селкетә-селкетә миңа ачуланып карады:

— Ай-яй, яшь башыңнан күкерт күк кабынасың икән син!

— Бу яңгырда ат эчә димени?.. Ат сугарырга туктамаган син, әйт, кая барасың?

Моннан ары һич көтелмәгән хәл булды, мин аптырап сүзсез-өнсез калдым... Кызыл сакалның иңбашлары калтыранды, зәңгәр күзләре мелт-мелт килде, ул тавышсыз гына җылый иде...

— Хәзерге заманда кеше кая юл тотсын, и надан?.. Нужа куа, нужа! Кеше нужаны куып бара, әйләнеп караса, нужа аның итәгенә ябышкан икән!.. Адәм белән нужа шайтан боҗрасына кергәннәр дә, бер-берсен куалар, бер-берсеннән аерыла алмыйлар.

— Төтен җибәрәсең, абзый кеше,— дидем мин.— Нәрсә кирәк сиңа бу коедан?

— Коеда нәрсә булсын анда, Ходай кошы? — диде ул, җиңе белән күз кырыйларын сөртә-сөртә.

— Синең ише гайбәт капчыклары узып китсә була икән шул! Кая барыш?

Торган саен ачуым кабара барды, мин аның елавына да, зарлануына да ышанмадым. Ул исә, башта кабарынып кына утырса да, соңра йомшый төште. «Сарман ягына барам, кыз кияүдә шунда минем, кияүне солдатка алдылар, кыз биш бала белән калды, үзе чирләшкә, балалары вак»,— дип, хәзерге чор өчен гадәти сүзләрне сөйли башлады. Боларына ышанмый да мөмкин түгел иде.

Кызыл сакал минем шигемне арттырса да, әлегә шикләнүдән уза алмадым, чөнки кулымда бер генә дә төпле дәлил юк иде. Арзуларга ярсып барып кердем, әмма аны-моны сиздермәскә тырыштым...

Арзу алдында мин моңарчы күрмәгән күн тышлы калын дәфтәр ята, ул бик бирелеп китаптан шул дәфтәргә шигырь күчерә иде. Өстендә кыска җиңле юка ак күлмәк, яланбаш. Өйләре җып-җылы, бишле лампа яна.

Мин аның муенының озын һәм гаҗәеп килешле, матур булуына игътибар иттем. Муенының түбән ягында, сулда нәни генә сөйкемле миңе дә бар. Чәчен ике толым итеп үргән дә толымнарын аркылы-торкылы баш өстенә күтәреп куйган, колак янында кап-кара йомшак бөдеркәләре сибелеп тора. Ак күлмәк, алсу йөз, кап-кара чәчләр... Озын, йомшак бармаклары белән дәфтәрне япты да күзләрен тутырып миңа карады... Аның нур тулы күзләре бүген сер белән, мин белмәгән, белергә дә тиеш булмаган ят моң белән туп-тулы иде. Әллә минем керүне яратмадымы? Үзе өйдә булса да, җаны еракта, моннан читтә вакыты идеме аның? Мин комачауладыммы?.. Чыгып китәргә дә, аның янына якынрак барырга да кыюлыгым җитмәде, шулай бер-беребезгә карап, сизелер-сизелмәс кенә елмаешып шактый тордык бугай... Юк, ул мине кумый, киресенчә, елмая, озын керфекләре тетрәнеп китә, бер-берсеннән ерактарак утырган күзләре нидер сөйли, ымлыйлар, ишарәлиләр...

Кыюланып дәфтәр янындагы китапны кулыма алдым: Есенин!

— Каян кулга төшердең моны?

Бишмәтемне, фуражкамны салып чөйгә элдем. Есенин! Без аны ишетеп кенә белә идек.

— Бабай алып кайтып бирде.

— Бабаң? Ул Есенинны беләме? Бу китап үзеңнеке булгач, нигә дәфтәргә күчерәсең?

Бер мизгелгә генә мин үземнең артык кыю, әрсез булуымны сизендем, теге кызыл сакал янындагы кызулык сүрелеп бетмәгән иде шул! Әмма Арзу үпкәләмәде, мин тартып алмасын дигән төсле, дәфтәрне үзенә табарак шудырды, битенә куе кызыллык йөгерде.

— Истәлек дәфтәре бу минем... Син бит егет кеше, көләрсең...

Арзу авызыннан «егет» сүзен ишеткәч, мин шәбәеп тә киттем!

— Сиңа минем хисләр сәер дә тоелыр,— дип дәвам итте ул.— Шигырь күчерергә яратам! Күчергәндә, аңлатып булмый торган тойгы кичерәм. Шагыйрьнең иҗат газапларын күз алдыма китерәм: шушы хәрефләрне үз кулы белән тезеп барган бит ул дип уйлыйм... Шунда мин аның әйткәннәрен, шигырьгә салган йөрәк серләрен ачыграк аңлыйм. Хәтерем әйбәт, күчереп алганда бер очтан яттан да өйрәнеп алам.

Дәфтәргә үрелдем, ул теләр-теләмәсрәк аны миңа бирде.

— Пушкин, Лермонтов? — дидем мин, битләрне тизтиз актарып.

Тукай, Есенин, Такташ, Гейне исемнәре күренде.

— Боларның барын да яттан беләсеңме?

— Белмичә.

Беренче ачылган шигырьне бармагым белән төртеп күрсәттем.

— Яле, Арзу?!

Аның нечкә сызылган борын яфраклары тетрәнеп китте.

Край любимый! Сердцу снятся
Скирды солнца в водах лонных.
Я хотел бы затеряться
В зеленях твоих стозвонных...

Иң ахырдан: «Я пришел на эту землю, чтоб скорей ее покинуть», — дип, шыпырт тантана белән укып бетергәч, без икебез дә тынып калдык. Шигырьне моңарчы белми идем, ул миңа искиткеч ошады, аннан да бигрәк Арзуның күкрәк тавышы, укыган саен аның күңелендә үсә, актыра барган гаҗәеп олы ят хис, зурлык, тугрылык, шулай әйтергә яраса, тиңдәшсез мәхәббәт гаҗәпләндерде. Юк, укымады Арзу, ул җырлап бирде, моңын чайпалдырып түкте, күңел тирәнлегенә мине дә чакырды...

«Лонных» дигән сүзне аңламадым, сорарга да базмадым. Сорасам, шигырьнең бөтенлеген, олылыгын киметер-

мен төсле тоелды. Арзу авыл урамыннан, шушы яңгырлы караңгы кичтән, нигәдер өметсезлек сиздереп искән көзге җилдән, кызыл сакаллар, Сирайлар, Мәүлиха апалар арасыннан йолкып алып мине дә шигърият югарылыгына күтәрде, минем дә аннан ким буласым килми, ул кичергәнне тулаем кичерәсем килә иде.

— Хәтерлисеңме, Искәндәр! «Пионер каләме»нең актыккы битендә Тукайның «Күңелле сәхифәләр» исемле шигыре басылган иде? Менә шул шигырьдән башланды да хикмәт!.. Укыйм мин моны, укыйм, аңламыйм, ни булды? Юк, шигырьне аңлыйм, бик аңлыйм, үземнең хисләремне, күңелемне аңламыйм! Әллә ни булды миңа шулчак!.. Дөнья кинәт һәм берьюлы, тоташтан, җире-күге белән үзгәрде! Мин аермачык итеп Тукайның аучысын, аның сытык чыраен, җыерылган кашларын, җиту сакалын һәм мәҗрух эшләпәсен күрдем! «Ха-ха-ха!» да «Хи-хи-хи!» дип, аннан егыла-егыла көлеп калучы адәмнәрне күрдем, тавышлары колагымда яңгырады... Шунда, кешеләр арасында, мин уйчан-моңсу Тукайның үзен күрдем!.. Шигырьләрнең кодрәте мине үзе белән йотып, суырып алды, онытылдым. Миңа күңелле, ифрат рәхәт иде. Мин бай идем, юмарт идем, чиксез бәхетле идем! Беренче мәртәбә мин үземне кеше итеп, кыз кеше итеп һәм... чибәр, сылу кыз итеп тойдым!.. Шуннан башка шигырьләрне укый башладым... Шуннан китте дә китте! Хәзер исә, әгәр шигырь, матурлык булмаса, мин үксез, бәхетсез һәм гарип булыр идем. Тукай аша Пушкинны таптым, аннан Лермонтовны... Ниһаять, Есенинны. Рус халкын таптым... Хәзер Есенин белән Такташтан аерыла алмыйм.

— Бу дәфтәрне миңа да биреп торчы, Арзу?

— Бик күпне сорыйсың түгелме, Искәндәр?

— Ярамыймы?

— Ярамый дип... Хәер, берәр көнгә генә бирсәм инде. Тик бүген түгел, хәзер түгел! Яз җитсен әле, көннәр озайсын, кояш түргә менеп утырсын. Ул чакта мин ул кадәр үк ялгыз булмам... Яктылыкны яратам мин!.. Бер көнгә генә бирсәм, үпкәләмәссеңме?

Аның минем алда шулай уңайсызланып, ялгансыз кызарып утыруын ике төрле аңларга була иде: серен ачарга уңайсызланамы? Әллә берәрсенә гашыйкмы ул? Күрше кызы булса да, мин аны бөтенләй белми йөргәнмен икән!.. Ул Зәйгә еш барып йөри. Комсомол райкомында пленум члены. Кунып та кайта. Хатлар да ала. Кемнәре юктыр дисең син аның?! Нигә ялгызлыктан зарланып куйды алайса? Ялгызлык шул ук сагыну түгелмени?

Әре бизәкле, түшәмнән идәнгә хәтле төшкән чаршау артында Гайнекамал карчык йөткерә башлады. Арзу йөгереп аның янына китте.

— Берәр нәрсә кирәкмиме, Май әби?

Ул озаклап әбидән нидер сораша, чаршау артындагы сөйләшү пышылдашуга күчә, нидер шылтырый, чыжтырдый, ава... Икесе дә тыелып кына көләләр. Ә мин нишләргә белмим, бер минут, бер секунд Арзусыз торалмам кебек, ишекле-түрле йөренәм...

## 10

Бәрәңге алып бетердек дияргә була. Ал-ялны белмичә тырышуыбыз бушка китмәде: колхозыбыз планны икеләтә үтәде. Колхозны, безнең мәктәпне, Арзуны, Рәфгатьне, тагын берничә кешене район Мактау тактасына керттеләр. Район газетасында аларның рәсемнәре басылып чыкты, җентекләп караганда һәрберсен танырга да була!.. Шуннан тоташ яңгырлар китте. Үзе суык, йогышсыз, теңкәгә тия торган яңгыр. Көтү соң гына чыга да, төш авышуга авылга кайтып та җитә. Җомга көнне безнең сыер кайтмады. Мал-туарны барлап алып кайту сеңлем Нәсимәгә йөкләнгән булса да, бүген, шундый эт йөрмәс көндә, аны басуга чыгарасым килмәде, әтинең кожанын кидем (таман гына, иңе генә бераз киңрәк), билне каеш белән кысып будым, башлыкны күтәрдем дә лачтыр-лочтыр урам сазын яра башладым...

Авыл тирәли әйләнеп чыктым, ардым, чыландым, җеп бөртегем калмады.

Арып, ачыгып өйгә кайтып керсәм, әни лапаста, коп-корыда сыерны савып утыра.

Арзулар капкасыннан җайдаклы берәү чыгып китте. Иске эшләпәсен батырып кигән, чүпрәк ияргә ябышып утырган бу кеше Хәбибрахман абзый иде.

— Кая китте микән ул? — дип сорадым әнидән.

— Арзулар да сыерларын таба алмыйлар әле, күзеңә чалынмадымы? — диде әни.

Әнинең сыер савып бетереп, өйгә кергәнен генә көтеп тордым да Арзуларга юнәлдем, ишегалларын уздым, өйалды ишегеннән башымны тыгып:

— Арзу, Арзу! — дип эндәштем. Өйдән Гайнекамал карчыкның нидер аңлатырга теләп тамак кырганы, йөткергәне генә ишетелде, Арзу, мөгаен генә, өйдә юк иде.

«Нишләп ишекләрен элеп йөрмиләр икән болар? Кич бит инде?» дигән шикле уй күңелемә килде. Хәер, моңарчы да ишекләрендә йозак-мазар күргән булмады, анда-

монда киткәндә дә бик тимеренә агач чөй генә тыгып куялар иде...

Төне буе яңгыр тынмады. Җил көчәйде, кузгатырга мөмкин булган бар нәрсәләргә кагылып, аһылдап, төн йокысын качырып туктаусыз усалланды...

Иртән Арзу мәктәп атын җигеп кайтып керде.

— Бүген минем дәресләргә башка кеше керер, Искәндәр,— диде ул.

— Ә син? — дидем мин, күңелсезләнеп.

— Райком пленумы бүген. Ленинградтан эвакуация белән биш йөз бала килгән, шуларны урнаштырабыз.

— Яңа детдом ачалармы әллә?

— Анысы ишетелми...

— Сыерыгыз кайттымы? — дип сорадым мин, өй түбәләренә тияр-тимәс кенә шуышкан авыр, кара болытларга карап.

— Кайтыр,— диде ул, тезгенен капка баганасындагы боҗрага бәйләп.— Ярты авылның малы таралышкан кичә. Көтүчене күрдем, аптыраган үзе дә! «Әрәмәгә кергән маллар, кигәвен вакытындагы кебек, койрык чәнчеп чабып чыгалар! Әллә бүре-мазар шаярды инде?» дип торды...

Арзу булмагач, Зөләйха апа ике сәгать тарих укытты. Икенче дәресне тәмамларга өлгермәдек, аны чакырып алдылар. Укытучы чыгып китүгә, без дә кузгалыштык. Тәрәзәгә карасам, мәктәп капкасы төбендә Арзу җигеп киткән ат тора. Арзу үзе дә шунда. Ул арада бишмәтен кия-кия Зөләйха апа да аның янына чыгып җитте, алар бер-ике сүз алыштылар да трантаска менеп утырып пычрак чәчә-чәчә юрттырып китеп тә бардылар.

Рәфгатьнең андый чакта елгырлыгы бар шул, белеп тә өлгергән, ишарәләп мине коридорга чакырып чыгарды.

— Кил әле.

— Нәрсә бар?

— Арзуларның сыерын үтергәннәр.

— Нәрсә-ә?

— Сәнәк белән эченә кадаганнар!

— Кемнәр?

Рәфгать тә шуннан ары берни белми икән. Кичкә хәтле, Арзу районнан әйләнеп кайтканчы, чыбыксыз телефон ташыган имеш-мимешләр белән тукланып тордык.

Югары авыл белән Зәй арасында, урта юлга җитәрәк, куе әрәмә бар. Әрәмә, юлны аркылы кискән елга агышына буйсынып, борыла-сарыла төньякка да, көньякка да сузыла, ике яктан да калын-калын урманнарга барып тоташа. Шул әрәмәгә җиткәндә генә Арзуның алашасы

чыгымчылый башлаган. Ул «тизлекне бераз арттыру өчен» чыбык сындырып алырга уйлаган. Трантастан төшеп юл кырыена керсә, нәкъ каршысында, ачыклыкта чуар сыерларының башы күренеп китә. «Монда төн уздырган икән, рәхмәт төшкере... Җилене ничек чыдый икән?» дип, Арзу сыерга таба атлаган... Керсә... сыер үлеп бер читтәрәк ята икән, башын кемдер очлы каен казыгына кадап, юлдан күренерлек итеп кенә җиргә бастырып куйган. Ике мөгез арасына чабата киндерәсе белән язу да бәйләгәннәр. «Сөт тәмле булсын, быржин!»

Авылга тикшерүче килде. Байтак кешене чакырып сөйләште. Кичләрен, минем эчне пошырып, Арзуларга килеп утыргалады, эш чыгара алмады бугай, китеп барды. Ике-өч көн узгач аларның икесен дә — Хәбибрахман абзыйны да, Арзуны да Зәйгә чакырып алдылар.

Районнан килгән тикшерүченең фамилиясе Асылов иде...

Егет кеше икән. Асыловны Арзу белән рәттән күргән саен, күңелем тилмереп-тилереп алса да, беркемгә берни сиздермәдем. Шулай да Асылов хакында, аның килешкилбәте, өстенә ятып торган форма киеме турында Рәфгать белән еш кына сөйләшә торган булып киттек. Рәфгать, киек барын сизенгән ау эте кебек, ярсып-кызып йөри башлады. Ни сөйләшсәк тә сүз сыер вакыйгасына килеп ялгана. Асыловның бер эш тә кыра алмый китеп баруын мин астыртын гына үз файдама борырга телим, сернең ачылмый калуын бары тик тикшерүченең булдыксызлыгыннан гына күрәм, Рәфгатькә эшнең нечкәлеген ачмыйча гына, үземчә, Асыловтан үч ала идем... Чынлап ук тикшерү эвәслегенә кереп киткән Рәфгать бер-бер нәрсә сизендеме, кичләрнең берсендә минем серне «алды». Сүз иярә сүз чыгып, үземнең шик-шөбһәләремне, Мәүлиха апа белән шикле кызыл сакал турындагы уйларымны аңа сөйләп ташладым. Рәфгатьнең кысык күзләре йомылдылар да ут булып миңа кадалдылар:

— Син нәрсә, син нәрсә? — диде ул, гомердә тотлыкмаганны бүген тотлыгып.— Акылыңдамы, юкмы?

— Соң мин...

— Күрәм, соскансың тилебәрән орлыгын! Нигә белгәнеңне Асыловка сөйләмәдең?

Ансат аңа Рәфгатькә! Сөйли аламмы мин боларны Асыловка?

— Нәрсәсен сөйлим? — дидем мин, ярсымаска тырышып.

— Менә миңа бик шәп сөйләдең бит, шуларны сөйлә идең!.. Яшереп йөргән була бит, кара син аны!

— Нәрсә сөйләдем мин сиңа? Йә әйт!

— Күлмәкне таптыңмы? Таптың! Шикле юлаучыны күрдеңме? Күрдең.

— Күлмәкне Арзу тартып чыгарды. Ул тапты. Кирәк икән, үзе сөйләсен иде. Нигә үзе сөйләмәгән?.. Шул-шул менә!

— Каян беләсең? Бәлки, сөйләгәндер дә,— диде бераз юашланып Рәфгать.

— Юк дигәч юк инде. Сөйләми аны Арзу! Син дә телеңне урынында тот.

— Нигә, Искәндәр?.. Җепнең очы, бәлки, шул коеда ятадыр?

— Анысы безнең эш түгел. Арзу синнән-миннән акыллырак...

— Ул хатын-кыз, син ир була бел, егет бул!..

Китте, китте, ике арадагы кызышуның гел бикәргә икәнен күңелләребез аңласа да, бер башлагач, тыела алмадык, байтак әрепләштек. Бер-беребезне ачыктан-ачык гаепләмәсәк тә, авыр сүзләр әйтештек. «Йоклап йөрисең син!» диде Рәфгать. Сизәм, бәхәсебезнең төп сәбәбе — безнең көчсезлек иде. Гаепле кеше, җинаятьче шушында, үз арабызда гына йөри, ә без аны белә дә, таба да алмыйбыз.

Күңел дигәнең шундый икән ул, гаепне бер дә өскә аласы килми, ак эт бәласен ягарга кара эт эзлисең! Мин:

— Асыловны әйтер идем, йөри шунда кукыраеп... Аның урынында булсам, ярты авылны актарыр идем! — дип ычкындырдым.

Рәфгать сабырын җыярга өлгергән иде инде, «Әйдә актарыйк!» — дип әйтерен көткәндә, тыныч кына:

— Җае бардыр аның, тәртибе,— дип куйды.— Теләсә кем, теләсә ничек авылны актара башласа, беләсеңме, ул кая китә?

— Ә бер кеше теләсә ничек авылның котын алып торганда ничек була?

— Монда бер кеше кулы уйный уйнавын,— дип дәвам итте Рәфгать.— Күлмәкне дә ул ташлаган, сыерны да ул чәнчегән!

— Кем?

— Дошман.

— Нинди дошман?

— Аяклы-куллы. Кара эчле. Әллә герман фашистын гына дошман дип саныйсыңмы син? Уяулык турында газеталарда язалармы? Күпме генә язалар әле.

Дошмандыр, анысына каршылыгым юк. Мәгәр бер

нәрсәдә Рәфгать ялгыша: Арзуның көлмәгән ташлау — вак мәсьәлә. Сыер үтерүгә килгәндә, бусы инде чын җинаять! Болар икесе ике кеше эше. Соңгысын, мөгаен, Хәбибрахман абзыйга үч итеп эшләгәннәрдер. Яшен яшәгән кеше, эшен дә эшләгән, дусы-дошманы юктыр дисеңме аның?!

Беркөнне Арзу, безнең класска кереп, үткән дәрес материалларын кабатлата гына башлаган иде, класс ишеге ачылды, зур куян бүрек күренде, бүрек артыннан Сирай үзе килеп керде. Ишек катында таптанып торды да, алап авызын ерып, туп-туры арткы партадагы буш урынга юнәлде. Утырды. Без аптырашып бер Арзуга, бер Сирайга караштык.

— Берәр кешедә йомышың бармы, Хәбибов? — диде Арзу, йомшак кына.— Безнең дәрес монда.

— Беләм,— диде Сирай, парта арасына җайлабрак утырып.

— Белгәч, нигә килеп керәсең?

Сирайның җавабын ишетеп, бөтен класс шаркылдап көлеп җибәрде. Кырык бернең июненнән бирле мондый тоташ, бердән көлүне ишеткәнебез юк иде әле.

— Бәй, укырга килдем лә, күрмисезмени? — диде Сирай һәм куанып, исе дә китмичә безгә кушылып хихылдый башлады.

Күздән яшь чыкканчы, эчләрне кату алганчы көлдек. Яшь мөгаллимәбез, башта көләргә дә, көлмәскә дә белмичә, берсүзсез карап-карап торды да безгә ияреп көлә башлады.

— Нигә, ярамыймы әллә? — диде Сирай, гаярьләнеп башын артка ташлап.

Арзуның тиз генә сер бирмәве безгә ошады.

— Нигә ярамасын, ярый,— диде ул.— Тик, уйла әле, син классларны бутагансың шикелле!

— Бутамадым. Минем монда укыйсым килә... Уку ягына килгәндә, куып җитәм мин аларны, күрерсең.

Безнең кызлар Сирайны күрсәтешеп нидер пышылдашалар, көлешәләр, аның һәр әйткән сүзе көлеш учагына май була бара. Арзу, тәҗрибәсез булса да, тиз үк аңга килде.

— Булды. Күңелләрне ачтың, әмма син дәресне бүлеп торасың, Хәбибов,— диде.

— Соң син миңа карама, укыта бир... Мин дә тыңларга килдем.

Бусы инде оятсызлык иде.

— Кабатлап әйтәм, син безгә комачаулыйсың.

— Ничек алай? — Сирайның ирен читләре юешлән-

де.— Нигә комачаулыйм? Мин укырга килдем. Укыйсым килә... Юлда яткан ташмы мин комачауларга?

— Ахыр чиктә, синең уку-укымау мәсьәләсен мин хәл кыла алмыйм, бар, директор янына кер. Зөләйха апа монда гына.

— Ярамый дисең инде? — Аның өстендә калын сары тун, муенында кәҗә мамыгыннан бәйләнгән калын шарф, тирли үк башлады егетең, маңгаена бөрчек-бөрчек тир сибелде.— Мине дурак, дисең? Надан, дисең? Шушы Дындыптан да наданракмы инде мин?

Класс тып-тын калды, чебен очканы ишетелерлек иде. Соңгы вакытларда никрутлар сафында военкоматларга йөри башлагач, кушаматын ишеткәндә Рәфгатьнең кәеф бик каты кырыла иде. Монда класс, кызлар алдында ничек түзеп утырырга кирәк?.. Шартлап ярылыр дип көткән идем, Рәфгать ярылмады, иреннәрен кысты, чыраена кара коелды. Аның каравы Арзу кыза төште:

— Чык класстан,— диде ул, нык итеп.

— Чыкмыйм,— диде Сирай, партага чытырдап ябышып.— Укырга килдем. Тыярга правогыз юк. Мин дә кеше.

Анда да, монда да Сирайның кыланышыннан ачулы авазлар, сүзләр яңгырады:

— Өреп чыгарырга кирәк аны!

— Тапкан уен!

— Тинтәк!

— Тыймыйм, укы,— диде Арзу, сабыр гына.— Тик укуның үз тәртибе бар... Алтынчыда туктадыңмы әле син?

— Хәзер сугыш заманасы. Нәрсәгә миңа алтынчы? Алтынчы бетләре белән утыртыр идеңме әллә мине оялмыйча? Миңа унынчы булсын. Аз да түгел, артыгы да кирәкми.

Ниһаять, Рәфгать дерт итеп урыныннан купты, мин дә сикереп тордым.

— Яле, тай моннан,— диде Рәфгать, Сирай янына басып. Мин тун җиңеннән умырып тоткач, Сирай тунын сала-сала парта арасыннан чыкты.

— Йә сук! Сугып кара! Сук-сук! Мәктәпкә килгән өчен сугып кара.— Үзе безгә эндәшә, үзе каш астыннан гына сөзеп Арзуга карап тора.— Шкулдан очырырлар, укытучы җитми дип тормаслар...

Икәүләшеп йолкыйбыз, тегермәнче малае егәрле, Рәфгатьне кагып кына җибәрде, без әүмәкләшә үк башладык, Арзуның класстан чыгып китәнен дә сизми калганбыз. Төрле яктан яңгыраган тавышка баш калкытып

карасак, классташлар безне сырып алганнар, арада кызыкның дәвам итүен теләүчеләр дә табылды, алар ачыктан-ачык Сирайны котырталар, көләләр, күпләр Рәфгать белән миңа көч биреп тора.

— Ябышма диләр сиңа!

— Чыгып кит, тегермән күсесе!

— Ә-ә, күсеме? Нәрсәңне кимергән? Йә әйт! Сирай минем касыкка китереп төртте, мин дә аңа берне ямадым. Ашыгып Зөләйха апа белән Арзу килеп керде, класс тынып калды, Сирайның тимерче күреге күк мышнаганы гына ишетелеп тора. Зөләйха апа усаллыкта ирләргә биргесез хатын, моны Сирай да белә, шуңа күрә директор керүгә шиңеп, башын түбән иде. Зөләйха апа ипләп кенә килде, борчак күбәсе хәтле куян бүреген идәннән партага алып куйды да күзенә карап:

— Эчеп килдеңме әллә? — дип сорады.— Сала диләр сине, Хәбибов. Нәрсәгә тавыш чыгарасың?

— Минмени? Алар бит! — диде җыламсырап Сирай.— Алар!..

«Алар» сүзен шундый тирән нәфрәт белән әйтте Сирай, бер мәлгә аптырашып, бер-беребезгә карадык...

— Үртиләр,— дип дәвам итте Сирай.— Урамда очрасам да буш уздырмыйлар... Дындыбы да шул, Искәндәре дә... Аулак өйгә кертмиләр. Клубка менсәм, такмак чыгаралар. Нәрсә мин? Тиле Миннәхмәт артыннан таш атып калалар... Миңа да шул гына каламыни?! Мин андыймы?.. Алар унынчыда, янәсе... Булсалар ни?..

Зөләйха апа кызып килеп кергән иде, Сирайның сүзләрен ишетеп, ул да бераз сабырланды, алай да дилбегәне кулыннан ычкындырмады:

— Укуны ташлагач ничә тапкыр өегезгә бардым? Әтиеңне чакырттым. Онытгыңмы?

— Бәләкәй чакта бөтен кеше дурак була,— диде Сирай.

Ул кинәт юашланды, үзгәрде, тырышып-тырышып нидер аңлатырга, төшендерергә маташты, аннары, ниятенең өметсез икәнлеген аңлагандай, кулын селкеде, мышный-мышный тунын киде, күзен елтыратып бүлмәдәгеләрне карап чыкты, бүреген идәнгә тиярлек итеп селкә-селкә чыгып китте.

Дәреснең барыбер рәт-чираты булмады, Арзу да тәртип урнаштыра алмады, азакка таба Рәфгать миңа: «Кигәвен тешләгәнме әллә бу Сирайны? Нигә килеп керде икән?» — дип язып җибәрде. Шул турыда баш ватып утыра идем, Рәфгатьнең соравы борчулы уйларымны күбәйтеп җибәр-

де. Арзуның аз сүзлелегенә, гадәттән тыш җитдилегенә карап: «Ул да шушы сорау белән газаплана түгелме?» — дип уйладым.

Кич белән Сирайны мин тагын очраттым, ул Мәүлиха апалардан чыгып килә иде. Ул уң кулын иңбашыма салып мине үзенә табарак тартып китерде һәм сасы аракы исе куша-куша:

— Бик кирәге бар иде мәктәбегезнең... Надан булсам да, мин сездән акыллырак! Сугыш бит ул шундый нәмәрсә... яши белсәң яшәтә, яши белмәсәң... әйдә... фьют!.. Минем кебек берегез дә яши алмый!.. Берегез дә! — дип сөйләнде.

Мин көч белән аны читкә кактым һәм ашыга-ашыга кереп киттем. Болдырга менгәч борылып карадым: Сирай урыныннан кузгалмаган, Арзулар тәрәзәсенә карап каткан да нидер көтә иде...

## 11

Безнең елгыларны тагын военкоматка чакырдылар. Ишетүгә әни балавыз сыга башлады. «Соңгысын алалармы? Соңгысынмы, ә?!»

Рәфгать безгә керде, иртән иртүк кардыга төшеп киттек. Чаңгы белән генә элдермәкче идек, соңгы көннәрдә рәттән каты-каты бураннар булып торды, бөтен җир — урам-тыкрыклар, басу юллары ап-ак кар көртләре астында күмелеп калды... Унике чакрым! Яңа кардан эз салып шулхәтле җирне узу алҗыткыч булачак, шуны уйладык та, никрутларча әрсезләнеп, председательдән ат сорадык...

Каравыл өе янындарак Рәфгатьнең туганнары яши, йомышы бар икән, ул аларга кереп китте, мин җилдән ышыкланып каравыл өе янында берьялгызым басып калдым. Өйалдында ике ир кеше сөйләшәләр иде. Башта үз уйларым белән мавыгып мин аларга игътибар да итмәдем. Ирләрнең берсе Мәүлиха апа исемен атагач, сагаеп тыңлана башладым. Тавышларыннан таныдым, Гыйбадулла чулак белән Сирай сөйләшә иде.

— Май кап, май! — диде Гыйбадулла.— Май капсаң, озак яшәрсең!

— Майны кабам анысы, Гыйбадулла абый...

— Мин сине бер чакта да юньсезлеккә өйрәтмәдем, хәзер дә ялгыштырмам!.. Ак мамык кебек кыз, сиңа ни кирәк тагын? Син анда булсаң, миңа да җайлырак булачак... Барып йөрергә дим...

Гыйбадулланың сүзләрен аңлап булмый башлады, ул бик бирелеп, ышанып Сирайны үгетли, тегесе карышып маташкан була, шул ук вакытта риза икәнлеген дә сиздереп куя.

Рәфгать чыгып миңа кул болгады, теләр-теләмәсрәк атлап аның янына киттем. Сирай турында сүз башларга гына торганда, мышлый-мышлый үзе безне куып җитте.

— Мине дә утыртып барасызмы?

— Әллә сине дә чакырдылар?

Бер сүз әйтеп булмый башлады бу егеткә, шул сүзебезгә бәйләнә калды бит! «Юньсезләр сез» диде. «Кансызлар!» дип бетерде. Кәефләнеп кенә атлый башлаган идек, тәмам ачуны чыгарды, сөйләшмәс булдык. Җитмәсә, төшә-төшүгә, Хәбибрахман абзый Сирайга ябышты.

— Сиңа ат бирмим,— дип кырт кисте ул.

— Кем чыгарган закун әле бусы? — диде Сирай, бүртенеп.

— Бирмим дигәч бирмим.

Болай да бүселеп, ачуланып төшкән Сирай кып-кызыл булды:

— Бирерсең, бирми кара,— дип янады.

— Янама,— диде Хәбибрахман абзый, сабыр гына.

— Син быржиннан сораган кеше дә юк. Мин никрут, хөкүмәт кешесе, йөгерә-йөгерә җигәрсең!

Рәфгать, Сирайны жәлләп:

— Йә инде, Хәбибрахман абзый,— дип ялынып карады. Әмма картның тынычланыр исәбе күренми иде:

— Егетләргә дә утыртмаска кушам. Шәт, олы кешенең сүзен җиргә салмаслар... Утыртып бармагыз шул мөртәтне!..

— Нигә алай? — дип сорадым мин, аптырап.

— Шулай. Ул гыжлауны барыбер солдатка алмыйлар... Гыйбадулла чулак белән тәмәке суы эчеп яталар бит алар. Нигә гыжлый дисең?..

Хәбибрахман абзый дөресен әйтә, ахры, каян белгән диген! Сирай бер мәлгә аптырап, югалып калды, аннары, тегермәндә төрле бәрелешләрдә шомарган икән каһәр, ырлап Хәбибрахман абзыйның якасына ябышты:

— Каян күрдең? Падсуд җибәрәм мин син быржинны!.. Теге чакта нефть базасын яндырып чүт кенә өтермәнгә бөтереп тыкмадылар үзеңне! Хәзер котыла алмассың!..

Хәбибрахман абзый Сирай янында колга буе, җиңел генә аны селтәп җибәрде дә, безгә аңлатып бирде:

— Узган атнада бер атны яндырып кайтты инде. «Пи-

гәш»не. Кая барганын да әйтми. Нишләп йөргәнен белгән кеше дә юк.

Ул да булмады, Сирай атылып килеп Хәбибрахман абзыйның яңагына чалтыратып та җибәрде:

— Син... син... Атларны юньләп карамыйсың! Фураж карагы! Бур син! Бирмәс иде бугай!.. Кулың кыскарак шул! Синең замана узган инде, безнеке замана. Җитәрлек кан эчтең, быржин!

Хәбибрахман стенадагы агач чөйдән дуга алып Сирайга кизәнде. Рәфгать түзмәде, алагаемга Сирайга китереп орды, чана үрәчәсенә барып төште малаең. Мин дә берне өстәгәч, ул бераз юашланып калды, торып тун итәген какты.

— Син нәрсә, атаң күк кешегә кул күтәрәсең...

— Атаң... Атаң шундый булса,— диде ул һаман явызланып.

Тагын тыпырчына башлаган иде, башын култык астыма кыстырдым да баш бармакны батырып чәчен кирегә сыдыра башладым. Бик тиз акылга китерә ул кайберәүләрне!..

Барыбыз да чак тынычландык...

Өчәү чанада барабыз. Җирән бия шактый көр булса да, чананы авыр тарта, уйсу урыннарда гына түгел, кашлакта да тирән кар ята. Түбән авылның озын, тын урамын узганчы сөйләшми-нитми генә бардык. Рәфгать белән әллә ниләр гәпләшер идек, чанада Сирай бара, чанада минем ачу, нәфрәт бара.

— Озаталар безне, егетләр! — диде Рәфгать, калкынып.— Ипидер шуңа чакыралар!

— Озатырлар дисеңме?

Тегендә, карды ишегалдында, кыдрач әтәч күк кабарынган Сирай «озаталар» дигәнне ишеткәч сүнде, сүрелде:

— Алырлар дисеңме, малай? — диде ул, чак өнен җыеп.

— Алалар дигәч алалар! — дип куәтләдем мин Рәфгатьне.

— Мужыт язга тиклем ашыкмаслар?

— Алмасалар, үзем китәм, доброволь булып!

Рәфгатьнең шаярып сөйләшмәгәнен мин генә түгел, Сирай да сизә.

Җирән бия пошкырып-пошкырып куя. Тирә-юньдә күз камашырлык аклык. Офыктан чак кына аерылган кояш, үги кыз кебек керфекләрен сүрән генә уйната.

— Ярый ла син төз атасың,— дигән булды Сирай.— Биш патронга кырык җидене җыйдыңмы әле? Минем кул кәкере, тигерә алмыйм.

— Күгәрченнәрне мелкашкадан кыеп кына төшерәсең диләр бит!

— Кем әйтә? Күрсәт миңа шул йолкышны! Чыраен умырып алып казык башында элеп киптерәм!

Тагын бераз чана шыгырдаганын тыңлап бардык, Сирай һич кенә дә тик ята алмый, боргалана-сыргалана, тамак кыра.

— Рәфгать яшьти,— диде ул чыдары беткәч,— унынчыларга брүн ди бит, алмыйлар, ди, аларны, укытып чыгаралар, ди.

— Кем әйтә?

— Кем дип... сөйлиләр инде! Гыйбадулла абый да ишеткән.

— Чулак сөйләр ул... Тел сөяксез.

— Алай димә, яшьти. Районда әллә кемнәрне белә ул. Аны да беләләр. Пужар начальнигы аның первый әшнәсе...

— Көмешкә чөмергәндә әшнәдер...

— Көмешкә эчми ул, корсагына ярамый! Аңа чиста аракы булсын!

Сирай үзенең артыграк ычкындырганын сизеп туктап калды, озак кына уфылдап, әйләнгәләп ятты.

— Кемгә брүн кирәктер, миңа бирсәләр дә алмыйм,— диде Рәфгать, кыска гына.

Җәй киткәннәр: «Көз кайтырбыз!» — дип хушлашканнар иде. Көз киткәннәр: «Кышка безне көтегез!» — дип саубуллаштылар. Кыш башындагылар: «Язгы чәчүне бергә чәчәрбез!» — дип киттеләр. Хәзер китүчеләр анымоны әйтми генә китеп бардылар, сугышның ил өстенә килгән чагыштырмасыз зур афәт икәнлеген, без уйлаганга караганда күп мәртәбәләр җитди, авыр булачагын хәзер барыбыз да белә идек.

Бүгенге чакыруның да бушка гына түгеллеген дөрес чамалыйбыз. Рәфгатьнең шулай үҗәтләнеп Сирайны үртәп баруы да аңлашыла... Ирештерә торгач аз-маз ачылды малаең, Гыйбадулла белән сердәш икәнлеген дә таныды. Иш ишен таба, диләр бит. Никрут Сирай белән Гыйбадулла иш икән, нәрсә дуслаштырган аларны?

Китүчеләр, калучылар турында сүз купты, искәрмәстән, кызлар турында сөйләшә башладык. Сирай, карап торуга бозау гына, Түбән авылның Кәбир кызы Мөгыйнә белән йөри икән. Авызыннан төкерекләрен чәчәчәчә, дөньясын онытып, кинәнеп сөйли башлады: «Әткәсе белән тегермәнгә килгәннәр иде, әле язлыкта, кеше мыж! Төнгә калдылар болар... Әткәсе келәт алдында агайне белән тәмәке пыскытып утыра, ә мин

кызны шомырт агачына посырдым... Шунда агач арасында кочып үптем, малай... Имиләре, имиләре! Шалкан да шалкан, бу да шалкан... Кулны аскарак та төшермә келим, җибәрми, малай!»

Мактанырга, шапырынырга җай чыгуга Сирай бик шатлана иде, искәрмәстән, минем янтыкка нык кына төртте дә:

— Искәндәр яшьти, сиңа үч бар әле! — диде.

— Нинди үч?

— Бер тапкыр таш белән маңгайны яра язган идеңме?

— Кайчан? — дидем дә телемне тешләп тыелып калдым. «Ә-ә-ә!» дигән фикер күңелемдә яшен ташы булып сызылды.

— Кайчан икәнен үзең бел,— диде мактанган сыман Сирай.

— Хәтерләмим.

— Әй, хәшәп, шуны оныткан! Көзлектә Арзу артыннан иснәнеп кайткан идеңме? Күрмиләр ди бугай, әй кайта инде бүлтерек бәрән күк терек-терек! Үзе курка тагын, биш чакрымга артта калган!..

Менә сиңа мыштым Сирай!

— Кое бурасы артында син идеңмени ул?

Ул канәгатьләнеп көлеп җибәрде:

— Мин булмыйча, койрыклы җен йөрсенмени анда? Туңыбрак бара идем, кан тамырларыма кайнар кан йөгерде.

Рәфгать тә сызгырып куйды:

— Менә сиңа әбиеңнең кабармаган камыры!— диде ул.

Сирайның сүз буасы тагын ерылды:

— Нәрсәкәй, әллә мине урамыгызда йөртмәс идеңме? Ким дисеңме? Арзу үземнеке дип уйлыйсыңмы?..

— Кемнеке соң? — дип ычкындыруымны абайламый да калдым.

— Кемнеке дип... Теге чакта алышкан идекме? Синең тез капкачың аерылганда?.. Уртага Арзуны куйган идем мин! Син җиңелдең!..

— Әллә Арзуга өметләнә инде бу кеше? — дип көлде Рәфгать.— Мөгыйнә җитмәгәнме аңа?!

— Миңа Арзу кирәк! — диде чатнатып Сирай.— Яратам мин аны. Белдегезме?.. Бабасы булмасамы?.. Бабасы аркылы төшә!.. Мине сугышка алмыйлар, үпкәдә бар минем. Сез китәсез... Арзуга кул салырлык нинди егет кала авылда? Кем миңа аркылы төшә ала?..

Ишетмәсәң ишет, Искәндәр!.. Менә эшләр кая таба китте!..

Арзуны үземнеке итеп санарга уйларымда, хыялларымда да кыймый идем мин. Кая ул телдән үк шундый йогышсыз сүз әйтү! Мин аны аяклы-куллы гади хатын-кыз итеп түгел, илаһи бер югары зат, тиңдәшсез олы итеп санап йөрим. Кичләрен, йокы алмый яткан газаплы мизгелләрдә, ул миңа таңгы нур көлтәсе, кечкенә шәфәкъ, күз явын алырлык кыңгырау чәчәк бәйләме, сары такыя булып, салават күпере төсле елкылдап кына күз алдыма килә иде. Шундый илаһи кешене, Есениннарны, Такташларны юлдаш иткән кешене «синеке, минеке» дип ничек бүлешеп барырга мөмкин?!

Җитмәсә, «синеке түгел!» диләр бит әле... Кем әйтә диген...

Ике бозауга кибәк аера белмәгән бер апара корсак...

Арзуның ал битләре, чем-кара күзләре күренеп киткәндәй булды... Сикереп тордым да Сирайга акырдым:

— Син маташтыңмы Арзуны бозарга?

— Ничек? Нишләп бозыйм ди мин аны?.. Бозым белән пычагымны кырырсың бик... Егете бар аның. Йөргән егете.

— Кем? — дидем мин, гаять гарьләнеп.

— Сары төймәле егет килгән идеме? Асылов. Мәскәүдә югары укуда булып кайткан, син-мин түгел, партийный. Арзуның егете шул. Әллә ничә тапкыр Зәйдә күрдем үзләрен. Берсендә ак чиркәүдән кинодан чыгып киләләр иде.

Сирай янында үземне бик олыга куеп барсам да, Асылов исемен ишеткәч, мин артка чигендем... Сирай белән без бик артта калдык, алгы планда Арзу янәшәсендә япа-ялгызы Асылов калды.

Озынча буйлы, ябыграк гәүдәле, зур, акыллы күзләрен тутырып карап, йомшак тавыш белән ашыкмый-кабаланмый сөйләшә торган, өр-яңа затлы киемнәр кигән Асылов янында мин үземне янымдагы Сирай рәвешендәрәк күрдем. Арзу янына Сирайны бастырып мин ниләр уйлый алсам, шундый ук эшне Асылов та эшли ала, бу юлы кызганыч кеше хәлендә мин үзем кала идем...

Мин тындым, Рәфгать кенә басылмады, ул Сирайны кат-кат кысып карады, юмалады, янады, әмма тегермәнче малае терәлеп каткан иде: «Юк! Бозымны-мазарны белмим. Батырмагыз мине, буямагыз! Ә Асылов турында әйткәнем хак! Тегермәндә анда информбюроң бер якта торсын! Барын беләләр! Бырҗиннарның сыерын суйганнан бирле шәп тәтелдиләр анда!..»

Рәфгатьнең юравы юш килмәде: безне әлегә алмадылар. Үзебез китәргә дәртсенеп, военком янына кердек. Елмайды майор, урыныннан торып, аркадан какты. «Көне-

сәгате җиткәч чакырырбыз, әлегә тырышып укыгыз, Кызыл Армиягә белемле егетләр дә бик кирәк»,— дип озатып җибәрде.

Эленке-салынкырак булса да, тагын мәктәпкә йөрибез. Рәфгать белән көннәр буе бергә аралашсак та, электәге татулык, эчкерсезлек юк арада хәзер. Юк кына нәрсә өчен дә әләгешеп киткәлибез, Рәфгатьнең сүзе бер генә: ул мине ваемсызлыкта, боламыклыкта гаепли.

— Ак белән караны аера алмыйсың... Хәбиб малаен чанадан сугып та төшерә алмагач, егет булып йөрүең корсын! «Юк» дисә дә бозымны ул салган! Бозымга, сихермихергә ул наданнан башка кем ышансын!.. Теге кызыл сакалны да авыл советына тарттырырга иде! Үзе «шыпион» түгел микән?!

— Дәлилең юк килеш закон каршына кешене ничек бастырасың дип карыйм, сүземне колагына да элми.

— Көт алайса дәлил! — дип кенә җибәрә. Аның ялгызы гына райкомолга барып кайтуын, фронтка ашкынуын Арзу кайтып әйтте. Рәфгатьтән: «Нигә миңа әйтмичә киттең?» — дип сораган идем, «Куркак ич син!» — дип авызымны йомды.

— Син батыр булып ни кырган? — дип мыгырдандым.

— Сөйгән кызы өчен бер тапкыр булса да канга-кан тузышмаган егет егетмени ул?!

— Нинди сөйгән? Кем?

— Куркак булу өстенә ялганчы да икәнсең әле син, Искәндәр!..

Рәфгатькә мине табаларга җай гына чыгып тора, дүшәмбе көн мәктәпкә барсак, кайсы явызыныңдыр безнең класс тәрәзәсеннән ике олы өлге пыяла урлап китүе мәгълүм булды. Ике көннән соң, тагын шулай төнлә, өч зур өлгене алып китteләр. Ашыкмаганнар, курыкмаганнар, ипләп кенә алганнар да сызганнар. Зөләйха апа, директорыбыз, ашыгыч боерык чыгарып, укытучылардан һәм өлкән класс укучыларыннан мәктәптә даими төнге дежурлык билгеләде.

Бер караганда, артык мәшәкать булса да, ул дежурлык дигәннәре яшь-җилкенчәккә мач та килде әле! Аулак өйләрдә утырганны әнием яратып бетерми иде, хәзер, теләгән саен, «дежурга барам!» дисең дә, чыгып китәсең. Арзу анда чакта мәктәптән кайтып кермим, үзебезнең класс кызлары өчен дә калгалыйм. Әни шиккә төшеп беркөнне дулап та алды:

— Бу ни бетмәгән жужур булды инде, тәмамысы язгы бизгәккә әверелде! Син анда, матри, Фатима кызы белән

кыҗыр-быҗыр куерта күрмә... Абыең абына язды, синнән дә ерак йөрмәс, күзләрең бик елтырый... Алтын-көмеш яксалар да Фатима кызы Фатима кызыдыр инде. Нәсел — нәсепкә, тилчә — тамырга... Алма агачыннан ерак тәгәрәмәс...

Әни кадәр энидән шундый нахак сүзләр ишеткәч үтә рәнҗедем, кычкыра башлавымны сизми дә калдым:

— Мин аның әнисен белмим! Әгәр ул әшәке кеше булган икән, Арзу үз агачыннан ерак тәгәрәгән алма. Аны бабасы карап үстергән... Ул... Ул...

Әни дә миңа аптырап карады:

— Чү, чү, балам, кычкырма... Сугыш әллә нинди бәлаказалар чыгара ул. Язгы ташкында бөтен чир-чор, чүпчар купкан кебек, сугыш заманында юлдан читтә яткан таш та кыймылдый, ди иде синең бабаң!.. Бу араларда бозым ише нәрсәләр турында еш ишетелә, бозмаганнардыр ич сине?.. И-и Аллам...

Чуклы чүпрәк белән песи баласын ирештереп идәндә кайнашкан Нәсимә, купшакланган танавын тартып:

— Беләм инде, беләм! Арзу апа Искәндәр абыйга яулык чигеп биргән! — дип чәрелдәде.

Нәсимәнең борынына нык кына берне чирттем, теләсә кая сузмасын. Ул шыңшып калды, әнидән оялып ишегалдына йөгереп чыктым. Яланөс кенә утын яргалап ташладым; кызып китеп Рәхимҗан бабайларга барып кердем, көздән бирле ишегалларын тарыктырып, күзгә кереп яткан карама түмәрләрен ваклап, лапас астына ташып өйдем. Хәтимә апаның да, Рәхимҗан бабайның да исе китте, чәйгә дип бик кыстаганнар иде, кермәдем... Аркам манма су булды, ә балтам, ышанасызмы, ут кебек кызган иде, үзебезгә чыгып җиргә ташлавым булды, кар чож итеп куйды...

Авыл арасында «чиккән яулык» дигән сүз тараткannar икән... Нәсимә юеш борын берәрсеннән ишетеп калып сайрый аны. Мин чынлап торып халык теленә керерлек, Арзу исеме белән исememne янәшә куеп йөртерлек егет булганмын икән!.. Ә Асылов? Ә Сирай?.. Ә мин белмәгән «бозучы»! Алар бу мәсьәләгә ничек карарлар?!

Юк, Рәфгать ялгыша... Тукмый ала идем мин Сирайны. Нык ук бирә идем. Военкоматта: «Тезе тотмый ич аның, шырт итә дә ычкына!» — дип лыгырдаганы өчен генә булса да, җир күмере ясый идем... Шулай да тимәдем: ни гаебе бар аның? Сөйләнә икән, сөйләнсен, тел сөяксез! Арзу дип безне үчекләп кенә барды ич ул. Кое янында без очраклы гына туры килешкәнбез. Алар Гыйбадулла белән ачы бал чөмереп Мәүлиха апалардан чыгып киләләр икән, мине абайлаганнар. Гыйбадулла аяк

чалып мине тәгәрәткән, Сирае чишмә сукмагы буйлап элдерткән. Ничек күрмәгәнмендер мин аларны, анысын һичничек аңлата алмый идем.

Юк, юк, Сирай Арзуга гыйшык тота дип әйтергә телем дә бармый!

Юк, юк!..

Димәк, гыйшык юк җирдә нәфрәт каян булсын? Сирайга кул күтәрә алмадым, Рәфгать теләсә нәрсә әйтеп сүксен, кыйнамадым апара корсакны, жәлләдем.

Минем шөбһәләрне ачыклагандай, нәкъ Яңа ел алдыннан, җомга кичендә, Мәүлиха түти көмешкә эчеп шактый мәлҗерәгән Сирайны үзләренә ияртеп кайтты. Кәримә белән икесенең туен озак тотмадылар. Сирайның әнисе сәке йөзлегенә ябышып елый икән, дип сөйләсәләр дә, Мәүлиха түти кияүдән бик канәгать иде.

— Аллага мең шөкер, ихлас күңелле егеткә тап булдык. Кәримәнең аяк арты җиңел булсын,— дип, өй борынча шатлыгын уртаклашып йөрде.

Сирайның солдатка китәр алдыннан гына ишле гаиләгә йортка керүе акылга сыеп бетмәсә дә, без, Түбән очлар, аңлый идек: Мәүлиха түтиләр ир-атсыз яши алачак түгел, кыш уртасында суыкка ябышып катачаклар. Тик менә нигә Сирайны сайлады Мәүлиха апа? (Кәримә дип әйтергә һаман телем бармый!) Горур, үзенә күрә тәкәббер, һавалы Кәримә ничек аңа чыгарга ризалашты? Түбән очның «яшь әтәчләре» яшелле-мөшелле тавыш белән:

Чүке болынында оча
Аллы-гөлле күбәләк.
Кызы озын, егете кыска —
Үбешәләр чүгәләп! —

дип такмаклап узганда, ничек түзде?

Озакламый бу табышмакка да азмы-күпме ачыклык керде. Сирайны армиядән бөтенләйгә калдырып торалар икән, дигән хәбәр таралды. «Ындыр артыгызга фронт килеп җитсә генә сине обозга алачаклар, егет»,— дигәннәр, имеш...

Гыйбадулла чулак: «Сирайны солдаттан бер оя үрдәк алып калды. Үрдәкләрнең шулай, көчле булуын беренче тапкыр күрүем»,— дип сөйләнгән, имеш.

Авыл халкы бусына ышанып та бетмәде, шундый юкбарларга оста иде шул алдар Гыйбадулла!

Сирай безнең оч кияве булды. Иртән дә, кичләрен дә очрашып торабыз диярлек. Икәүләшеп коеның өстен ачып ташладык, ул аска төшеп чиләккә тутырып торды, мин түктем — коены күңел булганчы чистарттык.

Нык эшли малай, сүз дә юк, мин аның җаена чак-чак өлгерәм.

Коедан чыккач, аның ниндидер яшерен сагыш белән Арзулар тәрәзәсенә карап торганын сиздем... Шушы мокыт Сирайда да никадәрле сер бар бит, уйлап карасаң!..

## 12

Төнге уннар чамасымы, әллә унберме? Беребездә дә сәгать юк, мәктәп ихатасы тирәли байтактан йөрибез. Алдан Арзу бара, аның артыннан тар сукмактан Рәфгать белән этешә-төртешә без атлыйбыз. Салкын. Чалт аяз төн. Купшы күк үзенең бар булган алтын-көмешләрен таккан, япанчасына энҗе-мәрҗәннәрен сипкән, бизәнгән. Офыклар гына көрәнсу кара, тар гына ай урагы офыкларны яктырта алмый...

Йолдызлар атыла. Без «әнә!» дип бер-беребезгә йолдызларны күрсәтергә ашыгабыз, минем, нәкъ сабыйларча, йолдызларны күбрәк һәм Рәфгатьтән алданрак күрәсем килә...

Төнге дежурлык куелганнан бирле мәктәп тәрәзәләренә кагылмыйлар, утынын да урламыйлар...

Өченче көн этидән хат килде, Калинин фронтында икән.

*«Безнең хәлләрне гәҗитләрдән укып беләсездер, шул бер чама, сугышып ятабыз... Кышкы суык бик яман, ну, немецны да куыра. Үзегездә ни хәлләр? Искәндәрне алмадылармы әле? Безнең янга алар елгылар кила башлады, хәере белән булсын азагы. Барыбер җиңеп кайтырбыз»*,— дигән...

Бездә ни хәлләр? Яңалык шул икән, этигә язасы булыр. Атна элек кенә Гайнекамал әбине җирләдек. Мантымады бичара, Арзу ни тырышты, җилкәсендә күтәреп алып барып эссе ләүкәдә мәтрүшкәле-бөтнекле себерке белән чабып карады, юкә чәчәгеннән ясалган төнәтмә парында сәгатьләп утыртты, авызыннан сары майда кетердәп пешкән коймак өзмәде, балдан-майдан мәхрүм итмәде, барыбер карчыкның җанын саклап кала алмады. Зурлап күмдек...

Хәлләр шул, агач мылтыкларны асабыз да чаңгыга басып, Басу арты урманыннан әйләнеп кайтабыз. Авылга кергәндә агач гранаталар ыргыта-ыргыта, «ур-ра!» кычкырып чапкан булабыз... «Их» дип көрсенә Рәфгать...

— Керик, малайлар,— диде Арзу.— Суык та. Сез азмаз йоклап алырсыз, минем бер кочак тикшерелмәгән дәфтәрем ята.

Керә-керешкә Рәфгать белән икебез укытучылар бүлмәсендәге күн диванга сузылыштык, Арзу җиделе лампаны кысып кына куеп директор кабинетында утырды. Ут яктысы урамга төшмәсен өчен, тәрәзәләргә географик карталар эленгән... Ябылып бетмәгән ишектән кылыч кебек кенә сызылып безнең як идәнгә ак нур төшә, әнә шул нур миңа йокларга ирек бирми, әлләниләр уйлата, чыгардай җанымны тетрәтеп ул якта ара-тирә кәгазь кыштырдап ала...

Мин йокламыйм, йоклый алмыйм, минем аның янына чыгасым, аның бирелеп дәрес әзерләгәнен читтән генә булса да күзәтеп торасым килә. Мин уйларым белән әллә кайчан анда, аның янында, тик чыгарга ярамый. Әдәпме, оятмы, ниндидер бер хис мине тыеп тора, аның шунда якында гына икәнен тою, ул сулаган һаваны сулау, аяк тавышын ишетү үзе дә зур бәхет ич, тиңдәшсез бәхет! Минем тын тартырга да куркып ятуымны сизәдерме ул? Сизәдер, сизәдер!..

Мин бер мәлгә генә Асылов турында да, Сирай турында да онытып торам, хыялымда ул, бары тик ул гына кала...

Кай арада йокыга киткәнмендер: «Малайлар, малайлар, торыгыз!» — дигән тавышка чәчрәп уяндым. Рәфгать тә торып утырган, йодрыгы белән күзләрен уа.

— Торыгыз, тор, пожар!

— Ә?! Нәрсә?! Кайда? Йокы куян булып качты.

— Әнә, карагыз.

Күрердәй әүвәл, урам яктан: «Пожар! Янабыз!» — дип акырышканнарын ишеттек, җанны өшетеп чаң кага башладылар. Йөгерешеп тәрәзәгә сарылдык, берни белеп булмый, пыялаларга кунган абагалар алтын сары чәчкә атканнар! Куркыныч. Дәһшәтле куркыныч. Әллә салкыннан, әллә куркудан өчебез дә дер-дер киләбез, тешләр тешкә тия. Бишмәтләребезне кия-кия ишегалдына атылып чыктык. Куркынычы монда икән әле аның! Моннан якында, йөз атламнар чамасында гына, бәрәңге бакчасы мәктәп тәрәзәләре каршысына ук килеп җитә торган чат Нургалиләр өе дөрләп яна иде. Әрсез ут шактый үрләгән инде, салам түбәне эре-эре телләре белән ялмап маташа, ут яктысында әрле-бирле йөгерешкән кешеләр, август эссесендә аяк астыннан төрле якка сикерешкән чикерткәләр төсле, куркынган һәм кечкенә булып күренделәр. Мәктәп ишегалды, йортлар, тәрәзәләр, ак кар җан өшеткеч сәер ал төскә манылган, күк йөзе кап-кара, йолдызлар югалган. Без дә: «Пожар! Пожар!» — дип сөрән салып Нургалиләргә таба чаба башладык. Безгә ияргән Арзу кычкырып җибәрде:

— Малайлар! Ә мәктәп?! Без бит постта!

— Мәктәп янмый ич!

— Җил кайсы яктан исә? Нәкъ мәктәп өстенә бит!

Кай арада җил чыккан диген, нәкъ менә мәктәп өстенә исә! Чат Нургалиләр түбәсеннән тубал-тубал күтәрелгән очкыннар нәкъ мәктәп түбәсенә җитәрәк сибелешеп сүнәләр. Ә сүнми калсалар? Янгын көчәеп кенә бара ич, сүнми калсалар, рәттән салам белән ябылган биналар тоташтан ут азыгы булачак! Арзу акылын җыеп өлгерде:

— Егетләр, түбәгә менегез! — дип кычкырды. Карлыбозлы авыр баскычны каз каурыен йөрткән күк кенә очыртып пожар ягына чыгардык та түбәгә сөядек; балта, көрәк, багор, ломише әйберләрне дә шул тирәгә ташыдык. Торабыз. Ул арада мәктәпне сакларга байтак кеше җыйналды. Түбә кары эреп безнең өскә су булып ага башлады, хәл минут саен хәтәрләшә бара иде. Рәфгать, мин, тагын бер-ике укучы түбәгә менеп киттек һәм сүрән генә төти башлаган салам кисәкләрен кар белән томалый башладык. Эссе. Түбәдә янгын тагын да дәһшәтлерәк күренә иде. Сугыш кыры күз алдыма килеп китте. Анда да шушындый соры, үлек төс белән шәһәр-авыллар янадыр, тик як-ягында бомба, снаряд кыйпылчыклары гөҗләп яуганда кешеләрдә янгын сүндерү кайгысы бар микән? Әле менә шушында, бөтен авыл җыелып сүндергәндә дә, кешеләр һушларын җуеп, каушап калдылар. Җил күтәрелгәннән-күтәрелде, яман сызгырып очкыннарны гына түгел, вак чыбык кисәкләрен дә мәктәп түбәсенә яудыра башлады. Түбәләрнең утка караган ягында кар эреп агып бетте, җылы төшмәгән якның карын көрәкләр белән бу якка атып бетердек.

Нургали үзе балта остасы иде, ихаталары әйбәт нараттан салынган, берничә торык лапас өстенә, сыер абзары һәм таза гына келәте бар. Аларның олы малайлары безнең Нәсимә белән бишенчедә йөри, тагын өч бала, кечкенәләр. Хәзер менә шулар утырып яналар! Агачмы,ниләрдер шартлый, ата, көлтә-көлтә ялкын гүләп күтәрелә. Пожарның үз тавышы, дәһшәтле шомлы гүләве бардыр дип һич уйламаган идем! Әгәр бал кортлары урынына мең тилгән яки козгын күч булып оча башласа, нәкъ менә шушындый куркыныч, канны өшетә торган авазлар чыгар иде.

Әле анда, әле монда түбә көйри башлый; без, юеш, черек саламга балтыр тиңентен бата-бата, түбә буйлап чабабыз; кайбер урыннарда аяк бот төбеннән аска кереп китә, салам астындагы чыбык арасына эләгә; Рәфгать

миңа кычкыра, мин аңа; арабызга Сирай килеп кергәнен тавышыннан гына абайладык.

— Нәрсә катып торасың, су менгер, су! — дип кемгәдер акыргач кына айнып киткәндәй булдык. Сирай баулы чиләк тотып менгән икән, астагылар көянтә-чиләк белән мәктәп коесыннан су ташыйлар, ул шул чиләкне түбәгә менгереп тора, имеш...

Сирай безгә дә кычкыра башлады:

— Катып тормагыз әле, тәре баганалары! Әнә ич, күзле бүкәннәр! Теге почмак көйрәп ята!

Без бата-чума «теге почмакка» ташланабыз, көйри башлаган түбәне толыкманы белән аска ишеп төшерәбез.

Сирай су да сибәргә өлгерә, көрәге уйнап кына тора, тыны гыжлый, маңгае, бите кап-кара булган. Мәүлиха апа да киявен күзәтергә килеп җиткән, учларыннан бүрәнкә ясап авызына китергән дә пожар тавышын басып чәрелди:

— Кияү, кияү, сак бул! Аягың таймасын дим... Ай, тырыш шул минем кияү балакаем!.. Сирай кияү дим, алай кырыйга килмә! Килмә! Әллә киеменә ут капты инде. Искәндәр, дуңгыз малай, минем кияүне карачы!..

Мин Сирай өстенә кар сибәм, аннан төтен күтәрелә, ул яман итеп сүгенеп җибәрә.

Эш арасында Арзуга да күз салырга өлгерәм, алар Зөләйха апа белән укытучылар бүлмәсеннән акрын-акрын әйберләрне чыгара башладылар, җил бик хәтәр өрә шул, шикләнәләр булса кирәк. Ул арада Түбән авыллар менеп җитте, мәктәп янында халык ишәйде, кемнекемнән аерып булмый башлады. Ничек булгандыр, түбә белән мавыгып сизми дә, ишетми дә калдык, Сирай түбәдән туп-туры җиргә сикереп төшкәч, башкалар «ах» итеп куйгач кына аска карадык. Кемдер түбәдән бер кочак утлы салам ишеп төшергән, салам су күтәреп килүче Арзу өстенә төшеп аны аяктан еккан... Ут, су бергә буталып беткән... Арзу бер минутка гына һуштан язган, янындагы хатын-кызлар чикылдашсалар да, нишләргә белми аптырашканнар. Сирай мокыт каян белешеп өлгергәндер, туп-туры җиргә сикереп тә төшкән, тезләнгән килеш Арзу янына килеп өлгергән, саламны арчып аны уттан һәм судан аралап алган... Минем дә бик төшәсем килде, әмма мөмкин түгел иде... Арзуны күтәреп мәктәп бүлмәсенә алып кереп киттеләр.

Өй янып бетеп килгәндә, акырып-сызгырып пожар насосы тагып, Гыйбадулла килеп җитте, ике-өч хатын өс киемнәрен салып ыргытып насос басарга тотындылар,

көпшәдән нәзек кенә сызылып чыккан су ут өстенә барып төшкәнче күздән югала иде.

Ут акрынлап сүнде, шиңде. Без дә түбәдән төштек. Мин, Рәфгатькә бер сүз дә әйтмәстән, Арзу янына йөгердем... Ул бит-күзен юып, чистарынып үзе минем каршыга чыгып килә иде.

— Өйләрегезгә йөгерегез, егетләр, югыйсә салкын тияр сезгә! — диде ул.

Мин аның кулыннан тотып алдым:

— Хәлең ничек?

— Күрмисеңмени? — диде ул, көлеп...

Икенче көнне өйдә дә, мәктәптә дә сүз төнге ут турында гына барды. Кәҗә башы урамыннан кайбер кызлар янгын барын ишетмәгәннәр дә йоклап калганнар. Алар, безнең дежурда булганны белгәч, төпченеп сорашалар. Баш авырта, йокы килә, авыз минут саен ачылып-ачылып тора, ярминкәдә булмаган ич, аның нәрсәсен сөйлисең, утның?! Имеш-мимешләр янгынның үзеннән дә хәтәррәк дөрли башлады. «Нургали хатыны сыер бозауламады микән дип абзарга кергән дә шунда ут төшереп калдырган»,— диючеләр булды. «Нургалинең Әнәсе, бишенчедә укучы ташбаш, качып тәмәке пыскыта икән, өй почмакларының мүген тартып бетергән, шул мур кыргырының эше генә бу!» — дип тә сөйләделәр. Авыл гөж килде...

Имеш-мимешләр расланмады, Нургали хатыны төнлә чыгып йөрмәгән, Әнәсе дә тәмәке тартмый икән, янгын чыккан җирдән ерак та түгел, ят чиләк белән, керосинга манчылган чүпрәк кисәге дә табып алгач, бөтен Югары авыл «ах!» итте.

Милицияләр килде, эт китереп бата-чума эзләнеп йөрделәр.

Асылов та килде.

Бу юлы беренче башлап Рәфгать белән мине чакырды, икебезне ике ягына утыртып бергә дә сораштырды, аерым-аерым алып калып та сөйләште. «Сез ул төндә йокламагансыз... Арзу Ямашева сезне, игътибарлы, күзәтүчән егетләр ди. Ниләр күрдегез? Урамда кемнәр йөрде? Ят кеше күзегезгә чалынмадымы? Укытучылар кайчан китеп бетте, берәр кешенең үз-үзен тотышында үзгәреш сизмәдегезме? Өлкән класс укучыларыннан мәктәптә калучылар булдымы? Имеш-мимешләрне кем тарата? Сүз кемнән чыкканын белеп булмасмы?»

Белгәнне сөйләдек. Ләкин Асылов без белгәннәрне бик азсынып, сытык чырай белән баш чайкап утырды.

Икәүдән-икәү генә калгач, Асылов, уйларга вакыт бир-

гән сыман, байтак кына дәшми утырды. Аннан көрсенеп тәрәзә янына барып басты, кинәт кенә миңа таба борылды да:

— Сирай Хәбибов турында ни уйлыйсың? — дип сорады.— Белгәнеңне яшермә!

— Ни уйлыйм дип... Уйлаган юк!

— Аны беләсеңдер бит?

— Беләм белүен... Беләм дип тә бетерә алмыйм, монда тормый ич Сирай. Тегермәндә. Быел гына ешрак күрәм... Безнең оч кияве бит...

— Чыгып йөргәлиме ул? Кемнәр белән аралаша?

— Мәүлиха ападан бик чыгып йөри алмассың...

Асылов миңа табарак иелде дә:

— Арзу Ямашева белән аларның мөнәсәбәте ничек? — дип сорады.

— Каян белим ди анысын?..

Почмакта иске чүпрәк белән төреп куелган бер нәрсә бар иде, Асылов шуны сүтеп җибәрде. Карасам — янган чиләк.

— Бу чиләк сиңа таныш түгелме? Тутык кисәкләре кубып-купшып торган янган чиләкне кулыма алып әйләндереп-әйләндереп карадым. Таныш дип, тукта әле, менә бу ике сызык... Көз көне багор белән без сызган идек түгелме соң боларны? Мәүлихалар чиләге түгелме соң бу?.. Түгел, түгел... Без сызганнар тирәнрәк тә, озынрак та иде бугай...

Әгәр мин бу чиләкне беләм дип әйтсәм?.. Арзу турында сүз кузгалачак... Сирай телгә керәчәк... Әнә ич, Асылов нидер сизенә, нәкъ менә шулар турында сүз алырга тели...

Әйтергәме? Әйтсәм... Мин кем булып саналырмын монда? Көнчелектән, көчсезлектән яла ягучы булып калмаммы? Ярый ла әйткәнем раска чыкса? Ә чыкмаса? Мондый калшайган чиләкләр азмы әллә кешеләрдә?..

Чиләкне әйләндереп-әйләндереп карадым да, кире суздым:

— Белмим, иптәш Асылов, күргәнем юк,— дидем. Эт икән бу Асылов дигәннәре, минем күңелдәге каршылыклы уйларны сизенде бит:

— Тикшерүгә ярдәм итәргә теләмисез алайса? — дип куйды.— Аңлагыз! Монда эш уеннан узган! Кемдер Нургали Исхаковларга ут салып мәктәпне яндырырга теләгән. Без ул кешене табарга тиеш!

Тик мин артыгын бер сүз дә әйтмәдем. Әгәр Асылов урынында башка берәү утырса, ихтимал, үземнең шикләремне сөйләп тә биргән булыр идем. Бу очракта мин

аның җиңүен, тантана итүен теләми идем. Ике арадагы сүздә Арзу исеме телгә алынуын теләми идем...

Әле мин ул кичне Асыловның Нәҗип атлы булуын да, аны Арзу шикелле комсомол пленумы члены икәнлеген дә, аларның төрле җыелышларда гел-гел бергә утыруларын да, егетнең кызда өмете барлыгын да белми идем.

Бездән соң Асылов янына Арзу керде, мин бәбкә саклаган тилгән күк колхоз кәнсәләре тирәсендә уралсам да, ахыргача түзә алмадым, көн бик суык иде, аяклар шыкранлап каткач, өметемне өзеп, өйгә йөгердем...

Яңа ел килеп озак та тормады — колхоз председателебез Лотфулла агайны сугышка алдылар. Идарәдә баш булып партоешма секретаре, ферма мөдире Нәгыймә чәтертән калды. Аны председатель дә иттеләр. Өлкәннәр арасында: «Тотарга да Хәбибрахман картны куярга кирәк!» — дигән сүзләр йөргән иде дә, тыштан белдермәсә дә, аның нык ук сырхау икәнлеге мәгълүм булды. Авыру димәссең үзен, тынмый, гел өйдә тормый диярлек, атлар яныннан кайтты исә, чәчүлекләрне тикшерергә келәтләргә төшеп китә, алачыкта күрек баса...

Мин элеккечә Арзуларга кереп утыргалыйм, «аулак өйләр мөбарәк булсын» дип кай арада Рәфгать тә килеп чыга. Керә дә, ут төшми торган караңгырак почмакка урнашып, тезләрен кочаклап сүзсез генә тыңланып утыра. Күрше-фәлән кызлары да кергәли. Беркөнне, юк-бар суган сатып, көлешеп утыра идек, ачу белән ишек дөбердәттеләр.

— Ишек ачык, керегез,— дип эндәште Арзу.

Озын куныччлы ак итек кигән, куян шарфын пиджак якасы өстеннән генә ураган Сирай килеп керде, яланбаш.

Безнең авылда яшь кияүләр бер-ике ел буена аулак өйләргә килгәлиләр, әмма Сирайның шулай яланөс, яланбаш килеп керүенә бераз гаҗәпләндек. Мәүлиха апа киявен түгел, өй тулы кызларын да Арзуларга кертми иде.

Сирай, хуҗаларча эре-эре атлап, өстәл янына ук узды, сәкедә тезелешеп утырган кызларны чеметкәләде, авызын бөреп хихылдап куйды.

— Утырасызмы, аккошларым?

— Монда карчыгалар да бар,— диештеләр кызлар.

— Искәндәрме? Ябалак дигез әле шуны!

Почмак яктан Рәфгатьнең тавышы чыкты:

— Сирай, көлүең матур матурын... Ичмасам, бер генә мәртәбә булса да, нигә көлүеңне беликче?

— Ә-ә, Рафа да монда икән!.. Күрми торам. Нихәл, парин?.. Шуны карчыга дидегезме әллә, аккошларым? Рәфгатьне әйтсәгез ярый! Егет ичмасам!

Аның шулай оятсызланып, бөтен игътибарны үзенә җыярга омтылып утыруы җенемне кузгатты:

— Бар әле, Сирай,— дидем.— Кәримә тәтиеңне урламасыннар! Җилгә чыккан җирдән генә качып кергәнсең бит!

— Минме? — диде ул, хәтере калып.— Тышауда дип беләсеңме әллә мине? Мин иректе кош, теләсәм очам, теләмәсәм...

Сирайның чыгарга исәбе күренми иде, безнең бәхеткә капка ягыннан яман чәрелдәгән тавыш килде, шунда ук тәрәзә кага башладылар. Мәүлиха апаның тавышын иң әүвәл кияү таныды, сикереп урыныннан купты, кызларны кочаклаган булды, Рәфгать янына барып аның аркасыннан какты, бусага янына басып көлде, куян шарфын муенына урый-урый чыгып та йөгерде.

— Ишекне яп! — диде бер кыз.

— Фу, кәҗә тәкәсе исе килә үзеннән,— диде икенчесе.— Сарымсак тыгынган, бирән корсак. Арзу гаепле кеше төсле миңа карады:

— Ни кирәктер бу эшем иясенә. «Мин сине үлемнән коткардым!» — ди дә килеп керә! Мин ачулы идем:

— Аягын кыскартырга кирәк аның алайса,— дидем.

Рәфгать почмактан:

— Кыскартучысы синме? — дип кычкырды. Ачуымны китереп кызлар шаркылдап көлде. Арзу белән мин, башкаларга сиздермичә генә, бер-беребезгә караштык.

Кичләрнең берсендә Арзу белән икәү озак кына утырдык. Дәрестән соң бөтен унынчы класслар сыер-бозау абзарларыннан тирес түгәргә барган идек. Эшче куллар кимегәне кая карасаң да сизелә шул, сыерлар тездән пычрак арасында калганнар! Председатель Нәгыймә апа:

— Китәбез дә китәбез дип түш киереп йөргәнче, көчегез ташып торса, фермага төшкәләгез сез! — диде Рәфгать белән миңа карап.— Хатын-кызларның егәре җитә торган түгел бу эшкә!..

Янбашларына сызлау төшкәнче тирес түктек, Арзу да безнең янда эшләде... Мин туп-туры аларга кайттым, өйгә кагылып та тормадым...

Вакыт шактый соң булса да, ул мине чыгармый. «Утыр азрак, ялгызыма күңелсез!» — ди. Мин утырам да утырам, бер заман буран аша капка шапылдавы ишетелде.

Арзу, сискәнеп:

— Бабай кайтты бугай! —диде.

Хәбибрахман карт белән болай соңарып очрашасым килмәдеме, тиз-тиз киендем дә, Арзуга ияреп, өйалдына чыктым, бабасы өйгә узып киткәнче дип, чоланнарына

кердем. Арзу этә-төртә мине кертеп җибәрде дә көлә-көлә өйалды ишеген ачты:

— Озак тордың, бабай. Бик туңмадыңмы?

— Озаккарак тартылды шул, нишлисең...

Алар керергә ашыкмадылар, Хәбибрахман карт тырышып-тырышып итекләреннән кар себерде, тамагын кырды, ютәлләде. Арзу туңмый микән анда?

— Барысын да алдылармы, бабай?

— Барысын да, Арзу, барысын да... Унтугыз ат алып барган идем. Унтугыз җан! Берьюлы унтугызны...

— Болары урынына башкалары булыр, бабай. Әнә нинди колыннарың бар бит. Миңа күрсәткәненә нинди исем куштың әле? «Акъялмы?»

Хәбибрахман картның күңеле тулган, ахры, тавышы нечкәрде, моңсуланды. Арзу аны юатырга кереште. «Туа тора, үсә тора... Әллә нинди юртакларың булыр»,— диде.

— Иң шәпләре, иң акыллылары китте. Озаттым. Өй эчебездән берәү дә фронтка китмәде дип кыенсынып йөри идем, хәзер менә, күр... Ул «Актояк»ны әйтерсеңме, «Корыч»нымы?.. Сабан туе юртаклары ич алар. Адәм акыллары бар иде бит аларда! Иптәшләрем, сердәшләрем иде.

— Сугыш бит, бабай...

— Белмәгән кая, сугыш!.. Ир башы белән ат башы күрә, дигәннәр... Ирләр китәрләр дә хат язарлар... Ә минем бахбайларым?.. Улларым юк минем. Улларым юк, ә илгә бурычым күп!.. Минем канатларым, ак канатым «Актояк»!.. Әй, карыйлар миңа мөлдерәп! Әй, казыйлар җирне тояклары белән! Военкомат каршындагы баганаcontaining кимереп бетерделәр, иреннәреннән кан тама! Аерылганны сизенәләр, бахырлар... Бер караганда, сөенәм, Кызыл Армиядән унтугыз юртак артмас... Бер караганда, кызганам... Ну, бу германны! Ну, бу фашистны! Гөлдәй тормышыбызны көл итте!.. Югалалар алар шулай, малкайларым, дим... Берәрсенең хәбәрен генә булса да ишетәсе иде... «Актояк»ка, ак канатыма, атландырып җибәрерлек балам булмады бит... Анысы бер үкенеч...

— Син мине яратмыйсыңмы, бабай? Миннән канәгать түгелме?

— Сугыш бит, Арзу, сугыш!.. Илгә дошман килә!..

Арзу, юату сүзләре әйтә-әйтә, ниһаять, бабасын өйгә алып кереп китте. Мин аяк очларыма басып чоланнан ишегалдына, аннан шыпырт кына урамга сыздым.

Ну бу Арзуны! Бабасының атлар озатырга киткәнен әйтмәгән дә иде!.. Әллә миңа әйтер сүзе бармы дисәм... Бабасы өчен хафалануы гына булган икән...

## 13

Авылның «сугыш!» димәгән сулышы юк хәзер... Элек өч кеше эшләгән урыннарда бер кеше эшли, әтиләр, абыйлар урынында үсмер кызлар, үсмер егетләр калды. Ферма коесының сиртмәсе бер караңгыдан икенче караңгыга менеп-төшеп тора, алачыктан чакы-чокы тимер тавышы ишетелә. Әле алда озын кыш булса да, авыл яз турында уйлый башлады. Яз!.. Язгы чәчү! Келәт алларында җилгәргечләр әйләнә, триерларда борчак шыбырдый... Яхшы белән яман янәшә яшиләр икән, авылда вак-төяк бурлыклар да ешайды. Кибәнне кардан арчыйлар да бәләкәй чанага төяп печән алып китәләр. Ындыр табагыннан борчак, тары чәлдерүләр турында да озын колактан ишетелгәли. Ашлык сугу ярты кышта да бетмәде, болай булса, ындыр табагында эш язга хәтле сузылыр дип торабыз. Мәктәптә дежур торулар күңелле булып китте: Югары очта да, Түбән очта да төнге каравыллар бар хәзер, урамга кайчан чыксаң да күңелне күтәреп шакылдавык тавышлары яңгырый. Яңгырый да безне сабый чакларга, кызлар киндер тукмаклаган кичләргә алып кайта...

Иген амбарлары, ферма биналары тирәсендә дә кеше аягы өзелми, авыл активлары, комсомоллар йөреп, тикшереп торалар. Чулак Гыйбадулла гына зарлангалап ала:

— Йөриләр... Йокыларын җәлләмичә убыр күк йөргән булалар! Йөреп ни файда? Урлыйм дигән кешегә тишеге күп аның! Сәвитнеке мул ич аның, барыбызга да җитәрлек,— дип куя.

Кышкы каникул узгач, төнге дежурлыкка тагын Рәфгать белән туры килгәләдек, әмма хәзер төне буе сагалап йөрмибез, кичләрен ихатаны бер урап чыгабыз да суыктан качып классларга кереп утырабыз. Кыш гаҗәп суык килде, класслар да салкын, утын янга калсын дип, мичләргә җан сакларлык кына җылы биреп торалар...

Ул кичне мин, Рәфгать, биология укытучыбыз юантык, алтын тешле Нәҗия апа дежурда идек. Нәҗия апа кызыллы-сарылы шакмаклы тастымалга төреп мичтә тәгәрәткән бәрәңге алып килгән, ак капкачлы бушаган кершән савытына эре-эре бөртекле тоз тутырган, бәрәңгесен шул тозга мана-мана бик тәмләп ашады да: «Кер юып бик ардым, укучылар, хәлем юк, ишәк тә ишәк, мин дә ишәк, үзегез караштырырсыз инде»,— дип, күн диванга менеп тә ятты.

Ихатаны тиз-тиз генә бер әйләндек тә укытучылар бүлмәсенә кайттык. Иртәгәге дәрес караштырасы да бар. Иртәгә физика. Немец теле. Икесеннән дә Арзу керә. Мин аның дәресләренә аерата тырышлык белән әзерләнеп барам.

Рәфгать белән кара-каршы утырып, физикадан мәсьәлә чишәбез. Маятникның тирбәнү вакыты Т фәләнгә тигез... Димәк... Шулай... Әгәр маятникны Җирдән Айга күчерсәк, аның тирбәнү вакыты күпмегә үзгәрер?.. Ай массасы Җирнекеннән 81 мәртәбә кечерәк... Ә Җир радиусы Айныкыннан 3,7 мәртәбә зуррак.

Җилле, суык февраль төне. Ертык-портык болытлар арасыннан тулган ай күренеп китә. Кулларымны артыма куеп, тәрәзә каршысында басып торам. Мәсьәлә чишелми... Маятник түгел, минем хыяллар еракка, болытлар арасына, офыклар артына күчәләр...

Өйалдында нидер шапылдады, сөйләшкән тавышлар ишетелде, ишек ачылды һәм, итекләрен бер-берсенә бәреп кар кага-кага, Асылов белән Зөләйха апа килеп керде. Нәҗия апаның йокысы сак икән, шундук торып утырды, итәген җыештырды. Асылов җитди һәм ачулы, Зөләйха апа куркынган, каушаган кешегә охшаган иде.

Асылов:

— Нихәл, егетләр? Сезгә гел мач килеп тора инде,— дип, ияк кагып кына исәнләште дә пирчәткәләрен салып кесәсенә тыкты, күгәрчен тәпие төсле кып-кызыл бармакларына туктаусыз өрә башлады. Бераз җылынгач, укытучылар бүлмәсеннән коридорга чыга торган ишекне ачып карады, аскы иренен тешләп уйланып торды.

Зөләйха апа башын чайкап:

— Моның булуы мөмкин түгел, Нәҗип иптәш, юк,— диде.

Асыловның күз кабаклары йокысызлыктан кызарган, ул нәзек, матур кашларын җыерып безгә карады да:

— Эш болайрак тора, комсомол егетләр,— дип сүзен башлады.— Байтак колхозларда икмәккә кул сузу фактлары ачылды. Усал ниятле кайберәүләр, ындыр табакларында эшнең сузылуыннан файдаланып, шактый гына ашлык урлаган булырга тиеш!.. Сезнең авылдан да җитди генә сигналлар алынды.

— Барыбер ышанмыйм мин моңа! — диде Зөләйха апа.

— Сигналларның кайберләре раслану алдында тора,— диде көлемсерәп Асылов.— Кайберәүләрне тоттык без бүген. Төнгә алар белән юлга чыгып булмый, бер-икесен идарәдә калдырабыз. Анда участковый саклар. Ә бер-ике кешене монда китерербез...

Зөләйха апаның кулга алынганнарны мәктәпкә китерәсе килмәве күренеп тора, алар Асылов белән ачулы пышылдашып та алдылар.

— Таңнан алып китәбез аларны, Зөләйха апа! — диде, ниһаять, Асылов.— Укучылар белми дә калыр. Беразга тынлык урнашты, Зөләйха апа:

— Нишләмәк кирәк, хәерле булсын!.. Эш укучыларда гына түгел бит, иптәш Асылов. Мәсьәләнең икенче кыен ягы да бар!.. Үзегез дә аңлыйсыздыр,— диде.

— Миңа җиңел дип беләсезме? — диде Асылов, аннары безгә мөрәҗәгать итте: — Күз-колак булырсыз, егетләр!

Алар чыгып китүгә тиз-тиз китап-дәфтәрләрне җыештырып куйдык, физика онытылды, кемне эләктерделәр икән, кайда, дип баш вата башладык. Нәҗия апа сукранырга тотынды: «Аягым тартмаган иде бүген, шушыңа булган икән, күрәчәгемә!»

Җил көчәйдеме, әллә без тырышып тыңлаганга шулай тоелдымы, тәрәзәләргә шапы-шопы бәрә, әллә кай җирләрдән, мүк араларыннан тишек-тошык табып эчкә үтә, аякларны туңдыра. Асыловлар итегеннән калган кар кисәкләре эреми яталар... Рәфгать куян эзенә төшкән сунарчы күк ярсыган, кычкырып көлеп тә җибәрә: «Менә күрерсең! Йомгак бер тәгәрәсәме, сүтелер!»

Ярты сәгать тә узмагандыр, бүлмәгә Хәбибрахман абзыйны, Кәҗә башы урамыннан Сырур апаны, аның кызы Гөлбәдәрне ияртеп, милиционер белән Асылов килеп керде. Асылов милиционерга китәргә рөхсәт итте, теге кабаланып, чыгып та югалды.

Гөлбәдәр, бездән оялыпмы, әнисе артына посты. Сырур апа, бер дә исе китмәгән кыяфәттә борынын чөеп, түшәмгә карап тора иде. Аның зәһәрлектән кысылган тулы иреннәрен, ачу тулы җете кара, тере күзләрен һәм бәреп чыгарга җыенгандай кабарган хәтәр түшләрен гомергә онытасым юк.

Гөлбәдәр мәктәптә безнең абыйлар белән укып йөрде, аннары Шатура ягына торф чыгарырга китте, шунда якташ кызларының күлмәк-күнчекләрен урлап сатып, ызгышып, талашып кайтты да хәзер колхозда эшли. Сырур апа чалгы пәкеседәй үткен, яшен ташыдай елгыр хатын; бакча артындагы мунчасында күмешкә пешерә, авылга милиция килеп төштеме, аның курасына кагылмый китмиләр, тикшерәләр.

Хәбибрахман абзыйны, авыл активы буларак, пүнәтәй сыйфатында ияртеп кергәннәр дип уйладым. Аның дәү, бөкре күләгәсе мич аклыгына төшкән, ул олы, калын

табанлы киез итекләренең үкчәсен солдатларча бергә кушып баскан да аска караган, тик кенә, тын да тартмыйча, нәрсәдер көтеп тора, сагайган.

— Хәбибрахман абзый, утырыгыз монда,— дип, мин аңа урындык суздым. Ул миңа түгел, Асыловка карады.

Асылов та аны күзәтә иде. Хәбибрахман абзыйның түгел, киресенчә, Асыловның гөнаһ өстендә тотылган кебек уңайсызланып, газапланып, кыйналып басып торуын күргәч кенә, миемә уй йөгерде, мин эсселе-суыклы булып киттем.

— Тикшерү вакытында өчегез дә кулга алынасыз,— диде ул.

Без телсез калдык. Асыловның: «Өчесен өч класска ябып торыгыз»,— дигән сүзләрен дә ишетмәдек. Апалар кузгалдылар, Асылов, йомшак тавыш белән:

— Ә сез, гражданин Ямашев, калып торыгыз,— дип өстәде.— Утырыгыз.

Хәбибрахман карт мин куйган урындыкка авыр гына килеп утырды, көрсенде, кайры тунының агач төймәләрен ычкындырды, бүреген салды. Кыска гына калдырып алдырган җирән чәчләре сүрән ут яктысында тоташ көмеш булып җемелдәде. Асылов та көрсенде, суыкта туңган сумкасын көч-хәл белән ачып, аннан язулы кәгазьләр чыгарды, таратып ташлады, аннары гына Наҗия апага карады:

— Гафу итегез, фамилиягезне белмим,— диде.

— Раббаниева,— диде Наҗия апа, курка-курка.

— Кайтып ял итсәгез дә була сезгә. Иртәгә эшкәдер бит?.. Монда егетләр дә бик җиткән.

Наҗия апа, кат-кат рәхмәт укып җыена башлады, тастымалы чишелеп китеп, идәнгә бәрәңге кабыклары, эреэре тоз кисәкләре чәчелде, апабыз, тезләнеп, тоз бөртекләрен берәмтекләп җыеп учына тутырды, аннары, Хәбибрахман абый ягына карамаска тырышып, юан аякларын көчхәл белән сөйрәп чыгып китте.

Асылов башта: «Гражданин Ямашев!» — дип, кырыс кына эндәште дә, төзәтеп: «Хәбибрахман агай!» — дип сүзен башлады.

— Болай итеп, мондый хәлдә очрашырбыз дип көтмәгән идем... Очрашканбыз икән, эшне тизләтергә тырышып карыйк. Икебезгә дә шулай кулайрак булыр. Дөресме?.. Без, пүнәтәйләр Мөхәммәтшина һәм Баянова-лар белән бергә, авыл советы депутаты Әхияров катнашында, сезнең йортның чоланыннан потка якын, дөресрәк итеп әйтсәк, унбиш килограмм да өч йөз илле грамм

борчак алып чыктык. Менә тентү акты. Менә үлчәү акты. Сезнең борчакмы ул?

Хәбибрахман абзый гайрәт белән бер кузгалып куйды да кире утырды, күкрәгендә кайнаган утны йотты, сабыр гына:

— Нинди борчак соң ул? — дип сорады.

— Быелгы уңыш борчагы. Сезнең агач кисмәккә тутырып куелган.

— Безнең колхоз быел борчак өләшмәде.

— Кисмәк сезнекеме?

— Почмактагы буш кисмәкне әйтсәгез — минеке. Анда бернинди дә борчак булырга тиеш түгел... Әллә кай гомердән буш тора ул кисмәк.

— Димәк, сез ул борчак минеке түгел дип барасыз.

— Дөресе шулай булгач, нәрсә әйтим?

— Яхшы! —Асыловның нидер эзләп түгел, болай гына, уеның очына чыгарга тырышып кына кәгазьләр актарганы безгә дә аңлашылып тора иде.— Яхшы! Мин дә шулай дип уйлыйм ди. Ә бу — потка якын борчакны нишләтәбез? Хуҗасы кем аның? Чолан сезнеке. Кисмәк тә чит түгел икән. Борчагы кемнеке? Ачыклыйк шуны.

— Кем салган, шул ачыкласын.

Асылов, эшнең уеннан узганлыгын, монда чамадан тыш җитди булырга кирәклеген искәртеп, сорауларын тагын бер тапкыр кабатлады.

Бу эш белән маташу аның үзенә дә ифрат читен икәнлеге күренеп тора, мин, мөгаен, Асылов, карт белән икәүдән-икәү генә калырга читенсенгәнгә безне чыгарып җибәрмәгәндер дип уйладым.

Хәбибрахман абзый эндәшмәгәч, ул аны үгетләргә үк тотынды.

— Бер сездә генә түгел, башка авылларда да икмәк белән шаяралар. Каракларга каршы көрәшне көчәйтәчәкбез. Сезне карак дип уйламыйм, алай уйларга хакым да юк. Гражданнар сугышы ветераны, колхоз төзешкән кеше... Бер кисмәк борчакка кызыккансыз дип уйлый алмыйм, ышанмыйм. Аңлыйм... Әмма, факт — аяусыз нәрсә! Бу очракта исә ул сезгә каршы.

— Минем сүзем бер — борчак урламадым. Ант итә алам.

— Ул чагында чоланга борчакны Арзу Ямашева алып кайткан була.

Хәбибрахман абзый, кыяр-кыймас кына, урындыгыннан купты, калтыранды, урындыгы авып китте.

— Сез, Асылов иптәш, чамалап авыз ачыгыз! Арзуның нинди бала икәнен бик яхшы беләсез... Белмәсәгез, аны хатынлыкка сорап килмәс идегез... Мин бирмәдем

аны сезгә! Мин! Мине гаепли аласыз, әйткәнегезчә, фактлар аяусыз нәрсә... Гаепләгез, мәгәр балага тел тидермәгез... Мин икән, мин...

Асылов, бушлыкка күз текәп бик озак сүзсез утыргач, өзек-өзек, ят тавыш белән Хәбибрахман абзыйга болай диде:

— Мин... гражданин Ямашев... элгәрге тикшерү генә уздырам... Сезнең эш... һичшиксез... башка хезмәткәргә тапшырылыр... Шуны өсти алам: бүгенге күңелсез хәлгә Арзу Ямашева белән булган мөнәсәбәтебез һич тә катнашмый!.. Чирткеле уйнамыйбыз, уголовный җинаять тикшерәбез!.. Сугыш заманасының иң каты законнары таләп иткәнне башкарабыз!.. Ә теге мәсьәләгә килгәндә, ялгышасыз, сез түгел... Арзу үзе мине кире какты...

— Ярый. Риза. Арзуның катнашы да юк ди... Мәгәр борчакны урлаучы мин түгел! Түгел!

— Сигнал бар, Хәбибрахман абзый,— диде Асылов.— Сигнал, факт. Сораша-белешә торгач, шаһитлар да табылды.

— Нинди шаһит? Ни сөйлисез сез?.. Кайда?

— Хәзер китерерләр... Уйлап карагыз: сигнал алынды, борчак сездән чыкты, шаһитлар табылды... Мин нишли алам?

Җил сызгыра, бүлмәбез тып-тын. Рәфгать белән без, сүз эндәшергә дә куркып, яр карлыгачлары кук, берберебезгә сыенышып күн диванда утырабыз. Аяк астына чәчелгән юка бәрәңге кабыклары бөтерелеп-бөтерелеп килүче әкәм-төкәмнәр булып күренәләр, озак карап торганга алар кыймылдыйлар, куркыталар...

Милиционер керде.

— Алып килдем,— диде ул, бияләенә ютәлләп.

— Керсен монда,— диде Асылов.

Милиционер ишекне ачты, чуклы-чачаклы калын шәл бөркәнгән, тире якалы яңа бишмәтен кигән Мәүлиха апаны үз яныннан уздырып җибәрде.

Хәбибрахман абзый да дүрт күз белән ишекне күзәтә иде, Мәүлиха апаны күргәч түзмәде:

— Эх, эзләгән чучка... юлыгыр! — дип, ике кулы белән шап итеп тезләренә сукты.

Мәүлиха апа, бүлмәгә ят ис — хушбуй исе таратып, алгарак узды, шәл чукларын ычкындыра-ычкындыра, башын артка ташлап, рәхәт итеп елмайды. Асылов аңа урын тәкъдим итте:

— Утырыгыз, гражданка Мөрсәлимова.

— Утырып ук торыйм микәнни соң?

Мәүлиха апаның мондый да төче, иркә тавышын бе-

ренче тапкыр ишетә идем. Аңарда без бар дип бернинди ятсыну, читенсенү әсәре юк иде. Хәбибрахман абзыйны бик хаклы рәвештә эләккән дип санагандыр инде, үзен бик мөһим эш башкаручы кеше кебек хис итеп, Асыловның авызыннан нинди сүз чыгар икән дип, аңа таба авышкан иде. Урыныннан канәгатьләнмичә урындыгын өстәлгә якынрак тартты да, баягыдан да татлырак итеп җырлап:

— Утырып ук торыйм микәнни соң? — дип куйды. Аның шулай шәбәеп, олы сымакланып утыруын күргәч, кылт итеп, Мәүлиха апаның актив чаклары, президиумга менеп, ботын-чатын ерып утыруы хәтеремә төште, һаман авыл активы буласы килеп йөри икән апаның, менә хәзер, җай чыккач, ул шатланган, аның күз алмалары рәхәтлек диңгезендә йөзә, чыраена, кыяфәтенә бәйрәм төсе кергән иде.

— Гражданин Ямашев, сез игътибар белән тыңлап торыгыз.— Асылов бердән корыланды, Мәүлиха апага да кырыс, ямьсез тавыш белән эндәште.— Менә сез, гражданка Мөрсәлимова, бүген кичке очрашу вакытында: «Яңа ел бәйрәме алдыннан, кичке эңгер-меңгердә, күршебез Хәбибрахман Ямашевлар капкасыннан капчык күтәргән кеше кереп китте»,— дип күрсәттегез.

Апа, чишмә челтерәгәндәй, көлеп җибәрде.

— Бәй, кергәнне кермәде дип әйтмәм инде, апаем. Миндә ялганлау сыйфаты юк... Нәселебез белән...

— Ничәнче число иде ул? — диде Асылов, аны бүлдереп.

— Числосын-мислосын хәтерләмим, иптәш лачаннык, численник карарлык идеме соң?.. Кәримәмне, әле син ишетмәгәнсеңдер дә, кияүгә бирдем бит!.. Җыелышып карарга — күз даруына дип — егетне йортка керттек. Егылыплар уңдык инде кияүдән! Шәп егет икәнен белә идем, ул хәтле үк булыр дип башыма да килмәде. Юаштыр үзе, тел-теш күтәрмәс, сәвит өчен җаны фида, калхуз тегермәнендә көне-төне ята, йорт эшенә дә өлгерә, сөйләп биргесез!

— Сез... мәсьәләгә якынрак килсәгез иде!

— Киләм, бик киләм! Якын да килермен... Ни сөйли идем соң? Ә-ә, шул, кияү балакайны сөйли идем бит.— Бу урында Мәүлиха апа, шәлен иңенә төшереп, күз яшьләрен сөртеп алды.— Ул туйлар... туйлары, мин сиңа әйтим... Тирә-якта бер булды инде! Кызым да уңган... Бер юньле эш кенә чыкмады үзенә... Менә, иптәш лачаннык, шуны сорарга онытмыйм дигән идем: сезнең кантур тирәсендә берәр күңеллерәк эш юкмы?

Мин Мәүлиха апаны куып чыгарырдай булып утырам, Асыловның түземлелегенә исең китәр, шул гайбәтчене сабыр гына тыңлый бит!

Ниһаять, ул да түзмәде:

— Капчык күтәргән кешене тәгаен күрдегезме? — дип кабатлады.

— Чат дөресен генә әйтәм! Икмәктер, валлаһи, таллаһи, ипинең чырае хәрәм булсын әгәр, берәү капчык күтәреп мыштым гына кереп китте.

— Кем икәнен таныдыгызмы?

— Кем дип...— Мәүлиха апаның көлкесе тагын килде.— Кеше капкасыннан чит кеше йөри димени хәзер? Аннары, авылда ир-ат калдымыни? Хәзер менә бөтен эш үзебезгә өелде. Пычагын кайра — үзең, утынын яр — үзең, мунчага су ташы — үзең, өй!.. Ир-атсыз ничек гомер итмәк кирәк... Әле дә ярый кияү бар... Син шуны да әйтеп кит, иптәш лачаннык, сугыш кайчан бетә дә, Биктимеремне кайчан кайтарырлар?

— Сез фикерне читкә алып киттегез.

— Бер дә читкә түгел, буразнасыннан гына барам. Сугыш булмаса, Хәбибрахман абзый, дим, олы кеше, дим, бер капчык икмәк күтәреп йөрер идеме? Борчак та булдымы ризык, тфү, әйттем исә кайттым! Кызыл олаулар белән китереп аударалар иде безнең Югары авылда игенне, әргән уйнатып, кызыл әләмнәр элеп... Балын бүлерләр иде, кыярын-кәбестәсен... үзең яратмасаң, әнә малыңа ашат иде... Бар иде минем әктив булып ударникларча җөргән заманалар! Зират тавы өстенә мәк чәчә торган идек... Каравылда Гыйбадулла кода торыр иде... Бай идек без!

— Гражданка Мөрсәлимова!

Мәүлиха апаның битенә ягылган кызылын ярып ике битеннән дә эре-эре яшь бөртекләре ага, кинәт кызарып киткән борыны мышкылдый... Асылов каты гына дәшеп куйгач, ул тиз-тиз бит алмаларын ышкыды да тагын кояштай балкыды.

— Нәрсәкәй, тагын ялгышрак ычкындырдыммы?

— Аның капчыгында борчак икәнне каян белдегез?

— Бәй, үзең әйттең ич!

— Әйтмәдем.

— Кояштыр, әйттең. Әйтмәсәң дә бөтен авыл белә аны: «Быржиннан бер капчык борчак чыккан»,— дип, этебете бытылдый.

— Ярый.— Асылов нидер язарга уйлады да язмады.— Капчык күтәреп кайтучы кеше Хәбибрахман Ямашев иде дип, тагын бер кат раслыйсызмы?

Мәүлиха апа, һич тайчынмыйча, Хәбибрахман картның иелгән көмеш башына карап торды.

— Шул иде. Шул үзе иде дөмеккере! Ул булмыйча, безнең очта кем буталып йөрсен? Быржин шикелле атына-атына кайтып килә иде. Кәмит инде, кәмит, чынкый уйласаң!

Асылов Мәүлиха апа әйткәннәрне теркәп куйды, кул куйдырды. Шаһитны кайтарып җибәргәч, тагын гаепләнүчегә эндәште.

— Йә, ни дисез?

— Ни әйтим? Әйтмим. Әйтерлеге юк.

— Шаһит Мөрсәлимованың сездә үче бармы, ачуы?

— Ачуланышкан юк. Каян булсын... Дус дип тә әйтә алмыйм. Күз алдыгызда икәү утырып тордык... Кайсыбызга ышанырга икәнен үзегез чамаларсыз тагын...

Хәбибрахман абзыйны класс бүлмәсенә озатып куйгач, Асылов безгә эндәшергә дә тиеш тапты:

— Шулай ул менә,— диде күңелсез генә.— Күрдегезме, егетләр?.. Сез мондагы сүзләрне ишетергә тиеш түгел идегез түгелен... Юри чыгармадым мин сезне! Бердән, шаһитның ныклыгын сыныйсым килде. Кайберәүләр кеше юкта әллә ниләр сөйләп бирәләр дә, халык күз алдына чыккач, киресен сукалый торган булалар. Бу апа андыйлардан түгел... Куркыныч шаһит!.. Менә шул... Районнан милиционер килеп җитсә, мин аны монда җибәрермен. Аңынчы болар янына берәүне дә кертмәгез.

## 14

— Нишлибез? — дидем мин Рәфгатькә

— Нишли алабыз соң без?

— Урлагандыр дисеңме?

— Юктыр, әй. Булмас.

— Урламаган! Урлыймы соң! Беләм мин аны...

Хәбибрахман абзыйның атларны сугышка озатып кайткан кичен хәтеремә төшереп, тагын бер кат: «Урламаган!»— дип кабатладым.

Икебез дә тирән хәсрәткә төштек, мәктәп иминлеге өчен дә курка башладык. Асылов сүзләреннән соң тирә-якта бары тик караклар, әшәке кешеләр генә яшидер кебек тоелды. Рәфгать сакта калды, мин йөгереп кенә мәктәп ихатасын әйләнеп чыктым. Тәрәзәләр салам маталар белән тырышып-тырышып капланган булса да, мин бер нәрсәне абайладым: байтак йортларда кешеләр йокламый иде. Димәк, теге яки бу дәрәҗәдә аларга да Асыловның килүе кагылган! Кемгә тентү кергән, кемне шаһит итеп чакырганнар, кемнең болай гына кайгысы тулып ташыган...

Кырык беренче — кырык икенче еллар!

Хәтәр еллар!

Рәфгать янына керәм дип торганда гына, укытучылар бүлмәсенең ишек катында кара шәүлә күренде. Кемдер кармана-кармана нидер эзләнә иде. Утын урларга йөриме, әллә аннан да зуррак бурлыгы бармы? Күзәтә башладым. Таныш та, таныш түгел дә кебек бу кеше. Ишек эзли икән, тапты да ача алмый маташа. Янына йөгереп килдем. Рәхимҗан бабай ич бу! Олы кешедән: «Нишләп йөрисең монда?» — дип сорап булмаганга, мин аның белән сәлам алыштым да сүзен көтеп калдым. Ул, әлбәттә, мине танымады.

— Караңгы,— диде ул.— Ишек таба алмыйм. Укытучыларның кәнсәсенә керимме әллә дигән идем.

— Менә ул ишек, Рәхимҗан бабай!

— Шундамыни, ай, рәхмәт төшкере... Син укучымы соң?

— Укучы. Искәндәр мин, Рәхимҗан бабай. Күршең!

— Бәрәкалла, шулаймыни? Алайса син Хәбибрахман абзаңның кайдалыгын да беләсеңдер?

Рәхимҗан бабайны кочаклап ук аласым килде, ул миңа әкиятләрдәге яхшылык алып килгән фәрештә булып тоелды. Мин аны җитәкләдем, карманып эчкә уздык. Ишектән керүгә:

— Рәфгать! Хәбибрахман абзый янына килделәр! — дип кычкырдым.

Сөмсере коелып утыра иде, аның да авыз ерылып китте, тиз генә класс ишеген барып ачты да:

— Хәбибрахман абзый, йокламыйсыңмы? Монда сине күрергә килделәр,— дип эндәште.

Хәбибрахман абзый акрын гына чыкты да җан ачысы белән: «Эх!» — дип кулын селкеде. Алар кочаклашып күрештеләр. Рәхимҗан бабай, озак сәфәрдән соң очрашкан кеше кебек, Хәбибрахман абзыйның аркасын кочып торды, шапылдашып идәнгә төшкән чүпрәк тышлы тире бияләйләрен мин җыештырып өстәлгә куйдым.

— Әһ-һә! — дип кеткелдәде ул тешсез авызы белән.— Әһә-һә! Менә бит агай... Күрәсең булса, күркә талап үтерер!.. Кем уйлаган иде дә... Әһә-һә!

Еламсырады Рәхимҗан бабай, үзе һаман ирлегән ир итеп кеткелдәде.

Өчебез орынып торган күршеләр булып гомер итсәк тә, Рәхимҗан бабай белән Хәбибрахман абзый арасында шундый якынлык, ирләрчә кырыс дуслык бардыр дип уйламаган идем. Алар шулай, ике карт имән төсле, егылып китмәс өчен бер-берсенә тотынышып, сабыйларча куанышып, сүзсез генә иияк кага-кага байтак басып тордылар да җансыз, салкын бүлмәне әйтеп бетермәслек җылылык, пакьлек белән тутырдылар.

— Нихәлләрдә соң, Хәбибрахман?

— Күргәнеңчә, Рәхимҗан абзый, күргәнеңчә. Менә монда утыр. Утыр, утыр... Миңа да урындык бирүеңме, Искәндәр? Рәхмәт, рәхмәт... Әйе, Рәхимҗан абзый... Менә шул, егетләр белән кадер киче уздырабыз, күк капусы ачылмасмы дип көтәбез...

— Очратмаммы дип, әүвәл өеңә кагылдым,— дип башлады Рәхимҗан бабай, җайлап кына урындыкка утыргач.— Карыйм, өеңдә юк икәнсең. Алып киттеләр диләр... Әһә-һә... Төштән соң безгә дә яшь кенә бер нәмәстә кагылып чыкты. Прокулол дидеме... Милиция ишедер дип калдым. Шул бик җентекләп сорашты. «Ямашевның борчак алып кайтканы сизелмәдеме?» — ди.

— Туп-туры Ямашев диме?

— Шулай ди шул, бәхете арткыры!

— Син ни-нәрсә дидең инде аңа, прокурорга, дим?..

Рәхимҗан бабай җавап бирергә ашыкмады, соңгы тапкыр карап калыйм дигәндәй, төссез күзләре белән күршесенә текәлеп торды. Колакчынын салып тезе өстенә куйды, сул кулы белән түбәтәен җайлап урнаштырды.

— Нәрсә әйтим? Кирәген әйттем, Хәбибрахман, кирәген!

Картлар, хатирәләр дөньясына киткән сыман, беравык икесе дә тын калдылар, без, әдәп саклап, бер читкәрәк утырыштык.

— Гомер буе Ямашевка ышанып яшәдек без, дидем... Егерме тугызда атымны җитәкләп, беренче булып калхузга илттем, Ямашевка ышанганга илттем, дидем.

Хәбибрахман абзый эре-эре кайнар тамырлар йөгергән сипкелле кул аркасына ияген ышкыды, сүзсез генә Рәхимҗан бабайны куәтләде, күзләрен йомды.

— Җан җегәремне биреп, тау-таш ватып алган атым иде... Минем чаптар алашаны, шәт, онытмагансыңдыр, ә? Карап торырга үшән сымак кына булса да, юртак иде бит, ботларны ничек-ничек каерып сала иде... Сырт өсте кара-көрән юл иде бит...

— Хәтерләмичә... Хәйриләр токымы иде... Затлы мал! Мин җигеп йөргән «Актояк» та шулар нәселеннән килә бит!..

— Әйе, димен, гомер буе Ямашевка ышандык, димен... Тик аны моңарчы берәүгә дә әйтергә генә туры килмәде. Сораган кеше дә юк иде... Хаталык кыласыз, димен... Хаталык! Үзе болай ару кешегә дә охшаган, җүләрләнеп нишләп прокулол булып йөридер... Ипләп тыңлады, бүлдермәде, дәфтәренә теркәп куйды... Калхузга кергәндәге табагач тамгамны салдым. Котылырсың, иншалла.

Күземнән яшь атылып чыгардай булды. Бер мин генә җебегән дисәм, Хәбибрахман абзый үзе дә йомшады, кул аркасы белән туктаусыз күз чокырын сыпыргалады.

— Авызыңа бал да май, Рәхимҗан абзый. Ярый ла син уйлаганча булып чыкса!

— Үзең дә нык тор, Хәбибрахман! Ныклыкның өлгесе булдың моңарчы, бирешмә! Нахак бәлане өстеңә алма. Син әле яшь кеше. Дөньялыктагы бурычларың үтәлеп бетмәгән. Кызыңны аякка тәмамысы бастырырга кирәк, урнаштырырга дигәндәй... Шуңа күрә әйтүем булсын, кызып китә торган гадәтең бар. Үксезгә үгет бирергә килмәдем, дус итеп, күрше хакын хаклап килдем.

— Мәүлияхатти әкияте генә ич болар! — дидек без Рәфгать белән бер авыздан.

— Шулаен шулай да,— диде, шөбһәләнеп Рәхимҗан бабай.— Файдасызга чаярак хатын булды шул... Иман юк ул хатынның авызында. Гыйбадулла чулак стрәпкәсе. Ә Гыйбадулласы... Бөтен дөньяга ачулы-үчле бәндә! Акны сөймәс, кызылны кичермәс, үте сытылган кеше... Гарип кешеләр йә бик кече күңелле, йә чып-чыны збир булалар! Бу шуларның збиренең збире!

Картлар тагын хатирәләр дөньясына күчеп тындылар, без дә дәшәргә кыймадык.

— Сүзең тагын хак, Рәхимҗан абзый. Син — ил агасы. Авылда иң өлкәнебез булсаң да, зиһенең күпләрнекеннән ачык. Күңел күзең күпне күрә! Ләкин үлчәү табасына тегеләй дә, болай да салып карагач, мондыйрак исәпкә киләм мин: хәтәр эшкә тарыдым!.. Хәтәр... Өскә күрсәтеп торучы да бар... Язып та җибәргәннәр... Сугыш заманында ил табынына кул сузучыга үзем дә рәхим-шәфкать күрсәтмәс идем... Һәм менә көтмәгәндә килеп явыз кеше казыган базга төштем... Сизенә күңелкәем, Рәхимҗан абзый, кадерлем, баздан үзем генә котылып чыга торган түгел. Түгел!..

Хәбибрахман абзыйның ни уйлаганын белү кыен түгел. Ул да, Рәхимҗан бабай да, Рәфгать белән без дә: «Кем булыр? Кем шушы явызлыкны эшләр?» — дип туктаусыз баш ватабыз. Шушы шомлы сорау барыбызның да күңелен биләгән.

— Көчем дә бетенкерәп торган чак!.. Вакытын белеп чалдылар аякны... Гомеремне беләсең,— дип дәвам итте ул, ара-тирә Рәхимҗан бабайның йөзенә төбәп карап.— Бар да ил-күз алдында узды. Үзем канәгатьмен. Эшкә ашмас хыял белән үземне интектермәдем, булмастайга үрелмәдем. Бәхетне туя татыдым. Бер яктан алай да күңел китек булды: Зөлхәбирә мантымады, бер бөртек бала белән калдык... Инде менә юанычка кыз үстердем. Акыллы бала булып чыкты. Кеше арасына иртә керде. Кыз башы белән ил күзенә менде...

Рәхимҗан бабайның да иреннәре кыймылдый, ни

әйткәне генә ишетелеп бетми: «Әйе, әйе... шулай, бик шулай»,— дигәннәре генә аңлашыла. Хәбибрахман абзый иелеп терсәген тезенә терәгән, ияген учына салган, бер җайга гына һаман сөйли бирә. Менә ул, тезләренә учы белән таянып, урыныннан күтәрелде, Рәхимҗан бабай каршысына барып басты.

— Гозерем шул сиңа, Рәхимҗан абзыкаем, васыятем итеп кабул итсәң дә риза, ил арасында сүзең үтә — берүк Арзуны кыерсытмасыннар! Бәлки, мин дә югалмам, алай хөрт уйларга ниятләмим, дөреслек, мөгаен, бер ачылыр. Мәгәр дөнья хәлен белеп бетереп булмый, бәхилләшик. Кем бар, кем юк дигәндәй, Рәхимҗан абзый, күз нурым, бәхилкәй бул! Кайсы кеше белән ашка-суга да әллә ни йөрешмисең, очраганда сүз дә ничектер үрчеми, иллә мәгәр шул кешенең җир йөзендә барлыгын белеп тору гына җан рәхәте була! Шундый якты кеше безнең өчен син булдың, Рәхимҗан абзый. Бәхил бул, гаебем-кыегым булса, рәнҗеш-каргышыңны төшермә, кичер. Авыр сүз әйткән булсам, йөрәгеңдә калдырма, үткәреп җибәр, ярармы?! Ил өчен сугышып яткан солдатларны уйласам, йөрәгем өзелеп төшеп китә: шулар авызыннан икмәк урлады дигән гаеп белән китеп барам бит!.. Шунысы читен, шунысы гарьлек!.. Үз чыраеңа үзең төкергән күк, үз капкаңа дегет яккан сыман!.. Белеп чалдылар минем аякны, белеп!..

Картларның бәхилләшкәнен күрүем беренче мәртәбә иде минем, алар аягүрә басуга, түзмәдек, без дә аларга якынрак килдек, дүртәүләшеп кочаклаштык, керфекләр чыланды...

Рәхимҗан бабайны өчәүләшеп өенә хәтле озата бардык, ни булса булган!

Арзу бүген өйдә юк, ул Зәйдә иде. Аның бүген өйдә юклыгын башта бәхет дип санасам (мондагы хәлләрне үз күзе белән күрми ичмасам), хәзер аны бик тә юксындым. Аны күрмичә бер минут торырлык тәкатем калмады...

— Рәфгать, мин Зәйгә чыгып китәм,— дидем мәктәпкә кайтып, Хәбибрахман абзыйны класска ябып куйгач.

— Файдасы булырмы соң? — диде минем тугры дустым, хафаланып.

— Бармыйча ярамый хәзер. Арзу булмагач әллә ничек!..

— Иртәгә хәтле көтик... Безгә мәктәпне генә түгел, кешеләрне дә ышанып тапшырдылар...

Аптырашып, туңып байтак утырдык. Асылов вәгъдә иткән милиционер озакламый килеп тә җитте. «Тәртипме?» — дип, безгә бер күз генә салды да, класс ишекләрен ачып, кешеләрне барлады, аннары, кыршылган ак

тунын салып, күн диванны мич буенарак тартып китерде, диван астыннан чыккан чүп-чарны күрсәтеп:

— Кузгата башласаң, чыга инде шулай? Бер кузгалса, яхшысы-яманы ачык күренә! — диде, күз кысты һәм, күперенке мыегын сыпыра-сыпыра, диванга сузылып ятты.

Ятуга йоклый да башлады.

— Әйдә, әйләнгәләп керик, азрак җылынып булмасмы,— диде Рәфгать, туңган кулларын бер-берсенә ышкып.

Урамда җил, урамда буран котырына. Өй кыекларында кара өермәләр уйный. Күз ачкысыз әшәке, шыксыз төн. Җылынырга ниятләп билләрне алышып карыйбыз, булмый. Эчкә, күңелгә суык төшкән. Телләргә сүз килми... Буран битне чеметсә дә, мин аны сизмим, җил күзенә карап торам...

Буран арасыннан чыгып яныбызга килеп баскач кына, без аны абайладык:

— Арзу, син түгелме соң? — дип кычкырып җибәрдем.

— Кайтып җиткән!

— Тәмуг газаплары күрдем,— диде ул, кашына каткан кар юлларын кулы белән кубарып.— Бураны яман. Ярты юлда адашып сулга кереп киткәнмен, әле ярый, ат акыллы, текә яр өстенә җиткәч туктады...

Тындык. Кайсыбыз сүз башлар икән дип көтәбез. Арзуның сүзсезлегеннән мин барын да аңладым:

— Белеп кайттыңмы? —дип сорадым.

— Монда кайткач әйттеләр... Бабай ни хәлдә?

— Керик, күрерсең.

— Юк,— диде ул, миңа кагылып.— Иң әүвәл миңа синең белән киңәшеп алырга кирәк.

Болай да аңгырайган башымнан хәвефле уй йөгереп узды, ис тигән кеше төсле чайкалып киттем: Арзу атын тугармагандыр, хәзер бабасын алып качарга җыенадыр, мине шуңа үгетләргә телидер сыман тоелды. Курка-курка гына:

— Кая барабыз? —дип сорадым.

— Туңдым мин, Искәндәр.

Рәфгать эчкә кереп китте, без ялгыз калдык.

— Арзу! — дидем мин, аңа таба омтылып.— Ни кушсаң да үтәрмен!

Ул миңа килеп сыенды, мин аны кочакладым...

Аларга кайттык. Арзу өйгә кергәч пальтосын салырга ашыкмады, туңган бармакларына өрә-өрә, туктаусыз йөреп торды, савыт-саба шкафын ачып карады, чоланга чыгып керде, гасабиланып нидер эзләде, гүя ул үз

өйләренә кайтмаган, яратмаган ят кешеләргә фатир төшкән юлчы хәлендә иде. Баягы шигем тагын күңелгә килде: «Качыйк без, алып кит!» — дисә...

Мин качарга да әзер идем, мин Арзу өчен бөтенесен эшләргә әзер идем бүген!

— Өе дә бит аның, җылы әсәре калмаган. Мичкә ягып җибәрим булмаса!..

Ниндидер уртак эш табылуына мин гаҗәп шат идем:

— Як, Арзу, як! —дип кычкырдым.

Көне буе кеше өзелмәгән, милициясе-башкасы, пүнәтәе-мазары дисеңме, ишекне аннан-моннан ябып йөргәннәр, өйнең җылысы качкан, тәрәзәләрдә катлы-катлы боз. Арзу тиз-тиз чыра телде, пальто төймәләрен ычкындырды, шәле таралып муенына төште, мин йөгереп кенә лапастан берничә каен яркасы алып кердем. Ут күңелле генә яна башлады, без, артсыз эскәмияне мич алдынарак куеп, янәшә утырдык.

— Эчемә суык төшкән,— диде ул, калтырап.— Җылына алмыйм.

— Ял итәргә кирәк сиңа, Арзу. Сәгать ничә икән?

— Туктаган,— диде ул, герләре идәнгә хәтле салынып төшкән стена сәгатенә карап. Ул да, мин дә урыннан кузгалмадык, сәгатьне җибәрәсе килмәде.

Мин аның кулларын учыма алдым, ул карышмады гына түгел, ризалыгын, сөенгәнен белдереп, сизелер-сизелмәс кенә елмаеп, миңа табарак тартылды. Аның шушы кыен төндә елмая алуы өчен әллә ниләреңне бирерлек иде! Еламады, зарланмады, карганмады, елмайды!.. Шушы буранлы кара төндә ул үзенең якты күңеленә иптәш итеп мине сайлады, елмаюын миңа бүләк итте...

Әллә бабасы белән булганнардан соң бераз йомшап төшүе генәме Арзуның? Мин аның йомшаклыгыннан файдаланып кәпәренеп утырмыйммы?!

Кадерле, бик кадерле бармакларын иреннәремә якынайтып, җылы тыным белән өрә башладым. Ул баягыдан да җылырак хис белән миңа карады, мин аңа. Юк, юк, Арзу җебеп төшә торган кыз бала түгел, мин дә аның егылганын түгел, калкынганын көтәм. Бу аулакта, бу мизгелдә аның саф күзләренә туйганчы карый алам...

Чак кына күперегеп торган сусыл, алсу иреннәр пышылдадылар да минем исемне әйттеләр:

— Искәндәр...

Бервакыт әнием аңа: «Шушы хәтле кызыл сөртмәсәң, Арзу, абау!»— дигән иде. Арзуның әнкәсенең иреннәре дә шулай кызыл, теп-тере булган дип, бераз мәсхәрәләп сөйлиләр иде авылда, шуңамы, ул бик читенсенде, ак кулъяулыгы белән иреннәрен кат-кат сөртеп әнигә

күрсәтте: «Үзе шундый ич, Фәгыйлә апа!» — дип бик өзгәләнде.

Минем өчен Арзудан да кадерлерәк кеше юк хәзер дөньяда! Сүзе — җыр, карашы — моң, үзе — аккош баласы. Тик ятим...

Чынлап уйласаң — үксез бала ич ул! Ата-ана назыннан мәхрүм калган бер ятим. Моңлы бала... Гәрчә ул бу турыда бер чакта да сүз кузгатмый, ятимлеген искә төшергәнне яратмый.

Ә менә бүген, шушы хәлдә, ятимлеген кискен тоядыр ул!

Нигә бабасы янына кермәде икән?

Нигә Рәфгатьнең барлыгын да онытты...

Мине чакырды, мине сайлады...

Нигә?

Дөрләп янган ап-ак каеннарга текәлгән кап-кара күзләрдә нинди уй? Алсу иреннәр нигә шулай ярсып кысылган?! Йомарланган йодрыкларда нинди сер?!

Ут шәүләсе аның күз алмаларында бии, битен тагын да алландырып, серле итеп күрсәтә. Колак бөтеркәләренә эленгән кызыл алкалар ут яктысында әле куе шәмәхә, әле кан тамчысыдай дәһшәтле ал булып яналар...

Сүз башларга теләп, ике-өч тапкыр талпынып карадым, ул бармаклары белән минем авызны томалады.

— Кирәкми, Искәндәр.

Сүз кирәкми икән, эш кирәк! Ә нәрсә эшләргә? Үпкәләргәме, сөенергәме — белмим. Арзу минем янда, минем янымда!.. Ләкин бабасы... Тегендә калды, тоткынлыкта... Иртәгә Арзу шул класс бүлмәсенә, балалар янына барырга тиеш... Балалар каршысына... Ни уйлый ул, нигә дәшми?

Уйларының уртасында мин дә бардыр дип санарга йөрәгем җитми. Төне ул түгел, вакыты ул түгел.

Нигә мин утырам соң алайса аның янында?!

Болай сүзсез, берни аңламыйча, берни белмичә күпме газапланырга мөмкин?!

Өй җылынмады, без кайнарландык, бишмәтләребезне салып ташлап, тагын янәшә утырдык. Бу юлы мин аның тән кайнарлыгын ныграк, ачыграк тойдым, миңа бик рәхәт, ифрат рәхәт, бер үк вакытта чамасыз газаплы, сагышлы иде. Күңел беркавымга онытылып иркәләде дә тагын сызланды.

— Арзу!..

— Түз, Искәндәр!..

Түзмәдем, түзәр чамам калмады, сикереп тордым, сәгатьнең боздай салкын герен өскә күтәрдем. Буявы купшакланган сәгать келт тә келт йөри башлады, вакыт-

ны, чама белән, өч дип куйдым... Сәгать тавышыннан өй эчендә нидер үзгәрде, моны икебез дә ачык сиздек. Вакыт тукталмаган икән, ага икән ул, безнең тамырларыбызга тулып ага, төн карасы белән кушылып ага, безне, Хәбибрахман абзыйны, Рәхимҗан бабайларны, илләрне, чикләрне, окопларны, танкларны үзенә ияртеп ага... Бу иртә, бу таң безнең барыбыз өчен дә ни китерер?

Мичтә чатыр-чотыр каен утыны яна, мич казнасына сыймаган ялкын телләре, ябырылып, мич авызына тартылалар. Ялкын безнең тезләрне пешерә, күзләрне сукырайта. Эскәмияне чак кына арткарак күчерәбез. Алда ут, ялкын, артта караңгы, салкынлык, бүрәнәләр суыктан шартлап ярылалар!..

Сәгать келт-келт йөри... Вакыт хәзер безнең ихтыярдан ычкынды, без вакытның колларына әйләндек... Тиздән беренче, икенче әтәчләр кузгалыр... Тиздән таң атар, тиздән Хәбибрахман картны алып китәчәкләр...

— Арзу!

Ул минем авызны томалагач, сәгать тавышын мин тагын да ачыграк ишетәм, кыяр-кыймас кына аның хуш исле бармакларын үбәм. Чак кына калтыранган озынча, салкын бармаклар иреннәремнән аерылып минем битемне сыйпыйлар, каш-керфекләремне барып табалар («Кашлар, Искәндәр, үзеңдә!» — дип пышылдый ул), иркәлиләр, ул минем йөземне үзенә табарак китерә... Кыюланып аны кочып алам, ул ялкын телләренең ал шәүләсе белән уралып минем куенга иңә, иреннәр ялкынланып бергә кушылалар...

— Искәндәр,— дип пышылдый ул, күзләрен ярым йомып.— Хәзер барысы да мин теләгәнчә булды.

Аh, бу сәгать тавышы да булмаса. Нигә кузгаттым мин шул карга оясын! Ямьсез тавышлы икән ул, каты тавышлы...

Арзу!

Мин куркып артка тайчынам, ул ычкындырмый, йотылып минем күзләремнән нидер эзли... «Минем күзләремдә комсыз мәхәббәт ич, Арзу, карама... Минем күзләремдә шик белән шөбһә генә ич, эзләнмә, Арзу!»

Акыллы иптәшем күзләремнән барын да эзләп таба, ал иреннәр арасыннан ак сызык булып тешләр җемелдиләр...

— Әйтмәсәң дә беләм, Искәндәр, яратасың... Син дә миңа бик якын. Дөньяның бик кадерле бер кисәге син минем өчен,— ди...

Мич янып бетеп, шау күмер төшкәнче бер-беребезгә сыенып утырдык. Йокы килми, сәгать һаман искә төшереп торса да, без дөньябызны бөтенләй оныттык бүген.

— Искәндәр, исеңдәме? Миннән шигырь дәфтәремне сораган идең.

— Әйе. Син бирмәгән идең.

— Бүген ал. Мә.

Дәфтәр минем кулда, тик мин куана алмыйм, аптырап Арзуның дымлы күзләренә карыйм. Көтелмәгән юмартлык мине сагайта, куанычымны киметә.

— Ни уйлый синең җаның, Арзу? Нигә бабаң янына кермәдең? Нигә дәфтәрне хәзер бирәсең? Көндез ярамыймы?

Ул башын югары күтәрде:

— Иртәгене кем белгән, Искәндәр. Бабай янына кермәдем, сәбәбен сизәсеңдер... Гомер юлыңны тәмамлап килгәндә, чал сакалыңа «карак» дигән яманат ябыштырсыннар әле... Күтәрә торган хәсрәтме соң бу?! Мин уйламыйча моны кем уйласын?! Ул бит миңа әти дә, әни дә булган кеше... «Таянып ял итә торган талларымны кискәннәр» дигән җырны ишетеп беләсең... Талсыз калдырдылар мине... Бабайның үзен дә!.. Ә дәфтәрне ал син, ал, курыкма!.. Чын шигырьләргә бер чакта да пычрак кунмый, гайбәтче теле дә кисә алмый аларны!.. Ал, ал, сихерләмәм! Сихерем булсамы...

— Нишләр идең, Арзу?

Сәгать тавышы аны да борчып торган икән, ул тиз генә барып аны туктатып килде.

— Их, Искәндәр! Елан кабыклары салып берни эшләтә алмаганнар иде, бер пот борчак кертеп башны ашадылар. Сихерем булсамы, шул явызларны җинаять өстендә тотып алыр идем... Утлы күмер өстендә яланаяк биетер идем мин аларны!

Шушы сүзләрдән соң, Арзу күзгә күренеп үзгәрде, сабырланды, җитдиләнде, сораганнарга җавап бирмәде, таләпчән тавыш белән кайтып китүемне үтенде.

Ул мине озата чыкты. Капка төбендә тездән карга батып без тагын кочаклаштык. Кайгы китердеме аны минем кочакка, ялгызлыгымы? Мәхәббәтме, нәфрәтме? Сөенергәме миңа, көенергәме? Гашыйклар да шундый хәлдә кала икән, и дөнья!..

Иртәгә бик озакка, бик күпкә аерылырга җыенган кешеләр төсле хушлаштык.

— Арзу!..

— Булды, Искәндәр. Хуш, тугры дустым. Бүгенгә дәфтәргә карамый тор, яме.

Тукайларны, Есениннарны салкын мәктәпкә, Хәбибрахман абзыйның бер төнлек төрмәсенә әйләнгән мәктәпкә алып барасым килмәде, ишегалдыбызга кердем дә

дәфтәрне лапастагы печән арасына кыстырдым. Печәннән кояш исе, Арзуның чәч исе килә иде. Әллә мин кыштырдаганга уянып, әтәчебез кычкырып җибәрде, аны күрше әтәчләр күтәреп алды. Мәктәп янына җиткәнче тынмады Югары авыл әтәчләре. Ни хәбәр итәсез сез бүгенге таңда? Ни сөйлисез? Буран басылса да, минем күңелдәге бураннар басылмаган бит әле!..

Әтәчләр «кикри-күк!» тә «кикри-күк!» дип һаман бер җырны суза дигән кешеләр тирәнтен ялгышалар... Ул төндә әтәчләр, үз йортларының серләрен ачып, һәммәсе үзләренчә кычкыра иде... Берәүләр «Хуш!» диде, икенчеләре «Буш!» диде... Ә миңа хәбәр кирәк бит, әтәчләр, җылы хәбәр кирәк... Кайсы йортның алтын кикриге шул хәбәрне китерер безгә?!

## 15

Күзгә йокы кермәде. Кайгы булганда күңелдә йокыга урын калмый. Асыловның килеп җитүен сабырсызланып көтеп тордык. Нәрсә булса да ачыклый алмадымы икән? Безнең кулдан килмәде, бөтен өмет хәзер аңарда иде.

Җыештыручы апалар килеп мичкә ягып җибәргәч, милиционер да торып утырды. Тоткыннарны барып карады, почмактагы су багыннан кружкага салкын су агызып, учы белән бер-ике тапкыр битенә сипте, канәгатьләнеп пошкырды, кесәсеннән тарак сыныгы чыгарып, мыегын бөртекләп тарады, шуннан соң, кәефләнеп, тәмәке кабызды. Рәфгать белән без дә аннан берәр төрерлек сорадык. Өчәү диванда утырып төтәтәбез.

Йокысызлыктан йончыса да, чип-чиста итеп кырынган, кардай ак күлмәген кигән Асылов яктырыр-яктырмаста килеп җитте. Килеп тә керде, Хәбибрахман абзый ябылган класс ишеген ачып:

— Сез азат, өегезгә кайтыгыз,— диде.

Карт үз колакларына үзе ышанмады, ахры, беравык партага таянып тик карап утырды. Асылов сүзен кабатлагач, иңенә элгән тунының җиңнәрен киде, төймәләп тормады, саубулашмады, селлин-селлин атлап чыгып китте.

— Бичара агай! — диде Асылов.— Шатланды шатлануын... Тик үзен нинди хәбәр көткәнен генә белми.

— Борчакны кем урлаган соң? — дидем мин, түземсезләнеп.

Асылов җавап бирергә ашыкмады, бераздан тамак төбе тавышы белән:

— Арзу Ямашева,— дип куйды.

— Ничек ул? — дип кычкырып җибәрдем мин.

— Үзе килде. «Мин гаепле»,— диде.

— Ә Мәүлиха апа?

— Егет, егеткәй! — диде әрнеп Асылов.— Кичә шулай дигән иде, бүген иртән бөтенләй башкача... Арзу Ямашеваның идарәгә килеп, гаепне үз өстенә алуын каян ишетеп өлгергән диген! Җитмәсә, ике кызын да иярткән.

— Кәримә дә килдеме?

— Әйе. Арзуның капчык күтәреп кайтканын күрдек дип өчәүләшеп чатнатып торалар.

— Кияүләрен дә ияртмәгәннәрме? — дидем мин.— Ул да күрми калмагандыр!

Ачу белән әйткән сүзләремә дә Асылов җитди җавап бирде:

— Анысы өйдә юк. Тегермәндә куна калган, диләр. Мин чәчрәп алгарак чыктым.

— Ямашева борчак урламаган, ул борчакны аларга кертеп куйганнар! —дип кычкырдым.

— Бәлки, син моны исбат та итә алырсың?

Асылов шаяртмый иде, күренеп тора. Мин:

— Тырышып карыйк! — дидем һәм көзлектә кое янында булган хәлләрне, күлмәк эченнән чыккан хәшәрәтләр турында, Арзуны бозарга теләүләре турында, кабалана-кабалана, сөйләп бирдем.

— Нигә моңарчы су кабып йөрдең? — диде Асылов кызып.— Күлмәк кайда?

— Күмгән җиреннән казып алыйммы соң?

— Эзләп кара! Тиз бул!

Рәфгать йодрыгы белән миңа төртте:

— Сөйләгәч, барын да сөйлә! —диде.

— Мәүлиха ападан чиләк сорагыз сез, иптәш Асылов. Көз көне коега төшкән чиләкне, диегез. Янгыннан соң чиләк күрсәткән идегез бит, таныш кебек тоелды ул миңа.

Асылов бер агарынды, бер күгәренде:

— Малай! — дип кычкырып җибәрде.— Казы! Күлмәксез күземә күренәсе булма!..

Мәктәпкә берән-сәрән генә укучылар килә башлады, милиционер Сырур апа белән Гөлбәдәрне алып чыгып китте, без идарә яныннан йөгергәндә, җыелган халык уртасында Арзуның ак шәлен күреп алдык. Янына барып торырга вакыт тар иде, тиз-тиз безгә чабып кайттык, әни болдырда борчылып кычкырып калды, без лом, кәйлә, агач көрәк, тимер чөй ише кирәк-яракларны алып тыкрык башына йөгердек. Бабайның таш чыгаргандагы коралларының кирәге чыкты!

Әле ярый, кычыткanlыкка күмгән идем, хәзер дә ку-

райлары җилдә сызгырып утыра, билгеле урын, арада уйдык-уйдык буш урыннар да шәйләнә, табарга ансат булыр. Беравык эзләнеп, чамалап карадым да:

— Менә шушында бугай,— дидем. Рәфгать ачулы иде:

— Син «бугай» күмдеңме, әллә күлмәкме?.. Асылов сине чын исемең белән атады, ахры! Малай син!

— Шушында! — дидем мин дә, кызып.— Шушында! Әнә теге чатлы казык төбеннән ат башы хәтле таш китереп салдым. Шушында!

Эшкә керештек. Агач көрәк белән карны арчып җиргә хәтле төштек, чал аю күк бәсәргән туң җир күренгәч, бишмәтләребезне салып ыргытып, ломга тотындык. Казыйбыз, казыйбыз, кәйлә белән дә селтәнеп карыйбыз, туңган җир суккан саен, әчтерхан чикләвеге хәтле генә куба, йокысызлыктан арган күз төпләре сызлый, кайчаннан бирле туя аш күрмәгән эчләребез авырта, әмма без бер тынга да туктамыйбыз. Рәфгатьнең җилкәсеннән сыек пар күтәрелә, мин дә күлмәк изүе турыннан корсак өсләп тир тамчыларының аска йөгерүен сизәм.

— Казыган җиргә охшамый бу бер дә,— диде Рәфгать, маңгаеннан куе тир сыпырып.— Тоташ туң.

— Шушында булырга тиеш!

— Икеле-микеле сөйләшә торган әкәми булып чыктың син дә!.. Авызны тутырып сөйләшер чакта, теш араңда камыр әвәлисең!

Яктырды. Апалар, җиңгиләр суга төшә башлады, алар туктап кызыксыналар: «Окоп казыйсызмы әллә?»— диләр, «Ни тилереп болай азапланасыз, хәзинә-мазармы әллә?»— дип көлешәләр, без дә аларның сүзен уенга борып җибәрергә телибез, ләкин ярсудан күгәргән иреннәрдән шушы туң балчык төсле салкын, авыр сүзләр генә кысылып чыга.

Мәүлиха апа да күренде, кичәгечә ару шәлен бәйләгән, томырылып төшеп килә, биимени! Авызы ачык:

— Бәрәкәт, алтын чокыйсызмы әллә, бик тырышасыз! — дип көлде ул.

Сүзенә игътибар итмәдек, әмма аның кыланып һаман китми торуы, көянтәсен бер иңеннән икенчесенә көяз генә күчерә-күчерә, кечкенә күзләре белән тишеп-тишеп каравы нидер аңлаткан төсле булды.

Күз төпләреннән зәһәр ага, нәфрәт ага.

Нигә шултиклем куралмый икән ул мине?

Юк кына бит, егылып үләсеңмени, күлмәк тә юк, чурт та юк, өстенә бастырган таш та чыкмый.

— Дөмектергәнсең икән үзең дә! — диде Рәфгать, өметсез тавыш белән.

— Дускаем Дындып! — дидем мин, әрнеп.— Егылыр урынымны белсәм, түшәк кабартып куяр идем, дип әйтте ди берәү!.. Төшкә дә кермәгән хәлләргә дучар булдык. Кем уйлаган бит ул чагында... Җире йомшак, ачуым бик каты иде...

Арып, алҗып, эт булып, үзебез казыган чокырга аякларыбызны асылындырып утырдык та көрәк сабы белән тирәнлекне үлчәп алдым.

— Юк. Монда түгел. Үпкәләмә. Болай ук тирәнгә китмәгән идем.

— Җире каты, ачуы да катыракмы бүген? — дип көлемсерәде Рәфгать.

Чатлы киртә баганасыннан атлам белән үлчәп, икенче ачыклыкны чокый башладык. Мәүлиха апа икенче кат суга төште...

Җил кычыткан куралары арасында усал сызгыра, бүселеп чыккан күлмәк итәкләрен җилфердәтеп аркага кереп тула, өшетә, яман! Бу юлы дөрес казыганбыз икән, аршын чамасы төшкәч тә, мин күмгән таш килеп чыкты, таш тирәли ныгытып-ныгытып казысак та, күлмәк тә, черек чүпрәк-фәлән дә, күлмәк эченә тутырылган хәшәрәтләр дә күренмәде.

— Тычкан кимереп бетермәгәндер бит ләгънәтне? — диде Рәфгать.

Ул бер төн эчендә сураеп, курачланып калган, кара шадралары чабата-чабата тирәнәйгән, уң күз астындагы җәрәхәте кара кучкылланган. Ләкин ул эзләшергә әзер, тагын бер түгел, ун чокыр казырга, булышырга, табарга, минем өчен, Арзу өчен яхшылык эшләргә атлыгып тора...

Мин ни төсле идем икән?!

Асылов, кулга алынганнарны районга озатырга җыенып, түземсезлек белән безне идарәдә көтеп утыра иде. Халык төркеме безгә юл бирде, башымны түбән иеп аның янына кердем, ишек яңагына сөялдем, сөялмәсәм аварлык хәлгә җитеп арган идем. Асылов күтәрелеп карады да барын аңлады.

Бүлмәдә ул берьялгызы, идәндә Мәүлиха апалар чиләге. Без коедан алган чиләк. Очлы багор белән сызылган ике сызыгы да бетмәгән. Чиләк исән, чиләккә ияреп чыккан күлмәк кенә юк...

— Югалган... Юк, Нәҗип абый,— дидем мин, шашынып.

Идарә алдына чыктым. Идарә алдында халык. Уртада милиционерның ак туны, Хәбибрахман абзыйның көмеш сибелгән башы һәм Арзуның кәҗә мамыгыннан үзе бәйләгән ак шәле күренеп китте. Нишләргә?

Мәүлиха апа, ыштыр бит, кызларын ияртеп чыккан, Кәримә белән чыш-пыш колактан колакка нидер сөйләшәләр, ызгышалармы шунда: Кәриманең күз яшьләре менә тамам, менә тамам дип мөлдерәп тора.

Моңарчы ялкаулык дисәләр — күз алдыма Мәүлиха апа килә иде.

Моңарчы гайбәт дисәләр — бары тик аны уйлый идем, Мәүлиха апаны.

Моннан соң мәкер дисәләр, шул апаны исемдә тотармын.

Онытырлык итмәде. Нәфрәт тә Мәхәббәт кебек үк үзен мәңгеләштерә белә! Моннан соң Нәфрәт дисәләр, хәтеремә кара күләгә булып шушы көн, шушы көннең илһамчысы булып Мәүлиха апа иңәр!.. Их, чыраена берне төкерергә! Суймас пычак белән тиресен тунарга!.. Ачу килгәндә безнең авылда шулай диләр...

Тик мин ни кыра алам? Мәхәббәтем Нәфрәтем янында көчсез бүген. Мәхәббәтем Мәкер алдында тез чүкте. Гыйбадулла чулак безне Сирай белән көрәштергәндә: «Ягез әле, ягез... Кайсыгызның кавырсыны каткан икән? Кайсыгыз өлгереп җиткән?» — дип, юкка гына бер-беребезгә өстермәгән икән. Мәхәббәт һәм Нәфрәт хокукын алыр өчен дә өлгереп җитәргә кирәк икән!

Аптырагач, Рәфгать янына барып бастым, беләм, безнең йөрәкләр бердәй тибәләр бит бүген... Беләм, ул мине дә гаепли. Әгәр көздән үк тәвәккәлрәк булсам, бүген бу хәлләр... бәлки... бәлки...

Күңелләрне шомландырып идарә алдында ике ат тора. Алларына салган коры печәнне ясканып ашыйлар. Шунда ук алама сакалына тигәнәк кисәкләре укмашып каткан арык кәҗә дә ялманып йөри, ике-өч малай трайлы уйныйлар, ат тизәге тибәләр...

Алама кәҗә, карак кәҗә!..

Югары авыл урамнары, кешеләре, морҗаларыннан чыгып җиргә түшәлгән аксыл төтен дә ят бүген... Барыбыз да идарәдән Асыловның чыкканын, аның кузгалырга әмер бирүен көтәбез.

Кәҗә башы урамы хатыннары Сырур белән Гөлбәдәр тирәсендә. Сырур апаның теле монда да тик тормый, җыелганнарга нидер сөйли, көлешеп тә алалар. Чыннан да, «утка кергән хатынның утыз авыз сүзе бар»! Гыйбадулла чулак каламы, ул да монда! Монда! Кулларын җиңе эченә тыгып, юри бөкрәеп, төркемнән төркемгә иснәнеп йөри, дәшми, тыңлана. Яхшырак ишетер өчен, колакчынын өскәрәк күтәреп куйган. Онытгы Илдусны, килене Хәтимәне ияртеп, Рәхимҗан бабай да килеп җитте. Хәтимә апа, ак тастымалга төреп, күчтәнәч алып килгән,

шуны Арзуга бирде, яулык чите белән күз яшьләрен сөртә башлады. Кара син, әнием дә монда икән бит, Арзу янында ук басып тора; Нәсимә дә шунда, әнинең бишмәт итәгенә тагылып борынын мышкылдата.

Кешеләргә күтәрелеп тә карарга базмыйча, алар янына барып җиттем.

— Арзу...

— Менә Искәндәр дә озатырга килеп җиткән,— диде ул, моңаеп кына.

— Нишләдең син, Арзу? — дип пышылдадым мин.

— Ни булды?

— Нишләдең?

— Башкача җае юк иде, Искәндәр,— дип пышылдады ул.— Башка юлы юк.

Менә председателебез килеп идарәгә кереп китте, озак та үтмәде, алар Асылов белән болдырга чыктылар, халык төркеме чайкалып алды. Асылов сүзсез генә кул изәде, милиционер кулга алынганнарны утырырга өнди башлады.

Айлар буе фронтларга кеше озатып тордык-тордык та, мә сиңа, төрмәгә җибәрәбез!..

Айлар буе фронтларга итен-маен, икмәк-бәрәңгесен, башка кирәк-ярагын озатып яшәдек тә, менә сиңа каракларны озатабыз... Югары авылдан биш кеше. Шул бишнең берсе Арзу...

Алама кәҗә чанага ук менгән, куганны да белми, ашыгып-ашыгып печән чемченә. Бер чанадан куып төшергәннәр иде, икенчесенә барып ябышты, мөгезле шайтан, сансыз, һайт, мәлгунь!

Шау-гөр килдек, кемдер үксеп җылап җибәрде, олаучылар каушап, дилбегәләре ат аягы арасына кереп буталды. Аннан кинәт тынлык урнашты. Кәҗә башы урамыннан, тегермән ягыннан кушаяклап атын чаптырып берәү килә иде. Ул чанасына аягүрә киерелеп баскан да, дилбегәсен болгап, атын туктаусыз чарлый, сызгыра, акыра, чана әле бер якка салулый, әле икенче якка шуып китә, кар сиптерә. Кеше егылмый, атын җан-фәрманга һаман каулый.

— Туктагыз, әй! Тукталыгыз, һай! Көтегез, көт!

Баягы кәҗә чак кына ат астында калмады, борын тишекләре чамасыз киңәйгән, манма су булган ат халык төркеме арасына ерып керде дә, тәртә башлары белән кемнедер егып, шып туктады. Чанадан Сирай сикереп төште. Туны җилбәгәй, яланкул, күлмәк изүенә хәтле ачык, изүеннән аксыл куе йон үскән таза күкрәге күренеп тора.

Моңарчы бу чуалышка һич катнашы, бер гаме юк кебек читтән-чоттан гына йөргән Гыйбадулла кай арада Сирай янына барып җиткәндер, хәзергә хәтле аңламыйм.

Сирай ике сикерүдә тоткыннар төялгән чана янына барып җитте дә:

— Арзу, сине виноват ясадылармы? Сине алып китәләрме? — дип кычкырып җибәрде.

— Күргәнеңчә,— диде Арзу, толып итәге белән аякларын төреп.— Нигә алай дидең, Хәбибов?

Милиционер иңе белән Сирай бер читкәрәк какты да чанага тезләнде:

— На-а, кузгалдык,— дип, атка да, олаучыга да эндәште.

— Тукталыгыз! — дип акырды Сирай.— Тукта!

Асылов, идарә баскычыннан төшеп, тиз-тиз чаналар янына килде. Кызарынып-бүртенеп торган Сирай, шашынып, аңа борылды:

— Арзуның гаебе юк. Ул бур түгел,— диде.

— Кем гаепле соң? — диде Асылов, егеттән күзен алмыйча.

— Борчакны мин керттем. Чоланнарына керттем дә бушаттым. Кисмәккә.

Тирә-яктагылар аһ итте, арттарак торганнар ишетмәделәр, алар, Сирай белән Асыловны кысрыклап, уртага ябырылдылар, терсәкләр хәрәкәткә килде.

— Прокурор иптәш,— диде Гыйбадулла, Сирайның атын бора-бора,— күрмисезмени, исерек бит. Кеше таптата язды, юньсез. Кәҗәнең боты сынмадымы икән, тикшерәсе бар!

Сирай өчен Гыйбадулла юк иде бу минутларда, Арзуга карап йотылган иде ул. Милиционер да чанадан төште, сорау белән Асыловка карады. Арзу толыбын чанада калдырып карга сикерде, Сирай каршысына килеп басты:

— Йә, йә, Сирай!

Мәүлиха апа бер яктан, Гыйбадулла икенче яктан Сирайга асылынып, читкә сөйри башладылар.

— Исерек ич, исерек! Чак басып тора,— дип чәрелдәде Мәүлиха апа.

— Алай булыр дип уйламадым, Арзу, ышан. Уен диебрәк санадым...

— Хәбибов, әйтеп бетер,— диде Асылов, аны кызулап. Гаҗәп хәлнең башлануы гына кирәк икән! Ерылган буаны саклап алып калырмын димә, теләгән хутын ала икән ул... Кеше арасында җайсыз кысылып торган олы гәүдәле Кәримә иренең күкрәгенә килеп капланды, илереп җылады:

— Әйт барын да! Әйт! Калдырма! Котыл, Сирай! — дип инәлде.

Сирай сыңар кулы белән Кәриманы үзенә тартты, кочаклады.

— Борчак минеке. Арзу бур түгел,— дип кабатлады.

Мәүлиха апа, вак тешләрен ыржайтып, этәч шикелле очынып, кызына кунды, чәченә ябышты.

— Төнлә туган! Тилебәрән орлыгы ашаган исәр! Төнтек! — дип чырылдады. Әниләренең яман тавышын ишетеп башка кызлары да чырылдаша, җылаша башладылар. Хәбибрахман абзый, нишләргә белмичә, әле бер кеше янына бара, нидер әйтергә тели, аскы ирене калтырый, сүзләре чыкмый.

Кәримә, чәчен әнисе кулыннан ычкындырырга теләп, төрле якка йолкына-йолкына бөтен урамны тутырып кычкыра башлады:

— Җитәр! Ашадың башымны! Артыгы булмас, булмас... Сирай, җаныкаем, сөйлә. Түзәр әмәлкәем юк! Гомер буе Арзу белән тиңләп, аның белән чагыштырып җанымны таладылар. Аннан узар өчен яшьли кияүгә бирделәр... Үзем үз була алмадым. Чулагын да әйт, башкасын да, аяма берсен дә!..

Без барыбыз да, тетрәнеп, сүзсез калдык,

* * *

Алдагы атнада безне военкоматка чакырып алдылар. Ниһаять, теләгәнебез алга килде: безне хәрби уку йортына озаталар. Аннан фронтка, фашистларны тукмарга. Рәфгать тә китә, мин дә. Югары авыл урамнарын бер итеп, никрутлар булып йөрибез...

Китәр көн дә җитте... Авыл чыкканчы безне шактый кеше озата барды. Арзу, Рузилә... Кәримә дә монда...

Иң шәп атларны җигеп, Хәбибрахман абзый безне Бөгелмәгә кадәр илтә барды.

*Июнь, 1972. Сентябрь, 1973*
*Займище — Казан*

# Язгы кәрваннар

Җанны өшетә торган салкын коры кич килде.

Көндез алдаучан җылы булып торды да, төш авышуга, мә сиңа, зират тавыннан өзлексез җил исә башлады. Зират тавыннан, кояш баешыннан искән җил, гадәттә, үзәнлектә ышыкланып утырган безнең бәләкәй авыл өстенә язын-көзен яңгыр, кышын исә кар-буран алып килә торган иде. Бүген битләрне аяусыз чәнчеп, киемсалымнарны әрсез йолыккалап туктаусыз коры салкын җил исте, суытты, көн ямьсезләнде. Карт-корылар мич яңакларын сыйпаштырып чамалап тордылар да тиз үк мичләргә ягып җибәрделәр, ишегалларында, җил утәрдәй араннарда калган мал-туарны җылы абзарларга куып керттеләр.

Көне буе ачык һавада уралганга, без көннең аз гына үзгәрүен дә сизеп-искәреп торабыз. Җил азаюына игътибар иттек, чын күңелдән сөенештек, ындырдан җиде олау солы төяп төнгә каршы Чаллы элеваторына юлга чыгасыбыз бар иде.

Кабан авылы аша барсак, юл шактый кыскара кыскаруын, әмма ике авыл уртасында җиде чакрымлы кара урман ята, кичә-бүген аязып торса да, урман юлларына тоташ яңгырлардан соң баш тыгарлык түгел. Шул сәбәпле әйләнечтән — Түбән авыл аша барабыз. Анда да шул ук кара урманның дәвамы, әмма андагы юл өстендә такта яру заводы бар. Завод дип, хәзер аның исеме генә калган. Сугышка хәтле анда чыннан да такта яралар иде, җидеме-сигезме түгәрәк пычкылары да бар иде, безнең тып-тын урманнарны ярып аваз салырлык бердәнбер гудок та шушы заводныкы иде. «Ду-у-у!» дип, безнең яшь йөрәкләрне җилкетеп, күңелне кузгатып кычкыртып җибәрә торган иде, искиткеч! Бишавыл базарына кыяр сатарга барганда урманда гудок тавышыннан сискәнеп

калтырансам да, авылга кайткач ,малайлар алдында атна буе үземнең дә мактанганым бар. Завод янышнан узу үзе бер рәхәт иде. Түгәрәк пычкылар күз иярмәс тизлек белән чож да чож әйләнәләр... Бөтен җиргә сап-сары нарат такталарны сыртлап өйгәннәр. Ап-ак юкә тактасы өемнәре дә бар. Бер кырыйдарак пычкы чүбе таулары, тары көшеле сыман, кояшта ялтырап яталар. Малайларның шау-гөр килеп шул таудан шуып уйнауларына карап, без үлеп көнләшә идек! Бөтен җирдә борынны кытыклый торган әчкелтем-татлы агач исе...

Хәзер завод үзе юк, озынча моңсу баракларның түбәләре, арык ат сырты төсле бөгелеп, җиргә иңгән... Аркылы-торкылы такталар белән ярым томаланган тәрәзәле бер-ике бүлмәсендә ялгыз карчыклар, тол хатыннар һәм җиту чәчле, җиткән тырнаклы балалар яшәп ята... Үткән-сүткәндә коеларыннан су эчеп китәбез, гаҗәп, кое суларыннан да нарат сагызы тәме килә аларның, ат сугарабыз, кышкы бураннарда, көзге караңгы төннәрдә барак тәрәзәләрендәге тычкан уты кебек кенә җемелдәшкән сүрән утларны күргәч эчкә җылы йөгерә!..

Авыр, мәшәкатьле юлларда һәр җан иясенә куанасың, ут яктысы ялгыз түгеллегеңне искәртә, терелтеп, көч биреп җибәрә!..

Шакмаклап-матурлап өелгән такталарны ташып бетерделәр, түгәрәк пычкыларның күгәреп тешләре коелды, пычкы чүбе көшелләре череп муртайды, аларны юан нык сабаклы алабуталар, сажин-сажин кычыткannар күмеп китте...

Урман юлын сугыш алдыннан гына вак таш җәеп, тракторлар белән таптатып ныгытканнар иде, хәзер аның да күп җирен яңгыр-кар суы юып бетерде, юл кылдыйбылдыйга әйләнде, шулай да ул кыргый, тар Кабан юлына караганда корырак, өметлерәк. Җиде чакрым әйләнеч безнең өчен бик күп, бик артык югыйсә, әмма нишлисең, телне тешләп булса да йомышка-юлга, Чаллының атаклы икмәк складларына Түбән авыл аша йөрибез...

На, бахбай!..

Шулай дәрт иттек, урау юлдан Түбән авыл аша барабыз! Җил тына төшү дә безнең файдага, югыйсә җилгә каршы бару атларга да хәлгә килә, безнең дә ачуны чыгара, Имән урамын чыккач та, Түбән авылга таба тоташ үр төшә, арада каһәрле генә ике чокыр бар. Берсе Сай

чокыр, икенчесе Тирән чокыр... Гел безне сагалап торган шул каһәр суккан тәбеләр дә булмаса... җил дә уңайдан иссә... әйләнечтән юл турырак!

Йөк өстенә ике солы көлтәсе бәйләп куйган идем, арка терәп утырырга бик җайлы, фил колагы тикле якалы толып-чикмәнгә төренәсең дә һәйбәтләп менеп кунаклыйсың.

Күз тимәсен, юл да болай коры гына, җир дә сурыккан, соңгы атналарда солы тирәсендә бераз тугайган атлар да күндәм генә баралар, майламаган тәгәрмәчләр генә, ризасызлык белдереп, шыгырдыйлар...

Имән урамын чыгып бер җир буе киттекме икән, уң яктан, Олы су дип йөртелгән үзебезнең инеш буеннан, үзәнлектән җыр тавышы ишетелде. Бер кыз җырлый иде. Башта, бу суыкта, күз бәйләнгәндә кайсы исәре шырылдап йөри икән дип, мәзәк итеп кенә тыңлаган идем, кинәт калкынып турайдым, чикмән якамны кайтардым. Кызның тавышы аермачык ишетелә, кызның тавышы йөрәкне өзәрлек моңлы, ягымлы иде.

Җил басылды, бөтенләй тынды-сүнде, атлар адымнарын акрынайттылар, сагайдылар, тәгәрмәчләр генә әрсезләнеп шыгырдый, тын тартырга куркып колакларымны үрә торгыздым. Кыз юлга таба чыга иде, ахрысы, чөнки аның тавышы яңгырабрак, моңы үтемлерәк, сүзләре ачыграк ишетелә башлады. Ни тырышсам да, кызны аермачык таный алмадым, җыры исә бөтен барлыгымны, арбаатымны, юлымны, барырымны һәм кайтырымны, каралып-куерып килгән офыкларны күмеп китте, онытылдым! Ташкын иде аның тавышы, моң дәрьясы иде!

Үз ирекләренә куелган атлар тагын да акрынрак атлыйлар, кызның сүзләре ап-ачык ишетелә башлады. Кыз кабат-кабат бер үк сүзләрне кабатлый икән.

Алтын булып агаем да...
Көмеш булып тамаем!..

Аның да күңелендә иләс-миләслек, ярларына сыешмаслык яшьлеге тулышып ага иде бугай, чөнки ул шушы сүзләре белән сихерләнгән, тылсымланган иде. Бары үзе өчен генә, үзенең моңлы күңеле өчен генә, үзенең татлы рәхәте өчен генә яшертен җырлавы, шуннан тәм табып бәхет эчендә йөзгәне аңлашылып тора, ул инеш үзәнлегендә, Олы су иңкүлегендә, алай гына да түгел, җир йөзендә, чиксез-үлчәүсез галәмдә бары тик үзе генә дип

уйлый иде. Түбән авыл юлында җиде атлы аны тыңлап барадыр дип, уена да кертмәгәндер.

Без — җиде кеше. Җиде төрле ата баласы. Толлар да бар арабызда, буй җиткән ятим кызлар да, безнең сыман егет-җилән дә бар. Кем елагандыр, кем сөенгәндер, бу җырны берәвебез дә ишетми калмагандыр...

Атлар Тирән чокырның караңгы авызына барып туктагач, сискәнеп киттем: кем мин, кая барам болай?!

Иң арттагы аттан төшкән Дамир, кыскарак кәкре аякларын яза-яза, миңа якынлашты:

— Ибраһим, әй, ишеттеңме? — дип сорады.

— Саңгырау түгел лә,— дидем мин, атымның аркалыгын тикшереп.

— Син дә инде,— диде Дамир, кинәт үпкәләп.

Уңайсызланып киттем, һич уйламаганда, иптәшемне үртәп маташам икән ич! Сугыш безнең елгыларга да якыная башлагач, хәрби комиссариаттан кайтканда Дамир: «Колак сызлый, малайлар, минем, ишетүем хөрти»,— дип сөйләнгән иде. Андыйга сизгер егетләр шундук эләктереп алдылар: «Колакай да колакай! Саңгырау да миңгерәү! Армиягә барырга дигәч, Дамирның колагына гөмбә үскән!»

Солдатка каралучылар теленә эләкмә, ник әйткәненә үкенгәндер Дамир... Яшьтән үк кушаматларга бай булды ул. Әтисе дә тапкан исем, тьфү... «Тамыр» да диделәр аны, «Камыр»да, Дамир дип әле ничә ел гына эндәшә башлаганнар иде, хәзер «Колакай»!..

Аны-моны абайламыйча мин дә шуңа ишарәләгән булып чыктым...

Чокыр тирәсендә бөялешеп торганда, җыр тонык кына булып тагын яңгырап китте, хәзер инде ул шактый еракта сүзләрен дә, моңын да тәгаен аерып булмый, җыр авыл ягыннан минем йөрәккә тоташ моң булып кына сызылды, язын килгән тургайлар, былбыллар барысы бергә җыйналып, китәр алдыннан безнең яклар белән хушлашып, суык шәфәкъка карап күмәк иңриләр төсле тоелды.

Каян килгәндер минем иләс-миләс күңелгә мондый чагыштыру, валлаһи, ул мизгелдә шулай уйладым!

Тирән чокырда мондый караңгы кичләрдә аерата сак булырга кирәк, аның җәенке төбенә ел саен яңа эз салабыз, ел саен аны язгы ташкыннар тирәнәйтә, киңәйтә,

авызыңны ачыбрак барсаң, атың-арбаң белән берәр яры тәкмәрләвең бар! Барыбыз да арбалардан төшәбез, алга чыгып, дилбегә башын тартып тотып, атлар белән янәшә атлап, аларны тыеп, алдагы олауның тәгәрмәчләренә генә карап барабыз. Иң алга яшен утыдай үткен күзле, йокы белмәс Сабираттәй чыга, аның хәтере искиткеч шәп, Чаллы юлындагы бөтен чокыр-чакырларны үзләренең мич төбен белгән кебек белә ул.

Хәвеф-хәтәрсез генә бу шомлы урынны да уздык.

Хәзер атларны йолыккалау юк, аларны үз җаена куеп, җәяү генә барабыз. Дамир тагын минем яныма килде, камчы сабы белән юантык муенын кашып:

— Кем икәнен белдеңме? — диде.

Төпченеп баруына ачуым чыкты, искәрмәстән яңгыраган моңны үземнеке генә итәргә теләдем, шуңа күрә баягыдан да кырысрак итеп җавап бирдем:

— Йөри шунда тилереп!

— Югары очның Әдилә тутаң булыр ул!

Сискәнүемне белдермәс өчен йөткерендем, үзем дә Әдиләдер дип уйлаган идем аны! Шул икән, үзе икән...

Әдиләнең җырлаганын байтактан ишеткән юк иде. Былтыр яз, кар астында кышлаган башак ашап, Сарсаз авылында кияүдәге апасы үлде Әдиләнең, дүрт баласы тезелешеп калды. Әдилә шул ятимнәрне карарга Сарсазга җизнәләренә китте дә инде ике җәйне, бер кышны шунда уздырды. Җырны шунда өйрәнеп кайткан дисәм, ай-һай, дүрт сабый янында җырларга вакыты калды микән? Хатыны үлгәннән бирле, җизнәсе дә бик рәтсезләнгән, бик эчә дип сөйләгәннәр иде. Бөтенләйгә кайтты микән Әдилә, әллә сагынып, кунакка гынамы?

Җизнәсе Сталинград янында кулын гарипләтеп, кырык иkенең азагында ук сугыштан кайткан иде, кулын асып безнең авылда өйдән өйгә ашка йөргәне дә хәтердә. Гармунчы кеше иде ул, тирә-якта бер иде, хәзер гармун уйный алмагач бара-бара да, туктап, әче итеп сызгыра... Сыңар кулы белән хатынын кысып коча да тагын сызгырып җибәрә иде... Гомердә дә андый зәһәр сызгырган кешене күргәнем юк иде. «Халык саны ишәйсен!» дигән аның җизнәсе, һәм алар ел саен бәбәй алып кайттылар...

Көтмәгәндә хатыны үлеп киткәч, Әдиләгә өйләнергә ниятли икән дигән сүзләр дә йөрде, балалар чит кулга

калмасыннар, синең үз каның бит, дип җизнәсе бик ялына икән, диделәр... Инде өйләнешкән дигән хәбәр дә тараттылар.

Сугыш елларында чыбыксыз телефон бик шәп эшләде, кем турында ни генә сөйләмәделәр, һәр ялтыраганның алтын түгеллегенә без күнеккән идек инде, соңгы имеш-мимешләргә ышанмадык. Дамир «Әдилә тутаң» дисә дә, бездән ике-өч яшькә кече бит әле ул, гәүдәгә түгәрәк кенә булса да, без җиденчедә йөргәндә билсез сары бишмәт киеп, киндер букчасын асып дүртенче класста укыды. Дүрт балалы иргә чыгамы соң Әдилә?! Шулаен шулай да сугыштан соң ир-атның базары күтәрелде, торна баласы төсле озын торыклы алты-биш Шририяз Фәрите дә өч-дүрт хатын алып аерды инде!..

Әдилә... Әдилә... Бер-ике тапкыр чәчен тартып елатканым да бар... Ул үзгәргәндер, без дә үстек... Сылу гына кызлар Дамир белән безгә дә каш сикерткәлиләр хәзер, аулак өйгә чакыралар, чиккән кулъяулыгы бирәләр, апак өч пар пирчәткәм агач чемодан төбендә ята...

Юк, Әдилә акылсыз бала түгел. Югары оч кызы булса да, мин аны әйбәт беләм, Сабирҗан абзый кызы, дүртенче-бишенчеләрдә укыганда ул «Мирсәет бәете»н җырлап карчык-корчыклардан балавыз сыктыра торган хисле, моңлы бала иде бит ул.

Дамир ничек танып алган диген, менә сиңа колакай!

Үзгәргәндер Әдилә, күрмәгәнгә ике җәй, бер кыш узды лабаса! «Көмеш булып тамаем» диме? Зарлану, кайгыру түгел ич монысы, кешегә, дөньяга, җиргә яхшылык теләү! Изгелеккә, юмартлыкка омтылып җирсенә бит кыз күңеле! Кияүгә китсә җырлап йөрмәс иде, җырласа да сүзе, моңы бүтән булыр иде, чыкмагандыр, юктыр, юктыр, юктыр...

Арба тәгәрмәчләрем күңелле генә шыгырдыйлар...

Көмешне күргән бар анысы! Әллә нинди ят ил императорларының олысымак сурәтләре сугылган көмеш талирлар әбинең чулпысында чың-чың итеп китә торган иде.

Әдиләне элекке кебек итеп сәхнәгә чыгарасы иде бер, тамсын иде, чәчелсен иде көмеш булып!

Юк, Әдилә алай ансат кына билен бирмәс, усаллыгы да, чаялыгы да җитәрлек кызыйның. Бер заман, ул бишенчедә чакта, артык иртә калкынган күкрәкләренә уй-

нап кына кагылып киткән идем, сул яңагыма шундый чәпәде, искә төшкәндә хәзер дә кызарам...

Арба тәгәрмәчләрем шаярышып җырлашалар!..

Кайчан кайтты икән, кайчан?

Кайчан китә икән?

Китәме?

Борылып иптәшемә кычкырдым:

— Дамир!

— Нәрсә бар? — диде ул, иренеп кенә.

— Бернәрсә дә юк!..

— Юкка мин үзем дә тук.

Без ел әйләнәсендә диярлек Чаллыдан кайтмыйбыз. Көзен икмәк илтәбез, язын симәнәгә элеваторга барабыз, сельпога товарларны Чаллыдан алып кайтабыз, Казан — Мәскәүләргә дә юл Чаллы аша, пристаньнан районга тозны да шуннан ташыйбыз. Кайчан кушсалар да, вакыт дип, читен дип тормыйбыз, берсүзсез чыгабыз да китәбез. Күнегелгән эш, таңда да кузгалган бар, ярты төндә дә, атлар гына хәлле булсын, алар чыдасын, без карышмыйбыз, безнең эшебез шул, яшәвебез шул. Тик бүгенге сәфәр минем өчен аерым бер мәгънә алды, шушы мәшәкатьле дөньяга кирәгемне мин шушы кичтә ачыграк тойдым, үзебезгә йөкләнгән гап-гади эшләр олы да, кирәк тә булып киттеләр... Моңарчы карышусыз гына, баш иеп кенә атлы эштә йөрүебездә безнең җитлегүебез, өлгерүебез дә күренә икән!

Юлыбыз да уңды: яңгыр яумады, атлар талчыкмады, икенче көнне төшкә келтерәтеп элеваторга ук барып кердек. Чират та тиз узды, йөкләр дә яхшы чыкты, Гыймай Фатихының йөгеннән генә ике пот солысы җитмәде. Төптөгәл утыз ике килограмм... Җитмәүчелекнең болай төптөгәл булуы безне бераз шиккә төшерсә дә (Фатихның чак кына шаярганын белеп йөрибез, артка да калгалый, күздән югалып йөргән чаклары да була. «Эч авыртты, парин, рәт югалып тора әле... Фатирга төшкәч, шомырт суы кайнатып эчми ярамас!»), җиде олауга утыз ике кило күпмени ул, үлчәгәндә ялгышканнардыр, дигән фикергә килдек. Фатих үзе, кояшта уңган солдат фуражкасын салып селкә-селкә, ай-кояшлар белән карганды, элеваторга икмәк кабул итүчеләрне мутлыкта гаепләде.

Кызыкканнар ди анда синең ике пот солыңа! Фатихның каргануы безнең шикне арттырса да дәшмәдек...

Кәгазьләргә кул куярга кергәндә, син урысча әйбәт беләсең дип, олау башлыгыбыз Сабираттәй кантурга мине дә алып кергәли. Бүген дә чакырды, утыз ике кило җитмәгәч, бер-бер сүз купмагае дип уйлагандыр инде. Накладнойларга кул куючы юантык кына, алтын тешле түтенкә:

— Ничек әле анда, китерәсе икмәк күп калдымы калхузыгызда? —дип сорап куйды. Моңарчы чеп-чи марҗа дип йөргән түтенкәбез чыкылдаган татар апасы икән!

— Күбе каян килсен,— диде Сабираттәй, өзелеп.

— Симәнә калдыра алдыгызмы соң? — дип кызыксынды апа.

— Бар булганын кырып-себереп алып килдек,— диде кистереп Сабираттәй.— Быелгы иген дә келәт күрмәде, бурага төшмәде, амбарлар җылашып утыра, ындырдан туп-туры монда ташыдык, хөкүмәт үзебезнеке әле, язын орлыксыз калдырмас. Монда ышанычлырак сакланыр.

Апа артык тирәнгә кермәде, маңгаен җыерып, безгә бик мәзәк тоелган иренен бөреп торды да чуар тышлы шәмәхә карандаш белән безнең кәгазьләргә кул куйды. Йөкләр янына чыккач карасак, теге җитмәгән ашлыкны безнең өстән чигергән икән.

Сабираттәйне бу яхшылык куандырмады, аның Фатих мутлыгына үз хөкеме булгандыр, ахрысы, кәгазьләрне аннан-моннан гына төрде дә түш кесәсенә салды. Аның болай да калкып торган түше тагын да зуррак булып бүлтәйде.

Әйе, Сабираттәй теге апага ачы хакыйкатьне әйтеп бирде: ындыр тирәсенә ашык-пошык куелган соңгы эскертләр дә язгы кар көртләре кебек эреп бетте, сушилка калайлары ялтырап калды, келәтләр буп-буш, хуҗалыклардагы бураларда да тычкан куанырлык та бөртек юк иде. Барын ташып бетердек. Алда авыр, озын кыш. Председатель «фуражга-нужага» дип, аз-маз чүпле солы белән, печән өстенә, халык бик киселгәндә тотылыр дип, чак кына бодай калдырырга чамалаган икән дә, районнан боерык биреп үзен нык кына пешерделәр. Калганын да тиз үк илтеп тапшырдык...

Икмәк бетте, эш кенә бетмәде. Атка да, безгә дә тынгы юк. Мәктәп утынсыз утыра. Авыл советына, идарәгә, клубка да кыш ягарлык әзерләргә кирәк. Үзебезне дә онытып бетереп булмый, төннәрен, председательгә әйтми-

чә генә, Кабан урманыннан йөге-йөге белән өрәңге әрдәнәләр чәлдереп кайтабыз. Туган-тумача да сорый, карчык-корчык, ятим-ялпы да ялына, ташымасаң читен, үпкәлиләр. Утын чыгару солы ташу түгел, икмәк тирәсендә акмаса да тама шунда, кыска җәйдә болай да ныгып җитмәгән бахбайлар утынга йөри башлагач, тагын йөгәнеп калдылар. Бер атлыйлар да ике ял итәләр, бу әле көз, язга таба ни булыр?.. Буш вакыт, сирәк эләккәнгә, безнең өчен бик кадерле. Бүген шундый кичләрнең берсе. Геренә бәләкәй йозак тагылган күгәргән калайлы стена сәгатебез кичке сигезне күрсәтә. Урамда дөм караңгы. Өйгә тәмле ис таралган, казанда бокыр-бокыр тары боткасы пешә. Тәрәзәләр тирләгән, шабыр суда. Чөелдерек бавы эзләргә дип кичкырын келәткә кергән идем, киштә түреннән җиденчедә укып йөргән китапларны табып чыктым. Киселев «Алгебра»сы, «Ана теле». Саргайганнар. Тышлары купшакланган, бит почмаклары кителгән...

Шул китапларга карап ятам. Тамыр алу да онытылган, кушма җөмләләр турында әллә ни белмим... Икс, игрекларның барысы да «икс» миңа хәзер.

Ишек шапылдады, әнкәй керде дип калкынсам, ят тавыш тамак кырды, кәнсәләрдән дежур килгән икән.

— Ай-яй, тәмле ис тараткансыз,— диде ул, шадра танавының киң тишекләрен киереп иснәп.— Каз итеме әллә?

— Утыр, Бәдәр җиңги,— дидем мин,— сыйланырсың. Сөтле ботка пешә.

— Вакыты бармы соң аның? — диде Бәдәр җиңги, чабата башына ябышып каткан карын кага-кага.— Көн йөгертәләр, төн йөгертәләр. Әллә сабан туена чабышка әзерлиләр инде?

Ул үз сүзенә үзе рәхәтләнеп кеткелдәп көлеп җибәрде.

— Тагын нәрсә булды? — дидем мин, нидер сизенеп.

— Ни дип, сине чакыралар. Әйдә, киен.

Әнкәй күршеләргә көнбагыш мае сорарга кергән иде, ул чыкканны көтеп кенә тордым да идарәгә киттем.

Кәнсәләрдә шул ук күренеш. Шәп-шәрә өстәл артында председатель Хәкимҗан абзый утыра, өстәрәк, калын, саллы рамы белән түшәмне терәп, Сталин портреты эленгән. Сугыш беткәнгә байтак вакыт узса да, председе-

дателебез һаман медальләрен тагып йөри. Сул почмакта өстәл лампасы янында хисапчы утыра, ул үзенең калын кенәгәсенә кадалган.

— Җә, ускәнем,— диде Хәкимҗан абзый, медальләрен чыңлатып.— Нихәлләрең бар? Иминлекме?

Берәүнең дә миннән «хәлең ничек?» дип сораганын хәтерләмим, уңайсыз булып китте, аптырап иңбашларымны боргаладым. Председательнең минем хәлне белешәсе килүе сүзгә җилем булсын өчен генә икән, җавап көтеп тә тормады, сүзгә күчте.

— Менә ни иде бит әле, ускәнем, сиңа пачутлы гына бер эш табылып тора әле монда. Әкәләле имән ауган дип әйтимме, тавыгыгыз алтын күкәй салган дип үк җибәримме, мәгәр үзең до чамаларсың, төтенең йөрми түгел, йөри, җиде тулы класс белемең бар, ТБУМ бетердең, без менә дүрт класс белән җитәкчелек итеп киләбез, күреп торасың, урамга куып чыгарган кеше юк. Аннары ки шул, тормыш көйләнебрәк бара. Көйле тормышка яңачарак кешеләр кирәк.

— Кая барырга? Кайчан? Бүгенме? — дидем мин, түземсезләнеп.

Хәкимҗан абый, эре төкле очлы ияген бик тәмләп кашый-кашый, күзләрен челт-челт йомып куйды:

— Кабаланма син, ускәнем, ни сөйлидер идем әле? Әә, менә шул булыр сиңа, гәҗитләр караштырасыңдыр, ягъни Казаннан да язалар. Мәскәүдән иптәш Сталин үзе күрсәтмәләрнең иң кирәген биреп тора, авыл хуҗалыгы бүгенгесе көннән башлап шундыен чәчәк атачак ки, ускәнем, шаклар каткыч булыр. Менә шул ие минем сиңа әйтер сүзем. Әйе, Мытыестан кәгазь килде, ике пичәт басылган, район начальствосы да кул куйган, трактористлар курсы ачалар, бездән өч кеше сорыйлар.

Нигәдер көләсем килеп китте.

— Юк сүздер ул, Хәкимҗан абзый. Юк тракторга нинди курс ачсыннар? Безнең авылдагыларына эш юк.

— Син алай сөйләп, ускәнем, нитмә, беләсең... Тракторлар кайтып төшкәч кенә, соңга калу булыр ул. Үрдәк кенә астына су кергәнен көтеп бакылдап утыра, әйе, без хәзерге моментның вәжнилеген бер минут та истән чыгармаенча яшиек, шул. Димәк ки, болай итик, ускәнем. Гәүдәң шәп, җегәрең бар, тракторга аңа көч тә кирәк. Тракторчылар бар дисең икән, кемне әйтәсең алай? Саби-

ра апаңнымы? Искерделәр инде алар, туздылар. Карап торырга гына яңа... Син, пример әйткәндә, яшь кеше, сиңа укуы да кирәк. Өч айда әллә ни тиклем гыйлем алырга була, дәрт иткән кешегә ел кирәкми. Чүт-чүт кенә калхуздан да ярдәм оештырырбыз, Мытыес үзе дә гел үк буш итмәс, байлыклары бар, җыен, өч айга Чаллыга барырсыз. Тик, матри, адәм көлдереп йөрмә, тиешле-тиешсез кеше белән, бигрәк тә азгын хатын-кыз белән чуалма. Югары авыллар сыната торганнардан түгел, сугышта да үзләрен күрсәттеләр.

Ул тагын рәхәтләнеп сакалын кашыды, медальләре кул хәрәкәте җаена челтер-челтер чылтырадылар, хисапчы кенәгәдән башын калкытты да лампаның филтәсен күтәрде.

Кәефем килгәнне сиздерми генә, ярар, дип, башымны иеп чыгып киттем. Тракторчы!..

Безнең Югары авыл керәшен белән кара-катыш булып, авылыбызның беренче тракторчысы Будрин Борис иде. Авылда кушаматсыз кеше юк, Бурис дәдәйгә дә яңа һөнәре кушамат булып ябышты. «Будрин Бурис — тракторист!» дип такмаклый иде малай-шалай... Әллә кызыгып, әллә көнләшеп гел аның артыннан ияреп йөри торган идек...

Бөдрә чәчле, кара тутлы чибәр йөзле Гөргери дәдәй колхоз машинасы белән сугышка чыгып китте дә машинасыз кайтып керде. Исән кайтуына сөендек, аның да кушаматы «шофер Гөргери» булып беректе. Машинасы булмаса да — «шофер». Чөнки ул беренче! Хәзер безнең авылда бензин исе районнан югары начальство килгәндә генә аңкып кала, кыйбатлы хушбуй исе белән бер безгә бензин исе! Мытыес тракторлары безнең бәләкәй колхоз кырларына килеп тә карамыйлар, чират җитми.

Кайтыр тракторлар, ансыз булмас, хәлле-хәлсез унҗиде ат белән әрем-билчән баскан кырларны уңдырышлы итәрмен димә, тракторсыз һич ярамый безгә! Шәп төрәнле сабан тагып ургылып кереп китәсе иде дә офыктан офыкка сөреп ташлыйсы иде!..

Сабира апа хәтергә төшеп, аны жәлләдем. Тузгандыр да шул, бар иде аның мактаулы чаклары, башта плугарь булып йөрде дә, Чат Нурлыгаян малаен сабанга утыртып, үзе трактор йөртә башлады. Нурлыгаян малаен егет итте, ир итте, алак-шалак йөргән кешедән ударник яса-

ды; Казанга механизаторлар конференциясенә бергәләп бардылар, Мәскәүдә Калинин белән рәттән утырып карточкага төшеп кайттылар. Сабира апага медаль дә биргәннәр иде... Сугыш башлангач, ире танкист булып китте. Сабира апаны алмадылар, йөрәгендә бар икән, диделәр... Булса да булгандыр, ире Орел каласы янында танкта янып һәлак булгач, идарә баскычы төбендә егылып чак дөнья куймады... Тузарсың да!

Мытыестан ашыктырдылар, атна да узмагандыр, җәй буе йөрткән сбруйларымны Дамирга илттем, нык арыгайган, зур күзле юлдашым Озынъял белән саубуллаштым.

Такта чемондага чабата киндерәсе белән киндер тышлы колак мендәрен бәйләдем дә Чаллыга юлга чыктым. Бу юлдан байтак кешеләрне әле сугышка, әле бәхет эзләргә Пермь, Яраслау якларына озатканым бар, хәзер үзем китеп барам, хәерлегәме? Дөнья безнең кулга күчеп бара торгандыр шул...

Имән урамын чыгуга, әллә нишләп күңелем тулды. Юк, авылдан китү, әнкәйдән аерылу сагышы түгел иде минем күңелдә. Чаллы ерак түгел, бик сагынсаң җәяүләп кайтып килергә дә була! Минем күңелне моңарчы тоелмаган, моңарчы бар икәнлеге дә беленмәгән ят сагыш, ят моң биләгән иде. Имән урамының ава-түнә утырган искемоскы текмә читәннәренә тикле моңлы, сагышлы иде бүген... Колак төбемдә, тургай җыры кебек булып, сихри өн чыңлый иде.

Алтын булып агаем ла!..
Әлә-лә-ләү!
Көмеш булып тамаем!..
Әлә-лә-ләү!..

Көн суык. Көн шыксыз. Юл кантарлары бозланып каткан. Ак чебеннәр оча, чокыр-чакырлы юлдан арба дырык-дырык бара. Дамир — олаучы, ул безне Чаллыга хәтле илтергә тиеш.

Дамир белән безнең аралар кызык кына була башлады. Ни атна, ни шимбә дигәндәй, тиктомалдан, Әдилә турында сүз башлый да минем күңел кылларын тарткалап карый. Йә булмаса бер дә юкка Әдиләне яманларга тотына. Чигү-тегү эшен дә белми, имеш. Фәлән дә төгән, имеш. Аның кызыксынуын сизеп, мин дә сер бирмәскә булдым. Ак димим, күк димим, белми торсын әле!.. Ма-

лай җүләр түгел, сизенде, сизенгәч, үчегешергә кереште. Юлга чыксак, атын иң алга куа. Кичке уенга җыелсак, минем сүзләрне очсызга чыгарырга тырыша. Гомергә уртага чыкканы юк иде, гармунчы чакырып мунчаларында биергә өйрәнә башлаган! Күрегенең җиде җиреннән тын өреп торган җиде бакалы тальянын кардыга, ат карауч ылар йортына илтеп куйды, буш вакыты булдымы — шуны шырылдата, өйрәнә, янәсе! Гел алга чыгарга, гел узарга тели Дамир.

Минем курска барасын ишеткәч, шартлый язды малаең! Бусында үзем дә аны жәлләдем, өйләренә бардым.

— Әйдә, мин әйтәм, Хәкимҗан абзыйны кодалыйк, бергәләп укырбыз.

«Юк», дип, кул гына селкеде бу. Мин үгетләргә тотынгач, серен сөйләп бирде. Теге вакытта военкоматтан «колагым каты» дип юрамалый әйтеп кайткан икән ул! Төс аермый икән егет, дальтоник икән! Кызылы белән яшеле бер икән тегенең. Военкоматта караган күз врачы аңа кистереп әйткән: «Армиягә дә алынмыйсың, машинага да утырмыйсың, үзеңә кулай бер һөнәр тап»,— дигән...

Тез астына суктылар егетнең! Без Чаллыга укырга китәбез, тирә-юньдә дан таралды, ә ул монда җимерек кардыда атлар янында кала...

Телгә алмыйм дип тырышсам да, Дамирга карауга шул искә төшә: кызыктыр инде ул, ә? Болыннар кызыл булып күренәме аңа? Ә шәфәкъ ямь-яшелме? Менә сул кул яктагы Сарсаз авылына хәтле сузылган уҗымнар аңа кып-кызыл булып күренәдер? Ә кызларның бит очлары ямь-яшел... Яшел иякле Әдилә!

Чыдый алмыйча шаркылдап куйдым, Дамир сизенә, төс аермый торган күзләрен акайтып, миңа карады:

— Шүрәле кытыклыймы әллә сине?

— Юк ла, бер кызның ияге искә төште.

— Кутырлаганмы?

Дамир һич кенә дә тик утыра алмый, боргалана, терсәге белән минем касыкка килеп орына, авырттыра, артка да карый, як-якка да, тегенең нидер әйтәсе киләме шунда, кысталган кеше кук, бара да бара. Ахырда чыдамады егет, күзләрен читкә борып:

— Тегене күрмәдеңме! — дип сорады.

— Кемне?

— Кыланып барма инде, белмиләр ди! Әдиләне инде... Җырлап узган иде бит.

Ул да нәкъ шуларны уйлап бара икән! Юк шул, күреп булмады Әдиләне, өйләрендә җан әсәре сизелмәде. Күршекүләннән сорашырга читенсендем...

Теге чакта, җыры белән безне озатып калганда, Әдилә ике-өч көнгә кунакка гына кайткан булып чыкты...

Бу араларда клуб ачылмады; каз өмәләре башланмаган; аулак өйләр дә тынып тора. Ни арба, ни чана дигәндәй, тегермәнгә баручылар да юк, вак-төяк йомыш белән Чаллыга, йә башка олырак урыннарга чыгып китүче дә күренмәде. Менә без генә өчәүләшеп китеп барабыз...

Кар сизелерлек оча башлады, вак кына үткер кырлы ярма кисәкләре бит очын чеметтереп-чеметтереп коелалар. Дамирга аркамны терәп барам, болай җылырак та, сөйләшмәскә дә җайлы...

Тик аның белән сөйләшергә туры киләчәк, бик нык сөйләшергә туры килер, күңелгә шулай тоела...

Күңелгә килгән — алга килә, диләр, рас икән, безне ашыгычрак озатканнар булып чыкты. Курслар менә-менә оешып кына килә икән, бинасы да юньләп каралмаган, уку әсбаплары да юк, тегесе җитешми, монысы әзерләнмәгән. Безгә, иртәрәк килгән бәхетле кулларга, байтак вак-төяк эш белән маташырга туры килде. Ишек-тәрәзәләрне ныгыттык, пилорамнан пычкы чүбе ташып нигезне җылыттык. Кыскасы, без килеп ике атна узгач кына, барысы оешты. Һич көтмәгәндә, эшләгән өчен безгә бераз акча да биреп куйдылар, күңел күтәрелде, курсантлар да җыелып бетте, уку башланды. Бик дәртсенеп тотынган идек, өч айда гына программаны уза алмадык. Трактористка ни кирәге бардыр, безне капиталистик илләрнең географиясен дә, тарих та укытып җәфаладылар.

Үз бусагаңнан чыгып киттеңме, туган җиреңне аңлый башлыйсың, ныграк сагынасың, диләр. Рас икән, Әдилә матур турында торган саен ешрак уйлый башладым. Ятсам төштә, торсам истә дип, бик белеп җырлыйлар икән безнең Югары авылда!

Кызның хәлен кем аша белергә дип, озак баш ваттым. Үзенә атап хат язар идең, уңайсыз. Төрле-төрле гайбәтләр йөрде, дөресме алар, түгелме — кем җеп очын эзләгән? Әнидән сорап язар идем, өйдән чыкмый яткан кеше яшьләр арасындагы хәлләрне каян белсен?

Тоттым да Дамирга хат яздым. Бик озак көттереп, Яңа ел бәйрәмнәре узгач кына, авылдаштан җавап килде. Кич иде, зәңгәр эңгердә, тәрәзә бозына иңемне терәп, авыл хәбәрләрен укыдым.

*«...Куып кайтармасалар, ят рәхәтләнеп, озак тоттылар дигәнне теленә дә алма... Клуб үз урынында. Якмыйбыз. Утын бетте. Яңа ел вечерына дип, чәнәшкә белән утын алып кайткан идек, вечерның да рәте булмады... Үлем-җитем юк. Өйләнүче юк. Үзем атлар арасында — генерал. Старший конюх иттеләр дәдәңне. Гармунда «Сирбиянка»-ны сиптерә башладым... Печән бетте, рига төбәсеннән салам ташыйбыз. Теге известь базлары янындагы чокырларга тутырган айбагыр силосы черген булып чыкты, су үткән. Ярамады. Аулак өйләр буламы дигәнсең, монда безнең уен кайгысы түгел, сезнең сымак казна ипиендә симерешеп ятмыйбыз. Әдиләне сорагансың, кайтканы да, күренгәне дә юк. Кияүдә дә диләр, юк та дип әйтәләр. Җизнәсе куены татлыдыр шул аңа! Кайткач үзең сорашып белерсең, миңа кирәге шултиклем генә, үпкәләмәссең. Чәчүгә кайтып җитә аласызмы? Тракторны шуннан ук биреп җибәрәләрме?»*

Кызарындым, бүртендем, нишләргә белмәдем. Иртәгесен зачет иде, белгән сорауга җавап бирә алмыйча, «начар» эләктердем...

Каян тешләргә белгән бит малаең! *«Җизнәсе куены»* дигән... *«Трактор биреп җибәрәләрме?»* дигән! Көнендә очраса, салма савытының читен китә идем китүен...

Сүз тыңлый торган гадәтем бар, шуңамы, яратып, тырышып укыдым. Тракторны гына түгел, башка машиналар тирәсендә дә «ипилек-тозлык» беләсем килде. Мастерскойдагы кыру станогын бик яраттым... Тик һаман да тәмам онытылып китеп булмый, яз якынлашкан саен күңелдәге пошаман үзен ныграк сиздерә иде. Дамирның тетмәсен тетеп тә, юмалап та хатлар язып карадым, күңелдәгедәй итеп җавап язмады егет, Әдиләне кабат телгә дә алмады.

Имтиханнардан котылдык, кулга «тракторист» дигән документ тоттырдылар. Иптәшләр, укытучылар белән саубуллаштык та фатирларга таралыштык. Олау көтәбез. Алдан хәбәрләшкән буенча, безне алырга ат җигеп Дамир үзе килергә тиеш. Председатель айгырын җигеп килер микән, әллә үзе җигеп йөри торган берәр җегәрле атта гына килерме?

Минем дә, авылдашым Торна Хәмитнең дә тракторист булып авылга шәбрәк атта юрттырып кайтып керәсе килә! Председатель айгырында выжлап авылга барып керәсе иде дә бит!..

Хәмит дигәннән, өч-дүрт ай бергә аралашсак та, якынаеп китә алмадык без аның белән. Өйдән күчтәнәч-мазар килсә, почмакка кереп, юрган астына посып кына сохари кимереп йөри торган бу ач яңаклы, аксыл чырайлы егет үтә дә аз сүзле иде. Мыдыр-мыдыр китап ятлап утыруыннан башка аның тавышын ишеткән дә юк. Дөнья турында, кызлар турында аның белән бер сүз алышып булмый иде, әллә нинди төнлә туган нәмәрсә! Кайтырга җыена башлагач кына, малайның чырае яктырып китте, кайтасы килүен дә, тракторчы булуыннан канәгать икәнен дә беренче тапкыр шул көнне ишеттем.

Бишенче мартта килергә тиешле Дамир күренмәде, бәйләштереп куйган урын-җирләребезне сүтеп, төн кундык, күз текәп торсак та, председатель айгыры икенче көнне дә күренмәде. Мур кырмагандыр бит Югары авылны диештек. Инде тәмам аптырашып, өметсезләнеп торганда, кичкырын, күз бәйләнгәндә безнең фатирга Дамир килеп керде. Ул үрәчәле дәү генә чана тарткан иде.

— Кайда атың?

— Сатып эчтеңме әллә? — диештек без Хәмит белән бер авыздан.

Дамир, кыска муенын бүрек колакчыны белән сөртә-сөртә, чанасын мөгезеннән тотып болдырга ук тартып китерде.

— Менә сезгә ат. Менә олау. Сыясызмы? Бик симермәдегезме? — диде ул.

Хәмит белән икәүләп Хәкимҗан абзыйны сүгә башладык. Без кызган саен Дамир сүзсезрәк була бара. Бүген юлга чыгу турында уйлыйсы да юк иде, Дамир бөтенләй хәлдән тайган, өшәнгән. Тагын куна калдык.

Юл буе әрләсәк тә, Дамир ак димәде, кара димәде.

— Үзең конюх! — дидек без, алмаш-тилмәш.— Җитмәсә, старший. Иң шәп атны тотарга да җигәргә иде! Эх син, бәрәңге боламыгы!

Чаллыда ятып шәпләнгәч, тракторчы исемен алгач, борын күктә иде, авылга чана тартып кайтып керергә бик хурланган идек, ярый әле, караңгы төште, авылдашлар безне күрми калды.

Дамирнең көнләшүдән бавыры кабарган, белеп торам, ул минем таныклыкны ике тапкыр сорап алды, кат-кат укып, пичәтен иснәп карады. Әчемнән генә тантана иттем: менә җиңешеп караган идең, карама мөгезле чана сөйрәп калдыңмы, абзаң һөнәр иясе булды!

Курсларда укыганда күңелләр күтәренке иде. Барыбыз да яшьләр, төрле районнардан җыелган булсак та, бик тиз дуслашып өлгердек. Чак кына дөнья мәшәкатьләреннән аерылып, дәреслекләрдә сөйләнгән, китапларда язылган тормыш беләнрәк яши башлаган идек без. Мин үземнең авылга кайтып керүемне дә шулайрак итеп, шәп итеп, һич югында, тантаналы итеп күз алдыма китергән идем. Менә мин кайтып төшәм, янәсе... Председатель дә куана, гомергә елмаймаган хисапчы да көлә, әнкәй дә шатлана, агай-энеләрне әйткән дә юк!.. МТС директоры безне җыеп ала да әле яңа гына Бөгелмә станцасыннан кайтып төшкән, буяу исе килеп торган тракторларга утырта... Музыка, байраклар, котлаулар.

Шушы тантананың бер читендә мин һәрвакыт Әдиләне дә күрә торган идем! Мондый күңелле киләчәктә Дамирга бик бәләкәй, бик кысан урын калдырган идем мин: танавыңны чөеп, хат язарга иренеп йөргән идеңме, мә сиңа!

Әнкәй куанды, сүз дә юк, мыштым гына елап та җибәрде. Бәрәңге дурычмагы белән сыйлады. Мунча якты. Әнкәй юып үтүкләгән күлмәк-ыштанны киеп, әнкәй җәйгән җылы урында яту нинди рәхәт!..

Уяндым да, аннан-моннан капкалап, идарәгә чаптым. Озаграк йоклаганмын, Хәмит әллә кайчан килеп тә җиткәндер, йокыга сак егет... Нинди яңа хәбәрләр бар икән, дим...

Кояш шактый күтәрелсә дә, идарәдә беркем юк иде. Җыештыручы Бәдәр җиңгинең борынына корым кунган, ул соңгарып кына мич томалап маташа, бүлмәгә зәһәр күмер исе чыккан иде. Борынымны җыерып бераз көтеп утыргач, түзмәдем:

— Болар кайда соң? — дип сорадым. Бәдәр җиңги дә, беренче күргәндәй, урындыкларга, таплы-таплы эскәмияләргә күз ташлады, төтен кызарткан сирәк керфекле күзләрен челт-челт йомгалап:

— Кайсысы кирәк ие соң сиңа? — диде.

— Соң, Хәкимҗан абзый кайда? Башкалар?

— Аларның ни, белмисеңме әллә?

— Белмим бит. Мин кичә генә Чаллыдан кайтып төштем.

Чаллы сүзенә дә исе китмәде Бәдәр җиңгинең.

— Кардыда алар,— диде, күзләрен сөртеп.

— Нишлиләр анда?

— Төшеп кара, үзең күрерсең.

Төшәсе дә килә, килми дә. Монда, идарәдә, халык арасында очрашасы килә иде. Хәкимҗан абзый белән! Баскыч төбендә таптанып торган арада, карды ягыннан бер төркем кеше менеп килүе күренде. Бригадирларны ияртеп, Хәкимҗан абзый кайтып килә иде, эчемә җылы керде, ирәеп кенә ак пирчәткәмне киеп куйдым. Председатель яңа сырма өстеннән иске, кыршылган кожан кигән кожан җиңнәре пычранган, бригадирлар да таш чапкан төсле мыжлап төшкәннәр иде. Саргайган бармаклары арасына юан-юан тәмәке кыстырганнар, пыш-пыш суыралар. «Берәр бия колынлый алмый интегәдер» дип уйладым. Килүчеләр минем шактый кычкырып әйткән сәламемә баш кактылар да идарәгә кереп киттеләр. Хурланып, гарьләнеп мин дә аларга иярдем. Хәкимҗан абзый керә-керешкә кожаны белән сырмасын бергә салып мич арасына урындыкка ыргытты. Күкрәгенең медальләрдән буш икәнлеген абайладым, гаҗәпләнүем тагын да арта төште.

Бригадирлар, аларга ияреп кергән кешеләр, бер сүз дә дәшмичә, кайсы кая таралып чүмәштеләр, кысылган иреннәрдә чытыр-чытыр тәмәке янды, идарә эче, яңа ягылган мунча күк, зәңгәр төтен белән тулды. Тәрәзәдән карап көлеп торган март кояшы төтен арасыннан үтеп кереп кешеләрнең сүрән йөзләрен яктырта, аларга караган саен мин шомлана бара идем.

Телефонны шактый боргаласа да, теге башта алмадылар, ахры, председатель әче итеп сүгенеп җибәрде:

— Утыралар шунда аналары яламаган нәрсәләр, сагыз чәйнәп!

Мин кып-кызыл булдым. Хәкимҗан абзыйның сүгенгәнен беренче ишетүем иде. Аны юаш, тәмле телле булуы өчен председатель итеп сайладылар да. Хәтеремдә, кырык бишнең башында, Хәкимҗан абзый фронттан кайтып төшкәч тә, гомуми җыелыш җыелган иде. Шунда Сабира апа, чыгыш ясап:

— Без, Хәкимҗан абзый,— дигән иде,— барыннан да бигрәк тәмле телне сагындык. Тәмам аптыраш бит хәзер: үзебез дә сүгәбез, безне дә сүгәләр! Нәсел-нәсәбегез белән тәмле телле булдыгыз, кулыгыздан эш тә килде, әйдә, дилбегәне кулыңа тот але! Безгә камчы кирәкми, дилбегә каксаң да эшлибез без!

Ә бүген тәмле тел сүгенә... Ниһаять, дежур кызлар аңа район җир бүлеген тоташтырдылар, байтак әрепләшкәч, МТС директорын эзләп таптылар. Кәнсәләрдә халык ишәйде, Хәкимҗан абзый аларның керүенә, сәлам бирүләренә дикъкать тә итмичә, һаман сөйләшә иде. Райкомны да алды, райбашкарманы да. Симәнәләр, чәчкечләр, культиваторлар турында сүз куерды, председатель соңгы сүзе итеп һәркемгә: «Азрак фураж табышмассызмы?» — дип әйтеп карады. Ара-тирә кычкырып та алды, песи кебек булып та карады, тик беркайда да аңа өметле җавап бирмәделәр бугай, калын, аксыл кашлары тагын да кырысрак җыерылды.

Берәү бер сүз дәшмәгәндә, мин дә шым гына утыра бирдем.

Менә председатель телефон трубкасын шап иттереп рычагка куйды да тирләгән кул сырты белән иреннәрен сөртте, аннары, бүлмәдәгеләргә карап, кулларын җәйде:

— Фураж сорыйм, фураж! Ярдәм кирәк! Чүп-чар, солы... Ни булса да ризамын, дим, юк! Телефоннан акырышып эш чыкмас, су язып май төшми! Берәр атнага чыгып китми ярамас!..

Ферма мөдире, бригадирлар, аларга ияргән кешеләр, капылт кына урыннарыннан куптылар да, бер сүз дә әйтмичә, тешләрен кысып урамга чыгып киттеләр. Хисапчы, борыны белән калын гроссбухларга төртелеп, чырт та чырт чутын сала башлады. Мич арасыннан борыны җепшек Бәдәр җиңги килеп чыкты.

— Өй борынча чыгарга кирәк, кем, Хәкимҗан,— диде ул.

— Шулай туры килә.

— Бер ун пот бәрәңге мин бирермен. Соңгысы. Атларга җәл түгел. Атлар да үлеп бетсә, кая барырбыз? Ун пот бирәм.

Хәкимҗан абзый, аны ишетмәгән кебек, ияген учлап утыра бирде. Мин Бәдәр җиңгидән шыпырт кына:

— Кая киттеләр алар? — дип сорап, ишеккә ымладым.

— Кардыга,— диде ул.

— Нигә?

— Аңышмадыңмыни, бахыр, бүген тагын ике ат җан биргән.

Сикереп тордым да кардыга чаптым. Ике ат! Минем Озынъялым да шулар арасында түгел микән?.. Трактор белән җенләнеп йөреп мин үземнең канатымны, аерылмас тугры дустымны, шушы еллар эчендә ничәмә-ничә йөз чакрымнар бергә узган Озынъялымны бөтенләй хәтеремнән чыгара язганмын! Йөз, мең чакрымнар узылган. Ә аның бер чакрымы да җәһәннәм баскычларын үтү белән бер иде ич!

Карды янына төшмәгән булсамчы!..

Безнең кардылар Олы суның аръягында, калку урында. Мин кардыга җитәрәк атларны күмеп кайтып киләләр иде инде. Каршыма очраганнарның мал зиратыннан кайтып килүләрен авыр адымнарыннан ук абайладым. Абзыйларга:

— Исәннәрмесез,— дип сәлам бирдем. Икесе эндәшмәде, берсе — безгә кода тиешле Галимҗан абзый:

— Сорама инде, туган,— дип узып китте.

Озынъялым үлмәгән икән үлүен...

Дүрт җиреннән юан арканнар белән өрлеккә асылынган ат мине танымады, мин аны... Дамир күрсәткәч кенә янына бардым хайванның... Ул зур күзләрен тутырып миңа карады, таныды, дымлы борын тишекләрен кыймылдатып куйды, нәзек тавыш белән ыңгырашып сәлам бирде. Юк шул, янымда сиңа дигән күчтәнәчем юк шул, акыллым... Кесәмдә икмәк кыерчыгы түгел, таныклык ул... Мин тракторчы дигән язу... Моннан соң синең яныңа буш кул белән төшмәм, бәрәңге кабыгы белән булса да сыйлармын үзеңне!..

Дамирга вак-төяк өчен үчегешеп маташуларым шундук онытылды, кичкә хәтле кардыдан чыкмадым, атларның асларын тазарттым, кыргыч белән ябагаларын кырдым, түбәдән су тама башлаган урыннарын ямадык...

Фураж да, солы да юк иде атларга, күгәрә башлаган салам белән җан саклап торалар икән бичаралар.

Кичке чәйдән соң, мин тагын кәнсәләргә атладым. Бу юлы Хәкимҗан абзый берүзе генә утыра иде. Күрештек.

— Тракторчы дип кәгазь бирделәр,— дидем мин, юаш кына.

— Анысын булдыргансың,— диде ул, кәгазьгә кырын күзе белән генә карап.

Белдермәскә теләгән идем, үзеннән-үзе үпкәмне әйтеп салдым:

— Сөендереп булмады сине, Хәкимҗан абзый,— дидем.

— Сөенәм, үскәнем, бик шатланам.

— Кул кысып котламадың. Кәгазьдәге билгеләргә күз салмадың.

— Күңелем белән бик котладым, үскәнем... Тик күңел бит, әллә ничегрәк дип әйтимме... икегә бүленгән! Яртысы, олы яртысы җылый аның, үскәнем, синнән яшерене юк. Менә мартка кердек. Калхуз келәтендә бөртек симәнә юк. Күзгә кырып салырга бер бөртек журна юк! Атлар барысы өрлектә... МТС машиналарына өмет бар, мәгәр чират кайчан җитә?..

— Трактор бирәчәкләрме соң?

— Аннан ни файда? Инеш буеннан вак таш җыеп чәчәрсеңме? Менә бүген нәрәт килде. Сарман ягыннан, Кәсле дигән глубинкадан өч йөз центнер солы симәнәсе язганнар. Иртәгәдән шуны ташый башларга кирәк. Кәслегә иртәгедән калмый, ишетәсеңме, иртәгедән калмыйча, җитмеш баш чана чыгарырга кирәк. Ә ул җитмеш бишне әфсен укып җыясыңмы? Шүтке түгел, алтмыш биш чакрым, диләр аны Кәслене! Ә җибәрмәсәң — бәла! Атна-ун көннән юл өзеләчәк. Өзеләчәк, көт тә тор, син ашыкканда гел шулай була ул, үскәнем. Ярты авыл — карт-коры. Яртысы — аксак та туксак. Менә син чана тартып Кәслегә барасыңмы? Кесәңдә дукамент, син дә трактор дауларга килгән!

— Дауламыйм, Хәкимҗан абзый,— дидем мин, тыйнак кына.

— Даула син, үскәнем, даула. Әгәренки даулашмасак, эшебез җайга китәчәк түгел безнең. Дауларга кирәк. Тракторын да, машинасын да, барын да даула! Булачак ул трактор, бирәчәкләр аны. Тик менә бүгенгесе кыен, журна дигәне чәчне агарта! Солы Кәследә. Алтмыш биш чакрым!.. Бодайны Чаллыдан чыгарачакбыз, анысын Мытыес ташып бирәм, ди. Солыны атна арасында ташып бетерергә кирәк, пример әйтик, җитмеш биш чана чыгарсак... Чана саен өчәр пот салсак...

— Ир-ат дүрт потны тарта.

— Ашыкмыйк, үскәнем, өчәрләп чамалап карыйк... Ул чут төймәләрен ике куллап тартты да уфылдап куйды:

— Ике йөз дә егерме биш пот була. Ярыйсы икән, үскәнем. Тик менә җитмеш биш чананы каян табарга? Олы мәшәкать бу, олы...

Шулчак ишек ачылды, ап-ак мамык шәлгә уранган, ак пирчәткә кигән түгәрәк кенә кыз килеп керде. Карадым да каттым: Әдилә ич бу!

Председательгә әллә ни әйтмәк булам, телем тотлыга. Әдилә Хәкимҗан абзый белән оялып кына исәнләште дә миңа кулын сузды:

— Ибраһим да кайткан икән, исәнме.

— Мин кайтырга киткән... Менә син ничегрәк? — дидем, туп-туры.

Ул, шәл почмагына авызын яшереп, көлемсерәде.

— Мин дә менә... җизнине өйләндереп кайттым.

— Ниндирәк кеше алды инде? — диде кызыксынып председатель.

— Анысын кем белсен инде, Хәкимҗан абзый! — диде Әдилә, җитди генә.— Күршеләрендә кодача тиешле бер апа бар иде. Ире сугыштан кайтмаган, бер малае белән тора. Шул ике тол бергәләп оя кордылар.

— Гомерле булсын,— диде председатель, іяген кашып.

— Бөтенләйгә алайса? — дидем мин, шатлыгымны яшермичә.

— Бөтенләйгәдер инде,— диде ул, нигәдер миңа түгел, Хәкимҗан абзыйга карап.

— Кайтуың яраган,— диде ул.— Менә солы симәнәсе ташырга керешәбез. Син дә барырсың.

— Кая?

— Кәслегә.

— Бик якын икән! — дип көлде кыз.— Күршетирәдән, әйтик, шул ук Сарсаз глубинкасыннан симәнә алып булмыймы? Анда да бардыр ич солы? Әллә Кәследә могезлесеме?

Хәкимҗан абзый төксе генә елмайгандай итте:

— Ә-ә, үскәнем. Кыз бала шул син, җиңел уйлыйсың. Һе, хатын-кызның шул... Кайсы глубинкада нәрсә бары анысы инде аның дәүләт сере. Сугыш сере белән бер анысы! Безнең катнаш юк анда. Менә Чаллыдан килгән

нәрәт. Пичәт басылган, кулы куелган. Кәследән диелгән и бетте-китте. Барасыңмы?

— Ярар, барырмын,— диде Әдилә, җәберсенмичә генә.

— Мин дә барам,— дидем, кинәт кенә.

Хәкимҗан абзыйның чырае яктырып китте, ул ике куллап чутка ябышты һәм, чырт-чырт итеп, төймәләрне авыштырды.

Кәнсәләрдән без икәү чыктык. Язгы төн. Төн айлы, анда-санда гына юка болытлар ага. Урам яп-якты, инә эзләп табарлык. Урам буп-буш. Анда-санда гына тәрәзәләрдә зәгыйфь утлар җемелди, кеше күләгәләре уйный.

— Кайтыр юлың ерак, усал маһмайлар күп, озата барыйммы! — дидем мин, кыюланып.

— Эшең булмаса, бар,— диде ул.

Барабыз. Элек урам уртасыннан киң, төз ат юлы була торган иде, хәзер тар сукмак, атлаганда бер-беребезгә тиеп-тиеп китәбез.

— Иркен яшәдегез, ахры, Чаллыда,— диде Әдилә, кинәт.

— Нигә?

— Бер матур белән танышкансың икән.

Эсселе-суыклы булып киттем.

— Каян белдең?

— Дамир сөйләде.

— Ә, татлы тамыр! — дигән булдым мин.— Сөйләр ул!

— Бер дә ояты юк,— диде Әдилә, олыларча,— әйбәт кыздыр бит?

— Беркем белән дә танышканым юк,— дип мыгырдандым мин.— Кирәге-кирәкләре бер тиен.

— Арзан бәяләдең син кызларны.

— Мин укырга бардым ич анда, Әдилә.

Юк, Әдиләгә ачуым килеп түгел, Дамирның сүзләренә каным кыза башлады! Каян уйлап чыгарган диген, белә малаең кайсы почмакта сагалап чалып егарга кирәклеген! Сүзне тиз-тиз икенчегә бордым, югыйсә кызып ук китүем бар иде.

— Тутаңның балалары җылашып калдымы?

— Җыламый нишләсеннәр? Миңа иләнделәр. Олы кызын алып кайттым әле, бездә торып торыр.

— Җизнәң нихәлдә?

— Җизнигә нәрсә? Куенында яшь кәләш, авыз ерык...

— Өмете синдә икән дип сөйләделәр.

— Аның өмете булгандыр да, минем өмет башкада шул!

Әдиләнең шулай олыларча, кыю итеп, ачыктан-ачык сөйләшүенә исем китте.

— Кемдә инде ул синең өметең? — дидем мин, йөрәгем дөпелдәгәнен ишеттермәскә тырышып.

Әдилә көлеп җибәрде:

— Бик тиз белер идең бугай.

Сүзсез калдырды бу кызый мине, тәмам зиһенемне бутады. Беравык дәшмичә бардык.

— Әллә оныттыңмы? — дип сорады ул, кинәт.

— Нәрсәне, Әдилә?

— Оныткан, икмәктер, оныткан!

— Әйт инде!

— Минем чәчне тартып китүеңне! Яңагыңа чалтыратуым хәтереңдәме?.. Әллә син башка кызларның да чәчен тарта идеңме?

— Онытмадым, Әдилә! Башкаларныкын тарткан булмады, кояштыр!

— Сөям дигән ымың түгел идемени ул, Ибраһим?

— Ай-һай, каты чәпәгән идең яңакка!

— Онытырлык булмасын дидем, Ибраһим... Егетләрнең хәтер кыска бит аларның... Яшене нинди, күкрәве шундый булсын, дидем!.. Син дә чәчне каты тарткан идең бит... Яңагың шешмәгән идеме, кая, карыймчы, эзе калмаганмы?

Ул ак пирчәткәсен салып минем яңакны сөйде.

— Кытыршы,— диде ул.

Аның бармаклары йомшак, кайнар һәм хуш исле иде. Мин ихтыярсыздан аның кулын эләктереп алдым, икебез дә оялып читкә тайпылдык.

Аларның йорт турындагы карт тирәкләр тонык кына гөжлиләр.

— Иртәгә иртә торасы бар, Ибраһим,— диде ул. Мин аның йомшак бармакларын учымда иркәләдем.

— Хушлашабызмыни, Әдилә?

— Иртәгә күрешәбез бит.

Аны-моны уйлап тормастан, аңа тартылдым, ул бер генә секундка минем кочагыма керде дә, җитез җәнлек кебек йомылып, чыгып та китте, борын төбемдә генә капка ябылды. Аяк тавышы ишетелеп торды, менә ул, тукран төсле генә тукылдатып, ишек шакыды, әтисенең: «Кем йөри анда, кызым, синме?» — дигән карлыккан тавышы ишетелде...

Мин, Түбән оч бозавы, хат язарга куркып йөргән булдым! Үскән Әдилә, үзгәргән... Ике кыш, бер җәй дүрт баланы карап, гаилә башлыгы булып яшәгән кеше шул!..

Күз алдым яктырып киткән кебек булды, күтәрелеп карасам, тулган ай болыт астыннан чыгып килә...

Бүгенге көн өчен вакыйгалар артык күп булса да, бер җепкә тезгәч, алар бары тик бер мәгънә алалар иде: әйе, яшәү җиңел булмаячак! Әмма яшәргә, тырышырга кирәк! Әйе, авыр, җәфалы, бөлдергеч сугыш беткәнгә кайчан гына бит әле! Күкрәкләр тыныч сулый башлаганга күпме вакыт узды... Әйе, безнең буын бәхетлерәк... без күкрәкләргә салкын мылтык түтәсе түгел, кызлар кыса алабыз...

Әдиләне озаткан кичтә мин, эссе көндә чишмә суын туйганчы эчкән кеше төсле, сафланып, тынычланып кайттым...

Кайтышлый Дамирларга кагылдым... Дамирның әнисе, сорамый-нитми генә, ишек ачты, кече якта сукыр лампа яктысында җеп эрли икән. Дамир, җылы яраткanga, мич башына менеп утырган.

— Кем бар? — дип кычкырды ул, муенын сузарга тырышып.

Сырма төймәләремне чишеп җибәрдем дә аның янына мендем. Менгәч, сырманы салып ук куйдым. Мич төбе кап-кайнар, һава бөркү иде. Икебез дә аякларны асылындырып утырдык.

— Кайтып кына егылган идем,— диде Дамир, акланып.

— Чанагызны сорап торырга кердем. Бер көн Чаллыдан бик җилле алып кайткан иде.

— Кәслегә барасыңмы? —диде Дамир, бераз көттереп.— Мин дә барам.

— Сине дә җибәрәләрме?

— Үзем барам. Мужыт атларга бераз өлеш чыгарырлар. Чәчү алдыннан аларны азрак сыйламыйча ярамас. Барам! Мин алып кайтканын, мужыт, карлыга төшерерләр... Улаклар күгәрә башлады бит... Ята алмыйм тик кенә карды өендә, йокыга китә алмыйм!.. Алар бит төне буе ыңгырашалар!..

Өйгә кабаланып кайтып, иң әүвәл лапаска кагылдым, караңгы почмакларда кармалана торгач, чананы эзләп таптым. Тавык тизәгеннән арындырдым, чистарттым.

Таза гына күренә болай, бер як табаны гына чалышайган. Бау белән мөгезенә тарттырып бәйләсәң, ул ягы да турыланыр. Өйгә чана күтәреп керүемнән әнкәй барын аңлады.

— Барасыңмы?

— Исәп шулай, әнкәй.

— Хәкимҗан абыеңны күрә алдыңмы соң?

— Күрмичә...

— Ни диде?

— Ни дисен?! Әйтмәде.

Балалар йоклый. Без әнкәй белән икебез ике якта көрсенешеп ятабыз... Ул ни уйлыйдыр, утыз биштә тол калган хатынның төннәрен ниләр уйлаганын әле мин белмим, ә минем уйларым гел Кәсле юлына барып тоташа. Чак таңны аттырдык...

Җитмеш биш чана дигәч, бер дә исем китмәгән иде, бик күп була икән ул! Көн артык җылы да, салкын да түгел, сирәк кар ява. Кешеләр җиңелдән киенсәләр дә, җылы киенгәннәр, билләрдә каеш, аллы-кызыллы сөлгеләр, төрле төстәге билбаулар. Муеннарда җылы шарф. Яз ае булса да, март тотрыксыз ул, кәефе кырылып буранлаган чагы да еш була. Арада өлкән апалар, җиңгиләр дә, егет-җилән дә бар. Егетләр, хатын-кыз арасына катнашырга читенсенеп, идарә болдыры тирәсенә бөяләп тәмәке көйрәтәләр. Хатын-кызларның байтагысы соңгы вакытларда эшкә чыкмаган. Югары очлар Түбән очларны, Түбән очлар Югары очларны танып алып, ерактан ук бер-берсен сәламлиләр, кочаклашалар, бер-берсен күрми торган арада гәүдәләренә сарган хәсрәтне коярга теләгәндәй, җилтерәтешеп тә алалар, бер-ике минут сүз әйтә алмыйча, елмаешып торалар да китә сүз чишмәсе челтерәп!.. Кем өйләнгән дә кем аерылган, кемнең сыеры бозаулаган да кемнең сарыгы кысыр калган! Тавыклар күкәй саламы, казлар утырамы, курмы-утын запаслары бетмәгәнме, басуларда кар ятамы, кышкы чир-чорлар кимегәнме?.. Бетәмени дөнья сүзе хатын-кыз берберсен зарыгып очратканда?!

Арыш арасындагы бодай кебек, бер-ике ир-ат та бар. Болары — кичәге фронтовиклар. Алар җитди, кырыс, шушы гайре табигый җанланышның бар хикмәтен алар гына белгән кебек, фронтовиклар председательгә тартылганнар. Куллар шинель кесәсендә, һәр шинельдә кесә

бар, һәр кесәдә кул гына юк... Хәкимҗан абзый үзе дә юлга чыгарга җыенган төсле, кыска тунының билен зәңгәрсу пута белән кысып буган. Речь сөйләргә җыена, ахры, йөткеренә, тамагын кыра...

Ниһаять, Әдилә дә килеп кушылды...

Шуны көтәм икән, шуны эзлим! Башкалар күземә күренмәс булды, ярминкә гөжләгәндәй тавышлар тынды, берәү дә сизмәслек итеп кенә сәлам алыштык, рәхәт булып китте.

Карасам, дәү, биек мөгезле чанасын сөйрәп Дамир Әдилә янына барып та җиткән, җим тырмаган тавык кебек, аягы белән кар тырмаган була, нидер сөйли. Тик кыз егетнең үзенә түгел, чанасына карады.

— Чана дисәң дә чана бу! — диде ул.— Үзең ясадыңмы?

— Ясамыйча? Арсаң-нитсәң, чанаң-ниең белән утыртам да кайтам,— диде Дамир, авызын ат дагасы кадәр ерып.

— Әйем,— диде Әдилә, иркәләнеп.— Куркам.

— Нигә?

— Кем чанасына утырсаң... ни диләр әле?

— Үзеңә Әдилә чанасына кунакларга туры килмәгәе,— дидем мин, Дамирның Чаллыга килеп кергәндә алҗыган кыяфәтен хәтерләп.— Конюхларның аяк йомшак аларның, төшке ашка да айгыр җигеп кенә кайталар.

Бусы үчекләшү иде. Әдилә көлде, Дамир, усалланып:

— Ә син шөшлесез чабатачы! — диде.

Ул арада Хәкимҗан абый өскәрәк, такталары кылдый-былдый торган болдырга менеп басты.

— Туганнар,— диде ул.— Исән-аман йөрергә тырышыгыз. Бер-берегезне юлда ташламагыз. Инде быелгы читен яз соңгысы булсын. Тезләнсәк тә, егылыр өчен түгел, сикереп торып, йөгереп китәр өчен тезләнербез. Быелгысы елда без тәмам ныгып, көчәеп, йөгереп китәргә тиешлебез ки, и анысы шулай күренеп тә тора! Ягез, туганнар, иплэп кенә кузгалыгыз...

— Атлылар очраганда таптап китмәгез! — дип кычкырды кемдер. Кемнәрдер күңелле генә көлеп куйдылар. Хәкимҗан абзый бу ялгыз тавышны ошатып бетермәде бугай, шул якка карап әйтә куйды:

— Быел яз бирешмәскә кирәк, туганнар! Быел яз!.. Алдан хатын-кыз кузгалды.

— Яшь кәҗә тәкәләрен алга чыгарыйк! — дип чәрелдәде арадан берсе.

— Карт сыерлар артка калсын өченме? — диде егет-җиләннәрдән берәү.

Сабираттәй дә монда икән, моңарчы аны күрми торганмын, борылып карап бер генә сүз әйтте:

— Яшь тәкәләр такыр юлны чамалыйлар әле, артка калалар! — диде. Туктап мине көтеп алды, кулымны кысты. Башка вакыт булса, мин аның кытыршы, бирчәйгән бармакларының нигә калтыравын аңламас идем, бүген барын төшенеп алдым. «Менә, Ибраһим нәнәм, көзен интегеп бер якка ташыган идек, хәзер икенче яктан алып кайтасы була» дигән кебек иде аның калтыравыклы кул кысуы...

Бер уйласаң шулай... Икенче уйласаң, әгәр солы безнең амбарларда калган булса, язга чыгып җитәр идеме икән?

Кар төшә. Эре-эре ак күбәләкләр, иркәләнә-иркәләнә тирбәлеп, юлга төшәләр дә безнең чабата астында шадраланып сытылалар. Юл тар, юл бәләкәй, без тар күпер аша чыгучы сарык көтүе кебек кысылышып барабыз. Зәй белән Сарман арасындагы олы юлга чыккач кына бераз иркенәйдек. Бу юлдан аракы заводына Сарсаз сазлыгыннан торф, безнең урманнардан утын ташыйлар, атлылар көн саен диярлек узып тора, унтылар инде безнең якның йөзәр яшьлек имәннәрен, карасаң картузың очып төшәрлек юкәләрен!.. Завод атлары икмәктә, әнә тизәкләрендә чәчрәп-чәчрәп солы бөртекләре ята, җегәрле атлар! Без шул атлар такырайткан юлдан озын бау булып сузылдык. Хәзер янәшәдә ике дә, өч кеше дә атлап була, төрле озынлыктагы бауларга бәйләнгән чаналар гына бер-берсенә дык та дык бәреләләр, мөгезләре белән сөзешәләр.

Авылда чактагы ыгы-зыгы күзгә күренеп кимеде, һәркем җанына якын юлдаш, күңеленә уңай сердәш сайлап алып, шуның белән гәп куертып бара. Сүз юлны кыскарта, юлдагы сүз — чыннан да җан азыгы, сүз озынавыр чакрымнарны санатмый. Юлда иң куркынычлысы — уй һәм ялгызлык...

Без өчәү атлыйбыз. Өчәү булгач, адымнарыбыз эре, җиңел, күңелләр көр. Дамирның уены-чыны бергә, мине тешләргә тырыша, сүзләре белән чәнчеп-чәнчеп куя, мәгәр мин тыныч. Безнең Әдилә белән икәү генә белгән сере-

без бар, безнең икәү генә узган юлыбыз бар. Җитмеш биш җан арасында барсак та, без икәү! Икәү генә, икебез генә! Бу кышкы юл, бүгенге юл, иртәгәге юл ничаклы озын булмасын, ул барыбер кичә без икәү үткән юлның дәвамы гына...

Йөзе белән борылып, ул миңа чана бавын сузды:

— Җәле, Ибраһим, шәлемне генә рәтлимче.

Миңа сузды бит, Дамирга түгел! Дамир сыртына камчы төшкән чыгымчы ат кебек алга ыргылды, без янәшәдә икәү генә калдык. Минем кулда ике чана бавы. Юк, мин ике чана тартып бармыйм хәзер, мин ике йөк бәхет тартып барам, ике куаныч минем кулымда! Юл буенда гына учма-учма саламнар кадалган — маяклар. Күземә алар парлы-парлы булып күренәләр... Мин сабан туенда чаптар атта бараммыни!.. Сары маяклар — тирә-яктагы кызларның сары яулыклары, сары кәләпүшләр, сары тасмалар... Рәхәт!..

Әдилә туктап ак шәлен рәтләде, сырма кесәсеннән чите китек көзге чыгарып купшыланган булды.

— Матур син, бик матур,— дидем, үз-үземне белештермичә.

Ул ялт кына як-ягыбызга карап алды.

— Миңа матур булмыйча ярамый.

— Әйе шул.

— Бик тиз ризалашасың әле син! Шундый көндәм кешеме дисәм...

— Тиз түгел, Әдилә. Мин күптән шулай уйлап йөрим.

— Ни дип уйлыйсың?

— Син җырчы кыз. Җырчы кыз матур булырга тиеш. Җырчы кыз — үреп салган такыя төсле, аны бөтен кеше күрә.

— Остарган син... Чаллыда...— диде ул, күзләре белән мине иркәләп.

Шәл читеннән дулкындай чыгып торган чәчләрен азмаз җыештыргач та, ул бияләен кияргә ашыкмады, ялан кул гына чана бавына үрелде, мин аның үтә йомшак бармакларын тотып алдым, сөйдем.

— Эссе,— дидем мин, туп-туры алга карап. Әдиләгә карарга да кирәкми иде хәзер, безнең куллар бер-берсенә нидер әйтәләр, сөйләшәләр. Аларның сүзен-ымын, сихри өнен без икәү генә аңлап барабыз.

— Синең кулларың ныгыган,— диде ул.

— Тимерне нык бордык тегендә.

— Чаллы матурдыр?

— Әллә ни күреп тә булмады. Кыш бит, кар ерып кая барасың. Җәен матур гына була. Кама буйлары, аргы якта зәп-зәңгәр урманнар, анда, Тарловкада, санаторий, диләр, чирлеләр ята икән. Ап-ак пароходлар йөзә. Ә Чаллы үзе сары ком. Элеватор тавы биек-биек, текә яр, әллә кай төшләр күренеп тора.

— Тауны яратам мин... Сарсазда чакта түтинең олы кызы белән Кашка тауга әллә ничә барганым бар.

Сарсаздан Кашка тауга дүрт-биш чакрым, бала җитәкләп әнә кая барып йөргән икән Әдилә!

— Таудан мин сине күрдем!

— Ничек?

— Югары авыл урамыннан атка утырып чыгып килә идең!

Көлештек. Кар мулрак төшә башлады, җил дә исеп куя, кар бөртекләре шомырт чәчәкләре күк коелып безнең юлга түшәләләр, безнең сырма җөйләренә килеп куналар. Әдиләнең сызылып торган кара кашларын агарталар... Без барабыз. Без хәзер бер сүз дә сөйләшмибез. Куллар кулда, сизәм: уйлар да тоташкан...

Бераздан көн җепшетте, юл авырайды, алдагы рәтләр буталышып тукталдылар. Без әлегә арттан барабыз, еракеракка сузылган кәрван күз алдыбызда. Без дә тукталдык. Куллар, теләр-теләмәс кенә, бер-берсеннән аерылдылар.

Алдагылар:

— Яшьрәкләр алга чыксын,— дип шауладылар.

— Майлары эресен бераз.

— Такыр юлдан парлашып кына теркелдәрләр иде бугай...

Бусы безнең капканы кагулары булды. Мин алга ыргылдым, Дамир миңа иярде, Әдилә дә бездән калмады. Кыз-кыркын, егет-җилән, чыр-чу килеп, безнең эзгә төште, базар ясады. Өлкәнрәкләр, юл сабып:

— Юртакларга урын бирегез!

— Сабан туе чабышкылары килә,— дип кычкырып, сызгырып, тел шартлатып, көлешеп безне озатты.

Әдилә белән икәү иң алга чыктык. Элек, без арттан барганда, бөтен кеше күз алдыбызда иде, хәзер без аларның күзе алдында. Безнең янәшә барган җилкәләр аларга серне ачып ташламаса ярар иде! Бая тотаклашкан

җылы куллар шултиклем шаһитлар алдында бер-берсеннән ерагайсалар да, без бик якын, ым-ишарәләр аңлашылырлык дәрәҗәдә якын идек...

Уйлыйм-уйлыйм да, ышанырга да, ышанмаска да белмим: каян килде миңа шушы хәтле бәхет?! Сугышның беренче аенда ук ятим калып, тол ананың сыңар канаты астында, туйганчы аш ашамыйча, күңел юанырлык кием кимичә, кайчагында кимсенеп тә, кайчагында чамасыз гарьләнеп тә яшәп килгән сынык күңелне нишләттең, Әдилә?! Гомер онытырлык итмәдең...

Ләке урманына җитәрәк борылып карасак, авылдашларны бер җир буе артта калдырганбыз икән. Безнең арттан ук диярлек мышный-мышный Дамир килә. Кар тагын да ныграк ява башлады, җитмәсә, үзе дымлы, җепшек кар, авыр кар. Бусы бик начар иде, өсне чылата, юлны авырайта торган март кары. Урман юлның бер ягында, сулда гына, уңда — япан кыр, чуп-чуар чигешле куян эзләре күзгә күренеп тирәнәеп, күмелеп баралар.

Урман ышыгында рәтләр тыгызланды, уртак сүзләр купты. Бөтен кеше тизрәк заводка барып җитү турында хыяллана иде. Анда аз-маз хәл алып тамак ялгарга исәп. Ләке урманын узгач та, түбәнгә озын, сөзәк үр башлана, юл бераз җиңеләергә тиеш. Офыкларны иңләп, күңелләрне басып, җылымса, авыр болытлар шуышты. Сабираттәй:

— Буран-кыян чыкмагае, сул кулымны күтәрә алмыйм, сызлый,— диебрәк торды, һәркем үз тәнендә, үз күңелендә булган үзгәрешләрне көн бозылуга юрады. Берәүләрнең колагы кычыткан, эт аунаган, каргалар түбәнтен очкан...

Барыбызның да курыкканы буран иде. Бик мәкерле, бик алҗыткыч, бик дәһшәтле була җепшек, кара март бураннары! Кешенең адымын салмакландыра, акылын җуя, изрәтә, зиһенне томалый, авыр кар дөньяны да, күкне-җирне, нужалы юллардагы адәм балаларын да күмеп-каплап китә... Әдилә белән башта һәр кар бөртегенә куанышып барсак та, безнең иреннәр дә кысылды, илдә хәсрәт барда тыйнак булуың әйбәтрәк! Барабыз, барабыз да иреннәргә кунган карны ялый-ялый, ымсынып, күккә күтәрелеп карыйбыз. Күк шундый түбән, салынкы, үрелсәң, болытларны сөзеп алып булыр төсле. Ява, туктарга һич исәбе күренми. Кәрванның ахырын, азак-

тагы кешеләрне түгел, бездән ун-егерме сажинда баручыларны да аерып танып булмый. Бер якка янтаебрак, иелеп атлап барганга кешеләрнең ярты якларын кар сарып киткән...

Зарыгып күтелгән завод үрен төшә башладык, хәзер бераз гына уңайрак булачак. Буш чана да килә-килә кулны талдыра икән, уң кулымның беләзеге сулык-сулык сызлап куя.

Үр уртасына җитәрәк, безгә каршы менеп килүче атлар очрады. Биек-биек чаналарга юл биреп төрле якка сибелештек. Борыннарга ат исе, авыл кешесе өчен гаҗәеп якын, кадерле терлек исе килеп бәрелде. Дамирга карадым, аның соры күзләре зур булып ачылган, шаккатудан иреннәре дә ачык, үзе әкиятләрдәге шүрәлене күргәндәй хәйран калып, тораташ каткан иде.

— Икмәк ашыйлар шул, таза икмәк! — Дамирның күзләренә моң чыкты, тавышы калтыранды. Әдилә, шукланып:

— Дамир, бу атларның берәрсен сиңа бирсәләр, нишләр идең? — дип сорады.

Дамир телсез калды, Әдиләнең соравын ишеткәннәр көлешә башладылар.

— Дамирга бирсәң, күрсәтә ул.

— Киптереп өрлеккә элә.

— Казылыкчы Дамир!..

Атлылар узып бетте, сүз җебе шуларга ялганды. Кемнәр кайсы сабан туенда нинди атта чабышканнар, кайсы авыл атлары фәлән елларда беренче килгән, кем малае егылып ничә кабыргасын сындырган... Сабираттәй: «Мин килен булып төшкән елны уникe ат җигеп килгәннәр иде»,— дип куйды. «Керәшен очында Май чапканда* өчәр ат җигеп чыгар идек, унар-унбишәр кеше төялсә дә, атлар йөрәк кагып кына барырлар иде»,— диештеләр Түбән очлар... Бер генә тантана да, бер генә бәйрәм дә ир канаты — аттан башка узмаган, һәркемнең атка бәйләнешле бик кадерле истәлеге бар икән, колыннар, байталлар, чабышкылар, юртаклар, йөк батырлары барысы да хәтердә сакланган, заводның шома сыртлы, кыска койрыклы тук атлары шул истәлекләрне кузгатты, барыбыз да күңел сандыкларыбызны ачып, хатирәләр-

* Керәшен татарларында масленица бәйрәме.

не уртак итәргә тырыштык. Сүзләр буранны оныттырды, хатирәләр эчпошыргыч җепшек бураннан көчлерәк булып чыкты...

Хәзер исә атлар өрлектә, кешеләр ятим...

Атларга да кешеләрсез читендер, хәрәкәтсез тору бик кыендыр. Төннәрен ыңгырашалар, ди ич Дамир! Аларның төшләренә дә чуклы-чәчәкле, аллы-гөлле сабантуйлары, колын койрыгы төсле йомшак-ефәк уҗымнар, бәйгеләр, ярминкәләр. Май чабулар, яшел аланнарда керт-керт итеп, тукранбаш кыркып йөргән чаклары керә торгандыр... Алар да карды ярыкларыннан сызгырып кергән тыгыз, март җилен тоялардыр, аларның да каннары кайнарланып китәдер... Бик тирәндә, зәңгәр томанлы ат хыялында айгыр кешнәгән тавышлар яңгырыйдыр...

Без, алдагылар, хәзер тубыктан диярлек кар ерып барабыз, әлерәк кенә узып киткән ат-чана эзләре чак-чак шәйләнәләр. Бездән арттарак килүче Дамир кинәт кычкырып җибәрде:

— Бүреләр!

Шып туктадык. Тыгыз ак пәрдә аша алда, юлдамы, кырыйдаракмы, ниндидер кара төрткеләр кыймыл-кыймыл килгән күк булды.

— Нәрсә бар? Нигә туктадыгыз? — диделәр арттагылар, безне тыгызлап.

— Бүре күргәннәр.

— Йөри ди сиңа, көпә-көндез!

— Бүре дигәч бүре инде! — дип этәчләнде Дамир.— Ләке урманында мыж алар, чокыр-чакырлы урман бит, бүре оясы. Шуны белмисезме әллә?

Белми идек, шулай да шиккә төштек.

— Шушы хәтле халыкны ашап бетермәсләр әле,— диде Әдилә.

— Чукмарны аласы калган,— диде үкенеп Дамир.— Бабайдан калган чукмар бар безнең. Келәттә ята.

Акрынлап атлыйбыз, кара күләгәләр дә якынлаша. Ат дисәң, атлы түгел, кеше дисәң, кешегә дә охшамаган. Нәрсә булыр бу?

— Йөктән төшеп калган нәрсәдер, селкенми,— диде кемдер.

Янына килеп җитәрәк кенә безне өркеткән кара нәрсәнең юл уртасында туктап, яртылаш карга күмелгән «ХТЗ» тракторы икәнен белдек. Атлар үткәндә, Дамир-

ны кәмит иткән идек, хәзер чыбык очы миңа чажлап килеп тиде.

— Тракторчы чана тарта, тракторы юлда ята! — дип такмаклады Дамир.

— Ибраһимны көткән бу нәмәрсә!

— Трактор ятмый,— дидем мин, җәберсенеп. Күңелдә: «Ничек итеп бу тракторны авылга алып кайтырга?»— дигән сорау туды. Җилдән ышыкланып трактор тирәсенә сырышкан хатыннарны аралап, әле уңга, әле сул якка чыктым. Ягулыгы бетеп туктаганмы, әллә берәр урыны ватылганмы, белмәдем, трактор байтактан монда тора, ахрысы, тәгәрмәчләрен кар күмә язган.

— Эх,— дидем мин.

Сабираттәй минем ни уйлавымны төшенде, ул да килеп җитеп, күзләрен тутырып тракторга карап тора иде.

— Келтерәтеп кенә авылга алып кайтыр идеңме?

— Эх, Сабираттәй!

— Әллә кайчан талап бетергәннәр инде моны! — диде Дамир.— Юньле часте калмагандыр. Мин тәмам кызып киттем:

— Кем талаган? Магнетосы монда! Алсалар аны алырлар иде. Свечалар да урында... Радиаторы төзек күренә. Карбюратор ике шөреп белән генә беркетелгән. Алыйм дигән кешегә момент! Аны да алмаганнар.

— Ә утыргычы! Утыргычын каерып алып киткәннәрме?

— Утыргычынмы? Анысын аның тракторчы урламаган. Анысын инде кулы кычыткан комсыз бәндә чәлдергән.

— Сцеплениенең татарчасын беләсеңме? — дип сорады Сабираттәй.

— Белмим.

— Фирәзә булыр аның исеме, Ибраһим. Нинди матур исем кушканнар.

Тракторның исән, бөтен булуы, детальләрнең таланмавы минем дәрәҗәне күтәреп җибәрсә дә, корыч айгырның карга чумып мескенәеп юлда утыруы күңелемә бик авыр тоелды. Кем кузгатып чыгарган аны юлга? Нигә ташлап киткән?..

Петровка аракы заводына килеп җиттек. Игәнә суы аркылы салынган күпергә кергәндә, борылып карадым, трактор күренми иде инде...

Ах-ух килеп, йортлар арасына ышыккарак барып кердек. Көннең кайсы вакыты икәнен дә аермачык белмибез. «Минем корсакның торышына караганда, төш авышкан булырга тиеш»,— ди берсе. «Минем корсакка төш Ләке урманында ук җиткән иде»,— дип җорлана икенчесе. Ял итеп, тамак ялгап алырга берәүнең дә каршылыгы юк иде. Теге яктан озын үрне төшсәк, монда каршыбызда бик биек тау бар, ял итмичә, ашап алмыйча без бу тауга менә алачак түгел.

Беркадәр өскәрәк менгәч, аркылы урам уза. Аркылы урамның ике ягына агач кибетләр, ашханәләр, учреждениеләр урнашкан, почта да шунда. Телефон чыбыклары яман усал үкерәләр. Җил арасынан завод гудогы да юаш кына, тук песи мырлаган кебек кенә ишетелеп китте. Чаналарны кибет ишеге төбенә тартып китердек тә, төркем-төркем булып, эчкә кердек. Тик без кызыгырлык берни дә юк иде кибеттә. Балта сабы, көрәк сабы, агач көрәкләр, җилпуч... Кәнфит-прәннекләр күзне кыздырса да, алары карточкага гына бирелә икән.

Чабата кары эрегәнче тизрәк урамга чыктык. Урамда калган иптәшләр арасында ниндидер җанлылык сизелде.

— Ичмасам, без эш майтарып йөрибез,— диде кибеткә каршы бинадан чыгып килүче Сабираттәй.— Ашханә икән анда!

— Югары авыллар килә дип, майлы бутка пешереп куйганнармы?

— Белен дә, майлы бутка да юк, иллә мәгәр чәйләре бар!

Бу хәбәр утә сөенечле иде, каты-коты белән салкын җилдә тамак ялгауга караганда, җылыга кереп бер-ике стакан кайнар чәй эчеп җибәрсәң, бу инде юлга көч дигән сүз. Ә безгә көч бик кирәк иде әле... Бик кирәк!

Бәләкәй ашханә барыбызны да сыйдырмады, өлкәнрәкләр эчкә узды, яшь-җилкенчәк аптырап тормады, «Насыйп түгел икән, бигрәк әйбәт!» дип гөрелдәшеп тышта калды. Берничә чананы уртага куеп, үзебез шулар тирәсенә утырыштык. Байтак кеше калай кружкадыр, котелоктыр тыккан икән; ашханәдән уттай кайнар ике чиләк су алып чыктылар, кем кишер чәе, кем җиләк чәе йөздереп, шуңа әйбәт төс керттек. Дамир да, мин дә кружка тыкмаганбыз икән, Әдиләнең бизәкле ак чәшкесенә чират алдык.

Өйдән чыккан ризыкларны уртак табынга куярга кирәк иде.

Иң кыен вакыт иде бу. Берәүләр кыенсынып тынып калды, күзләр җиргә тәгәрәделәр... Кысыр сыер җилене тиклем генә ризык капчыкларыннан нәрсә-кара чыга башлады. Алабута кушып пешерелгән, кайрактай кара катламалар, бәрәңге кырып шуңа сыңар уч кына әремле арыш оны кушып пешерелгән ләчтә ипиләр, тәгәрәткән бәрәңгеләр... Таза ипиләр дә солы, ясмык, борчак оны кушып пешергәнгә вакланып, уалып торалар.

Болар барысы да уртага чыгып тезелделәр. Уртадагы чана өстендә чиста ашъяулыкта урын калмады диярлек. Каян башына килгән диген, ашъяулыкны Әдилә тыккан икән!

Гыймай Фатихының яссы күкрәкле, бөкрерәк кызы Гөлбәдәр генә, «күрәләрме-күрмиләрме» дигән сыман, аска карап, табынга бер кыерчык бодай ипие куйды. Аның кыерчыгы яңа туган ай күк балкыса да, табын уртасында ахыргача утырып калды...

Куллар табынга үрелде...

Юлда, ындырда, җилдә киселеп, яргаланып беткән, бирчәйгән бармаклы, эре, калын тырнаклы куллар... Тупырдатып бала сөясе урында, җыерчыклы күз тирәләреннән күз яше сөртеп өйрәнгән куллар...

Гомер-гомергә иннек-май күрмәгән иреннәр шау кайнар чәйле кружкаларга тиде, кояш нурларында төссезләнгән сирәк керфекле күзләр рәхәтләнеп кысылды, тартылган яңак сөякләре шытырдап китте...

Табын янында гына була торган тантаналы тынлык урнашты. Алабута катнашкан булса да, алда — ризык. Аны олыларга кирәк!.. Кешеләрнең сулыгып-сулыгып ризык сораган ашказаннарына рәхәт җылылык йөгерде, йөзләргә кызыллык белән елмаю чыкты, төс кунды, беренче рәхәттән соң телләргә татлы сүз килде, туганлашу, татулашу килде. Берәүләр: «Бик күңелле башланды бу сәфәр, ахыры да шулай хәерле тәмамлансын»,— диделәр. Очрашуларына, бергә сәфәр чыгуларына куанышкан хатын-кыз тук казлар кебек каңгылдаштылар. Сугышка хәтле баеп, ныгып калган авылларны телгә алдылар, икмәкне кызыл олаулар белән йөгейөге китереп аудара торган, һәр елда җитәрлек кадәрле балын, яшелчәсен, йонын бүлә торган үзебезнең «Ле-

нин юлы» колхозының элеккеге чакларын сагыныштылар...

Әзерлексез чыккан без агач авызларга да чәй чираты җитте, теләгәнчә кинәндек. Борын өстенә борчак-борчак тир бөртекләре чыкканчы эчтек. Мондый да тәмле чәйне, ай-һай, моңарчы эчкәнем бар идеме икән?!

Завод урамында чәй эчеп утыру бик тансык булса да, безгә ашыгырга кирәк иде. Әбәт иткәндә чак кына тыелып торган буран тагын кар өерә-өерә уйнаклый башлады. Аяклар кызганда хәрәкәт итәргә кирәк иде. Барасы җир байтак, бүген барып җитеп, Кәследә кунарбыз да иртәгә таңнан кире борылабыз...

Үрне шәп кенә, күмәк кенә төшсәк тә, тау менә башлагач, сынаттык. Моңарчы язгы су кебек тоташ бара идек, хәзер исә юл чуарланды, берәүләр өстә үк, икенчеләр мыш-мыш менеп килә, шактый халык әле тау итәгендә диярлек, завод урамын яңа чыгып киләләр.

Сабираттәй дә шулар арасында икән, ул да тауга иң соңгыларның берсе булып менде. Бите тимгел-тимгел кызарган, утлы күзләре чокыраеп тирәнгә баткан, Әдилә дә шуңа игътибар иткән икән:

— Сабираттәйнең чанасын үзеңә ал, Ибраһим,— диде ул.

Сабирәттәйнекен дә алдым, тагын бер-ике алҗыган апаның чанасын үземнекенә бәйләдем, миннән күрмәкче Дамир да өч-дүрт чананы бергә төйнәде, без аның белән лилипутларның корабларын сөйрәп баручы Гулливерга охшап киттек...

— Булмас бу,— диде Дамир, өметсезләнеп.— Бүген шулай җөгәнгән хатыннар иртәгә ни кырырлар?

— Иртәгә мондый алҗыткыч тау юк инде,— диде Әдилә.— Кайту ягына юл җиңелрәк тә була.

Заводтан соң алты чакрымда Тарлау авылы. Тарлауга кергәндә, кара буран чыкты. Моңарчы яннан искән җил әле каршыдан бәрде, әле артка төште, эре-эре кар кисәкләре өерелеп очып килеп яңакларга, керфекләргә сыланды, болай да салынган башлар тагын да түбәнрәк иелде.

— Булмый,— диештеләр берәүләр.

— Шушында куна калыйк.

Азчылык шулай дигәч, күпчелек икеләнде.

Әдилә болай диде:

— Бүген ничек булса да барып җитәргә кирәк.

— Нигә кунып чыкмаска? — дидем мин дә азчылыкны уйлап.

— Бүген куна калсак, иртәгә барып кына җитәбез. Тагын көн ярым кайтырга... Ә нәрсә ашарбыз? — диде Әдилә. Сабираттәй буылып-буылып йөткеренсә дә, аны яклады:

— Барыйк без... Кәслегә барып җитү кирәк. Әйдәгез, тагын бер нык кына талпыныйк.

Ишле халыкка кара буран да куркыныч түгел алай, йөрәксенеп, Тарлау урамын да чыгып киттек. Авыллар ешайды... Әхмәт, аннары Әлмәт... Бәләкәй Әлмәт... Бөгелмә ягындагы Әлмәтнең адашы...

Авылда чакта юлны ничек узасын, көчебезнең күпмегә җитәсен берәү дә күз алдына китерә алмый иде. Анда барысы да сер иде. Хәзер исә юлның без уйлаганга караганда күп авыр, алҗыткыч булуы күренде. Шушы таркаулык мизгелендә, гомуми аптырашта Әдиләнең тапкырлыгына, кыюланып сүз әйтә алуына, Сабираттәй кебек авылның авторитетлы хатыннарының аңа ияреп китүенә мин хәйран калдым.

Каян килгән аңа шундый сизгерлек? Каян килгән төпле итеп сөйли алу?

Егет-җиләнгә эш артты, без әле артка калабыз, әле юл таптарга алга чабабыз. Олы гына апалар бакча балалары күк тотаклашып атлыйлар, чөнки җил, гәүдәләрне сындырырдай җил, һаман тукталмаган җил! Телефон чыбыклары безгә хәбәр китергән кебек ачыргаланып, өзгәләнеп сызгыра...

Теләк уртак карарга әверелде: тырмашып булса да, Кәслегә барып кунарга! Иртә таңнан исән-аман солыны төяп чыга алсак, үз авылыбызга соңгарып та кайтып керә алырбыз. Иртәгә ашыкмасак та булыр, бүген бирешмәскә кирәк. Бүген, бүген, бүген!..

Күңелгә күптән ишеткән бер кызык килде, үзалдыма көлеп куйдым.

— Сөйлә, сөйлә,— диде Әдилә,— башкалар да белсен!

— Белмиләр ди аны...

— Белмәгәне дә бардыр...

— Әлмәтлеләрне «әметиләр» дип йөрткәнне беләсезме? — дип сорадым мин якындагы кешеләрдән. Беләбез дигәнне ишетмәдем.

— Аларны азрак кына хурлау сүзе булыр бу... Тари-

хы болай булган. Әлмәт авылы коры җирдә утыра, инеше-елгасы да, чишмәсе дә юк авылның. Шуңа күрә әлмәтлеләр йөзә белмиләр. Бер заман шулай, ярминкәләр әле бик шәп чакта, әлмәтле унөч кеше Нөркәйдән кайтып киләләр икән. Төнгә калганнар, җәяүлегә юл ерак шул! Азрак кына төшергәннәр ди болар, кәефләнеп җыр суза-суза кайталар, имеш. Бер заман, Әхмәт авылын үткәч, карабодай басуына барып чыкканнар болар. Ярминкәгә киткәндә генә ямь-яшел булып калган басу дулкын-дулкын ак-ак чәчәккә күмелгән икән. «Бәй,— дигән өлкән бер агай,— харап булдык бит, егетләр, Агыйдел монда күчкән бит! Нишлибез?!»

Утырып озак кына уйлашканнар болар, шешә төбендәге калдыкларны капкалагач, Агыйделне йөзеп чыгарга карар биргәннәр... Кочаклашып бәхилләшкәннәр, чишенеп ташлап күлмәк-ыштаннарын, күчтәнәчләрен бәйләп кул очына күтәргәннәр дә ап-ак чәчәктә утырган карабодай диңгезенә чумып йөзә башлаганнар. Байтак быкырдаганнар болар, азаплана торгач, теге як ярга йөзеп чыкканнар. Теге акыллы агай: «Ходаның рәхмәте белән йөзеп чыктык, инде санап карыйк, берәребез батып үлмәдеме икән?» — дигән. Шешәдәге калдык белән, бераз җылынгач, болар саныйлар, саныйлар икән, бер кешегә ким чыга икән. Үкерешеп җылашалар икән әлмәтлеләр! Кем батып үлгән дә, кем харап булган! Әле ярый, Әхмәт авылының бер егет кунактан кайтып килә икән, Әлмәт йөзәрләрен тезеп куеп санап биргән бу. Барысы да исән-сау икән, хикмәт шунда, әлмәтлеләрнең санаганы бере үзен исәпкә кертми калдыра килгән... Шуннан бирле Әлмәт авылы кешеләрен, «әметиләр, карабодай басуында йөзүчеләр» дип шаярталар... Бу хикмәтне авылның даны китсен өчен әлмәтлеләр үзләре уйлап чыгарган дип тә сөйлиләр...

Минем мәзәк рәтләр буйлап китте, Әлмәт авылына барып кергәнче, авылны узганчы шуны тугыладык...

Әлмәтлеләр, кичерсеннәр, шушы гөнаһсыз мәзәк безгә көч кертте.

Кәслегә җитәрәк, Әдилә җиңелрәк сөякле өч-дүрт кызны ияртеп алга китте, алар, без тупланып барып кергәнче, идарәдә фатирлар белешеп, кешеләрне җидешәр-сигезәрләп кайсын кемгә бүлеп тә куйганнар иде. Без исә Кәслеге кеше аягы басылгач кына барып әлгәштек.

Берзаман Кәсле урамнарына бөтен Югары авыл күченгән кебек булды, анда да, монда да җилдә карлыккан тамаклар кычкырып бер-берсен, иптәшләрен эзлиләр, фатирга эндәшәләр, кар сарган капкаларны көч-хәл белән ачалар. Иңнәренә бишмәтләр, туннар салган хуҗалар, кулларын төкереклəп, капка алларын көриләр, юлчыларны чакыралар. Тавыш, шау-шу.

— Гафифәти, безнең белән керәсеңме?

— Нурия, гырламасаң, безгә ияр!

— Үлҗәнәне күрмәдегезме, кадалгыры!

— Без монда-ау!

Капкалар ябылды, тавышлар тынды. Иң аргы фатирга иптәш кызлары белән Әдилә төшкән икән, Дамир белән мине шунда чакырдылар.

Без кергән өйдә ишле генә гаилә яши икән. Хуҗабыз Габбас абый сугышта булган, ахры, өстендә искерә төшкән юка гимнастерка. Ул, без тезелешеп кергән чакта, ишек яңагына таянып баскан иде, чишенеп, өс-башларыбызны таратып ташлаганчы шуннан кузгалмады. Аның яңаклары эчкә суырылган, йөзе кырыс, сирәк сакалының бөртекләре эре-эре булып төрле якка чәбәләнгәннәр. Пошынып та куйдым, идарәдән керткәннәрдер кертүен, хуҗага безнең ябырылу бер дә ошамады, ахрысы! Аның караvы, хатыны Сәрвәр апаның теле телгә йокмый, орчык күк тирәбездә бөтерелеп йөри, анысын-монысын сораша, тула оекларны кибәргә үзе элде, киемнәрне җылыга мич буена таратты.

Алардан тыш өйдә тагын бер өлкән кеше бар иде. Сөннәтчә кырма сакаллы, ап-ак чәчле бер карт без кергәндә түр сәкедә намаз укып утыра иде, менә ул, Алла белән әңгәмәсен тәмамлап, тезләрен бөкләп намазлык өстендә утырып калды, берәм-берәм барып аның җылы, сөякчел кулын кыстык.

Мич арасында юан сүс муенчак белән бәйләп куелган кызыл бозау күренде, мич башында өч-дүрт бала мыштым гына әүмәкләшәләр. Йоклаган булгандыр инде алар, без гөжләгәнгә уянганнардыр.

— Комачау ясадык сезгә,— дидем мин, Габбас абыйга карабрак.— Балаларны да кузгаттык. Хуҗа һаман эндәшмәде. Сәрвәр апа, бәрәңге әрчегән җиреннән бүленеп:

— Куйсана,— диде,— без күнегеп беттек инде, әле

өченче көн дә унике кеше кунып чыкты. Сез дистәгә дә тулмаган!

— Унике? — дип, ах иттеләр кызлар.

Әдилә барып бәрәңге әрчешмәкче дә булган иде, Сәрвәр апа: «Ял ит, хәлдән тайгансыз ич»,— дип, тегенең кулыннан пычакны тартып алды.

— Глубинкабыз зур шул безнең,— дип аңлатты Сәрвәр апа.— Үзебездә үскән игенне дә читкә ташымыйбыз, сортовой орлык кына чәчәбез. Казаннан килеп тикшереп кенә торалар безнең басуларны!

Сорт участогы икән бу Кәсле! Аерым хисапта яшәүче бәхетле колхоз!

— Сарсазлар да ярты басуларына сортлы орлык чәчәләр,— дип сүзгә катышты Әдилә.

— Габбас абый гына безне өнәмәде шикелле,— дидем мин, һаман ишек катында басып торган сүзсез хуҗага карап.

— Сөйләшми ул,— диде офтанып Сәрвәр апа,— сугыштан шулай кайтты. Инде кырык дүртнең кышында, немецның койрыгына каты кыл бәйләнгәндә, яннарында гына мина шартлап телсез калган... Болай, ачылыр әле, диләр, ничек булыр инде, Ходай ни язган. Балалар бәхетеннән ачылып китсә кана да бит...

Бабай бездән: «Кайсы авыллар сез, озак килдегезме, юллар ничек?» — дип сорашып алды...

Дәү казанда, түгәрәк капкачны биетеп, бәрәңге быгырдый башлады. Сәрвәр апа казан астына коры йомычкаларны өстәп кенә тора. «Көзен мунча күтәргән идек, шуның йомычкасына рәхәтләндек». Без һаман да юл хатирәләре белән уртаклашабыз, трактор турында, завод турында сөйләшеп алдык. Сәрвәр апа башкаларның кемгә фатир төшүләре турында да кызыксынды. Алты-җиде кешенең моннан өч өй аркылы гына туктауларын белгәч, башын кагып иренә ымлады. Габбас агай бик җитдиләнеп, җыерчыклы киң маңгаен тагын да җыера төшеп аңа текәлде, аннан ризалыгын белдереп башын какты, беренче тапкыр йөзендә елмаюга охшаган яктылык чагылды. Намазлык өстендә утырган бабай да, аларның ымнарын аңлап:

— Җайсызрак булган икән шул,— дип өстәде.

Сәрвәр апа бабайның сүзен ачыклагач кына без эшнең нәрсәдә икәнлеген аңладык.

— Ни инде, Мәҗит хатынына, Минниса җиңгиләргә кергәннәр, алайса, сезнекеләр,— диде ул.— Күңелләре тар түгел аларның, юк, бик тә әйбәт кешеләр, фатирына да кертәләр, йомышка-юлга йөрергә дә ипле күршеләр, мәгәр тамак яклары кысанрак быел... Өй эчләре тулы хатын-кыз, Мәҗит үзе Сталинградта калды, Минниса үзе саулыкка мохтаҗ... Бил белән интегә. Җитмәсә, былтыр бик казаландылар, Ходай күрсәтмәсен! Сыерлары уҗым ашап күбенде, чак чалып калдылар... Бәрәңге базларына су кереп әллә нихәтле бәрәңге кисәүгә әйләнде... Сезнең андагыларны бәрәңге белән сыйланырга монда дәшәрбез. Калган ашым да бар, кысыр умач булса да, сөт белән агарткач ару гына булыр әле. Ипиемне дә угыз белән изгән идем...

— Алай икән, алай,— диешеп тыңладык. Сәрвәр апа тагын җиде кешене ияртеп кайткач, болай да кысан өй эчендә инә төртерлек тә урын калмады. Габбас абзый һаман урынга утырмады, аяк өсте тегеләрне каршылады, чишендереште, олы табак белән бәрәңгене дә табынга үзе китереп утыртты.

Ян сәкегә яр карлыгачлары күк тезелешеп утырышсак та, һәр урындыкка икешәр кеше калды, чоланнан буш тәпәннәрне керттеләр, әйләндереп каплагач, алар да эшкә ярады. Алай да Дамир белән миңа урын җитмәде, бәрәңге тутырган калай табакны минем тез өстенә куеп, икебез җылы мич янына чүгәләдек.

Ир кешеле өй... Хуҗасы бар өй! Әтиле өй!.. Дамир да, мин дә ятимнәр... Ә монда әтиле балалар... малайлар... Кергәч тә, мин аларга көнләшебрәк караган идем, хәзер әллә ничегрәк...

Өстәл янындагылар да һаман-һаман шул сүзгә әйләнеп кайтабыз. Элек матур гына сөйләшкән кешенең авыр контузиядән соң, тынсыз-өнсез калуына барыбызның да күңел сызлый, бу хәл белән берничек тә килешәсе килми иде. Сәрвәр апа да ике сүзенең берендә ирен телгә ала:

— Ял итсен, диләр... Диңгез буена барсын, диләр. Нинди диңгез ди әле монда! Нинди ял! Карап торган ирләребез биш-алты бөртек булгач, ел әйләнәсендә көнетөне эшлиләр. Сезгә дигән симәнәләрне хәстәрләп куючылар да шулар! Менә тормышлар аруланыр, җайланыр, аннан дәваланырга да өлгерер, теле дә кайтыр. Менә сез дә яхшы теләктә торыгыз!..

Ул ак яулыгының очы белән күз яшьләрен сөртте.

Зиһенем ачылып, күз алларым яктырып китте. Бу мәшәкатьләр, кадерле кунакны каршылаган кебек каршылау, егермегә якын кешегә әзерләгән сыйлы табын, өченче көн генә кунып чыккан унике кеше — үз яхшылыгыннан тыш аның өчен дә — Габбас абый өчен эшләнә! Аның исән кайту куанычы шултиклем зур, сөенече шулкадәр мул — Сәрвәр апа бу сөенечне тел белән генә гомердә дә әйтеп бетерәчәк түгел!.. Шуның өстенә якын кешесен — балаларының газиз әткәсен телле итәсе килү теләге шундый көчле ки, ул һәр кичне утыз-кырык кешене фатирга кертергә риза, базында бәрәңге барында, чоланында он барында ул барысын туганнарча бүлешәчәк, кергән мөсафирлар аларны онытмасын гына, Габбас абыйлары өчен теләктә генә торсыннар!

«Кешеләрне Габбас абыегыз гозерен үтәп кертәм»,— диде ул соңыннан... Мөгаен, анысы да хактыр. Юк, бу теләкләре уртак аларның, алар өй эчләре белән чиксез бәхет тоеп, сөенешеп яшиләр, үз бәхетләре белән кешеләрне дә шатландырырга телиләр.

Яшәүнең иң бөек максаты, кешенең иң гади сыйфаты шул түгелмени?

Алтын булып агаем ла...
Көмеш булып тамаем!..

Шушы җырдагы кебек ич аларның тормышлары... Әдиләне бер җырлатасы иде...

Аркада җылы мич, тездә бушап бара торган кайнар табак... Өй эчендә әйтеп, сөйләп бетерә алмаслык рәхәтлек. Һәркем үз күршесенә бәрәңгенең тәмлерәген куярга тырыша, күңелне күтәрә торган татлы сүзләр әйтелә... Бәрәңгене ялт иттердек. Аннан чәй килде. Чын чәй, куе итеп ясалган такта чәй. Сәрвәр апа чоланнан бал керткәч, барыбыз да ах иттек. Бал, бердән, бик кадерле кунакка гына куела торган нәрсә, зур сый, икенчедән, март ае булса да аларның баллары шикәрләнмәгән, ягъни утырмаган, кичә генә суыртып куйган төсле сапсары, сәмих сагыз диярсең! Чак кына куерган балны, ояла-ояла, калак очларыбызга эләктереп кенә бер-ике каптык...

Күршедә тукталган юлдашларыбызны андагы хуҗалары, Минниса апалар, безнең янга бәрәңге ашарга бик

авырыксынып кына җибәргәннәр икән. «Юлга алган ризыкларыбыз бер капчыкта иде» дигәч кенә ризалашканнар. Чәйдән соң без Әдилә белән аларны озата чыктык. Чыннан да, Минниса апаларның бәләкәй тәрәзәләрендә ут җемелди, безнең иптәшләрне анда да йокламыйча хуҗалары көтә иде...

Ниһаять, Әдилә белән икәү генә калдык... Күршеләрне озатмаганда да була иде, әмма мин шушы минутны уйлап, шушы минутны көтеп чыккан идем...

— Кайтыйк, Ибраһим, син бик аргансыңдыр! — диде ул.

— Ә үзең?

— Мин бит биш-алты чана сөйрәмәдем. Кәрванның бер очыннан икенче очына чабып та йөрмәдем.

Калдырган эзләребезгә баса-баса кайтып барабыз. Төнге буран урамның ике ягына тыгыз тезелгән йортларны күздән яшереп, безнең ялгызлыкны тагын да көчәйтте, ник бер җан иясе булсын! Этләр дә өрми, ичмасам, шомландырып җил генә сызгыра.

Әдилә кинәт миңа таба тартылды:

— Тукта әле,— диде ул, пышылдап. Икебез дә тын тартмыйча тыңланып торабыз. Йорт араларында җил йолкына, безгә үче бар сыман, колак төбендә сызгыра.

— Бүреләр! —диде Әдилә.— Чукмар менә кайчан кирәк булган икән!

Мин дә ишеттем, бүреләр улый. Берәү генә түгел, икәү, өчәү, шактый зур өер, ахрысы, берсе сузып-сузып җибәрә дә, икенчеләр кыска-кыска көчле тавыш белән аны күтәреп алалар. Алар әллә кайда, без әллә кайда йортлар арасында булсак та, бер өер бүре улаганда тән чымыр-чымыр итеп куя, кот бот тирәсенә төшә...

— Этләр шуңа тынган,— дидем мин.— Бүредән шүрли алар.

— Керик,— диде Әдилә, калтыранып.

— Ерак ич алар,— дидем мин, батыр күренергә тырышып.

Габбас абыйларның өй турына гына җиткән идек, безне тәмам куркытып, гөрс итеп өй кыегыннан зур кар кисәге ишелеп төште...

— Әдилә! — дидем мин, кызның күзләрен күрергә тырышып.

— Куркыныч монда, Ибраһим.

— Күптән синең җырлаганыңны ишеткән юк.

— Әллә шушында җырлатыр идеңме?

— Түгел лә...

— Күптән җырлаган да юк инде...

— Нигә?

— Җыр бит ул язгы су кебек... Үз вакытын белеп кенә кузгала... Март башы — яз башы. Мин март башын бик яратам... Кешеләр уйлап чыгарган бәйрәм түгел ич бу, табигать биргән бәйрәм... Яз җитте, җырларга урыны туры килми, вакыты туры килми.

— Кояш җитми сиңа алайса, җылылык җитми.

— Алай да димәс идем. Бүген менә озын юл үтсәк тә, кәефем шәп...

— Син җырлап җибәрсәң, җил дә тынар, бүреләр дә туктар.

— Каян беләсең?

— Былтыр көз, Чаллыга барганда синең җырыңны ишеттем мин, Әдилә.

— Кайчан иде икән? — диде ул, нигәдер оялып.

— Кич иде. Матур кич иде! Син, җырлый-җырлый, бер башың Олы су ягыннан юлга таба менә идең...

Әдиләнең калку күкрәкләре, нидер сөйли-сөйли, минем күкрәгемне иркәлиләр, назлыйлар, көне буе җилбуран гына кагылган иреннәремне аның иреннәренә якын китерәм, аның май җиледәй тәмле-татлы сулышын тоям, ул күзләрен йоммый, тагын да зуррак ачып миңа карый, елмая, мин аның ап-ак матур тешләрен күрәм, тагын да якынрак тартылам, Әдилә көлә, башын артка ташлый, аннары мине суырып үбә...

Иптәшләр йоклаган. Сеңгәннәр. Сәрвәр апа утны кысып бәләкәй якка күчергән, өйдә ярым караңгы.

— Гаепләштән булмасын, сезнең икегезгә урын мич арасында калды,— диде ул. Кәнфитләнеп торыр чак түгел, без, аны-моны уйлап тормастан, тиз-тиз чишенеп ыргыттык. Әдилә минем йон аякчуларымны, чабатаны мичнең буш калган урынына җайлап урнаштырды, мин лампаны күтәреп аңа яктыртып тордым. Ул көлә, мин дә аңа карап көлми түзә алмыйм.

— Тс-с,— ди ул, миңа бармак янап.

Мич арасына юка гына кыршылган палас җәелгән иде, баш астыбызда әллә чалбар, әллә пинжәк, төймәләре калкып-калкып тора. Өстебездә үзебезнең дымлы кием-

нәр... Баш очыбызда бозау, сарык бәрәннәре. Без кыштырдагач, алар да уянды, бәрәннәр тып-тып өскә үк менеп киттеләр. Мин түзмәдем, көлеп җибәрдем. Әдилә йомшак учлары белән минем авызны эзләп табып томалады...

Аяклар арган... Аяк табаннары гүләп тора... Ничә чакрым җир узган аяклар... Ничә кешенең эзенә басып үткән аяклар... Җирнең моңын, җирнең кодрәтен татый торган крестьян аяклары... Мин үз аякларым янында Әдиләнең аякларын тоям, арганлык та, юлда, тау башында улап утырган ач бүреләр дә онытыла... Бозау әнкәсен сагынып мөгри, бәрәннәр кычкырып мәәлдәп куя, Әдилә миңа таба тартылып, кочагыма керә... Без бер-беребезгә сарылабыз, саф иреннәребез әле кадере югалмаган, бер генә тапкыр әйтелә торган сүзләрне әйтәләр:

— Яратам мин сине, Әдилә!..

— Мин дә, Ибраһим...

Быелгы язны, быелгы җәйне күз алдыма китереп карыйм... Ни генә булмасын, безне алданиләр генә көтмәсен, тыныч яз ич бу! Тыныч дөнья!.. Хат ташучы үткәнен куркып һәм өметләнеп көтәсе юк... Безнең елгыларны әле армиягә алмый торалар. Сугыш безнең яшьтәшләргә килде дә терәлде. «Немецның койрыгын бәйләделәр»,— ди әнә Сәрвәр апа... Әдилә хәзер гел-гел авылда булачак... Әдилә... Аны олылыйлар... Иптәш кызлары да, башкалар да... Ни дисәң дә, тормыш чынлыгы белән күбрәк очрашкан шул ул, ачысын-төчесен иртәрәк татыган. Апасын күмгән... Дүрт баланы карап гомер иткән... Күңеле һәм тәне гарип җизнәсен караган...

Куенымда минем бар байлыгым, өметем, киләчәгем... Куенымда Әдилә... Ул миңа шулкадәр якын, үз булса да, әле мин өйләнү турында уйлый алмыйм... Анысы миңа тиңдәшсез хыял, гомергә эшкә ашмаслык хыял булып тоела әлегә...

Өйдә тагын кемдер йокламый иде. Йомшак кына шыгырдап чыпталы ишек ачыла да, берничә секундтан безнең борыннарга салкынча, рәхәт һава килеп бәрелә. Сәрвәр апа бераздан безнең янга килде.

— Йокламыйсызмы, балалар? — Аның тавышында шатлык ишетеп икебез дә калкындык.— Абзагыз тикшереп тора, буран басылган, суыта!

Чыгып йөрүче Габбас абый икән. Кочагымны тутырып, Әдиләне күкрәгемә кыстым.

— Суыта, Әдилә...

— Суыта сиңа, мин янып пештем...

— Миңа да бик эссе.

Төн уздымы, әллә төштә генә күренеп киткән сихри бер мизгел идеме бу, әйтә алмыйм. Кәсле авылына, Сәрвәр апаларга рәхмәтләр әйтеп сикерешеп тордык... Хуҗалар безне: «Юл төшсә, туп-туры үзебезгә керегез»,— дип озатып калды...

Иртәнге кояш! Рәхмәт сиңа. Күңелләрдә өмет, тәндә көч. Аяклар ял иткән. Өс-баш, чабаталар коп-коры, җиңел. Билләр кысып буылган... Моңа синең якты нурларыңның шифасын өстәргә кирәк, иртәнге кояш. Авылыбыздан киткәндәге җанлылык кабатланмаса да, иптәшләр күңелле генә сөйләшәләр, шырык-шырык көләләр. Иртән кояш күренмәсә, кешеләр сирәк көләләр...

Тиз үк юлга чыктык, кәслеләрнең тәҗрибә зур икән, эшне печеп башкардылар. Җитмеш биш чана. Җитмеш биш капчык солы. Һәркем, хәлле хәленчә, кем чанасында өч пот, дүртне алучылар да бар, ике белән калучылар да булды. Бер кәгазь, бер үлчәү...

Буш чана сөйрәү җиңелрәк булса да, солылы капчыкларны тарту күңеллерәк икән! Юлыбызның бер максатына ирешелгән. Чәчүлек орлык тутырылган. Эре, сортлы солы! Чәчүлек кайта Югары авылга, тереклек кайта.

Дамир чанасында төгәл алты пот... Иртә таңнан Кәсле кардысына төшеп менәргә дә өлгергән ул, авызы ерык:

— Колын күрдем бүген, малайлар...

Колын... Дамирның иң зур хыялы. Монысын мин беләм. Икенче зур хыялы аның Әдилә! Монысын Әдилә белән икебез дә беләбез.

Нишлисең, барлык хыяллар да тормышка ашмый шул...

Алты пот солысын атларга калдыру турында уйлый Дамир...

Колын!.. Тиз генә күреп булмас әле колыннарны Югары авылда!

Әтисе дә конюх иде Дамирның. Биш яшеннән атка менеп чапкан, җиде яшеннән ызанга тырмага төшкән, ун яшьтән чытыр арба белән көлтәгә чыккан иптәшем-

нең хәлен Кәсле юлында аңладым. Сөйгән ярсыз да, атсыз да калган егетнең хәле яман, бик яман иде...

Әлмәткә кайтып җиттек. Кичә кич авыл урамнарын узганда, күз ачкысыз буранда, Әлмәттә тереклек иясе юк сыман тоелган иде. Бүген анда да, монда да кыска бишмәтләрен җилбәгәй җибәргән, бүрек колакчыннарын күтәргән карт-коры күзгә чалынды, малае-шалае шунда урала, капка төпләрен көриләр, урамны — без узасы юлларны — ялт итеп арулап куйганнар. Кара кашлы, шалкан төсле ак йөзле апалар, кулларын каш өстенә куеп, безне каршыладылар:

— Исән-саулармысыз?

— Чәчелмичә барып җитә алдыгызмы?

— Чәй эчеп чыгыгыз!

Чәй эчеп тормадык, урамны көрәп куюлары өчен рәхмәтләр укып юлда булдык. Әлмәтләр авыл белән безнең кәрванны озатып калды.

Завод тавына тиклем шәп кенә бардык дияргә ярый. Берничә кеше шома юлда тәгәрәп китте дә, бер чана ватылды, Зарифа апаның капчыгы ертылып солысы юлга ага башлады, аны берәмтекләп чүпләп тутырдык, тегәрҗеп белән шытырдатып капчыгын ямадык... Үкчә кырылганын, чабата башларына үсеп чыккан әрсез мыекларны санап тормадык...

Заводка җитеп тын алабыз дип куанышканда гына, кәрван уртасында нидер буталды, алдагылар чаналарын ташлап артка борылдылар, арттагылар бер урында бөялделәр. Әдилә белән без дә шулар янына ашыктык.

Сабираттәйнең йөрәк өянәге кузгалган иде.

Торымнан торымга йөрәге кузгала икән аның, дип сөйлиләр иде, бәхетсезгә вакытсыз дигәндәй, шул яман хәл завод тавы өстендә башланган икән...

Без барып арага кысылышканда, Сабираттәй, капчык өстендә кырын ятып, бияләеннән кар ялый иде.

— Хәлең ничек? —дип сорыйбыз аннан. Сабираттәй эндәшми, башын гына чайкый...

Нишләргә? Кеше йөрәге тишек капчык яки ватылган чана түгел, түгәрәк ясап уралган кешеләр бер-икешәр адым читенеп, хафада калдылар.

Хатыннар Сабираттәй чанасы тирәсенә җыйналгач, мин үзебезнең өс-башыбызның нинди таланган, йолкынган иске-москы булуына игътибар иттем. Ябык идек без,

ямьсез идек... Кояшлы март көнендә, тау өстендәге апак кар арасында, барысы аермачык күренде, йончыган идек без, арган идек... Башкалар шулай йончылганда, йөрәк авырулы хатын ничек түзә алсын? Хәкимҗан абзыйның «тузган ул!» дигән хөкеме исемә төште.

Дамирның бөтен авылга атаклы чанасына яңа эш табылды. Аның авыр капчыгын минем чанага салдык. Сабираттәйне, үрәчә арасына аякларын суздырып, Дамир чанасына утырттык.

— Түзми әмәлең юк, Сабира апа,— диде Әдилә.— Завод күренеп кенә тора. Анда инде врач бардыр, каралып чыгарсың.

Хатыннар үз чаналары тирәсенә таралышканда да сүз гел шул турыда барды:

— Кем белән кунды ул?

— Тамагына каптымы икән?

— Йоклый алдымы?..

Чанамда саллы гына ике капчык. Әдилә чанасын Югары очның бер егеткә тактык. Сабираттәй янында Дамир белән Әдилә. Тау төшкәндә чана салулап китү куркынычы бар, Әдилә чытырдап үрәчәгә ябышкан, карап-чамалап кына төшәбез. Аяклар тая, авыр чанам дык итеп тез астыма килеп бәрелә, мин егылып та киткәлим. Сабира апа, мәрткә киткән кебек, сүз дә дәшми, күзен дә ачмый... Ә кояш җете, ак кар күз кабакларын сызлата!..

Бригадир «барма» дигән икән аңа, бөтен авыл кузгалганда ничек түзеп ятмак кирәк дип, дәртсенеп үзе юлга чыккан. Солыны өч пот салдырган...

Тау төшү ифрат авыр булды. Моңарчы чыдап килгән баулар, арканнар өзелгәләде, бер чана хуҗасын бәреп китте дә телефон баганасына барып сыланды, капчык ярылды, солы акты... Егылган кешеләргә карата такмак чыкмый инде хәзер, кешеләр тын, борчулы һәм үтә җитди иделәр. Аяк таймасын өчен бер-берсенә тотынышып, кочаклашып төшәләр...

Бара-бара завод урамына төшеп җиттек. Сабираттәй дә, тынычланып, күзләрен ачты...

Хәзер эшләр җайлана!

Тик заводта врач юк икән, сугышка чаклы бар иде, хәзер тиенә алганыбыз юк шул, диештеләр кешеләр. Фельдшер бар икән, медпункт якында гына, без өчәүлә-

шеп — Әдилә, Дамир һәм мин — Сабираттәйне шунда алып киттек. Башкаларга: «Калып торыгыз, тамак ялгагыз»,— дисәк тә, байтак кеше безнең белән барды.

Сабираттәйне чаршау артындагы ап-ак җәймә җәелгән агач караватка кертеп салдык. Хәзер безгә аның юеш чабаталары белән идәнгә үк салынып төшкән сырма җиңе генә күренеп тора.

Фельдшер апа бераздан безнең янга чыкты. Озын гына, эре сөякле, бераз шадрарак апа. Калын кофтасының түшендә орден ленталары. Сугыштан кайткан, күренеп тора.

— Каян кайтып киләсез! — диде ул, каты «къ» белән.

— Кәследән иде дә, солы симәнәсе алып кайтып барабыз.

— Атларыгыз калмадымыни соң?..

— Атлар ни, бары белән югы бергә...

— Кайсы авыллар?

— Югары авыллар идек.

— Ничек соң, апа! — диде Әдилә.— Ни хәлләр бар?

Фельдшер җавап бирергә ашыкмады, тәрәзә каршысына басып урамга карады.

— Ничек дип әйтим икән? Фельдшер гына мин... Ә йөрәк...

Моңарчы абайламаган идек, ишек яңагы янында стенада телефон бар икән, фельдшер апа шалтырата башлады. Сарман больницасын сорады. Аннан завод идарәсенә шалтыратты. Аның шөбһәле сүзләрен ишетеп без бик каты шүрләдек... Сабираттәйнең хәле әйбәттән түгел икән!

Кем белән сөйләшүен аңламадык, мәгәр сүз гел безнең турыда барды. Трубкасын куйгач, ул безне ашыктыра башлады:

— Хәзер заводтан унике ат торфка китә икән. Югары авыл шундадыр бит? Сез күпер төбенә җыйналып аларны көтеп торыгыз. Өлкәнрәкләр утырып та кайтыр, ә капчыкларның бар булганын шуларга төягез.

Өчебез беравыздан:

— Ә Сабираттәй? — дидек.

— Иптәшегезне алып калам. Больница белән киңәшәм дә үзем ат белән Сарманга озатып куярмын,— диде фельдшер.

Иптәшләр янына чыктык, атлар турындагы хәбәргә

сөенешсәләр дә, Сабира апа турындагы хәбәрне ишеткәч, аларның да борын салынды... Аптырашып Игәнә күперенә төштек, монда озак юансак, завод атларының китеп баруы мөмкин, йөкчеләре дә кырысрак аларның, үткән-сүткәнне утыртырга бигүк яратмыйлар. Шулай булып чыкты да, олаучылар:

— Йөк төяп нишләп йөрик ди? Бүген әйләнеп кайтасы бар. Атлар көне-төне юлда,— дип карышып маташтылар. Без боек кына таралыша башлагач, кул селкеп, чаналарыннан сикерешеп төштеләр һәм безнең капчыкларны чаналарга төяргә булыштылар. Арганракларга, өлкәннәргә урын да табылды.

Атларга төялешеп тә, җәяүләп тә иптәшләр кайтып китте, без Әдилә белән монда калдык. Медпунктка борылып менгәндә фельдшер апа телефоннан сөйләшә иде. Байтак кына көтеп утырдык. Менә теге яктан Сабираттәйнең:

— Косасы килә,— дип әйткәне ишетелде. Әдилә белән мин, белештермичә, аның янына атылып кердек. Чалкан яткан Сабираттәйнең ияге очлайган, күзләре төпкә чумган, чырае танымаслык булып үзгәргән иде.

Фельдшер:

— Чыгып торыгыз моннан,— дисә дә, без кузгалмадык.

Сабираттәй:

— Косасы килә,— дип пышылдады. Аннары күзләрен йомды, хырылдый башлады, юка гәүдәсе буйлап дулкын йөгереп узды. Аннары кинәт тынды.

— Үлде бичара,— диде фельдшер.— Нишли генә алам соң мин? Таланган ич аның йөрәге, ватык сәгать күк келтерәп тора!

Әдилә, ирennәрен тешләп, миңа тартылды, йөзен иңбашыма яшереп капланып төште...

Фельдшер безне: «Үземдә кунарсыз, ялгыз торам мин, иртәгә иртән ат белән китәрсез»,— дип үгетләсә дә, кунарга заводта каласы килмәде. «Иртән килеп җитәрбез»,— дип, без кайтырга чыктык. Ниндидер көч безне өйгә, юлга өндәде...

Трактор яныннан бу юлы сүзсез генә узып киттек...

Безнекеләр авылга кайтып та җиткәндер инде... Юл озын булса да, без бер җирдә дә тукталып тормадык, атладык та атладык.

— Иртәгә үк Хәкимҗан абзыйны күреп сөйләшергә кирәк,— диде нык итеп Әдилә.— Моның башка берәр җае юкмы икән? Кит аннан, шушы кадәр кешене интектерергә, тузга язмаганны!

— Иртәгә түгел, бүген үк күрербез.

— Алла боерса диген... Кайтып җитәсе бар әле! Мин каралҗым-зәңгәр урман өстенә тиз-тиз тәгәрәгән суык кояшка карадым.

— Җитәрбез...

Аяклар талды — аны сизмәдек. Тамак ачты — тукталырга вакыт кызгандык. Барган шәпкә генә ипи сынықларын кимердек. Ни хакында сөйләшсәк тә, сүзнең очына Сабираттәй килеп ялгана иде. Аның көтелмәгән үлеме безне ашыктыра, нидер эшләргә куша иде.

— Балаларын кая куярлар инде?

— Ничәү әле аның?

— Өчәү.

— Өчәү үк икән шул.

Минем Әдиләгә:«Бала карарга синең тәҗрибә җитәрлек инде»,— дип әйтәсем килә, кыймыйм. «Өйләнешсәк бер-икесен үзебезгә алырбыз!»— дип ычкындырырмын дип куркам... Хәзерге минутта андый сүзләргә урын юктыр сыман тоела.

Үзебезнең урманны чыкканда, күз бәйләнә башлады. Урман юлы монда туп-туры, урман юлы тулы кеше! Кемнәр болар? Кая баралар? Ашыгыбрак атлый башладык, беләсебез килә, ара тиз якынайды, безнең кебек үк бәләкәй чаналар тарткан кешеләр килеп җитәрәк, юл читенә чыктык. Бездә буш чаналар, ә аларда... Каршыбызга безнең Югары авыл кәрваны чамасы ук озынга сузылган ишле чаначылар килә иде. Без туктагач, алар да туктады. Иң алдагы чаналы, сыңар куллы ирдән:

— Кайсы авыллар? — дип сорадык.

Ул, теләр-теләмәс кенә:

— Ераклар,— дип куйды.

— Шулай да?

— Чокырлыдан без,— дип, сүзгә катышты аның артыннан килүче йомры хатын.— Ишеткәнегез бармы?

— Юк.

— Кәслене беләсездер алайса?

— Беләбез, аны бик беләбез.

— Шуннан биш кенә чакрым безнең авыл.

— Ничек? Ничек? Ә симәнәне каян алып кайтасыз?

Бу сорауны соң дәрәҗәдә гаҗәпләнгән Әдилә бирде.

— Солы симәнәсе бу,— дип ачыклады хатын.— Сарсаз глүбинкәсеннән чыгардык менә...

Без, аптырап, сүзсез-рухсыз катып калдык. Безнең кыяфәтне күреп, кузгала башлаган чаначылар туктап калды.

— Бәй,— диде тузынып Әдилә,— ә без солы симәнәсенә Кәслегә кадәр барып җиттек. Югыйсә Сарсаз аяк очында гына лабаса. Күрше авыл!

— Безне шулай әрле-бирле йөрткән бәндәләрнең кулы корысын! Тамакларына аш үтмәсен! — дип, Чокырлы кәрванчылары зарланырга тотындылар. Без аларны үтеп киттек, алар һаман зарланып, карганып юл уртасында калдылар.

Урманнан үзебезнең авылга йөгереп дигәндәй, кайттык. Туп-туры идарәгә барып кердек. Хәкимҗан абый, эвене янган кеше сыман, башын кыйгайтып шунда утыра иде.

— Кайтып җиттегезме, үскәннәрем? — диде ул, юаш кына.

— Без кайттык,— диде ярсып Әдилә,— Сабираттәй генә...

— Үлеп калды. Мәгънәсез юлга кугансыз безне! Председатель дәшми, без дә эндәшмибез.

— Чокырлылар очрадымы? — дип сорады ул кинәт.

— Очраттык шул менә! Аңыша гына алмадык!

— Сез, үскәннәрем, болай итегез инде... Чокырлы кешеләрен очратуыгызны бүтәннәргә тишмәгез... Ишеттем мин аны! Нишлисең, кушканны үтәмичә ярамый. Көне буе районда шуны даулап йөрдем! Әлерәк кенә телефонограмма алдык, симәнәне безгә Сарсаздан, якын глубинкадан бирә башлыйлар... Чаба-чаба үзем дә койрыксыз маэмай булып кайттым менә... Тик бу юләрлекне башкаларга әйтмәгез, сеңсен шунда... Эх, Сабира кызганыч!

Иреннәребезне кысып, йодрыкларыбызны йомарлап, идарәдән чыгып киттек, әйтмәдек без ул хәлне, берәүгә дә сөйләмәдек. Җәрәхәт өстенә нигә җәрәхәт өстәргә?

* * *

Икенче көнне Сабираттәйне алып кайтып җирләдек. Балаларын әлегә ерак әбиләре алып торды. Өченче көнне, таң белән, Сарсаз глубинкасына элеккедән дә ишлерәк булып, озын кәрванга тезелеп юлга чыктык. Ара якын булгач, малай-шалай да безгә иярде. Дамир өйдә калды, аның атларына да солыдан әз-мәз өлеш чыгардылар. Дамир, атларының ашарына салгач, безне озатып калды.

Әдилә белән без иң актыккы кешеләр булып барабыз. Көн матур. Чалт аяз. Кар өстенә карасаң, күз чагыла. Авылны чыккач та, зират тавы аермачык күренеп тора. Зиратта яңа кабер. Кызыл балчыктан өелгән бәләкәй генә таучык ак карда уйнаган кызыл төлке кебек кенә күренә...

*Май — июнь, 1972 ел,*
*Казан — Займище*

# Эчтәлек

Балта явызлар кулында. *Ф.Миңнуллин* . . . . . . . . . . . . . . . 7

**Хикәяләр**

Үги ана яфраклары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 11
Тәрәзәләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 31
Өч тәгәрмәчле арба . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 48
Уналты яшь . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 71

**Повестьлар**

Качак . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 96
Дүртәү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 146
Өч аршын җир . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 190
Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят . . . . . . . . . . . . . . . 256
Язгы кәрваннар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 377

Литературно-художественное издание

*Гилязов Аяз Мирсаидович*

## *Избранные произведения*

в пяти томах

**Том 1**

(*на татарском языке*)

Мөхәррире *Р.Х.Корбанов*
Рәссамы *В.Е.Булатов*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *Н.Н.Мусина*
Корректоры *Р.В.Сабирҗанов*

Оригинал макеттан басарга кул куелды 23.11.2002.
Форматы 84×108 1/32. Офсет кәгазе. «Школьная» гарнитурасы.
Офсет басма. Шартлы-басма табагы 22,68+ф.0,21.
Шартлы буяу-оттиск 23,0. Нәшер-хисап табагы 23,58+ф.0,36.
Тиражы 3000 д. Заказ Б–374.

Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул.Баумана, 19.

**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

«Идел-Пресс» нәшрият-полиграфия комплексы дәүләт унитар предприятиесе.
420066. Казан, Декабристлар ур., 2.